# Казан утлары

8.1995






**Казан. 1990 ел. Август көннәре.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**8**

**(874)**

**1995**

КАЗАН

## *Бу санда*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ СУВЕРЕНИТЕТЫ ТУРЫНДА ДЕКЛАРАЦИЯ КАБУЛ ИТЕЛҮГӘ — 5 ЕЛ

Биш еллык гомердә. *(Татарстан Республикасының Премьер-министры Ф. Х. Мөхәммәтшин белән әңгәмә)* ..... 3

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

З. ФӘЙЗИ. Сазлыкка ауган чәчәк. *Повесть* ..... 8
К. БУЛАТОВА. Бу языклы дөньяда. *Шигырьләр* ..... 44
И. СИРМАТОВ. Керәшен кызы. *Моңсу повесть* ..... 48
Г. САДӘ. Ак бүре. *Шигырьләр* ..... 72
Т. ГАЛИУЛЛИН. Сәмруг кош. *Хикәя* ..... 78
И. ӘХСӘНОВ. Баш иям — иләргә. *Шигырьләр* ..... 92

ДРАМАТУРГИЯ

Р. МИНГАЛИМ, Р. ХӘМИД. Идегәй *(Нәфис фильм өчен драма)* ..... 96

САЛИХ БАТТАЛНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

С. БАТТАЛ. Төрле еллардан. *Шигырьләр* ..... 130

ТУФАН МИҢНУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

Кама җилләре чыныктырган егет ..... 135
Т. МИҢНУЛЛИН. «Кызыл тышлы дәфтәр»дән 144

АБАЙНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

АБАЙ. Дөнья — салкын... *Шигырьләр* .....

САФА САБИРОВКА 80 ЯШЬ

Р. НИЗАМИЕВ. Ул һаман фарватерда ..... 161
С. САБИРОВ. Бишбалта мөгаллиме ..... 162

АТИЛЛА РАСИХКА 80 ЯШЬ

Р. ЗАРИФ. Хакыйкатьне юлдаш итеп ..... 169

ӘДӘБИ МИРАС

М. ГАЙНЕТДИН. Вакыйф Җәлалның гает шигырьләре ..... 175

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Р. ӘХМӘТҖАН. Тукай әкиятләрендә күчмә сюжетлар ..... 180

Котлыйбыз ..... 187
Укучы сүзе ..... 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 191

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Ростәм Мингалимов**
**Минтаһир Миңһаҗев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Б е з н е ң  а д р е с: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Т е л е ф о н н а р:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Беседа с Премьер-министром Республики Татарстан Ф. Х. МУХАМЕТШИНЫМ.
«Проза и поэзия»: повести З. ФАЙЗИ «Цветок упавший в болото», И. СИРМАТОВА «Безответная любовь», рассказ Т. ГАЛИУЛЛИНА; стихи К. БУЛАТОВОЙ, Г. САДЭ, И. АХСАНОВА.
«Драматургия»: драма Р. МИНГАЛИМА и Р. ХАМИД «Идегей».
«К 90-летию Салиха Баттала»: стихи С. БАТТАЛА.
«К 60-летию Туфана Миннуллина»: выступления друзей, коллег; рассказы-миниатюры Т. МИННУЛЛИНА.
«К 150-летию Абая»: стихи АБАЯ.
«К 80-летию С. Сабирова» статья С. САБИРОВА «Учитель Слободы».
«К 80-летию А. Расиха» статья Р. ЗАРИФ посвящена творчеству А. Расиха.
«Литературное наследие»: статья М. ГАЙНЕТДИНОВА «Стихи Вакифа Заляла».
«К истории литературы»: статья Р. АХМЕТЗЯНОВА «Сюжеты сказок Г. Тукая».
В номере отмечаются 60-летия М. Маликовой и Н. Лаисова.
На наших обложках: шамаил Р. Мухаметзянова; известный поэт и общественный деятель, главный редактор журнала «Казан утлары» Р. Файзуллин. Озеро Лебяжье, 1995 год.

## In our issue

The conversation with the Prime Minister of Tatarstan Republic F. Kh. Mukhametshin.
«Prose and Poetry»: Z. Phaizi's novel «The Flower Fallen in the Bog», I. Sirmatov's novel «Unrequited Love»; T. Galiullin's story, the verses of K. Bulatova, G. Sada, I. Akhsanova.
«The Drama»: the drama of R. Mingalim and R. Khamid «Idegei».
«To the 90th Anniversary of Salikh Battal»: S. Battal's verses.
«To the 60th Anniversary of Tuphan Minnullin»: congratulation of friends and colleaques: T. Minnullin's stories.
«To the 150th Anniversary of Abai» Abai's verses.
«To the 80th Anniversary of S. Sabirov»: S. Sabirov»'s article «The Teacher of Sloboda».
«To the 80 th Anniversary of A. Rasikh»: R. Zariph's article devoted to the creative work of A. Rasikh.
«Literary Heritage»: M. Gainetdinov's article «The Verses of Vakiph Zalyal».
«To the History of Literatyre»: R. Ahmetzyanov's article «The Topics of G. Tukai's Tales».
The 60th Anniversary of M. Malikova and N. Laisov are also marked in this issue.
In our corvers: R. Mukhametzyanov's shamail; the well-known poet and public figure, the editor-in-chief of the magazin «Kazan Lights» R. Phaizullin. Lebyashie lake, 1995.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Марсель Гали, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 6.07.95 ел. Басарга кул куелды 10.08.95 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 ¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 7821. Заказ Д-363.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1995 ел.

*Татарстан Республикасының Дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителүгә — 5 ел*

# БИШ ЕЛЛЫК ГОМЕРДӘ



**Татарстанның Премьер-министры ФӘРИД ХӘЙРУЛЛОВИЧ МӨХӘММӘТШИН белән «Казан утлары» журналының публицистика бүлеге редакторы, язучы Марсель Галиев әңгәмәсе.**

**— Татарстанның Дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул ителгәнгә быелның август аенда биш ел тулды. Шушы еллар эчендә республика икътисади, сәяси, мәдәни яктан нинди уңышларга иреште, дип уйлыйсыз?**

— Икеләнмичә әйтә алам: биш ел элек татар халкының дәүләтчелегендә яңа эпохага нигез салынды. Әлеге биш ел эчендә күп нәрсәләр эшләнде. Республика тарихына, вакыйга булып, референдум кереп калды. Халкыбыз суверенитет өчен «әйе» дип каттый сүзен әйтте. Суверен Татарстанның Конституциясе кабул ителде. Шактый четерекле каршылыкларны үтеп, Татарстан белән Россия арасында килешү төзелде. Республикабыз ышанычлы адымнар белән бүгенге көндә дөнья аренасына чыкты, төрле дәүләтләр белән һәръяклы элемтәләр урнаштыру гамәлгә кереп бара. Милләтара һәм территориаль конфликтларны тыныч юл белән чишү алымын өлге итеп «Татарстан моделе» дигән термин бөтен дөньяга таралды.

Бу — Татар халкының милли аңы үсешенә көчле этәргеч бирде. Туган телнең яңадан терелүе, милли мәдәниятнең үзгә бер сыйфатта күтәрелеп алуы — күз алдыбызда. Шушы дулкынны сүндермәү, ирешелгәннәрне ныгыту — безнең уртак максатыбыз. Әлбәттә, конституциядә билгеләнгән татар һәм рус телләренең тигез хокуклылыгын гамәлгә ашыру өчен бик күп эшләргә кирәк әле. Бусы инде директив алымнар белән генә хәл итеп булмый торган катлаулы, четрекле мәсьәлә.

**— Россия белән мөнәсәбәттә, Декларация кабул итмәгән республика һәм регионнар белән чагыштырганда безнең нинди өстенлекләребез бар?**

— Беләсезме, суверенитет игълан итү, факт буларак, эмоциягә күбрәк карый, гамәли тормышта әллә ни өстенлекләр бирми. Әгәренки ул Россия һәм дөнья илләре тарафыннан танылмаса, шактый күңелсезлекләр дә китереп чыгарырга мөмкин. Кайбер республикалар белән шулай булды да.

Безгә Декларациягә кергән төп маддәләрне Конституция белән беркетеп кую өчен тагын ике ел кирәк булды. Бөтенләй безнең позицияне кабул итмәгән Россия житәкчелеген үзара аңлашыр дәрәжәгә китерү өчен күпме түземлелек һәм үҗәтлек сорала иде һәм без моңа, энә белән кое казыган кебек, әкренләп ирештек. Дөнья сәясәтчеләре арасында абруй казанган Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең ихтыяр көче бу очракта зур роль уйнады. 1994 елның 15 февралендә Россия һәм Татарстан арасында тарихи Договорга кул куелганнан соң гына һәм ул дәүләтара килешүләр блогы белән сипләнгәннән соң гына безнең Декларация гамәли тормышка аяк басты.

Без нинди өстенлекләргә ирештек соң әле, дигән табигый сорау туа. Төп уңышыбыз шул — Татарстан халкы хәзерге көндә үз тормыш-көнкүреше мәсьәләләрен үзе хәл итә. Әйтик, Россия законнарының кайбер маддәләре ошамый икән, без үзебезнекен кабул итәбез. Без тышкы икътисади бәйләнешләрне үстерүдә мөстәкыйльлеккә ирештек. Салым-налоглар элек тулысынча Мәскәүгә җибәрелеп, яңадан андагы чиновниклардан ялынып-ялварып сорарга туры килә иде, хәзер бу салымнарның шактый өлеше республикада кала.

**— Россия дәүләте җитәкчеләренең дипломатик мөнәсәбәтләрдә көч-янау кулланулары тарихта мәгълүм. Әйтик, Бөек Ватан сугышы алдыннан (В. Молотов моны ачыктан-ачык әйтеп калдырган) Балтыйк буе республикасы җитәкчеләрен Мәскәү Кремленә чакыртып «эшкәртәләр». Нәтиҗәдә, әлеге илләр «үз теләге белән» СССРга кушыла. Бүгенге көндә дә, Мәскәү югарылыгында сөйләшүләр вакытында, тупас рәвештә басым ясаулар булгалыймы?**

— Үз чорында мондый этапны барыбыз да үттек. Яхшы хәтерлисездер: Россиянең матбугат органнарында безнең суверенитетка каршы нинди көчле шаукым-кампания барды. Хәзер инде заман үзгәрде. Республиканың җитәкчеләре белән Россия коллегалары арасында төпле, эшлекле мөнәсәбәтләр урнашты, дип ачыктан-ачык әйтә алам. Күп мәсьәләләрдә без уртак фикергә килә алабыз. Әмма... сәясәт ул барыбер сәясәт инде — анда көтелмәгәнлекләр дә килеп чыга. Киләчәктә, бәлки, лаеклы ялга чыккач, истәлекләр язармын, ул чакта инде күп кенә кызыклы хәлләрне сөйләргә булыр...

**— Татарстанның, кайчан да булса, чын мәгънәсендә мөстәкыйль дәүләт булачагына ышанасызмы?**

— «Тулы мөстәкыйльлек» — бу инде реаль тормышта булмый торган абстракт категория. Хәер, моны тормышта бернәрсәгә дә җавап бирмәүче философлар хөкеменә калдырыйк. Миңа Президент һәм республиканың парламенты тарафыннан бүгенге постымда бик зур җаваплылык йөкләнгән, моңа инде, әлбәттә, туган Татарстанның әйбәт һәм тыныч шартларда яшәргә тиешлеге дә керә.

Бу дөньяда барыбыз да бер-беребезгә бәйле. Россия картасы янына килеп карагыз әле, Татарстанның урыны кайда, аның җирләрен нинди елгалар сугара, нинди стратегик магистральләр кисеп үтә... образлы итеп әйткәндә, Мәскәү — Россиянең йөрәге булса, Татарстан исә — аның иң нәзберек җире... Сез мине дөрес аңларсыз дип ышанам.

Мин, реаль сәясәтче буларак, Татарстанның бәйсезлеген болай дип аңлыйм: ул — бай, югары технологиягә ирешкән, фәне, мәдәнияте нык үскән, дөнья илләре каршында шөһрәтле, иң мөһиме — үз гражданнарының хөрмәтен казанган республика булырга тиеш. Моңа ирешү өчен безгә ай-һай күп эшләргә кирәк әле. Шушы уңайдан АКШның беренче президенты Авраам Линкольнның сүзләрен китерсәм, урынлы булыр сыман. Ул болай дигән: «Илнең бөеклеге аның гап-гади кешеләренең яшәү дәрәҗәсе белән үлчәнә».

**— Үз мөстәкыйльлегенә омтылган Чечнядагы фаҗигане дөнья илләре аңлап та бетерми кебек. Картадан зурайткыч пыяла аша гына күренерлек ил-җиргә Россиянең коралы армадасы басып кереп, анда корал сынау, хәрби күнегүләр тулы бер халыкны кыру юлы белән эшләнә. Бу варварлыкка Казагыстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан кебек мөселман илләренең битараф калуын ничек бәялисез?**

— Менә сезгә тулы бәйсезлек хакында тере мисал. Чечня — уртак ярабыз, Россиянең хурлыгы. Дөнья җәмәгатьчелеге бу бәләкәй генә илдә барган золымга үз хөкемен чыгарды. Безнең республика да — Президент, парламент, киң җәмәга-

тьчелек бу мәсьәләдә кискен сүзен әйтте. Шулай ук без чечен халкына гуманитар ярдәм кулын да суздык.

Дипломатик якны күздә тотып, мин аерым бер дәүләтләрнең позициясенә бәя бирергә ашыкмыйм. Бу — аларның үз эше. Шунысын да искәртим, мин илләрне дини мәнфәгатьтән чыгып аерып карау яклы түгел, бигрәк тә сүз гомумкешелек әхлагы, кеше гомере хакында барганда.

**— Без, татарлар, океан уртасында бүленеп калган утраулар хәлендәбез. Республика читендә калган миллионлаган милләттәшләребезгә һәрьяклы ярдәм йөзеннән шул регионнар белән килешүләр төзү ничегрәк куелган?**

— 1992 елда үткәрелгән Бөтендөнья татар конгрессы бу проблеманы чишү мәсьәләләрен югары кимәлгә куйды. Анда оештырылган Комитет Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез белән элемтәләрне жайлау буенча мөһим эш башкара. Татар җәмгыятьләренең тәкъдим-үтенечләрен республика житәкчелеге игътибарсыз калдырмый. Дөресен әйтим, һәрчак ярдәм итә дә алмыйбыз, бигрәк тә зур финанс чыгымнары соралганда.

Монда бер юл бар: үз гражданнары — татарларның милли мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү өчен бюджет чыгымнарын бүлеп бирүне урындагы хакимиятләрдән һәм Россия житәкчелегеннән таләп итү. Соңгы елларда бу юнәлештә аз эшләнмәде. Россия федерациясенең субъектлары белән төзелгән килешүләрдә бу хакта аерым матдә бар. Әлеге проблеманы аңлап кабул итүче коллегаларга мисал итеп Мәскәү администрация башлыгын, Омск, Астрахань өлкәсе, Башкортостан һәм башка республика житәкчеләрен китерергә була. Ләкин барыбер илдә сан ягыннан икенче урында торган милләт өчен Россия хөкүмәте дәрәҗәсендә эшләнәсе күп эшләр алда әле. Без милләт эшләре Министрлыгын һәм Россия федерациясенең региональ сәясәтен тәнкыйтьләп торабыз. Әгәр милләтләр проблемасы төптән уйлап хәл ителсә, конфликтлар да кабынмас иде, канлы учакларны сүндерүгә дә көч китмәс иде.

**— Мәскәү вакытлы кумирларның һәйкәлләрен кубарып ату, тарихи шәхесләргә яңа һәйкәлләр ачу, храмнар төзү буенча нык эш алып бара. Рус халкының рухын торгызу буенча һәрьяклы сәясәт үткәрелә. Ә бездә... Митингларда кычкыру, матбугатта чаң сугудан узып берни кыра алганыбыз юк. Инде зуррак проблемаларны санамастан, хәтта урам, колхоз исемнәре дә үзгәртелмәде бит, һаман шулай, халыкны канга батырган кешеләрнең исемнәре аталып йөртелә. Казан Кремлен реставрацияләүдә Мәскәү дә ярдәм кулын сузмакчы. Димәк, монда татар архитектурасына караган истәлекле урыннарны торгызу булмаячак?**

— Сез үзегез үк җавап бирдегез, әйе, колхоз һәм урам исемнәрен алыштыру зур мәсьәлә түгел. Колхозлар — совет хакимиятенең җимеше, исемнәре дә шуңа тәңгәл килә. Исем үзгәртүгә карап кына асылы үзгәрмәячәк бит. Авылны үзгәртеп корсак, яңа исемнәр дә пәйда булыр. Урам исемнәренә килгәндә, ошыймы алар безгә, юкмы — алар берничә буын кешеләрнең тарихын чагылдыра түгелме! Мәскәү тәҗрибәсе шуны күрсәтә: урам, мәйдан, метро тукталышы атамаларын дәррәү үзгәртеп ташлауны мәскәүлеләр бик жиңел кабул итмәделәр. Мин инде моңа киткән чыгымнарны, адрес бутауларны әйтеп тә тормыйм.

**— Әйтик, Казанның Ленин урамына элекке чиркәү исеме — Воскресенская исемен кайтарсак, ничегрәк кабул итәр идегез?**

— Татар архитектурасы мәсьәләсендә сезнең пессимистик караш белән бер дә килешмим. Кремльне реконструкцияләү программасында Казан ханлыгы дәверенә караган археологик казылмалар алып бару күздә тотыла. Нәрсә табыла, барысы да саклаearnачак һәм халыкка күрсәтеләчәк. Казанны яклаганда һәлак булучыларга истәлекле таш кую да гадел булыр. Моңа инде беренче адым ясалды да. Мөселманнарга Иске Таш мәчете кайтарып бирелде. Риваятьләр 1552 елда һәлак булган татар яугирләре нәкъ менә шул урында күмелгән диләр.

Мәчетләр хакында искә төшергәч шуны да әйтим, татар архитектурасына караган һәйкәлләрдән — Җәмигъ һәм Солтан мәчетләре яңартып корылды. Соңгы елларда гына республикада йөзләп мәчет төзелде. Болардан кала тагын Казанда Иске татар бистәсен яңарту, Болгарда һәм Биләрдә татарның изге корылмалары хәрабәләрен саклау һәм торгызу эше бара. Карагыз сез, хәтта замана бинасын — Казан консерваториясе дә Шәрекъ стилендә яңартып корылды! Ышанасы килә, безнең башкалабыз Шәрекъ һәм Гарәпнең гүзәл төсләрендә балкып торачак әле.

**— Борын-борыннан патшалар, ханнар, корольләр язучы-әдипләр белән киңәшеп яшәүне хуп күргәннәр. Чөнки дәвернe кеше йөрәгенә якын тел белән**

**язучылар теркәп калдыра. Бу җәһәттән Сез дә, Фәрид Хәйруллович, Президентыбыз Минтимер Шәймиев тә әдәбият-сәнгать кешеләрен санга суга беләсез. Ләкин... вәгъдәләр сүздә генә кала бирә. Китап нәшриятының хәле авыр. Газета-журналларның тиражы коточкыч кимүгә таба бара. Гонорарларны арттыру турындагы указ финанс белән ныгытылмаган. Дәүләт җитәкчеләренең нәкъ менә беренче таянычы булган язучы-журналистларга түләү бик түбән дәрәҗәдә. Күрше Башкортостан белән һәрчак чагыштыруыбыз юкка түгел. Аларның язучылары элек тә бездәгедән әйбәтрәк яши иде, хәзер дә шулай. Һәм алар үз җитәкчеләренә һәрчак рәхмәтле булдылар.**

— Килешәм, күпләр тарихны әдәби әсәрләр аша укып белә. Әмма тарихи темага язылган бөек әсәрләрне гадәттә монархлар ышыгында торучы әдипләр түгел, ә шул эпохадан соңрак яшәгән каләм ияләре яза.

Сез җитди проблема кузгаттыгыз. Әйе, талантлы язучы әдәби хезмәте белән тамак туйдыра алмый икән, бу инде хәвеф уята. Җәмгыять бер читтән икенче читкә ташланды: элек урта кул китаплар бихисап санда дәүләт хисабына басыла иде, бүгенге көндә исә чын талант ияләре дә матбугатта күренә алмый. Китап киштәләрен көнбатышның болганчык әдәбияты басты...

Экономика җитди кризис кичергәндә, башка тармаклар кебек үк, китап басу, полиграфия эше дә авыр хәлгә тарыды. Дәүләт ярдәменнән башка алар аякка баса алмаячак. Мәгариф, фән, медицина өлкәсен әйтеп тә тормыйм... Бүгенге көндә нәшриятлар, күп кенә газета һәм журналлар дәүләт дотациясендә тора. Әмма республика бюджеты чикләнгән.

Бу чорда без якын арада көчәеп, республика казнасына салым-мая кертә алырдай тармакларга беренче чиратта ярдәм итәргә тиеш. Быелгы ел республика экономикасында борылыш елы булыр дигән өметтә торабыз. Халык хуҗалыгында эшләр җайга салынуга, китап басу эше дә алга китәчәк. Кешеләр китапларны да сатып алачак, газета-журналларга да күпләп язылачак. Реклама тотучы байлар, спонсорлар күбәер — менә шул чакта инде сезнең коллегаларның эшләре гөрләп китәчәк. Ул чакта, бай илләрдәге кебек, талантлы әдипләр, журналистлар дәүләттән бәйсез булачаклар. Шуңа омтылыйк.

**— Икътисад турында кузгаткачбыз икән, республиканың эре промышленность потенциалы (зур заводлар күздә тотыла) ни хәлдә? Аларның якын елларда алга китү мөмкинлеге ничек?**

— Ниһаять, промышленностьта гомуми күләмнең түбән төшүен туктатуга ирештек. Нефть чыгару арта бара, шин, полиэтилен, каучук һәм башка товарлар эшләү дә ныклы юлга салынды. 1993 елгы янгын афәтеннән соң «КамАЗ» да аякка басып килә. Кызганыч, быел кинофотопленка, магнитлы тасмалар, полимер пленкалар, электр машиналары эшләү, электр энергиясе бирү кимеде.

Күп кенә предприятиеләр базар экономикасына ярашып, конкуретлар белән ярышырлык продукция җитештерә башладылар. Боларга мин, тәүге чиратта, Түбән Каманың «Нефтехим», шин һәм Казанның «Оргсинтез» акционерлык җәмгыятьләрен кертер идем.

Ләкин машина төзелеше предприятиеләрендә хәл кыенлашты. Бу өлкәгә бит бөтен промышленностька караган эшчеләр санының яртысыннан күбрәге керә. Хәзерге көндә исә боларның промышленность җитештерүе биштән бер өлешне генә тәшкил итә. Хәрби заказлар кимү сәбәпле оборона предприятиеләре бигрәк тә авыр хәлдә калды. Күз алдына китерегез, элек Казан промышленносте эшләп чыгарганның 80 проценты оборона тармагына туры килә иде, хәзерге аяныч нәтиҗә йөз меңләгән казанлылар язмышына китереп сукты. Дәүләт казнасын кайчандыр баеткан, торак фондын, шифаханәләрне, мәдәният сарайларын, санаторий, пионер лагерьларын тоткан индустрия флагманнары бүген инде үзләре ярдәмгә мохтаҗ. Әгәр ситуацияне кулдан ычкындырсак, республика башкаласында социаль тетрәнүләр кузгалырга мөмкин. Без Россия хөкүмәте белән берлектә бу өлкәдә җитди эшләр алып барабыз.

Кичектергесез максатыбыз — экономиканы тотрыклы хәлгә китерү, бу инде җәмгыять тормышындагы бөтен тармакларны да җайга салу дигән сүз. Татарстан икътисадны кризистан чыгаруның үз алымнарын эшли. Бу проектны гамәлгә ашыруда чит ил инвестициясе дә ярдәм итәргә тиеш. Һәртөрле катлаулылыклар, проблемалар гадәттән тыш күп. Татарстан бу авыр полосадан башка регионнарга һәм гомумән Россия Федерациясенә караганда алданрак чыгачак. Мин моңа ышанам.

**— Чит ил белгечләре, эшкуарлары революциядән соң (1917) Россиягә капитал кертеп карадылар. Соңыннан аларны большевиклар талап, пыр туздырып бетер-**

**деләр. Бу сабакны алар мәңге оныта алмый күрәсең. Бүгенге көндә дә сак кына эш итүләре шуны күрсәтә. Ә безнең республика белән җитди эшкә тотынырлык килешүләр төзергә теләк белдерүчеләр бармы?**

— Бүгенге көндә Россиядәге тотрыксызлык күп кенә чит ил инвесторларын куркыта. Бу хәл безнең республикага да карый. Моның өстенә, Татарстан — милләтара конфликтлар учагы дигән стереотип Көнбатыш илләрендә әле дә яшәп килә. Татарстанның сәяси яктан төпле регион икәнлеген безнең яшь дипломатия бөтен дөньяга таныта бара. Зур-зур чит ил фирмаларыннан «разведкага» көн аралаш килеп торалар. Иң беренче аларны нәрсә кызыксындыра? Республикада татарлар белән руслар арасындагы, Татарстан белән Россия арасындагы мөнәсәбәт. Республиканың тыныч көнкүрешенә бернинди куркыныч янамавына инангач кына бизнесменнар сөйләшүгә баралар.

Хәзерге чорда республикада чит ил капиталы кергән уннарча предприятиеләр уңышлы гына эшли башлады. Бәйсез экспертлар бәяләвенчә, Татарстан, инвестиция уңайлыгы ягыннан, Россия регионнары арасында беренче бишлеккә керә. Чит ил фирмалары катнашында гамәлгә ашырылачак проектларның кайберләрен — зурдан зурларын гына мисалга китерәм: «ЕлАЗ»ны төзеп бетерү; Ауропада иң зур саналган химик һәм нефтехимик предприятиеләрне яңартып кору («Нижнекамскнефтехим», «Оргсинтез» Яңа Менделеевск химзаводы); «КамАЗ»ны торгызу һәм яңа технологиягә көйләү; Казан аэропортын яңарту.

**— Фәрид Хәйруллович, Сез «Премьер-министр көндәлеге» дигән китап язарга уйламыйсызмы?**

— Төп эшләр турында көндәлек матбугатта чыга тора инде. Вакыйгаларга шәхси бәя, хис-тойгыларга килсәк, миңа да ахры, күп кенә дәүләт эшлеклеләре кебек үк, пенсиягә чыккач, каләм алырга туры килер... Әлбәттә, сау-сәламәт булсак. Бүгенге катлаулы, кызыклы борылышлар чоры мемуарлар өчен бай азык бирәчәк. Язучылар да читтә калмас, дәверебез турындагы дөреслекне килер буыннарга юлларлар дип уйлыйм.

**— Әңгәмәгез өчен рәхмәт. Эшегездә, тормышыгызда һәммә уңышлар сезгә.**



Заһид
Фәйзи



# САЗЛЫККА АУГАН ЧӘЧӘК

ПОВЕСТЬ

1

Машинадан төшүгә, артыннан ишеген ябып та тормастан, Венера подъездга юнәлде.

Аның беркайчан да мондый күңелсез кыяфәттә кайтканы юк иде әле. Авыру кешенеке кебек йөзләре агарып, канаты каерылган кош сыман, сүрелеп калган. Ул, күзенә берни күренмәгәндәй, ишек төбендә сөйләшеп торган карчыклар белән дә исәнләшеп тормастан, өйгә кереп китте. Бүген аңа киң басмалы иркен баскыч та тар һәм караңгы кебек иде.

Өченче катка күтәрелеп коридорга керүгә, артыннан күзчекле тимер ишекне шалт итеп бикләп тә куйды. Ә үз фатирының ишеге ике катлы итеп эшләнеп, тышкысына өч йозак куелган иде. «Төрмә түгелмени бу?!» — дип, ачынып алды ул, бөҗрадагы ачкычларны аралап. Рухына, җанына кысан булганга, тизрәк тынычлап, иркен сулап җибәрәсе килә иде аның. «Их, шушындый чакта эч бушатып сөйләшерлек кешем дә юк бит, ичмасам!» — диде ул, ишекне ачып керүгә плащын салып ташлап.

Венераның башында, чуалган җепләр кебек буталып, берсеннән-берсе катлаулырак уйлар кайнаша иде бу минутларда. Аның, шуларны тизрәк аралап һәм очына чыгып, тәгаен бер карарда ниндидер бер эш кыласы килә. Ләкин, каядыр куйган үтә кирәкле әйберен таба алмый интеккәндәй, нишләргә дә белмичә газап чигә. Ул, аптырагач, әле бер, әле икенче бүлмәгә кереп, йөренергә тотынды. Азрак кына салып кайткан булуга карамастан, үзендә исереклекнең әсәре дә юк. Юынып чыксам, нервыларым тынычланып, уйларым ачылып китмәсме дип, ванна бүлмәсенә кереп суны таманлап агызып җибәргәннән соң, диванга ятып бераз хәл алырга теләгән иде. Алай да булмагач, торып, йөренүен дәвам итте.

Тынлык: чурлап су акканы гына ишетелә...

Ванна тулгач, Венера башта озак кына җылы суда утырды. Аннары ак күбеккә батып юынып-коенып алганнан соң, ашыкмый гына тәннәрен корытты да, аягына чүәкләрен генә элләктереп, олы якка чыгып, көзге каршына басты.

Кырык өч яшьлек хатын. Ул әле бер, әле икенче ягына әйләнеп, көзгедәге шәүләсенә карый. Аның үзенең ялангач кыяфәтенә болай игътибар иткәне юкка хәтсездән инде. Бер генә бала тудыргангамы, имиләре дә, буй-сыны да кыз вакытындагы кебек җыйнак, матур иде әле. Тик хәзер Венерада ул чактагы нәфислек, нәзакәт юк. Ничектер тәненә ягымлылык бирә торган уты кимегән кебек. Озын толымнарын кистереп кызгылт-сарыга буяту аны шулай күрсәтәдер, бәлки. Элекке үзенә җәлеп итә торган көләмсәр серле карашында, үтәли күрергә теләгән кебек, үткенлек һәм кырыслык сизелеп тора хәзер.

Ул өстенә ефәк якалы, затлы халатын гына бөркәнде. Зиннәтле импорт гарнитур һәм келәмнәр белән җиһазландырылган биек түшәмле иркен бүлмәдә укалы чүәкләр киеп басып торган Венера, әйтерсең, ханбикә! Тик борчулы карашы белән агарып киткән йөзе генә горурлыгын югалткан сыман. Ул кофе кайнатып эчеп алды да йөренүен дәвам итте. Офыкка төшеп килгән алсу кояш нурлары бүлмәгә сихри төс керткән иде. Уйларының очына чыга алмый газапланган Венера комодтан коньяк чыгарып фужерга гына салды да бер сулышта йотып җибәрде. Сындырып шоколад капмакчы иде, кабып торырлык нәрсәме бу дигәндәй, аны кире өстәлгә ташлады. Үзен явызларча кысучы мәкерле кешегә бирешмәслек чара таба алмаудан җаны өзгәләнә иде аның!..

Бераздан, исерткеч үзенекен итеп, Венераның йөзенә төс кереп киткәндәй булды. «Ник? Ничек бу хәлгә төштем мин?» — дип, үзенә-үзе сорау бирде ул. Һәм шунда, җанлы картиналар сыман, үткәннәре күз алдына килеп баса башлады.

* * *

Аның күңелендә онытылмаслык хатирәләр калдырганы үсмер чагы — кыз булып өлгереп килгән еллары иде.

Сигезенче класста укыганда гашыйк булды. Күңелендә мәхәббәт уты кабызучы — унберенче сыйныф укучысы Мансур иде. Ул, мәктәпнең иң абруйлы отличнигы булуга карамастан, һәрвакыт гади, үзен башкалардан беркайчан да югары куймый торган егет. Классташларына да, түбән сыйныфта укучыларга да, теләсә кайчан вакыт һәм җай табып булыша, ярдәм итә. Күзлектән йөргәнгә һәм галимнәр кебек күп белгәнгә күрә, аны, яратып, «профессор» дип йөртәләр иде хәтта. Шундый абруйлы булуга карамастан, Венерага әллә бар, әллә юк иде ул. Ә сигезенче классны тәмамлар алдыннан үзенә гашыйк булды да куйды!

Соңгы чирек җитеп, имтиханнар якынлашып килгән вакыт. Мәктәпне тәмамлаганнан соң медицина училищесына керергә хыялланып йөргән Венера үзен математикадан йомшаграк сизә иде. Беркөнне ул мәктәптән кайтып килгәндә, Мансурны туктатып:

— Миңа математикадан катлаулы мәсьәләләрне чишәргә, формулаларны ныграк үзләштерергә ярдәм итә алмассыңмы? — диде.

— Ярый, булышырмын, — диде Мансур, уйлап та тормыйча. Һәм шул көннән үк аңа ярдәм итә дә башлады.

Икәү дәресләр әзерләп утырганда, гади, ачык күңелле һәм кешелекле егет Мансур Венераның күңелен тартканнан-тарта бара иде. Моңарчы, гел уку һәм җәмәгать эшләре белән мәшгуль булып, кызлар турында уйлап та карамаган Мансур да күзгә күренеп үзгәреп китте. Аның иртән торуга тизрәк мәктәпкә барасы, Венераны күрәсе килә башлады.

Алар шулай, яктыга үрелгән чәчәкләр кебек, бер-берсенә көннән-көн ныграк тартыла бара иде.

Мансур, мәктәпне тәмамлаганнан соң, университетның радио-физика бүлегенә укырга керде.

Бер-берсен күрергә атлыгып торганга, алар каникуллар җиткәнне түземсезлек белән көтеп алалар иде.

Шулай ике ел үтеп, Венера да кулына өлгергәнлек аттестаты алды. Тик хыялы тормышка ашу насыйп булмаган икән. Ул медицина училищесына керергә документларын әзерләп йөргәндә генә шәһәрдән әнисенең сеңлесе Мәрьям кайтып төште дә, аның укырга кая керергә җыенганын белүгә, нотык укырга тотынды:

— Медсестра булып ни файда? Аларның өстендәге ак халаты гына бит. Ике-өч җирдә эшләп тә акчага тиенгәннәре юк. Бүгенге тормышта акчасыз кая барасың? Медсестра булу — бела торып үзеңне кысан тормышка дучар итү ул. Күрәсеңме сатучыларны: өсләренә карасаң, өс-башлары чәчәк кебек! Акча дисәң — акчага кинәнеп яшиләр! Бернигә карама, шәһәргә кил дә сату эшенә кер! Танышым Сабира аркылы кибеткә урнаштырам үзеңне.

— Минем укыйсым, шәфкать туташы буласым килә, апа,— диде Венера, карарыннан кайтасы килмичә.

— Укысаң, каршы килүче бармы әллә? Укы, тик сәүдә буенча кит.

— Сәүдә институты читтән торып укый торган гына бит. Анда сатуда эшләп стажы булган кешеләрне генә алалар,— дип, каршылык күрсәтте Венера.

— Син дә, бер ел эшлә дә, алдагы елны укырга керерсең. Әйтәм бит, медсестра булам дип алданып йөрмә — шул!

Ни дисәң дә, тормыш күргән өлкәннәр сүзе үтемлерәк бит. Әти-әнисе дә апасы киңәшен хуплагач, Венера, теләмәсә дә, карарыннан кайтырга мәҗбүр булды.

Хәзер ул үзен канаты каерылган кош сыман хис итә иде.

Авылда эшен бетереп шәһәргә килеп төшүгә, Мәрьям аны якын танышы Сабирага күрсәтте. Ә тегесе исә Венерага иртәгә үк эшләгән җиренә — кибеткә килергә кушты.

Венера Сабира белән танышканда ук укуын дәвам итәргә теләге барын әйткән иде.

— Борчылма. Кушканны-әйткәнне тыңлап кына эшләсәң, эшең дә барыр, укырсың да. Синең кебек кызларга рәхәтләнеп үсәргә була хәзер!..— дип аңлата башлады Сабира, Венера кибеткә килгәч.— Бездә эшләргә уңайлы. Ике кибеткә бер директор. Хуҗабыз Радик Хафизович белән минем уртак тел табылган. Аның утырып эшли торган җире икенче бинада. Монысында мин бүлек мөдире — үзем хуҗа дигәндәй. Әйткәнемчә, сүздән чыкмый гына эшләсәң, югалмассың.

Сабира Венераны, директорга алып барып күрсәтеп, ике көн эчендә кече сатучы итеп урнаштырды да.

Шәһәр читендәге бу кибеттә азык-төлек, яшелчә-җимеш һәм бөтен төрле эчемлек сатыла иде.

— Шушыннан башлап өйрәнсәң, сату эшенең серенә тизрәк төшенерсең. Үзеңнән бер дигән сәүдә кешесе чыгар,— дип, Сабира Венерага сөт бүлегендә каймактан бушаган фләгеләрне юарга, сатучы хатыннарның кул арасына кереп булышырга кушты.

Яшьтән эшләп үскән авыл кызы Венера кушканның бөтенесен җиренә җиткереп, ялт иттереп куя башлады.

Кибеттә шулай: унике сәгатьлек эш көне белән бер атна эшлиләр дә, бер атна ял итәләр. Вакыты-вакыты белән, сатучыларның, бер-берсен алыштырып, атнадан артык эшләгән чаклары да булгалый. Шундый көннәрнең берендә Венера сөт әйберләре складында әле чынлап танышырга өлгермәгән бер хатынга булышып, тырышып-тырышып каймактан бушаган фләгеләрне юып азаплана иде.

— Ник алай ук казынып маташасың?! Буялып-сыланып калган җире беттеме — җиткән! — диде Сабира, килеп керүгә.— Мең галәмгә ярамаган тагы!..

Венера эш атнасын тутырып ял итеп килгәннән соң, Сабира аны подвалга алып төшеп, үз кулы белән лимон һәм мандаринның эре, чиста һәм өлгергәннәрен генә алып күрсәтте дә:

— Шушындыйларын гына сайлап әрҗәләргә тутыр! — дип, менеп китте.

Венера, бар тырышлыгын куеп, башта әбәткә кадәр мандарин сайлады, аннан соң лимонга тотынды.

Подвалда тынчу, һава юк. Сәгатьләр буе баш күтәрмичә эшли торгач, билләре, иңсәләре авырта, сулышлары кысыла башлады. Бармак очлары суелып, эт тырнаклары чыкты. Сабира исә, әледән-әле төшеп, боларның берсен дә күрмәгәндәй, эшен карап, мактап киткән була.

«Һаман шулай барса, бу эш аяктан егачак», — дип уйлана башлады Венера.

Смена тәмамланыр алдыннан, Сабира подвалга директор белән төште.

— О-о, мин сине мондый уңган, мондый булган кыздыр дип башыма да китермәгән идем! Һичшиксез, эшләр уңга китәчәк болай булгач! — дип, Венераны мактап алды Хафизов, аңа тәмам соклану белдереп.

— Мин сиңа начар кызларны тәкъдим итәмме соң, Радик Хафизович! — дип, мактанып алган булды Сабира һәм, кинаяле итеп, өстәп куйды: — Алтын бәясендәге кыз бу, алтын бәясендәге кыз! Тик аңа, ярдәм итеп, үсәргә булышырга кирәк.

— Мондый кызларга ярдәм итмиләрме соң, Сабира Гаязовна! Кулымнан килгәннең бөтенесен эшләргә әзер!

Директор белән Сабира, Венераны шулай күңелле мактап, подвалдан менеп киттеләр.

Икенче көнне Венера эшкә килгәндә, кибетнең арт ягында, подвал ишеге төбендә ябулы зур машина тора иде. Кабина янына әрмәнгә охшаган куе кара мыеклы бер кеше баскан. Ул, Сабираны күргәч, аңа каршы килеп исәнләште дә, икәүләп, подвалга төшеп, нидер сөйләшеп менделәр. Һәм әлеге кеше шундук шофер белән йөкчене эшкә дә кушты. Кичә Венера сайлап әрҗәләргә тутырып куйган лимон белән әфлисунны берсе китереп подвал тәрәзәсеннән биреп тора. Икенчесе — алып, машинага ташый.

Венера монда махинация бар дип башына да китерми иде әле.

Әбәт җитәрәк, Сабира аны бүлмәсенә чакырып алып:

— Кичә тырышып эшләгәнең өчен, шефтан. Тыгып куй да авызыңа май кап! — дип, кулына акча тоттырды.

Әле болай беркайчан да акча алганы булмаган Венерага сәер иде бу, билгеле. «Мәктәптә укыганда, колхозда эшләгән өчен ала торган аз гына акчаны да исемлек буенча кул куйдырып бирәләр иде. Ә монда, әле атна гына эшләгән кешегә дә бернинди ведомостьсыз-нисез акча бирәләр. Кибеттә хезмәт хакын бирү тәртибе шулай түгелдер бит?» — дип, эчтән генә гаҗәпләнеп алды әле берни белештермәгән Венера. Бу нинди акча дип сорарга да, Сабирага рәхмәт әйтергә дә белмичә, чыгып китте.

Кибеттә шактый еллар эшләп шомарган Сабира шулай Венерага сату эшенең «серләрен» көннән-көн ныграк төшендерә бара иде.

— Үзеңне үлчәү-герләр белән ничек эш итәргә, сатып алучылар белән ничек исәп-хисап ясарга өйрәтәм дә сөт әйберләре бүлегендә үзең генә эшли башларсың. Сәүдәдә эшкә озак өйрәнеп тору юк, матурым. Шуңа күрә иртәгә эшкә бер сәгать алдан кил, — диде ул, кисәтеп.

Иртән килүгә, Сабира, арт ишектән генә Венераны сөт әйберләре складына алып керде дә:

— Монда салкынча, эшне тиз тотарга кирәк, — дип, стенаны каплап торган зур суыткычның ишекләрен ачып җибәрде.

Анда флэгеләр белән китерелгән каймак, шешәле кефир һәм катык иде.

— Ни кушасың, Сабира апа? — диде Венера, өстенә халат киеп алуга.

— Әнә буш флэгеләрне идән уртасына китереп куй да һәркайсына унар шешә катык, унар шешә кефир бушат!

Алар унлап фләгегә шулай кефир белән катык салып, аннары пломбалы фләгеләрне ачып, алардан каймак өстәп, тутырып чыктылар. Шунда эшнең кая барганын аңлап алган Венераның куркудан тәннәренә суык йөгергәндәй булып, калтыранып куйды.

— Боларны нишләтергә? — диде ул, беравык нишләргә белмичә аптырап торганнан соң, кефир-катыктан бушаган шешәләрне күрсәтеп.

— Су агызып ал да, чайкатып, әрҗәләргә тутыр.

Сабира шулай диде дә, почмактагы аралыктан озын саплы итеп ясалган агач калакны чыгарып, шуның белән кефир-катык кушкан каймакны бутарга тотынды.

— Моннан соң үзеңә генә шушылай кайнаштырырга туры килер. Иренмичә, төерләр калмаслык итеп бутарга кирәк,— дип, аңлатуын дәвам итте ул.

Венераның: «Кибетчеләр каймакка кефир-катык кушып сата»,— дигәнне ишеткәне бар иде. Әмма болай кушалар, бу кадәр күп кушалар дип күз алдына да китерми иде. «Сатучыларда оят белән кешелек дигән нәрсә бөтенләй юк микәнни?» — дип уйлана башлады ул.

Шушы минуттан алып, Сабираның бу эшенә канәгатьсезлек белдерергә уңайсызлану гына түгел, Венера аңардан курка да башлады хәтта.

Бушаган шешәләрне әрҗәләргә тутырып почмакка урнаштырганнан соң, алар фләгеләрнең берничәсен прилавка артына чыгарып куйдылар. Һәм кибетне ачып, кешеләр керә башлауга, Сабира:

— Әйдә, сата башла! — дип, прилавка белән склад арасында кайнашкан булып, Венераның эшен күзәтә башлады.

Болай ук тиз мөстәкыйль эшли башлармын дип уйламаган иде Венера. Шуңа күрә беренче минутларда алдында торган үлчәү-герләрне күрмәгәндәй каушап, югалып торды. Әгәр Сабира килеп:

— Кемгә нәрсә кирәк, җибәр, матурым! — дип айнытып китмәсә, ул шул хәлдә, бәлки, озаграк та торган булыр иде әле.

Ниһаять, ул сату итә. Кайсы сөт йә кефир ала, кайсы — эремчек. Данәләп сатыла торган әйберләр җибәрергә дә, исәп-хисап ясарга да җиңел.

Тик бу озакка бармады. Бер әби, банка сузып:

— Шушыңа каймак салып үлчә дә бер пачка эремчек бир, кызым,— дигәч, Венераның тәннәре эсселе-суыклы булып, куллары хәлсезләнеп китте. «Йа аллам, чынлап та хәрәм эш белән шөгыльләнүче булып китәрмен микәнни?» — дип, эчтән генә ачынып алды ул, катык-кефир кушкан каймакны салып.

Карчык алдына куйган банка белән эремчекне үзенәрәк тартып куюга, ябыгудан тиреләре юкарып, зәңгәр кан тамырлары менә-менә тишелеп чыгар кебек торган куллары белән кульяулык төенен чишеп:

— Мә, бар акчам шунда, үзең санап ал, кызым,— дип, Венера алдына куйды.

Әбинең картлык ялын кешечә тукланып уздырырлык та акчасы булмаганны да күргәч, Венераның йөрәген нидер көйдереп үтте, әйтерсең.

Аның кәефе киткәнне Сабира сизеп тә өлгергән иде. Ул:

— Кызурак җибәр, матурым, кешеләрне тотма! — дигән булып, Венераны ашыктырды.

Сизелә, бу аңа хәрәм эштән тартынып тормасын өчен әйтелде, билгеле. Ә Венерага болай да хисләргә бирелеп торырга форсат юк иде. Прилавка алдында чират — туктаусыз сатарга кирәк.

## 2

Венера кайтып керүгә, апасы Мәрьям:

— Нишләп болай төсең китте, авырыйсыңмы әллә? — дип сораша башлады.

— Юк, апа, авырмыйм...— диде Венера, чак кына елап җибәрмичә.— Кибеттә эшлисем килми.

— Нигә?! Ник алай дисең?— дип, ачыкларга тотынды Мәрьям.— Дустым диярлек танышым аркылы эшкә урнаштырдым үзеңне. Ни булды, берәр ярамас эш кылдыңмы әллә?

— Әйе, кылдым. Чөнки хәрәм эш бара анда. Ә минем кеше өлешенә керергә намусым җитми, кулым бармый, апа.— Венера кибеттәге хәлләр һәм сатып алучыларны ничек алдауларны сөйләп, сулкылдап еларга тотынды:— Бу эш ошамый миңа — китәм! Заводка йә фабрикага эшкә керәм.

— Әй, юләр, юләр! Бүтән җирдә андый хәл юк дип уйлыйсыңмы әллә?— дип битәрли башлады апасы.— Бөтен дөньясы шундый бит хәзер. Монда эшең чиста, җылыда, ичмасам. Барганда-кайтканда транспортта суккаланып йөрмисең. Юлың бары җиде-сигез минутлык кына. Азык-төлекне дә рәхәтләнеп үз кулың белән сайлап алып кайтып ашыйсың.

— Юк, гөнаһлы эштән куркам мин, апа, тартынам.

— Сөйләшмә! Тормышы шулай барганда, намус саклыйм дип, син генә фәрештә булмассың. Мондый керемле җиргә йә бик якын танышлар аркылы, йә башлыкларына акча төртеп кенә урнашалар әле, беләсең килсә. Шулай булгач, куанып эшләвеңне бел!

— Юк, апа, юк! Аңла, мин яраткан эш түгел бу,— диде Венера. Һәм моннан соң да Мәрьям үзенекен тәкърарлый биргәч, эченнән генә үземә кулайрак эш тапканчы гына эшләп торам да китәм дигән карарга килеп, сүзне бетерде.

Ул кабат бәхәсләшеп тормагач, Мәрьям дә:

— Эшлә әле, эшлә! Соңыннан ошап китеп, үзең үк уеңнан кайтачаксың, күрерсең,— дип, тынып калды.

...Венера китү турында беркемгә бер сүз ычкындырмыйча, эшләп йөри. Ә Сабира исә аны сату эшенә тартканнан-тарта бара иде. Ул кыска гына вакыт эчендә үзен үлчәү-хисапка өйрәтеп, ныклап эшләтә башлады. «Венера алтын куллы кыз булып чыкты — ут уйнатып эшли!» — дип, иптәшләре арасында мактап та ала. Хафизов та күргән саен: «Синнән бер дигән сәүдә хезмәткәре чыгачак! Мин сиңа укырга керергә дә, үсәргә дә ярдәм итәчәкмен, Венера»,— дип әйтеп тора, җитмәсә.

Әле чынлап дөнья күрергә өлгермәгән, кешеләргә ышана торган кыз, мондый сүзләрне ишетеп торганга күрә, китәргә дигән карарыннан кире кайтмаса да, акрын-акрын йомшый килеп, кибеттәге хәлләргә иялəшә-яраклаша бара иде. Тик директор гына, йә эше белән кызыксынган булып, йә юк кына йомыш кушкан булып үз янына чакырта да, мактап һәм әллә нинди серле сүзләр белән башын әйләндереп, күңеленә шик сала. Ул күзләрен мут мәченеке кебек майландырып, сөйләндергәндә, Венераның, уңайсызланудан, йөзләре кызарып чыга хәтта.

Башка сатучылар Хафизовның хатын-кызга карауга күңеле аның итәк астына йөгерә торган кәнтәй икәнен күптән беләләр иде. Араларында аның белән гөнаһланганнары да юк түгел. Сабира исә, директорның сөяркәсе булып йөреп, бүлек мөдире дәрәҗәсенә күтәрелде хәтта. Тик утыз сигез яшьлек директор хәзер, үзенең иң көчле һәм дәртле чагы икәнне белеп, күбрәк яшьләрне күзли башлады. Алай да дуслыклары нык — берсе өчен икенчесе үлеп тора.

Хуҗа кешенең Венераны эшкә алуга, аңа елыша башлаганын да хатыннар шундук сизеп өлгергән иде. Берәүләре: «Чибәркәйне нишләтеп туктар икән бу?» — дип, читтән генә күзәтеп йөрсә, икенчеләре, көнләшеп: «Чибәрлек, яшьлегең белән хуҗаның башын-күзен әйләндерден, кызый. Тирәндә ничек чуала, ә!» — дип, Венераның үзенә әйтергә дә өлгерделәр. Мондый сүзләрне дә ишеткәннән соң, Венераның директордан шикләнү-тартынуы тагын да көчәя төште. Ул ничек тә аның белән күзгә-күз очрашмаска, ялгыз чакта үзе белән туры килмәскә тырыша. Ә

Хафизов исә, киресенчә, ничек кенә булмасын, очрашу, икәүдән-икәү булу җаен туры китерергә йөри.

Сөт әйберләре сатылып беткәндә, смена тәмамланырга сәгатькә якын вакыт калган иде.

Венера сатудан кергән акчасын санап, хисапчыга тапшырып чыгуга, Сабира үзен чакырып алып:

— Бар, шушы накладнойларны директорга илтеп бир дә шуннан кире килеп йөрмәссең,— дип, кулына кәгазьләр тоттырды.

Хафизов карамагында кибетләр бер-берсеннән алты-җиде минут барырлык арада урнашкан иде.

Венера кызу-кызу атлап кибеткә килеп керде. Бу бина тегесенә караганда шактый искергән, караңгырак та. Хафизов кабинеты зур булмаган кетәк кебек кенә. Ул склад артындагы култыкка урнашкан иде. Аңа ишектән аз гына киңрәк аралыктан керергә кирәк. Түшәмендә менә-менә сүнәргә торган кебек кызарып кына кечкенә лампа яна. «Сабира апа, бүлек мөдире генә булса да, бүлмәсе иркен дә, яктырак та. Ни өчен Хафизов, директор була торып, шундый караңгы почмакта утыра икән?» — дип гаҗәпләнеп алды Венера.

Ул килеп кергәндә, директор сейфын ябып маташа иде. Күренә, таман гына салып алган.

— Әйдә, уз! — Ул, аягөсте басып, Венерага өстәле каршындагы йомшак кәнәфине күрсәтте.— Утыр, Венера!

— Рәхмәт, Радик Хафизович! Менә, Сабира апа җибәргән кәгазьләрне китердем,— диде Венера, накладнойларны директор алдына куеп.

— Рәхмәт. Әйдә, утыр әле, Венера, сөйләшик! Мин синең турыда күбрәк белергә тиеш.

Уңайсызланудан тизрәк чыгып китәсе килгән Венера ирексездән утырырга мәҗбүр булды.

— Беләм, син авыл кызы, тартынасың, шикләнәсең әле,— дип башлады Хафизов.— Ә бит хәзерге тормышта, бигрәк тә сәүдә эшендә, мондый сыйфат белән ерак барып булмый. Син гади сатучы гына булып калырга тиеш түгел, сиңа үсәргә кирәк. Алга таба укырга теләгең барын Сабира Гаязовна берничә тапкыр минем колакка төшерсә дә, үзеңнең бу турыда никтер бер сүз дә әйткәнең юк әле, ә зрә. Чөнки сәүдә институты шундый уку йорты, аңа яхшы аттестат белән дә, толкачың булмаса, узам димә.

Венера, аны тыңлыйсы килмичә:

— Әй, узмасам, укымый калырмын,— дигән иде, Хафизов тагын да үтемлерәк итеп сөйләргә тотынды:

— Ялгышма, чибәркәй. Сиңа укырга һәм бары тик сәүдә буенча үсәргә кирәк. Күренеп тора, синдә бу эшкә сәләт бар. Ә минем үз кадрларымны үстерәсем, аларга ярдәм итәсем килә. Синең шуннан файдаланып калырга теләмәвең гаҗәп.

Венера, моңа каршы ни әйтергә дә белмичә, дәшмәде.

Хафизов, ничек кенә булмасын, аның белән арасын якынлаштырырга тырыша иде. Венераның ничек тизрәк чыгып китәргә белми утырганын сизеп торса да, моны аз гына да абайламагандай, сүзен дәвам итте.

— Ярдәм кулы сузучы булганда, мөмкинлекне ычкындырмаска кирәк.— Хафизов өстәл тартмасыннан ике шакмак шоколад һәм коньяк чыгарып куйды да, ике рюмканы тутырып:

— Әйдә, синең киләчәк уңышлар өчен! — дип, рюмканың берсен Венерага сузды.

— Юк, юк, Радик Хафизович, рәхмәт! Минем эчкәнем дә юк, эчмим дә! — дип, уңайсызланудан йөзе кызарып чыккан Венера урыныннан ук торып басты.

— Ярый, салмасаң, кыстамыйм, аз гына утыр әле, әйтәсе сүзләрем бетмәде.

Венера чарасыздан тагын утырды. Ул инде «Әллә үзен калдырып чыгып китәргәме? — дип уйлана башлаган иде.— Тагын ниләр әйтмәкче икән?»

Хафизов, тәмләп кенә эчеп җибәргәннән соң, шоколад сындырып капты. Ә башланмаганын:

— Эчмәсәң, менә монысын ал! — дип, Венерага сузды.

Венера:

— Юк, Радик Хафизович, рәхмәт! — дип, моңардан да баш тартмакчы иде. Директор:

— Бусы бөтенләй әйбәт түгел, шоколадтан да баш тарту килешми,— дигәч, аны алып, кесәсенә тыкты.

— Миннән зрә шикләнәсең, чибәркәй,— дип дәвам итте Хафизов, утырган җиреннән торып.— Мин сиңа яхшылык эшләргә генә телим. Ә син шуңардан баш тартырга тырышасың, мин моны аңламыйм?

Хафизовның һаман шулай якынлаша баруыннан ныклап шикләнә башлаган Венера:

— Институтка кермәсәм дә, исем китми,— дигән булды, тизрәк сүзне бетерәсе килгәнне сиздереп.

— Юк, юк, син прилавка артында гына калырга тиеш түгел! — диде Венера янына килеп баскан Хафизов, аның маңгаена төшеп торган чәчләрен төзәткән булып.— Сиңа үсәргә кирәк, үсәргә. Моның өчен мин бар көчемне куячакмын.

Хафизовның куллары кагылуга тартынудан тәннәре эселе-суыклы булып киткән Венера, артка чигенеп, китәргә кузгалган иде.

— Ник шикләнәсең, чибәркәй, мин сине ашарга җыенмыйм бит,— дип, Хафизов аның каршына басты.

— Уйнамагыз әле, Радик Хафизович, юкса...— дип бүленеп калды Венера һәм, читкә тайпылып, ишеккә атлады.

Ә директор исә, арада берни булмагандай итеп:

— Кәгазьләрне китергән өчен рәхмәт. Шаяруны онытып, институтка керү турында уйла, чибәркәй, ярыймы? — дип әйтеп калды.

— Ярый,— дигән булды Венера.

Кибеттән чыгуга, ул бүредән ычкынган сарык кебек, як-ягына да карап тормастан, кызу-кызу атлап, өенә ашыкты.

Хафизов аңа күңел кайтаргыч кына түгел, хәтта куркыныч тоела башлаган иде. «Ничек төлкеләнгән була. Мине намусын югалткан кыз дип уйлый микәнни, оятсыз! Нишләргә инде? Бу хәлне тагын апага зарланып, кибеттән китәм дисәм дә, файдасыз. Ул моңа барыбер каршы киләчәк. Ял атнасы җитүгә, миңа ныклап эш эзләргә керешергә кирәк. Тулай торагы булган эш табып, апалардан да китәм. Шунсыз миңа тынгы булмас.

Икенче көнне Венера эшкә килеп, икесе генә калуга, Сабира:

— Кәгазьләрне хуҗага тапшырдыңмы? Ничек кабул итте? — дип сорау бирде.

Венераның бу турыда сөйләшәсе дә килми иде.

— Тапшырдым, Сабира апа,— дигән булды ул, теләр-теләмәс кенә.

— Ник болай сүрән җавап бирәсең, әллә үпкәләттеме үзеңне?

— Юк.

Шулай да, киләчәктә Сабира мондый йомышлар кушмасын өчен, Венерага үзенә директор ничек бәйләнгәнне сөйләп бирергә туры килде.

— И-и, юләр икәнсең! Шикләнеп торалармы аңардан?! Киресенчә, күзенә керергә кирәк аның! — дип, авыз күтәреп көлеп алды Сабира.— Үзенә шулай ярдәм итәргә торганда форсатны ычкындыралармы соң? Эх, синең кебек яшь чагым белән синдәге чибәрлек булса икән миндә, ничек сыгарга белер идем аны!..

Бу сүзләр Венераның күңелен кайтарып кына калмыйча, Сабирага карата ышанычын тагын да киметә төште.

Шушы сөйләшүдән соң, Сабира Венераны көн эчендә хисаплау машинасында эшләргә өйрәтеп, кассага утыртты.

Бу, әле яңа эш булганга, Венера өчен кызыклы иде. «Монда утыргач, директор килеп күзен майландырып, әллә нинди сүзләр белән баш әйләндереп йөрмәс»,— дип шатланган иде ул. Юкка куанган. Хафизов, тындырмыйча, касса каршына килеп тә, кабинетына чакырып та аның ихтыярын сындырырга маташуын дәвам итте. Венера кассада эшли башлагач, директорның Сабира аркылы сатучылардан ай саен «взнос» дип йөртелә торган ришвәт алып ятканын белде. Бу — сатучыларның чумарадан, кергән акчасыннан өлеш алу иде. Ул шулай көйләнгән: директор сатуга махинация һәм спекуляция ясардай дефицит әйберләрне никадәр күбрәк кайтартса, «взнос»ны да күбрәк ала. Венера сатып алучыларның тиененә дә тими. Шулай да Сабира уртак «взнос»тан аңа да өлеш чыгарып бара иде. Венера моңа ризасызлык белдереп караган иде, Сабира:

— Син генә фәрештә була алмассың, ал! — дип кисеп куйгач, каршы торыр хәле калмады.

Шуңа да карамастан, ул мөмкин кадәр гөнаһланмаска тырыша иде.

Яңа ел алдыннан, сатуга күп итеп очсызлы колбаса, тозлы балык, ике-өч төрле цитрус җимешләре һәм эчемлекләр китереп тутырдылар.

Кибетчеләр чек буенча да, акчаны кулга алып кына да саталар. Ә кассада утырган Венерага баш та күтәрмәле түгел.

Әбәт җитүгә, ул, кассаны бикләп, үзенә дип сайлап алып куйган мандарин һәм балыкны сумкасына салды да өенә ашыкты. Башка сатучыларның да күбесе кайсы-кая таралыштылар. Кибеттә Сабира, ит чабучы һәм йөкчеләр белән экспедитор гына калды. Һәркайсы үз эше белән мәшгуль: итче ит чаба, экспедитор, машина янына басып, йөкчеләр эшен күзәтә. Ә Сабира, анда-монда йөреп, барысына җитәкчелек итә.

Ул бер арада залга кереп касса тартмасын ачты да ячейкалардан бераз-бераз акча алып, халат кесәсенә яшерде. Аннары, кассаны бикләп чыгып, берни булмагандай, яңадан кешеләр янында кайнашуын дәвам итте. Тегесенә барып нидер әйткән-өйрәткән була, монысына нидер күрсәтеп китә, башка бернидә ай-вае юк, әйтерсең.

Әбәт үтүгә, Венера, берни абайламыйча, эшен дәвам итте. Баш та күтәрмичә чеклар җибәрә.

Смена тәмамланып, сатудан кергән акчаны санап чыкканнан соң, туры киләме дип хисаплау машинкасындагы санга караган иде — исе китеп, коелды да төште! Баш югалырлык акча җитми. Ул курку һәм югалып калудан калтыранган куллары белән пачкаларны ашыкмый гына тәртипләп куеп, акчаны яңадан санап чыкты. Дөрес саналган — акча чыкмый. Венера, кассаны бикләп, Сабира янына йөгерде.

— Үләм, Сабира апа, акча җитми! — дип, үксеп җибәрде ул.— Ни булгандыр, белмим.

Сабира беравык каушап, аптырап калгандай булып торды да:

— Ялгышкансыңдыр. Әйдә, яхшылап тикшерик әле! — диде.

Ни булганны белүгә, сатучылар да һәркайсы үзләрендәге чекларны яңадан барлап-тикшереп карадылар. (Урланган акча чыгамы соң!)

— Кассага ачкыч яратып урлаганнар дияр идең, әбәт вакытында үзем кибеттә булдым. Йөкчеләр дә, ит чабучылар да залга кермәде. Ә экспедитор, гел машина янында кайнашып, йөкчеләр белән мәшгуль иде. Кемнән дә шикләнерлек тә түгел, бит,— дип, гаҗәпләнгән булды Сабира.— Кеше күп булу, ыгы-зыгы мәхшәрендә башың катып шулкадәр ялгыштың микәнни?

— Юк, Сабира апа, юк! Күрә идең бит, моңарчы гел тиенгә-тиен чыга иде. Монда нидер бар: хисаплау машинасы дөрес эшләмичә хата җибәргәнме, белмим? — диде кайгыдан сулып калган чәчәк кебек булган Венера, елавын дәвам итеп.

— Кая, Радик Хафизовичка шалтыратыйм әле, тизрәк берәр чара күрергә кирәк.

Күп тә үтми, Хафизов килеп җитте. Йөзендә аз гына да борчылу-гасабилану күрмәссең. Әйтерсең, ул кешене теләсә нинди хәтәрлектән коткарып калырга һәм йолып алырга сәләтле кеше.

Сатучыларның күзе аңа төбәлгән.
— Милициягә-фәлән хәбәр итмәдегезме? — дигән сорау булды аның беренче сүзе.
— Юк, юк, Радик Хафизович, синнән башка шалтыратабызмы соң! — диде Сабира. — Моңарчы беркайчан булмаган хәл бу, беркайчан!.. Шуңа күрә ничек уйларга да белгән юк.
Хафизов, кыяфәт-карашына аерым бер тәкәбберлек чыгарып, Венерага төбәлеп:
— Хисаплау машинасы барахлить итмәгәндер, перебой белән эшләмәгәндер бит, Венера? — диде.
— Юк, яхшы эшләде кебек.
— Акча белән машинадагы күрсәткечне яхшылап чагыштырып тикшердек дисез инде?
— Тикшермиме соң, Радик Хафизович, тикшердек.
— Алайса, эштән кайтып тормыйча, хәзер үк сатылган һәм сатылмаган әйберләрне барлап-санап тикшерүгә керешегез, буталу-ялгышлык юкмы. Моны һич тә сузарга ярамый!
Кибетчеләр эшкә керешүгә, Хафизов, нишләргә икән дигәндәй залда йөренеп алды да:
— Бу турыда беркемгә берни ычкындырасы булмагыз! — дип кисәтеп, китеп барды.
...Бөтенесен энәсеннән-җебенә кадәр тикшереп барган сатучылар, икенче көнне таң белән килеп, эшне төгәлләделәр. Нәтиҗә куандыра торган түгел иде, билгеле.
Директор хисапчы белән сатучыларны Сабира кабинетына чакырып:
— Кабатлап әйтәм, бу турыда кешегә түгел, өегездә дә ләм-мим сүз ычкындырасы булмагыз! — дип кисәтте дә, Венера язмышы өчен борчылгандай, уйга калды.
Тынлык. Бөтенесе аның карарын — авызыннан чыккан сүзне көтә. Венераның башы да эшләми, хәсрәтеннән салкын мумиега әйләнгән, әйтерсең.
— Ярый, — дип, хәтәр эшкә тәвәккәлләгән кебек өстәлгә сугып алды Хафизов. — Бөтен көчемне куеп, коткарырга тырышып карыйм әле Венераны. Ә сез, әйткәнемчә, берни булмагандай, эшегезне дәвам итегез.
Икәүләп залга чыккач, Сабира, Венерага изгелек эшләүне үтенгәндәй:
— Ничек тә тырышып кара инде, Радик Хафизович! — дип, директорны озатып калды.
Венера, эченнән ут йотып, чеклар биреп утыра. Кайгысы бөтен кыяфәтенә чыккан иде. Моңарчы алма кебек алсуланып торган йөзендә төс, нур калмаган. Аның болай күңелсезләнеп утыруы Сабирага ошамый иде, ахры. Ул касса каршында кеше бетеп торган арада Венера янына килде дә:
— Башың Себер китәргә торган кебек утырма! Күрдең бит, хуҗа үзеңне: «Саклап калырга тырышырмын», — диде. Мин дә тырышуын кат-кат үтендем. Ул — сүзендә тора, әйткәнен эшләргә көченнән дә килә торган кеше. Шулай булгач, бетешмә: халык алдында йөзеңне ачып эшлә! — дип әйтеп китте.
Венера эштән икенче көнне дә кәефсез кайтканга күрә, апасы Мәрьям тагын:
— Нишләп болай төсең юк, әллә берәр күңелсезлек бармы? — дип сорарга мәҗбүр булды.
Шунда күңеле иләсләнеп киткән Венераның елый-елый үз хәлен сөйләп бирәсе килсә дә, кибеттә кисәтелгәнен искә алып, тыелып калды. Апага сөйләсәм, ул, Сабира апага барып йөреп, хәлемне катлауландырыр гына дип уйлап:
— Юк. Кичәле-бүгенле эш күп булды, арыдым, — диде.
Төрмәгә утыртмасалар ярар иде дип ут йотып, төнен керфек какмый уздырган Венера, тамагына да юньләп ашамыйча, эшкә китте.

Сабира исә аның өчен туктаусыз борчылып йөргән кебек, әледән-әле янына килеп:

— Артык кайгырма әле. Директор үзеңне коткару өчен бар көчен куеп тырышып йөри,— дип, юаткан була.— Үзең дә анардан кыргый кебек читләшеп торма! Каршында курчак кебек боргаланып, янында песи кебек сырпаланып йөрергә кирәк сиңа. Шулай итсәң, ул синең өчен тагын да ныграк тырышачак, күрерсең,— дип, киңәшләр биреп китә.

Сабира ниләр генә әйтмәсен, алар Венераның күңеленә ятмый иде. Ул, аның сүзләре һәм кыланышларына карап, «Акчаны Сабира апа үзе үк урламады микән?» — дип шикләнә башлады хәтта. Икәүдән-икәү генә калганда, сатучылар арасыннан да, кинаяләп кенә: «Сабира үзе дә, җае килсә, эләктерергә генә тора торган хатын»,— дип, мондый шикне колагына төшерүчеләр булды. Тик бернинди дәлиле булмаган авыл кызы Венераның бу усал хатынга моны әйтергә кыюлыгы җитәме соң?

Акча югалып өч көн үтүгә, Хафизов сатучыларны тагын җыйды.

— Безгә ничек тә бу хәлдән тизрәк котылырга кирәк, иптәшләр! — дип башлады ул.— Кассада чиратлап эшләгәнлектән, беләсез, мондый бәхетсезлек теләсә кайсыгыз белән булуы мөмкин. Шуңа күрә аны бергәләп кичерергә кирәк. Миндә шундый тәкъдим бар. Иртәгә — акча алу көне. Бөтенебез ведомостька имзаларны куябыз да акчаларны кулга алмыйбыз: бухгалтер сейфында торып торсыннар. Алай гына түгел, өйдә дә булган кадәр акчаларыгызны әзерләп куегыз. Эш контрольлек итүче органнарга сизелеп, ревизия ихтималы булдымы — аларны тиз генә җыеп алабыз да, сатудан кергән акча итеп, җибәрәбез. Борчылмагыз, берегезнең дә тиене дә югалмас. Менә шулай итеп, атна-ун көн эчендә без бу хәлдән котылырга, дөресрәге, кызыкайны коткарып калырга тиеш.

Шушы сүзләрне ишетеп, бәладән котылу өмете арткан Венера: «Радик Хафизович, чыннан да, олы җанлы кеше икән»,— дип уйлап, директорга эченнән генә рәхмәтләр укып утыра иде.

— Йә, ничек, килештекме? — диде Хафизов, сатучыларга күз йөгертеп. Шунда ук Венераның күзендә яшь мөлдерәп торганны күрсә дә, моны абайламаганга салышты.

— Килештек, Радик Хафизович, килештек. Мондый чакта бер-береңне ташларга ярыймы соң! — диештеләр сатучылар.

Хафизов эшлекле төс белән дәвам итте:

— Хуҗаларны җайлап-майлап сөйләшеп, күп итеп дефицит әйберләр китереп булмасмы дип, өченче көн чабам инде. Әгәр барып чыкса, «кереме» дә зуррак булып, мәсьәлә тизрәк хәл ителер иде.

— Әйе, әйе! Бик әйбәт булыр иде, Радик Хафизович! Тырышыгыз инде, тырыш! — дип куәтләде сатучылар, «кереме» дигәннән чумараны күз алдына китереп.

Сатучылар белән хисапчы чыгып китеп, бүлмәдә икесе генә калуга, Хафизов Сабираның шома булып калкып торган ботына сугып алды.

— Йә, берәр рюмка салыйк әле!

— Эш уңайга баргач, кәеф шәп синең, ә? — диде Сабира, өстәл тумбочкасыннан коньяк белән рюмкалар чыгарып.

— Шәп булмаска, зөфаф төне якынлашып килә бит, Сабира!.. Туй алдыннан булган кебек дулкынлана башладым хәтта,— дип, хыйхылдап алды Хафизов.

— Һай, нәкъ дулкынлана торганы инде син!..

Директор белән бүлек мөдире бер-берсенә әле кәнтәйләрчә күзләрен майландырып, әле үтәли күрергә теләгәндәй үткен караш ташлап алалар иде.

— Асыл кошны тозакка керттек бит тәки,— дип, кеткелдәп алды Сабира.— Юкса болай гына баш бирә торганнардан түгел иде кызый. Шигем юк, гыйффәтенә җил дә тимәгән әле аның! Ә син андый чибәрләрнең бәясен яхшы беләсең. Шуңа күрә, эш барып чыкса, миңа «бүләк» тә кечкенәдән булмас дип уйлыйм.

— Ну нәфес зур да инде үзеңдә! Минем аркада болай да майда гына йөзеп яшисең бит инде. Ишетсен колагың, «бүләк» дип, кассадан эләктергән акчага миннән башка кул тидерәсе булма! — дип, кисәтеп алды Хафизов, рюмканы бушатуга шоколад кабып.

— Нишләп кагылыйм инде?! Ул икебезгә генә кирәсе бит.

— Әлбәттә. Шулай булгач, аз булыр дип борчылалармы соң!. Башта максатка ирешик әле.

— Болай булгач, очына чыкмый туктау юк инде! — диде салудан күзләре елтырый башлаган Сабира. — Ә бүген, кайтышлый, миңа кагыласың, Радик! Юкса, яшьләр артыннан куып, миннән читләшә башладың. Искеләрне дә ташлап бетерергә ярамый — бел!..

Хафизов:

— Ярар, кагылырмын,— дип, Сабираның артын сыйпаштырып кузгалды.

Шушы сөйләшүнең икенче көнендә үк, Хафизов кибеткә башта ике машина аракы китереп бушаттырды. Кибетчеләр күз буяр өчен аның беразын гына сатып, калганын икеләтә бәядән аткару өчен, складның караңгы почмакларына яшереп һәм өйләренә ташып бетерүгә, көнендә сатылып бетә торган очсызлы сарделька, цитрус җимешләре һәм җиңел үтә торган башка азык-төлек кайтарта башлады. Боларның күбесе ялган документлар белән турыдан-туры җитештерүче завод һәм база махинаторлары аркылы кайтарыла иде.

Кибеттә бөтенесе әвеш-тәвеш китерү белән мәшгуль. Сабира, әледәнәле килеп:

— Читлеккә эләгәсең килмәсә, тырыш, матурым! — дип әйтеп китә башлагач, Венера:

— Тырышам бит, тагын нишлим инде,— диде, ачынып.

— Болай гына эш акрын бара. Ә акчаны тизрәк җыеп тапшырырга кирәк. Милиция кибет тирәсендә таң белән йөрми. Сиңа, иртүк торып, үзегезнең кибет тирәсендә булып алырга кирәк. Талон буенча сатылган аракы гына ирләргә нәрсә ул. Алкашлар таң белән кибет янына килеп, аракыны ике-өч бәясенә алып баш төзәтәләр. Син монда эшкә килгәнче, анда да берничә шешәне аткарырга өлгерәсең әле.

Төрмәгә эләгәсе килмәгән Венерага бу киңәшне дә кабул итәргә туры килде. Шулай итеп, әле чын тормышны, кешеләрне аңларлык тәҗрибәсе булмаган Венера, пычрак юлга басмыйм дип, күрәләтә җинаять һәм бозык юлга керә бара иде.

Тиздән үзенә пачкалап акча кирәсен белеп торган Сабираның хәзер активлыгы аеруча көчле. Ул, прилавка артына басып, сату да итә, тегесенә-монысына барып булышып та йөри, йөкчеләргә дә ярдәм иткән була хәтта.

Ниһаять, Венераны йолып калу сәгатьләре.

Сабира, сатучылардан кирәк кадәр «взнос» җыюга, кассадан урлаган кадәр акчаны капларга бухгалтерга кертеп чыкты да Венераны чакырып алды.

— Бәхетең бар икән шулай да,— дип, җиңел сулап куйган булды ул.

— И-и Сабира апа, җаным, бу арада ниләр кичергәнемне белсәң икән!..

Венера шатлыгыннан елап җибәрде.

— Белмимме соң, баш китәрлек хәл иде бит бу! Директорның кешелекле булуы сатучылар өчен сөенеп туймаслык бәхет ул! Көне-төне чапса чапты, үзеңне коткарып калды тәки. Моның өчен син аңа бик зур бурычлы инде, матурым,— Сабира өстәл тумбочкасыннан коньяк чыгарып кәгазьгә төрде дә Венерага бирде:— Бар, хәзер үк шушыны кулына тоттырып, рәхмәтләреңне әйтеп кил үзенә! Мин дә шалтыратып рәхмәт әйтермен.

Куанычы ташып чыккан Венера, йөгерә-йөгерә барып, директор бүлмәсенә килеп керде.

Хафизов ниндидер кәгазьләр актарып утыра иде.

— Мине бәладән коткарып калуыгыз өчен бик зур рәхмәт инде, Радик Хафизович! — диде ул, Сабира җибәргән коньякны Хафизов алдына куеп.— Бик зур рәхмәт сезгә!

— Бусы ни тагы?! — дип, төргәкне ачып җибәрде Хафизов.— О-о, ник китердең моны?

— Ни әйтергә дә белмичә уңайсызланып калган Венераның йөзе ут кебек янып чыкты. Битенең ничек кайнарланып киткәнен үзе дә сизде хәтта.

Киеренке тынлык.

Бүген Венерага басым ясарга мөмкинлек зур булса да, берничә тапкыр якын килергә тырышып та барып чыкмаганга күрә, Хафизов, хәйләләрен арттыра төшеп, аның алдында үзен мөмкин кадәр әдәпле күрсәтергә тырыша иде.

— Сез, хатын-кызлар, шулай инде, директор шаянлык күрсәтеп үзегезгә якынлаша башладымы, фәрештә кебек кыланган буласыз,— диде Венерага карап күзләре калҗа күргән мәченеке кебек янган Хафизов.— Ә берәр авыр хәл йә бәхетсезлек чыктымы, ул кирәк. Бу нәрсә белән килгәнсең икән, шатлыгыңны юабыз инде, әйдә утыр!

«Тагын ни була инде бу?!» — дигән шом төшкән Венера, Хафизов тартмадан рюмкалар чыгара башлауга:

— Берүк кыстый күрмәгез, Радик Хафизович, мин барыбер эчмим! — дип, кисеп куйды.— Рәхмәт.

— Ник алай, Венера? Шушындый зур куаныч уңаеннан да, аз гына да эчмисеңмени? Димәк, синдә шатлык юк бүген...

— Бар, Радик Хафизович, шатлыгым бик зур! Моның өчен бик зур рәхмәт сезгә!

— Шулай булгач, символически бер рюмка гына эчеп куярга була бит.

— Юк, эчмим, Радик Хафизович! — диде Венера, тизрәк китәсе килеп.

— Нишләп моны күтәреп килдең соң, алайса? — дип, кетkeлдәп алды директор.

— Минеке түгел ул, аны Сабира апа җибәрде. Мин... Мин күп итеп рәхмәт әйтергә килдем. Ярый, китим инде, Радик Хафизович.

Венераны эчәргә күндерә алмаган Хафизов исә:

— Әйе, аның җибәрүе дә гаҗәп түгел, бу — барыбыз өчен дә зур күңелсезлек иде бит. Хәер, эш вакыты булганга, уңайсызланасыңдыр. Изгелекне аңлап, рәхмәт әйтергә килгәнең өчен үзеңә рәхмәт. Бүген генә димәгән, җае белән, билгеләп үтәрбез әле бу шатлыкны,— диде дә, ярый, тотмыйм алайса дигәндәй, кулларып җәеп, иңен сикертеп алды.

Венерага шул гына кирәк иде. Ул, тагын бер кат рәхмәт әйтеп, ишеккә ашыкты.

Кыз читлектән ычкынган кош, әйтерсең! Канатлары булса, күкләргә очар иде! «Бу көнне күрәсем бар икән, раббым!» — дип куйды ул, рәхәтләнеп сулап җибәргәннән соң.

Әйе, кассада акча чыкмаган көннән алып бүгенгә кадәр ниләр кичергәнен Венера үзе генә белә иде. Аның яшь кенә килеш хурлыкка калып төрмәдә утырганчы, елгага төшеп, суга ташланыйммы әллә дип уйлаган чаклары булды хәтта. «Шушы бәладән исән-сау котылсам, берңигә карамыйча, бу эштән китәр идем!» — дип йөри иде ул. Ниһаять, бу көнне күрүгә иреште. «Миңа кичекмәстән китәргә кирәк! Хәзер үк гариза язып, директорга яңадан керергә микән? — дип уйлана башлады Венера.— Юк, юк! Аның күзенә ничек күренә алыйм хәзер үк!.. Бүген үк эштән китәргә йөри башласам, үземне коткарып калу өчен тырышкан сатучылардан да яхшы түгел. Аз гына сабыр итим — түзим инде».

Венера, башыннан шундый уйлар кичереп, бүлек мөдире янына кайтып керде.

— Йә, хуҗа ничек каршылады? Ничек кабул итте үзеңне? — дип сорау бирде Сабира, хәйләкәр елмаеп.

— Яхшы каршылады, Сабира апа, әйбәт,— диде Венера, бу турыда сүз куертып торасы килмичә.— Рәхмәт әйтергә килгәнем өчен үзебезгә рәхмәт әйтте, җитмәсә.

— Йөзеңдә берни дә күрмим, шатлыкны отмечать итмәдегезме әллә?

— Юк. Ул нәрсәне авызыма да китермәгән килеш, ничек директор белән эчеп утырыйм инде, Сабира апа?..

— Зрә, матурым, зрә. Пешмәгәнсең, бәяңне белмисең икән. Эх, белештермисең шул әле!.. Ярый, бар, бүлеккә чыгып, эшеңне дәвам ит!

Венера эштән кайтканда, өйдә апасы Мәрьям генә иде. Ул, икәүдән-икәү булудан файдаланып, аңа булып алган хәлләр, ниләр кичергәне турында сөйләргә тотынды.

Сеңелесен тыңлап, курку һәм гаҗәпләнүдән Мәрьямнең күзләре зур ачылып, тыны кысылып калган иде. Шуңа да карамастан, Венераның эштән китәргә карар кылганын ишетүгә:

— Юк, юк, уйлама да! — дип бүлдерде ул.— Ничек инде бернинди һөнәрсез төзелештә эшләмәк кирәк?! Анда сиңа носилка да көрәк кенә тоттыралар бит. Балчык-тузан эчендә измә-ком ташып, бетәсең бит син анда!

— Кешеләр эшли бит әле, үлмиләр, апа.

— Эшләсеннәр, кешегә карама!

— Шәһәрдә эш тапмасам да, бу эштә калмыйм! Авылга кайтып китәм. Фермада эшләрмен.

— Авылдан бер тәвәккәлләп чыгып киткәннән соң, ни йөзең белән кире кайтмак буласың хәзер? «Венера тормышка яраксыз кыз икән»,— дип, гайбәт таратып көләрләр, бары шул. Бүгенге җитешмәгән тормышта кибеттән китәләрме соң! Теләсә кайсы азык-төлекне күпме телисең, шулкадәр үз кулың белән яхшысын гына сайлап алып кайтасың. Көннең-көнендә чумарасы кереп тора. Болар эчеңне тишәме әллә?

— Хәрам әйбернең кирәге юк, апа, берсе дә кирәкми, калмыйм анда!

— Акчаң чыкмаудан котың алынган икән. Бу ялан саен була торган нәрсә түгел бит. Моннан соң, алдыңны-артыңны карап эшләрсең. Бәлки, анда сине, яшь дип, кыерсыталардыр. Сабираны күреп, барысын сорашып сөйләшәм әле.

Мәрьям шулай һаман үзенекен тәкърарлый биргәч, Венера:

— Сүз куертып, Сабира апага барып йөрмә! Тагын бер уйлап карармын әле, алайса,— дигән булып, сүзне бетерде.

Ул, касса хәлләре суынып телдән төшкәнче генә эшлим дә китәм дигән уй белән, бу турыда кибеттә берәүгә дә белдермичә, матур гына эшләп йөри иде. Ә үзе, буш вакытларында, тулай торагы булган җирләрне сорашып, эш эзли. Бала чагыннан ук мал-туар, йорт эшләрен карап һәм фермада сыер савучы әнисенә булышып үскәнлектән, аны авырлык аз гына да куркытмый иде.

Венера шулай бер, эшкә урнашырга тәгаенләп кайтып, кибеткә гаризасын тотып барды.

Сабира моны башына да китермәгән иде. Ул Венераны китмәскә үгетләве барып чыкмагач, гаризаны алып, Хафизов янына китте.

Шуннан соң күп тә үтми, директор шалтыратып Венерага килергә кушканны әйттеләр.

Ул килеп кергәндә, Хафизов белән Сабира икесе генә сөйләшеп утыралар иде.

— Күңелсез хәл тагын кабатланыр дип курыктың, ахры,— дип башлады директор.— Бу эшкә сәләтем дә юктыр дип уйлыйсыңдыр әле, җитмәсә. Тик тегеләй дә, болай да ялгышасың. Кибеттә бер дигән итеп эшләргә дә, алга таба укып, үзең җитәкче булырга да бөтен данныйларың бар синең! Институтка керү дигәндә, әйткәнемчә, берсүзсез ярдәм итәчәкмен!

— Әйтәсең дә юк, Радик Хафизович! — дип сүзгә кушылды Сабира.— Кайнарланып, ялгышма, матурым: гаризаңны ертып ташла да рәхәтләнеп эшләвеңне бел!

Хафизов белән Сабира шулай әле берсе, әле икенчесе эшкәртүдән уйлары томанланып киткән Венера, апасы үгетләрен дә исенә төшереп, тәгаенләгән карарының дөреслегенә шикләнә башлады. Һәм кисеп кенә ни әйтергә дә белмичә:

— Гариза сездә калып торсын. Тагын бер уйлап карармын, алайса,— дип әйтергә мәҗбүр булды.

— Монысы икенче эш!

— Чынлап уйласаң, гаризаңны ертып ташлаячаксың, күрерсең! — диештеләр канәгатьлектән йөзләре балкып киткән директор белән Сабира.

Шуның белән сөйләшү йомгакланып, Венера кире кибеткә — эшенә китте.

Ялгызлык уйларның буасын ера дигәндәй, Венера яңадан баш вата башлады. «Инде нишләргә? Әллә, чыннан да, ялгышаммы? Башта Мәрьям апа китмәскә кушып үгетләде. Әле болар ниләр генә аңлатмый!.. Беләм, бу минем урынга алырга кеше тапмаудан түгел. Апа әйткәнчә, кибеткә белер-белмәс кешене аласылары килми — шул гына. Ник дисәң, белгән кешеләр белән махинация һәм спекуляция белән шөгыльләнергә җиңел. Юк, миңа бармый бу эш! Шушы атнамны гына эшлим дә: «Китәргә булдым»,— дип әйтәм.

Венера кайтып бер сәгатьләп эшләүгә, янына Сабира килеп басты.

— Ничек эшләр, барамы?

— Бара.

— Минем сиңа бер үтенечем бар иде, матурым.

— Нинди үтенеч, Сабира апа?

— Өйдә бер бүлмәмә обой ябыштырып аласы бар иде. Зур эш тә түгел инде югыйсә, һаман тора: ялгызым гына тотынырга кулым бармый. Шуны икәүләп эшләп алсак, җиңел дә, күңеллерәк тә булыр иде.

— Ник бармыйм — булышырмын, Сабира апа! Әйт, кайчан ябыштырабыз?

— Болай сүз кузгаткач, шушы арада эшләп алсак, яхшы булыр иде. Берсекөнгә ябыштырып алыйк, булмаса.

— Ярый, ярый, Сабира апа! Эштән туры сиңа китәрбез дә...

— Юк, юк! Ул көнне эшкә чыгып тормыйсың! Болай да ул синең ял алды көнең бит. Берсекөнгә синең урынга башка кешене куярмын. Иртәнге якта сәгать уннарга кил.

### 3

Венера, өйдә үзе генә калгач, бүлмәләрне ялт иттереп юып-чистартып чыгарды да Сабирага китте.

Аның бүген көне тулысы белән планлаштырылган иде. Ул Сабирага булышып кайтуга, имтиханнарга хәзерләнергә керешәчәк. Бүген сөйгәне Мансурның да килеп чыгуы ихтимал. Ник дисәң, Венера колхозларга урып-җыюга җибәрелгән университет студентларының шушы арада кайтасын ишетте. «Җай булса, киләсе очрашуга билетлар алып куярмын да театрга барырбыз»,— дигән иде. Шуңа күрә әзер булып торырга кирәк,— дип уйлана башлады ул.— Мансур матур киенергә ярата. Ә миңа, кыз кешегә, аңардан да матуррак булырга кирәк. Сабира ападан кайтуга, киемнәремне карап, үтүкләп куйыйм әле. Мансур кибеткә урнашуымны белгәч: «Сиңа бара торган эш түгел бу. Сәүдәдә кешенең намусы югала. Сиңа үзең сайлаган һөнәр буенча китәргә кирәк иде, Венера»,— дип, ризасызлык белдергән иде. Булып алган хәлләрне белсә, ни әйтер әле тагы!.. Хәер, кибеттән китәргә гариза бирелгән, соңгы сүзне әйтәсе генә.

Венера, шушы уйлары белән мавыгып, Сабираларга килеп җиткәнен сизми дә калды.

— Хуш киләсең, рәхим ит! — диде Сабира, ишекне ачуга аны бүлмәгә уздырып.— Әйдә, чишенеп, түргә үт!

— Рәхмәт.

Кухняда тәмле булып парланып пешкән ит һәм кисеп куйган лимон исе аңкып тора иде.

Венера, плащын салып, аягына чүәк эләктерде дә Сабира артыннан кухняга узды.

— Кунаклар-фәлән көтмисеңдер бит, Сабира апа? — диде ул, өстәлгә мул итеп әзерләнгән закускалы ашамлыкларны күреп.

— Син кунак түгелме әллә, эшләргә дип килгәч тә. Синең миндә булганың юк бит әле.

— Алай да, минем өчен генә шулкадәр мәшәкатьләнү кирәкме соң?.. Кая, ни кушасың, Сабира апа, эшли торыйм.

— Ашыкма! Тамак туйдырып алабыз әле башта. Аннары, кәеф булса, тотынырбыз. Булмаса, яна торган эш түгел, калып торыр. Әнә, бүлмәне кереп күр, бәлки, кагылып та тормабыз әле үзенә.

«Кайчан, ничек җыйды икән бу кадәр әйберне?! — дип уйлап куйды Венера, бүлмәләргә күз йөртеп чыккач, исе китеп.— Гарнитур стенкасындагы алтынга манылган бәллүр белән савыт-сабасы гына да миллионнар торырлык моның!»

Обойларга дигән бүлмәнең стеналары да аз гына да таушалмаган, балкып тора иде әле.

— Нишләп обойларга уйладың ул бүлмәне, ябыштырганы да яңа бит әле? — диде Венера, Сабира янына кереп.— Монысыннан да матурракны ябыштырам дисәң генә инде.

— Әйтәм бит, бәлки, маташып та тормабыз әле, алайса,— диде сәгатькә карап алган Сабира.— Әйдә, ризыкларны олы якка чыгарыйк!

— Кухняда гына утырсак, ярамасмыни, Сабира апа?

— Яраса соң. Иркендә утыру рәхәтрәк бит.

Кемдер табын әзерләгәнне генә көткән, әйтерсең, ишектә кыңгырау шалтырады. Сабира барып ачса — Хафизов!

Кырынып-чистарынып, яңа галстук тагып, тагын да матуррак костюм кигән — туйга әзерләнгән кияү егете диярсең!

— Әйдә, рәхим ит, Радик Хафизович! Өстәл әзерләгәндә генә килеп кердең, мактап йөрисең икән. Әйдә, уз!

— Сезне дә мактамасам!.. Чакырылган кунак та шулай әзер табынга гына килеп кермәс, чыннан да, бәхетле икәнмен,— диде Хафизов.— Кичә ит комбинатыннан шалтыратырга тиешләр иде. Көтмәгәндә бер җитди эш чыгып, кибеттән чыгып китәргә туры килде. Үзем юкта сиңа шалтыратмадылар микән, шуны белеп чыгыйм әле, дип керүем иде.

— Юк, Радик Хафизович, шалтыратучы булмады. Бик җитди сөйләшү идемени?

— Алай ук түгел дә...

— Шулай булгач, борчылма: шалтыратырлар. Әйдә, бергәләп утырыйк әле!

Хафизов:

— Мин дә шулай уйлыйм. Кунак кызың да булгач, болай гына китмим инде,— дигән булып, костюмын салып утыргыч аркасына элеп куйды.

Килеп керүгә, Венераны башта Сабираның мул итеп закускалы ризыклар әзерләве, аннары, обойларга дигән бүлмәнең стенасы әле аз гына да искермәгән булуы гаҗәпләндергән иде. Шуннан соң, тиздән киләсе кешесе булгандай, сәгатькә күз алуы сәерсендерде. Әле исә, өстәл әзерләүгә генә Хафизов килеп керде. «Очраклы хәлме бу? Әллә, бөтенесе алдан сөйләшеп, махсус оештырылганмы? — дип уйланып алды күңеленә шомлы шик төшкән Венера.— Берәр сәбәп табып чыгып китәргә дә уңайсыз: үзләрен санга сукмаган кебек була».

Ул, шулай сагаеп калган хәлдә, Сабирага булыша бирде.

— Менә ничек бит, ә? Мондый вакытта туры килермен дип башыма да китермәгән идем!..— диде астан гына Венераны күзәткән Хафизов.

— Җыясы ризык теш сындырып керә, диләр бит, шул инде бу,— дип кеткелдәде Сабира моңа каршы.

— Шулайдыр, Сабира Гаязовна, шулайдыр, юкса...

Венера тәлинкәләргә аш салып чыгуга, Сабира өстәлгә шампан шәрабе белән коньяк китереп:

— Йә, Радик Хафизович, син — егет кеше, без кызларны сыйла инде! — диде.

Моны ишетүгә, директор башта, ашыкмый гына күлмәк якасының төймәсен ычкындырып, галстугын бушайтып җибәрде. Аннары фужерларны алдына елыштырып куйды. Һәм шуннан соң гына аерым бер канәгатьлек белән шешә бөкесен шартлатып аттырды да фужерларга чажлап-күбекләнеп торган шәраб салып чыкты.

— Йәгез, кызлар, матур ял өчен күтәрик әле! — диде ул, фужерларны Сабира белән Венерага тоттырып.

Венера чәкештереп алуга:

— Гафу итегез, мин эчмим, рәхмәт! — дип, фужерны кире куйган иде, Сабира белән Хафизов икәүләп кыстарга тотындылар.

— Бу алкашларны түндерә торган нефть суы түгел, матурым, импортный шампански! Моның бер зыяны да юк: шаулап торганда эчеп җибәр, әйдә! — диде Сабира, коры гына.

— Әйе, әйе, бу исертә торган нәрсә түгел лә! Эчмәсәң, безне хөрмәт итмәү, санга сукмау була бит,— дип өстәде Хафизов.

Шулай ике яклап кыстауга каршы тора алмаган Венера:

— Алайса, шушыны эчәм дә, кабат кыстый күрмәгез! — дип, фужерны бушатып куйды.

— Менә шулай! — диде Сабира, канәгать елмаеп.— Гомергә фәрештә булып йөри алмассың. Мондый чакта азрак кәефләнү була инде.

— Дөрес, дөрес! — дип өстәде Хафизов, фужерларны яңадан тутырып. Һәм тагын кыстау китте.

Венера ничек кенә каршылык күрсәтмәсен, тагын ярты фужер эчәргә туры килде.

Шәраб, тылсымлы сыекча сыман, аңардагы киеренкелек белән тартынуны киметкәннән-киметә бара иде.

Бераз капкалап, шаян сүзләр сөйләп алгач, Хафизов, рюмкаларга коньяк салып:

— Бусын ни өчен эчәбез? — диде.

Моны күреп, тәмам исерүдән курка башлаган Венера:

— Зинһар, мине кыстый күрмәгез! — дип эчүдән котылмакчы булган иде, Сабира торып ук басты.

— Юк инде, матурым! Монысын бәладән котылу шатлыгыннан эчәбез!

— Бусыннан баш тарта алмыйсың инде, Венера! — дип, торып басты директор да.— Әгәр ул хәлне вакытында йомып калмасак, син бүген монда түгел, читлектә утырыр идең, чибәркәй... Шуңа күрә шатлыкны билгеләп үтмәсәк, гөнаһ булыр. Әйдә, шушыны эчеп бетереп куй да, аннары кыстамабыз, үзеңә карарсың...

Венера тагын ирексездән эчәргә мәҗбүр булды. Коньяк, исерткечләрне әле бер генә дә авызына алганы булмаган Венераның тамак төбен көйдереп үтеп, тәннәрен кымырҗытып, бөтен гәүдәсенә таралды. Һәм шуннан соң, оялу-тартынуы да юкка чыгып, үзенә рәхәт булып китте хәтта. Сабира белән Хафизов, гүя, үз тиңдәшләре хәзер. Иңнәре авыраеп, гәүдәсе сыекланып киткән Венераның күз алдында ниндидер томан элпәсе барлыкка килеп, дулкын тирбәткән көймәдә утырган сыман, чайкалып-чайкалып киткән кебек тоела башлады. Хәзер ул тартынусыз сөйләшә, шаян сүзләр булса, рәхәтләнеп көлеп җибәрә.

Венера бераз вакыт үтеп, рюмкалар яңадан тулгач, Сабира:

— Без сиңа бары тик яхшылык телибез, матурым. Чөнки сине яратабыз. Безнең яктан сиңа һәрвакыт поддержка булыр, борчылма,— дип, Венераның аркасыннан кагып алды да Хафизовка борылды:— Син Венерага институтка керергә ярдәм итәргә тиеш, Радик Хафизович! Ул үсәргә тиеш — шул!

— Әйттем бит инде, Сабира Гаязовна, берсүзсез булышачакмын! Йәгез, теләгебез тормышка ашсын өчен күтәрик әле, алайса!

— Уңышлар өчен! — дип куәтләде Сабира.

Исерүе җиткән Венера монысында инде кыстаусыз эчте.

Хәзер ул, сәер-сәер хәрәкәтләр ясап, кычкырып көлеп җибәрә, теләгәндә, хуҗаларын бүлдереп, үзе дә сөйли.

— Йә, рюмкаларны тутырып куй да, биеп, танцевать итеп алабыз, Радик Хафизович! Юкса болай гына кан таралмас...— диде Сабира, магнитоланы җибәреп.

— Ай, гафу ит, Сабира Гаязовна! Искә төшермичә үзегезне сыйлый да белмим, пешмәгән! — дигән булды Хафизов. Аннары, симез калҗа кимергәндә майга баткан кулларын салфетка белән сөрткәннән соң, яңадан рюмкаларны тутырып чыкты.— Рәхим итегез!

Кыз, үзен контрольдә тотуын югалта барып, чайкала башлаган иде. Ул, хуҗаларга карап, тагын эчеп куйды.

— Менә булды, ичмасам! — диде Сабира, чытлыкланып.— Хәзер рәхәтләнеп танцевать итәргә дә була...

Хафизов, джентльменнарча баш иеп, Венераны танцевать итәргә чакырды. Венерада хәзер бернинди каршылык та, тартынып тору да юк иде инде. Ул торып басканда:

— Аһ, исердем, Радик Хафизович, исердем!..— дип, чайкалып китте.

— Зыян юк, чибәркәй, бер зыян да юк,— диде директор, аны үзенә кысып.

Сабира исә, үзегез карагыз инде дигәндәй, йомыш табып, кухняга кереп китте.

— Мин бу көнне күптән көтә идем, Венера: бәхетемә ирешеп киләм, ниһаять! — дип, Хафизов камыр кебек йомшап чыккан Венераны кысып алды.

— Ай, әйләндермәгез, Радик Хафизович!.. Болай да башым әйләнә, ай!..

Исерүдән чайкалган Венера, егылмыйм дип, үзе дә сизмәстән тагын да Хафизовка авыша төште. Ә тегеңә шул гына кирәк иде. Ул аны таза куллары белән кысып алып, комсызланып кайнар иреннәрен суырып үпте.

— Сөеклем минем!..

Исергән Венерага Хафизов моңарчы булгандагы кебек куркыныч та, күңел кайтаргыч та түгел иде. Шуңа аның үбүен дә теләп алган кебек кабул итте.

Танцы көйләре бетүгә, Сабира бию көйләре язмасын җибәреп, өчәүләп биеп алдылар да тагын салдылар. Шуннан соң ул:

— Минем бер җиргә барып киләсем бар иде. Әйләнеп кайтыйм әле. Ә сез иркенләп, рәхәтләнеп ял итегез! — дигән булып, чыгып китте.

Хафизов исә аның артыннан ишекне бикләп калуга, магнитоланы сүндереп:

— Ниһаять, без икәү генә, гүзәлем!..— дип, ниндидер әрсез ашкыну белән исерүдән эреп торган Венераны күтәреп алды да йокы бүлмәсенә алып кереп китте...

Аўнып, Сабира белән Хафизов тарафыннан алданганын, ничек яшьлек чәчәген өздергәнен аңлап алуга, Венераны ачы кайгы басты. Бу хәлне кешегә түгел, апасы Мәрьямгә сөйләргә дә оят иде. Нинди генә уйлар кайнашмый башында!.. «Нишлим инде, раббым? Әллә башымны юк итим микән? Авылга кайтып китсәм дә, апа әйткәнчә, үземнән көлүләре генә бар. Их, шулкадәр бәхетсез булырмын микәнни!.. Хәзер ни йөзем белән Мансурга күреним инде? Әгәр, кайбер кызлар кебек, бу хәлне үзенә сиздерми генә йөри бирсәм, ни булыр? Ай, юк! Үземне янып яратып йөргән саф күңелле кешене алдасам, мин кем булам. Мин намусымны югалткан кыз түгел бит...»

Венера ике көн буе шулай уйланып йөргәннән соң: «Бетте — мин Мансурга лаеклы түгел хәзер. Кичекмәстән аның белән араны өзәргә генә калды»,— дигән ныклы карарга килде.

Өченче көнне колхоздан кайткан Мансур килеп җитте.

Гадәттәгечә, өс-башын балкытып матур итеп киенгән. Ягымлы һәм күтәренке күңелле иде.

— Киен дә киттек, әйдә! Шәһәрдә рәхәтләнеп сөйләшеп йөрербез,— диде ул, Венераны кочаклап үбеп алуга.— Булса, театрга билетлар да алып куярбыз.

Аның шулай сагынып килүенә каршы Венерадан бернинди ягымлылык күрсәтү юк иде.

— Чыгып йөри алмыйм, Мансур. Кайдадыр җил бәргән, башым авырта. Савыккач, үзем тулай торагыңа килермен әле,— дип ялганлады ул.

Мансур, Венераның агарынып киткән йөзенә карап һәм әйткән сүзләренә ышанып, тизрәк савыгуын теләп, кайтып китте.

Венера эшкә чыкканнан соң атна буе Сабира белән Хафизов күзенә күренергә оялып йөрде. Мондый хәлгә төшүенә алар түгел, әйтерсең, үзе гаепле. Ул Сабирага эчкә бер чиркану һәм саклык белән карый башлады хәзер.

Сабираның Венера алдында аз гына да гөнаһы юк диярсең, аңа изгелек эшләүче кеше кебек, тирәсендә бөтерелеп йөргән була.

Хатын-кызны күп күргән Хафизов та кызның үзеннән ничек күңеле кайтуын яхшы белә иде. Ул, Венера үзеннән читләшмәсен өчен, аңа аеруча игътибарлы булып күренергә тырыша. Телефоннан шалтыратып та, кибеткә килеп тә, хәлен, эшен сорашып: «Миннән ярдәм-фәлән кирәкмиме?» — дигән була.

Бүлек мөдире белән директор шулай юхаланып һәм юмалап, Венераны көннән-көн үзләренә авыштыра, кибеттәге шартларга өйрәтә-яраклаштыра баралар иде.

Шәһәрдә яши башлаганнан бирле, Венера болай да, кая гына бармасын, кайда гына булмасын, гаделсезлек күрә, ялган һәм кара эшләргә тап була иде. Бозык юлга басмаска теләп тә, Сабира белән Хафизов тозагына эләгеп мәсхәрәләнеп калгач, ул бөтенесенә битарафка әйләнде. Кибеттән китеп башка эшкә урнашса да, барыбер шулай булыр кебек тоела иде аңа хәзер. Шуңа күрә башка сатучылар ни эшләсә, куркыпшикләнеп тормыйча, ниһаять, ул да шуны эшли башлады.

Бераз вакыттан соң, Мансур Венераның эшләгән җиренә килде.

— Көтеп-көтеп тә булмагач, әллә ныклап авырып киттеме дип борчылып калган идем. Шөкер, исән-сау икәнсең. Ник сүзеңдә тормадың, ни булды? — диде ул, урамга чыгуга, Венераның килмәү сәбәбен ачыкларга теләп.

Хәзер Венераның аны, алдап йөртмичә, үзеннән тизрәк биздерәсе килә иде.

— Гафу ит, Мансур, минем беркем белән дә йөрисем килми.

— Нишләп алай?! Ни булды сиңа, Венера?

— Берни дә булмады, йөрисем килми, шул.

Мансур Венера күңелендә ни булганны, әйтмәсә дә, чамалап тора иде. Ләкин ул аның, сәбәбен әйтмичә, үзеннән котылырга маташуын ничек кенә ачыкларга тырышып карамасын, барып чыкмады.

Бераз вакыт узгач, ул, театрга билетлар алып, тагын килде.

Венераның карарында үзгәреш юк иде. Мансурның һаман шулай ябып йөрүе йөрәгенә артык әрнеткәнлектән, бусында ул:

— Кабат килеп йөрмә инде, Мансур, мин сиңа тиң дә түгел. Мин икенче егет белән таныштым...— диде.

Мансур колхозда булып кайтканчы Венера белән ничек яратышып йөрүенә карап та, аның үзен сәер тотуына карап та бу сүзләрнең дөрес түгеллеген сизә иде.

— Әйтмисең генә, синдә ниндидер күңелсез сер бар, Венера. Син беркайчан да болай түгел идең бит, ни булды сиңа?

Менә-менә елап җибәрүдән тыелып торган Венераның иреннәре дерелди иде.

— Ышан, Мансур, дөресен әйттем. Син мине гафу ит инде,— диде Венера, тамак төбенә килеп утырган төерне көчкә генә йотып җибәреп. Һәм, менә-менә яшь мөлдерәп чыгарга торган күзләрен читкә борды.

Мансур: «Нишләп болай көтмәгәндә генә мине кире кагарга уйлады икән?» — дип баш вата иде.

— Юк, ышанмыйм! Синдә нәрсәдер бар, яшерәсең генә, Венера,— дип, тагын да ныграк үҗәтләнеп карады ул.

Кыз, Сабира белән Хафизовтан шикләнә торып, аларның кыставына карап эчкәне өчен берничек тә гафу итә алмый иде үзен. Ул болай йомшаклык күрсәтүен Мансурның саф мәхәббәтенә хыянәт итү дип саный иде. Арада саф мәхәббәт белән тугрылык булмаса, бәхет буламы соң. Менә шуны уйлап, Мансур белән арасын өзәргә карар кылган Венерага ул кабат килеп йөрәгенә әрнетмәсен өчен, араны тәмам өзәргә кирәк иде бүген.

— Мин дөрес әйттем, Мансур. Ул егет миңа кияүгә чыгарга тәкъдим ясады хәтта. Калдыр мине, үтенеп сорыйм! — дип ялганлады Венера.

Моннан соң Мансурга сөйләшеп торуда мәгънә юк иде. Ул:

— Нишләмәк кирәк, ул егетне ныграк яратасың икән, миңа үзегезгә бәхет теләргә генә кала. Хуш, Венера! — дип, башын түбән иеп, китеп барды.

Болай аерылу Венерага тагын да авыррак тәэсир итте. Әйтерсең, Мансур йөрәгенең бер өлешен үзе белән алып китте. Ачуланып, пычрак сүзләр әйтеп китсә дә җиңелрәк булыр иде, мөгаен.

Венера, үзенең нинди зур югалтуга дучар булганын әле аңлап җиткермәсә дә, күңелендәге матур хыяллар, татлы ярату хисләре урынына сары сагыш кереп оялаганны яхшы сизә иде.

Төн буена, өйдәгеләргә сиздермичә, мендәргә капланып яшь түкте ул.

Венераның тормыштан күңеле кайтып, каны суынган иде. Үзе белән эшли торган хатыннарның күбесе байлык-акча дип теләсә нинди түбәнлеккә төшәргә әзер булганга күрә, ул беркемгә дә ышанмый, таяныч күрми хәзер. Шул комсызлык аркасында, ирләренә хыянәт итеп, директор белән гөнаһланып, туктаусыз сөяркәләр алыштырып торучы Хафизов тарафыннан соңыннан яраксызга чыгарылган бу хатыннар гайбәтчегә әйләнгән. Гаеп-мәзәк эзләргә аеруча хирыс Зөмәрә директорның Венерага күз төшкәнне беренче көнне үк сизеп алган иде. Әле Венера кайгы-кичерешен кая куярга белми йөргәндә, тотты да:

— Син хуҗаны Сабирадан тәмам биздерүче булырсың, ахры,— дип әйтеп салды.

Венера шулкадәр оялды, җир ярылса, җир тишегенә кереп китәр иде. Ул, нинди җавап кайтарырга да белмичә, тынып калды.

Ирле хатыннар, яманатларын чыгармас өчен, гөнаһларын яшереп, авызларына май кабып йөри, ичмасам. Ә бу, ире дә, хәзер үзенә караучы да булмагач, һәркайда гаеп, килешмәгән җир эзләп, гайбәт таратып йөри.

Венера эчтән генә нәфрәтләнеп дәшми торганны күргәч, Зөмәрә:

— Әйе, хуҗа белән ара якын булгач, яшәргә дә җиңелрәк, рәхәтрәк тә шул...— дип, яңадан төрттереп алды.

Моннан соң, Венерага ничек тә гайбәтченең авызын капларга кирәк иде.

— Яшькә олырак булса да, директор миңа ошый шул,— диде, горур елмаеп.

Бу сүзләрне әйткәндә, гарьлегеннән, аның күзләренә чак кына яшьләре бәреп чыкмаган иде.

Кибеттә бөтенесеннән күңеле кайтты хәзер Венераның. Бернинди таяныч, яклаучы юк үзен. Хәзер аңарда бер генә теләк — югалтканнарны кире кайтару. Ул, гайбәтчеләргә үч итеп, Хафизов белән ачыктан-ачык диярлек йөри башлады. Араларында бернинди тоткарлык юк. Сабира үзләрен әледән-әле өендә очраштырып тора. Венера директор бүлмәсенә килеп йөрергә дә тартынып тормый хәзер.

Шулай да, көннәрнең берендә, үзенең балага узганын белеп, Сабирага килеп, еларга тотынды.

Мондый хәлләрне күп күргән бүлек мөдиренең моңа аз гына да исе китмәде, белгеле.

— Эше булгач, җимеше дә була инде, матурым,— дип көлеп алды ул. Аннары кайгырмаска кушып: — Хуҗа белән сөйләшермен дә, бер чарасын күрербез,— диде.

Сабира «яңалыкны» кичекмәстән хуҗага җиткергән иде.

Икенче көнне үк Хафизов Венераны кабинетына чакырды.

— Синдәге яңалыкны Сабира Гаязовна әйтте,— дип башлады ул, канәгать елмаеп.— Була торган хәл, гүзәлем. Әмма рухыңны төшермә. Сабира Гаязовна белән сөйләштек. Ул нишләргә кирәк, бөтенесен белә, бер дә борчылма!

Шуннан соң, күпмедер вакыт узгач, Сабира аны, бер гинекологка алып барып, бала табудан коткарды.

Венера әнә шулай ирексездән һәрьяклап тәҗрибә туплый бара иде.

Хәзер, оялу-тартынуны белмичә, һәр мөмкинлекне үз ягына файдаланып калырга тырыша. Кирәк икән, Хафизовка шалтыратып әйтә дә өенә кайтып китә. Сату иткәндә дә кайда эшләргә җиңел һәм чумаралырак — ул шунда. Әйберләргә бәяләр күтәреләсен белеп, башка сатучылар аларны, соңыннан яңа бәядән сату өчен, өйләренә сумкалап ташыганда, Венераның аларны директор машинасына йөкләп төяп кайтарып килгән чаклары да аз түгел. Кыскасы, хәзер ул Хафизовка үзе генә бирмичә, аның үзеннән дә ала иде. Директор белән якын мөнәсәбәттә булганга күрә, хәзер хатыннар да аның белән бик сак һәм чамалап сөйләшә башладылар.

Ә өлкән сатучылыкка күтәрелгәч, хәтта Сабира да сагаерга мәҗбүр булды. Ул белә: Венера эшендә үсүгә бара. Сабира аны Хафизовтан ничек мәсхәрәләтүен дә һәм бу яшь кызның йөрәгендә нинди кара эз калдыруын да онытмый иде. Шуңа күрә Венера белән мөмкин кадәр сак булырга — аның белән алдын-артын чамалап сөйләшергә тырыша хәзер.

Венера исә, берәү белән дә каршылык-бәхәскә кермичә генә, һәрьяклап шомара, үткенләнә бара иде.

Табигать һәм тормыш ничек үзгәрүнең даими шаһите булып, вакыт ага бирә. Тагын җәй җитте. Бу — Венераның Казанга килеп эшли башлавына бер ел булды дигән сүз.

Ул, институтка имтиханнар тапшыру өчен, кирәкле кәгазьләрнең бөтенесен әзерләп куйган иде. Хафизов, вәгъдәсе буенча, ял атнасының беренче көнендә Венераны, машинасына утыртып, институтка алып китте.

Кояшлы матур көн иде. Янында чәчәк кебек матур яшь кыз утырып барган директорның йөзендә канәгатьлелек елмаюы.

Ул институтка килүгә, кабул итү комиссиясе утырган бүлмәнең ишеген ачып карады да:

— Хәзер комиссия рәисе чыга,— дип, Венераны читкә алып китте.

Алар коридор башындагы тәрәзә төбенә барып бастылар гына, бүлмәдән өстенә балкып торган импортный костюм кигән урта яшьләрдәге күзлекле кеше чыгып, үзе артыннан барырга баш изәде.

— Комиссия рәисе,— диде Хафизов.

— Аңладым,— дигәнне сиздереп алды Венера.

Комиссия рәисе бүлмәсен ачып аларны уздыруга, Хафизов белән кул биреп күреште дә:

— Бигрәк чибәр туташ алып килгәнсең! — дип, хәйләкәр елмаеп алды, Венерага баштанаяк күз йөгертеп.

— Күз тидермә тагы! — диде Хафизов моңа каршы һәм горур гына өстәп куйды: — Булгач-булгач, чибәрен сайларга кирәк.

— Килешәм, дөрес әйтәсең. Кая, кәгазьләрегез булганмы?

Венера:

— Рәхим итегез,— дип, документларын өстәлгә куйды да читкәрәк тайпылды.

— Так-так: бусы әйбәт, монысы да яхшы. Аттестатта «дүртле» дә «бишле» генә икән — бусы тагын да әйбәт! Документларыгыз булган — калдырыгыз. Үзем алып керермен. Чибәркәй, сиңа сүзем шул: абитуриентлар белән аралашып, консультацияләргә йөр. Анда яхшырак әзерләним дип баш ватуың не обязательно, күренеп йөрүең кирәк. Ә имтиханнар биргәндә, юри соңгылардан булып керерсең, аңлашылдымы?

— Аңлашылды.— Венера ягымлы елмаеп куйды.

— Димәк, борчылыр нәрсә юк, шулай бит? — диде Хафизов, сөйләшүне тагын бер ныгыткандай итеп.

— Юк. Чибәрең тиздән студент булыр, Радик Хафизович. Минем вакытым тар, хушлашыйк! Җаең белән, шушы арада шалтыратырсың әле.

— Обязательно! Әлегә сау булып тор!

Чыгып машинага утыруга, Хафизов, Венерадан сорап та тормастан:

— Әйдә, шәһәрдән чыгып, сахрада кинәнеп кайтыйк әле! — дип, машинаны чажлатып алып китте.

Венерага Хафизов белән кая барса да куркасы юк иде хәзер. Шулай да:

— Ул кешегә ышанып вакыт әрәм итеп йөргәнче, миңа имтиханнарга әзерләнә башлау хәерлерәк түгелме? — дигән булды.

— Борчылма! Минем аның белән беренче генә эш итүем түгел, сүзендә тора торган кеше. Сиңа, мәшәкать-борчылусыз рәхәтләнеп йөреп, имтиханнар җиткәч, ул әйткәнне эшлисе генә калды. Бөтенесе алдан сөйләшенеп хәл ителгән икәнне күрдең бит.

Шәһәрне чыгуга, Хафизов газга тагын да баса төште.

Тәрәзәдән кергән ягымлы кыр һавасы Венераның чәчләрен җилбердәтә. Күзгә кебек тигез юлдан илдереп барганда, яшелле-сарылы булып сузылып калган басу-кырларда ниндидер сихри матурлык бар кебек. Борынына бәрелгән хуш ис ләззәтеннән Венераның күзләре йомылып-йомылып китә иде.

Машина, асфальт юлдан чыгып, Чабакса күле ягына юнәлде. Зур булмаган арыш басуын кисеп үткән юлдан бишектә тирбәлгән кебек акрын гына чайкалып бару үзе бер рәхәт. Хафизов, шау чәчәкле аланчык читендәге култыкка кереп машинасын сүндерүгә:

— Рәхим ит, гүзәлем! — дип, ишекләрне ачып җибәрде.

Хуш истән баш әйләнерлек иде. Тирә-якта сайраган кошлар тавышыннан башка берни ишетелми.

Венера ашыкмый гына машинадан төште.

— Ай, нинди матур җир!..

— Әйтәсең бармы! Кара диңгез, Балтыйк диңгезе буйларыннан кай җире ким моның?! — диде Хафизов, кулларын җәеп.

— Күргәнем булмагач, әйтә алмыйм. Ә мондый матурлыкны беренче күрәм! — диде Венера.

— Диңгезне дә күрерсең, гүзәлем,— дип, Венераны кочаклап үбеп алды Хафизов.— Анда баруның планы күптән төзелгән. Син институтка урнашуга, отпускаларны алабыз да Кырымга йә Балтыйк буена курортка китәбез. Путевкалар мәсьәләсендә сөйләшенгән, тиздән кулда булачак. Мин сиңа бик күп нәрсәләр күрсәтермен әле, гүзәлем, так что...

Венера, иге-чиге булмаган диңгез киңлекләрен күз алдына китереп, елмаеп куйды.

Хафизовның бөтенесе алдан каралган иде. Ул багажниктан брезент чыгарып куак төбенә җәйде дә кыйммәтле шәраб, кызыл уылдык консервасы, шоколад, печенье һәм металл рюмкалар китереп:

— Эх, нинди романтика, ә! — диде, күлмәк-чалбарларын салып.— Чишен — тәннәрең рәхәтләнеп китсен!

Венера, алданып, күңеле катып, ояты качкан булса да, үзеннән күпкә өлкән, хатынлы ир алдында тугарылып ятарга тартына иде. Шулай да ул, бетәсе баш беткән инде дигәндәй, өске киемнәрен салып атып, табын әзерләргә тотынды. Сыйланып, иркәләнеп-назланып туйганнан соң, ялга туктадылар.

Җәймә читендәрәк Венера ята. Аның нәфис тәнле сылу гәүдәсенә, тырпаеп торган җыйнак күкрәгенә һәм матур йөзенә Хафизов кына түгел, кояш та сокланып карый кебек иде. «Бу гүзәл миңа гомерем буе рәхәтлек бирергә тиеш!» — дип уйлап алды һаман да Венерага нәфесләнеп яткан Хафизов.

Венера кырын яткан гәүдәсен матур гына җыя төшеп, терсәгенә таянган. Озынча муены буйлап аккошныкы кебек талгын гына түгәрәкләнеп килгән иңнәре аркылы зифа гәүдәсенә төшеп торган куе чәче аңардагы нәфислекне тагын да арттыра иде. Шәрык хатын-кызларыныкына тартым юка яфраклы борыны үзенә бертөрле матур. Өлгергән чия кебек мөлдерәп торган иреннәрен ачып, энҗе кебек тигез тешләрен ялтыратып көлеп йә елмаеп җибәрсә, йөзеннән нурлар чәчелеп китә!

— Белеп тор, моннан соң мин сине Афродита дип йөртәчәкмен,— диде Хафизов, Венераның тырпаеп торган йомры имиләрен сыйпап.

— Ник? Минем исемем ошамыймыни? — дип елмайды Венера.

— Ошый, гүзәлем, бик матур исем. Шулай да сине Афродита дип йөртәсем килә.

— Нинди исем соң ул, Радик Хафизович?

— Ташла инде миңа шулай эндәшүеңне, без эш урынында түгел ләбаса!

— Әй, Радик дип кенә әйтергә әллә ничек уңайсыз... Ярый, моннан соң, икәү генә булганда, шулай әйтермен. Әйдә, Афродитаны аңлатып бир, алайса!

Хафизов, иңсәсенә башын куеп яткан Венераның куе чәчләренә бармакларын тыгып, сөйли башлады:

— Бездә планеталарның берсен Венера дип йөртәләр, шулай бит?

— Әйе. Венераны безнеңчә Таң йолдызы да, Чулпан да диләр.

— Алай гына түгел, Зөһрә йолдыз да диләр әле. Борынгы римлеләр мифологиясендә Венера — матурлык белән мәхәббәт алиһәсе. Ә греклар-да ул шәхес Афродита исемен алган. Аларда ул матурлык һәм мәхәббәт алиһәсе генә булып калмыйча, мәңге яшьлек гәүдәләнеше дә. Афродита — күк алласы Уран кызы. Ул диңгез дулкыны күбегеннән яралган. Ягымлы җилләр аны Кибрис утравына китерә. Шунда диңгез дулкыныннан чыгуга, үзен канатлы үсмерләр чолгап алып, өстенә алтын тукымадан эшләнгән кием бөркәндереп, башына чәчәкләр такыясы кидерәләр дә Олимпка алып китәләр. Ул шулай балкып һәм хуш ис аңкытып торган

зиннәтле киемнәр киеп барганда, Кояш тагын да ныграк яктырта, чәчәкләр таҗларын ача, урманнан чыгып, киек җәнлекләр янына йөгерешеп киләләр, көтүе белән кошлар очып килә. Юлбарыс, пантералар килеп, сырпаланып иркәләнәләр хәтта! Афродита шулар чолганышында бөтенесен таң калдырып, горур басып атлап бара. Аның юлдашлары — үзенә хезмәт күрсәтүчеләре дә күңел ачу һәм матур йөрү алиһәләре. Афродита барганда, артыннан баскан җирендә чәчәкләр үсеп чыга хәтта!

Олимп аллалары аны сәламләп, зурлап каршы ала. Аңарда мәхәббәт шундый көчле була ки, ул хәтта аллаларда, үләчәк кешеләрдә ярату хисе уята! Мәңге матур һәм мәңге яшь мәхәббәт алиһәсе шулай балкып килеп, Олимп аллалары арасында мәңге яшәп кала.

— Әй, сөйләп тә карыйсың!..— дип куйды бу сүзләрне әллә нинди хыялларга бирелеп тыңлап торган Венера.— Әкият дисәң, әкият түгел, чын дисәң, чын түгел бу. Моны үз башыңнан чыгарып сөйлисеңме шулай?

— Миндә андый талант булса, бик ярар иде!.. Мин боларны китаптан укыдым. Болар бөтенесе синең чибәрлегеңә сокланудан искә төште. Әйтәм бит, моннан соң, үзебезнең арада, мин сине гел шушы исем белән йөртәчәкмен. Син — минем рәхәтләнеп туймас Афродитам хәзер, бел!

Хафизов, кайнарланып-дәртләнеп китеп, яңадан Венераны кочып алды...

* * *

Венераның кибеттә эшли башлавына бишенче ел инде. Ул, бу гомер эчендә бик күп нәрсәләрне күрергә-кичерергә өлгереп, сату эшендә дә яшенә караганда артыгы белән чарланып, шомарып бетте.

Институтта укуы да көйләнгән. Зачет-имтиханнарга әзерләнәсе бар дип борчыласы юк. Җаны теләгән вакытта гына бара да зачеткасына шәп билгеләрне генә куйдырып кайтып китә. Ул инде соңгы курста. Хәзер, товар белгече булып алгач, Хафизов махинацияләрендә, хисапчы белән бергә ялган документлар, актлар төзеп, ул да катнаша.

Соңгы елларда урынга менгән түрәләр һәм алар оештырган органнар тарафыннан төрле «эшмәкәрлек»кә яшел юл ача торган законнар чыга башлагач, Венера бу яктан тагын да шомара, остара төште.

Аның күзгә күренеп үсә баруын күреп торган Сабира: «Озакламый бу минем урынга басмагае?» — дип, көннән-көн ныграк шикләнә бара иде. Ниһаять, беркөнне, түзмичә:

— Синең эшләр хутта, дәрәҗәң үсә, синең белән мавыгып киткәч, Радик Хафизович безнең кебекләрдән читләшә дә башлады. Берни дә эшләп булмый, син яшь тә, чибәр дә шул...— дип төрттереп алды.

Венера Сабира белән директор арасында якын бәйләнеш барлыгын да, соңгы вакытларда Хафизовның аңа игътибары күзгә күренеп кимегәнне дә сизеп йөри иде. Бу сүзләрне ишеткәннән соң, Сабираның үзенә нинди кабахәтлек кылганын искә алып, йөрәгән әрнетерлек итеп әйтәсе килсә дә, түзеп калды. Бары, йөзенә аз гына да ачу чыгармыйча:

— Мин аны синнән тартып алмадым бит, Сабира апа. Мине син үзең аның куенына тыктың. Хәзер җәллисең, үкенәсең икән, ә? — диде.

— Хәзер миңа, картая башлаган кешегә, бик исе китми шул инде хуҗаның. Кемнәр белән генә иснәшмәгәндер ул... Миңа нинди генә төче сүзләр әйтми иде, тасма тел! «Мин сине әсирләнеп яратам. Син — дөнья гүзәлләренең берсе Данаяга охшаган, имеш. Икәү генә булганда, мин Сабира түгел, гүзәл Даная гына идем. Соры корт кебек согынны эчә-эчә дә, туйганнан соң, башкага күчә, паразит!

Боларны тыңлап, Хафизовның үзен дә Афродита дип йөртүеннән күңеле болганып киткән Венера:

— Шундый кеше икәнен белә торып, ничек мине аңардан мәсхәрәләргә вөҗданың җиткәндер, Сабира апа?..— дип әйтеп куйды.

— Минем урында үзең булсаң, нишләр идең икән? — дип акланмакчы булды Сабира.

— Юк инде, байлык-акча дип, кешегә андый вәхшилекне эшлимме соң, Сабира апа! Бу — чамасыз түбәнлек бит.

— Әйтергә ансат,— дигән булды Сабира, сүзен бирәсе килмичә.— Яшәргә кирәк бит... Аның белән бәйләнүдән зыян күрәсеңме әллә? Үзенә туктаусыз булышып тора. Әгәр ул ярдәм итмәсә, болай җиңел генә институтка кереп, шундый кыска вакыт эчендә товар белгече була алыр идеңме? Болай барса, тиздән бүлек мөдире булып куюың да бар әле...

— Урыныңа утырмам, Сабира апа, курыкма. Күтәрелгән очракта синеке кебек урыннар башка кибетләрдә дә табылыр.

Сабира күптән күңелен тырнап торган сүзне әйтеп, Венерадан шундый җавап ишеткәч, эчтән генә: «Ярый, колагына вакытында төшереп яхшы иттем әле!» — дип куанып алды.

Арада бер мәлгә сөйләшергә сүз бетте, әйтерсең. Һәркайсы, үзалдына уйланып, тынып калды.

Венера бәхетсезлеккә таруына апасы Мәрьям, Сабира белән Хафизов сәбәпче икәнне тәмам аңлап бетергән иде хәзер.

Мансур белән арасын өзеп елдан артыграк вакыт узгач, ул Мөнәвир исемле егеткә кияүгә чыккан иде. Ире, техникум тәмамлап, заводта мастер булып эшләүче, эчми-тартмый торган акыллы егет иде. Әтиәниләре дә әйбәт, кешелекле кешеләр иде. Ләкин түбән җанлы Хафизов яшь чибәр Венераны шул хәлдә дә тынычлыкта калдырырга теләмәде. Ул аңа бизәргә, араны өзергә ирек бирмичә, әрсезләнеп, йөрүен белә. Кызганыч ки, бу вакытта Венераның да иркәләргә оста Хафизовтан бөтенләй аерылып бетәсә килми иде. Алар: «Базага барып киләбез»,— дигән булып машинага утырып китәләр дә Сабира фатирына баралар иде.

Көннәрнең берендә Мөнәвир, Венераның хыянәт итүен сизенеп, алар шунда бикләнеп зина кылып яткан чакны туры китергәннән соң, Венераны өеннән куып чыгарды һәм тиз арада аерылышып та куйды.

Бу вакытта, аборт ясатырга теләсә дә, соң иде инде. Аның кызы туды. Шулай итеп, Венера, Хафизовның тырнагыннан ычкына алмыйча, балалы хатынга әйләнде.

Шушы хәлләрне йөрәк әрнүе белән күз алдыннан кичергәннән соң, Венера:

— Акча дип, мине бәхетсез итәр өчен нык тырыштың инде, Сабира апа, рәхмәт,— дип әйтеп куйды.— Мин директорның күңелен күрүче бер курчак кына бит хәзер.

— И-и, юкка үзеңне түбәнсетәсең, матурым! Бөтенесе сатыла, акчага алыштырыла торган заманда син югалткан әйбер нәрсә генә ул!.. Хуҗа чибәрлегең белән яшьлегеңә табынып үзеңне канат астында йөртә икән, аны рәхәтләнеп файдаланып калуыңны бел. Үзеңә бер дигән фатир алып бирде. Моны кем күргән? Синең кебекләрнең кайсы шулай җиңел генә фатирлы булган әле?

— Өеңдәге әйберләрне күргәч, белдем, син яшьлегең белән элекке матурлыгыңны начар файдаланмагансың, Сабира апа,— дип төрттереп алды Венера.— Тик, акча-байлык дип, яшьләрне директор астына тыгу белән шөгыльләнмәскә кирәк иде. Бу — бик зур гөнаһ бит.

Сабира моңа каршы ни әйтергә дә белми торганда, Венерада аның белән директорга карата җирәнү булып алды хәтта.

Шулай булмаслык та түгел бит. Сатучы хатыннарның берсе пенсиягә чыгып эштән китүгә, аның урынына Мәрдия исемле нәкъ Венера кебек бер яшь кызны алдылар. Күп тә үтми, Венера Сабираның аны да үзе кебек Хафизов корбаны итәргә маташуын сизеп алды. Һәм, кешегә сиздерми генә, моны кызның колагына төшереп, теге, кичекмәстән гариза язып, кибеттән китеп барды.

Венера белән Сабира арасындагы сөйләшү икесе өчен дә күңелле сөйләшү түгел иде бүген. Шуңа күрә алар озакламый сүзне дә бетерделәр.

## 5

Беркөнне директор Венераны кабинетына чакырып:

— Мин сиңа әйткәннәрнең бөтенесен үтәп барам, шулай бит, Афродита? — диде.

Венера моңа каршы, ягымлы елмаеп:

— Әйе, рәхмәт яусын инде, — дип җавап кайтарды да шундук сорау да бирде: — Ник алай дисең, миннән канәгать түгелсеңме әллә?

— Синнән дә канәгать булмасам!.. — Директор, күзләрен майландырып, Венераның билен сыйпап алды. — Киресенчә, син — минем иң зур рәхәтлек бирүчем. Шуңа күрә гел яхшылык эшләп, куандырып торасым килә үзеңне.

— Рәхмәт инде! Тагын нинди яңалык бар?

— Син ун айдан соң кулыңа диплом аласың, шулай бит?

— Әйе.

— Ә бу — сиңа үсәргә мөмкинлекне тагын да арттыра дигән сүз.

— Әллә инде?..

— Әллә инде түгел, арттыра. Мин бу турыда хуҗалар белән күптән сөйләшеп килә идем. Мәскәү районында эшләр өчен уңайлы зур гына бер кибетнең директоры пенсиягә китәргә җыена. Мин шуның урынына синең кандидатураны тәкъдим итеп, хуҗа белән сөйләштем. Үзеңне алып килеп күрсәтергә кушты. Алдагы атнаны аңа барабыз, белеп тор. Эш барып чыгарга тиеш, так что...

Венера, яңалыкны ишетүгә, эченнән генә: «Гайбәтчеләр оясыннан китеп үземчә эшли башласам, әйбәт булыр иде!» — дип куанып алса да, икеләнгәндәй:

— Директор булып эшли алырмын микән? — дигән булды.

— Урнашып алсаң, эшли алмыйсыңмы соң! Анда күчеп китсәң дә янында мин буласын онытма! Мөмкинлекне ычкындырмаска кирәк, шул гына!

— Сизәм, яңа сөяркә тапкансың да миннән котыласың килә, дигән булды Венера, күңелсезләнеп киткәндәй итеп. — Шулай булгач, аерылу икебез өчен дә хәерлерәктер, мөгаен.

— Әй, юләр баш! Синнән туеп башкаларга карыйммы соң! — дип, торып, Венераны үбеп алган булды Хафизов. — Син — минем татлы Афродитам бит! Сине үстерәсем килә. Ул кибетнең урыны да уңайлы җирдә, керем өчен мөмкинлекләре дә зуррак, беләсең килсә. Сер итеп, шуны да әйтим инде, Торг хуҗасының урынбасары җәмәгать туклануы системасына күчәргә йөри. Ул китсә, аның урынына мине куюлары бар. Шулай барып чыкса, безнең эшләр тәмам колачланып китәчәк әле!..

Чынында Хафизовның максаты — беренчедән, Венераны үзеннән ераклаштырып, кибеткә яңа бер яшь кыз алу һәм аны үзенең сөяркәсе итү булса, икенчедән, Венераны кибет директоры итеп, үзе Торг башлыгы урынбасары булып алганнан соң, әвеш-тәвешне тагын да киңрәк җәелдерү иде.

— Син — зур тәҗрибәле җитәкче. Шуңа күрә синең киңәш — миңа закон, — дигән булды Венера. — Димәк, алдагы атнаны Торгка барабыз.

— Әйе. Мөмкинлекне һич тә ычкындырмаска кирәк. Тик, кара аны, шеф алдында күз уйнатып боргаланасы булма! Юкса ул сиңа тамгысын суза башлаячак.

— Әй, юкны сөйләмә әле! — дигән булды Венера.

## 6

Венера директор булып күчкәнче үк, «кара эшләр» белән кул пычрата башлаганчы, кул астымда буласы кешеләр нинди икәнне белергә, ышанычлы булмасалар, беренче чиратта шулардан котылырга кирәк, дип уйлап куйган иде. Шуңа күрә директор булуга, эшен үзенең ярдәмчесен һәм хисапчы белән товар белгечен сынаудан башлады. Башта: «Мин бүлмәдә генә утырып эшли торган кеше түгел. Миңа кичкенә бүлмә дә җитә»,— дип, иркен директор кабинетына товар белгече белән хисапчыны күчереп, үзенә аулак почмактагы Хафизов бүлмәсенә охшаш кетәкне алды. Шуннан соң кибет тирәсендә чуалучы, кибеткә бәйләнешле милиция хезмәткәрләре белән танышып элемтәгә керү иде исәбе.

Күрде: мондагы сатучылар да әвеш-тәвеш дигәндә үзе эшләп киткән кибетчеләрдән ким түгел икән. Ярдәмчесе һәм товар белгече, хисапчысы да теләсә нинди махинациягә әзер икәнлекләрен сиздереп торалар иде.

Шушыларны ачыклауга, Венера, Хафизовтан өйрәнгәннәргә үзе белгәннәрне дә өстәп, колачлап эшкә кереште.

Моңарчы кибеткә әйберләр башлыча сәүдә идарәсе аркылы яшелчә-җимеш базаларыннан, ит комбинаты һәм колбаса заводыннан китерелә иде. Ә Венера, болар белән генә чикләнмичә, турыдан-туры колхоз-совхоз басуларыннан китереп тә саттыра башлады. Алар гына түгел, кыска гына вакыт эчендә Урта Азия, Кавказ сәүдәгәрләре белән дә элемтәгә кереп өлгерде хәтта. Кибеттә бөтен әйбер тулып тора хәзер. Аларның бер өлеше, бернинди исәп-хисапка алынмыйча сатылып, акчасы «поставщиклар» белән Венера арасында бүленеп бара. Документ буенча китерелгәннәре дә, юлдан үтеп, җепнең очы товар белгече белән хисапчы тарафыннан суга төшерелеп бара.

Венера үз кул астындагы кешеләрнең бөтенесенә игътибарлы. Ярдәмчесеннән алып җыештыручыга кадәр, хезмәткә керткән өлешенә карап, «өстәмә» чыгарып бара. Ул шул юл белән кибет коллективын кыска гына вакыт эчендә бер дигән шәп йодрыкка әйләндерде. Шуңа күрә бәяләр күтәрелү турында үзеннән сигнал булуга, әйберләрне, соңыннан китереп югары бәядән сату өчен, кайсы-кая дәррәү ташып, яшереп тә өлгерәләр. Венерага акча да учлап кына түгел, янчыклап керә хәзер. Ә Хафизов башта Торг директоры урынбасары, аннары директоры булып алганнан соң, колач киңәеп, акча тагын да күбрәк агыла башлады.

Кешегә акча чире йокса, шулай бит: ул, комсызланып китеп, аны торган саен күбрәк җыярга тырыша башлый. Венера белән дә шулай булды. Кибет директоры булып егерме елга якын эшләү дәверендә ул бик күп акча тупларга, мал җыярга өлгерде. Аның ике «Волга» машинасы алып куюы да акчасын кая куярга белмәгәннән генә иде. Тик менә юньләп аларның куанычын гына күргәне юк әле.

## 7

Иртән, кешеләр эшкә китеп йорт тирәсе тынып калуга, почмактагы агачлар ышыгына ниндидер җиңел машина килеп туктады да, шуннан таныш булмаган ике кеше чыгып, Венера торган подъездга юнәлде.

Аларның берсе букет тоткан. Икенчесенең кулында дипломат. Букетлы кеше соргылт төстәге күн куртка кигән. Башында кояштан саклый торган озын козыреклы импортный чуар картуз. Джинсы чалбардан, аякларында кроссовкага охшаш ботинкалар. Күксел күзлек кигәнлектән, йөзен аерырлык та түгел иде. Икенчесенең өстендә яшькелтрәк джинсы

костюм, башында киң читле эшләпә. Борын астындагы кара мыегы болай да зур булмаган йөзен тагын да ямьсезли, әйтерсең.

Кыяфәт-йөрешләренә караганда, икесе дә урта яшьтәге кешеләргә охшый.

Өченче катка күтәрелүгә, аларның берсе тиз генә күзлеген салып кесәсенә тыкты да кыңгырауга басты. Шул арада иптәше дә мыегын куптарып алып яшереп өлгергән иде. Анысы, эчтән караган кеше күрмәсен өчен, ишектәге күзчектән читкә китеп басты.

— Өйдә булса ярый ла.

— Булыр, кая китсен әле.

Озак көттермәстән ишек ачылып, Венера күренде һәм әлеге кешеләр, ягымлы елмаеп, эчкә уздылар.

— Иртүк визит ясавыбыз өчен гафу ит, Венера Кәримовна.

— Зыян юк, рәхим итегез,— диде Венера, йөзенә канәгатьсезлек чыгармый гына.

— Бу сиңа шефтан,— дип букетны Венерага тоттырды ирләр.— Персональ бүләк.

— Рәхмәт инде.— Хафизовтан булганлыктан, аның ихлас күңелдән җибәрелмәгәнлеген Венера яхшы белә иде. Шуңадыр, ахры, чәчәкләрдән бөркелгән ис кан исе сыман күңелен чиркандырып, үзен тагын да сагайта төште.— Нинди уңайдан бу?— диде ул, йөзенә ясалма елмаю чыгарып.

— Радик Хафизович анысын әйтмәде. Аның белән сез бик якын дуслар бит, үзегез беләсездер.

Венера чәчәкләрне, сулы вазага тыгып, өстәлгә куйды.

Ирләр аның салкын карашын сизеп торалар иде.

— Күрәбез, безнең килү сезне артык шатландырмый, Венера Кәримовна,— диде аларның берсе.

— Шатландырырга, изге ният белән түгел, сатулашырга килгәнсез бит.

— Әйе. Бераз Радик Хафизович гозерен үтәүчеләр бүген. Аның ни теләгәнен — үзеннән нәрсә таләп иткәнен яхшы беләсең. Әгәр аны канәгатьләндерсәң, безгә дә күңелле булыр иде.

Моны ишеткәннән соң ачуы йөзенә бәреп чыкса да, Венера, аны сиздермәскә тырышып, елмаеп куйган булды.

Аңа букет тотып килгән кеше — район сәүдә идарәсенең тәэминат башлыгы Барлас Рафиков. Ул — Хафизовның якын дусты. Ә икенчесен, кавказ кешесенә охшаганын, Венераның беренче күрүе иде.

Рафиков шәһәр мафиясе арасында рядовойлардан гына түгел. Шуңа күрә кемнәр нәрсә болгата, ничек казна белән халык байлыгын талый — бөтенесен биш бармагы кебек белә. Кемнән дә булса үч алырга йә кемне дә булса юлдан алып ташларга булса да, арадашчы булып, кем файдасынадыр сүз алып барырга дигәндә дә аңардан остарак, хәйләкәррәк кеше юктыр.

Кичә, Венерага басым ясап та теләгенә ирешә алмаган Хафизовның бүген сөйләшергә аны җибәрүе дә юкка гына түгел иде, билгеле. «Ни дип, ни өчен Рафиков белән бу ят кешене дә җибәрде икән Хафизов?— дип эчтән генә баш вата иде Венера.— Кем булыр бу? Минем турыда барын белгән кебек сөйләшкән була, җитмәсә. Ник Рафиков аның белән таныштырмый икән? Хәер, һәрхәлдә, аңардан шикләнеп сөйләшүнең мәгънәсе юктыр хәзер...»

Торг директоры да булып алгач, Хафизовның борыны маңгаена күтәрелгән иде. Ул хәзер ни тели — шуны эшли. Кая барса, шунда сүзе үтә. Инде олыгаю ягына авышуга карамастан, әле һаман берничә хатын-кыз белән өстерәлүен дәвам итә. Заманы шундыйга киткәч, түрә кешеләргә андый мөмкинлекләр тагын артты бит. Яңа гына уку йортларын тәмамлаган япь-яшь кызларның күбесе, тизрәк күтәрелү өчен, җитәкче кешеләргә тән сатудан да тартынып тормыйлар. Торг кәнәфиенә менеп утыргач, Хафизовка үзеннән унтугыз яшькә кече һәм сокланып

туймаслык чибәр Венера да карт күренә башлаган иде. Шуңа күрә ул, аның белән уйнаш итүен ташлап, «бизнес»ка күбрәк игътибар бирә төште. Шулай комсызланып китте ки, берьюлы әллә ничә кибеттән ришвәт алып ятуына карамастан, аңа һаман аз тоела. Хәзер Венераның керемнәренә дә көнләшеп карый һәм ул биргән ришвәтне гел азсына, гел канәгатьсезлек күрсәтә иде.

Рафиков белән иптәше өстәл артына килеп утыруга, Венера коньяк, кабымлыклар һәм рюмкалар китереп куйды.

— Рәхим итегез! — диде ул, үзе дә утырып.

— Мондый чакта житди темага кагылып та тормаска иде югыйсә,— дип, шешәне ачты Рафиков.— Хөрмәтле Радик Хафизович сорагач, сөйләшергә туры килә.

— Сез вәкилләрне җибәрмичә үзем белән генә сөйләшсә, ни булыр иде? Без бер-беребезне белмәгән кешеләр түгел бит,— диде Венера, рюмкасын бушатып куйганнан соң.

— Алай дисең дә, кичә сөйләшүегез барып чыкмаган бит, Венера Кәримовна. Шуңа күрә бүген безне җибәрде Радик Хафизович.

— Иптәшең белән таныштырмадың да, Барлас Сафиярович. Ачыктан-ачык сөйләшергә уңайсыз.

— Бу иптәш чит илдән. Сәүдә буенча килеп йөрүче Сурен Ардарович була. Ул Радик Хафизович аркылы синең турыда шактый хәбәрдар кеше. Иртән Радик Хафизовичта очраштык та, шунда гәпләшеп алганнан соң, сиңа икәүләп килергә булдык. Сурен Ардаровичтан шикләнмичә сөйләшә аласың, ул — безнең кеше.

— Әйе, әйе! Шулай булмасам, мондый сөйләшүгә мине җибәрер идемени Радик Хафизович! — дип җөпләргә тотынды тегесе.— Ул сезне аерым бер хөрмәт һәм ярату белән телгә ала. Сез, чыннан да, нәкъ ул сөйләгәнчә чибәр икәнсез. Яшьрәк чагыгызда сезгә күңеле төшмәгән егет булмагандыр!

— Йәгез, нәтиҗәле сөйләшү өчен күтәрик әле! — дип эчеп җибәрде Рафиков. Һәм лимон телемен суырып ташлады да дәвам итте: — Әйе, һәрнәрсәнең үз чоры, үз вакыты була дигәндәй, матурлык белән мәхәббәт тә мәңгелек түгел шул. Венера Кәримовна белән Радик Хафизовичның арасы суынмаса, шундый дәгъвалашуга барып җитәрләр идемени. Венера Кәримовна үзенең яраткан кешесенә — шефына шулай каршылык күрсәтер идеме?..

— Ничек каршылык күрсәтмәскә, ул минем еллар буе эшләп җыйган акчама алган машинам белән гаражымны таләп итә бит. Ни өчен шулкадәр комсызланадыр, белмим. Югыйсә миннән башкаларны да аз сыкмый бит ул. Ә миңа замымнан алып кибет тирәсендә иснәнеп-ялманып йөрүчегә кадәр өлеш чыгарырга кирәк. Шуннан соң күпме кала?.. Ә шуны белә торып, каныкты үземә.

— Сүз дә юк, Радик Хафизовичка солидный «взнос» кирә,— диде Рафиков, рюмкаларны яңадан тутырып.— Тик кереме нинди булса, чыгымы да шундый бит аның.

— Әйе, әйе, аңардан югарыда утыручыларның аппетиты да икенчерәк шул...— дип кеткелдәп, Рафиковны куәтләде иптәше.— Шуңа күрә Радик Хафизович таләп иткәнне юкка күпсенәсез.

— Мин ул машина өчен күпме көч, күпме акча түкмәгән!..— Венера, ирләргә карап тормастан, рюмканы бушатып куйды.— Ә бит аның гына түгел, минем дә кешечә яшисем килә.

Венераның тәлинкәдәге апельсиннарны гасабиланың кисүен күргән ирләр:

— Кая, көйрәтеп алыйк әле булмаса. Ә син уйлый тор,— дип, урыннарыннан кузгалдылар.

Венера, барып, балкон ишеген ачып:

— Әнә, тартыгыз шунда,— диде дә кухняга кереп китте.

— Рәхмәт.

Бу арада борчылып һәм нервыланып туктаусыз эчкәнгә күрә, йөрәге кагып, кан басымы күтәрелгән иде Венераның. Ул эчүне туктатып, тәмам савыкканчы авызыма грамм да алмам дисә дә, һаман эчәргә туры килә. Һаман шул акча-мал өчен. Бүген үзен үгетләргә, ихтыярын сындырып Хафизов теләгән үтәргә күндерергә килгән ирләр алдында йомшаклык күрсәтмәс өчен эчә.

Ирләр, көйрәтеп алганнан соң, яңадан өстәл янына килеп утырдылар.

— Күрәбез, үзеңнекеннән кайтасың килми, Венера Кәримовна,— дип, сүзне яңартып җибәрде Рафиков.— Ә бит Радик Хафизович, ачуланса, бик каты бәгырьле икәнне беләсең. Ул, тотса, сындырмыйча туктамый.

— Беләм, бик яхшы беләм. Ул минем бөтен яшьлегемне — бәхетемне алган кеше,— диде Венера, ачынып.— Алай да күзе туймый, хәзер малымны таларга тотынды.

— Юкка ярлыланасың, Венера Кәримовна.— Рафиков, үзен ничек кысып китергәнне күреп тор дигәндәй, иптәшенә карап алып, дәвам итте: — Син үзең машина йөртмисең. Хәзер инде, кырыктан узганнан соң, аны йөртергә өйрәнеп тә тормассыңдыр дип уйлыйм. Шулай булгач, нигә артык сатулашырга, гаражы белән машинаңны бир дә тынычлап кал.

— Юк, бирмим! Мин аның үзе белән тагын күзгә-күз карап сөйләшәм әле,— диде Венера, үҗәтлек күрсәтеп.— Туйдым, муеннан гарык, кибетеннән дә китәм. Башка җирдә, акчасы булмаса, җаным тыныч булыр, ичмасам.

— Күрәм, җиңел генә чыгармын дип уйлыйсың икән уеннан,— дип кеткелдәп алды Рафиков.— Ялгышма, Венера Кәримовна.

— Чыкмасам, калырмын. Миңа машина йөртә белмәсәм дә ярый. Ул кызым белән оныгыма дип алынган.

— Аларга бер «Волга» җитмимени?

Моны ишетүгә, «Барын белеп торалар икән бәдбәхетләр!» — дип уйлап алган Венера, рюмкасын бер сулышта бушатып:

— Машинамның икенчесен сатып, акчасына төзелеп яткан өйне эшләтеп бетерергә кирәк,— дигән булды.

— Беләбез, беләбез. Аны, машинаңны сатмыйча да, шаярып кына эшләтеп бетерә аласың — керемең аздан түгел!..

— Кешенекен тикшереп йөрү — түбәнлек! Мин кем күпме үзләштергәнне барлап йөрмим. Радик Хафизовичка әйтегез, аңа бирерлек малым юк! — диде Венера, кистереп.

— Син аның сөяркәсе булганың өчен генә дә болай карышмаска тиеш идең югыйсә,— дип елмайган булды Рафиков моңа каршы.

— Яраткан сөяркәдән болай көлмиләр. Хафизов астында булып ташланганнар да, әле ятучылар да бер генә түгел. Шуңа күрә мин аның бер корбаны гына. Аның курчагы булып, күңелен аз күрмәдем — житәр. Аңа бирер бер нәрсәм дә юк хәзер.

— Әйтәм бит, болай гына уеннан чыга алмассың дип.

— Чыкмасам — төрмәгә тыгарлар. Тик белсен, анда Хафизовичка да урын җитәрлек... Кая, шалтыратып әйтим әле үзенә!

— Мәшәкатьләнеп торма! — дип, Венераны туктатып калды Сурен Ардарович дигәне.— Ул: «Бүген эш урынымда булмыйм, шәһәрдә йөрисем бар»,— диде.

Шуннан соң, ирләр, башка сөйләшеп торуда файда юк дигәндәй, бер-берсенә карашып иннәрен җыерып алдылар да:

— Ярый, алайса. Без машинаңны көчләп алырга килмәдек, Венера Кәримовна,— диде Рафиков, урыныннан кузгалып.— Безгә бу сөйләшүне Радик Хафизовичка кайтып җиткерәсе генә калды.

— Әйе, әйе, Барлас Сафиярович: без миссиябезне үтәдек,— дип өстәде иптәше.

Венера, караңгы чырай күрсәтмәскә тырышып:

— Мин Радик Хафизович белән тагын бер сөйләшәм әле,— дип, ирләрне озатып калды.

Коридорга чыгып бер этаж төшүгә, Сурен Ардарович дигән кеше ясалма мыегын яңадан ябыштырды да эшләпәсен батырып киеп куйды. Барлас Сафиярович та караңгы күзлеген киеп өлгергән иде инде.

Алар, подъездан чыгуга, кызу-кызу атлап машиналары янына килделәр дә китеп бардылар.

8

Венера, Хафизов җибәргән кешеләр алдында үзен кыю тотса да, тирән шиккә, куркуга төшкән иде. Ирләр белән бертигез эчүгә карамастан, башында берни юк. Әйтерсең, хәмер дигән нәрсә парга әйләнгән. «Ничек бу Хафизовтан котылыйм инде? — дип баш ватарга тотынды ул. — Җаһилнең дә җаһиле икән, елан! Дөрес әйтәләр, ул шәһәрнең иң зур түрәләре, милиция җитәкчеләре белән бер мафиядә бит. Шулай булгач, каршы тора аламмы соң мин аңа? Юк, булмый. Эх, «аңа бирерлек малым юк» дип кисеп әйтми торырга кирәк иде мин юләргә! Ярар, тагын бер уйлап карармын дип тәгаенлек күрсәтмичә сузарга кирәк иде. Хәзер миңа кичекмәстән нәрсә дә булса эшләп калырга кирәк! Әллә хәзер үк секретарена шалтыратып: «Радик Хафизовичка әйт, ул теләгән нәрсә була», — дип шалтыратыргамы? Бирергә кирәк машинаның берсен — күзенә капლансын. Шунсыз котылдырмас бу. Ничек янаган була Рафиков: «Уеннан болай гына чыга алмассың», имеш. Әйтерсең мин кеше үтерүчеләр арасында. Алар гына бер-берсе белән шулай сөйләшә бит. Шулкадәр астыртын кеше булыр икән!... — дип иңрәп куйды Венера, Хафизовның Чабакса күле янындагы төче сүзләрен исенә төшереп. — Мондый кабахәтләргә аз гына да кеше рәнҗеше төшми микәнни?»

Җанын кая куярга белмәгән Венераның Сабира белән Хафизовка гына түгел, үзен сату эшенә көчләп урнаштырган һәм кибеттәге пычрак эшләрне күреп китәргә карар кылгач та җибәрми калган апасы Мәрьямгә дә нәфрәте кайнап тора иде. «Ул медицина хезмәткәрләре начар торалар дип әйткәч тә, аларның берсе дә ач та, ялангач та түгел. Булганы белән рәхәтләнеп яшиләр — җаннары тыныч, ичмасам. Ә мин кеше күзенә күренә алмыйча, директорның себеркесе булып, яшьлегемне уздырдым. Бөтен бәхетемне алу гына җитмәгән: «Минем сөяркәләрем бары тик мине генә канәгатьләндерергә тиеш», — дип, җыйган малымны да талап алмакчы, хәсис!

Хафизов белән йөреп азу-тузуның ни икәнен аңлаган Венера, директор булып алганнан соң, үзе дә аңа гына карап тормады, билгеле. Керемле әйберләрне кибеткә күбрәк кайтартырга кирәккәндә, кешеләренә карата тән җылысын да жәлләп тормый иде.

Җаны утлы табада пешкән кебек өзгәләнгән Венераның күз алдына яңадан Хафизов корбаны булудан котылып калган Мәрдия килеп басты. Менә ул кеше сүзенә карамый торган нык характерлы, ичмасам! Алда нинди бәхетсезлек буласын белеп алуга, кибеткә төкереп китте дә тегү фабрикасына барып урнашты. Хәзер — бер дигән тегүче мастер! Иргә чыкты. Ире белән матур итеп яшәп, ике бала үстерәләр. Ә мин, кеше сүзен тыңлап, нинди түбәнлеккә төштем!.. Ни ашарга, ни киярга теләсәм — шул бар. Ә бернинди куаныч-канәгатьлек юк. Җитмәсә, үз шәүләңнән үзең куркып яшә — тормышмыни бу?!

Венераның бәхетле чаклары исенә төште.

Тугызынчы классны тәмамлаган елы. Сабан туе җитеп килә. Университетның беренче курсын тәмамлаган Мансур каникулга кайткан.

Венера авыл тегүчесе тегеп биргән чәчәкле күлмәген киеп очрашуга килгәч: «Син бүген, әйтерсең, күбәләк, Венера!» — дип, Мансурның исе китте. Хәтта Сабан туенда йөргәндә дә үзенә бер генә сокланмады ул. Шул көннәрдә нинди бәхет хисе кичергәнен Венера үзе генә белә! Хәзер кигән киемнәренең берсе генә дә ул вакыттагы киемнәренең бөтенесенә

торадыр! Ә шуларның бернинди матурлыгын күрми, бернинди шатлыгы юк. Киресенчә, кеше өлешенә кереп җыйган акчага алынганга, күңеленә шом салып торалар әле. Әгәр өен тутырып торган әйберләрне хәләл акчага гына алган булса, алар шатландырмаса да, үзенә канәгатьлек бирер иде.

Аптыраудан йөренә торгач, Венера китаплар шкафы өстендәге рәсемгә — алдына кечкенә нәниен утыртып төшкән кызы Рәсимәнең фотосурәтенә төбәлеп калды.

Тормышы мул булганлыктан, ул аны уч төбендә генә үстергән кебек үстерде. Рәсимәнең җаны ни теләсә шул бар иде. Укуга сәләте уртача гына булса да, акча төртеп институтка кертеп, дипломлы экономист итте.

Рәхәттә генә үскәнгә, Рәсимә артык иркә, чамасыз һавалы һәм җенси яктан да үзен йөгәнсез тота иде. Шуңа күрә, бер дигән акыллы егеткә кияүгә чыкса да, торып китә алмады. Аның да аерылганнан соң туган буласы үсә. Фазыл исемле борчак кебек тере малай. Өч яшь инде үзенә.

Венераның бар карап торганы, җыйган байлыгының варислары — кызы да шул оныгы гына. Акча очсызланганда да бәясен югалтмый дип, гаражлары белән алып куйган ике машинасы да, әле торып ята торган мул җиһазлы, эре габаритлы өч бүлмәле квартиры да аларга булачак. Ә үзе, картлык көнендә иптәш булырдай кеше табып, киләчәктә шуның белән шәһәр янәшәсендә төзелеп ята торган коттеджга күчәргә исәпли. Кыскасы, Венераның үзе өчен дә, кызы белән оныгы өчен дә гомер буе рәхәтләнеп яшәрлек итеп бөтенесе булдырылган иде. Әмма татлы хыяллары урынына ачы кайгы килде. «Кызым белән оныгымның да бәхете юк микәнни, ичмасам?» — дип ачынып куйды ул. Һәм эче янудан аптырап, барып, телевизорны җибәрде. Анда ниндидер мафияләр арасындагы акча, алтын өчен барган дәгъвалашуны күрсәтәләр иде. Җан ачуы белән: «Үзем дә моңардан гарык!» — дип, розеткадан шнурны тартып алды ул.

Йөрәге әле күкрәген бәреп чыгардай булып атлыгып тибә, әле менә-менә туктарга торган кебек тибүен акрынайта башлагач, Венера дару эчте.

Соңгы тапкыр күренгәндә, табиблар аз гына да эчәргә ярамаганны әйтеп җибәргәч, ул чынлап саклана башлаган иде. Хафизов белән машина өчен дәгъвалашу киткәч, ирексездән яңадан эчәргә тотынды. Кыюлык өчен дә, нервысын басар өчен дә, кайгы-кичерешеннән дә эчә.

Йөрәк тибеше күтәрелгән Венера, су алып нитроглицерин йотып җибәрде дә стенканың аскы тартмаларын актарырга тотынды. Аларда кирәк булуы бар дип, дарулар ясый торган заводта эшләүче таныш хатыны аркылы табып яшереп куйган наркотик белән агу саклана иде.

Ниһаять, кечкенә тартманы табып, пакетны чыгарды. Аның эчендә баш бармак кадәр генә кара шешәдә агу иде. Венера шуннан кәгазьгә шикәр вагына охшаган порошокны бераз гына агызып, төбәлеп калды. «Менә нинди икән ул кечкенә чеметеме дә мизгел эчендә теләсә кайсы җан иясенең гомерен кисәргә җитә торган нәрсә!» Ул шулай уйланып торганнан соң, кәгазьгә тагын бераз өстәде дә калганын яңадан яшереп куйды. «Мин ашыгырга — Хафизовтан алдарак өлгерергә тиеш!» — дип пышылдады ул, телефонга килеп. Торгка шалтыратты, Хафизов юк иде. Бераздан тагын шалтыраткан иде, секретаре аның бүген эш урынында булмаячагын әйтте. «Сизәм, секретарена мин сорасам, урынында булса да, «юк» дип әйтергә кушкан. Мин сине табарга тиеш, Радик Хафизович, табарга! Минем болай гына җинелеп каласым килми. Кая, потрошительгә шалтыратыйм әле тизрәк: аңа да задание бирергә кирәк».

Потрошитель дигәне ике-өч тапкыр төрмәдә утырып чыккан бер башкисәр иде. Венера директор булып күчеп йөргәндә, бу кешенең беркайда да эшләмичә, кибет тирәсендә чуалып, сатучылар белән салырга яратучылар исәбенә тукланып һәм эчеп йөргән чагы була. Ул, Венера эшне кабул итеп алуга, туп-туры аның кабинетына кереп:

— Мин сезгә йөкче булып урнашырга телим. Алсагыз — ялгышмассыз,— диде.

Венера мондый кешеләрне кибет тирәсеннән биздерергә куркыныч икәнне, алар белән дуслашсаң, кирәккәндә үзләрен матур гына файдаланып булуны да белә иде. Ул, җавап бирергә ашыкмыйча, тынып калгач, рецедевист аңлатырга тотынды:

— Мин кибеттәге бөтен кара эшләрне күреп-белеп торам. Шулай булгач, мин кирәкле органнарга моны сиздермәс өчен, мине болай да туйдырып, эчереп тотачаксыз. Алай иткәнче, иң яхшысы — мине эшкә алу. Ул чагында, беренчедән, мин сезгә хезмәт итсәм, икенчедән, ышанычлы таянычыгыз, яклаучы-саклаучыгыз була алам.

— Минем андый кешеләрем бар — курыкмыйм,— дигән булды Венера. Аннары уйлап кына, төп фикерен ача башлады: — Таянычсыз эшләү авыр, дөрес әйтәсез. Хәзер миңа да яңа урында яңа кешеләр табарга кирәгер дип уйлыйм. Әгәр кибет тирәсендә кирәкмәс кешеләр комачаулап йөрмәслек итә, кирәккәндә, үзегез әйтмешли, таянычым, яклаучысаклаучым булсагыз, кабул итәм үзегезне.

Венераның ирләрчә сөйләшүе башкисәргә ошады, билгеле.

— Бөтенесе тәртиптә булачак! Без ике төрле сөйләшә торганнардан түгел,— диде ул, гариза язарга кәгазь алып.

Юнир Данишев атлы бу кеше, паспортында урыс диеп язылган булса да, урыс та, татар да түгел иде. Куе коңгырт чәчле, таррак маңгайлы, уртачадан калкурак таза гәүдәле кеше. Кыяфәте белән күз карашыннан ук көчле һәм кырыс икәне күренеп тора. Аның янына, сөйләшүләренә караганда, үзенә охшаш бер кеше килеп йөри. Күренә, алар барда кибет тирәсендә ир-атлар шым булып торалар. Юнир йөкче дә булып алгач, тагын да тынычлык артып, сатучылар әвеш-тәвешне рәхәтләнеп җәелдереп җибәрделәр. Юнир теләсә нинди куркынычтан кirтәләп, саклап тора үзләрен. Аның шулай турылыклы хезмәт иткәнен искә алып, Венера да бурычлы калмый иде. Тегенең янына иптәше килгән саен диярлек:

— Дустыңны кунак ит,— дип, аңа аракы һәм закускалар тоттыра.

Мондый игътибар белән хөрмәтне күргән Юнир беркөнне:

— Мин барында беркемнән курыкмый яшәгез, Венера Кәримовна! Мине тән сакчыгыз да, потрошителегез дә дип саный аласыз хәзер,— диде.

Шунда Венера:

— Потрошитель кем соң ул? Мин бу сүзне беренче ишетәм,— дигән иде. Юнир:

— Потрошитель ул безнең телдә — җәза бирүче, җан алучы. Суд әһелләре аны, еш кына, ялланып кеше үтерүче, диләр,— дип аңлатып бирде, хәйләкәр елмаеп.

Моны ишетүгә, тәннәренә кырмыскалар йөгереп: «Бу ерткыч белән бик сак эш итәргә кирәк икән», — дип уйлап алган Венера:

— Әйе, янда син булганда, миңа курыкмый яшәргә мөмкин,— дигән булды.

— Әлбәттә! Безнең халык изгелекне онытмый бит.

Шушы сөйләшүдән соң, Венера бу кешегә тагын да игътибарлырак булып, үзенә каршы килүчеләрне өркетүдә тагын да остарак файдалана башлаган иде. Бүген, Хафизов белән көрәш хәлиткеч чиккә җиткәч, ул: «Миңа кичекмәстән Юнирны да файдаланырга кирәк!» — дигән нәтиҗәгә килде. Венера аңа акчаны күпме сораса, шул кадәр бирәчәк. Тик Хафизовны, кабат бәйләнмәслек итеп юлыннан алып ташласын гына.

Венера кибеткә шалтыратып, Юнир белән сөйләшеп алмакчы иде — булмады. Ярдәмчесе аны экспедитор белән базага әйберләр алып кайтырга җибәргәнлеген әйтеп:

— Саулыгың ничек, Венера Кәримовна? — дип сораган иде.

— Иртәгә эшкә чыга алмам, ахры, кәефем начар: йөрәгем бик кага,— диде Венера.— Юнир кайтуга әйт, миңа шалтыратсын, ярыймы!—дип өстәп куйды.

— Ярый, ярый,— дигән җавап ишетелде трубкадан.

Шулай сөйләшеп алуга, Венера шкаф артыннан сумка чыгарып, шуннан берничә пачка акча алып куйды да: «Туктале. Юнир белән сөйләшкәнче Хафизовны күрә алмаммы»,— дип, өеннән чыгып китте.

Ул Торгка килеп керүгә, бер бүлектә хатыннардан читләтеп кенә сорашып, үзе шалтыратканда Хафизовның эш урынында булганлыгын, аның әле күптән түгел генә Торгтан чыгып киткәнлеген белде. Шуннан соң ул, кабул итү бүлмәсенә кереп:

— Радик Хафизович кайтмадымы әле?—дип сораган булды.

— Юк. Кабат Торгка килеп йөрмәстер, мөгаен. Шулайрак әйтеп киткән иде. Җитди йомышыгыз бар идемени?

— Әйе, бар иде шул. Кайтыры билгеле булмагач, көтеп тормыйм инде. Кайта калса: «Венера Кәримовна сораган әйберегез була», дип әйтте диярсең үзенә, ярыймы? Нәрсә икәнен үзе белә ул. Сөйләшәсе килсә, шалтыратыр, өйдә булам.

— Ярый, әйтермен,— дип калды секретарь.

Венера: «Хафизов, секретарена шалтыратып мин булып киткәнне белсә, яңадан Торгка кайтуы ихтимал»,— дип уйлап, Идарәдән ерак китмичә, йөрештерергә тотынды.

Аңа беразга гына булса да, Хафизовның кайнарлыгын сүндереп торырга кирәк иде. Аның карары нык хәзер—ул Хафизовның башына җитәчәк!

Күк йөзен тоташ кара болыт каплап алганга күрә, көзге көн караңгыланып та өлгерде.

Венераның башында мең төрле уй. Кайсын гына аралап карамасын, күз алдына хәвефле билгесезлек килеп баса. Ә алда шомлы билгесезлек торудан да яманы юк. Кеше, үлемгә дучар ителсә дә, аның кайчан һәм нинди буласын ачык белсә, ничектер салкын кан белән тынычланып кала, аны тынычланып көтә. Ә Хафизов белән килеп чыккан каршылык Венераны әлегә берничек тә тынычландыра торган түгел иде.

Йөренеп шактый вакыт сарыф иткәннән соң, Венера: «Тагын көтеп вакыт уздырсам, Юнир белән дә сөйләшә алмый калуым бар»,— дип, өенә юл тотты.

Кайтып кергәндә, вакыт алтынчы киткән иде. Ул, өс-башын да салып тормастан, кибеткә шалтыратты. Кызганыч ки, Юнир ул уйлаганга караганда шактый иртәрәк кайткан. Йөкне бушатырга керешкәнче дә, аннан соң да үзенә берничә тапкыр шалтыратып караган, алай да җавап бирүче булмагач, «Җитди нәрсә юктыр. Булса, өеннән чыгып китмәс иде. Иртәгә иртән тагын шалтыратырмын әле»,— дип, эшен бетерүгә, китеп барган икән.

Венера, уфырып, авыр сулап куйды. Юнирның өенә барып сөйләшер иде—өен дә, даими торып ята торган фатирын да белми. Чуала торган хатыннарының кайсы туры килсә, шунда төн уздыра. Ә аларның кайда яшәгәнен белсә, шайтан гына беләдер...

Хәерле булсын. Димәк, Юнир белән иртәгә иртән сөйләшергә калды, дип, көрсенеп алды Венера. Шушы туймас күз Хафизовтан исән-имин котылсам, берни гә карамыйча, кая да булса санаторийга китеп, тынычлап ял итәр идем. Миңа, эчүне туктатып, дәваланырга кирәк. Юкса, көтмәгәндә генә дөньядан китеп баруым бар. Йөрәгем моны көннән-көн ныграк сиздерә бара хәзер.

Венера шундый уйларны кичереп, ашарына пешерергә җыенганда гына телефон шалтырый башлады. «Кем? Кайсы икән?»

— Тыңлыйм,— диде йөрәге тибүдән туктагандай булып сагаеп калган Венера.

— Әни, әни!..

— Ни бар?! Ни булды?! — дип кычкырып җибәрде Венера, кызының сүзе тоткарланып калуга.— Әйт, кызым, ни булды?!

Трубкадан кызы Рәсимәнең үксеп-үксеп елаган тавышы ишетелә башлады.

— Үләм, әни, үләм!.. Фазылсыз калдым!..

— Машинага тапталдымы, ни булды? — диде, кинәт кенә буыннары хәлсезләнеп калган Венера, калтыранулы тавыш белән.

— Юк. Садиктан үзен алып кайтып килә идем, почмактан үтеп барганда артымнан кемдер килеп сугып екты. Һушыма килгәндә, Фазыл да, ул кеше дә юк иде.

— Мондый кайгыны да күрәсебез бар икән, йа раббым!!..— дип иңрәп куйды Венера. «Бу Хафизов явызлыгы булмагае. Баланы урлатып, аны кайтару бәрабәренә үземне талатмакчы күрәсең, кабахәт!» — Милициягә хәбәр иттеңме әле? Кайчан булды бу хәл? Кайдан шалтыратасың?

— Ун-унбиш минут та юктыр әле. Аңыма килүгә, кире садикка йөгереп килеп, милициягә шалтыраттым. Әле дә шундамын. Инде кешеләр балаларын алып бетерде диярлек. Ялгызым гына кайтырга да куркам хәзер.

— Ялгызың бер кая чыгасы булма! Тиз генә кибеткә шалтыратып алам да килеп җитәм!

Венераның йөрәге, әйтерсең, урыннан кубып чыкты. Тәмам хәлсезләнеп, дер-дер килә. Йөрәге генә түгел, аның бөтен гәүдәсе калтырана иде.

Кибеткә кат-кат шалтыратып та җавап бирүче булмагач, Венера, трубканы шап итеп куеп, өеннән чыгып китте.

Акны-караны күрмичә, әле йөгерә, әле атлый! «Кибеттә дә телефонга килүче булмады, ни хәл бу?! Алары кая олагышты икән тагы? — дип, ачынып алды ул.— Эх, шушындый чакта Юнир да юк бит, ичмасам!...»

Балалар бакчасына килеп, елап күзләре шешенеп беткән кызын күргәч, Венера тагын да исәнгери төште.

Шәһәрнең бөтен милиция бүлекләренә шалтыратып чыкты ул. Күргән-белгән милиционерлардан: «Зинһар, табарга тырышыгыз оныгымны — буш итмәм!..» — дип инәлде хәтта.

Венера, баланы Хафизов кеше яллап урлатмагае, дип шикләнсә дә, моны милициягә сиздермәде. Болай эшне тагын да катлауландырып җибәрүем генә бар, дип курыкты. «Тизрәк потрошительне генә күрим — Хафизовның башына җитмичә туктамыйм хәзер!» — дип куйды ул, эчендәге ачу белән ачы кайгысын кая куярга белмичә.

Кызы белән Венера өйгә кайтып, төнге бергә кадәр телефон яныннан китмичә, әле берсе, әле икенчесе шәһәрнең дежур милиция хезмәткәрләренә шалтыратып, ут йоттылар. Венераның ике тапкыр йөрәге тотып, нитроглицерин йотып кына калды.

Хәлләре күзләренә йокы керерлек булмаса да, бу вакытта туктаусыз шалтыратып торуда мәгънә күрмичә, йокларга яттылар.

Кызы Рәсимә әрнүе белән борсаланып ята торгач, бераз йокымсырап киткәндәй булды. Ә Венера йоклау түгел, керфек тә какмый иде. «Кайда, нинди явызлар кулында өзгәләнә икән бәгырем?» — дип, йөрәге телгәләнә иде аның.— Әрәм генә итмәсәләр ярар иде наныемны. Минем бөтен яшьлегемне югалтып яныш-тырышып йөрүләрем кызым белән шул бала өчен бит. Ул да югалса, миңа ни кала? Үзен исән-имин кайтарсалар, акчамы, машинамны сорыйлармы — берсүзсез бирәм, күзләренә каплансын! Әрәм генә итмәсәннәр иде нарасыем — карап торган өметемне.

Сәгать ике тулып килә иде. Венера белән кызы Рәсимә ярым йокылы, ярым уяу миңгерәп ятканда, телефон шалтырап китте. «Нинди хәбәр булыр?!»

— Тыңлыйм,— диде сикереп торып трубканы алган Венера, сагаеп.

Кызы да, телефонга килеп, шым булып калган иде.

Тынлык. Сулыш алу да юк!

Ниһаять, трубкада ниндидер ят тавышлы кешенең: «Балагыз подъездыгыз баскычында, чыгып алыгыз!» дигәне ишетелде.

Каушап калган Венера аңына килеп: «Сез кем, кайдан шалтыратасыз»? — дип сорарга да өлгермәде, трубка куелган иде.

Хәбәрне ишетүгә, халатын киеп өлгергән Рәсимә: «Улым, Фазылым!» — дип, шатлыгыннан үзен-үзе белештермәгәндәй, ишеккә ташланган иде, Венераның кискен тавышы яңгырап китте:

— Тукта! Алдап чыгарып, үзебезне һәлак итмәсеннәр — ашыкма!

Алар, күзчектән тышкы якны карап алганнан соң, коридорга чыгып, бер мәлгә тынып калдылар.

Аларның йөрәге төпсез упкын аша салынып чайкалып торган тар басмадан чыккандагы кебек сагаеп калган иде. Бернинди кеше тавышы юк.

— Әйдә, баскычны карыйк инде, кызым!

Венера белән Рәсимә коридор ишегенә килеп, аның өске өлешендәге рәшәткә аша тышкы якка күз салдылар. Күрәләр, каршыда посылка ящигына охшаган кәгазь тартма тора. Тышына ерактан ук таныплык итеп, эре хәрефләр белән Венераның исем-фамилиясе, фатир номеры язылган иде.

— Ни булыр бу, әни?!

— Белмим, кызым, әйтә алмыйм,— диде Венера, тамагына төер утыргандай калтыранулы тавыш белән.— Дәшеп, тавыш биреп карарга кирәк. «Аста кем бар? Улыбызны китердегезме, җавап бирегез! Фазыл улым, кайттыңмы, син кайда?»

Бернинди тавыш юк.

— Нәрсә икән ул, әни, ә?

— Белмим, белмим.— Венераның күңеленә әллә нинди шикләр төшеп өлгергән иде.— Шалтыратып алдадылар микәнни? Йа аллам, бусы ни икән тагы? Кая, алып керим әле үзен. Мин ишекне ачып алуга, аста шикле кеше-фәлән булып менә башласа, йөгереп керермен дә бикләп алырсың.

Венера, тиз генә чыгып, тартманы алып керде.

Аның йөзе үле кешенеке кебек агарып, куллары дер-дер калтырый иде.

Тартманы өстәлгә куеп, ачарга да, ачмаска да белмичә, тынып калдылар.

«Ни булыр бу?»

Ниһаять, Венера, җепләрне чишеп, тартманы ачып җибәрде. Эчендә ниндидер төргәк. Ул кат-кат төрелгән кәгазьләрне берәм-берәм сүтеп, соңгысын ачып җибәргән иде — оныгының башын күреп, бер мизгел тораташ кебек катып торды да лап итеп идәнгә ауды. Ә Рәсимә исә, акылыннан шашкан кебек чарылдап җибәреп, алагаем сөрән сала башлады...

# ШИГЪРИЯТ



Клара
Булатова

## Бу языклы дөньяда

* * *

Кулга каләм, дөрес, сирәк алам,
Ә шулай да шактый күп язам.
Кайчагында үзем уйга талам:
Кемнәр укый аны? Ник язам?

Җаннар ярып язган әйберләрең
Югалмасмы шушы кәгазьдә?
Бик ихтимал шулай булуы да
Басылмыйча ятса әгәр дә.

Ә аларда без яшәгән көннәр,
Без кичергән хәвеф аларда.
Гүя чорны ачар каберлекләр,
Көннең йөзен ачар авазлар.

...Каберлеккә барып йөрим әле,
Дөрес ансы: йөреш бик сирәк.
Ә базарга мена барганым юк,
Акчасызга базар ник кирәк?..

* * *

Белмим, ни өчендер
Тынгысыз бу җаным.
Беләмдер, мөгаен:
Рәте юк дөньяның.

«Хөрлек» дип, «Милләт» дип
Күпме сүз куерттык.
Асылда мөлкәт юк,
Милләтне оныттык.

Белекле кешенең
Кирәге калмады.
Түрдәге урынны
Җаһилләр яулады.

* * *

Нишләдем мин? Ни кыландым
Бу языклы дөньяда?
Ни кылсам да, ни җуйсам да
Җавап тотмыйм, сорама!

Нишләсәм дә, ни кылсам да
Хөкемдары сез түгел!
Киялеген үзем күрәм,
Үзем бары, сез түгел!

Кемне телим — шуны сөйдем,
Үз күңелем, үз тәнем.
Үз гөнаһым — үзем түлим,
Сорамагыз бүтәнен.

Нишләсәм дә, ни кылсам да
Бу языклы дөньяда,—
Минем эшем! Шуның өчен
Кагылмагыз сез аңа!..

## Торыйсын — Җафрак бәйрәме

Торыйсын, төшемдә күрдем:
Атылган йолдызсыман
Сызылып үтте яшьлегем,
Абайлар турысыннан...

Җафрак бәйрәмнәре җитсә,
Ләкедә, Торыйсында,
Җыела идек уенга
Абайлар турысына.

Ияреп кайчак бәйрәмнең
Өлкән кунакларына,
Кузгала идек Багыраж
Йә Сарсаз якларына.

Юк иде юкса ул чакта
Туган да, тумача да.
Куныплар йөрдек шул чакта
Туганнар булмаса да.

Бәйрәмнәр төптән бүленгән
Аталып авылларга.
Питравы — Ләкеләрнеке,
Торыйсын — Багыражга.

Кемгә кум, кемгә печнәчәм,
Кемгәдер кода килә.
Иртәдән алып кичкәчә
Аш йөри өйдән өйгә.

Кемдә бал, кемдә пүрчинкә —
Табында бар булганы.
Гаҗәеп кунакчыл иде
Керәшен авыллары.

Үз көе бала-чаганың,
Үсмернең үз кызыгы.
Ә кырда, алан, яланда
Яшьләрнең үз уены.

Егетләр, кызлар ярыша.
Җыр аша сер, сүз куша.
Күз кыса, ымнар кагыша,
Парлаша, озатыша.

Суларда кызлар «яр бага»,
Кем кемгә кайчан китә?
Торыйсын кушкан парларны
Покрауда туйлар көтә.

Торыйсын. Яфрак бәйрәме.
Яшь каен яфраклары.
Күңеленнән китми кемнең дә
Беренче сөйгән яры.

Тик миндә анысы булмады.
Минем бит, әйтсәм әйтим,
Туп-туры икенчесеннән
Башланды мәхәббәтем.

Аның беренче дигәне
Шул ерак Торыйсында
Ничектер югалып калды...
Абайлар турысында.

Ә бүген кайтты төшемдә
Яңадан җанны сызып.
Абайлар йорты өстендә
Атылган йолдыз булып.

* * *

Авыша көн-гомер кич ягына...
Сүнде менә тагын бер шәме.

Бирешмим дип тыпырчынам гына,
Үткән инде язның иң шәбе.

Бирешмим дип тыпырчынам гына,
Инде җисем-бәдән тетелгән.
Акылына күнмәс җор җан гына
Әллә ниләр көтә бу көннән.

Акылына күнмәс җор җан гына
Язлар диеп һаман шәбәя.
Якынлаша гомер азагына,
Пыскып кына сүрән шәм яна.

* * *

Тау ярылды, аерылды.
Яр убылган.
Ата шайтан үзе чыккан
шул упкыннан.
Чыгу белән йөнтәс кулын
безгә сузып,
Сүз башлады: «Туганлашыйк!» —
дигән булып.
Шайтан белән туганлашып,
кем ни откан?
Моңа барыр — бары тарихны
оныткан...
Кызганычка каршы әле
имансызлар
Җитәрлек шул. Ә упкынга —
Халык чумар.—
«Туганлашкан» түрә үрә,
өстә калыр:
Алар һаман рәхәт яшәү
җаен табыр.



Индус
Сирматов

# КЕРӘШЕН КЫЗЫ

МОҢСУ ПОВЕСТЬ

Ул якларга барасым билгеле булгач та, ничектер кинәт кенә Якты Күл авылы исеме төште. Дөресрәге, Якты Күл үзе түгел, кайчандыр шул авылда ике-өч тапкыр очрашкан керәшен кызы Начтый. Начтый димәктән, алар туу турында таныклыкларына язылган исемнәрен бервакытта да тулысы белән әйтмәсләр. Әллә ничек матур гына итеп бозарлар да, килештереп кенә бүтәнчәрәк әйтерләр. Николай аларга Микулай булыр, Алексей — Әлүш, Пелагия — Палка, Екатеринасы — Кәти. Начтый дигәнемнең дә чын исеме — Анастасия, Питәй җизнинеке — Петр, Виркә җиңгинеке Вера иде. Ул чакта без, татар малайлары, аларның чын исемнәре ничек икәнен белмәгәнбездер дә инде, ихтимал, артык кызыксынмаганбыздыр да.

Якты Күл дигән керәшен авылыннан да уңдырышлы җирләрдән, урман-су буйларыннан мөселманнарны куган заманнарда Зәй якларындагы Светлое Озеро дигән урыс авылыннан күчереп утыртылганын белми идем әле. Менә шулай күчеп килгәннәр дә алар, тирә-якта җитмешсиксән чакрымгача урыс авыллары булмагач, гел татарлар-башкортлар белән аралашып, телләрен онытканнар. Әмма диннәрен саклаганнар һәм инде йөз елдан артык керәшен атамасын йөртәләр икән.

Якты Күл керәшеннәре белән без бик дус яши идек. Аның билгеле бер сәбәпләре дә бар. Әмма алары турында аз гына алдарак әйтеләсе булганга, хәзергә тукталып торыйм. Хәзергә без юлда. Без дигәнем — үзем һәм сәбәпчесе шушы юл булган тынгысыз уйларым...

Иң башта шул ике-өч тапкыр очраштык дигән Начтый искә төште. Исән микән ул? Авылында микән? Әллә, хәзерге замандагы бик күп кешеләрнеке кебек, язмышы аны да кайларгадыр илтеп ташлады микән?

Беренче очрашуыбыз... Әйе, әйе, ул көнне әнкәй мине бик иртә уятты. Кичтән һәр көндәгечә көтүлектә сыер саклап, үзем кебек малай-шалайлар белән учак янында әкиятләр сөйләшеп, чыр-чу килеп, төрле уеннар

---

Индус СИРМАТОВ (1937) — *Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, күп кенә телевизион спектакльләр һәм «Еллар шаһит», «Әткәй сәгате» китаплары авторы. Казанда яши.*

уйнап, тәмам арып-талып, таң беленә башлаганда гына кайтып ятканга болай иртә тору газапның да газабы иде. Бүген Якты Күл керәшеннәрендә бәрәңгегә барасыбыз алдан ук сөйләшенгән булганга, тормыйча да кала алмыйсың.

Әнкәйне хәйләләп булмасмы, тагын ярты гына сәгать, ун гына, юк, ике генә минут йоклап булмасмы дигән уй белән иске юрган астыннан чыктым да урыннан күтәрелә башладым. Әнкәй ишек янынннан китүгә яңадан юрган астына чумдым. Әмма хәйләм барып чыкмасын үзем дә белә идем инде. Минут та үтмәгәндер, әнкәй келәткә әйләнеп керде. Өстемнән юрганны йолкып алды да кулымнан тартып торгызды һәм иркәләп чәбәкли-чәбәкли, ишек алдына чыгарды. Мин, эче-тышы кызыл балчык белән сылап, өстеннән ак балчык белән агартылган салкынча читән келәттән аерыласым килмичә генә, юынгыч янына барып бастым. Белеп торам, йокым тизрәк ачылсын өчен әнкәй юынгычка салкын кое суы салып куйган. Монда да йокым ачылмаса, кар базына салкын катык алып менәргә төшереп җибәрәчәк. Ике бармакны гына чылатып, күз тирәсенә тигезеп алдым да читәнгә элENгән сөлгегә сөртенгән булдым. Юыну шуның белән тәмамланды. Ярый әле базга төшәргә туры килмәде. Әнкәй:

— Бар, улым, өйгә кер, катык өстәлдә,— дигәч, йокыдан айнып бетмәгәнгә, күзләремне йомган килеш, чайкала-чайкала өйгә кереп, өстәл янына утырдым. Сыек сөттән оеттылган салкын катыкны агач кашык белән чөмерә башлагач, эчкә суык йөгерде, йокым ачылгандай булды. Балчык кәндидәге катыкны ничә секундта башкарганмындыр, мин ишек алдына чыкканда әнкәй, бәләкәй арбаны тәртәсеннән тотып, капка төбендә басып тора иде инде.

— Әйдә, улым, хәере-рәхмәте белән кузгалыйк. Көн кыздыра башлаганчы атлап калыйк,— диде ул.

Мондый юлларга чыгу беренче генә түгел анысы, курыккан юк. Кичә үзем белән бергә сыер саклаган малайлар-кызлар рәхәтләнеп йоклап калганда миңа Якты Күлгә чаклы егерме чакрым теркелдисе.

Арбаны әнкәйдән алдым да, ул килеп җиткәнче коена торырмын дип, Сөнгә таба элдерттем. Мондый иртәләрдә шунысы рәхәт, ялан аякларың белән чыклы бәбкә үләннәре өстеннән сыптырасың да, Сөн буена җитүгә, киемнәреңне салып ташлап, арбаң-ниең белән суга кереп китәсең. Ә-ә, юк, башта ялтыр-йолтыр килеп су өстендә сикерешүче чабакларга, вактөяк кызылканатларга кызыгып карап торасың икән әле. Аннары гына суга кереп китәсең. Арба тәгәрмәчләрең бүртенә тора, үзең исә суга чумасың. Сөннең җылы кочагыннан аерылып, сөртенми-нитми генә күлмәк-чалбарыңны кигәч, салкынча һавада бераз дерелдәп аласың. Андый чакта инде йокың гына түгел, бөтен уй-кайгыларың кача. Дөнья рәхәте!

Ләкин бу юлы рәхәтлек кичереп, хыялланып торырга туры килмәде. Ялт итеп әнкәй дә килеп җитте. Ул чабатасын салып, күлмәк итәкләрен җыештырып, суга керә башлаганда, мин арбаны сөйрәп, китеп бардым. Бу турыда Сөн тирән түгел. Борылып карамасам да, беләм, әнкәйнең кендегеннән булыр, чөнки — минем муеннан.

— И-и суның рәхәтлекләре, иеме, улым,— ди әнкәй, кинәнеп.

Юри генә сораган була инде ул аны. Минем йокым ачылганмы-юкмы икәнен тикшерү өчен генә. Сөн аркылы чыкканда эчке киемен салмаганга, күлмәге ябык тәненә ябышып тора үзенең.

— Нигә эндәшмисең? Су җылымы, улым?

Җавапсыз калмас өчен генә: «Э-э» дип мөгрәп куйдым.

Шуннан соң шактый озак сөйләшми-нитми генә атладык. Бер чакрым үттек микән, икенеме, җиденеме — анысын кем санаган. Барыбер төшкә чаклы егерме чакрым үтәсе.

Инде әнкәйнең күлмәге кипте, минем исә авыз кибә башлады. Сеңгерән урманына керер алдыннан әнкәй миннән арбаны алмакчы булды. Буш арбаны гына үзем тарталмыйммы соң инде — бирмәдем.

Әмәкәй болынына да җиттек. Их, шушы болынның матурлыклары! Әллә ничә чакрымга сузылган эскәтер шикелле тип-тигез җир ул. Чәчәкләре дисәң дә чәчәкләре. Берсе икенчесенә һич кенә дә охшамаган тагы. Бар сарысы, бар сап-сарысы, алсуы, шәмәхә төслесе, кызгылты, кып-кызылы, зәңгәре, зәп-зәңгәре. Ә монысы, менә монысы ни төсле? Ничек икән бу төснең исеме? Шулай сокланып чәчәкләргә карап барганда абындым да егылдым.

— Ни-нәмә таптың, улым? Миңа да бир әле.

Егылганга ачуым килсә дә, әнкәй көлгәч, үземә елмаеп куйдым.

— Мә, ал, түлке яртысын гына,— дигән булдым.

— Җитәр, улым, бераз утырып ял итеп алырга кирәк. Әнә теге куак ышыгына сыеныйк.

Әнкәй беләкәй арбаның күчәр ягына чүмәште, мин — тәртә ягына. Агач күләгәсендә шул чаклы рәхәт иде. Бераздан тамак кибү дә онытылды, арыганлык бетте сыман. Мин яңадан тирә-ягыма күз салдым. Һәм кинәт тагын теге чәчәкне, үзем төсенең исемен белмәгән чәчәкне күреп алдым. Шуны өзеп алыйм дип, сикереп торган идем, әнкәй шыпылдап җиргә утырды.

— Әнкәй, ни-нәмә таптың? Миңа да бир әле.

— Әбиеңнең койрыгын таптым. Әйтми-нитми торалармыни, арба чөйлектереп!

Әнкәй үзе ачулана, үзе көлә — чынлап ачуланмый икән әле. Теге чәчәкне өзеп алдым да дөньямны онытып, карый башладым. Уртасы һәр чәчәкнеке төсле сап-сары, таҗ яфракларының төбендә күтәрелгән саен сыеклана баручы куе зәңгәр сызыклар сызылып киткән. Таҗ яфрагының бүтән җирләре... Чыннан да, нинди төс соң бу? Шулкадәр дә матур төс булыр икән! Бу төснең исемен белүче бар микән?

— Әнкәй, бу нинди төс?

— Бумы? Бу ни инде бу... Әйдә, улым, кыздыра башлады. Тизрәк атлыйк әле.

Әнкәйнең арбаны үзе тартып киткәнен сизмәдем, чәчәгемне күзләремә бер якын китереп, кулымны бер ераккарак сузып атлыйм да атлыйм икән. Тагын нәрсәгәдер абынып, кулым белән юл тузанын «сөртеп» алдым.

— Бер юлда икешәр әйбер тапмыйлар инде, улым. Бик алҗыттымы әллә?

— Юк ла, шушы төснең исемен белӛлми карап кына барадырыем ла. Ничек соң монын исеме, әнкәй?

— Бу төснең исемеме? Бу ни инде, улым... Ташлале, юк белән баш катырмале... Соңга калмагаек.

Мин чәчәгемне чалбар кесәсенә салдым да тәртәгә ябыштым. Буш арбаны икәүләп тартып баруы кыен ла ул. Берең озын, берең тәбәнәк булгач — бигрәк тә. Бераздан әнкәйнең, алҗырсың бит, улым, диюенә карамый, арбаны үзем генә сөйри башладым.

Кояш кыздырганнан кыздыра. Маңгайдан елга булып тир ага. Юл тузанында аяк табаннары пешә. Карын ачты. Авызда төкерек кибеп бетте. Ә күңелдә — теге чәчәк. Ничек икән соң аның исеме? Төсе нинди исем белән атала икән? Андый төстәге буяу була микән?

— Әнкәй, тәки әйтмәдең бу чәчәк төсенең ни икәнен.

— Э-э, әнә килеп тә җиттек, улым, Якты Күлгә. Тагын бер тын атласак, алла боерса... Питәй җизнәң генә өйдә булсын. Аның бәрәңгесе дә әйбәт, кыйбат та сорамый.

Чынлап та, керәшен авылына килеп җиткәнбез икән. Әнкәй әйтмешли, тагын бер тын атлауга, Питәй җизниләрнең капка төбенә килеп туктадык. Безне тәрәзәдән күрептер инде, каршыбызга Виркә җиңги йөгереп чыкты.

— И-и кодаем, кунаклар килә икән. Безгә килүгегезме? Әйдәгез, әйдә, үзебезгә, үзебезгә. Бүтәнгә килсәгез дә, башта безгә керегез. Ризык авыз

итеп чыгарсыз, кодай биргәненнән. Питәй, ишетәсеңме дим, җегетен ияртеп, Әнисә килен килгән. Мактап кына җөрисез икән, аш өстенә килеп төштегез. Әле генә бәрәңге пешеп чыкты. Начтый кызым, бар әле катык-сөт алып кер. Баздан сыра да менгер. Җегетнең тамагы кипкәндер. Җегетен бигрәк матур, Әнисә килен. Кайда бу чаклы тузанга манчыдың аны? Җул бик тузанлы мыни суң, исемең ничек әле? Җуынып җибәр. Сездәге Сөн суы бездә дә бар ул.

Виркә җинги, уенын-чынын бергә катнаштырып, үзенең керәшен шивәсендә текелди-текелди, безне ишек алдына алып керде. Болдыр өстендә безне Питәй җизни каршылап тора иде.

Бернинди туганнарыбыз булмаса да, без аларны, Питәй җизни, Виркә җинги, дип йөртәбез. Шулай дигәнне үзләре дә яраталар. Безнең авылда һәр өйнең Якты Күл керәшеннәреннән берәр «җингие» йә «җизнәсе» бар. Исәмәт базарына барганда безнең авыл аркылы үтәсе булганга, Якты Күл керәшеннәре дә шунда туктап ял итәләр. Еш кына кичтән килеп кунып та чыгалар. Аннары иртүк торып, бездән биш чакрымдагы Исәмәткә китәләр. Керәшеннәрнең базарда сатыр әйберләре күп. Чөгендер, кыяр, кишер, суган ише әйберләрне гел алар гына сата диярлек.

Минем белән күрешергә кулын сузып, Питәй җизни болдырдан төште.

— Кәбир дә килгән икән. Исәнме, Кәбир дус.

— Исәнме, Питәй җизни. Тик мин Кәбир түгел, Хә-бир. Хәбир диген.

— Ник, мин дә Кәбир дим бит инде. Безнеңчә шулай була инде ул. Әйдәгез, җуыныгыз да өйгә керегез.

Кулны-битне генә түгел, тез тиңентен аякларны да юып җибәргәч, арулар онытылып китте. Ашыйсы килү генә күрше абыстай түгел икән, тизрәк өйгә керү ягын каердым.

Ярмаланып пешкән кайнар бәрәңге янында куе сөттән оетылган салкын катык та булса, миңа бүтән берни дә кирәкми. Ә монда тагын тозлы кыяр, кишер кушып тозлаган кәбестә. Виркә җинги каерып торып кисеп, алдыма бер телем арыш ипие дә куйгач, дөнья бөтенләй түгәрәкләнеп китте. Ашка башта олылар үрелгәнне генә көтеп тордым да, Питәй җизни, әйдә, җегет, сынатма, диюгә, «утыз икем»не эшкә җиктем. Ипи сындырып кабудан бушаган арада бер кулым ярмалы бәрәңге ташыса, агач кашык тоткан икенче кулым катык салынган балчык табак белән авыз арасында очып йөри башлады. Кәбестәсен-кыярын да кырыйга куймадым.

Әллә тамагым туя башлады, әллә Питәй җизнинең миңа елмаеп карап алуы тәэсир итте, дәртемне бераз гына басарга туры килде. Җиҥмәсә, әнкәй дә ишетелер-ишетелмәс кенә:

— Чәйнәбрәк аша, улым,— дигәч, кашык тоткан кулым бигүк жилпенми башлады.

— Тимә, килен, җегеткә. Аларның әле үсә торган чаклары. Аша, җегет, аша. Ашаган малда өмет бар. Виркә, ипиеңне җәлләмә, кисеп куй.

— И-и кодаем, кем җәлләсен! Күрми дә торам икән. Менә, менә. Рәкәтләнеп аша, җегет.

Виркә җинги яңадан кисеп куйган ипигә кагылырга ярыймы, дип, әнкәйгә карап алдым да, аның тарафыннан кисәтүле караш сизелмәгәч, монысына да тотындым.

— Кодаем, онытып та торам, сатарга дигән бәрәңге баздан чыгарылмаган бит әле. Базны карый торырга кирәк. Мин чыгыйм әле. Виркә. Сез чәй эчкәч чыгарсыз,— дип, Питәй җизни урыныннан кузгала башлады.

Әнкәй: мәшәкатьләнмәгез, үзебез төшеп алырбыз әле, дисә дә, Питәй җизни, җае бар аның, икс-өч капчык кына монда өстә дә бар ул барын, сезгә эсбижиен бирен җибәрәсе килә, дип, чыгып китте.

Виркә җинги:

— Начтый, тойт, кайда җөрисең, чәй китер,— дигәч кенә, мин Начтый безнең белән өстәл янына утырмаганын күрдем.

Әнисенеке кебек үк нәфис житен сүсеннән үзләре шакмаклап суккан киндер күлмәк кигән Начтый ялтырап торучы зур жиз самавырны көчкә күтәреп өстәлгә китерде. Берәүгә бер күтәрелеп карамыйча, берәүгә бер сүз әйтмичә, ул барыбызга да чәй ясап бирде. Әллә кайдан гына алып, агач банкага салынган бал, кызыл эремчек эченә бер йомарлам май батырылган керәч тәлинкә китереп куйды.

— Әйдә, кызым, үзең дә безнең белән. Нишләп син дә утырмыйсың?

— Жук, минем эчәсем килми әле,— диде кызый.

— Олылар жанына утырмый ул. Гәдәте шулай. Ояла.— Виркә жиңгинең миңа төрттерүе булдымы бу, әллә чынлап та олылар белән бер өстәлдә утыру гадәте юк иде микән, Начтый икенче бүлмәгә чыгып китте. Хәер, кунаклар килгәндә олылар янында утыру бездә дә бик үк хупланмый инде анысы. Эчендә бүре уласа да, кунаклар кузгалып китмичә, табын янына килү түгел, карап тору да тыела. Йә кече бүлмәдә көтеп утырасың, йә өйдән үк чыгып торасың.

Кызыл эремчек белән балларына бик кагылмаска тырышып кына, әмма ипи телеме өстенә майны мулдан ягып, чәй эчеп утырганда Виркә жиңги ипиемне алды да мае белән буташтыра-буташтыра калын итеп бал сылап бирде.

— Берсе дә сатып алган түгел. Бөтенесе дә үзебезнеке. Рәхәтләнеп сыйлан.

Яшиләр дә соң керәшеннәр! Катыкны куе сөттән оеталар. Бәрәңгене ипи белән ашыйлар. Баллап-майлап, кызыл эремчекләр белән чәй эчәләр. Ә без бәрәңгене дә алардан сатып алабыз. Күңелгә шундый уй килде дә, чәй чәшкәсен ничектер өстәлгә куеп, күтәрелеп карадым. Анда, мин караган якта, бүлмә ишеге төбендә елмаеп, Начтый басып тора иде. Карашларыбыз очрашуга, ул ишек пәрдәсе артына чумды. Мин ишек пәрдәсенең дә хужаларның күлмәкләре төсле шакмаклы киндердән эшләнгәнлегенә игътибар иттем.

Авылда, керәшен әкәйләре (хатыннары) кыш буена сүс эрләп, киндер суга, ирләре киезката баса, арба-чана ясый, шуңа алар мул торалар, дип сөйләнәләр иде. Хак икән. Әнә бит, тәрәзә пәрдәләре дә үзләре суккан киндердән. Буй-буй киндердән.

— Тамагың туйса, бар, улым, Питәй жизнәң янына чыга тора. Хәзер мин дә чыгып житәм. Әйдә, алайса, бер амин.

Әнкәй кул күтәреп, дога кыла башлады да, нишләп миңа кушылмый дигәндәй, аптырап, Виркә жиңгигә карады. Аннары алар берсе бер сүз әйтмичә көлешеп алдылар. Әнкәй яңадан кул күтәреп, ялгыз гына амин тотты. Виркә жиңги аны көтеп торды. Шуннан соң Виркә жиңги торып басты, почмакка карап, иелә-бөгелә чукынып алды. Әнкәй аны көтеп торды.

— Теге чакта сездә, аштан соң торып, мин дә почмагыгыздан сурәт эзли-эзли аптырап беткәнием,— диде Виркә жиңги.— Сез кул күтәреп амин кыла башлагач кына, үземнең жалгышканымны аңлаганыем. Әй көлешкәниек.

— Э-э шул. Әле мин дә, нишләп амин тотмый бу дип торам. Онытып жибәргәнмен. Ярар, рәхмәт аш-суыгызга. Исәнлек-иминлек белән, кайгы-хәсрәтсез яшәргә язсын.

Әнкәй шулай рәхмәт укый калды. Мин ишек алдына чыктым. Анда, алды ачык такта сарай эчендә, Питәй жизни агач мичкәләр, әллә нинди тартмалар арасында мәш килә иде.

— Булдымы, жегет. Булса, кил әле монда. Мин сезгә астан биреп торырмын, сез Начтый белән алып, шунда жайлаштырып куя торырсыз. Кызым, боларын читкәрәк этегез,— диде дә, Питәй жизни базга төшеп китте.

Дөресрәге, әлеге такта сарай эчендә баз барын мин ул төшеп киткәч кенә аңладым. Ә Начтый кай арада чыккандыр, анысын сизмәгәнмен дә икән.

Хужа кеше, мыш-мыш килеп, баздан яңадан-яңа мичкәләр, өсте каплаулы агач чиләкләр, тартмалар чыгара тора. Начтый белән без аларның кайсын сөйрәп, кайсын шуыштырып, читкәрәк ташый торабыз. Кечерәк буйлы булса да, Начтый эшкә миннән ныграк икән. Мичкәләрне уйнаклатып кына йөртә. Минем дә сынатасым килми бит инде, каударланып киткәнмен дә, авыр гына бер агач чиләкне этеп барганда әйләндереп җибәрдем. Чиләк капкачы ачылып китте дә ишек алдына тозлаган кыяр сибелде. Начтый «прых» итеп читкә борылды. Мин, ашыга-ашыга, түгелгән кыярны чиләккә тутыра башладым.

— Аудардыңмы? Саграк кирәгие. Җарар, маташма. Рассулы түгелгәч, барыбер эшкә җарамый ул. Дальше саграк кыланыгыз.

Үзебездә булса, моның өчен мине тотып ярган булырлар иде инде. Хәер, безгә каян килсен ул тозлаган кыяр. Кәбестә-кыяр тозларга, без керәшенмени!

— Кызым, менә монысын икәүләп апкитегез. Алма катыштырып тозлаган кәбестә бу. Җук, туктагыз, үзем.

Чираттагы мичкәсен чыгаргач, Питәй җизни шулай диде дә, бик кадерләп кенә кочып, лапаска кертеп куйды. Ул арада Начтый минем аркама төртеп тагын бер пырхылдап алды. Төртсә сүзем юк, әмма пырхылдавы ачуымны китерде. Ләкин нишлисең, ул түгел, мин гаепле, кыяр чиләген мин аудардым бит, пешмәгән. Каш астыннан гына Начтыйга караган идем, ул тагын пырхылдап куйды.

Күпме вакыт үткәндер, бу нәрсәләрне ташый-ташый мин инде арып беттем. Ярый әле Виркә җиңги белән әнкәй дә чыгып җиттеләр. Алар да шактый тирләгәч, Питәй җизни, эш бетүен аңлатып, иркен сулыш алды.

— Кая капчыкларыгыз?— диде ул.— Писмилла әйтеп, үзегез тутырып алыгыз.

— Ә-ә, шулаймыни? Ярар, ярар. Улым, мин базга төшәем, син, алып, капчыкка салып торырсың,— дип, әнкәй базга төшәргә әзерләнә башлады.

— Җук, анда ике кеше төшәсе. Бәрәңге астагы базда бит.

Бу кадәр чиләкләрнең, мичкәләрнең ни өчен шулай чыгарылуын мин базга төшкәч кенә аңладым. Баз ике катлы булып, бәрәңге астагысында икән. Анда төшү өчен башта базның беренче катын бушатырга кирәк булган икән. Әнкәй астагы базга төшеп китте. Ул биргән чиләкне мин, агач баскыч буйлата сөйрәп, өскә менгерә тордым. Миннән Виркә җиңги ала барды. Шулай әрле-бирле йөри торгач, Виркә җиңги:

— Килен, чыгыгыз, булды,— диде.

Моны ул мин соңгы чиләкне баз авызына сузганда әйтте. Шул арада, әллә каян килеп, Начтый чиләккә үрелде.

— Кит, әни, үзем,— диде ул. Минем өчен чиләкне кем алса да барыбер иде. Ләкин чиләк Начтый кулыннан ычкынды да бәрәңгеләр, дөбершатыр, минем башка коелды. Әллә юри аударды инде Начтый бәрәңгеләрне. Яңадан төшеп чиләккә тутырырга туры килде.

Әнкәй белән без баздан чыкканда Начтый ишегалдында күренмәде. Ә бәрәңге ике капчыкка тутырылып, капчык авызлары бәйләп куелган иде.

— Бу әйберләрне кире төшерергәдер бит инде?— диде әнкәй.— Әйдәгез, бергә-бергә төшереп куйыйк.

— Җук, баздагы бәрәңге чыгарылгач кына төшерелә болар,— диде Питәй җизни.

— Бәй, бик күп бит анда бәрәңге. Ничек чыгарып бетерерсез икән? Мондагы әйберләрегез җылыда бозыла торган әйберләр түгелме соң? Көннәр бик эссе тора.

Питәй җизни сатарга дигән бәрәңгене әле киләсе атнада гына чыгарырга җыенган булуларын, кеше яллап та куйганлыкларын, әле безгә искермәгән-пәжемәгән бәрәңге биреп җибәрәсе килгәннән генә баз ачуларын, кеше таба алсалар, бүген үк чыгартасыларын, табалмасалар, иртәгә калдырасыларын әйткәч, әнкәй чартлап ябышты. Алай безнең өчен генә

булгач, әйдәгез, үзебез чыгарышабыз, дип караса да, Питәй җизни дә, Виркә җиңги дә риза булмадылар.

Әнкәй:

— Без эштән курка торган кеше түгел, бергәләшеп сәгать эчендә чыгарып бетерәбез, кайда куясыз, элеккечә шул келәтегезгә ташыйсызмы,— диде дә базга төшәргә үк әзерләнә башлады.

Чарасыз калган Питәй җизни башта нигәдер кояшка карап алды, аннан:

— Җарар суң, барыбер кеше чакырасы,— дип, ризалашуын белдерде.

Яңадан баз. Яңадан бәрәңге тулы чиләкләрне баскычтан сөйрим. Инде алҗып беттем. Чыгарасы бәрәңгенең иги-чиге күренми кебек. Ник кайтып китмәвебезгә үкенә үк башладым.

— Пиримин ясап алыйк,— диде шул чакта Питәй җизни.— Чык әле, җегет. Килен, син дә. Җартысы булды. Чәй эчкәч, базга үзем төшәрмен. Көн дә кичкә авышты, инде бүген кайтып җөри алмассыз. Иртәгә иртүк кенә китәрсез.

Әнкәй дә бик арыгандыр, ахрысы. Каршы килеп тормады. Әллә инде башлаган эшен ярты юлда калдырасы килмәде.

— Ярар соң,— диде ул.— Мин дә киткәндә үк өйдәгеләргә, бүген кайтып житәлмәсәк, көтеп интекмәгез, дип киткән идем.

Көндез нык кына тамак туйдыргангадыр инде, минем ашыйсым килми иде. Бер чәшке чәй эчтем дә, рәхмәт әйтеп, урыннан кузгала башладым. Питәй җизни миңа гаҗәпләнеп карап алды.

— Нишләп бер дә ашамадың, җегет? Арыткანмыни? Арыганда башта шулай ашыйсы килмәгән кебек була ул. Аннары эчәгең сызгыра башлый. Начтый, син кайда? Әнә ипи белән теге чиләгегездән тозлы кыяр алыгыз да урманга барыгыз. Каен пиннеге кисеп кайтырсыз. Бүген — мунча көне бит.

Начтый өстәлдән ике кисәк ипи эләктерде дә йөгереп чыгып китте. Мин ишек алдына чыкканда ул, бая мин аударган агач чиләктән кыяр алып, барысын бергә шакмаклы киндер чүпрәккә төреп маташа иде. Капкага җитеп килгәндә безне Питәй җизни туктатты да, үзе абзарга кертеп куйган мичкәсеннән алып, тозлаган ике алма бирде.

— Озак җөрмәгез, кайткач мунчага су китерерсез,— дип калды ул.

Начтый урам буйлап йөгерде, аннан калышмаска тырышып мин юырттым.

Урман дигәннәре авылга терәлеп үк торган куаклык икән. Начтый шунда килеп җиткәч кенә, йөгерүеннән туктады. Кулындагы төенчеген шапылдатып җиргә ташлады да, шакмаклы күлмәк итәген җилпеп алып, үзе дә үлән өстенә утырды.

— Әйдә, ашыйбыз.— Бу авылга килгәннән бирле Начтыйның беренче сүзен ишетүем шул булды. Тавышы матур гына икән, күгәрчен гөрләвен хәтерләтә.— Син нәрсә җаратасың? Мин тозлы алма җаратам. Син?

Гомеремдә тозлы алма кабып караганым булмаса да, яратам, диген булдым. Арыш ипие белән тозлы кыяр, тозлы алмадан да тәмлерәк ризык юктыр дөньяда! Кыяры кетер-кетер итә. Алмасын капканда авызга теш араларыннан ургылып су тула. Әллә алма суы, әллә теш төбенең үзеннән чыга — белгән юк.

Начтый кыярын йә алмасын тешли дә миңа карап, кеткелдәп көлеп куя. Үзе туктаусыз сөйләнә. Сөйләнә, дисәң, дөрес тә булмас. Ул, әллә ничек, күгәрчен кебек гөрли иде. Кеткелдәп көлгәндә шулай микән, әллә үз тавышы шундыймы — аңлавы читен.

Менә ул соңгы кисәк кыярын кабып йотты да, мөселманнарча кулын күтәреп, пис-пис-мулла дип пышылдый-пышылдый, дога кылган булды. Аннары кинәт сикереп торды да мине төртеп екты. Үзе йөгереп куаклыкка кереп китте. Мин дә аның артыннан кергәндә ул инде, куаклык читенә чыгып, чәчәкләр-үләннәр өстеннән йөгерә иде. Мин, әлбәттә, аны куып тотарга, үзен дә төртеп егарга тиеш идем. Әмма күпме генә

йөгерсәм дә, аны куып житә алмадым. Начтый юри генә әкренрәк йөгергән була да, мин эләктерәм дигәндә генә, тагын кош кебек очып китә. Сынатасым килми генә бит. Тик бу кызны куып тоту һич мөмкин түгел иде. Менә тотам, менә бер-бер жиреннән эләктерәм дигәндә генә йә уктай атылып алга омтыла, йә берәр куак артыннан әйләнеп уза да, мин килеп житкәнче, телен чыгарып, мине үртәп ала. Инде жан ачуларым чыга башлады. Нишләтәсемне белмәсәм дә, ну, тотсам нишләргә белермен, дим тегенә.

Әллә абынды, әллә ялгыш атлады, Начтый кинәт кенә үлән өстенә җәелеп барып төште. Йөгереп килүгә, мин дә аның өстенә капландым. Сөрлеккәндә берәр нәрсәгә тотынып калырга тырышу галәмәте белән, мин нәрсәнедер чытырдатып эләктереп алдым. Егылганда шакмаклы киндер күлмәгенең итәге, бот төбенә кадәр күтәрелеп, Начтыйның тәне ачылган, мин аның тез капкачын умырып тотканмын икән. Шунда ук аның... күлмәктән башка эчке киеме булмавын да күреп алдым. Тәнем чымырдады, кинәт башым әйләнде, үзем, күргәнемнән оялып, мәлҗерәп калдым. Секунд та үтмәгәндер, Начтый сикереп торды, үрмәләп тора башлаган жиреннән мине тагын төртеп екты да, йөгереп китмәкче булды. Мин аның аягыннан эләктереп алырга өлгердем. Начтый, бераз алгарак иелде дә, элеккечә кеткелдәп көлә-көлә, ике кулы белән ике жилкәмә басып, мине жиргә иңдерде. Шәп йөгерүе өстенә көчле дә икән үзе. Мин шактый кыенлык белән тезләнгәндә ул да, кулларын жилкәмнән жибәрмәгән килеш, үләнгә тезләнде. Безнең күзләребез очрашты. Һәм, йә ходай! Мин аның күзләрендә иртән болында очраткан теге чәчәкләрне күрдем. Нәкъ шулар, нәкъ шул чәчәкләр төсле иде аның күзләре. Аларга карап, мин яңадан коелып төштем.

Миңа карап, Начтый шундук житдиләнде, шакмаклы күлмәгенең тирән кесәсеннән кыныга тыгылган зур пычак чыгарды.

— Әйдә, пиннек кисәбез,— диде ул.

Мин пычагын аның кулыннан алдым да каен ботакларын кыеп-кыеп төшерә башладым. Начтый аларны җыеп кырыйга чыгара торды.

— Син пиннекләрне бәйлә, мин мәтрүшкә җыям,— диде ул һәм куаклар арасына кереп югалды.

Мин киселгән каен ботаклары яткан жирдә үсүче теге чәчәкләрне күреп, аптырап калдым. Аларны өзеп алдым да шуларга текәлдем.

— Нәрсә карап торасың, нигә пиннек бәйләмисең? Мә, мәтрүшкәләрне кыстырып бәйлә. Нәрсә ул кулыңда?

— Чәчәк бу, Начтый. Карале, Начтый, бу нинди төс дип атала? Нәкъ синең күзләрең төсле үзләре... Нинди төс дип атала соң бу?

Әле генә мәтрүшкә сабаклары тотып елмаеп торган Начтый кинәт уйчанланды, иелеп, каен ботакларын кочагына алды да авылга таба йөгерә башлады:

— Безне жугалтканнардыр анда...

Чәчәкләремне, иртәнге кебек, чалбар кесәсенә салдым да мин дә аның артыннан йөгердем. Начтый белән уйнап-шаярып, вакыт үткәнен сизмәгәнбез дә икән.

Без кайтканда инде баздан бәрәңгене дә чыгарып бетергәннәр, мунча ягып, томаларга да өлгергәннәр иде. Әнкәй белән Виркә жиңги, безнең капчыкларны бушатып, аларга ярылган бәрәңге күзләре тутырып утыралар иде. Әнкәй миңа усал гына карап алды. Үзе ачуланганын сиздермәскә тырышып:

— Әйдә, кил, син дә ярыш. Менә Виркә жиңгәннәр безгә бәрәңге урынына бәрәңге күзләре генә биреп жибәрергә булды әле, рәхмәт инде,— диде.

— Соңгарак калгансыз шул бәрәңге утыртырга, май ае бетеп килә бит,— диде Виркә жиңги.

— Шул орлыгы житмәү инде, жире казып куелган, югыйсә. Хәзер утыртасы гына. Рәхмәт инде сезгә. Әле тагын киләсе булыр ие. Болай

булгач, иртәгә утыртып бетерәбез инде, алла боерса. Бүтән килеп йөрисе булмас.

Әнкәй белән Виркә җиңги, шулай сөйләшә-сөйләшә, ике капчыкны шыплап бәрәңге күзе белән тутырдылар. Капчыкларны арбага салып бәйләгәч, мине мунчага, беренче парга җибәрделәр. Анда әштер-өштер юынып чыгуга, йокларга яттым.

Әнкәй мине кичәгедән дә иртәрәк уятты. Виркә җиңги, пешереп төйгән бәрәңгегә арыш оны кушып, боламык болгаткан икән. Сары май салынган кайнар боламыкны тиз-тиз капкаладык та, рәхмәтләр әйтеп, чыгарга әзерләдек. Юлда ашарсыз, табагын Исәмән базарына барганда үзем бер алып кайтырмын әле, дип, Виркә җиңги боламык та төреп бирде. Без чыгып киттек. Начтый өйалды идәнендә тыныч кына сулап йоклап калды.

Хәзер инде арба тәртәсен, теләсәң-теләмәсәң дә, икәүләп сөйрәргә иде.

Авыл башына җиткәндә әнкәй, ишетә күрмәсеннәр, дигәндәй:

— Урыс-керәшен белән дус булсаң, балта-пычагың яныңда торсын, дигән булалар. Бер дә дөрес түгел. Аларның да төрлесе бар шул. Әнә ничаклы бәрәңге күзен бушлай бирде Питәй җизнәң. Бушлай алырга уңайсызлангач, баздан бәрәңге чыгарган өчен бирәм, дигән була. Бүтән чакта ике капчык бәрәңгене бер пот бодай онына гына алыштырып бирәләр ие.

Авылдан чыгып бераз атлагач, каршыбызга таба килүче Начтыйны күреп алдык.

— Бәй, кызым, син йоклап калган иең түгелме соң? Каян болай?

— Бозауны көтүгә кудым.

Әнкәй:

— Бозауны?..— диде дә тукталып калды.

Ялганлый Начтый, билләһи, ялганлый. Бердән, бозау көтүе болай иртә чыкмый, сыерлардан соң гына чыга. Әле сыерлар да чыкмаган. Икенчедән, бозау куган булса да, безне узып китмәде бит. Ындыр артыннан гына сыптырган бу — керәшен кызы.

— Бездә җәй көне Майдан була, июньнең беренче җәкшәмбесендә. Майданга килегез, Әнисә түти. Табакны да шунда алып килерсез. Исән булыгыз, Әнисә түти.

Карале, кара, табакны да, диме? Йокламаган, тыңлап яткан бит бу кызый. Майдан була, ди. Алар Сабан туен шулай Майдан диләр. Тора-бара табак та, Начтый да, җиңги-җизниләр дә онытылды. Әнкәй, әнкәй белән бергәләп ике капчык бәрәңге күзе салынган арба сөйрәүче үзем генә калдым. Хәер, табак бер тапкыр искә төшкән икән әле. Сеңгерән болынына җитеп, суык боламыкны бармак белән эләктереп каба башлагач. Ялгышам, Начтый да бер тапкыр искә төшкән икән. Боламыкны ашагач, бармакны сөртим дип үләнгә үрелсәм, Начтыйның күзләре төсле теге чәчәкне өзеп алганмын. Бу юлы инде аның төсе ничек дип аталуын әнкәйдән сорап тормадым. Ул төскә үзем исем кушкан идем инде — Начтый күзе. Миләүшә дигән төс тә бар лабаса. Миләүшә дә кызлар исеме бит. Ә бу — Начтый күзе булыр.

Авылга бик соңлатып, төштән соң гына кайтып җитсәк тә, җыйнаулашып бәрәңгене утыртып бетердек. Орлык җитте. Ярты чиләкләбе артып та калды әле. Анысын әни өмәгә килүчеләргә пешереп ашатты.

Икенче көнне мин, ничектер кулны чалбар балагына тыккач, бармагымның йомшак әйбергә төртелүен сизеп, нәрсә икән дип алып карасам, теге чәчәкләрне тартып чыгардым. Алар төссезләнеп, ямьсезләнеп, бөрешеп беткәннәр иде... Миңа моңсу да, күңелсез дә булып китте.

* * *

Ул елны нигәдер Виркә җиңги дә табагын алырга кермәде, керәшен Майданына барасыбыз да искә төшмәде. Икенче елны гына әнкәй, Исәмәт базарында Виркә җиңгине очратуын, шушы якшәмбедә аларда Майдан буласын, мине кунакка чакыруларын әйтте. Берәр күчтәнәч салып, табакларын да алып барырсың, диде. Сабантуй иртүк башланасы булганга, дустым Ясәви белән шимбә көн төштән соң ук юлга чыктык. Ясәвине дә Микулай җизнәләренә кунакка чакырганнар икән.

— Кыстасалар да, иртәгә анда кунып ятмагыз, төш авышуга кайтырга чыгыгыз,— дип калды әнкәй.— Бәрәңге кәтмәнлисе бар, ишетсен колагыгыз.

Без башта Ясәвинең Микулай җизниләренә кердек. Аннары мин, аны калдырып, Питәй җизниләргә киттем. Виркә җиңги белән Начтый каядыр киткәннәр иде. Питәй җизни белән куыклы лампа яктысында чәй эчкәч, мин йокларга яттым. Иртән уянганда да Начтый өйдә юк иде. Майданга китте, диделәр. Китсә китәр, аны күрәсем генә килеп тормый әле. Алай да, әллә ничек, теге чәчәк күз алдымнан ялтырап киткәндәй булды. Сеңгерән болынында нишләп карамадым икән, быел да үсә микән ул чәчәк?

Мин ашап-эчеп урамга чыкканда, бер төркем керәшен малайларына ияреп, Ясәви дә килеп җитте. Аларда шундый гадәт икән, таныш булмаган кешеләр белән дә кул бирешеп күрешәләр. Шулай иткәч, без, барыбыз да күптәнге дуслар кебек шаулаша-шаулаша, Майданга киттек.

Әле Майданда көрәш-мазар башланмаган. Майдан буласы җирдә керәшен кызлары җырлый-җырлый түгәрәк әйләнәләр иде. Аларның түгәрәкләре дә бик кызык икән, бездәге кебек түгел. Бездә башкалар җырлап әйләнгәндә уртада бер кеше кала. Җыр бетеп, такмак әйткәндә ул берәрсен чакыра да икәүләп бииләр. Аннан баштагы кеше башкаларга кушылып әйләнә башлый, икенчесе түгәрәк эчендә кала.

Әйләнүен болар да әйләнә, түгәрәк эчендә кеше генә юк. Җыр бетәрбетмәстән уртага берсе чыга да бии башлый. Башкалары кул чабып такмак әйтеп тора.

Золото-ой радиатор,
Золото-ой карбюратор,
Золото-ой регулятор,
Золотой магнето.

Такмаклары шундый. Җырлары татарча, такмаклары урысча.

Икенче урында да түгәрәк әйләнәләр иде. Керәшен малайлары безне шунда алып китте. Анда да шул ук уен, анда да шул ук «золотой магнето». Бу миңа бик кызык тоелды. Магнетосы бер үк булгач, нигә бер җирдә генә әйләнмиләр икән болар? Без монда да озак тукталып тормадык, өченче түгәрәк ягына киттек. Билләһи кызык, болар бүтән җыр белмиләрдер, ахры. Монда да «золотой магнето»га бииләр иде.

Тагын шунысы кызык, керәшеннәрдә япь-яшь кенә кызлар да, буй җиткәннәре дә, олырак җиңгиләр дә, картаеп беткән әкәйләр дә шул такмакка кушылып бииләр икән. Безнең сабантуйларда гел яшьләр генә бии.

Без өченче түгәрәк янына килеп туктагач, олы гына яшьтәге бер әкәй, кулын чәбәкли-чәбәкли уенны туктатты.

— Кунаклар килгән, кунаклар! Кызлар, җегетләрне каршылагыз! Борька-а, җегетләрне уенга алып кер!

Безнең белән килгән малайларның берсе Борис исемле икән, шуңа кычкыруы булган икән әкәйнең. Борька ике әйткәнне көттереп тормады, бөтенебезне түгәрәк әйләндерә башлады. Җырларының сүзен белмәсәк тә, Ясәви белән без дә кушылдык.

Менә «золотой радиатор»га житүгә уртага бер кыз атылып чыкты да жилкенеп-жилкенеп биергә кереште. Күзләремә ышанмый торам, бу — Начтый иде. Биеп бетергәч, Начтый миңа таба күзен сирпеп кенә алды да, янадан түгәрәккә тотынды. Яңа жыр башлангач, Борька минем колагыма гына:

— Хәзер биергә синең чират,— дип пышылдады. Мин аңламыйча аңа карагач,— син Начтыйларның кунагы, Начтый биеде, хәзер сиңа тиеш, әдәт шулай,— дип аңлатты.

Менә сиңа мә! Керәшен гадәте шулай икән, кунак булгач нишлисең, буйсынырга туры килә. Жыр бетәр-бетмәстән уртага сикереп чыктым да, үземнең татар Сабантуенда түгел, ә керәшен Майданында икәнемне онытып, татарча биеп жибәрдем. Такмакның яртысына биегәч, тагын керәшен «әдәтен онытып» Начтый каршына килеп бастым. Үзебезнең авылдагы «дастуин» егетләр кебек кыланып, башымны игән булдым, кулымны суздым һәм тагын бер тыпырдап алдым. Үзен биергә чакыруымны аңлап, Начтый да озак көттермәде, кулларын кош канаты кебек жилпи-жилпи, каршыма тыпырдап чыкты. Мин аның кулын эләктереп, үзебездәгечә сигезле ясап әйләнмәкче идем, такмак та бетеп китте. Халык бер мәлгә шым булып калды. Ул арада теге безне уенга чакырган әкәй, рәхмәт яугыры, такмакны яңадан кабатлап жырлады:

Золото-ой радиатор,
Золото-ой карбюратор...

Инде туктарга да вакыт житкән иде, әмма такмакны тагын-тагын кабатладылар. Начтый белән без яңадан сигезле ясап, култыклашып әйләндек. Бию беткәндә минем күзләрем беркемне дә күреп аерырлык-танырлык түгел иде. Бөтен түгәрәк аллы-гөлле, яшелле-зәңгәрле буяулардан гына тора иде. Кая барырга, кай якка атларга белми аптырап торганда, йодрыклаган кулларын югары күтәреп, селки-селки кычкыручы Борьканы шәйләп алдым. Нәрсә кычкыруы булгандыр, аңламадым, шулай да аның янына йөгердем. Мин килеп житкәч, кулымнан эләктереп алды да бер генә сүз әйтте:

— Маладис!

Ул арада түгәрәк яңадан кузгалды. Кая атлаганымны белмичә, мин дә түгәрәккә иярдем.

«Золотой радиатор» яңадан бер-ике тапкыр кабатлангач, Борька мине түгәрәк читенә тартты.

— Житте, киттек моннан. Ату кадерең бетә.

Нигә алай дип әйтүе булгандыр, ул чакта төшенмәдем. Борька безне халык арасында озак йөретте. Көнбагыш (аларча — айбагыр) алып сыйлады. Ике-өч тапкыр сыра эчерде. Хәзер беләм инде, аларның сыра дигәне без белә торган сыра — пиво түгел, ипи квасы икән. Тәмлелеге — телеңне йотарлык! Аннан тагын, кунак икәнеңне белсәләр, ул сыраны сатып бирмиләр, бушлай гына сыйлыйлар икән. Кунакны да, кунакны ияртеп йөрүче хужаны да. Ул көнне Ясәви белән минем аркада сыйланды инде керәшен малайлары! Хәер, алар болай да бушлай эчкән булырлар иде: квас сатучы әкәйләр — үз әниләре бит.

Шулай күңел ачып йөргәндә, без Начтыйны яңадан очраттык. Белгән юк, әллә без аны очраттык, әллә ул — безне.

— Озак жоклыйсың икән, мин торып чыгып киткәндә дә жоклап калдың,— диде ул.

Бергәләп биергә өлгерсәк тә, әле «исәнме» диешергә өлгермәгән идек, исәнләшүе шушы булды. Мин ни әйтергә белми торганда:

— Кыз-катыннар жөгерүен карарга онытма, мин дә жөгерәм,— диде дә китеп тә барды.

Керәшен Майданында уеннар тәртибе безнең Сабантуйдан шактый аермалы икән. Керәшне дә түбәтәй кигән бабайлар алып бармый, әтәчле

колгага менү дә юк, уеннарда да олысы-кечесе бергә катнаша. Төрле җирдә түгәрәк әйләнәләр, биилəр, җырлыйлар. Яше-карты бергә.

Менә бераздан Борька «катыннар җөгереше» башланганын әйтте. Мине төрткәләде дә, әнә киләләр, дип, бер якка чапты. Халык икегә аерылып, коридор ясаган (анысы бездәгечә), коридор буйлата йөгерешче «катыннар» килә.

Авызына чырамы, шырпымы капкан, бите-йөзе акбурдай ап-ак «катын»ны безнең яннан үтеп киткәч кенә таныдым. Ул Начтый иде. Кара син аны, бөтен керәшен «катыннары» арасында иң шәп йөгерүче икән. Икенче-өченче килүчеләрне ул егерме-утыз адымнар артта калдырган иде. Башка йөгерешчеләр дә авызларына нидер капканнар, аларның да йөзләре агарган. Әмма берсенеке дә Начтыйныкы кебек үк түгел иде.

Борька белән без озак көтеп тормадык, Начтый артыннан йөгердек. Без барып җиткәндә Начтый шырпысын ташлаган, үзе күкрәген тота-тота, иелә-бөгелә көч-хәл белән генә сулыш ала. Бераз туктап тора да тагын кузгалып китә. Сулышы кабудан авызын зур ачып, тирән сулый да тагын иелә-бөгелә әллә нинди хәрәкәтләр ясый. Шунда ук, кулына яулык тотып, Виркә җиңги килеп чыкты.

— Менә, кызым, бүләгең. Нинди матур җаулык! Ай-ай-ай, ай-ай-ай, шулай үзеңне-үзең бетерәләрмени! Шул чаклы чабалармыни! Сиңа икенче килсәң җарамаганмыни, ай-ай-ай!

Виркә җиңги шулай такмаклый-такмаклый кызын битәрли.

Борька мине бу тамаша яныннан читкәрәк этәрде.

— Начтый үзенә җаулык кына биргәннәрен аңламый әле кызулыгы белән, — диде ул. — Беренчегә эрҗин кәлүш тиеш ие. Җыл да шулай бирәләр ие. Бераз тынычлансын да барып котларбыз үзен. Әдәт шундый. Чүтеки беренче килде бит җизнәгезнең кызы.

Әмма миңа аны тиз генә котларга туры килмәде әле. Инде тынычлангандыр, сулышы тигезләнгәндер дип барганда Начтый чирәмгә яткан да үкси-үкси елый иде. Виркә җиңги аның янына чүгәләгән, нидер сөйләнә, әрлиме, үгетлиме — белеп булмый. Менә ул Борька белән мине күреп алды да, аз гына елмайгандай итеп, бөтенләй башка назлы тавыш белән тезеп китте:

— Тукта, Начтый кызым, тор дим, әнә кунагың сине котларга килгән.

Начтый, аз гына башын күтәреп, яшьле күзләре белән безгә таба карап алды да, яңадан үләнгә төртелде. Мин аның күзләрендәге теге чәчәкләрне күрергә теләгән идем, булмады. Начтый йодрыгы белән җирне кыйный-кыйный такмаклый башлады:

— Мине алдадылар! Җүри мыскыл иттеләр мине!

Виркә җиңги безгә, китегез, дигән ишарә белән кулын селтәде. Борька сизгер икән — мине сөйрәп диярлек читкә алып китте.

— Аңлаган, үзенә тиешле бүләкне бирмәгәннәрен аңлаган. Моны җә алдаганнар, җә җалгышканнар. Беренче килгәч, бүләге дә беренченеке булырга тиеш. Шуңа кимсенә ул. Бетте, җәренге җыл Майданына чаклы җылыйачак ул кәзер.

Борька, кунагы алдында хур булуына Начтыйны кызганыпмы, хикмәтне әле генә аңлый башлаган мине кыен хәлдән чыгарыр өченме, шулай өзгәләнә иде. Минем Начтыйны тизрәк яңадан күрәсем, нәрсәдер әйтеп, тынычландырасым килде. Тик нәрсә әйтергә икәнне генә белми идем. Миндә хәзер үк Ясәвине эзләп табып, авылыбызга кайтып китү теләге туды. Шул хакта әйткәч, Борька аптырап калды.

— Начтыйны күрмичәме? Бер сүз дә әйтмичәме? Майдан бетмичәме? Питәй җизнәңнең көмешкәсен эчмичәме? Питәй җизнәң авылыгызга барып кыйнар үзеңне! Кунагын сыйламый җибәрсә, аңа хурлык лабаса.

Болай булгач, авылга тиз генә кайтып китеп булмый икән әле. Минем ни хәлдә булуым тәэсир иттеме, үзе бер-бер нәрсә уйлый идеме — Борька да күңелсезләнде. Мин исә ул чакта моңа бәя бирерлек түгел идем әле.

Каршыбызга керәшен малайлары белән Ясәви килеп чыкты. Барысы да бик шатлар, кызып-кызып нәрсәдер сөйләшәләр, бәхәсләшләр, көлешәләр. Беренче тапкыр күрүем — Ясәви авызына папирос капкан.

— Кайда йөрисез сез?— диде ул көлә-көлә.— Без көмешкә эчтек. Сезне табалмадык.

Керәшен малайлары миңа сүз әйтмәделәр, Борькага ташландылар.

— Кунак җегетен сыйламагансың да син, Борька. Бездән аерылып, җүри әллә кая киттегез. Кәзер без сине тотып кыйныйбыз, Борька. Кыйналасың килмәсә, әйдә, безне сыйла, Борька.

Борька авылдашларының «әдәтен» яхшы белә иде, ахрысы. Ул да сүзсез калмады, үзе үк аларга һөҗүмгә күчте.

— Ах, әле сез шулаймы? Бездән качып сыйланып җөрисезме? Без сезне эзләп табалмас дип белгәниегезме? Давай сыйлагыз безне! Җугисә, мин сезне...

Югыйсә нишләтәсе булгандыр Борька авылдаш малайларын. Анысын әйтмәде. Әмма бер төркем малайга шул сүзләре җитте. Алар шунда ук Борьканы юмалый, аңа ялагайлана башладылар. Бәхәс башта мәйданга уен карарга, аннары авылга кайтып сыйланырга дигән килешү белән тәгәлләнде.

Без төп уеннар бара торган мәйданга (майдан түгел, майдан булса, алда әйткәнемчә, сабантуй дигән сүз була, ә мәйданның ни икәнен беләсез инде) нәкъ кирәкле вакытында килеп җиткәнбез икән. Калын-калын такталардан биек кенә итеп эшләнгән күпергә баскан бер абзый, ике кулы белән рупор ясап, як-ягына борыла-борыла сөрән сала иде.

— Чернова Анастасия, Начтый, син мондамы? Катыннар җөгерешендә пирвый килгән Начтый, монда булсаң, бүләгеңне килеп ал. Патамушты бүләк итеп җаулык сиңа җалгыш бирелгән. Әрҗин кәлүшең белән ак наскиеңны килеп ал. Җаулыгың да үзеңә калсын. Ә, нәрсә? Әйе, әйе, Виркә түти килеп алса да җарый.

Абзый күпердән төшә башлауга:

— Краснов дәдәй, бир үзем илтеп тапшырам,— дип, Борька аның янына чапты. Бераздан ул, тутый эләктергәндәй шатланып, кулына ялтырап торган бер пар кәлүш һәм ап-ак фабрика оекбашы тотып, безнең янга килде. Малайларга шунда гына көтеп торырга кушты да мине үзе белән ияртеп алып китте.

— Менә, илтеп бирәбез. Син бирәсең. Җалгышканнарын аңлатырсың үзенә. Җаулыгың да үзеңдә кала дип әйтергә онытма.

Мин бу эшкә бернинди катнашым да юклыгын әйтеп, барсаң үзең генә бар, шушында көтеп торырмын, дигәч, Борька элеккедән дә ныграк шатланды сыман. Һәрхәлдә, ул чакта миңа шулай тоелды. Борька ничек ашкынып йөгереп киткән булса, бер-ике минуттан шулай ук чабып килеп тә җитте.

Авызы колак артына җиткән.

— Бирдем. Алмас дип курыкканыем. Алды. Әйдә киттек сыйланырга. Әйдә, Кә-би-ир!

Без малайлар белән Якты Күлгә кайттык. Кояш эссесеннән әлсерәгән өянке күләгәсенә тезелешеп утырдык. Керәшен малайларыннан бер-икесе, тиз генә өйгә кереп, ипи сыныклары, тозлы кыяр кисәкләре, буш стакан һәм бер шешә көмешкә күтәреп чыкты. Борька стаканга тутырып көмешкә салды да миңа сузды. Үзе, стаканын кулына тоткан килеш, миңа карап, җырлап та җибәрде. Күренеп тора, җырны ул әллә кайчаннан белә, үзенә бер тәм табып, әмма минем хөрмәткә җырлый иде:

Сулар гына буйлап барган чакта-ай
Көмеш тәңкә таптым әлләри.
Көмеш тәңкә безгә әлли ни.
Көмеш тәңкә безгә берни түгел, ләй,
Бер утырулары әллә ни...

Алдарак та сыйланып өлгергән кызмача Ясәви кеткелдәп көлеп алды да, гомергә керәшеннәр арасында яшәгән малай кебек, бик белдеклеләнеп, мине өйрәтергә кереште.

— Монда шулай. Җырлап бирәләр, җыр әйтеп эчәсең. Җырлап та стаканыңны алмый торсаң, тагын җырлап бирәләр.

Аның сүзләрен раслагандай, Борька икенче җырны башлады. Ләкин бу җырның бер өлешен шунда ук үзе уйлап чыгарды бугай ул.

Көмеш баллаккайлар, ай, кигәнсең,
Кунаккайлар булып килгәнсең,
Питәй җизниләргә килгәнсең,
Питәй җизниләргә генә килмәгәнсең.
Рәхмәт дустым, рәхмәт, хөрмәт итеп,
Безнең арабызга кергәнсең.

Мин да калышмаска булдым. Стаканны алдым да җырлап җибәрдем:

Безнең урам аркылы
Ага суның салкыны.
Акмый ла суның салкыны,
Яна йөрәк ялкыны.

Керәшен малайлары башта бер-берсенә караштылар, аннан елмаешып куйдылар, аннары инде көлешә үк башладылар.

— Җыруны үзләренчә җырлады инде бу, үзләренчә.

— Булсын, беренче тапкыр гына бит әле. Өйрәнер әле.

Җырымның бу табын рухына туры килмәгәнен аңлау миңа оят иде. Әмма Борька тагын мине кыен хәлдән бик тиз чыгарды, җырлый-җырлый, стаканын тагын түгәрәктән әйләндерә башлады. Ул чагында миндә, шешәдәге тизрәк бетсен, миңа килеп җитмәсен, дигән теләк кенә иде. Әмма син уйлаганча гына булмый икән шул ул. Стакан түгәрәкне ике дә әйләнде, өч тә, дүрт тә. Чиратым җиткәч, мин берәр йотым гына йота бардым, рәхмәт әйтеп стаканны кире бирә тордым. Ләкин җырламадым. Җырла дип кыстаучы да, башкача көлүче дә булмады. Рәхмәт яугыры, керәшен малайлары минем тәҗрибәсезлекне аңлаганнар иде инде.

Унбишләп малайга бер шешә көмешкә бушаткач, башкалар үзләрен ничек хис иткәндер, минем җиңелчә генә башым әйләнә, көләсем, шаярасым килә иде. Без, шау-гөр килешеп, Майданга киттек. Андагы халыкның да барсына да рәхәттер, бөтенесенен уйнап-көлеп, җырлап-биеп, күңел ачып кына йөрисе киләдер, берсенең дә кайгы-хәсрәте юктыр кебек тоелды миңа. Чынлап та шулай булгандыр. Бер җирдә түгәрәкләнеп утырганнар да кысташа-кысташа сыйланалар. Икенче урында гармунга кушылып җырлыйлар. Өченче төбәктә тузан туздырып бииләр. Без килеп туктаган урында, нәкъ иртәнге кебек, түгәрәк әйләнеп, бии-бии җырлыйлар иде. Кай арада мине күреп алгандыр, шулвакыт түгәрәктән Начтый атылып чыкты да янибызга килеп туктады.

— Чистый жугалдыгыз бит сез! Кайда җөрисез сун сез, Борька? Кунакны талчыктырып бетергәнсеңдер инде.

Начтый үзе шулай сөйләнеп, Борьканы тиргәгән була, үзе аңа әйләнеп тә карамый, күзе гел миндә. Көмешкә җиле минем дә кыюлыкны арттырды, ахрысы. Әрсезләнеп, Начтыйның күзләренә карадым. Теге чәчәк төсле күзләр нурлар чәчеп балкый иде. Ул нурлар минем күзләрем аша, барлык тамырларым аша узып, рәхәт кенә итеп йөрәк уртасына килеп кагылдылар. Йөрәгемне чәнчеп-чәнчеп алгач, яңадан бөтен тәнем аркылы йөгереп, колак яфракларымны кызыштыра башладылар.

Кем нәрсә әйткәндер, кайсыбыз моннан китәргә тәкъдим ясагандыр, хәтерләмим, бераздан без теге вакытта каен пиннеге сындырган куаклыкта идек инде. Ниләр сөйләшкәнебез дә истә калмаган, бәлки берни сөйләшмәгәнбездер дә, бары Начтыйның ничә яшьтә булуымны сораганы гына онытылмаган. Мин, унөчтә, дигәч, ул ничектер дерт итеп сискәнеп куйды сыман.

— Ә мин унбиштә,— диде ул нәүмизләнгән тавыш белән.

Унбиштә? Шушындый кечкенә генә кыз унбиштә булырмы? Мин дә гаҗәпләнеп аңа карадым. Шул каравымда беренче тапкыр аның күлмәге эченнән матур гына кабарып күренгән күкрәк йомрыларын шәйләдем.

— Әйдә, үскәнем, өйгә кайтыйк. Ачыгып беткәнсеңдер инде,— диде Начтый сүрән генә.

«Үскәнем» диюе белән үтерде дә салды бу мине. Бераз йөрик әле диярга теләдем — телем әйләнмәде. Тагын нәрсәләрдер әйтергә теләдем — сүзен табалмадым. Начтыйдан аерылып, Майданга китәргә теләдем — кыюлыгым җитмәде. Башымны иеп, үземнән бер-ике адым гына алдарак атлаучы кызыйга иярүдән башка чара калмады.

Сукмак читендә генә үсүче «Начтый күзен» күреп алдым да ачу белән өстенә бастым, аяк табанымны әйләндерә-бөтерә, чәчәкне изәргә керештем. Бу хәрәкәт кинәт кенә табанымны утлы күмергә баскан кебек көйдереп алды. Ялкыны аякларым аша узып, башымны тубалдай кабартты сыман. Күзләрем берни күрмәс булып томаланды. Шактый вакыт сукмакны күреп түгел, Начтыйның аяк тавышына гына ияреп бардым.

Ишек алдына кайтып җиттек. Кызый мине өйгә чакырды — кермәдем. Нәрсә булды, ачуыңны китердемме әллә, дип, үпкәли башлагач кына, аңа ияреп керергә мәҗбүр булдым. Эре шакмаклы киндер ашъяулык җәелгән өстәл өсте төрле ризыклар белән тулы иде. Бигрәк тә тозлы кәбестәкыярлар, гөмбәләр, бик еш күренми торган пироглар, теләмәсәң дә, өстәл янына чакырып тора иделәр.

Нигъмәтләрне бер-ике кабуга, Начтый пудра савыты кадәр генә пыялага салып, болганчык сыекча китерде.

— Эчәсеңме?

Көмешкә эчәргә һич теләгем булмаса да, юри, Начтыйга үч итеп, эчеп җибәрдем.

— Үзең дә эч!

— Жу-ук, миңа җарамый.

— Алайса, тагын берне бир.

— Сиңа да жук.

Начтый миңа карады да көлеп җибәрде. Бу көлүе, минем ни өчен икәнен үзем дә белмәгән, аңа булган бөтен ачуымны юды да төшерде.

Табын янынннан күтәрелгәч, без яңадан Майданга килдек. Ясәвине эзләп таптым да, Виркә җиңги белән саубуллашып, кайтып китәргә булдым. Ул башта бу турыда ишетергә дә теләмәде. Әнисә килен, куып җибәргәнсез дип әйтсә, мин минават булырмын, дип, үпкәли үк башлады. Мин, үҗәтләнеп, һаман үз сүземдә торгач, җитәкләп үк диярлек Питәй җизни янына алып китте. Алып китте, дип инде, алар шунда, якында гына, сыйланып утыралар иде.

— Питәй, дим, Питәй, карале. Кунак җегете безне җаратмаган. Кайтып китәм, дип куркыта.

Питәй җизнинең сүзе кыска булды. Ясәви белән икебезне дә кулдан гына сөйрәп алды да, табынга утыртты.

Китәргә кузгала башлагач, тагын калырга кыстадылар. Ясәви бер сүз әйтмәсә дә, кайтып китүебез минем өчен хәл ителгән иде инде. Дәлилем: әнкәй кайтырга кушты, бәрәңге күмәсе бар, диде. Ышандыра алдым, ахрысы. Виркә җиңги кесәләребезне чикләвек, көнбагыш белән тутырды да, без, рәхмәтләр әйтеп, кузгалдык. Безнең тарафтан итагатьсезлек булгандыр инде, Борькалар белән саубуллашып тормадык. Без киткәндә башкалар көлешә-көлешә шаулашып, безне мактый-мактый әллә ниләр сөйләнеп калдылар. Начтый гына бик күңелсез, хәтта алай гына да түгел, ниндидер сагышка дучар булгандай, безне озатып калды...

Шактый вакыт сүзсез атладык. Аяк атлавы җиңел булса да, гәүдәне тотуы кыен иде. Җитмәсә, күңел болгана башлады. Ясәвигә әйткәч, ул:

— Әйдә йөгерәбез. Тирләсәң бетә ул,— дип куйды.

Без бер-ике чакрым йөгердек. Башка вакытларда, йомыш төшкәндә, унар чакрымлы авылларга да бертуктамый диярлек йөгереп барып кайткан чаклар була иде. Бу юлы бик тиз хәл бетте. Ярый әле Сөн буена килеп җиттек. Якты күлдән безгә кайтканда бормаланып агучы Сөнне өч тапкыр кичәсе. Монысы — беренчесе иде. Күшегә башлаганчы, чума-чума су коендык. Эсседән соң су коену хәлебезне шактый гына яхшыртты.

Сөн барылмасы саен тукталып, соңгы тапкыр үзебезнең авыл янында су коенып чыктык та, караңгы төшә башлагач, безнең кар базы өстенә җәелгән иләнмәгән сыер тиресе өстенә сузылып яттык. Әлеге тире нича җәй инде безгә йоклар өчен урын-җир хезмәтен үти иде. Бу юлы да иртәнгә чаклы рәхәтләнеп черем иттек.

Сыер саварга чыккан әнкәйнең, бәй, сез кайткан идегезмени? Ярар, бәрәңгене кәтмәнләп бетерергә кирәк, дигәненә уянып торып басмакчы идем, эчем авыртуга түзә алмыйча, кире егылдым.

— Бәй, сиңа ни булды, улым?

Әнкәйгә җавап биреп торырлык хәлем юк иде, бәдрәфкә йөгердем. Анда ике-өч тапкыр кереп чыкканымны сыер сауган җиреннән күреп торган әнкәй ни булуы турында ныклап торып төпчена башлады.

— Бозык әйбер ашадыңмы әллә?

— Юк, бер әйберләре дә бозык түгел ие.

Тавышымның калай табак каккан кебек карлыгып чыгуына үзем дә гаҗәпләндем. Әнкәй исә шунда ук нәтиҗә ясап өлгерде:

— Алайса, көмешкә эчергәннәр бит сезгә. Бала-чаганы шулай итмәсәләр! Татарны бетергән шул аракы инде ул. Эх, беткән баш, беткән баш! Мин сине шуңа дип җибәрдеммени?! Күңел ачып кайтсын дип җибәрдем бит мин сине. Ясәви, син дә тор әле. Синең дә эчең китәме?

Әнкәй әрли дә әрли. минем аны тыңларлык рәтем юк икәнен дә уйламый. Эчем генә түгел, башым да авыртканын үзем генә беләм. Ниһаять, әнкәй, «парын» чыгарып бетереп, ачуланудан туктады. Әллә кызганды, әллә мине яңа «һөнәргә» өйрәтергә теләде.

— Бар, әнә, юка гына итеп ипи кисеп ал да өстенә мул итеп тоз сибеп чәйнә. Эч авыртуың бетмәсме.

Шулай эшләгәч, бераздан, чыннан да, эч авыртуым басылгандай булды. Бәрәңге кәтмәнләвемнең рәте булмаса да, көндезге ашка чаклы өйгә кереп күренеп йөрмәдем. Әмма үз-үземә ант иттем: бүтәнчә гомеремдә дә бер тамчы хәмер йотмам!

Инде әнкәйнең дә ачуы басылган иде.

— Болай кыланып йөрсәң, керәшен кияве итәрбез әле үзеңне. Әнә өч атнадан үзебездә Сабантуй буласы. Шунда бер керәшен кызын ярәшеп куярбыз.

Ачуланулары да шуның белән бетте. Мин дә тиздән бу хәлләрне оныттым. Начтый күз чәчәге дә, Начтый үзе дә алай әле генә исемә төшмәде. Кышкы каникул вакытында безне мәктәптән район үзәгенә концерт куярга алып киткәннәр иде. Шул кичтә Исәмәт базарына барган җирләреннән Виркә җиңги белән Начтый бездә куныл чыкканнар, миңа сәлам әйтеп калдырганнар, диделәр.

Куныл кына китсәләр дә, Начтые, апага ияреп, клуб урынына да йөри торган кәнсәләргә кичке уенга чыгарга өлгергән әле. Ясәви сөйләде, минем апа белән Начтыйны Сәлим озата барды, ди. Минем апаның үзенең берәүгә дә биргесез менә дигән егете бар. Шулай булгач, теге шалапай Сәлим Начтыйны озаткандыр инде, дип уйладым...

* * *

Икенче елның Сабантуенда Начтый белән Исәмәттә очраштык. Без, яшүсмерләр, анда атларыбызны, арбаларыбызны чигүле сөлгеләр, тастымаллар, төрле чүпрәк-чапраклар белән бизәп, дугалар-

га кыңгыраулар тагып, бөтен шартын китереп барган идек. Начтый белән берничә дус кызы, ике-өч малай, җиңгиләр-җизниләр, гадәттәгечә, берьюлы Сабан туе да карарга, аз-маз сату итәргә дә килгәннәр иде.

«Кардәшебез» булганга, Начтыйга Сабан туе күрсәтү дә апа белән миңа йөкләнгән иде. Мин бераз алар белән, аннары үзем ише малайлар янында озак кына күңел ачып йөрдем. Бервакыт Сабан туе мәйданыннан шактый читтә «золото-ой радиатор» җыры ишетелгәч, шунда киттем. Уенда күпчелеге керәшен яшьләре, сирәк-мирәк кенә безнең апалар булса да, алар уенга «төзәтмә» керткәннәр иде. Җыр барганда түгәрәк эчендәге кеше аннан чыкмый, такмак әйтеп бию башлангач та, ул биергә үзе теләгән кешене үзе чакырып чыгара иде. Килеп җитүемә мине дә түгәрәккә керттеләр. Уртада Исәмәтнең Сәгыйть исемле малае, бик килештереп, алпан-тилпән килеп, кыланып йөри иде. Биергә ул минем апаны чакырды. Шунда ук Начтый тыпыр-тыпыр бии-бии уртага керде дә каршыма килеп басты. Без сигезле ясап бер генә әйләнергә өлгердек, такмак бетте, яңа җыр башланды. Башкалар белән яңадан түгәрәк әйләнергә җыенган гына идем, әйдә сыра эчеп киләбез, дип, Начтый мине түгәрәк читенә алып чыкты. Сыра сатучы бер җиңги янына килдек. Начтый сорап тормыйча гына ике стакан сыра агызды. Көн инде шактый эссе булса да, сыраның салкынчалыгына гаҗәпләнеп, рәхәтләнеп эчеп куйдым. Начтый кайчан кайтасылары турында җиңги белән бер-ике авыз сүз генә алышты да без китеп бардык. Ләкин Начтый нигәдер «золотой радиатор» ягына түгел, Сабан туе мәйданы ягына атлады.

— Хәбир, безнең әрәмәдә быел теге чәчәкнең, и-и, күплеге!

Начтыйның мине керәшенчә итеп Кәбир димичә, исемемне дөрес әйтүе гаҗәпләндердеме, мин башта аның нинди чәчәк турында сүз әйтүен аңламыйчарак тордым. Инде аңлагач та, сүз таба алмыйча, шулаймыни, дип кенә куйдым. Аннары бераздан, матурлармы соң, дип өстәдем.

— Бәк матурлар. Түлке чәчәк барыбер чәчәк инде ул, кеше түгел... Матур чәчәк беткәнмени?!.

Безнең сөйләшү шуның белән тәмамланды да сыман. Мин көрәш барышын карап, мәйдан читендә калдым, Начтый «золотой радиатор»га биюче апалар янына китте. Мин әйләнеп килгәндә тагын керәшен уены уйнап яталар иде. Уеннарына да керәсем килмәде, читтән генә карап тордым. Һаман шул түгәрәкләнеп басканнар да уртага бер кешене керткәннәр. Шуңа карап әйләнә-әйләнә җырлыйлар.

Бөгелмәле-сыгылмалы
Көянтәң бардыр әле-е,
Кара кашлы, ак чырайлы
Сөйгәнең бардыр әле.

Беләм, бу уеннарын элек тә күргәнем бар иде. Уртадагы егетнең йә кызның йөргән кызы, йә егете булмаса, шулай дип җырлыйлар. Булса инде, сөйгәнең диясе урынга шуның исемен әйтәләр. Шул уртадагы кеше йә үзе җыр белән җавап бирә, йә түгәрәктән берәрсен сайлап ала да тегеләре такмак әйткәндә парлашып бииләр.

Әнә, әнә, уртада Шалапай Сәлим басып тора. Аның белән йөрергә бер кыз да риза түгел. Кемне кушып җырларлар икән? Бу кызыксынуым мине якынрак килергә мәҗбүр итте.

...Кара кашлы, ак чырайлы
Начтыең бардыр әле-е...

Начтый, диләрме? Сиңа тагын Начтый. И кыланмышы! И кыланмышы! Җырлап җавап бирер микән, биергә берәрсен чакырыр микән? Мин шуны уйларга өлгермәдем, Шалапай Сәлим, әтәч кебек кукраеп, бер-ике сикерде дә, Начтый каршына барып басты. И ала карга! И козгын! Кулларын җәеп, тыпырдап торуын кара син аның! Начтый синең белән биергә чыгамы соң инде! Начтый ул... Чыга бит, ә?! Чыкты шул.

Әйтәм аны, Майдан-Майдан, Сабантуй-Сабантуй, дип атлыгып тора. Башы-күзе әйләнгән икән. Шул вокзал ышпанасы Сәлим генә төс тә инде сиңа!

Көн кичкә авышкач, апа Питәй җизнидән безгә кунарга керәселәрен-кермиселәрен белеште. Ат җигеп килгәнгә кунып тормыйсыларын әйткәч, Питәй җизни, Виркә җиңги белән саубуллаштык та, үз юлыбызга китеп бардык. Бу вакытта Начтый алар янында юк иде. Мин аны күрә алмадым. Шуннан соң да ничектер бүтән бер генә тапкыр да очрашырга туры килмәде...

* * *

...Инде менә дистәләрчә еллар үткәч, шул вакыттагы истәлекләрне хәтердә яңарта-яңарта, алар авылына якынлашып киләм. Моңа чаклы нигә аны бер булса да күрергә вакыт тапмадым икән соң мин? Гаҗәп... Исәнме икән ул Начтый — билгесез чәчәкне хәтерләтүче сәер күзле керәшен кызы? Авылында яши микән?..

Якты Күлгә җитеп, авыл Советына кердек, колхоз ашханәсенә барып тамак ялгадык. Кич белән яңадан авыл Советында очраштык. Ләкин берәүгә дә Начтый белән кызыксынуымны әйтергә базмадым. Ничектер җае да чыкмады шикелле.

Эшлисе эшләрне башкарып, сөйләшәсе сүзләрне сөйләшеп бетергәч, фатир хакында белештем.

— Фатирыгыз әзер. Питәйләргә кайтасыз,— диде авыл Советы рәисе.

— Питәй җизниләргәмени?

Бүлмәдәгеләр көлешеп алдылар.

— Безнең Питәй «җизни» булып өлгермәде әле. Өйләнмәгән җәп-җәш егет.

Мин шунда гына сүзнең барысыннан да ныграк көлеп утыручы Петр исемле агроном егет турында баруын аңладым. Без инде мондагылар белән «син»гә күчеп, алар да минем «пәчти якташ» икәнемне белгәч, шактый ук дустанә мөгамәләгә күчкән идек.

— Ә-ә, син дә Питәй исемле бит әле. Кем малае соң син?

— Сергийнең.

— Кайсы Сергейнеке?

— Кызыл Сиргийнең.

— Мин «кызыл» кушаматлы Сергейне хәтерләмәвемне әйткәч һәм сөйләшә торгач, аның озак еллар авыл Советы рәисе булып эшләгән, теге Майдан көнне күпергә басып, Начтыйга «эрҗин көлүш белән наскиен» килеп алырга кушкан Сергей Краснов икәне ачыкланды. Әлбәттә Краснов булгач, «Кызыл Сергей» була инде. Агроном Питәй аның оныгы икән. Мин үзебезнең Питәй җизни белән кызыксынуымны белдергәч, аның да, Виркә җиңгинең дә инде әллә кайчан бу дөньядан китүләрен әйттеләр.

— Кәзер өйләрендә сукыр Начтый җалгызы гына җәши,— диде рәис.

— Сукыр Начтый? Ничек сукыр?! — дип сорадым аптырап.— Ничек, сукырайдымыни ул?

— Әйе-е. Җарамаган көмешкә эчеп...

Авыл Советы рәисенең бу җавабын ишеткәндә мин Питәйнең калтыранып куюын һәм карашын читкә яшерергә тырышуын күреп гаҗәпләндем. Җыелган кеше алдында моңа игътибар иткәнемне дә сиздермәдем, Начтый турында бүтәнчә сүз кузгатмаска булдым. Җае чыкса, Питәйдән сорашырмын әле, дип кенә уйлап куйдым.

Җае да бик тиз туры килде, Питәй бик сүзчән егет икән. Өйләре авылның иң читендә булганга, без рәхәтләнеп сөйләшеп кайттык.

— Начтый түти бит ул мин белә-белгәннән җалгыз җәши,— дип сөйләп китте Питәй.— Беренче ире — Борька дәдәйне мин әзрәк кенә

беләм. Комбайнчы ие. Бик пиридавай комбайнчы ие. Авыл музеенда ордены да тора иде. Менә шул комбайнда урганда Сөннең теге ягындагы басуга чыгасы булган аның. Әйткәннәр аңа, җә күпердән урап чык, җә трактор килгәнне көтеп тор, дигәннәр. Бу турыдан комбайн белән чыгып булмас, Сөннең ләмле җире, дигәннәр. Борька дәдәй вакытын бушка уздыра торган кеше булмагандыр инде. Көтмәгән. Сөнгә кереп киткән. Уртасына җиткәндә генә тәгәрмәче батып, бер урында әйләнә башлаган. Бер як тәгәрмәче ташлырак җиргә туры килгән, батмаган, икенче ягы ләмне чокыган да комбайны кыегаеп ава башлаган. Ава башлагач, нишләсен инде, сикергән бу. Сикермәскә кирәк булган аңа, җугисә. Машинадан ауганда сикермәсәң, үзе читкә алып ата бит ул. Бу да шулай булырые әле. Ә ул сикергән дә судан калкып чыкканчы өстенә комбайн ауган. Комбайн бер җире белән эләктереп су астында калдырган аны. Бөтен район белән җылаша-җылаша күмделәр үзен. Аларын мин белмим. Начтый түтинең ялгыз җәшәгәнен генә беләм...

Мондый фаҗигале хәлне тыңлавы бик авыр булганга, без бераз дәшми бардык. Аннан соң, малай чактагы танышым теге Борьканың фамилиясен белмәсәм дә, Петрдан шуны сорадым, комбайнчы Борисның шулмы-түгелме булуы белән кызыксындым. Петр, әлбәттә, анысына җавап бирә алмады. Фамилиясе Евдокимов булуын, музейда фоторәсеме дә барлыгын, иртәгә иргән кереп карасак, бәлки таныячагымны да әйтте.

— Анда бит аның җәш чактагы фотосы. Хәзер ул менә сезнең җәшләрдә, җә бераз гына олырак булыр ие,— дип куйды.

— Борька дәдәй беренче ире иде, дисең. Начтый түтиең янадан да тормышка чыктымыни?

— Чыкканые. Ансы җаңарак кына әле аның. Биш-алты җыл да җуктыр. Ансын мин дә җакшы беләм. Сезнең як татары ие ул. Исеме ничек ие суң кәле? Без аны Сергей дип йөрттек. Ну бик эчәдерие инде. Шул эчүе белән үлде дә. Баштарак бик сизелмәгән дә ие. Ну, тора-бара чистый алкаш икәне беленде. Үзләрендә булмаса, Начтый түтине авыл буйлата самогон эзләтеп җөртәдерие инде. Бармаса, тотып кыйный икән. Шулай берчак Начтый түтидән сораганыем дә әле, нишләп шул алкашка түзеп торасың, ку да чыгар, чыкмаса, үзебез куабыз, дип. Начтый түти күңеле җомшарып, җылый-җылый сөйләгәние үземә. Җаратам бит, әллә кай төшен ошатам дип әйткәние. Җаратсаң, кыйналып тор инде алайса, дидем дә бүтән сүз катмадым.

Безнең як татары кем булды икән ул, дип уйларга өлгермәдем, без инде Петрның өенә кайтып җиттек. Шыгырдап торган нарат бүрәнәдән биек итеп салынган йорт, керәшеннәрчә итеп челтәрләр белән бизәлгән кәрнизләр, тәрәзә яңаклары, төрле буяулар белән буялган урыс капка. Йорт каршындагы баганада яп-якты булып янып торучы электр яктысында болар барысы да аеруча матур күренәләр. Начтыйның язмышы белән кызыксыну сәбәбеннән, мин, әгәр бик ашыкмаса, Петрдан бераз капка төбендә утыруыбызны сорадым.

— Начтый түтиең үзе дә эчүгә сабышкан идемени? Көмешкәдән сукырайды, диделәр.

Электр яктысында Петрның тагын ничектер — калтыранышмы, уңайсызланышмы куюын шәйләдем. Әмма бу юлы да сәбәбен сорамый торырга булдым. Бәлки сүз уңаеннан аңлашылыр да әле. Кеше уңайсызлана икән, аны борчу килешми.

— Эчүгә сабышкан дип инде. Хәзер эчмәгән катын җук бит ул. Кайсылары ирләрдән дә шәбрәк сала. Түлке Начтый түти андый түгелие. Анысын точно әйтә алам. Ну, барбер самогоннан сукырайды, диләр бит инде. Значит, шулайдыр.

Начтыйның сукыраюы турында сүз чыкканда Петрның ник уңайсызлануын барыбер белә алмадым. Сорарга да кыенсындым. Җайлап кына, Начтыйны күреп чыгасым килүен әйткәч, Петр җанланып китте.

— Әйдәгез соң, барабыз да керәбез,— диде ул.

— Бу вакытта уңайсызрак бит инде. Йоклый да торгандыр.
— Җук, җокламый әле. Анысын точно беләм. Әйдәгез, әйдә.
Ник әйткәнемә үкенеп, кыенсынып кына кузгалдым. Начтыйлар өе янына җитеп, тәрәзәсендә ут янмавын күргәч, шуны әйткән идем, Петр баягы кебек кычкырып көлеп җибәрде.
— Сукыр кешегә нигә ул ут!
Петр капканы да, өйалды ишеген дә үзе ачып керде. Өйалдында ут яндыргач кына, өй ишеген шакыды. Эчтән хатын-кызның карлыккан тавышы ишетелде:
— Кем бар анда? Кер.
Без ишекне ачып керергә дә өлгермәдек, өй эчендә гөлт итеп ут янды. Ишек төбендәге электр кабызгычы янында бераз гына Виркә җиңгине хәтерләтүче, җилкәсе бөкрәйгәнрәк, шуннандырмы буе да шактый тәбәнәк күренә, йөзе җыерчыклар белән тулган, нечкә муенына утыртып куелган төсле чал чәчле башы аз-аз гына калтыранып китүче, ап-ак чырайлы карчык басып тора иде.
— Исәнме, Начтый түти! Кунак алып килдем сиңа.
— Исәнмесез,— дидем мин дә.
— Шулаймыни? Кунакмыни? Сине урамда көлүеңнән үк таныдым инде, Питәй. Кунагың кем соң? Мин белгән кеше түгел, ахрысы. Таныштыр.
Петрның ничек таныштырырга белми аптырабрак торуы миңа сүз башларга җайлы гына булды.
— Сез мине оныткансыздыр инде, Анастасия Петровна. Без, Питәй җизни, Виркә җиңги дип...
— Ай батюшки, ай гуспыди! Онытаммы соң! Кәзер үк танып алдым тавышыңнан. Хәбир, син бит бу! Синме бу? Сине дә очратыр көннәр бар икән! Исәнме, Хәбир җаным! Ай гуспыди!
Начтый үзе, исәнме, дип күрешергә кулларын сузды, үзе түргә таба китеп барды.
— Йа кодай, ничекләр килеп чыгасы иттең? Ничекләр итеп оныттың безне? Нинди җазмышлар ташлады туган җакларга? Сине әллә кайчан Казаннарда тора дигәннәр ие бит инде. Ай, гумерләр, гумерләр! Исәнме, Хәбир! Әйдә күрешик.
Начтый әллә көлә, әллә җылый, һәрхәлдә, тавышы сызланып-әрнеп чыга иде. Мин аның коры, салкын кулларын учымда озак кына кысып тоттым. Ул да кулын ычкындырырга ашыкмады. Читлектәге кош кебек калтырануын да яшереп маташмады. Бераз тынычланган сыман иткәч, түрдән урын күрсәтте.
— Сукыр әкәйнең өендәге пычракка батып үләрмен дип курыкмасаң, утыр әле каршыма. Күрмәсәм дә, тыңлыйм әле үзеңне. Сөйлә, ничекләр җәшисең? Петр, син дә утыр, басып торма.
— Казанда яшәвемне ишеткәнсез икән инде. Гаиләм бар, балаларыбыз. Яшибез инде шунда...
— Аларын беләм. Дөньҗа киң булса да, кешеләр сөйләп тора бит. Балаларың барын да беләм. Уңдыңмы соң катыннан? Балаларың әйбәтләрме? Үзеңә охшаганнармы?
Минем хәлләрдән шулкадәр хәбәрдар булуына гаҗәпләнсәм дә, кешеләр сөйләп тора бит, дигәч, безнең авыллар белән һаман да аралашалардыр, шуннан ишеткәлидер, дип уйладым.
Аның белән сөйләшүебез дәвам иткән саен Начтый холкындагы теге чактагы чалымнарның гел шул килеш калуын тойдым. Хәзер инде мин аны бетәшкән бер карчык итеп түгел, нәкъ шул элеккеге чәчәк күк күзле керәшен кызы дип кабул итеп утыра идем. Кызганыч, тик бер генә нәрсә бик кызганыч, мин аның күзләрен генә күрә алмый идем. Их, үткән гомерне бер генә минутка кире кайтарып булсачы!..
Начтый түтиенең тормышы турында Петр миңа азмы-күпме сөйләгән булганга, артык төпченеп тормадым. Ике ирдән дә бәхете булмаган,

ахырда тол калган хатынның ярасына тоз саласым килмәде. Йоклыйсыгыз да бардыр, дигән булып, китү хәстәрен күрә башладым.

— Нинди җоклау ди әле ул? Минем бит караңгы төшкәнен көтәсем җук. Көнем дә, төнем дә караңгы минем кәзер. Төннәр буе менә шулай чигү чигеп утырам да, урамда кеше тавышлары ишетелә башлагач, таң атканын белеп, җокларга җатам.

Өстәлдә таралып яткан чигү җепләрен, чигелә башлаган бер тастымал башын да күргәч, бераз аптыраган идем, бу сүзләрен дә ишеткәч, мин гаҗәпләнүнең чигенә җиттем.

— Чигү чигеп, дисезме? Күрмәгәч, ничек соң инде ул?..

— Күз күрмәсә дә, бармаклар күрә бит.

— Ә төсләрне, төсләрне ничек аерасыз?

— Кайчак кешеләрдән дә сорыйм. Җугыйсә, төсне генә бармаклар да күрә икән аны. Берсе җылырак аларның, берсе салкынрак. Бер төс шомарак була икән, берсе кытыршырак. Менә монысын бөтенесе арасыннан, ә, дигәнче аерып алам.

Начтый эшли башлаган тастымал башын сыйпаштырды да бармагы белән бер җиренә төртеп күрсәтте. Анда нәкъ үз төсендәге Начтый күз чәчәге чигелгән иде. Тәнемә электр тогы тоташтырдылармыни! Башым әйләнеп, авып китә яздым. Ярый әле Петр бик тиз ярдәмгә килде.

— Менә шундый инде ул безнең Начтый түти. Көне-төне чигү чигә дә шуны сатып баеп җата. Нәрсә генә чиксә дә, абизательне шушы чәчәген калдырмас. Нәрсәсе бардыр инде шуның? Каенлыкта да бетә торган түгел бит инде алар. Әйтәм бит, чәчәк чигеп баеп җата.

Начтый гел генә теге чактагы күгәрчен гөрләгән тавыш белән көлеп куйды.

— Баерсың! Акчагызның бик кирәге барые! Үзләре бирмәсә, алмыйм да мин аны. Алганнары да шунда җата. Искеләре дә алыштырмаган көе әле. Перестройка акчалары, дип көләм мин алардан. Перестройка бишлеге белән бүгенге илле меңлегегез минем өчен икесе дә киагазь.

Начтый өстәл тартмасын ачып җибәргән иде, анда, чыннан да, яңа акчалар белән туксан өченче елга кадәргеләре бергә буталганнар иде. Начтый тартманы этеп куйды да:

— Эркетирлар килеп алганчы җатсыннар шунда,— дип гөрләтеп көлде.

— Ярар, Анастасия Петровна, без китик инде.

— Озакка килдеңме суң? Үтеп барышлый гынамы — әйтмәдең дә.

— Озакка түгел. Эш бетте. Иртәгә китәрмен дә инде.

— Шулаймыни-и? Җарар, кереп хәлемне белүеңә рәхмәт. Киткәндә хушлашып чыгарга онытма инде. Анысы синең элек тә саубуллаша торган гадәтең җугые җугын. Очрашмасак, хуш, Хәбир. Мин җуләрне гаепләмә.

— Нинди гаепләү ди ул. Исән булсак, очрашуын да очрашырбыз, Анастасия Петровна.

— Каян килгән Анастасия Петровна да Анастасия Петровна инде, җә! Ич җугы бер генә тапкыр, Начтый, диген, ичмасам.

— Ярый, Начтый, хуш, үзең гаепләмә.

Без хушлашып чыгып киттек. Начтый ишек төбендә басып калды. Инде өе күренмәслек ара киткәндә дә аның тәрәзәсендә ут янып тора иде әле.

Иртән шоферым белән Петр машинабызга бензин салырга киткәндә, Анастасия түтиең белән хушлашып чыгыйм инде, үпкәләмәсен, мине шунда гына килеп алырсыз, дип Начтый өенә кереп калдым. Киләсемне белгәндәй, хуҗабикә мине идән уртасында каршылады. Инде кояш чыгып күтәрелгән булса да, электр лампасының янып торуын күргәч, мин, исәнләшүгә, утны сүндердем.

— Сүндермәскә иде, Хәбир. Кичә кич җандырган көе мин аны җүри шулай калдырдым. Син килеп кергәч, өем нурланган ие, шул нур озаграк

саклансын дип җүри сүндермәдем. Хушлашырга гына кергәнсеңдер. Хөкүмәт кешесенең вакыты җуктыр. Әйдә, озата чыгыйм үзеңне.

Ишегалдына чыктык та теге беренче килүемдә Питәй җизни чыгып баскан болдырга утырдык. Дөрес, болдыр да, өй үзе дә ул чактагы түгелләр иде инде. Ләкин төзелешләре, тормышлары гел шул иде. Хәтта түбәсе капланган, алды ачык баз өсте дә миңа таныш иде. Начтый миңа аларны күзәтеп торырга урын калдырмады, вакыт тар икәнен белеп, тизрәк сөйләшеп калырга тырышты. Мин дә аны аңлап, аны сөйләтергә тырыштым.

— Вакыт бер чакта да җитми инде ул, Анастасия Петровна. Безнекеләр килеп җиткәнче булса да, сөйләгез әле үзегез турында. Кичә күп тә сөйләштек, аз да булды.

Начтый мин инде белгәннәрне дә, белмәгәннәрен дә тезеп китте. Комбайнчы Борис, чыннан да, теге мин белгән Борька икән. Начтый артыннан күпме йөрсә дә, кыз башта аңа карамаган. Соңыннан, инде сазаган кызга өйләнеп калмас өчен генә, аңа кияүгә чыгарга ризалык биргән. Торуын әйбәт торсалар да, балалары булмаган. Шулай да, Начтый аның үлемен бик авыр кичергән. Хәтта бервакытны эчкечелеккә сабышып алган. Ләкин, үзе әйтмешли, «бу җаман адәттән кодай саклаган». Эчүен ташлаган һәм шуннан соң грамм да капмаган. Әмма аның иләс-миләс йөрүен эчүгә сылтаганнар. Бу хәл икенче ирен йортка керткәч, бигрәк тә еш кабатлана башлаган.

— Ул чакта мин фермада сыер сава иєм. Төн буе иремне көйлим, үзем куган бетсә, күршеләрдән эзләтә иде. Иртән эшкә барганда аякта басып торырлык хәлем булмый ие,— дип дәвам итте Начтый.— Ә кешеләр шуны исереклеккә җурыйлар. Күзләрем кызарып, битләрем шешенеп барган чаклар да җыш була торганые. Нигә куып чыгармадың, дисеңме? Җараттым мин аны. Яшь чагында өзелеп сөйгән бер җегеткә охшатып җараттым... Җаратуым хакына эчүенә дә түзә иєм. Кыйнап торулары бик авыр булды. Бер дә кызганмый суга ие. Төрмәсендәге кебек... Соңгы тапкыр кыйнавыннан менә шулай калдым инде, сукыраеп.

Мин әлегә бу ирнең кем булуын сорарга базмадым. Эчемнән генә теге безнең авыл Сәлимедер дип уйлап куйдым. Петр да, Сергей дип йөрттек, ди. Начтый да төрмәсендәге кебек, дип куйды. Мин дә бит Сәлимнең ябылуда булуын ишеткән идем. Димәк, шул инде.

— Ничек алай сукыраеп калдың, аңламадым. Гафу ит, Начтый...

— Аңламассың шул. Сиңа, бәлки, көмешкәдән дип сөйләгәннәрдер. Дөрес ансы, көмешкәдән, ләкин үзем эчкәннән түгел. Бер көнне айнырайнымас уянды да, эчәргә даулый бу. Үземнекеке беткән чак ие. Бик нык җәшереп куйган җартыдан башкасы. Көн дә, көн дә эзләп йөргәнче дип, бер чирек кайтарып бирдем мин аңа. Үзем эшкә киттем. Көндез кайтуыма вич эчеп бетергән. Тагын таптыра. Бүгенгә генә түз инде, бер чирек эчеп бетергәнсең дип тә карыйм. Җук, таптыра. Теге җәшергәнне алып биргән иєм, ансы да җарамады. Кемгә дип җәшердең аны дип бәйләнә. Бәйләнде-бәйләнде дә, шундый иттереп сугып җибәрде. Чәчрәп барып төштем. Ишек җаңагына башым белән бәрелеп, аңымны җуйганмын. Күпме җатканмындыр, ансын белмим. Ул көнне эшкә бармагач, иптәшләр килгәннәр дә Начтый ире белән икәүләп исереп җата, дип, чыгып киткәннәр. Төнлә торып караватка менеп түндем. Ул идәндә аунап калды. Икенче көнне иртән дә эшкә чакыра керделәр. Сүз әйтерлегем җук, ыңгырашып кына алдым. Тагын исерек, дип, чыгып киттеләр. Кичкә таба тырышып-тырмашып торып басканыем, ул һаман җата. Әллә суң баш астына мендәр салыйммы, дип карасам, тәне сап-салкын. Үлгән. Җарып карагач, җанып үлгән диделәр. Ул көнне кешегә әйтергә курыктым. Тагын иртән кереп багыр-багыр сөйләнәләр, сүзләрен аңламасам да, тавышларын ишетәм, үзләрен дә томанлы гына күрәм. Күмделәр инде. Күмәргә дә кешеләр артыннан гына ияреп бардым. Абынып егылганда да, кайгыдан шулай инде бу, диделәр. Начар күрүемне берсенә дә

сиздермәдем. Ату кыйнаганын әйтәсе була ие. Әйтергә курыктым. Хурландым да. Бөтенләй сукырайганымны белгәч, ире җанып үлде, үзе көмешкәдән сукыраеп калды дип чыгардылар. Менә ике җыл инде, шулай дип, гайбәтемне саталар.

— Гафу ит, Начтый, мин дә шулай дип ишеттем бит...

— Шулайдыр. Кеше теле тик тормый бит ул, сөйләнә. Белмәсә дә сөйли. Ә чын-дөресен бер кешедән кала берәү дә белми.

— Кем ул? Петрмы әллә?

Начтый бераз гына тынып торды да авыр сулап куйды.

— Ие, Петр. Азрак кына туганлык та булгач, үзе дә гел җакын иткәч, мин исән чакта беркемгә дә сөйләмәскә тәре тоттырып ант иттердем дә әйттем. Ә син аның ул икәнен каян беләсең?

— Юк, белмим. Үзең бер кеше генә белә дигәч, әллә Петрмы дип уйлавым гына иде.

— Сезнекеләр дә бик озаклады әле. Исән-имин генә йөрсеннәр берүк.

— Озак килмәүләре бик әйбәт булды әле. Ихлас сөйләшергә мөмкин булды, Анастасия Петровна.

— Җә инде, Начтый дигәнен бик матур әйтәсең бит. Шулай гына диген инде...

Аерылышу бик авыр тәэсир калдырмасын дип, мин әз генә шаяртып алырга булдым:

— Яшьли сөйгән теге татар егете белән нишләп кавыша алмадыгыз соң? Сер булмаса әйт әле, Начтый.

— Сере жук. Минем аны өзелеп сөйгәнемне белмәде дә бугай ул.

— Күрешкәнегез дә булмадымы?

— Аның беләнме? Очраштык, ләкин күрмәдем.

— Аңладым... Димәк, син аны әле яңарак кына, күзләрең күрми башлагач кына очраткансың, шулаймы?

— Шулай була инде, очраттым. Инде үлсәм дә үкенмим.

— Син бит чыгып йөри алмыйсыңдыр. Әле күптән түгел генә очрашкач, шушы як кешесе буламыни инде ул?

— Шушы җагын шушы җакныкы. Кәзер читтә.

— Кунакка кайткан идемени? Эш беләнме?

— Анысын белмим. Әйтмәде.

— Үзең сорамадыңмыни?

— Читтән нигә кайталар? Менә үзең ни җомыш белән кайттың суң? Кунаккамы, эш беләнме?

— Минме? Мин командировкада.

— Алайса, ул да командировкада була инде.

— Аңламадым.

— И-и кодаем! Нүҗәли әлегә кадәр аңламаган идең? Әллә аңламаган булып кыланасың гынамы? Нүҗәли җәш чакта бер дә сизмәдең? Үзең бит инде ул, Хәбир, үзең. Җарма инде җөрәгемне. Зинһар, кызган сукыр карчыкны.

Мин сүзсез калдым. Хәзер инде машина килсә дә, чыгып китәрлек хәлдә түгел идем. Ник сорадым, ичмасам! Ник төпчендем. Нигә кирәге бар иде миңа моның?!

— Гафу ит, Начтый! Зинһарлап сорыйм, гафу ит мине. Сиңа авыр буласын белгән булсам, сорашмаган да булыр идем. Югыйсә, ул чакта да гыйшык хәлләрен сиздерешмәгән идек бит.

— Ничек инде сиздермәгән?! Теге чәчәкне өзеп алып, синең күзләрең шушы чәчәк төсле икән, дип күзләремә өздереп караучы син түгел идеңме? Җаратмаган кеше алай карый алмый ул...

Менә ничек икән! Бер очрашудагы бер сүз кешенең гомеренә җитә икән бит. Әй, бу дөньялар! Ул чагында чәчәк кенә өзмәгәнмен, Начтый бәхетен дә өзгәнмен булып чыга түгелме соң?!

— Күзләрем сукыр булса да, ул чәчәкне әле дә күреп торам мин, Кәбир. Су сибеп үстерәм мин аларны. Күңелемдә генә түгел, бакчамда

да. Ышанмасаң, әнә, барып кара. Баз артындагы алмагач янында буе ике адым, аркылысы ике адым буш җирем бар. Икебезгә берәр адым. Бернәрсә дә чәчмим мин анда. Үсә торган җирләрендәге кебек булсын дип, кыр үләннәре кайтарып утырттым да, араларына күп итеп шул чәчәкләрнең орлыгын сиптем. Рәхәтләнеп үсәләр. Барып карыйсыңмы?

— Ышанам, Начтый. Тик, зинһар, кыстама. Баралмыйм.

— Дөрес итәсең. Син аларны барып күрсәң, минем соңгы өметем дә өзелер иде. Ә мин әле син бер килеп күрерсең дигән өмет белән яшәдем. Шулай яшәрмен дә, карт җүләр. Әнә, машинаң килә, ишетәсеңме?

Мин күрмәгәнне ул күрә, мин ишетмәгәнне ул ишетеп тора икән. Чынлап та, капка төбенә машина килеп туктады. Мин керәшен кызы Начтыйның күрә торган бармакларын, кулларын кысып тоттым да авырлык белән генә пышылдадым:

— Хуш, Начтый! Хуш, Анастасия Петровна!

— Хуш, Хәбир. Тик, зинһар өчен, өйгә кереп утны яндырып чык.

Мин, аның теләген үтәп, өйгә кердем һәм электр лапмасын кабыздым. Мин әйләнеп чыкканда Начтый сукырларга охшамаган ышанычлы адымнар белән баз артындагы алмагачы ягына кереп бара иде...

Бераз баргач, шоферым тәмәке алырга дип, авыл кибетенә кереп китте. Аңа ияреп мин дә керсәм, киштәдә теге вакыттагы Майдандагы төсле ялтырап торган эрҗин кәлүшләрне күреп алдым. Шунда ук башыма бер уй килде. Ак носки гына юк иде. Бер пар кәлүш сатып алдым да шоферга кире Начтый өе янына барырга куштым. Тик Начтый бакчада да, өйдә дә юк иде. Дәшеп карасам да, җавап бирүче булмады. Ә өйдә электр лапмасы янып тора иде.

Истәлегемне өйдә генә калдырып китсәм, әллә таба Начтый, әллә юк. Тапса да каян килгәнен белмәячәк. Ә минем белдерәсем килә. Күршеләренә калдырсам, әллә ни уйлаулары бар. Якты Күл авылында Начтыйның серен сакларлык бер генә кешене — Кызыл Сирги малае Питәйне генә белгәнгә, авыл Советына кереп, иясенә тапшырырсың дип, эрҗин кәлүшләрне аңа, Петрга биреп калдырдым.

Авыр уйлар белән тулган кайтыр юлымда Начтыйның, сине очраттым, инде үлсәм дә үкенмим, дигән сүзләре генә колагымда чыңлап торды. Кызык өчен генә әйтмәгәндер ул аны, чын күңеленнән әйткәндер. Берничә ел элек үзем белән дә шулай булган иде бит.

Ул чагында республика онкология хастаханәсенә кереп ятарга туры килгән иде. Унбиш кешелек палатада кешеләр гел алышынып тора. Көн саен дүрт-биш яңа авыру керә. Көн саен ике-өч кеше савыгып чыгып китә, ике-өч кешене хастаханә ишеге алдындагы кызыл кирпечтән салынган тәрәзәсез бинага кертеп куялар. Аларны аннан туганнары килеп, елыйелый алып китәләр. Миңа да гел операциядән соң шул кызыл кирпеч бинадан алып чыгарлар кебек тоела иде. Операциягә кадәр шул турыда, балаларымның, хатынымның баш очымда елап торулар турында уйлыйуйлый, тәнемә кызыл тимгелләр чыга башлаган иде. Инде әҗәл белән килешкән дә кебек идем. Тик бер генә теләгем бар иде: моннан нинди генә авыр хәлдә чыксам да, исән чыгарга. Чыгарга да, туган авылыма кайтып, Сөн буйларын, малай чакта аунап үскән чәчәкле болыннарны бер генә тапкыр булса да күрергә. Шул бәхеткә ирештергән өчен корбан чалырга. Исән дә чыктым, гаиләм янына да үз аякларым белән кайттым. Сөн буйларын да, нәкъ балачактагы кебек сакланган болын кисәген дә күрдем. Язмышым өчен Аллага рәхмәт әйтеп, теләгем үтәлде, инде үлсәм дә үкенмим, дип кабатладым. Чын күңелдән әйткән идем мин ул сүзләрне. Начтый да чын күңелдән әйткәндер.

Корбан чалырга гына һаман чират җитми. Нәзерем тотмагае! Ходай үзе сакласын.

*1994.*

# ШИГЪРИЯТ



## Госман Садә

### Ак бүре

*Баллада*

Урмандамы, кырдамы,
Шигырьдәме, җырдамы —
Кырдык кына бүрене,
...Соңгы бүре, ак бүре,
Үлеме син, тереме?

Төркиләрнең юлдашы,
Байрагында кояшы —
Бүре башы, син кайда?

Гасырлар чоңгылында
Югалдыңмы Кытайда?
Таркатып ыруыңны,
Туздырып җир-суыңны,
Монгол явы кудымы?
Муеныңа Чыңгыз хан
Чылбыр бәйләп куйдымы?

Мондый җәза-хурлыкка,
Кара төндәй коллыкка,
Елый-елый түздеңме?
Әллә зынҗыр-богауны
Чәйнәп кенә өздеңме?
Тагын яулар калыкты,
Алар сиңа каныкты,
Буйсынмас рухын күреп.
Соңгы бүре, ак бүре,
Каршыма кил йөгереп.

Афәттән йолып алыйм,
Иркәләп, сыйлап калыйм...
Юк, тарих кире какты.

...Таркалып төште беркөн
Төркиләр каганаты.

...Килде Явыз Иван да,
Сүнде илдә иман да —
Коелды кан, коелды.
Соңгы бүре, Ак бүре,
Күзең кайчан йомылды?

Йөрәктә әрни яра:
Таркалу һаман бара.
...Әгәр дә булсаң тере,
Үз иленә кайт кире,
Соңгы бүре, Ак бүре!

*1991.*

## Кремльдә — тарих дәресе

— Әйтче, әни, безнең Казан
Кремлен кемнәр төзегән?
— Аны, балам, Явыз Иван
Салдырган татар сөягеннән.

*Ана белән бала сөйләшүеннән.*

Ни өйрәндек, нәрсә белдек
Без тарих дәресеннән?
Бер җиңелгән гел җиңелә —
Куркаклык канга сеңгән.

Җиңелгәнне хурлау җиңел,
Безне дә хурладылар.
Күзне куркып ачалмагач,
Тарихны урладылар.

Үзләренә ничек кулай,
Язылды тарих шулай.
Урладылар хәтерне дә —
Барсы да килгәч унай.

Һаман урлый. Һаман туймый.
Һаман да әзсенгәне.
Урламакчы ахыр телне —
Иң соңгы хәзинәне.

Бер җиңелгән гел җиңелә —
Бу инде канга сеңгән...
Тарихымны эзләп йөрим
Урланган дәресемнән.

Кем тергезер тарих утын?
Урланган хәрефләре.

...Казанның нәкъ йөрәгендә —
Хәнҗәрдәй алтын тәре.

*1990.*

* * *

Мин керермен янган утка,
Сине аралап,
Ялкын теле алса әгәр
Ялмап-яралап.

Күрәләтә утка керү —
Сирәкләр эше.
Утсыз гына гомер кичә
Җирдә күп кеше.

Утлы юллар билгелидер
Гомер агышын.
Янар таулар түбәсенә
Менеп барышым...

Тарта күрмә җиң очымнан
Аска өстерәп.
Йөрәк кенә таулардан да
Яна көчлерәк.

Алар минем йөрәгемнән
Алыр җыр отып.
Янар таулар, янар алар
Сине җылытып.

*1991.*

## Бар итүчем, яратучым

Бар итүчем, яратучым,
Уемда Син гомер-бакый.
Синнән килгән тиңсез бүләк —
Мәхәббәтем ишек шакый.

Күрсен җиһан, күрсен галәм —
Ишегемне ачам иркен.
Мәхәббәттә яна белү —
Синнән күчкән бөек иркем.

Бар итүчем, яратучым,
Синең чиксез кодрәтеңчә,
Дәвамчыма сулыш өреп,
Җаным булып каным күчә.

Күрсен галәм: күрсен җиһан —
Ишек ачып улым көтә.
Синнән килгән бөек кодрәт —
Мәхәббәтем дәвам итә.

Исемеңне һәр иртәдә
Тел очымда яңартырмын,
Минем бөек яратучым!
Гомер-бакый яратырмын!

*1991.*

## Көзге өрәңге яфрагына карап язылган шигырь

Карурманда адашмаска
Бездән дә өйрәнерләр.
Көзге шәфәкъ сүнү белән
Кабына өрәңгеләр.

Өрәңгенең һәр яфрагы —
Кояшның керфегедер.
Шәфәкъ сүнгәч яна белү —
Гомернең бер середер.

Мин дә бер көн өрәңгеләр
Яфрагы ябынырмын...
Кичке шәфәкъ сүнгән булыр —
Яңадан кабынырмын.

*1989.*

## Раббым

*Сонет*

Синең хакта нидер сөйләү — гөнаһтыр һай,
Мин колыңны кичер, берүк, йа Раббым.
Җирне-күкне, утны-суны яраткандай,
Тиңнәр тиңе итеп мине яраттың.

Килгәннәргә дөнья якты, дөнья иркен,
Юктыр урын хөсетлеккә, тарлыкка.
Ләкин кемдер синнән үзен куя өстен,
Син аны да, Раббым, зинһар ярлыка.

Ялгышлардан азат түгел адәм заты,
Гөнаһ кыла, гашыйк була шагыйрь халкы,
Дөрләп яна сөю уты, ялкында.

Йөзләремә яга күрмә кара корым,
Яным калыйм дөньялыкта — шуны сорыйм,
Мин тезләнеп, Раббым, синең алдыңда!

*1993.*

## Тарихчы

Равил Фәхретдиновка

Күрәзәче өчен хаҗәтме соң
Куна-төнә яту архивта?
Юраса да сиңа матур язмыш,
Катнашы юк аның тарихта.

Йолдызлардан ерак тарих юлы...
Тарих юлы чумган тузанга.
Күрәзәче күркәм язмыш юрый
Уч тутырып көмеш сузганга.

Күрәзәче өчен көмеш барда
Нигә хаҗәт Алтын Урдалар?
Язмыш юлын кан-яшь югангамы
Тарихчылар сирәк туалар.

Күрәзәче юрый киләчәкне,
Кичәгедә аның эше юк.
Йолдыз теле белән сөйләшсә дә
Ил тарихын язар көче юк.

Кичәге көн архив тузанында.
Кичәге көн һаман өркетә.
Әй, тарихчы! Әйтче чын дөресен:
Киләчәктә безне ни көтә?

*1993.*

## Дүртьюллыклар

I

Кеше үлгәч, җаны кая китә?
Югаламы эреп бер эзсез?
Тере чакта моны кем дә белми,
Үлгәч кенә бары белерсез.

II

Яз житүгә жирдә гөлләр калка
Гөлләр белән тула һәр тараф.
Кеше үлгәч жаны гөлгә күчә...
Булма, берүк, гөлгә битараф.

III

Картайсаң да үзең, жан картаймый —
Бу сүзләрне бик еш ишетәм.
Жаным күккә очар... Соңгы тапкыр
Чыккан чакта гәүдәм ишектән.

IV

Бер күбәләк кунган тәрәзәмә...
Ирeккәдер тели чыгарга.
Аңлыйм аны: ул да кемдер жаны.
Кеше жаны тиеш очарга!

*1989.*

## Пәйгамбәрлек

Мин ачасы йолдызлар
Күптән инде ачылган.
Мин жыясы чәчәкләр
Печән итеп чабылган.

Йолдызларга үч итеп,
Сызгырыйммы ачудан?
— Ялгышасың, абый,— дип,
Жилләр тартты чабудан.

— Буран булып, кар булып,
Житмеш атта жилдердек.
Син ачасы йолдыздан
Сиңа сәлам китердек.

Ул йолдыз йөрәгеңдә,
Жаныңда балкып туган...
...Чәчрәп очты очкыннар
Житмеш ат тоягыннан.

— Сызгыру — кем өчен сер,
Кем өчен хәбәрдәрлек?
Жилләргә дә хас икән
Шигъри бер пәйгамбәрлек.

*1990.*



Тәлгат
Галиуллин

# СӘМРУГ КОШ

хикәя

Апас ягыннан килгән колга буйлы егет, җәтмәгә эләккән балык кебек, авызыннан ләм-мим сүз чыгармыйча күзләрен елтыратып тәк утырса да, доцент Мифтах Сәләхетдинов аңа «өчле» куйды. Керү имтиханнарын алучыларга өстән, егетләрне кире бормаска, дигән катгый әмер төшерелгән иде.

Начар билге алган авыл кызлары, ачы язмышларына ризалашып, укытучыга ни өчендер рәхмәтләр әйтеп, җылый-җылый чыгып китәләр. Шәһәрнекеләр үзләрен башкачарак тота. Әнә җыйнак гәүдәле, гыйнвар кары кебек ап-ак чырайлы Казан кызы, кабырга астына энәсен төртеп, Мифтахның кәефен бозып чыкты.

— Мин риза түгел. Рәтләп тыңламадыгыз, өстәмә сораулар бирмәдегез. Апелляциягә язам, барыбер укырга керәм,— дип тузынып сөйләште.

Нишләмәк кирәк, укырга керүчеләрне имтиханчы сайлап алмый. Кайда янгын — шунда җибәрелгән янгын сүндерүче кебек, укытучы да гариза биргән яшь адәми затны сыный, тикшерә, бәясен куя, киләчәгенә язмыш мөһерен суга.

Бүген соңгы көн. Ниһаять, котылдылар авыр җәзадан. Мифтах иркен сулап, өстәлдәге кәгазьләрен арттарак шудырып, кулларын өскә күтәреп, рәхәтләнеп киерелде, оешкан кан күзәнәкләрен уятып җибәрде. Бәхетле мизгелне, елак бала тавышы чыгарып, ишек ачылу бүлде. Бүлмәдә бер ир пәйда булды. Күңеле нидер сизенгән Мифтах, керүчегә игътибар бирмичә, кәгазьләрен җыештыруны дәвам итте.

— Сулешерга керек иде. Бик важно.

Үз телен оныткан татар шивәсе аһәңе килгән якка карамыйча гына:

— Хуш. Тыңлыйм сезне,— дип шөгылен дәвам иттерде доцент.

— Мин — минбыттан. Ибатулин Илдар булам. Максудович.

Яратып, иркәләп әйтә. Әйтерсең лә, элеккеге фирка исеменнән эшче халкына затлы бүләкләр өләшә.

— Мин двойка алган Шафикова Лэйсэн турында. Ул — миңа никто. Ятим бала. Соседлар без.

Мифтах рөхсәт сорап та тормыйча, янәшәдәге урындыкка оялаган әрсез зат ягына борылып карады. Имәнеп китте. Мондый кыяфәтле бәндәне янында түгел, урамда да очратканы булмагандыр аның. Юк, гарип-горабә дип булмый аны. Буе да уртачадан калкурак. Чандыр гәүдәне эченә алган соргылт-яшел куртканы элеккеге СССРның бүлгәләгән картасы шикеллерәк шакмаклы аксыл чалбар дәвам итә. Ә менә йөзе... Аны хәтергә кадаклап кую өчен ике кат күрешүнең хаҗәте юк. Көл сипкәндәй аксыл чырай. Бите шул чаклы кечкенә... Күзне, йөзнең яртысын каплаган калын пыялалы олы күзлек астыннан кош томшыгы кебек бәләкәй борын чыгып тора. Нечкә иренле, агач кашык та сыймаслык җыйнак авызны түбәнгә таба бөтенләй юкка чыккан аскы ияк тәмамлый. Уртача йодрык хәтле генә башны йомшак кәзирүкле кепканы хәтерләткән кәпәч томалаган.

Йөзе кемнедер, нәрсәнедер, нииндидер җан иясен искә төшерә. Мифтах аны бүре, мәче белән чагыштырып карады. Юк, берсе дә батмый. Олы кошка якынлыгы бәхәссез. Мәгәр нинди очар затка охшаганлыгын тәгаенли алмады. Сәер тойгы калдырды күңелендә чакырылмаган кунак.

Ихтыяҗ чыкканда, кырыс сөйләшә белү осталыгына ия иде Мифтах Нәфис улы. Якыннан белмәгән кешенең аркасыннан чымырчык суык үтәрлек иде аны тыңлаганда.

— Мин сезне белмим, кем иптәш. Дөресен әйткәндә, белергә дә теләмим. Минбыт белән бүрәнәләрем бүленгән. Гафу итегез, бәя куелган, эш беткән. Кыз ифрат йомшак, әзерлеге юк. Аңа ничек тартсаң да, «икеле»дән артык бәя куеп булмый иде.

Гаҗәеп хәл, кошбитнең кырыс тавышка кечтеки иягендәге йоны да селкенмәде.

— Оценка дурес куелган. Понимаете, ятим кыз. Соседлар. Әтисе үлде, пьяница иде. Әнисе — медсестра. Миңа алар никто. Ну, мин помогу! Жалко ведь баланы.

Китте-китте сөйләнеп, берүк нәрсәләрне кабатлый. Җитмәсә, авызында ботка пешерә.

Тәкате корыган Мифтах кайчы белән бау өзгәндәй кырт кисте:

— Минем белән сөйләшү файдасыз. Заяга вакыт уздыру гына. Миннән хәзер берни тормый. Хушыгыз!

Үзенчә кискен, катгый итеп әйтте кебек. Теге бәндә аны әллә ишетте, әллә юк. һәрхәлдә, җитди кабул итмәве, күренеп тора.

— Понимаете, минем өченге ул кем де тегел. Кыз жалко. Мин үзем Сахалинда туып-үскен. Казанда биш ел гына живу. Минбытта эшлим. Министр здравоохранениены яхшы беләм. Нового. Финанс-экономическийда знакомый профессорларым күп. Кыз жалко. Апелляциягә бирик әле? Минбытта эшлим мин.

— Анысы сезнең хокукыгыз. Апелляциягә дә бирә аласыз, жалоба да яза аласыз.

— Юк, мин андый человек тегел. Мине ул кыз кем де тегел. Минбытта эшлим. Кирәк булырмын.

Сөйләшүдән тәмам алҗыган, Ходай тәгалә гарык иткән бу афәттән ничек булса да котылу турында гына хыялланган Мифтах кулын селтәде.

— Барыгыз, сөйләшегез, мин каршы түгел.

Сахалин якларында үскән озын кулларын селти-селти, «кош» очып та китте. Кемнәрнең башын катыргандыр, нәрсәләр вәгъдә иткәндер, анысын алла белсен. Кабул итү комиссиясенә чакырылган Мифтахтан, «икеле»не «өчле»гә тәки төзәттерделәр. Башка фәннәрен яхшы тапшырган кызга мәктәп укучысы статусын яңага алыштыру өчен бик җиткән иде бу. Ярым ятим икәнен дә искә алганнар, күрәсең.

Өлкән имтиханчы буларак, Мифтах студентлыкка дәгъва итүгә хакы булган яшьләр белән әңгәмә уздырырга тиеш. Бу сөйләшүнең бер тиенлек файдасы булмаган кебек, әллә ни зарары да юк иде. Шулай кабул ителгән. Иң соңыннан Илдар Ибатулин белән бәхетле кыз керделәр.

— Зур авырлык белән үттегез институтка,— дип башлады сүзне җаваплы кеше.— Кадерен белергә кирәк. Тырышып укыгыз. Белемегез әллә кем түгел. Үзегез дә чамалыйсыз булыр...

Укырга керүченең ата-анасы, гаилә хәле турында сораштыру кабул ителгән.

— Әниегез кем булып эшли.

— Медсестра.

— Әтиегез?

Ак чырайлы кыз сискәнеп уянып киткәндәй булды. Йөзенә кызыллык йөгерде. Ян белән утырган Илдар ягына төртеп күрсәтте. Янәсе, әттәсе бередә утыра.

Башка берәү булса, сорашыр, төпченер иде. Мәсьәләнең шактый катлаулы икәнен шәйләгән Мифтах елмаеп кына куйды. Минбыт әһеле кызның тән хәрәкәтен күрмәмешкә салышты. Гүзәлне чыгарып җибәрделәр.

— Сез миңа понравились. Я не такой человек. Яхшылык эшлисем киле,— дип сүз башлады Ибатулин.

— Рәхмәт. Рәхмәт. Миңа берни кирәк түгел.

— Сез дөрес тегел атесез! Менә без живем. Мин үзем Сахалиннан. Татарча начар сулим. Аракы эчәбез, хатыннар белән йоклыйбыз, сатабыз, сатылабыз. Кемнедер... үтерәбез. Дураками прикидываемся. Шул халебезге привыкли. Бер уянып китесен... На тебе кемнендер взгляды. Кем ул? Син узенме, другой человекмы? Юк, ул синең долг, ничек әле Казанча, бурычын. Мин бурычлы кала алмыйм. Мин минбытта эшлим. Мин...

Илдар үзенә бер дәрт, көч белән илһамланып, онытылып, сүзләрне бутый-бутый, урта бармагына күгәрчен башы хәтле алтын балдак кигән кулларын һавада болгап сөйли. Аңа ышанасы килеп китте доцентның. Эчкерсез, ихласлы күренә бит.

— Соң нинди изгелек эшли алырсыз икән соң инде миңа? Болай гына соравым.

— Машинагыз бармы? Автомобилегез?

— Каян килсен ди ул. Окладта утырам. Хатын — балалар врачы. Ике малай үстерәбез. Әнә хәзер бәяләр нинди? Машина безнең өчен — тиләләр хыялы.

Илдар Максуд улы, Сахалин татары, урыныннан сикереп торып, бүлмә буйлап йөренеп алды. Йөзе тагын да тартылды, кечерәйде, куллары озынаеп, тезләрен узып китте.

— Можно сделать. Машинаны атэм.

— Ничек итеп? Миндә андый акча юк,— диде тавышында өметсезлек, чарасызлык тулы хуҗа.

— Оештырып була. Москвада бер фирма есть. Машинаны бик дешевога алып була. Мин минбыт егетләренә, финанс-экономическийнын ике профессорына сделал.

Мифтах ышанырга да, ышанмаска да белми утыра. Дон Кихотмы, Хлестаковмы, әллә үзебезнең милли Саламторханмы бу? Һәр адәм баласында җиңел тормыш ягына үгетләп яткан сары шайтан утыра. Бәлки...

Доцентның яңа танышы шул арада күп санлы кесәләреннән кәгазь белән ручка чыгарып язарга, санарга ук керешле.

— Акчаны анларга сдаем. Каждый месяцка 200 процент чиста прирост. Биш-алты айда новый машина алып була.

Гамәл нияттән тора. Йөзенә искитмәүлек, иллэм битарафлык пәрдәсе төшерергә тырышса да, эчен пәри тырнады, кабих комсызлык кытыгын уятты. Аңыннан бәйсез төстә сорап куйды.

— Арзанын ничә айда оештырып була, дисең инде?

— «Таврия»,— диде Илдар тантаналы рәвештә. Андыйны ике-уч месяцта можно организовать.

Каз каңгылдар һәр җирдә, ир абыныр тар җирдә, диләр шул. Танышы Барыйның «Таврия» маркалы машинасына кызыкканы исенә төшеп, бәгырен телгәләп үтте. Әче дару капкан баладай төкереген көчкә йотты.

— «Таврия»нең ишеге икәү генә инде аның. Җайсыз,— дигән булды үзенең машина тануына сокланып.

— Хазыр дурт ишеклене выпускают. Может шундые попадется.

Хыялы чүпрәле камыр төсле уянды доцентның. Менә өйләре каршында затлы ат кебек борынын өскә чөереп, ап-ак машина басып тора. Мифтах абзагыз уң як ишекне ача да, йомшак җирләрен чәбәкләп, малайларын артка төйи. Машинаны беренче күрүдә хатынының авызы тажрая, өнсез кала. Ә ул исе китмичә генә ишекне ача, табигать бизәгән алга утырта. Үзе ишекне яба, юк, менә бу хәтлесе ярамас. Эш хакым синекеннән артыграк дип болай да муенга атланып бара. Хикмәт акчада гынамыни? Абруең булсын, сүзең үтсен, кеше бул!

Шуннан, гәүдәсенә мөмкин кадәр җиңеллек биреп, алгы утыргычка үзен ташлый да чалбарын аска тартып куйгандай итә. Аңлаган кеше кебек, алдындагы аллы-яшелле саннарга, рәсемнәргә баккан була, шуннан соң гына ачкычны бора. Машина, хуҗасының кулы кагылуын көтеп кенә торгандай, тавышсыз гына ут ала һәм, урыннан дәррәү кузгалып китү өчен, газ биргәнне көтә. Чукча турындагы мәзәктә әйтелгәнчә, Мифтах дурак түгел. Ашыкмый. Йөрәген тиешенчә җылытасы бар машинаның. Ул, хатын-кыз кебек, үзенә иркә мөгамәләне ярата. Каударланма, абзый, ди. Автомобиль — бик якын, шәхси әйбер. Аның холкынфигылен яхшы беләсе. Үзенең уйлануларыннан бик мәмнүн-канәгать калды доцент.

Шул арада Илдар тәрәзә буена барып басты. Уйчан һәм эшлекле рәвеш алды. Мифтах тәрәзәдән иңгән яшеллек шәүләсендә яңа мөхлисенең олы уйлар, саф, изге ниятләр белән яшәвенә ышанырга тиеш иде. Гайре мәгъкуль фикерне аның хуплыйсы килде.

— Мин яңа марка «Москвич» алырга предлагаю. Биш ай, ну полгода кутерге туры килер. Предварительный взнос ике миллион. Бер өлеше яшел булуы желательно.

Аңышып җитмәдеме, әллә инде башын җүләргә салырга булдымы, Мифтах сорау бирде:

— Нинди яшел?

— Доллар инди. Мин Сахалинда туып үскән. Кешеләргә добро делать яратам. Счастливый итесем киле. Финанско-экономический профессорына машина бирдем. Яңа минздрав министрын беләм...

Таныш нотыкны янәдән тыңлап бетерергә хәле җитмәде доцентның.

— Күпме кирәк була инде дисез?

— Ике миллион, минимум. Пятьсоты зелененькие.

Нечкә иреннәрен түгәрәккә бөкләде дә, күзлек аша борын очына карап, дәвам итте:

— Минем бер друг бар. Майор милиции. Сорыйдыр: «Син аклар яклымы, кызыллар яклымы?» Мин атэм: яшелне яратам. Шуннан не пристает. Яшел цвет тынычлата.

Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас, дип, тәвәккәлләде Сәләхетдинов. Гөнаһлы җәмгыятьнең берәр төрле нурлы ягы булырга тиештер ич? Максуд абзый малае дилбегәне үз кулына алып, акча юнәтергә ун көн вакыт бирде дә, гаип булды.

Эзләгән корт бал табар, эзләгән ир мал табар, дип юкка гына әйтмиләр икән. Тегеләй итте, болай әйләндерде, саклык кассасында хатыныннан яшереп тоткан акчасын (күпме алып кайтсаң да, юкка-барга туздырып бетерә) алды, бурычка чумды.

Көтмәгәндә, уйламаганда машиналы булып кую өмете нишләтми икән адәм баласын. Кызган табага эләккән борчактай сикеренде, зык купты. Машиналы булса, хатыны «доцентик» дип мыскыллавыннан туктар иде хет.

Ибатулин бераз соңарып, 17 сентябрь көнне офыкта пәйда булды. Офык дигәнебез институт коридоры иде. Югалып торуын җиңел, егетләрчә аңлатты.

— Машина куаладым. Москвадан. Үземә. Хазыр тошып багабыз.

Доцентның җавабын, ниятен көтеп тә тормастан, җиңеннән тотып, аска алып китте. Әнә бераз читкәрәк куелган табышы мәгърур басып тора. Юеш ком төсендә. «Москвич» атлы арбаның иң соңгы казанышын кулына төшергән.

— Моның пять скоростей,— диде Сахалин татары.— Москвадан чыккач, мафия хвостка басты. 200 мен акча требуют. Теге гора башында бирермен, дидем. Скоростька чыктым, газга нажал, девяткалары белен хур булып артта калдылар. Йөртеп карыйсызмы? Юктырмы, ладно тогда, свой йөртерсез.

Машина эчендә утыралар. Илдар арабасын кабызып җибәрде. Йөзендә нәүмиз салмаклык. Телэгенә ирешкән бит егет. Арзан бәягә кулына нинди затлы машина төшергән. «Волга»дан аермасы юк диярлек.

— Минем идеалым бар.

— Нинди?— дип сорап куйганын сизми дә калды доцент.

— Ботен кешегә помогать итү, всех бэхетле ясау.

Дөньяда иң ачы нәрсә дә, иң төче нәрсә дә тел, дип дөрес әйтәләр икән. Гарип телле Сахалин татарының шул сүзләреннән Мифтах коры чыбык төсле шартлап сынды. Хатыны гомере буенча «син каты бәгырьле, миһербансыз», дип битәрләп йөрткән дәүләт доцентының күңеле тулды, соры күзләренә тозлы төерләр килеп бөялде. Кырында утырган битсез, чырайсыз, күзлек белән күп кесәле курткадан гына торган кешегә булган рәхмәт хисләре җылы агым булып, эретелгән бәлзәм, сары май төсле баш мие, лепелдәвен ешайткан йөрәге, тәненең барча уылдыгы аша үтеп, салкын үкчәсенә төште. Котып тавын да җылытты. Кытыршы теле белән сихерләде дә куйды үзен. Сәләхетдинов дулкынлануыннан, каушавыннан күршесенең кулын гына кыса алды. Ә куллары нык иде Сахалин татарының.

— Акчагыз азырмы?

— Бераз җитми әле.

— Сузарга нельзя. Мин поехал.

Шул күрешүдән соң Илдар кайнар тәнгә ябышкан каен себеркесе яфрагы булып китте: телефоннан шалтырата, кафедрага сугыла, бинадан чыгып барганда очрата. Кара кайрак ташы кебек, тынгы бирми.

— Ашыгик! Вахыт уходит!

Мифтахны өмете хәлиткеч адымга этәрде. Урыс акчасын, долларларны аерым-аерым ак фин кәгазенә төреп, үзе өчен зур байлыкны Илдар кулына тоттырды. Фәлән иптәштән фәлән чаклы бурычка акча алдым, дип ышаныч кәгазе яздырмакчы иде. Машинада булган сөйләшүдән соң, шул кәгазьне сорарга оялды. Сүз кодрәтенә буйсынды. Шундый риясыз, гөнаһлыларга җанын бирергә, бөтен татар халкына бәхет өстәргә омтылып торган, яралы йөрәгеңне кулы белән бәйләргә әзер әүлия кешегә ничек ышанмыйсың да, ниндидер намә яздырып, ничек кәефен бозасың!

Илдар акчаларны каударланмыйча гына алды, иркенләп санады вә кәгазьләрдән арындырып, күп санлы кесәләренә бүлеп куйды. Михнәт белән җыйган хәзинәсен карашы белән чит кесәләргә озатканда, ни өчендер Мифтахка моңсу булып китте. Әмма үзен бик тиз кулга алды:

— Рәхмәт инде сезгә яхшылыгыгыз өчен:

— Без ведь татарлар. Татар кешесе шедрый и доверчивый ул. Мин — Сахалин татары. Кешегә долгка бир, курыкма, ышан, не торгуйся. Сиңа уннан бере кире вернется, яхшы. Спасибо ать.

Ошбу сүзләрнең асыл мәгънәсенә төшенеп тә җитмәстән, Мифтах күңелен биләгән җылы тойгыдан һаман да арына алмыйча:

— Рәхмәт, рәхмәт, Илдар дус,— дип кенә әйтә алды.

— Сез артык стеснительный, ничек әле, оялчан. Күзләрегез...

— Мин хатын-кыз түгел лә,— дигән булды Мифтах. Үзенә рәхәт иде.
— Ярый, мин побежал.
Көтмәгәндә бөтен булган, бурычка алган акчаларын җиде ятка тапшырган хөкүмәт доценты егеткә нәрсәдер әйтергә тиеш иде.
— Кайчан күрешәбез?
— Бурчылмагыз. Я Вас найду. Мин яңа министр здравоохранения белән бер йортта тора идем...
— Адресыгызны да белмим. Телефоныгыз да юк. Каян табармын сезне?
— Мин сам найду. Волноваться итмәгез!
Туры һәм күчерелмә мәгънәләрдә җиңеләеп калган Мифтах, кулын изәп, уку бинасына кереп китте. Милләтнең менә шундый изге, кешелекле балалары читтә каңгырып йөри...
Көндәлек мәшәкатьләр белән үзең аша узган вакытны сизми дә каласың. Сәгате көнне, тәүлеге айны алыштыра, адәм баласының гомере шулай үтә дә китә. Мифтах Нәфис улы Яңа елны өендә генә каршы алды. Сахалин татарыннан хәбәр юк. Илдарның теге вакытта санап күрсәтүенә ышанганда, «Таврия»лек акча инде декабрь уртасына ук җыелган булырга тиеш иде. Күрәсең, егет үзенә тиң итеп, «Москвич» алып бирергә уйлагандыр. Хәбәр тотып алса, ярыйсы иде дә. Гел күренеп йөрү дә кирәк түгел инде анысы. Дустан дошман күп, дигәндәй...
Яңа ел алдыннан Мифтахка салкын бәрде. Дуңгыз елының икенче көненә кергәндә тәне кызышты, температурасы күтәрелде. Гомерендә беренче тапкыр диярлек кырынмады да. Өйләдән соң телефон шылтырады. Кемгә нәрсә кирәк икән, дип Мифтах үзе алды трубкәне...
— Это — Ибатулин Илдар. Күрешергә надо.
Ашыга-ашыга сөйләве нәкъ аныкы. Илдар үзе. Ура! Машина... Остап Бендер нәрсә әйткән әле? Машина — не роскошь, а средство передвижения, дигәнме?
— Соң өйгә килегез. Адрес сездә бар бит.
— Юк, телефон только дали.
Мифтах ничек килергә кирәклекне өйрәтте. «Бер частан сезде булам»,— диде Сахалин татары.
Аш-су бүлмәсендә кайнашкан хатыны сорашмыйча түзә алмады.
— Кем борчый анда?
— Бер мафиозник,— диде Мифтах тәкәббер генә. Мафия белән аралашуның гавам арасында бик абруйда икәнлекне чамалый иде хуҗа. Шулар белән танышлыгыңны әйтеп, теләсә кемне бәреп егып була.
— Нәрсә кирәк аңа?
— Соңрак белерсең, белгәч, йөгереп килеп үбәрсең. Мин әле кыйланган булырмын, кирәкми, дигән булырмын.
Тәк. Димәк, машинага чират җиткән. Аны Мәскәүдән үз хуты белән алып кайтырга туры килер, дигән иде Илдарчик. Әгәр бүген, йә иртәгә ук юлга чыгарга кирәк булса. Шоферлык таныклыгы булса да, йөртүе әллә кем түгел. Юл ерак. Һәр яңа машинаны мафия каравыллап тора, ди тукран борын. Юк, юк, башка аны ямьсез исем белән хурламас. Пәрәмәч кебек тулы биткә, кыпчакның бәрәңге борынына өйрәнгәнсең. Димәк, ул үскән Сахалинның дымлы, сулы, юеш һавасы, чит җир мохите киңәергә, җәелергә ирек бирмәгән.
Тукта, берәр тәҗрибәле кешене үзе белән машинаны алып кайтырга кодалыйсы булыр. Теләсә кемгә серне чишәргә дә ярамый бит әле. Карга авызлар җитәрлек. Хатынының энесе оста шофер лабаса. Ул шуңа хәбәр салды. Ләкин тегесе тиз генә килешмәде.
— Жизни, минем бер дә вакыт юк. Үземнең машинаны карыйсы бар.
— Ярый, ялындырасы булсаң, кеше табармын.
Бердәнбер жизнәсе, институт укытучысы белән бәхәскә кереп торуның төшемсез икәнен чамалап (ике кызы үсеп килә, укырга кертәсе була), тавыш кыйбласын үзгәртте:

— Ничек әйтсәң, шулай булыр, жизнәкәй. Бер сәгатьтән әзер. Команда котәм!

Мифтахның кәеф-сихәтләре күтәрелеп китте, кырынып ташлады, тәненең ясалма кызулыгы да кимегәндәй тоелды аңа. Кешене сөенеч яшәтә икән.

Илдарга ишекне үзе ачты, бик якын вә көтеп алган газиз кардәшен каршылагандай, ике куллап күреште, аркасыннан сыйпап, залга алып керде, ишекне яхшылап япты. Күрәсең, дуңгыз елы аңа бәхет алып килергә чамалый. Күпме мөмкин мескен булып, ятлардан миһербанлык көтеп яшәргә?! Чичәннәрчә шигырь әйтеп җибәрә язды.

Ибатулинның өстендә шул ук куртка. Юан пыяла артына, тирәнгә кереп урнашкан хөсетсез күзләре берни сиздерми. Кунак, Яңа ел белән тәбрикләп, вакыт уздырып торуны кирәк тапмады. Үгезне мөгезеннән алды.

— Мифтах Нефисевич, аз гына осечка булды. Бурчылмагыз! Все будек о'кэй. Фирма прогорела. Сволочь БХСС килеп счетларын арестовать иткән. «Москвич» везде 22 миллион тора, а монда шестка йиберелер. Ничек, почему? Лавочканы закрыли. Февральде мин тагы еду. Булыр. Пока акчаны китердем әле.

Мифтах берни аңламый. Колаклары тыгылды. Ни сөйли бу кош битле инсан, аңа нәрсә кирәк? Әйтерсең лә, кызышкан тәненә чиләге белән бозлы су тондырдылар.

Шул арада Сахалин татары курткасының сансыз кесәләренең берсеннән әзер кәгазь кисәге, каләм тартып чыгарды. Туктаусыз сөйләнә-сөйләнә, язды, сызды, санады. Сүз белән фикер бердәмлегенең нәтиҗәсен — доцент колагына тукыды. Дөресе, үтә күренмәле пакетка төргән акчаларны сабый хәлендә утырган Мифтахның сәлперәйгән кулына төртеп кертте.

— Сезге ике миллион акча. Считайте! В сентябрьдэ долларның курсы низкий иде. Җитми иде. 200 тысяч үземне добавил. Эни говорит, кеше ренҗеп утырыр. Отнеси, бехилен ал, дир.

Какса-сукса да замана, яшим әле, егетләр, дигәндәй, Сәләхетдинов озын кулларын туктаусыз хәрәкәтләндергән, каршысында утырган затка күтәрелеп карарга үзендә көч тапты. Маржа кешесенең туң балыкныкы төсле бер урында катып калган күзләренең төсен билгеләве кыен. Суы кипкән күл төбе төсле. Аскы ияге бөтенләй юкка чыккан. Шулай да кыяфәтендә, үз-үзен тотышында хәйләкәрлек, этлек сизелми сыман. Күктән бер гөнаһсызга сөрелгән фәрештә диярсең үзен.

Температурасы янәдән чикерткә төсле өскә сикерде Мифтахның. Ул инде санны санга кушарлык хәлдә түгел иде. Төп башына утыртуның ни икәненә ул соңрак төшенәчәк. Акчаны санап алырлык мөмкинлеге дә юк хәтта. Ишекнең теге ягында, эш кылган булып, хатыны кыштырдый. Колаклары затлы нәселле этнекедәй үрә торгандыр инде.

Ясалма кеше — робот төсле төргәкне чалбар кесәсенә шудырды. Сахалин татары каршысында таштан уелган сындай басып торган Мифтахны, сатлык Иуда төсле кочаклап үпте дә, сөяксез телен әйләндерүен дәвам итте:

— Скоро Китай мин барам. Несте нужно — привезу! Ну, пока!

Бу фани дөньяда Илдар Ибатулин белән соңгы күрешүе турында хәбәрдар түгел иде әле тышкы ишекне ябып, лып итеп кәнәфигә барып утырган дәүләт доценты.

Аның ялгыз каласы, ташка төшкән бәллүр пыяладай уалган зиһенен, ватылган тәнен җыясы, нәтиҗәләр ясыйсы килә. Кичен бик каты салган кешенекедәй башы чатный. Кая инде ул безнең илдә шәхес иреге дигән нәрсә була алсын ди? Кайгы-хәсрәтең белән күзгә-күз карашып калырга кем ирек бирсен, ди инде сиңа? Чуар халатыннан йомры тезбашларын алга ташлый-ташлый, Мифтахның хәләл җефте керде. Янына килеп кунаклады.

— Кем иде ул? Нәрсә кирәк аңа? Ник чәйгә утыртмадың?
Хатын-кыз сорау бирә башласа, бер белән генә чикләнмәс.
Башка вакытта югалып, каушап калуның ни икәнен белмәгән, сыртка салдырмаган мәче кебек, гел аякка төшкән Мифтах нәрсәдер уйлап чыгарырлык, ялганларлык хәлдә түгел иде.
— Беләсеңме, Мөршидә, бу мафия малае миңа арзанрак бәягә машина юнәлтеп бирермен дигәние... Кызы керде укырга... Мин бераз ярдәм иткәнием...
Мөршидә ханым барча җитезлеге белән урыныннан сикереп торды.
— Ой, шәп булыр иде ул... Иеме? Барып чыгар диме соң мафияң?
— Юк шул. Без өйләнгәч төн кыска, диләрме әле. Фирма янган. Пожар булган бик көчле.
— Нигә ул хакта миңа әйтми йөрдең? Темнила!
— Иртә кычкырган әтәчнең башы авырта. Сюрприз ясамакчы идем.
Мөршиданең сөмсере коелды. Олы кунаклар киләсе көнне мичтә бәлеше янган диярсең.
— Нишләп эч пошырып йөри алайса? Телефоннан гына әйтсә... Әшәке хәбәрен.
Хуҗа кеше тавышына төрттерүле, кинаяле юмор чаткылары үрләтергә тырышты:
— Мафия бит. Серлелек төсмере, төтен, томан кирәк аларга.
— Булдыксыз алып-сатулар белән аралашмасаң тагын... Мафия мондый үләт булмый. Әйткәнеңдә тора.
Хатыны белән килешкән хәлдә дә, Мифтах матурының тизрәк бүлмәне калдыруын теләде. Аның кайгысы башкада иде. Уң як чалбар кесәсендә бүлтәеп, бүселеп яткан акча беленмәсен. Киң учын куеп, аягын аяк өстенә ташлап карый, урыныннан торып, бердәнберенә ян белән басып, Наполеон позасын кабатлый. Ә агач акча бәйләменең күләме вакыт узган саен зурая баргандай тоела. Исәп-хисап, бурычларын түләгәч, ул калганын, әлбәттә инде, хуҗабикәсенә кайтарып бирер. Кая илтсен ул аны. Каты-котыда утырмаса да, түләүле сөяркәсе юк.
— Мин азрак ятып торыйм әле, хатын. Температурам күтәрелә бугай.
— Йоклап китмә! Тиздән ашарга утырабыз!
Фән әһеленең хәле, чыннан да, мөшкел иде.
Шул ятудан чын-чынлап хасталанып китте Сәләхетдинов. Авыруга китергән көчле кичерешләр дулкынының каян килгәнлеген үзе генә белә. Үпкә, рәнҗү хисе, эчтән януы, гарьләнүе аны аяктан екты. Җаны үксеп-үксеп елады.
Акчаларын санап карагач, аскы ияксез мөҗәһитнең үзен кычкыртып «печеп» киткәнен аңлады. Ул акчаны кайтарган көнне бер долларның кимәле дүрт меңгә менгән иде. Димәк ки, аның 500 тәңкә яшеле үзе генә дә Илдар тантаналы тапшырган акчага тора. 700 меңе дә өч ай эчендә шактый үскән булырга тиеш иде.
Иш янына куш дигәндәй, икенче көнне бичәсе эштән тагын бер «яңалык» төреп кайтты. «Ялган акчалар күп таралу сәбәпле, 50 меңлекләр алышына, юкка чыгарыла икән. Бер иллелегем бар иде, көчкә алыштырдым, дип, үзе дә сизмәстән иренең йөрәгенә үткен без белән кадап алды. Чөнки Ибатулин калдырган акчаларның барысы да диярлек иллелекләр иде.
Аңлашылды. Акча белән уйнау ихтималын ишеткән озын колак, бурычын ашыга-кабалана китереп аударган. Бер өлешен...
Кырык бишен алыштырган доцент Сәләхетдинов үзенең шундый ахмак хәлдә калганын хәтерләми. Беркатлы һәм йомшак күңелле, хәерче галим-голәмә халкын алдауның, сүз белән эретүнең җаен тапкан бит бер балаклы манкорт. Ул еш телгә алган хисап институты укытучылары да шулай ук муеннан нәҗестә утырмыйлармы икән? Хезмәттәшләре?

Гарьләнүдән йокысыз калды. Әллә нинди кабахәт төшләр күрде. Албасты, Ширин бабайлар, юха еланнар, шайтаннар белән булышты, шабыр тиргә батып, куркып уяна торган булып китте. Юк-бар өчен акылдан язарсың, дип шөлли калды. Үзен теләсә нинди җисемле сынландыруны кулланудан тартынып тормыйча әрләде: шыр тиле, дивана, ахмак, надан, кем инде сиңа тиктомалдан чирек бәясенә машина китереп тоттырсын. Аның максаты долларлар суырып алу булган. Шул кәсеп белән тамак туйдыручы шакал икәнен сиземләве кыен идемени? Йөзеннән, үзен тотышыннан, теленнән күренеп, эчкеченең авызыннан бәреп торган махмыр исе шикелле аңкып тора бит аның нинди нәселдән икәнлеге...

Алдакчыны тозлап-борычлап әвәләгәч, бераз җиңеләеп киткәндәй булды. Мәгәр йомшак ятакта иркәләнеп, чирләп ята торган вакыт түгел иде. Хәрәкәт итәсе, акчаны каядыр урнаштырасы... Долларга алыштыру ниятен сайлады акылы.

Бәяләр кискен күтәрелү, имеш-мимешләр таралу сәбәпле, акча алыштыру нокталарының күбесе ябык булып чыкты. Шөкер, «Совет» кунакханәсендә эшли икән. Таныш-белеш юкмы икән дип, як-ягына каранакарана, чиратка басты. Табигый ки, ул кассага килеп җиткәнче, долларлар сатылып бетте. Бу гамәл барып чыкмагач, бурычларын өләшергә кыйтыклады доцентыбыз.

Өенә соң гына, арып, хәлдән таеп кайтты. Әңгер-меңгер халәтендә теге мафия кешесен күрде. Каты итеп әрләде үзен: «Егетем, сез абзый берни аңышмый калды дип фараз кылсагыз, нык ялгышасыз. Кәсепче икәнегезне беренче күрүдә ук сиземләдем,— диде доцент үзен күтәребрәк куюны кирәк санап.— Бу кешедә намус заты аз-маз гына калмадымы икән, дип сынап карарга булдым. Иманыгызны сары шайтанга, нәфескә саткан кеше булып чыктыгыз... Жаль... Артык акчаларым югын беләсез. Сез сораганны байтак вакыт җыйдым. Югары уку йорты укытучысы башым белән базарга чыгып, җилдә җилфердәтеп хатын-кыз эчке киемен сатып утыра алмыйм ич.

Сезнең хакта фикеремне ачыктан ачык әйтимме? Кемнәндер ишетергә тиеш сез аны. Беренче очрашуда ук сезнең вак жулик, проходимец, шулер, прохиндей икәнегезне аңладым. Бу төшенчәләрне татар телендә дә аңлатып була. Тик сез аны татарча аңламассыз... Минем каргышым төшәр, балаларымның өлеше тотар! Гомеремдә беренче кат чын күнелдән рәнҗим мин. Тамагыңа балык сөяге булып кадалсын миннән урлап үзләштергән акчалар...»

Шулай берничә көн саташып, нотыгын үз-үзенә сөйләп һәм һавага өреп йөргәннән соң, бераз тынычлангандай булды мөгаллим әфәнде. Алдакчыны эзләп тә карады. Исем-фамилиясен хәтерләсә дә, эшләгән, яшәгән урыннарын белми иде. Еш телгә алынган «минбытта» андый кеше табылмады. Һәрхәлдә, кадрлар бүлеге аша үтмәгән.

Шунда апелляция белән укырга керергә ярдәм иткән кызый исенә төште. Эзләп тапты кәгазьләре арасыннан. Шәфикова Гүзәл икән. Аны табып сөйләшүнең файдасы булмастыр. Әтисенә кайтып әйтер дә, теге «кош» кояш чыгышы якларына очып та китәр.

Бердәнбер әмәл кала: кыз беренче имтиханын бирергә тиешле укытучыны табып, «ярдәмен» сорарга. Җиңел шөгыль түгел бу. Гадәттә, кемгәдер уңай бәя куюны, билгене күтәрүне сорыйлар. Ә биредә шуның киресен эшләүне үтенәсе була.

Сынау алучыга: «Арзан бәягә машиналы буласым килгән иде дә, бу абзагызны ыштанын салдырып, кырмыска оясына утырттылар, җәзасын гөнаһсыз сабыйдан алырга булдым»,— дип, дөресен әйтәсеңме? Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә шулай җиңел аңлашу, дөресен ярып бирү алымы яшәсә, шәп булыр иде дә. Юк шул, без аңлы тормышыбызның күп өлешен алдау, ялганлау, шомарту, хәйлә белән уздырабыз. Хакыйкать ачы, аны әйтергә йөрәгебез, тынычбыз җитми.

Ояла белү сәләтен ахыргача жуеп бетермәгән Нәфис агай малае, соравын түләүле уку өчен кертелмәгән акчалар, ялган документлар белән бәйләп, буталып бетте.

Гозер белән мөрәҗәгать иткән танышы егет кеше булып чыкты.

— Аңлатып торма. Син сорагач... Вуз укытучысының бөтен байлыгы — «бишле»дә, көче — «икеле»дә.

Шәфикова беренче имтиханын бирә алмады... Калганнары өчен кимсенеп сорап торасы да булмады. Югары уку йортында студентнын язмышын тәүге сынау хәл итә. Беренче фәннән эт койрыклы билге алса, бу — туачак бәхетсезлекнең ныклы нигезе. Түбәнге баскычта ук сөрлеккән талиптәлибәнең якты киләчәгенә, ил гыйлеменә өлеш кертүенә кем ышансын да, үзен хөрмәт иткән мөгаллим беренче билгене чыгарган, дөресе, берни дә куймаган коллегасына ышанмыйча, күзле бүкәнне, шыр наданны тыңлап, заяга вакытын уздырып утырсын, ди. Фәннәр, наданлык шикелле үк, үзара бәйле тормыш чылбырының боҗралары. Үрмәкүч пәрәвезне үрә тора...

Кыскасы, икенче укытучы элек куелмаган тамгага тулы ышаныч белдереп, алдында калтыранып утырган адәм баласына мондыйрак нәтиҗәсен ирештерә:

— Мин сезгә уңай билге куя алмыйм. Имтиханга әзерләнмәгәнсез... Лекцияләрне калдыргалагансыз... Болай ярамый... Теләгегез булса, тагын бер кереп карый аласыз! Тик белмим...

Өченче имтиханны алучы мөгаллимнең эше бөтенләй җиңел. Аның мәчесе куян тота. Вөҗдан атлы әкәм-төкәмнең борчылырга да әхлакый хакы юк. Ике фәнне аударган студент ничек инде ул алып барган иң катлаулы, авыр һәм иң кирәкле предметны беренче керүдә үк уңай бәягә тапшыра алсын, ди. Тузга язмаганны. Үз фәненең бәһасен, абруен төшерүгә юл куймас!

Менә шул мантыйк кануннары иләгенә эләгеп, Сахалин татарының күрше кызы өч сынауның берсеннән дә уңай нәтиҗәгә лаек була алмый.

Әрсезлек бар икән үзендә. Доцент Сәләхетдиновны эзләп таба.

— Исәнмесез? Мин Шәфикова Ләйсән булам.

— Хәтерләмим. Безнең авыл кызы мәллә?

— Юк ла. Миңа апелляция белән институтка үтәргә ярдәм иткән идегез.

— Искә төшергәндәй булам.

Шул ук ап-ак чырай, тар, арык җилкәгә сибелгән соры чәч. Тагын да ябыгып, кечерәеп, кәҗә бәтие хәтле генә калган. Имтиханнарын тапшыра алмаганга борчылганга охшый.

— Соң, тыңлыйм сезне. Миннән тагын ни кирәк? — диде доцент, кызның әлеге бичара хәлгә төшүенә өлеш кертмәгән кешедәй, шактый дорфа итеп.

Шәфикованың хәле мөшкел булудан хәбәрдар булса да, зарыгып көткән кешесе бу бәләкәч түгел иде. Шәриф Камалның депутаты кебек, алдан әзерләп куйган нотыгын күңелендә кат-кат әйләндереп, тегенең үпкәсенә, бавырына, бәгыренә төшәрлек итеп чарлап (аның уенча), үзен шулай туктаусыз чыбыркылап, кыздырып, ул аскы ияксез ни бәндә, ни кош булган җан иясе белән очрашуга өмет иткән иде.

Менә теге килеп керә бүлмәгә. Берни булмагандай лып итеп урындыкка утыра. Ләйсән турында сүз катуга, үтенечен әйтүгә, Мифтах бармакларын уйнатып әйтеп куя:

— Иптәш, әүвәл минем биш йөз яшелне өстәлгә чыгарып сал! Сәясәтчеләр әйтмешли, шул алшарт үтәлсә, әңгәмәбезне дәвам иттерербез.

Тегесе куртка кесәләреннән әллә нинди квитанцияләр, кәгазьләр чыгарып саный, сөйләнә, күзгә Сахалин томаны җибәрә башлый. Мифтах инде ирлек мәктәбен узган кеше. Бу юлы җиңел генә алдатмас!

Доцентның бу хыялы да чынбарлыкның явыз матурлыгына бәрелеп чәлпәрәмә килде. Кыз, кулындагы кичтәге кульяулыгын угалый-угалый, сүзен дәвам итте:

— Мин өч фәнемне дә тапшыра алмадым. Бик яхшы беләм дип масая алмыйм, әмма башкалардан, һәрхәлдә, «өчле» билгесе алганнардан кимхур сөйләмәдем.

«Мин бит сездә эшләмим. Ул факультетка катнашым юк»,— дип үткен пычак белән акмай аша гына үтмәкче иде дә, ялкынсынган мие, зиһене теленә ачкыч бирде, сорау тартып чыгарды.

— Теге ир кеше... Кем әле... Илдармы? Ул кайда хәзер?

Кызый һич көтелмәгәнчә, читлеккә эләккән бүре баласыдай күзләрен зәһәр уйнатып, кистереп җавап бирде:

— Ул юк. Юкка чыкты.

Кыска җавап доцентның яралы җанына тоз сибү белән бер булды. Аның әльгазиз яшел яфраклары да мәңгелеккә, галәм киңлекләренә очып киттеләр дигән сүз иде бу.

— Ничек инде ул юкка чыкты?

Ләйсән бу юлы сүзне тагын да кыскарак тотты. Кулларын як-якка җәйде дә, авызын сабый балаларча бөрештереп: «Тю-тю!..»— диде.

Мифтахның бәлеш төбенә үк төшәсе, беләсе, ачыклыйсы килүе табигый иде. Шәфикованы сөйләтте, ачы хакыйкатькә барып житте.

Ибатулин Сахалиннан кайткач, нәкь менә алар яши торган катта бер бүлмәле фатир сатып алган. Ләйсән исә, әнисе белән өч бүлмәледә яшәгән булган.

— Ни өчен яшәгән идек дип, үткән заманда әйттең әле.

— Фатирыбызны бүлдек.

— Әтиегез аерым яшиме? Ул аерылып... чыктымы?

Кыз Мифтах ягына бу юлы күзләрен мөлдерәтеп, әрнеп, үрсәләнеп карады. Бу абыйга барысын да сөйләргәме, юкмы икән, дип үзен борчып алгач, алдында утырган кешенең кызыксынып тыңлавын күреп, фикерен дәвам иттерергә булды. Эчендәгесен житди кешегә сөйләп, бушанасы да килгән иде аның.

— Юк ла! Теге абзый. Сез белгән Ибатулин фатирыбызны бүлде. Әтием үткән ел вафат иде. Сезгә әйткән идек кебек.

Ләйсәннең дулкынлана-борчыла сөйләвеннән Мифтах шуны аңышты. Сахалин татары күршесе Хикмәтулланың, ягъни Ләйсән әтисенең салырга яратканын сизеп алган да, кичләрен гел үзенә «капкаларга» чакыру йоласын керткән. Бер ящик «Рояль» атлы спирт алып кайткан. Ашамыйча эчү гадәте әтисенең бавырын, бөерен череткән, соңрак йөрәге тоткан. Агуланган, дигәннәр. Ярып, тикшереп тормаганнар.

Салкын чишмә суы капкандай тешләре камашты Мифтахның.

— Ибатулин безгә кучте,— дип дәвам итте кыз.— Мин аны «папа» дип атарга тиеш булдым.

— Үз фатирын нишләтте?

— Җавабы әзер иде. Минеке түгел иде ул,— диде. Безгә пропискага керде, тулы хуҗа булып алды. Бер ел чамасы узгач, әнигә, миңа көнетөне бәйләнде дә, фатирыбызны бүлде. Безгә ике бүлмәле хрущевка, аңа кирпеч йорттан бер бүлмәле эләкте.

— Әниең авыр кабул иткәндер.

— Ул әти белән дә интеккән иде. Тик мондый явыз, хәйләкәр, гасаби кешене күргәнем юк иде әле, ди. Байтак кеше безгә аның машина алып бирәм, дип алдалап алган бурычларын сорап килде. Куркытучы, янаучылары да булды. Безгә акча каян килсен! Менә шул. Дөрес, мондый мәшәкатьләр белән рәтләп укый да алмадым. Әмма «өчле»лек беләм мин абый...

Фикерен тәмамлады да, Сәләхетдинов ягына олыларча үпкә катыш житди караш ташлады, тагын нидер өстәргә иткән иде дә, кулын селтәп, тиз-тиз чыгып китте.

Кызый бәян кылган хәлләр аңа ифрат авыр тәэсир итте. «Йөзем ак, күңелем пакь», дип үзен тынычландырырга тырышса да, барып чыкмады. Бер дустының яраткан гыйбарәсе колагында чыңлый: ир-ат гоме-

рен ачы телле, көнче хатын белән ашамыйча эчкән хәмер генә бетерми, үпкәләү белән ваклашу күбрәк кыскарта. Доцент Сәләхетдинов ваклашты, кара чәүкә үчен чыпчыктан алды. Кызыйга эшләгән этлеге исенә төшкән саен җаны, үтәли җилгә эләккән яфрак кебек лепелдәде, йөрәге парә-парә килеп телгәләнде.

Кызга ничектер ярдәм итәсе булыр, дигән фикерне күңеленә беркетеп куйды.

Машинага мөнәсәбәттә фикере үзгәрде. Ахмак бер хыял булган икән ул. Йөртү тәҗрибәсе дә килделе-киттеле кешегә андый пырдымсыз аргамакның ниемә хаҗәте бар. Берәр җиргә китереп сыларсың, тырышып җыйган малың бер мизгелдә күккә очар. Әле үзең исән калсаң! Арбасы булса, куярга урыны, гаражы кирәк. Өй янында тотсаң, угрылардан саклап, үзеңә тышта кунасы була. Машиналы булу — баш авыртуы эзләү, теш сызлавы алу гына ул. Гомумән, ни чуртыма кирәге бар миңа машинаның. Эшли торган җиремә астыннан тимер тәртәләрен суырасуыра тимер әрҗә-трамвай унбиш дәвыйкәдә илтеп җиткерә, бакчага поезд дигәннәре алып бара. Машинасыз — кайгы-хәсрәтсез, вакыт-аргамакны үземә буйсындырып, үз җаема гына яшим әле рәхәтләнеп.

Әмма машина җене, дөресе, түләп бетмәгән бурычлары аны үз җәтмәсеннән тиз генә ычкындырмады. Әле хуҗасына долларларны кайтарасы бар иде.

...Хәзер доцент Сәләхетдинов туган анасына да дөресен әйтә алмас: ул чын-чынлап йокыга талган идеме, әллә изрәп, боламыкланып киткән вакыты гына булдымы? Акылы ком сәгате кебек эшли. Һәрнәрсәне ап-ачык хәтерли. Бер мәлне йокы бүлмәсенең урамга чыккан почмагы машина капоты кебек ачылып китте. Аннан, кабык түшәмне күтәреп, әнисенең яшереп куйган тәмле ризыгын чәлдерергә келәткә кергән малайдай бер җан иясе төште. Доцентның язу өстәленә аягымы, кулымы белән таянды да, идәнгә, аксыл келәмгә төшеп басты.

Сәләхетдинов башын күтәрде, ике кулы белән мендәренә ябышты. Коты очудан бигрәк, чакырылмаган кунакны яхшырак күрәсе килде. «Бу йә Әҗәл, йә Язмыш минем арттан килгән. Берсе җанымны теге дөньяга алып китсә, икенчесе сары йортка тапшырыр» кебегрәк ямьсез уйлар өермәсе миен көйдереп узды. Әүвәл иң борынгы мәҗүси затка — маймылның бер төренә охшаган җан иясенең куллары канат булып чыкты. Калын күзлекле кечкенә йөзен очлы, озынча томшык алыштырды.

Канатларын җәеп, җилпенеп куйды. Фәнни мәкаләнең язу өстәлендә яткан битләре, давылга юлыккан йомычкалардай, бүлмә буйлап очып йөри башлады. «Болай да язылып бетмәгән гыйльми хезмәтем, шайтан алгыры, зав. каф. өшерәчәк»,— дигән ямьсез уй зиһенен игәүләп үтте.

Шул арада түшәмнән иңгән зат телгә килде:

— Әй, син — суалчан, Сахалин татары синарга бурычлымы?

— Әйе. 500 доллар тиеш ул миңа,— диде Сәләхетдинов. Үз тавышын үзе ишетмәде.

— Ренҗеп ятасынмы?

Уйларга бер минут та вакыт бирелмәгән. Канатлар җилпенә, язу өстәлендәге кәгазьләр тишектән очып чыгып китә тора.

— Рәнҗүдән ни файда? Бурычка алганием... Түлисе була...

Шунда сөйләсәң кеше ышанмаслык хәл булды. Кош томшыгы белән саргылт-яшел курткасының күп санлы кесәләрен актара башлады. Алардан мөселманнар байрагы төсле куе яшел йөзлекләрне алып, Мифтах ягына ата башлады. Унны ташлады. Үзе мыскыллап, явыз итеп ырҗайды.

Бу хәлдән таң калган доцент мәрхәмәтле кошка исем эзләп зиһенен болгатты. Ләк-ләкме? Ул ак төстә бугай. Әниләре каргышы төшеп, күрешә алмыйча саргайган Сак белән Сокларның берсеме?

Халык иҗатында могҗизалы, беркем күрмәгән әкияти. Сәмруг кош бар түгелме әле? Шул үзе микән әллә, мур кыргыры?

Кош янә телгә килде:

— Танысынмы, свой долларларны?

— Таныйм дип. Алар бар да бер төсле.

— Бери, алар синеке!

Томшыгы белән җыеп алып, Мифтахның йонлы күкрәген каплаган ак җәймәле юрган кырыена ук китереп куйды. Мифтах кулларына алды. Әйләндереп-тулгандырып карады, кат-кат санады. Барысы да Сәмруг кош әйткәнчә.

Бурычын кире алуга тәмам өметен эзгәч, кәтмәгәндә акчаларының ике тапкыр артып кире кайтуыннан өнсез калган доцент иске сумала кебек каткан иреннәре аша көч-хәл белән берничә сүз кысып чыгара алды.

— Сезне кем дип белик?

— Мин — Сәмруг кош. Алла колы. Ишеткэнен бар? Мин беркемне обижайт итмим.

Тавышында, әллә каян, балачактан килгән бераз үзгә, бераз таныш чалымнар ишетелгәндәй булды. Хәтерли алмады.

— Эни сказала,— диде дә, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, канатларын җыеп алды һәм түшәмдәге тишеккә кереп китте. Капот шап итеп ябылды.

Күңеленә исәп төште доцентның. Тиз генә долларның бер өлешен Рәсәй акчаларына алыштырырга кирәк. Калганы бурыч түләүгә китәр. Суыткычлары, юыртып барган мәлгә чыгымчы аттай, тукталып калды. Түбән Кама тарафларыннан энесе җибәргән тана боты йомшап, сүлен агызып ята. Яңаны — чит илдә эшләгәнен алып, шатландырыйм әле хатынны бер. Болай булгач, отты бит әле абзагыз. Ниязга бурычын да чыгарып сала, яңа суыткычлы да була.

Өстенә зәңгәрсу күлмәген, иске коңгырт кәстүмен, пальтосын киде дә, атылып урамга чыкты. Акчаларны чалбар кесәсенә тыкты, сул кулын да шунда калдырды. Берәрсе долларга кызыкса, теләсә нинди Гали батырны, урам мафиясен бәреп егарга әзер булып, уң кулын чытырдатып йомарлады.

Эт чаба дип, бет чаба дигәндәй, ашыкты, «Совет» кунакханәсенә ничек барып җиткәнен хәтерләми. Касса ачык. Сап-сары чәчле, озын кара керфекле кызга эре генә биш данә «яшел»не суза.

— Тиз генә алыштырып бирегез әле?

Кыз акчаларны алды. Утка күтәреп карады, сәмәнне каядыр тыкты, аннан түгәрәк ак төймәгә басты. Шул арада күрше бүлмәдән килеп чыккан ала-кола киемле ике короллы егет безнең доцентны култыклап алдылар.

— Киттек, абзыкай! Без сине күптәннән көтәбез. Берничә банкны утырткан идең. Үзең дә яхшы каптың.

Мифтах кулларын, гәүдәсен ычкындырырга тырышып карады. Кымшана да алмады.

— Җибәрегез мине! Акчамны аласым бар. Жалоба бирәм. Мин — дәүләт доценты,— дип кычкырды ул.

— Әһә, әле доцент башың белән ялган акчалар ясап, шуларны таратып йөрисең икән! — диде омончыларның берсе.

— Бөтен хикмәт шул укыган кешеләрдән чыга. Тикшерерләр, ачыкларлар.

— Мин беркая да бармыйм. Акчамны аласым бар.

— Менә алар синең акчаларың, фальшивомонетчик!

Шунда гына доцент үзен ялган долларлар тапшыруда гаепләүләрен аңлады. Үкенечле сагыш тулы күз карашы белән әле генә кулында тоткан «яшел»ләрне сыйпап үтте. Йә хода, бар икән күрәселәрем! Юк, боларга аңлатырга, акланырга кирәк.

— Мин чын акчалар тапшырдым. Әнә президент башы ярылып ята.

— Президент башында эшең булмасын. Акчалар ясалма. Каян алдыгыз аны?

Дөресен ярып салмыйча, болардан ычкынып булмасын бөтен тәне, ашказаны белән сизенгән доцент Сәләхетдинов мәсьәләгә ачыклык кертте.

— Миңа аларны... аларны... бурычымны кош алып килде. Калдырып китте.

— Нинди кош? Сез ни лыгырдыйсыз?

— Сәмруг кош!

Омончылар, сары чәчле кыз, чиратта торучыларга бер-берсенә сәерсенеп карашып алдылар. Кулга алучыларның өлкәне зур җиңү яулаган Америка индеецлары кебек шатлыклы авазлар чыгарды.

— Без ул Сәмруг кошын күптәннән эзлибез! Бу кушамат безгә яхшы таныш. Ниһаять, ялган акча сугучыны да тоттык, дөнья-күләм наркобизнес белән бәйле кешене дә эләктердек. Ике көймәнең койрыгын тоттык. Ходай биргән нинди бәхетле көн!

Икенчесе аны куәтләде.

— Киттек, киттек, абзыкай, син безнең өчен кадерле кунак. Иң югары хуҗалар зарыгып көтәләр сине!

Мифтахны ике яктан култыклап, җилтерәтеп алып киттеләр. Ул карышты, тыпырчынды, үзе Сәмруг кыяфәтле Ибатулинга охшатып, туктаусыз сөйләнде.

— Мифтах, дим! Мифтах! Сиңа ни булды? Бастырыласың түгелме?

Ул таныш тавышны ишетеп, авырлык белән генә уянып китте. Кара болыт төшкән күз кабакларын көчкә күтәрде. Фирәзәдәй яшел таш күзле хатыны Мөршидә тёрткәли икән.

Доцент тонык күзләрен түшәмгә юнәлтте. Күк капусы ачылмаган. Бераз күтәрелә төшеп, өстәлгә күз салды. Һәммә нәрсә үз урынында. Ярый әле барысы да төшендә генә булган икән. Чәнчелеп китсен лә, Әмерикә президентының пеләш башы төшерелгән акчалары. Безгә бәхетне алар китермәс, мафия әһелләре дә алып бирмәс, ахрысы.

Башка вакытта уятса, йокларга бирмисең, дип мыгырданырга яраткан доцент Сәләхетдинов бүген хатынына рәхмәтле иде. Сөеклесенең ачык тезенә ялган акчалардан котылган кайнар тозлы кулын салды.

Әмма Мифтах хатынын ялгыш аңлаган булып чыкты.

— Сиңа килгәннәр анда.

— Нәрсә? Кемнәр?

— Сине сорыйлар. Нияз диме шунда. Долларлар алып торгание, срочно үземә кирәк, ди. Бар, үзең аңлаш!

## ИЛДАР ӘХСӘНОВКА 60 ЯШЬ



# Илдар Әхсәнов

## Баш иям — ияләргә

**Илдар Әхсәнов исемен укучыларыбыз яхшы белә. Ул — шигырь мәйданында илленче елларда күренә башлап, аннан шактый еллар Әлмәт төбәгендә тормыш һәм иҗат эзләнүләре белән кайнап, җитмешенче-сиксәненче елларда инде ныклап аякка баскан, китапларын чыгарган һәм бүген, ышанып әйтергә мөмкин, поэзиядә үз урыны булган шагыйрьләрдән. Аның шигырьләрен, бер сүз белән генә, эзләнүчән, кырыс тормыштан килгән уй-фәлсәфәле, халыкчан, моңлы иҗат дип бәяләп булыр иде.**

**Юбилее белән котлап, бу санда тәкъдим ителә торган яңа шигырьләр шәлкеме дә шул хакта сөйли, безнеңчә.**

### Наз

Башны башка куеп, һай, бахбайлар
Иркәләнә шундый наз белән,
Болай нәзакәтле яратышкан
Адәм затын хәтта аз беләм.

Күзләрендә — гакыл, бәхет нуры,
Башлар башка, сөеп, куелган;
Мәгънә сирпи йөзләр, югыйсә бит
Тик агачтан алар уелган.

Күккә сузып зифа муеннарын,
Татлы үбешәләр микәнни?
Рәссам кулы белән Ходай биргән
Бәхет диешәләр микәнни?

Шул бахбайлар мәхәббәтен көнләп,
Нигә икән үзәк өзелә?
Берсе булсам иде шуларның дип,
Хыяллана рәссам үзе дә.

Җил дә үтмәс — бер-беренә башлар
Сыенганнар шундый наз белән,
Мондый сөю-сөелү тылсымын мин
Тиңлим кодрәт биргән яз белән.

## Айлы төндә

Кайсы урман тарафыннан
Пәйда булган, күр әле,
Җиде төннең уртасында
Сәфәр чыккан Шүрәле.
Тынгы беткән хозурында,
Кая сиңа тынгылык?
Ахырзаман якынлаша,
Карурманнар кырылып.
Тернәкләнмәс инде бүтән
Җәнлек тулы аланнар:
Әкиятләр дөньясына
Тәмуг уты салганнар.
Кайсы урман хозурыннан
Мәхрүм калып, күр әле,
Адәми зат иҗтиһатын
Барлап йөри Шүрәле.
Бу соң нинди галәмәт ди,
Каршысында — таш урман;
Тәрәзәләр үз язмышын
Иблис җанга тапшырган.
Тоныкь яна төнге утлар,
Корулыдыр пәрдәләр;
Моңсулыкмы күзләрендә
Шүрәленең, әллә әр?
Күзәтә ул таш оясын,
Өнсезлеккә таң калып.
Яшәү табигатен җуйган
Соңгы үлән, тапталып.
Кемнәр ыңгыраша анда,
Кемнәрдер типтерә;
Шәүлә булып урам иңли
Шүрәлегә тиң әрәк.
Айлы төндә фатирсызлар

Кай тарафка сыенсын?
Этләр өрә, фәкыйрь затка
Таш илендә кыен соң!
Айлы төндә шул каланы
Бер күзәтеп йөр әле.
Уфтанадыр гомер бакый
Көлемсәр җан — Шүрәле...

## Ияләр

Рәссам Әхсән Фәтхетдиновның
иҗат күргәзмәсен карагач.

I

Эчтән балкый тансык илаһи нур,
Сыгылып төшкән моңнардан —
Сер иясе дигән бу балкышка
Өннәребез соңарган.
Соңарган ла үкенечкә каршы,
Заманалар буталган;
Кайтыйм дисәң мәгәр асылыңа,
Үзең белән бер Аллаң.
«Ияләр»нең бөтен фаҗигасен
Иясезлек биргәндер;
Ерак тамырларның ялгануы
Кабат туу белән бер.
Газаплыдыр бу яңарыш юлы,
Денсезлекләр газабы;
Милли тетрәнүгә терәр икән
Иясезлек сабагы!
Кыргый империя базарында
Татар өстән сатыла;
Үги булмас идек болай, без бит
Иясезләр заты ла!
Кылыч кисмәс диеп, безгә тагы
Башны күпме иясе?
«Ияләр»дә милләт тамырлары,
Җитми хәтер генәсе!
Уала тау-ташлар, болгана су,
Күктә йолдыз атыла;
Дөнья имин барыбер яратылган
Кавемнәре хакына.
Баш иям мин изге «Ияләр»гә,
Җан тартканга баш иям;
Тамыр көчен тоеп ләйсән яңгыр
Шифасыдай яшь коям.
Төсләрендә үгисенгән чалым.
Ә рух сөрелгән чорлар.
Йөрәктә — ут, газиз ияләрем
Кайчангача йончырлар?..

II

Иялəр күп,
Яшəү гамьнəренə
Ия кеше башлап син үзең.
Моржаларда йөри җил Иясе,
Керфек какмыенча төнозын.
Әле ничек адəм баласыннан
Бөтенлəйгə Иман качмады.
Исəннəргə баглап айлы кичтə
Дога укый кабер ташлары.
Тəрəзəгə ятып, гаярьлəргə
Бəддогасын ата Убырлы;
Белми явыз — хəят, уй башында
Затлы Тукай сүзе торырны.
Һич юк үлем, тормыш дəвам итə,
Бу хəтлесе безгə сер əле...
Айлы төндə үз əшнəсен сагынып,
Ишек ачып керə Шүрəле.
Татлы и балачак хыяллары,
Нəкъ кояшлы алан хозуры.
Бар табигать белəн бербөтенлек
Аңлы затны җирдə тудырды.
...Әйлəнеп тə тулганып төн кичə
Иялəрнең бөек Иясе:
Чын инану хисен кайтарырга
Янасы да əле көясе...



**Рөстәм Мингалим**

**Ризван Хәмид**

# ИДЕГӘЙ

(НӘФИС ФИЛЬМ ӨЧЕН ДРАМА)

## Икенче фильм

### I — бүлек

**1. Җаек елгасының аргы ягы. Иртә.**

**Идегәйнең сөт туганнары белән Бәхтияр учак ягып ашарга пешерәләр. Иярле атлары шул тирәдә утлап йөри. Идегәй үзе зур агач күләгәсендә уйланып утыра: аның күзләре — елга артында калган туган илендә.**

Идегәй *(моңлана)*.

Ап-ак кына тирмәм түбәсендә
Дога гөрли микән күгәрчен?
Ак догасы миңа ирешми шул,
Ишетмәсләр булдым, күрәсең?! —
Ишетмәсләр булдым, күрәсең, ай,
Ишетмәсләр булдым, күрәсең...

Якыннарым янда шикелле дә,
Кулым сузсам тапмыйм үзләрен.
Әллә күрмәс кенә булдымы соң
Бөркетләрдән мирас күзләрем?! —
Бөркетләрдән мирас күзләрем, ай,
Бөркетләрдән мирас күзләрем...

Алтын бакча, Алтын Урдам шаулый,
Бу кайларда тынар җил икән?
Тәкъдир җиле куган алтын яфрак —
Мин микән ул, әллә ил микән? —
Мин микән ул, әллә ил микән, ай,
Мин микән ул, әллә ил микән...

Бәхтияр. Табын әзер, Идегәй!

Идегәй *(бер карарга килеп, сикереп тора)*. Тамак сипләп алыйк та — Шаһ Тимергә киттек! Ризыгыбыз читкә язган булмаса, исән-имин урап бер кайтырбыз. Сәхрә малайлары ла без! Яңабаштан башлыйбыз алышны!

**Юлдашлары Идегәйне сырып алалар: түрәләренең бу карары — бик җитди адым! Шаһ Тимер — Алтын Урданың иң куркыныч дошманы бит, димәк, Идегәй туган иленә хыянәт итүгә бара.**

Бәхтияр *(җитди)*. Идел-Йортка хыянәт, дип саныйм мин моны, Идегәй! Һәрьягын ныклап уйладыңмы? Күк Урда әмирләре Туктамышка каршы җар салганыңны гына көтеп тора, алар белән агай-энеләрчә генә эш итсәң, булмасмы?

Идегәй. Әйе, хыянәт, Бәхтияр! Тик туган йортка түгел, Туктамышка. Шаһ Тимер иле — безнеке кебек үк төрки. Ике туган кыен чакта бер-берсенә сыена алмыймы?! Күк Урда әмирләре көчсез, чөнки таркау. Алар, бөтенесен бергә җыйганда да, Туктамыш янында көчек кенә. Бүген Туктамыш хан — зур фил! Ә Шаһ Тимер бүген — Туктамыш азманнан гайрәтлерәк. Менә нигә сыенам мин аңа! Шулай да, Туктамышның куенында андый әмирләребез булуына сөенергә кирәк: арткы аелың нык булса, ат дулап ни кылыр!

Бәхтияр. Шаһ Тимер кабул итмәсә! Куып җибәрсә? Кемгә сыенырсың?

Идегәй *(ышаныч белән)*. Куып җибәрми! Туктамыштан үч алырга җай гына көтеп йөри ул! Яшермим, барасы юл хәтәр һәм авыр. Сусыз ком чүлләре, дошман җирләр аша үтәргә туры килер безгә. Юл хәстәре ашыгыч эшләнде: ачлыгын да, чөлләсен дә баштан үткәрербез. Кемгә кул түгел — һәркем үзе хәл итсен.

Ашарыбызга калмаса, киекауларбыз, эчәребезгә бетсә — агач тамыры чәйнәрбез! Ике көнлек юлда безне Тимер-Мәлик ханның уллары Тимер Котлый белән Күнчә көтеп торырга тиеш — алар да Шаһ Тимергә сыенырга булганнар. Бәхтияр! Син — минем тугрылыклы дустым, азакка кадәр минем белән булырга әзер: лачын кошка һава кадерле. Сөт туганнарым, сезнең сүзне көтәм! Нишләптер, Исабәк абыемны күрмим?

Берсе *(караңгы чырай белән)*. Ул — Туктамыш хан белән калырга булды. Ә мондагыларыбызның сүзе бер, Идегәй, без — синең белән! Туктамышның колы булганчы, этнең улы бул!

Идегәй. Кайчан да булса Исабәк белән орыш кырында йөзгә-йөз очрашырга туры килүе бар, үкенмәссезме?

---

Дәвамы. Башы 7 нче санда.

Икенчесе. Туктамыш хан — кыргын чир вакытында безнең әтине, «Алтын Таш» капкасыннан кертмичә, урамга — үлемгә куып җибәргән кеше! Без Исабәкне бергә китәргә күндерә алмавыбызга гына үкенәбез. Үз язмышын үзе сайлады — ул үкенсен! Балалык тешләрен күптән ташлады.

**2. Дала. Көн.**

**Учак янып, казан асылган, быкыр-быкыр су кайный. Идегәйнең юлдашлары каклаган елкы ите пешерергә җыеналар.**

Идегәй килеп җитә: ул кыр кәҗәсенә охшаган киеген җиргә ташлый һәм атыннан сикереп төшә.

Идегәй. Елкы итен куегыз, ул соңрак кирәк булачак. Чүл башлангач, киек ату кыенлашыр. Менә моны эшкәртегез!

Бәхтияр *(киекне әйләндереп карый)*. Бу нинди адәм күрмәгән җәнлек?

Башкалар. Чынлап та... Күз күрмәгән, колак ишетмәгән нәрсә бу!

Идегәй *(елмая)*. Күрмәсәгез дә аш булсын!

**3. Шунда ук. Кичке як.**

**Идегәй** *(ит ашаган арада)*. Хәтәр тәмле ризык булды бу... Ә сез — күз күрмәгән нәмәрсә, дисез! *(Кинәт.)* Алла...

Бәхтияр *(ашый-ашый)*. Ни булды?

Идегәй *(авызыннан бик тә сәер формалы сөяк ала)*. Аңкауга кадалды... Шулкадәр ачыттырыр икән! *(Сөякне читкә ыргытмакчы була.)*

Берсе. Тукта, бир әле монда? *(Сөякне әйләндергәләп карый һәм кычкырып җибәрә.)* Нугай татарларының борынгы ыру тамгасы ич бу!

Бәхтияр. Каяле... *(Сөякне җентекләп тикшерә.)* Дөрес... Безнең бабаларныкы да кайчандыр шушы булган... Кызык!

Берсе. Бер дә кызык түгел! Идегәй! Бер серле хикмәт бар монда! Юлыбыз уңмас, ахры! Табу салган киекне атып алгансың!

**Барысы да, ашауларыннан туктап, Идегәйнең җавабын көтәләр.**

Идегәй *(хәлнең җитдиләшүен аңлап)*. Сөйләмә юкны! Киресенчә, ата-бабаларыбыз рухы безне кисәтә: сәфәрегез бик ерак, ниятегезне үтәп чыгарга ашыгыгыз, ди! *(Бәхтиярга.)* Тамганы ташлама, кесәңә салып куй: тылсымыбыз булыр. Кузгалдык!

**4. Коелы үзән. Кич.**

**Сәфәрчеләр куна туктаган. Тышаулы атлары якын тирәдә утлап йөри. Көн буе атта килгән җайдаклар бик арыган, ял итеп яталар. Бер читтә көлле учак: юлчылар ашап-эчеп, тамак туйдырганга охшый. Шул тирәдә үк сөяк-сыныклар аунап ята. Бәхтияр белән Идегәй бүтәннәрдән читтәрәк, башларын иярләренә куеп, әкрен генә сөйләшеп яталар.**

Бәхтияр. Кәефең юк, ахры, Идегәй? Ашавыңның да рәте булмады бугай.

Идегәй *(сөт абыйларына карап)*. Тегеләргә сиздермә, үзеңә генә әйтәм, Бәхтияр: аңкау бик каты шешеп килә... Тән кызыша... Җәрәхәт аша кирәкмәгән нәрсә үтеп, кан бозылуга китермәгәе, дип куркам. *(Ул шактый кыенлык белән сөйли.)*

Бәхтияр *(тирән борчылып)*. Күрсәт әле...

Идегәй. Чү! Бүтәннәр сизенмәсен, дим ич...

Бәхтияр *(бераздан)*. Шул гына җитмәгән иде!.. Кичкә чаклы әйтми килгән аны... Мин бер үлән беләм: караңгы төшкәнче эзләп карармын! Юкса, соң булуы бар! *(Китәргә кузгала.)*

Идегәй. Ашыкма... Исем бар чакта әйтеп куйыйм... Әгәр дә иртән тора алмасам, мине абыйларым белән калдыр да, Тимер-Мәлик малайлары янына чап. Шушы үзән буйлап, кояш сөңге буе күтәрелгәнче баргач, уң күздә текә кыя-таш күрерсең: алар шул кыя төбендә булырга тиешләр. Килмәделәр болар, дип китеп бармасыннар. Сүзем бетте. *(Күзләрен йома.)*

**5. Шунда ук. Төн.**

**Бәхтияр караңгыда, бүтәннәрне уятмаска тырышып, Идегәйне эзләп таба.**

Бәхтияр *(пышылдап)*. Идегәй! Таптым теге үләнне... Ачылыгына карама — чәйнә! Әйбәтләп чәйнәгәч, йотып җибәр... Шикләнмә, тегеләр гырлап йоклый... Мин иртүк, алар уянганчы, Тимер-Мәлик малайларын эзләп китәм, шушында көтегез мине. Хәзер бераз черем итеп алам: син үләннәрнең берсен дә калдырма, чәйнәп бетер! *(Ияренә башын куеп, йокыга китә.)*

**6. Шунда ук. Иртән.**

**Идегәй һушсыз. Сөт абыйлары аның тирәсенә җыелганнар һәм аптырашып торалар. Туганнарның кечесе, Булат, Идегәйне һушына китерергә тырыша.**

Булат. Идегәй!.. Ни булды сиңа?! Син мине ишетәсеңме? Китәргә кирәк моннан, Идегәй! Үзән башында Туктамыш ханның нөгәрләре күренгән! Безне бастыра килүләре бар!

Бүтәннәр. Ташла, Булат! Эше беткәнгә охшый моның! Кичә әйттек ич: ата-бабалар рухы тотты! Тегеләй-болай бәхете чыгып, терелә калса — ашарына җитәрлек калдырыйк та, китик тизрәк! Тугры дусты булып кыланган Бәхтияр эше түгелме икән бу? Төнлә безне ташлап качмас иде! Киттек!

**Булатның ай-ваена карамыйча, берсе тиз генә Идегәй янына капчык белән ризык китереп ташлый, икенчеләре ашыга-ашыга атларын иярлиләр.**

**Булат** *(дулкынланудан теле бәйләнә)*. Туктагыз инде, абыйлар... Шушы көе кешене ташлап китәргә ничек оялмыйсыз?! Үз туганыбыз кебек ич ул безгә!

Өлкәне. Күпне лыгырдама, әйдә! Калма бездән!

**Үзән буйлап алга таба чабып китәләр, чөнки кайтыр юлларында Туктамыш нөгәр-**

**ләре сагалавы мөмкин. Булат әле аты янына ташлана, әле кире йөгереп килә, Идегәйне төрткәләп карый. Абыйларының ерагаюын күреп, алар артыннан чаба. Үзәнлектә тынлык урнаша: аның югалткан Идегәй генә ара-тирә ыңгырашып, селкенеп куя. Күпмедер вакыттан ат тояклары тавышы яңадан яңгырый: Булат кое янына кире әйләнеп килә. Ул, тиз генә атыннан сикереп төшә дә, Идегәйнең атын иярли, аны ияренә аркылы сала, егылып төшеп калмасын өчен аны ияргә бәйли, капчыгы белән ашамлыкларны үз атының ияренә беркетә. Тиз-тиз генә төнге учак эзләрен бетерә, сөяк-сыныкларны читкә томыра. Атына атланып, Идегәйнең атын тезгененнән житәкли һәм, абыйлары артыннан китмичә, кирегә чаба. Кое янында кабат тынлык урнаша.**

**7. Үзәнлекнең куаклы өлеше. Көн.**

**Бәхтияр бер жайдак белән кызу юыртып кайтып килә. Ул әледән-әле юлдашын ашыктыра.**

Бәхтияр *(атына камчысы белән сыдыра)*. Тизрәк кыймылда, Тимер Котлый табибы! Һәр адымыбыз кадерле чак!

Табиб. Болай да ут чыккандай ашыгабыз бит инде, нөгәр улым! *(Атын шып туктата.)* Нәрсә ул?!

Бәхтияр. Кайда?

Табиб *(кулы белән алга күрсәтә)*. Безнең алда!

Бәхтияр *(күреп)*. Кеше мәетләре! *(Атын чаптырып китә. Табиб урынында кала.)*

Табиб. Йә, кемнәр ул?!

Бәхтияр *(каралып күренгән гәүдәләр турына житкәч, атыннан сикереп төшә)*. Идегәйнең сөт туганнары! *(Юлдашына тизрәк килергә кушып, кул изи.)* Уклары Туктамыш нөгәрләренекенә охшаган!

**Табиб та, тиз генә килеп житеп, атыннан төшә һәм мәетләрне тоткалап карый.**

Табиб. Минем кирәгем калмаган боларга... *(Саный.)* Берәү... Икәү... Әнә тегендә тагын берсе... Бүтән күренмиме?

**Тирә-якларына караналар.**

Бәхтияр. Безнең белән дүрт туган чыккан иде алар... Булат атлы иң кече энеләренең гәүдәсе монда юк... Соңардык микәнни?! Коега күп калмады инде, әйдә тизрәк! *(Атына ташлана.)*

Табиб *(ул да атлана, ләкин атын кирегә бора)*. Тайдык моннан тизрәк!

Бәхтияр *(ачу белән)*. Син кая?! Аһ, куркак куян! *(Тиз генә куып житеп, атының тезгененнән эләктерә.)*

Табиб. Зинһәр, жибәр мине, нөгәр улым! Мин карт инде! Балаларым ятим кала! Әй, мин юләр! Башта ми булмаса, аякка көч килер, ди...

Бәхтияр *(кылычын кыныннан ала)*. Борыл, кабахәт! Атын-ниең белән бергә урталай ярып төшерәм!

Табиб *(куркуыннан дерелди башлый һәм атын бора)*. Чү, балам, чү! Мин карышмыйм ич... Анда безне сагалап тормасыннар, дип әйтүем.

Бәхтияр *(кырыс)*. Алдан төш, Алла каргасы!

Табиб. Әй, ходаем... үзең сакла... *(Алдан китә.)*

**7. Кое яны. Көн.**

**Бәхтияр белән Тимер Котлыйның табибы кое янына чаптырып килеп житәләр: әмма анда беркем дә юк.**

Табиб. Әйтеп торам ич: юкка йөрибез...

Бәхтияр *(ярсып)*. Яп авызыңны! *(Атыннан сикереп төшеп, кое тирәсен җентекләп тикшерә: ят эзләр күренмәгәч, жиңел сулап куя. Тәжрибәле аучы кебек, кое тирәли әйләнеп йөри башлый, үзе генә таныган ниндидер эзләр таба.)* Әһә!... Бу якка киткәннәр! *(Атына сикереп менә.)* Калма минем арттан! *(Үзән буйлап чабып китә.)*

Табиб *(үз алдына сөйләнә-сөйләнә иярә)*. Әй, яшьрәк чагым булса!.. Сөйләшеп торыр идемме мин аның белән!.. Качып калып та булмый бит үзеннән, ичмасам!.. Ерткыч та ерткыч, бу да ерткыч!

Булат *(калкулык артыннан аларга каршы килеп чыга: ул ялгыз)*. Бәхтияр! *(Шатлыгыннан нишләргә белми, аты белән Бәхтияр тирәсендә әйләнә.)* Син кайда булдың? Минем абыйлар очрамадымы?..

Бәхтияр. Очрадылар. Идегәй кайда?! Ул исәнме?!

Булат. Исән, исән, Бәхтияр. Тик һушына килмәде әле һаман. Абыйлар нишләп синең белән кайтмадылар?

Бәхтияр *(кул селти)*. Үзең күрерсең! Тиз күрсәт: Идегәйне кайда калдырдың? Табиб алып килдем!

Табиб *(алар янына килеп житә)*. Ә, тегеләрнең кече энеләре Булат — шушымыни инде? Анда синең абыйларыңны...

Бәхтияр *(ярсып бүлдерә)*. Күп сөйләнмә! *(Булатка.)* Юл күрсәт!

**8. Урман авызы. Көн.**

**Бер куак астында Идегәй ята: ул аңына килгән, әмма үзенең кайда икәнлеген чамалап бетә алмый, ахры, аптырап тирә-ягына карана. Коргаксыган иреннәрен ялап куя. Аты урман эчендәрәк бер агачка бәйләп куелган.**

**Бәхтиярләр килеп житәләр һәм атларыннан төшәләр.**

Идегәй *(күнегелгән хәрәкәт белән кылычына тотына, үз юлдашларын таныгач, тынычлана)*. Су...

Булат *(шатланып)*. Ушына килгән бу! Хәзер, хәзер, энекәш! *(Куак астында яшерелгән күн капчыктан савытка су агызып, Идегәйнең башын күтәрә төшә, су эчертә.)*

Бәхтияр *(аның янына тезләнә)*. Син ничек, түрәм: хәлең әйбәтләнәме? Тимер Котлыйның табибын алып килдем. *(Табибка, тизрәк селкен дип, кул изи.)*

Идегәй *(авыр тын алып)*. Бүтәннәр кая? Бу нинди жир?

Булат. Мин яшердем сине монда, Кобогыл... Тфү. Идегәй диюем!

Идегәй. Ник?

Булат. Үзән артында Туктамышның нөгәрләре күренде... Абыйлар... Тикшереп кайтырга киттеләр. Ул-бу хәл килеп чыкмасмы, дип, мин сине монда алып килдем.

Идегәй *(үзе тирәсендә ыгы-зыгы килгән табибның кулы белән читкә этәрә)*. Ашыкма, табиб, житешерсең... Кая соң алар?

Булат. Менә — Бәхтиярләр килгәндә юлда очраттык, диләр.

Бәхтияр *(кырыс)*. Көтмә син аларны, Идегәй. Алар сине аңсыз хәлеңдә ташлап качканнар. Булат үзе дә башта абыйларына ияргән булган, соңыннан кире борылган. Һәм — бәхете! Абыйларының мәетләре моннан ике-өч чакрым җирдә үзәнлектә аунап ята... Туктамыш казакларының эше! Сине эзлиләр, димәк! Менә шундый-шундый хәлләребез, Идегәй батыр!

**Булат, кинәт сикереп торып, читкәрәк китә һәм бер агач артына баса.**

Булатның синең алда гаебе юк, Идегәй. Сине абыйлары белән бергә ташлап китмәс өчен бик нык карышкан, кое тирәсендәге эзләр шул турыда сөйли.

Идегәй *(кинәт ыңгырашып куя)*. Тургай тозагына лачын төшми, Бәхтияр... Өчәү генә калдык, димәк...

Бәхтияр. Башлангычы бик күңелле түгел, ахырын хәерлегә юрыйк, Идегәй батыр! Эшеңә тотын, табиб! *(Читкәрәк китә һәм үткен күзләре белән тирә-юньне күзәтә.)*

**9. Үзәнлек. Төн.**

**Үзәнлек буйлап, ай яктысында атларын сак кына атлатып, дүрт жайдак бара. Атларның тоякларына калын чүпрәкләр уралган. Менә жайдаклар күләгәлектән чыгар-чыкмас бер жирдә туктап калалар: алда ниндидер шомлы нәрсә селкенгән кебек була. Атлар колакларын кайчылыйлар.**

Бәхтияр *(пышылдап)*. Алда нәрсәдер кыймылдагандай итте, Идегәй!.. Туктамыш нөгәрләренең постырмасы булса, әнә теге яктан урап үтәрбез... Мин бу тирәләрне караптырып кайттым. *(Ук белән җәясен ала.)*

Идегәй. Нишләмәкче буласың? Әгәр анда күпләп качып торсалар?!

Бәхтияр. Куак күләгәсеннән өркү — ирләр эше түгел! Алар җыенып, монда килеп җиткәнче, без әллә кая китеп өлгерәбез. Тәвәккәллим?

Идегәй. Берәр нәрсә шәйлисеңме соң? Мин үземне бөркеттән начар күрмим, дип санап йөри идем — берни абайлый алмыйм.

Бәхтияр. Ниндидер җан иясе безне сагалап торганлыгын чамалыйм, тик кешеме ул, киекме — ачык кына аера алмыйм. *(Керешен бөтен иңенә тартып, угын атып җибәрә: ук сызгырган тавыш төнне ярып узa һәм, бөтен үзәнлекне тутырып, ерткыч үкергән тавыш яңгырый һәм кинәт тына.)*

Булат *(саклыкны онытып)*. Kha! Чуар юлбарыс тавышы! Анда беркем дә юк, димәк: ерткыч заты йөрмәс иде! *(Атын чаптырып китә.)*

Идегәй. Кая?! Анда алар берничә булуы мөмкин!

Булат. Чуар юлбарыс — ялгыз йөрүчән ерткыч! Җиңел яралы булып, качып китмәсен!

Бәхтияр *(хуплап көлеп)*. Бу да бик дуамал булып чыкты, әйдәгез, аннан калмыйк: чынлап та, яраланган гына булса, егетне харап итүе бар!

**Өчесе дә Булат артыннан ташланалар.**

Табиб. Мине көтегез!.. Мин кызу чаба алмыйм!.. Болай да бот араларым суелып бетте!

**Ул арада алдан чапкан Булат караңгы күләгәгә кереп югала һәм шул ук секундта чуар юлбарыс үкерүе һәм аның ачы итеп кычкыруы ишетелә.**

**Бәхтияр белән Идегәй, кылычларын кыннарыннан суырып алып, ерткыч ырлаган жиргә ташланалар: ат кешнәве, ирләр кычкыруы, ерткыч үкерүе — бөтенесе бергә кушыла. Табиб айлы үзәндә берүзе басып кала.**

**10. Шунда ук. Таң тишелеп килгән вакыт.**

**Зур учак өчен коры-сары, утын өелгән. Аның өстенә дүрт бертуганның гәүдәсе сузып салынган: борынгы йола буенча, мәетләрне яндырырга әзерләгәннәр. Өч ир: Идегәй үзе, Бәхтияр һәм Тимер Котлыйның табибы учак тирәсенә тезләнгәннәр һәм эчләреннән дога укыйлар. Менә Идегәй, догасын укып бетереп, битен сыпыра һәм, кесәсеннән чакма ташлары алып, бер-берсенә сугып очкын чыгара башлый: бер кырыйга кыстырылган коры мүккә ут дөрләтә.**

Идегәй. Рухларын Тәңрегә тапшырдык!

**11. Шунда ук. Иртән.**

**Учак янып беткән: Идегәй юлдашлары белән бергә мәетләрдән калган көлне туфрак белән күмә. Корганны хәнҗәрләр белән кисеп алган кәсләр белән каплыйлар. Бәхтияр иң өскә чуар юлбарыс башын куя.**

**12. Кыя-таш төбе. Көн.**

**Таш кыя астында берничә чатыр. Уртадагы чатыр затлырак һәм зуррак: ул — Тимер-Мәлик ханның өлкән улы Тимер Котлый чатыры.**

**Еракта сакчының сызгырган тавышы ишетелә. Чатырлардан баштан-аяк коралллы Тимер Котлый, Күнче һәм берничә нөгәр чыга. Алар күп түгел — уилап кына, шуна күрә бик сак кыланалар. Тимер Котлый хан белән Күнче солтан бик яшьләр, Күнче, гомумән, үсмер генә әле.**

Күнче *(ул Тимер Котлый белән бер чатырдан чыга)*. Кобогыл би килеп ятадыр, Тимер котлый абый...

Тимер Котлый. Күрербез... *(Нөгәрләренә.)* Атларны иярләгез!

**Сугышчылар атларын иярләргә тотыналар. Менә үзәнлек борылмасыннан Идегәйләрнең килгәне күренә.**

Күнче *(җиңел сулап)*. Кичәге егет! Атыннан таныдым.

Тимер Котлый. Хәзер мин дә күрәм: Кобогыл би килә... Нишләптер өчәү генә болар... Ул егет, без алтау, дигән иде кебек. Табиб белән җидәү булырга тиешләр... *(Нөгәрләренә.)* Иярләрне чишәргә мөмкин!

**Идегәй белән юлдашлары чатырлар янына килеп җитәләр.**

Тимер Котлый. Хуш килдегез, Кобогыл би! Сине исән-имин күрүемә бик шатмын!

Идегәй *(атыннан сикереп төшә; аның атын бер нөгәр читкә алып китә).* Мин дә сине исән-аман күрүемә шат, Тимер Котлый хан! *(Җиңелчә баш иеп, уң кулын күкрәгенә куеп ала.)* Сиңа да исәнлек-саулык телим, Күнче солтан.

**Бәхтияр белән табиб та атларыннан төшәләр.**

Табиб *(монда килеп җиткәч, ул бөтенләй үзгәрә, коры).* Ат сыртын яхшылап сөрт, казак! Бик тирләде!

**Бәхтияр аңа гаҗәпләнеп карап куя һәм елмая.**

Тимер Котлый. Чатырга рәхим ит, Кобогыл әмир! *(Казакларына.)* Кунак егетне ашатыгыз.

**Идегәйләр чатырга керәләр.**

**13. Чатыр эчендә. Көн.**

**Тимер Котлый, аның энесе Күнче солтан һәм Идегәй ашап-эчеп утыралар: нөгәрләрнең берсе алар алдына ашамлыклар куя.**

Идегәй. Күзләреңдә сорау күрәм, Тимер Котлый хан... Әйе, мин бер нөгәрем белән генә килеп җитә алдым. Һәм үзем дә үлемнән чак кына исән калдым. Синең табибың вакытында килмәсә... Чын йөрәктән рәхмәт сиңа, хан!

Тимер Котлый. Кызганычка каршы, бүгенке көндә булдырган бердәнбер файдам — шулдыр, Кобогыл әмир... Тыңлыйбыз сине.

Идегәй. Калган дүрт кешем — минем сөт туганнарым иде. Өчесе мине һушсыз ятканда ташлап киткән. Туган туганга таяна алмас көн килде... Тәкъдирләредер — Туктамыш казакларына тап булганнар: укка алган гәүдәләрен генә таптык. Кече агам Булат миңа тугры калган иде, ләкин анысының язмышы да аянычлы булып чыкты — кара төндә чуар юлбарыс тырнагына эләкте.

Тимер Котлый. Кайгыңны уртаклашам, Кобогыл әмир... Алга ниятеңне сорарга рөхсәт ит?

Идегәй. Мин ярты юлда туктарга өйрәнмәгән, Тимер Котлый хан!

Күнче *(ирennәрен кыйшайта).* Һм... хан! Берегез — илсез-тәхетсез хан, икенчегез — гаскәрсез түрә!

Тимер Котлый *(ризасызлык белән кашын җимерә).* Өлкәннәр сүзенә катышмый тор, Күнче солтан... *(Идегәйгә.)* Ачыграк әйткәндә?

Идегәй *(ул да Күнче солтанның сүзгә катнашуын өнәп бетерми).* Әлегә кояш баемаган, Күнче солтан... Батыр канынnан алтын коела. Каршы килмәсәгез, Тимер Котлый хан, юл газапларын сезнең белән бергә күтәрер идем. Сыенырга тырышу, дип кабул итсәгез... атым иярле!

Тимер Котлый. Ерак юлда бер юлдаш та артык түгел, Кобогыл әмир... Кузгалыйк, булмаса?

Идегәй. Кузгалганчы, бер сүзем бар сезгә, Тимер Котлый хан... Юлга чыкканда юлдашың үзеңнән яхшы булсын, диләр. Сезнең белән ачыктан-ачык эш итәсем килә. Сез миңа Кобогыл әмир, дип дәшәсез. Кобогыл түгел мин!

Күнче. Менә бу — кызык! Ә кем?

Идегәй. Кобогыл булсам — Туктамышка хыянәт итмәгән дә булыр идем, бәлки... Мин — Котлыкыя би улы Идегәй!

Тимер Котлый *(сикереп тора һәм кылычының сабына кулын куя).* Идегәй?! Минем атам Тимер-Мәлик ханны Туктамышка тотып биргән әмирме?!

Күнче *(абыйсын тынычландырырга теләп).* Кем булса да, ул — безнең чатырда кунак, абый!

Тимер Котлый *(уңайсызланып, кире утыра; күтәрелеп карамыйча).* Җавап көтәм, кунак!

Идегәй *(ул тыныч).* Әйе, мин — шул кеше, Тимер Котлый хан.

Тимер Котлый. Ул чагында бел, Идегәй әмир: син Туктамышка үз җизнәңне тотып биргәнсең!

Идегәй. Әйтеп бетер, Тимер Котлый хан!

Тимер Котлый. Безнең әни Йөзлебикә — Котлыкыя бинең өлкән кызы иде! Котлыкыя би — ерак бабабыз була, син — безнең якын агабыз, ә без — синең энекәшләрең!

Идегәй *(ике куллап башына тотына).* Йә, Хода!.. Теге вакытта мин сезне, бик яшь булганга кызганып, Туктамыш балтасыннан коткарып калган идем: Хак тәгалә йөрткән икән мине!..

**Авыр тынлык баса. Идегәй тора һәм кылычын, билennән сүтеп, алларына куя.**

Язмышымны синең гадел хөкемеңә тапшырам, Тимер Котлый хан. Бер генә үтенечем бар: минем нөгәремнең кыл да гаебе юк сезнең алда — аны үз юлына җибәрегез! Ул мине күп тапкырлар үлем тырнагыннан йолып алып калган кеше — шуның хакына сорыйм.

Тимер Котлый *(ул үз-үзен кулга алып өлгергән инде).* Үткәнне кайтарып булмый, Идегәй әмир... Туганлыгыбыз хакына без сине ярлыкадык! Кылычың үзеңә кирәк булыр.

Күнче *(кырыс).* Ә мин — ярлыкамас идем! *(Корал шалтыратып янап чыгып китә.)*

**14. Кола ялан. Көн.**

**Киң далада җәйрән кәҗәгә ау бара: Тимер Котлыйның нөгәрләре киекләрне, уратып алып, Идегәйләр ягына куалыйлар.**

**Идегәй, Тимер Котлый, Күнче һәм табиб белән Бәхтияр ук-җәяләрен күтәрәләр. Идегәй җәйрәннәргә каршы чаптырып китә. Шулвакыт Күнче солтан тиз генә ук ала һәм Идегәйнең аркасына атарга тели. Моны күреп өлгергән Бәхтияр, камчысы белән сыдырып, аның коралын бәреп төшерә.**

Күнче *(чыбыркы очы аның кулына дә эләгә)*. Ай! *(Кылычын кынынан суырып алып, Бәхтиярга чапмакчы була. Бәхтияр аның кылычын да камчысы белән бәреп төшерә.)* Хыянәт! Идегәйнең колы миңа чыбыркы белән сыдырды!

**Бу хәл шулкадәр тиз була ки, Тимер Котлый да, табиб та берни аңламый калалар. Идегәй тавышка борылып килә.**

Тимер Котлый *(кырыс)*. Кылыгыңны аңлат, нөгәр!

Бәхтияр. Аңлатасы юк: энекәшең Идегәйне уктан алырга теләде — шул гына.

Тимер Котлый. Хак сүзме бу, Күнче солтан?

Күнче. Алдак бу! Мин җәйрәнгә атарга теләдем!

Бәхтияр *(кинәт чыбыркысы белән Күнченең битенә сыдыра)*. Солтанга тел пычрату килешми!

Тимер Котлый. Нөгәрләрем! Минем янга! *(Кылычын чыгара.)*

Бәхтияр *(ул да кылычын суырып ала, тыныч)*. Мин, берүзем унбишләп нөгәрне үтереп, Мамайның башын кисеп алган кеше, ханзадә!

**Идегәй килеп җитә.**

Идегәй. Ни булды монда, Бәхтияр?!

Бәхтияр. Күнче солтаннан сора, Идегәй батыр.

Күнче *(бер кулы белән битен тоткан, еламсыраган тавыш белән Идегәйгә)*. Мин синнән барыбер, җайлы чак туры китереп, үч алачакмын!

Идегәй *(тыныч)*. Йә, нишлибез, Тимер Котлый хан? Туктамыш ханның тәхетен тартып алмыйча, тынычланмаячакмын мин. Ниятем — тәхеткә сине кайтару. Уйла.

Тимер Котлый *(кылычын кынына тыга; Бәхтияр дә шулай эшли)*. Күнче солтан берничә нөгәр белән Аллаярбәк әмир канаты астына кайтып китә.

Күнче *(кәҗәләнеп)*. Ә мин — сиңа буйсынмыйм!

Тимер Котлый. Ул чагында... башын чабылыр.

Күнче. Бертуган энеңнеме?!

Тимер Котлый. Мин әйттем! *(Аның чакыруын ишетеп борылып килгән нөгәрләргә.)* Бишегез әзерләнегез: Күнче солтанны Аллаярбәк әмиргә озатасыз.

**15. Комлы чүл. Көн.**

**Ком бураны. Атларны аяктан егарлык көчле җил. Биш кенә нөгәре белән калган Тимер Котлый, аның карт табибы һәм Идегәй белән Бәхтияр, көчәйгәннән көчәя төшкән ком бураны белән көрәшә-көрәшә, әкрен генә алга баралар. Нөгәрләренең атларына чатыр һәм башка кирәк-яраклар төялгән, шуңа күрә алар бөтенләй эштән чыкканнар — менә-менә егылып, ком астында күмелеп калырлар сыман. Тын куыргыч эшәке каршы җил җайдакларның битенә учлап-учлап вак ком сибә.**

Идегәй *(бар көченә кычкырып)*. Тимер Котлый хан! Артык әйберләрне ташларга кирәк! Атлар егылса — эшләребез харап!

Тимер Котлый *(ул сынатмаска тырыша, әмма эчрендә көч-хәл белән утыра)*. Боер, Идегәй әмир... Мин синең тәҗрибәңә ышанам.

Идегәй. Бәхтияр! Нөгәрләрне туктат!

**Бәхтияр алдарак барган җайдаклар янына ашыга.**
**Нөгәрләр бер урынга җыелалар.**

Идегәй. Тимер Котлый хан әмерен тыңлагыз, батырлар: чатырларны һәм бүтән артык авыр әйберләрне монда калдырырга! Кирәк кеше алыр. Үзебез белән корал, ризык һәм су гына алабыз!

**Нөгәрләр берсүзсез боерыкны үтиләр: затлы чатырлар, савыт-сабалар, тәбәнәк өстәл-урындыклар җиргә оча.**

Табиб. Минем чатырга тимәгез! Мин — карт кеше! Мин ачык һавада йоклый алмыйм!

Идегәй *(ишләргә белми иреләнеп калган нөгәргә)*. Хан әмерен үтә!

**Табибның чатыры да җиргә оча.**

Табиб. Ул чагында мин үзем да монда калам!

Идегәй. Ихтыярың, табиб! Табибка — ризыкның сигездән бер өлеше! Бер урында тормаска! Кузгалдык! *(Алга китә.)*

**Бер нөгәр ашамлык тутырылган капчыкны чишә башлый.**

Табиб. Кагылма! Кара син аны!.. Мине җиңел генә кирәмәткә ташлап китмәкчеләр! *(Бүтәннәргә ичрә.)* Нишлим соң? Койрыгыннан ныграк кыссаң, куян да чыраг кабызыр.

**16. Ком таулары арасында иңкүлек. Кич.**

**Ком бураны басылган. Хәлдән тайган җайдаклар һәм атлар төрлесе-төрле җирдә сузылып яткан. Һәркемнең алдында — өлешенә тигән каты-коты ипи кисәкләре һәм берәр локма каклаган ит. Күбесенең шуларны чәйнәргә дә хәле житмәгән — йоклыйлар. Идегәй белән Бәхтияр, тирән уйга чумып, әкрен генә ипи чәйниләр. Идегәй ипиен әледән-әле үз атына каптыра. Бәхтияр дә, моны күреп, атын ашата башлый. Табибның ыңгырашуы ишетелә.**

Идегәй *(торып, ком шытырдата-шытырдата аның янына бара)*. Нәрсә, хөрмәтлем, хәлең бик начармы? Мәле, кәүсәр суы йотып җибәр...

Табиб *(чинаган тавыш белән)*. Кагылма миңа... Шундый кабәхәт кеше икән-

легенне белгән булсам, дәваламаган булыр идем мин сине... Таш бәгырьле кеше син... *(Тына.)*

Идегәй *(көлемсерәп)*. Дөрес әйтәсең, табиб, бәгырем таш булып катты... *(Табибның карышуына карамастан, башын күтәреп, авызына су сала. Ансы бераз су йота да, хәлсез башын җиргә сара.)*

Идегәй *(картны калдырып, Бәхтияр янына килеп утыра)*. Картның хәле шәптән түгел... Иртәнгә чаклы түзмәс, ахры, мантырга охшамаган...

Бәхтияр. Ил ташлаган ирне гүр алыр, ди... Ансы-ансы, су бетеп килә, Идегәй... Атсыз калсак нишләрбез?!

**Идегәй дәшми.**

**17. Шунда ук. Иртән.**

**Берничә нөгәр хәнҗәрләре белән кабер чокыры казый: комлы җир бик тиз ишелә тора — кабер казучылар ишелгән комны учлары белән читкә ташлыйлар. Яннарында — табибның мәете ята. Ниһаять, кабер чокыры тездән була.**

Идегәй *(алар янына килә)*. Җитәр булмаса... Көн эссегә авышканчы кузгалырга кирәк... *(Мәет кырыена бара.)* Тотышыгыз!

**Бәхтияр, Идегәй һәм тагын берничә нөгәр картның гәүдәсен күтәреп, кабергә төшерәләр.**

Идегәй. Бисмилла... Тәңребезгә тапшырдык! Рәнҗеткән булсак, кичер безне, карт... *(Учы белән ком алып, өстенә сибә.)*

**Нөгәрләр, кабереннән чыгып качмасын дигәндәй, мәет өстенә тиз-тиз генә ком ишәләр.**

**Озакламый кечкенә калкулык хасил була.**

Идегәй *(Тимер Котлыйга)*. Аллага тапшырып, кузгалдык, хан.

Тимер Котлый *(гамьсез тавыш белән)*. Кирәкме икән, Идегәй әмир?.. Барыбер ком астында ятып каласы...

Идегәй *(сүзне кыска тота)*. Хан сүзе түгел бу, Тимер Котлый! Төнлә шакаллар елавы ишетелде: алар кеше яши торган җирдән ерак китмиләр. Борыным сизә: бүген сулыкка барып җитәчәкбез! *(Атына атлана.)* Нөгәрләр! Безнең арттан! *(Нөгәрләрнең үзара нидер чыш-пыш сөйләшкәннәрен күреп, туктап кала.)* Ни булды анда?! Боерыкны ишеттегезме?!

**Нөгәрләр, атларына менеп, аларны уратып алалар. Идегәй, Тимер Котлый һәм Бәхтияр уртада кала. Нөгәрләрнең кырыс йөзләрен күреп, өчесе дә кулларын кылыч сабына куя.**

Бер нөгәр. Тимер Котлый хан! Кичер безне: без ары бармыйбыз! *(Идегәйгә ымлый.)* Бу кешегә ышанмыйбыз без! Кем ул?! Ник синең өстән эш йөртә?! Ул безне сусыз ком чүленә үлемгә алып килде! Син үзең теләсәң нишлә, хан, без — атларыбызны кире борабыз! Киттек, егетләр.

Тимер Котлый *(югалып калган)*. Ханыгызны ташлап китәргә җөрьәт итәсез?!

Бәхтияр. Боер, Идегәй: бер-икесен акылга утыртам бу тутык гәмбәләренең?

Икенче нөгәр *(көдрәеп кылычына тотына)*. Йә, кем кемне акылга утырта?

**Тимер Котлый, таяныч эзләп, Идегәйгә карый.**

Идегәй. Калдыр, Бәхтияр... Китә бирсеннәр! Булган ризыкларны данә башыннан гадел бүлешик. Кызганам мин сезне, егетләр: сезнең берегез дә иленә исән кайтып җитә алмаячак!

Өченче нөгәр *(җиңел генә аерылышуга егетләнеп)*. Анысы — тәкъдиребездә язылганча булыр! Ризыкларны бүлеп куйдык инде без. Бу капчыкта су, монсында — ризык. *(Җиргә ике күн капчык ташлый һәм атын чаптырып китә.)*

**Бүтән нөгәрләр дә, Идегәйләргә сагаеп карый-карый, аның артыннан ашыгалар. Үзәндә өч җайдак басып кала.**

**18. Калкулык. Кичкә авышкан чак.**

**Ара-тирә вак куаклыклар белән капланган тәбәнәк калкулыкка өч кеше күтәрелеп килә: өчесе дә, хәлсезләнгән атларының иярләренә тотынып, камашкан аякларын көчкә сөйриләр. Атлары, адым саен диярлек туктап, берән-сәрән күренгән үлән утлыйлар. Идегәй, Тимер Котлый һәм Бәхтияр арының соңгы чигенә җиткәннәр: атларына ябешеп, егыла-тора бармасалар, күптән җирдә тәгәрәшеп ятырлар иде. Аларның максаты — шушы калкулыкка менеп җитү, ахры, бөтен көчләренә шунда омтылалар.**

**Ниһаять, чыдамлырак гәүдәле Бәхтияр беренче булып калкулыкка менеп җитә һәм туктап кала.**

Бәхтияр *(кулын атының ияреннән ычкындырып, алга таба карап чайкалып тора һәм кычкырып җибәрә)*. Су! *(Бер кулын алга сузып күрсәтергә тели һәм кираркан җиргә ава.)*

**Идегәй, атын ташлап, аның янына ашыга.**

Идегәй *(көч-хәл белән үргә менеп җитеп, түбәнгә карый: анда, чынлап та, зәп-зәңгәр сулы елга җәйрәп ята)*. Йә, Хода... *(Күзеннән яшь атылып чыгуын да сизми.)* Әҗәлебез җитмәгән икән әле! *(Аста туктап калган Тимер Котлый ханга таба борыла.)* Тизрәк мен, Тимер Котлый хан! Тәңребез ташламаган икән безне... Хәзер бернәрсәдән дә кысылмыйбыз. Анда — яшәр өчен бөтен нәрсә бар! Сусын калганчы су чөмер... Күңлең туйганчы киек аула... *(Аягы астында һушсыз яткан Бәхтиярга күзе төшә.)* Бәхтияр! Җан дустым... Чүл аждаһасын җиңеп чыктык, бирешмә! *(Бәхтиярга ярдәм итәргә теләп иелә һәм, гәүдәсен тота алмыйча, аның янына тәгәри: ул да аңсыз.)*

**Калкулыкка менеп житмәгән Тимер Котлый тагын бер-ике адым алга атлый һәм шулай ук йөзе белән җиргә каплана. Атлары,**

**хужаларына игътибар итмичә, туктаган жирләрендә үлән утлый бирәләр.**

**Идегәй белән Бәхтияр калкулыкның икенче ягына арырак күз салган булсалар, елга колагы буендагы ямь-яшел тугайлыкта тезелеп утырган чатырларны күрәселәр иде: анда ыгы-зыгы, атлар-дөяләр мәш килә, малбагарлар, кораллы гаскәриләр тыз-быз чаба.**

**19. Шунда ук. Иртән.**

**Калкулыкка, кача-поса, берничә кораллы кеше күтәрелә: алар жирдә һушсыз яткан Идегәйләргә якынаялар. Менә алар тавышсыз килеп житәләр һәм Идегәйләргә ташланалар: күз ачып йомган арада Бәхтияр белән икесен коралсызландыралар.**

Колгасар *(игътибар белән карап)*. Йокыда түгел болар — ушларын югалтканнар... Тизрәк су бирегез! *(Арадан берсе кечкенә кун савыт белән су бирә: учына агызып, Идегәйнең битенә сибә — Идегәй, дертләп китеп, күзләрен ача. Ул өстенә озын буйлы бер егет иелгәнен күрә. Аңа су эчерәләр.)* Кемнәр сез?

Идегәй *(үзен коралсызландырганнарын чамалап, гаскәриләргә күз йөртеп чыга)*. Кайда мин? Кемгә карый бу жирләр?

Колгасар. Син — Туктамыш ханның меңбашы Кара Тиен Йосынчы биләмәсендә. Без — аның хезмәтчеләре. Син кем?

Идегәй *(тәвәккәлләп)*. Мин — Туктамыш ханның төмәнбашы Кобогыл би! Аякка бастырыгыз мине!

**Гаскәриләр бер-берсенә карашалар һәм кабалана-кабалана аны күтәреп торгызалар.**

Колгасар *(каушап)*. Без сезне... юлбасарлар, дип уйладык, кичер, Кобогыл би! Мамайны жиңгән каһарман икәнлегеңне ишетеп беләбез... Хәзер... Коралларыңны кире бирәбез... *(Иптәшләренә ымлый: алар бер читкә өеп куелган кораллар янына ташланалар.)*

Идегәй. Житешерсез! Минем нөгәргә ярдәм итегез. *(Һушсыз яткан Бәхтиярга күрсәтә.)* Өченчебез кая? Минем энем дә монда булырга тиеш! *(Артка таба ымлый.)* Менеп житә алмыйча егылмаганмы — карагыз!

**Бер-ике егет ул күрсәткән якка йөгерә.**

Колгасар *(үз-үзенә)*. Су эчергәч, күңеле бөтенләй көрәеп китте моның...

**20. Кара Тиен Йосынчы чатыры. Көн.**

**Идегәй белән Тимер Котлый күбаралыклы чатыр хужасы Йосынчының мактануын тыңлый-тыңлый ашап-эчеп утыралар. Берничә ярымшәрә жария көнчыгыш музыкасына бию башкара. Берничә жария кунакларга аш-су китереп тора. Йосынчы үзен бик дорфа тота.**

Йосынчы. Нәрсәгә миңа Туктамыш?! Тфү! Мин үз биләмәмдә үзем Туктамыш! Ха-ха-ха! Сер итеп кенә әйтәм: беләсезме, мин нәрсә уйлап чыгардым? Аксак Тимер фарсылар өстенә яу китә — мин аның үз жирләрен талап кайтам, икенче вакыт Туктамыш урысларны бастырырга юнәлә — мин ханның олысларын аркылыга-буйга чабып пыр туздырам! Ха-ха-ха! Нәрсә бирә бу миңа? Байлыкмы? Байлык минем үземдә мең айлык! Ә менә нәрсә бирә: ачулары чыккан Аксак Тимер белән Туктамыш хан, түземлекләре бетеп, бер-берсенә минем өскә килмәчә-кләр. Ә мин, шома елан кебек, ике тукмак арасыннан шуып кына чыгам да читтән карап торам: ике тукмак — шап! Бер-берсенең маңгайларына! Ха-ха-ха! Кызыкмы?

Идегәй. Эчең катып үләрлек!

Йосынчы. Ха-ха-ха! *(Кунакларга бармак яный.)* Тик!.. Минем талкан бик коры... Кайткач, Туктамышка минем сүзләрне житкерсәгез, Кобогыл би... Мамай башын чапкан батыр, дип тормам! Сарайда минем кешеләр житәрлек! Ха-ха-ха! Шаяртам! *(Идегәйнең жилкәсен кагып куя.)*

Идегәй *(хужаның тупаслыгына ул бик кыенлык белән генә түзеп утыра)*. Йоклаганда да баш астына кылыч салып ятарга туры киләчәк, димәк? *(Елмая.)*

Йосынчы. Ышанмыйсынмы?! *(Чатыр ишегендә торган шыгавылга карамыйча кычкыра.)* Хәммәт бине кертегез! Хәзер... Кайбер нәрсәләрне аңларсыз!

**Чатырга, аяк очларына гына басып, бер ир килеп керә һәм колларча баш ия.**

Йосынчы. Якынрак кил! Кунакларга сөйләле: ниш.ләттем мин сине, Хәммәт би?

Хәммәт. Баш өсте, түрәм. *(Идегәйгә карап.)* Мин бер ай элек Йосынчы бигә кунакка килгән идем... Без аның белән күптәнге танышлар... Ярты ай чамасы кунак булдым — Хужа кайтып китү турында авыз да ачтырмый. Бик кунакчыл кеше!

Йосынчы. Хак сүз! Кунак сыйларга яратам мин. Ха-ха-ха! Ары такылда!

Хәммәт. Түзмәдем, бүрегемә киңәш иттем дә качып китәргә карар кылдым...

Йосынчы. Юк, син бөтенесен әйтеп бетереп сөйлә! Качып китеп, Туктамыш ханга минем өстән әләк житкермәкче булган идең син, Хәммәт би! Ә нәтижә?

Хәммәт. Мине, ярты юлда тотып алып, кире апкайттылар да... Йосынчы би, табан асларымны телгәләтеп, ат кылы сиптерде. Китәргә рөхсәт ит, Йосынчы би? Менә анда саварга бәйләнгән дөяләр көтә.

Йосынчы *(китәргә рөхсәт итеп, кул селти)*. Күрдегезме? Миңа карышкан кунакларны шулай юашландырам мин! Ха-ха-ха! Ә хәзер, адашып килеп кергән кадерле кунаклар, мин сезгә бер могжиза күрсәтәм! *(Кулларын өч тапкыр шапылдатып суга.)*

**Бер жария килеп керә.**

Йосынчы. Былбылымны кертегез!

**Жария баш иеп чыгып китә. Тынып торалар.**

**Чатырга искиткеч гүзәл яшь хатын килеп керә.**

Йосынчы. Йә, кем дип уйлыйсың инде бу сандугачны?

Идегәй. Кем?

Йосынчы. Аксак Тимернең кызы! Атасының күзе алдында кызына аю мае сөрттем! Ә хәзер — минем кәнизәгем! Ха-ха-ха! *(Хатынга чыгып китәргә ишарә ясый.)*

Идегәй *(ул моңа чынлап гаҗәпләнә).* Булмас, ышанып бетә алмыйм, Йосынчы би!

Йосынчы. Булмасмы? *(Зәһәрле елмая.)* Яхшы. Бүгенгә җитәр. Калган могҗизаларымны иртәгә күрсәтермен! Ышандырырлык итеп! *(Аның соңгы сүзләрендә янау яңгырый: кунаклар ирексездән кинәт аңа карап куялар.)* Ха-ха-ха!

**21. Идегәй чатыры. Төн.**

**Чатырда өч кеше ятканын чамалап була: Идегәй, Тимер Котлый һәм Бәхтияр әкрен генә сөйләшеп яталар.**

Бәхтияр. Чүлдән котылып, карсак шакал тырнагына килеп каптык, ахры, без, Идегәй батыр!

Идегәй. Монда — минем атым Кобогыл, гарәп...

Тимер Котлый. Йосынчының соңгы сүзләреннән соң, әлегә кадәр арка үзәкләрем чемерди минем...

**Шулвакыт төнге шомлы тынлыктан хатын-кыз җырлавы ишетелә.**

Бәхтияр. Аксак Тимер кызы җырлый!

Идегәй. Каян беләсең?

Бәхтияр. Җәйләү кешеләре сөйләделәр... Йосынчы аны көн саен йокыга китәр алдыннан җырларга мәҗбүр итә, имеш... Шунсыз йоклый алмый икән, кәбих!

**Сагышлы җыр тәэсиренә бирелеп, тынып калалар.**

Әсир кыз җыры:

Яулар чапкан әткәмдер,
Даннар тапкан әткәмдер,
Мине эзләп тапмады,—
Өзелә бит үзәгем.
Мине эзләп тапмады, һай,—
Өзелә бит үзәгем!
*(Йосынчы шаркылдап көлә.)*

Атым булыр Акбеләк,
Күнелемдә ак теләк,
Ят илләрдә саргаям,—
Калмады ла түзәрем.
Ят илләрдә саргаям, һай,—
Калмады ла түзәрем!
*(Йосынчы көлә.)*

Килер сыман бер батыр,
Әткәемә озатыр,—
Иренемдә батырга
Ал шәрабтай сүзләрем.
Иренемдә батырга, һай,
Ал шәрабтай сүзләрем!
*(Йосынчы көлә.)*

Алма-алма түшләрем,
Сачым булыр түшәге,—
Ул батырга йорт булыр
Сәмәркандтай гүзәлем.
Ул батырга йорт булыр, һай,
Сәмәркандтай гүзәлем...

**Төн тынлыкка чума.**

Бәхтияр. Ничек тә моннан ычкыну юлын табарга кирәк... Ир кичмәслек елга юк. Мин Йосынчының кайбер нөгәрләренең кылын тартып карадым, берсе дә аны мактамый! Хезмәтчеләрен әйткән дә юк... Ике көнгә берсенең башына җитеп тора икән, кабахәт! Күрлегенә түзми, димәк. Өченче көн бер егетне, атына атланганда аягы астына аркасын куеп өлгермәгән өчен, ике ат койрыгына бәйләтеп, ботын аерып ташлаган... Котырган эт айга сикерә!

Идегәй. Аннан котылу юлы бер генә... Үзенең башын юк итү!

Тимер Котлый *(өметләнеп).* Ничек итеп?!

Идегәй. Әкренрәк!.. Ансы — Бәхтияр белән минем эш...

Бәхтияр. Килешәм.

**Шулвакыт чатыр ишеге янында бер күләгә күренә.**

Бәхтияр *(кулына хәнҗәр алып, сикереп тора).* Кемдер чатыр янында искәнеп йөри! *(Сиздерми генә ишеккә якынлаша.)*

Хатын-кыз тавышы *(пышылдап).* Әй!.. Йоклыйсызмы, кунаклар?

Бәхтияр. Кем син?

Хатын-кыз тавышы. Шаh Тимер кызы...

Бәхтияр. Нәрсә кирәк?

Идегәй *(торып утыра).* Керсен!

Хатын *(чатырга керә).* Кайсыгыз — өлкән түрә?

Идегәй. Сүзеңне әйт.

Хатын. Минем исемем — Акбеләк...

Идегәй. Тыңлыйбыз сине, Акбеләк. Мин — Туктамыш ханның төмәнбашы Кобогыл. Болар — минем юлдашларым.

Акбеләк *(пышылдый).* Йосынчы лаякыл исерек... Чатыр шыгавылы — минем кеше... Йосынчы йокыга китәр алдыннан иртәгә сезне тас кол урынына мыскыл итәчәкмен, дип мактанды! Елан яше ялаган нәмәрсә ул! Аннан качып котыла алган кеше юк! Сез бәхетлерәк булырсыз, бәлки! Без сезгә иң яхшы атларны әзерләдек... Мине дә үзегез белән алсагыз, ярдәм итүчеләр табам!

Тимер Котлый. Әйдәгез!

Идегәй. Ашыкма, энем... Мине, кешегә сиздерми генә, Йосынчының чатырына алып керә аласыңмы, Акбеләк?

Акбеләк. Үлек кебек йоклый ул эт каешы!.. Тик мин аңламыйм: нигә кадерле вакытны әрәм итәргә?! Хәзер үк качсак, еракарак китеп өлгерәбез ич. Кобогыл би! Әй, Ходаем! Яхшыга көн юк, яманга үлем юк!

Идегәй. Чөнки Йосынчы чатырына керсәк — качарга ашыкмасак та була... Аның коралны нөгәрләре ничәү?

Акбеләк. Бу җәйләүдә — егермеләп булыр... Бишесе — аны җен урынына дошман күрә. Калганнарына ышанып булмый — койрыксыз этләр.

**Бәхтияр**. Барлыгы — сигез булабыз! Унбишкә — сигез. *(Әкрен генә көлә.)* Ир-ат өчен эш тә юк икән монда! Боер, Кобогыл би!

**Идегәй**. Чү! Тынычрак! Мине монда көтегез... Әйдә, Акбеләк! *(Кылычы белән хәнҗәрен алып, тышка юнәлә.)*

**22. Чатыр алды. Төн.**

**Чатырдан Идегәй белән Акбеләк чыга.**

**Нөгәр** *(алар каршына сикерә)*. Кая юнәлдең, кадерле кунак?

**Акбеләк**. Ах! *(Идегәй артына поса.)*

**Нөгәр** *(мыскыллы.)* Аңлашылды!.. Былбыл сайравын тыңларга баруың икән... Төн караңгы, тирә-юньдә карсак шакаллар шактый күп йөри — каравыл бирми булмас үзегезгә! *(Сызгырмакчы булып, ике бармагын авызына каба.)*

**Шуннан файдаланып, Идегәй аңа хәнҗәре белән кадый: нөгәр: эһ тә итәлми, җиргә ава.**

**Идегәй** *(чатыр ишеген ачып)*. Бәхтияр! Бер карсак ята монда — эзен юк ит... Кораллары кирәк булыр! *(Акбеләккә.)* Әйдә, син алдан атла...

**Йосынчы чатыры ягына китәләр.**

**23. Йосынчы чатыры алды. Төн.**

**Акбеләк белән Идегәй поса-поса чатыр янына килеп җитәләр.**

**Шыгавыл**. Кем килә?

**Акбеләк**. Бу мин — Акбеләк! Әкренрәк сөйләш.

**Шыгавыл**. Синең артта кем?

**Акбеләк**. Дус кеше... Чатырга без чыкканчы беркемне дә кертмә!

**Шыгавыл икеләнеп тора.**

Унбашы буласың киләме, шыгавыл! Килсә — шуны күңелеңә биклә дә, безгә юл бир!

**Шыгавыл читкәрәк китә.**

**Идегәй белән Акбеләк чатырга керәләр.**

**24. Йосынчы чатыры. Төн.**

**Идегәй белән Акбеләк чатырга керәләр һәм бертын кузгалмый басып торалар. Акбеләк Идегәйгә Йосынчының йоклаган урынына ымлый. Идегәй аңа аңладым дип баш кага һәм чатырдан чыгып китәргә ишарә ясый: Акбеләк шундук юк була. Идегәй иплән кенә көчле мышнау ишетелгән җиргә якынлаша.**

**Йосынчы** *(кинәт сикереп тора, карлыккан тавыш белән)*. Кем бар монда?! Шыгавыл!

**Шыгавыл**. Мин монда, түрәм!

**Йосынчы**. Ике күзең дүрт булсын: кара аны! Күзеңне ачып тор!

**Шыгавыл**. Тыңлыйм, түрәм!

**Йосынчы урынына ята һәм бераздан кабат мышнап йокыга китә.**

**Идегәй мәче җитезлеге белән аның янына сикерә һәм хәнҗәре белән күкрәгенә кадый.**

**25. Чатыр алды. Төн.**

**Идегәй** *(чатырдан чыга)*. Акбеләк!

**Акбеләк**. Мин бирелә, Кобогыл би.

**Идегәй**. Хәзер бик әкрен пышылдамасаң да була... Бар, үз чатырыңа кайт: иртәгә ерак юл чыгасы — яхшылап ял ит.

**Акбеләк китә.**

**Идегәй**. Шыгавыл! Ышанычлы бирәр кешең бармы нөгәрләр арасында?

**Шыгавыл** *(уйланып)*. Бар, Кобогыл би.

**Идегәй**. Бик яхшы. Бүтәннәргә сиздермәскә тырышып, оят та, икәүләп җайләүдә булган барлык менге атларны беркем тапмаслык итеп яшерегез. Үзең кабат шушында кайтып басарсың, ә таныщың атларны саклап калсын. Яхшылап аңлат үзенә: синең үзеннән яисә бездән башка кем күренсә дә — укка алсын!

**Шыгавыл**. Яхшы. Кобогыл би! *(Караңгыга кереп югала.)*

**27. Шунда ук. Таң атып килгән чак.**

**Йосынчы чатыры янына баштанаяк коралланган Идегәй, Тимер Котлый хан һәм Бәхтияр килә. Чатыр ишеге янында йокымсырап утырган шыгавыл, аларның аяк тавышларын ишетүгә, сикереп тора.**

**Идегәй**. Ул-бу хәл булмадымы?

**Шыгавыл** *(йоклавы өчен үзен гаепле санап, бераз каушап)*. Бары да тәртиптә, Кобогыл би! Була гына күрмәсен...

**Идегәй**. Соңгы үтенеч сиңа, унбашы: ышанычлы нөгәрләрне, иплән кенә уятып, монда чакырчы.

**Шыгавыл** *(унбашы дигән сүзне ишеткәч, йөзе ачылып китә)*. Баш өсте, төмәнбашы Кобогыл би! Күз ачып йомганчы монда булырлар! *(Бүтән чатырлар янына йөгерә.)*

**Шулвакыт чатыр эчендә тонык кына ыңгырашкан тавыш ишетелә.**

**Идегәй**. Бәхтияр, син монда күз-колак бул! *(Тимер Котлый белән бергә чатыр эченә ашыга.)*

**28. Йосынчы чатыры. Шул ук вакыт.**

**Идегәй белән Тимер Котлый чатырга керәләр һәм Йосынчы яткан урынга ташланалар. Идегәй хәнҗәрен әзерли.**

**Йосынчы** *(теле көрмәләнә)*. Син... үтердеңме мине, Кобогыл би? Ни үчен бар иде миндә? Үлемнән коткарган... өченме?

**Идегәй** *(карынты тавыш белән)*. Әйе, минем куллан китәсең, канэчкеч Кара Тиен Йосынчы! Синең кебекләргә җир өстендә урын юк! Төнлә кулым әз генә махы биргән икән — хәзер ялгышмас! Тик шуны белеп кит, җәһәннәм кисәве: синең алла Кобогыл

түгел — Котлыкыя би углы Идегәй! Ә хәзер — Туктамыш атлы этнең кан дошманы!

Йосынчы *(күтәрелергә тырышып карый, әмма хәле җитми)*. Котлыкыя би углы? Һай!.. Мәртәт икәнсең...

Идегәй. Тамагың тыгылсын! *(Хәнҗәре белән аңа кадамакчы була.)*

Йосынчы. Ашык... ма... житешерсең... Син дә... мин белгән ачы хакыйкатьне... белеп кал, Идегәй... Син иң якын... туганыңны суйдың... Без синең белән... ике туган балалары... Аналарыбыз бертуганнар... иде безнең... Көн элгәре дөресен... әйтсәнче!.. Кем белән кайгыларыңны-шатлыкларыңны бүлешерсең... Идегәй?.. Кемгә... таянырсың?.. Нәсел корткыч икәнсең... Ялгыз калдың... Кара каргышым... төшсен сиңа! Көн күрмә... *(Тынып кала.)*

Идегәй *(бу ачыш аны тетрәндергән)*. Дәлилләрең бармы?! *(Йосынчыны җилтерәтә: әмма ул җан тәслим булган инде.)*

**Чатырга Бәхтияр килеп керә.**

Бәхтияр. Нөгәрләр җыелды, Идегәй. Көн бите башланганчы...

Идегәй *(Бәхтиярне танымый тора)*. Ә?.. *(Кул селти.)* Нөгәрләргә хәлне үзең аңлат, Бәхтияр... Тимер Котлый хан, син дә чык, зинһар... *(Башын тотып, Йосынчы янына чүгәли.)*

**Тимер Котлый белән Бәхтияр тышка юнәлә.**

Тимер Котлый *(әкрен генә пышылдый)*. Йосынчы — Идегәй әмирнең якын туганы булган икән...

Бәхтияр. Ишетеп тордым, хан...

**Алар чыгып киткәч, Идегәй Йосынчы гәүдәсенә каплана: аның җилкәсе калтырый. Тыштан Бәхтиярнең нидер сөйләве ишетелә.**

Идегәй *(җиргә тезләнгән килеш, ике кулын кушырып маңгаена куя һәм башын югары күтәрә)*. Тагын бер тапкыр кисәтүеңме бу, и Тәңрем?!. Хәерсез юлга чыктым микәнни соң? *(Ул ике бите буйлап күз яшьләре тәгәрәгәнен дә сизми.)*

**29. Елга буе. Көн.**

**Яшел тугайлыктагы чатырларның исе дә калмаган, еракта, зәңгәр рәшә аша, китеп баручы кәрванның арты гына күренә. Монда — көлчәк эзләре генә.**

**Яр башына өелгән биек корган янында Идегәй бер ялгызы басып тора. Иелеп бер уч туфрак ала һәм кабер өстенә сибә. Атына атланып, юлдашларын куа китә.**

**30. Туктамыш хан сарае. Көн.**

**Туктамыш хан кулга иялләштергән чуар юлбарысының колак артын кашып тора.**

Җанбай. Бөек каган! Җантимер бинең өлкән углы Исабәк сиңа баш ора.

Туктамыш *(ризасызлык белән)*. Аты корсын! Җантимер көчекләре турында Сараемда ишетмим яңадан.

Җанбай. Кичер, бөек каган, түбәнчелек белән хәтереңә төшерергә җөрьәт итәм: Исабәк би сиңа һәрвакыт тугрылыклы булды. Идегәй үзенә кушылырга үгетләгәндә, ул энеләрен һәлакәтле юлдан саклап калырга тырышты, әмма, кызганычка каршы, котырган эт Идегәй аларның утырып өлгермәгән акылын агулаган булган инде. Эткә ияргәнне эт үлеме көтә: сиңа хыянәт итеп, Идегәй белән качып киткән дүрт туганның өчесе шундук синең батыр нөгәрләреңнең кылычына эләккән, дүртенчесе чуар юлбарыска азык булган. Исабәк би моңа үзен битәрли, бөек каган.

Туктамыш. Миннән нәрсә тели ул?

Җанбай. Бер төмән гаскәр сорый.

Туктамыш *(кашларын җыерып, күз койрыгы белән карый)*. Тәхетемне дә сорамыймы тагын?

Җанбай. Минемчә, Исабәкнең нияте безнең максатка бик ярашлы, бөек каган. Ул — безнең күз кешесе.

Туктамыш. Кыскарак тот, вәзир.

Җанбай. Шаһ Тимергә ныгыган тешләребезне күрсәтергә вакыт, бөек каган. Ышанычлы кешеләрем хәбәр итә: Сәмарканд әмире фарсы илләренә яу чыгып, муеннан баткан. Безнең белән ике арадагы Хәрәзем мәмләкәте хакимнәре Иләкмеш углан белән Сөләймән суфи Шаһ Тимернең аркасына пычак кадарга әзер торалар — тик үз көчләренә ышанып кына бетмиләр. Исабәк би аларга ярдәм тәкъдим итә һәм шуның белән сиңа тугрылыгын да тагын бер тапкыр исбатларга тели. Моның белән без берни дә югалтмыйбыз, бөек каган: явы уңса — Шаһ Тимернең борынына чиртәбез, кыйналып кайтса — Исабәк үзе синең алда җавап бирә. Исабәк бинең Идегәйгә сөт туган тиешлеген дә истә тотыйк, бөек каган. Очрашып, бер-берсен җәһәннәмгә олактырмаслармы! Ике карчыга талашканда бер мендәрлек йон чыга.

Туктамыш. Яхшы. Без уйлашырбыз.

**31. Өргәнеч каласы. Көн.**

**Данлыклы каладан ике-өч кенә хәрабә калган, бөтен җир сукаланган. Анда-санда кызарып яткан кирпеч кисәкләреннән генә бу урында кайчандыр зур биналар булганлыгын чамалап була.**

**Идегәй юлдашлары белән хәрабәләр янына килеп җитеп туктый.**

Бәхтияр *(телен шартлатып)*. Менә сезгә утыз мең кешеле данлы Өргәнеч каласы... Күек исе килә бу кырдан!

Идегәй *(бөтен кырны күздән кичерә)*. Син ялгышмадыңмы, Акбеләк? Чынлап та Өргәнеч каласымы бу?!

Акбеләк *(ул чиктән тыш югалып калган)*. Ике ай элек кенә монда зур кала шаулап-гөрләп тора иде, Идегәй... Берни аңламыйм!

**Хәрабәләр арасында көнҗәләдәй тузган башлы бер сәер кеше күренә һәм шундук юк була.**

Бәхтияр *(нөгәрләргә)*. Әнә бер кеше! Бер-икегез минем арттан! *(Сәер кеше күренгән җиргә чаптырып китә: ике-өч нөгәр аңа иярә.)*

Акбеләк *(аклангандай)*. Иләкмеш углан белән Сөләймансуфи дигән ике тере көек түрәләк итә иде монда... Берсен көйләп, икенчесен сөйләп кенә иплеккә күндерәләр иде үзләрен. Атамның сөйләвенә карағанда, Туктамыш хан белән әшнәлек кылмакчы булганнар алар — абыйларым килеп бастыргач кына, койрыкларын кысканнар, имеш.

Идегәй дәшми.

Акбеләк. Без бик нык урау юлдан кайттык... Турыдан китсәк, яуга тап буласы булганбыздыр, бәлки...

Идегәй *(салкын)*. Сәмәркандта бар хатын-кызлар да күп сүзлеләрме шулай?

**Акбеләк аңа кинәт чәнечкеле караш ташлый һәм читкәрәк китә. Бәхтияр белән нөгәрләр теге ир-атны ике кулыннан сөйрәп диярлек алып киләләр: Идегәй янына килеп житкәч, кулларын жибәрүгә, ул йөгереп качмакчы була — аны тотып алалар.**

Идегәй *(ягымлы булырга тырышып)*. Курыкма бездән. Без сиңа тимибез... Кем син?

Бәхтияр *(пышылдый)*. Дивана, ахры...

Идегәй *(коенә торырга тырыша)*. Әйтче, абзый кеше: Өргәнеч каласы моннан еракмы?

Дивана *(карышудан туктый)*. Өргәнеч каласы?! *(Кычкырып көлә.)*

Идегәй. Ник көләсең, абзый кеше? Соравым бик көлке тоеламыни шулай?

Дивана *(кинәт көлүдән туктый)*. Сукыр икәнсең син, юлчы! Өргәнеч каласының базарлы урамында басып торасың ич! Менә көлке дисәң дә көлке! *(Көлә)*. Әнә — кәрван-сарай! *(Бармагы белән сөрелгән жиргә төртеп күрсәтә.)* Күзеңне киеребрәк ачып кара, юлчы! Күрәсеңме, нинди матур бизәкле?

Идегәй. Чынлап та... Хәзер мин дә күрәм. Аңлатчы, абзый кеше: бу калага бик күптәннән килгәнем юк, мин югында нәрсәләр булды монда?

Дивана. Нәрсә булдымы? Аксак Тимер каланы башта көл итте, аннан, сукалатып, ясмык чәчтерде! Нәрсә булды, имеш, тиле көржә... *(Тагын көлә башлый.)* Нәрсә булганын беләсең килсә, югалып йөрмиләр аны! Кызыклар күргән булыр идең!

Идегәй *(кесәсеннән алтын акча алып, диванага суза)*. Безгә дә сөйләче үзең күргән кызыкларны?

Дивана *(аның кулына сугып, алтынын бәреп төшерә һәм ачу белән аны жиргә сеңдереп таптый)*. Алтын сузма миңа! Монда базар да, кибетләр дә юк хәзер, белдеңме, аңгыра юлчы?! Көләрсең дә, еларсың да синең белән! *(Көлә.)* Туктамыш хан Исабәк атлы бер кешесен гаскәре белән Аксак Тимерне пычтерергә жибәргән иде. Аксак Исабәкнең үзен пычеп жибәрде! Һи-һи-һи! Вот тамаша дисәң дә тамаша! Бер төмән жайдактан бары йөз кеше, ясларына жибәрә - жибәрә, Исабәк белән бергә качып китте! Калганнарын, беләсең киләме, Аксак патша нишләтте?

Идегәй. Нишләтте?

Дивана. Валлаһи, белмисеңме?

Идегәй. Валлаһи-билләһи!

Дивана. Бөтенләй томана кеше икәнсең син, юлчы! Үлесе-тересе белән бергә жиргә тезеп салды да, өсләреннән үзенең атлы гаскәрен уздырды! Жайдаклар үтеп киткәч, карасак, эзләре дә калмаган тегеләрнең! Әйтеп бетергесез кызык булды! *(Көлә.)* Аның каравы — ясмык шәп уңачак монда! Әйтимме, ни өчен!

Идегәй. Йә-йә?

Дивана. Туктамыш хан гаскәренең каны гына житмәс иде ясмыкка! Өргәнеч каласының ярты халкын да өстәде ул тегеләр янына! Бигрәк тә, сабый балалар каны файдалы икән! *(Көлә.)* Ә мин — базда качып калдым! Хатыным белән балаларым, ахмаклар, мине тыңламадылар — качмадылар. *(Көлә.)* Менә хәзер үзләренә үпкәләсеннәр!.. Ясмыкка әйләнгәч, рәхәтләнеп ирештереп көләм әле мин алардан!

Идегәй. Исән калган ярты халык кая булды соң, абзый кеше?

Дивана. Абзый димә миңа! Миңа егерме дүрт кенә яшь әле, белдеңме?! Егерме дүрт кенә! Ялганлама, бохар ишәге!

Идегәй. Кичер, дус кеше: эне тиеш икәнсең син миңа... Соравыма жавап бирмәдең?

Дивана. Нинди соравыңа?!

Идегәй. Исән калган халык кая китте, дим?

Дивана *(ачулы)*. Кая китсен?! Аксак аларны Сәмәркандка кирпеч суктырырга куды! Хәрәземдә бер кеше дә яшәми хәзер! Миннән башка! Бөтен мәмләкәткә мин үзем халык, үзем патша! *(Көлә.)* Бирешә каты кеше ул Аксак: халкымны миңа үлсә дә кире кайтармаячак! Күнеленә нык бикләә!

Идегәй. Алай... Ни белән тукланып яшисең соң син?

Дивана. Әй сантый син, юлчы! Юкка бетенмә! Күсе-тычкан беткәнмени?!

Идегәй. Бер арбага утыртыгыз бичараны, калдырмагыз монда! *(Атын чаптырып китә.)*

**32. Сәмәрканд яны. Көн.**

**Идегәйләр биек булмаган бер калкулыкка менеп житеп туктыйлар: алар каршында аста яшеллеккә күмелгән искиткеч матур кала жәелеп ята. Кайда да сыр-сыр гөмбәзле төрбәләр, мәһабәт биналар, гүзәл бакчалар, тулы сулы арыклар һәм сарайлар.**

Акбеләк *(горур)*. Атамның пайтәхете Сәмәрканд!

Идегәй *(ул да соклана)*. Шаһ Тимернең ни өчен Сәмәркандны пайтәхет итеп сайлап алуын аңладым мин хәзер... Яшәр өчен жир-суы яхшы, дошманнан сакланыр өчен — әйләнә-тирәсе уңайлы!

Бәхтияр. Кунакчылмы, түгелме икәнлеге генә билгесез... Кайберәүләр илгә барса илгәзәк, өенә барсаң — бик мәзәк була!

Акбеләк *(серле елмая)*. Ә бу — түрәннән торачак, гарәп! Бездә туйны кырык көн итәләр... *(Каш астыннан гына Идегәйгә карап ала.)*

Идегәй *(кинаяне аңлый)*. Кызганыч — буйдак түгелмен!

Бәхтияр. Шәригать кануннары дүрт хатынны хәләл ди, Идегәй батыр! *(Көлә.)*

Идегәй. Мыегыңа чорна, Тимер Котлый хан!

Акбеләк. Хан?!

Идегәй. Ялгыш ишетмәдең, сылу Акбеләк.

Тимер Котлый. Тик — жирсез-сусыз калган хан... *(Күңелсез генә елмая.)*

Бәхтияр. Безне күрделәр, ахры: ниндидер гаскәр килә!

Акбеләк *(шатланып)*. Атамның жан сакчылары! Чапкыннарым бездән алда кайтып, хәбәр житкергәннәр, димәк!

**Юлчыларны ыспай киемле жайдаклар уратып ала: барысы да таза егетләр, кораллары — алтын-көмештән елык-елык итеп тора, атларының өстенә юлбарыс тиреләре ябылган.**

Ясаул *(Акбеләк алдында атыннан төшеп, ачык йөз белән йөгенә һәм аның итек очын маңгаена куеп ала)*. Туган йортыңа исән-имин кайтып керүеңә чиксез шатбыз, Акбеләк солтан! Бөек падишаһыбыз Шаһ Тимер сөенчегә алтын иярле аргамак әзерләтеп куйды — куанычлы хәбәрне атаңа тапшырырга кайсыбызны сайлыйсың? Мин үзем — падишаһыбыз каршына басканчы сине озата кайтырга тиешмен.

Акбеләк *(куанычы эченә сыймый, шаян)*. Егетләрең барысы да арысландай батыр йөрәкле күренәләр, ясаул! Үз нөгәрләрең арасыннан ласклысын үзең сайлап ал!

Ясаул *(Акбеләк сөйләгәндә хөрмәт белән баш ия)*. Сүзләрең һәрвакыттагыча зирәк, үзең элеккедән дә сылурак, Акбеләк солтан! *(Уң кулын күкрәгенә куеп, баш ия һәм егетләрнең берсенә ишарә ясый: ансы, шатлыгыннан авызын ерып, калага таба чаба.)* Ә хәзер — пайтәхеткә рәхим итегез, кадерле кунаклар һәм мәмләкәтебезнең йөзек кашы Акбеләк солтан! *(Атына сикереп менеп атлана.)*

**33. Олуг мәйдан. Көн.**

**Мәһабәт биналар белән уратып алынган мәйдан уртасындагы баганага ярымшәрә бер ир бәйләп куелган. Алтын гөмбәзле сарайның киң болдырында каба сакаллы Шаһ Тимер утыра: аны якыннары һәм тән сакчылары уратып алган. Мәйдан халык белән тулы.**

Сөрәнче *(Шаһ Тимер ярлыгын укый)*. «Туран мәмләкәте падишасы Тимер Бырлас Шаһ Тимер сүзе. Ошбу кеше мәкерле рәвештә безгә хыянәт итеп, астыртын һөҗүм ясарга жөрьәт итте һәм безне ике тапкыр ук белән яралады. Җәзасын биру — безнең кулда. Әмма без, мәрхәмәтлелек күрсәтеп, аны ярлыкамакчы идек, ләкин Диван киңәше риза булмады, шуңа күрә жәза бирү өчен аның үз коралын сайладык һәм уктан алдырырга булдык. Мин әйттем».

**Шаһ Тимер, әмерне үтәгез дип, кулы белән ишарә ясый.**

**Сорнай кычкырту, барабаннар кагу башлана. Йөз укчы хөкем ителгән кешене түгәрәк ясап уратып ала. Шулвакыт ул бер кулын югары күтәрә: моны күргән Шаһ Тимер сул кулын сизелер-сизелмәс селтәп ала — барабан кагу, сорнай кычкырту шундук тына. Әмир кырында басып торучыларның берсе баганага бәйләнгән ир янына бара. Ансы аңа нидер әйтә. Йомышчы әмир янына әйләнеп килә һәм аңа нидер пышылдый: Шаһ Тимернең йөзендә гаҗәпләнү билгеләре чагылып үтә һәм ул риза дигәндәй, сул кулын гына селти. Йомышчы сөрәнчегә нидер әйтә.**

Сөрәнче. Халык! Җәзага хөкем ителгән хыянәтче үзен баганадан чишүләрен үтенде! Мәрхәмәтле бөек падишабыз аның үтенечен канәгатьләндерде: моның белән ул тагын бер тапкыр гадел хаким булуын раслый!

**Халык арасында жанлану башлана. Корбанны чишәләр: ул, тәне бар яктан да укчыларга ачык булсын өчен, баганадан читкәрәк китеп баса, кулларын күкрәгенә кушырып, башын югары чөя — бу Шаһ Тимерне чыраен сытарга мәжбүр итә, әмма тамашага килгән халыкка ошый. Кабат барабан кагу, сорнайлар кычкырту тавышлары яңгырый. Укчылар жәяләрен күтәрәләр һәм бөтенесе берьюлы атып жибәрәләр. Йөзләп ук корбанның бөтен тәнен тишеп чыга һәм ул, кинәт энәләре тырпайган керпегә охшап, бер мизгел катып басып тора да, әкрен генә жиргә ава. Барабаннар кагу, сорнай кычкырту тына. Мәйданда шау-шу башлана: «Батыр йөрәкле икән — сынатмады үзен! Чын яугир булган!» кебек сүзләр ишетелә. Мәйданга сөенче алырга ашыккан жайдак чабып килеп керә һәм, Шаһ Тимергә янына килеп житәргә ун-унбиш адымнар калгач, атыннан сикереп төшеп, бер тезенә төшеп йөгенә, әмма ритуалны азакка кадәр үтәргә түземлеге житмичә, авызын ера.**

Җайдак. Бөек падишабыз! Акбеләк солтан кайтып житте!

**Кырыс йөзле Шаһ Тимер бөтен вәкарьлеген онытып сикереп тора.**

Сөрәнче. Бөек падишабызга — ат!

**34. Сәмәркәнд каласы урамы. Иртә.**

**Киң урам буйлап сөрәнчеләр тарала.**

Сөрәнче. Тыңлагыз! Туран мәмләкәтенең бөек хакиме Әмир Бырлас Шаһ Тимер сөекле кызы Акбеләк солтанның авыр сәфәрдән исән-имин кайтып төшүе хөрмәтенә кырык көнлек бәйрәм игълан итә! Һәркем үз чатыры белән Дөлделкөш бакчасына барырга тиеш! Һөнәрчеләр, кул осталары үзләренең һөнәрен күрсәтә, итчеләр — ит пешерә, мунчачылар күчмә мунчалар әзерли! Мәмләкәтнең һәр кешесе бөек әмирнең шәхси кунагы саналачак!

**Падишаһ сарае капкасыннан чапкыннар чыгалар һәм түрәләрне бәйрәмгә чакырырга ерак олысларга таралалар.**

**35. Дөлделкөш бакчасы. Көн.**

**Иксез-чиксез киңлекләргә сузылган зур яшел бакчаның тугайлыгында Шаһ Тимер чатыры куелган: ул искиткеч зур һәм матур**

**бизәлгән, аның хәттә иң өске каты да алтын-көмеш парчалы. Падишаһ чатырының тирә-ягында аның хатыннарының һәм туган-тумачаларының, якын кешеләренең чатырлары урнашкан, ә арырак урам-урам булып төрле түрәләрнең, әмирләрнең һәм ханнарның чатырлары тезелеп киткән. Алар 20 меңнән артык. Олы капкадан бертуктаусыз пешкән итләр тояган җигүле атлар, дөяләр керен тора: тузан, ыгы-зыгы, шау-шу, әмма тәртипсезлек сизелми — ясауллар, бөек әмирнең тән сакчылары кечкенә тәртипсезлекне дә шундук тыя торалар. Артыграк кычкырып сөйләшә башлаучыларны, кулларын артка каерып, тиз генә каядыр алып китәләр, ә кайберләрен, борынына чылбыр тагып, урамга таба сөйриләр.**

**37. Бөек падишаһ Шаһ Тимер чатыры. Көн.**

**Шаһ Тимер биек урынга куелган тәхетенә аякларын бөкләп менеп утырган. Уң кулы тәхет култыксасына беркетелгән күн тышлы мендәр өстендә: күптәнге ярасы сызлый, күрәсең, ул аны сул кулы белән сыпыргалап утыра. Зур сакаллы, кысыграк күзле, кылыч борынлы таза кеше. Аның тирәсендә берничә улы һәм оныклары урнашкан. Бер читтә шәхси катибе аның һәр сүзен язып утыра. Бөек әмир һәм аның якыннары алларында торган алтын савытлардан төрле тәмле җимешләр ашыйлар.**

**Чатырга Акбеләк килеп керә һәм атасының уң кулын үбә: Шаһ Тимер сул кулы белән кызының башын сыйпый. Кызын бик нык яратуы әллә каян күренеп тора.**

Тимер. Йә, кыргый җәйрәнем, сора: нинди теләгең бар? Бүген — бар теләкләрең үтәләчәк!

Акбеләк. Шайтан кулыннан коткарган Идегәйгә кияүгә бир мине, галиҗәнәп әтием!

Тимер. Ныклап танышып өлгермәдем бит әле мин аның белән, бәтием... Бәлки, ул синең кисеп ташлаган тырнагыңа да тормыйдыр?

Акбеләк. Бүтән андый кеше юк бу дөньяда! Синең үзеңне санамаганда, әлбәттә.

Тимер *(елмая)*. Хәйләкәр син! Карт әтиеңне күңеләеңнән бөтенләй үк сызып ташламагансың икән әле, шулай да... *(Кырыс.)* Идегәйнең асылы нинди икәнлеген тиздән күрербез: үзбәкләрне акылга утыртасы бар.

Акбеләк. Мин аның сугышка китүен теләмим!

Тимер. Ә үз абыйларың белән үз атаңа орышта башларын салсалар да ярыймы, күке баш?

Акбеләк. Сез дә бармагыз! Әмирләрең күп ич — алар сугышсыннар.

Тимер. Алар сугышырлар. Тик кулга төшергән байлыкка да үзләре хуҗа булырлар шул, юләр бәтием... Бар, теләгең турында уйлашырбыз!

**Акбеләк әтисенең кулын үбеп чыгып китә.**

Гомәр Шәех. Кияүне кайдан да табарбыз, Идегәй безгә Алтын Урданы бүләк итәчәк кол булырак кына кирәк, дип туп-туры әйтергә иде, әти!

Тимер *(кырыс)*. Хатын-кыз колагына кергән сер сөйгән кешесенең колагына күчми калмый, Гомәр улым! Идегәйне кертсеннәр.

**Гомәр Шәех кулларын шапылдатып суга: шыгавыл керә.**

Гомәр Шәех. Бөек падишаһ Идегәйне күрергә тели!

**Шагавыл баш иеп чыгып китә. Якында гына булган, ахры, берничә секунд үтми — Идегәй килеп керә. Шундук каяндыр килеп чыккан ике ясавыл, ике яктан тотып, аны җиргә тезләндерә һәм баш идерә. Аягына бастырып, алга таба берничә адым атлатып, тагын шулай ук бөек хаким алдында йөгендерәләр. Шул ук ритуал янә бер мәртәбә кабатлана.**

Тимер *(ачык йөз белән)*. Хуш киләсең, Идегәй әмир, рәхим ит — утыр. *(Уң ягында торган тәхетеннән түбәнрәк бер утыргычка уң кулы белән күрсәтә: кулының терсәктән бераз бөгелеп катканы сизелә.)*

Идегәй *(кулын күкрәгенә кушырып)*. Рәхмәт, бөек падишаһ. *(Күрсәткән урынга утыра.)*

Тимер *(беркемгә дә карамыйча)*. Падишаһ кунагына — җимеш сые!

**Кайдандыр, тылсым көче белән пәйда булгандай, бер кыз калыга һәм Идегәй алдына савыт белән җимеш куя.**

Тимер. Житеш, кадерле кунак... *(Үзе дә җимеш каба.)* Борынгы ата-бабаларыбыз йоласы кунакны кырык көнсез сораулар белән борчымаска куша... Шулай да, агара башлаган чәчләремә хөрмәтенә кичерерсең, дип өметләнәм.

Идегәй. Сора, бөек падишаһ. *(Җимеш каба.)*

Тимер. Ата-анаңнар кемнәр, исән-саулармы, олан?

Идегәй. Анамны белмим, бөек падишаһ. Мине тапканда вафат булган. Атам башта Ырыс ханда, соңарак аның улы Тимер-Мәлик ханда әмирләр әмире булган, диләр.

Тимер. Диләр?

Идегәй. Әйе. Чөнки Туктамыш хан анам фани дөньядан киткән көнне аның башын чаптырган.

Тимер. Атаңның аты кем иде?

Идегәй. Котлыкыя би.

Тимер *(уллары белән күзгә-күз карашып алалар)*. Котлыкыя би улы? Яхшы ата улы икәнсең, олан. Котлыкыя би гаярь ир иде! Туктамышка баш имичә, минем дуслыкны кабул иткәне өчен башы чабылды аның. Ә син үзең ничек исән калдың?

Идегәй. Туктамышның аталыгы Җантимер би, бишектә яткан чагымда чабыласымны белгәч, минем урынга үз төпчеген салып, бер кашык канымны саклап калган. Кобогыл исеме белән үстем мин.

Тимер *(тагын бер мәртәбә уллары белән карашып ала)*. Кобогылның батырлык-

лары хакында күп ишеттек, олан. Ул — син икәнсең. Хуп!

Идегәй. Инде хәзер, үземә дә күптән түгел генә җиткән серем ачылгач, Туктамыштан качып китәргә туры килде. Рөхсәт итсәң, мәрхәмәтле канатларың астына сыеныр идем, бөек падишаһ?

Тимер. Сыену дип кимсенмә: син үзең дә бүре тибеп ала торган Төкле Аяк кебек лачын, Идегәй әмир! Күңелең сыйдырган кадәр кунагым бул. Каршы килмәсәң, бер илемә тарханлык биреп, якын дустым итәрмен.

Идегәй. Җылы сүзләрең өчен рәхмәт, бөек падишаһ. Арба тартып су ташучы итсәң — су ташучың булырмын, гаскәр биреп, яугир ясасаң — яугирең булырмын.

Тимер. Туры сүзең ошады безгә, Идегәй батыр! *(Өлкән улына ишарә ясый.)*

**Гомәр Шәех колларын шапылдата: кемдер, арткы ишеткән кереп, Идегәйнең җилкәсенә затлы тун сала.**

Тимер. Өстеңдә тузсын! Кинәнечен күр!

Идегәй *(кулын күкрәгенә куеп, баш ия)*. Рәхмәт, зурладың мине, бөек падишаһ. Алмак күрке бирмәк: ничек кайтарырмын икән?

Тимер. Ансы — соңыннан... Әлегә тагын бер генә соравым бар сиңа, кадерле кунагым... Былбылыбызның чүл карсагы тырнагыннан коткаручысының тургачына кунып сайрарга теләвен сизендек, син ничек карыйсың моңа, Идегәй батыр?

Идегәй *(башын иеп уйланып тора)*. Идел-Йортымда сөекле хатыным һәм берләч углым Норадын корытомшык калды. Кайчан аларны кабат кайтып күрә алырмын — бер Хак Тәгалә генә беләдер. Мин монда япа-ялгыз. Былбыл сайравы сагышлы йөрәгемә дәва булыр бәлки? Тавышын ишеттем — моңы үзәгемә тирән үтеп керде. Күзләрен күрдем — нурлары томаланган җанымны яктырткандай булды. Акылы зирәкләрдән зирәк икәнлеген белдем — зиһенемне үзенә әсир итте. Олы мәртәбә итеп карармын, бөек падишаһ!

Тимер *(йөзе ачылып китә)*. Сеңлегезне чакыртыгыз, улларым!

**38. Сәмәркандта Тимер Котлый хан йорты. Көн.**

**Кечерәк кенә, әмма бик матур сарай. Ишек төбендәге сакчы шыгавыллар — Шаһ Тимер казакларыннан, бары тик сарай эчендәге сакчылары гына үтерелгән Йосынчының Идегәйләр белән бергә Сәмәркандка килгән нөгәрләре: хуҗалар «кунак»ка бик үк ышанып бетмиләр, димәк.**

**Сарай ишеге янына атка атланган Идегәй белән Бәхтияр килеп туктый. Иярләреннән төшеп, атларын сакчыларның берсенә тоттыралар. Биек баскычтан күтәрелеп, ишеккә киләләр.**

Шыгавыл *(айбалтасын ишеккә аркылы куя)*. Кемнәр?

Идегәй. Шаһ Тимер киявен таныргa вакыт, шыгавыл! Тимер Котлый хан янына!

Шыгавыл *(салкын канлылык белән)*. Андый ханны белмибез без. Бу сарайда бөек падишаһыбызның кунагы Тимер Котлый атлы кеше яши — аны беләбез. *(Ишек аша эчке сакчыга.)* Бөек падишаһ кунагын юлдашлары күрергә тели — кабул итәме?

**Эчтә шул ук сүзләр берничә мәртәбә кычкырып кабатлана. Һәм бераздан: «Үткәрегез!» — дигән җавап кабатлана-кабатлана ишеккә килеп җитә. Шыгавыл айбалтасын читкә ала. Идегәй белән Бәхтияр сарайга керәләр.**

**39. Сарайның алгы залы. Көн.**

**Идегәй белән Бәхтияр ишектән килеп керүгә, яннарына ике сакчы килә.**

Берсе. Коралларыгызны калдырыгыз!

Идегәй *(ачуы чыга башлый)*. Кем боерыгы? Мине таныйсың ич!

Сакчы. Тимер Котлый хан әмере. Без беркемгә дә өстенлек бирмибез, кичер, Идегәй әмир.

**Идегәй белән Бәхтияр коралларын тапшыралар. Каршыдагы ишек ике якка ачыла. Кунаклар икенче залга үтәләр. Анфилада рәвешендә алда тагын шундый ук ишекләр ачыла. Ниһаять, дүртенче ишек ачылгач, киң сәкедә кырын ятып, озын көпшәле кальян тартучы Тимер Котлый хан күренә. Аның каршында талгын музыкага ярымшәрә бер кыз бии. Тимер Котлый вакытын кәеф-сафа корып уздыра башлаган, күрәсең.**

Идегәй *(җиңелчә йөгенә)*. Әссәламегаләйкем, Тимер Котлый хан.

Тимер Котлый *(ачык йөз белән, әмма артык шатлану белдермичә)*. Вәгаләйкемәссәлам, кадерле агам Идегәй әмир. *(Биюче кызга кулы белән китәргә ишарәли. Бәхтиярне ул сәламләргә кирәк дип тә санамый.)* Түргә үтегез, кунаклар. *(Ике бармагын шартлата.)*

**Тар гына ишектән бер җария керә.**

Тимер Котлый. Кунакларга — сусын.

**Идегәй белән Бәхтияр сәке алдындагы утыргычларга урнашалар.**

Тимер Котлый. Синe исән-аман күрүемә бик шатмын, агам. Туеңнан соң, күптән күрешкәнебез юк. Сараемда беренче тапкыр бит әле син, шулаймы?

*(Аның тавышында агасына төрттерергә тырышу сизелә. Җария кунаклар алдына алтын савытлар белән ниндидер эчемлек китереп куя һәм чыгып китә.)*

*Идегәй (эчемлекне кабып карый һәм елмая)*. Хәзер синең янга үтүе кыенлашкан икән, хан... Хәтта Шаһ Тимер киявенә дә корал белән керергә рөхсәт итмәделәр.

Тимер Котлый *(турыланып утыра, сөмсере коелып)*. Саклаганны саклармын дигән, агам!

Идегәй. Янаулар сизелмидер ич?

Тимер Котлый *(бавырлы караш белән.)* Мин хәзер беркемгә дә ышанмыйм! Ханнарның тәкъдире шундый.

Бәхтияр *(көлемсерәп)*. Тәхеттә утырганнарыныкы шулай, хан.

Тимер Котлый *(сүзгә кушылганына ачуы килеп)*. Үз йортымда мәсхәрә ишетүемме бу?!

Идегәй *(йомшак)*. Безнең үз йортыбыз әлегә дошманнарыбыз кулында, Тимер Котлый хан.

Тимер Котлый. Мин — өлешемә тигән көмешемнән канәгать. Бу эшне булдырырлык кеше күрмим.

Идегәй. Кызганыч. Без монда туган туфрагын сагынган яугир очратырбыз, дип килгән идек, хан. Май эчендә бөерәк кебек икәнсең! Бик кызганыч. *(Кузгала.)* Китәргә рөхсәтеңне сорыйбыз.

**Бәхтияр дә сусынын кабып та карамыйча кузгала.**

Тимер Котлый *(китүләреннән куркып, иләмсерәп сикереп тора)*. Кая ашыгасыз, кадерле кунаклар? Сүзләрем дорфа яңгыраган булса, кичер, агам!

Идегәй *(коры)*. Һәркем үз язмышын үзе сайлый, Тимер Котлый хан.

**Хан алдында җиңелчә йөгенеп, чыгып китәләр.**

**40. Сарай алды. Көн.**

**Идегәй белән Бәхтияр чыгуга атларын китерәләр. Ике дус, ат менеп, киң урам буйлап китә.**

Бәхтияр *(җирәнгән сыман)*. Хәерче кесәсендәге шикәр кебек шомарган бу... Тышкы сакчылар — Шаһ Тимернеке. Хан имеш — боламык! Юлларыбыз аерылыр, ахры... Килүебез әрәм!

Идегәй. Киресенчә, мин бик канәгать. Тиздән ул үзе миннән таяныч эзләп киләчәк. Бүтән чакта мөнәсәбәтеңне аңа ачык белдермәскә тырыш, гарәп! Туктамышны кугач, Сарай тәхетенә аны утыртачакмын мин.

**Бәхтияр, атын туктатып, аңа гаҗәпләнеп карый. Идегәй кычкырып көлә һәм атын чаптырып китә.**

**41. Шаһ Тимер сараенда кечерәк бүлмә. Көн.**

**Бүлмәнең ишеге дугасымак сыртлы итеп эшләнгән, алтын-көмеш бизәкләр белән инкрустацияләнгән. Ишекнең ике ягында алтынланган ике рәсем: берсендә изге Петр китап укып тора, икенчесендә — изге Павел сурәте. Ишектән кергәч тә уртада зур шкаф: ул тоташтан алтыннан ясалган һәм искиткеч матур эмаль сурәтләр белән бизәлгән. Шкафта корсаклы алтын-көмеш савытлар саклана. Ян-яклардан шкаф сырлы-сырлы итеп кыйммәтле асылташлар һәм энҗе-мәрҗән белән капланган. Шкафның урта киштәсендә алмаз-бриллиантлар таралып ята. Шкаф янында ике карыш биеклеге алтын өстәл: аңда бие дүрт-биш карыш, киңлеге карыш ярым чамасы зурлыктагы зөбәрҗәт такта ята. Өстәл кырындагы алтын чүлмәктә алтын кәүсәле, санап бетергесез ботаклы, кеше биеклеге агач тора. Кәүсәсе таза ир-ат кулыннан да юанрак. Алтын яфраклары имәннекенә охшаган, җимешләре эреле-вакты энҗе-мәрҗән, зөбәрҗәт, кызыл, зәңгәр якут һәм шулар ише бүтән төрле ләгъль якут асылташлардан ясалган. Алтын агачларның ботакларында эмаль белән бизәлгән кечкенә алтын кошлар утыра: кайберләренең томшыкларында фирәзәләр, бриллиантлар ялтырый. Кошларның кайберләре, очарга әзерләнгәндәй, канатларын җәйгән, кайсылары әле генә ботакка килеп кунган кебек тоела. Бүлмәнең ике ягында ике киң өстәл: алар да алтын-көмеш сурәтләр белән бизәлгән. Өстәлләрдә асылташлар белән бизәлгән алтын кувшиннарда эчемлекләр тора. Идәндә ефәк тышлы мендәрләр аунап.**

**Бу минутта бүлмәдә Шаһ Тимер ялгызы: ул, уң аягына бераз аксый төшеп, төрле халыклардан талап җыйган байлыгын карап йөри, вакыт-вакыт кувшиннарга күз сала: шул ук секундта, ян ишектән кереп, җария алтын касәләргә шәраб тутырып куя һәм югала.**

**Шаһ Тимер янына улы Гомәр Шәех керә.**

Гомәр Шәех. Ялыңны бүлдерергә рөхсәт ит, бөек атам.

Тимер. Тыңлыйм, Гомәр улым.

Гомәр Шәех. Кунаклар, ниһаять әле генә күрешеп, киңәштеләр.

Тимер. Нәтиҗә?

Гомәр Шәех. Тимер Котлый Алтын Урда тәхетеннән мәңгегә өмет өзгән, ахры.

Тимер. Ә киявебез?

Гомәр Шәех. Тимер Котлыйны ваемсызлыкта гаепләп, ачуланышкан. Шунысы сәер: сарайдан киткәндә йөзендә никтер канәгатьлек билгесе бар иде, диләр. Ул Алтын Урда тәхетен үзенә өмет итә булырга тиеш — арада кирtә калмый, дип куана, димәк.

Тимер *(башын чайкый)*. Ай-һай, улым. Тимер Котлыйның сүлпән кеше булуы сөендермиме икән аны? Тәхеттә андый хан утырса, Идегәйнең куләгәсенә әйләнәчәк ич! Аңа шул гына кирәк тә: чөнки хан булырга үзенең хакы юк.

Гомәр Шәех *(әтисенең зирәк акылына сокланып)*. Ә бит дөрескә охшый бу, бөек падишаһ!

Тимер. Былбылына яхшылап аңлат: иренең уенда ни бар — түгелми-чәчелми безнең колакта булсын!

Гомәр Шәех. Идегәй Алтын Урдага яу сораса, бирәсеңме?

Тимер. Ындыр артыбызда үзбәк дигән шакаллар күп: нәселен корытыйк башта. Бакчабызның каравылсыз калган чагын көтеп яталар булыр... Бер атнадан Бөек Королтай: ул ничек хәл итәр...

**42. Дөлдөлкөш бакчасы. Иртән.**

**Бакчаның киң даласында санап бетергесез зиннәтле ефәк чатырлар: бәйрәмдәге кебек казаннарда ит пешә, һөнәрчеләр күз алдында ук әйберләр ясыйлар, вак сәүдәгәрләр кечкенә кибетләрдә ашамлыклар, төрле кирәк-яраклар саталар. Шаһ Тимернең тән сакчылары тәртип күзәтә, салымчылар салым җыя, букаллар** *(завхозлар)* **капкадан**

**бертуктаусыз кереп торган азык-төлек ола-уларын кабул итәләр. Бер читтә ике агач арасына бау тартып бәйләнгән: анда бауда йөрүчеләр халыкка тамаша күрсәтә, елан биетүчеләр, курай уйнап елан биетә, ут йоту-чылар авызларыннан ялкын очыралар. Һәм-мә җирдә тавыш, ыгы-зыгы.**

**Барабан кагу, сорнай кычкырту яңгырый: падишаһ чатырыннан уллары, вәзирләре, әмирләре белән бергә Шаһ Тимер чыга һәм бер читтәге иркен мәйданга юнәлә. Идегәй, Тимер Котлый хан һәм төрле илчеләр дә шулар арасында. Дәүләт башлыклары алдан әзерләнгән тошкә урнаша. Бераздан быргы тавышлары яңгырый: иң элек үз чатырыннан әмиренең өлкән хатыны Биби ханым чыга: ул алтын парчалы кызыл ефәк күлмәк кигән. Озын киң итәген унбишләп җариясе күтәреп бара. Башында сугышчы очлымын хәтерләт-кән кызыл башлык: ул бик биек һәм йөзәр-ләгән энҗе-мәрҗән, асылташлар, бриллиант-лар белән бизәлгән, өстәвенә бик күп акияти кош каурыйлары беркетелгән — шунлыктан, башыннан төшеп калмасын өчен, аны бер-ничә җария куллары белән тотып бара. Биби ханым битен калын итеп акшарлаган һәм үтә күренмәле пәрәнҗә япкан. Сансыз вак толы-мнарга бүлгәләп үрелгән кап-кара чәчләре җилкәсенә сибелгән. Аны барлыгы өч йөзләп күренекле хатын-кыз озата килә. Биби ханы-мны, өстенә кояш нуры төшмәсен өчен, озын таякларга беркетелгән киң ефәк җилпәзә бе-лән каплап баралар. Биби ханым ире янына түбәнгәрәк барып утыра. Аны озатып йөрүче хатын-кызлар арткарак урнашалар. Берни-чәсе биек башлыгын утыргач та тотып тора.**

**Шундый ук тәртип саклап, аның артын-нан Шаһ Тимернең калган сигез хатыны да чатырларыннан чыгып утыра. Алар арасын-да Идегәйнең хатыны Акбеләк тә бар. Аксө-якләр урыннарга урнашып беткәч, мәйданга гадирәк халык җыела. Диван бие сәрәнчегә ишарә ясый.**

Сәрәнче *(биек урынга үтеп, Шаһ Тимер-гә түбәнчелек белән йөгенә һәм кычкырып игълаunion айтә)*. Туран мәмләкәтенең Бөек падишаһы Әмир Бырлас Шаһ Тимер фәр-маннарын тыңлагыз!

Бөек Корылтай хөрмәтенә боерабыз! Бе-ренче фәрман! Сәмәркандта баш вәзиребез Гаделбәк би кала бие булып калган иде, без югында, урыныннан явызларча файдала-нып, халыкны җәберләргә җөрьәт итте: дар агачына асыла һәм мал-мөлкәте казнага алына.

**Көчле барабан кагулар астында мәйдан-ның каршы ягына бер кешене алып киләләр һәм аны шундук дар агачына асып куялар. Халык аһ итә: чөнки ул — баш вәзир, Шаһ Тимернең үзеннән кала икенче дәрәҗә тот-кан кеше!**

Сәрәнче. Икенче фәрман! Бородай бәк, гадел хөкемгә тартылган баш вәзирне яклап, безгә дүрт йөз мең алтын ришвәт бирергә җөрьәт итте: дар агачына аягыннан асып куела һәм бөтен байлыгы казнага алына!

**Хөкем карары шундук үтәлә.**

Сәрәнче. Өченче фәрман! Без яуга чы-гар алдыннан өч мең аргамагыбызны Кил-дебәк бигә ышанып тапшырган идек — яу-дан кайткач, җиде данәсе суеп ашаганлыгы беленде. Ул явыз да, безнең мәрхәмәтебезне сатып алырга теләп, үзенең алты мең ар-гамагын тәкъдим итте: дар агачына асыла һәм мал-мөлкәте казнага алына!

**Өченче корбанны да асып куялар.**

Сәрәнче. Дүртенче фәрман! Безнең яу-да йөрүебездән явызларча файдаланып, кай-бер вак сәүдәгәрләр итне халыкка тиешен-нән кыйммәтрәк сатып ятканнар: аларның башлары чабыла һәм комсызлык белән җыйган мал-мөлкәтләре ятимнәр файдасы-на казнага алына!

**Куллары артка каерылып бәйләнгән бер-ничә кешене агач түмәрләр янына алып ки-ләләр һәм башларын зур кылычлар белән кыеп төшерәләр.**

Сәрәнче. Бишенче фәрман! Кадерле кунагыбыз Идегәй баһадир түмәнбашы итеп куела һәм аңа казна исәбеннән ун мең аргамак бәясе кадәр алтын билгеләнә.

**Идегәй урыныннан тора һәм Шаһ Тимер алдына хөрмәт белән йөгенә. Шаһ Тимергә сыеныбрак утырган бер хатыны Идегәйгә кызыксынып карап куя.**

Сәрәнче. Алтынчы фәрман! Без бүген бөтен Сәмәрканд халкын үзебезгә мәҗлескә алабыз! Бөек Туран мәмләкәтенең Бөек па-дишаһы Әмир Бырлас Шаһ Тимер сүзе әй-телде!

**Барабаннар кагу, сорнайлар кычкырту башлана: Шаһ Тимер үзенең яраннары белән чатырына юнәлә. Алар югалгач, быргы та-вышлары яңгырый: Шаһ Тимернең хатынна-ры һәм кызы белән киленнәре, дәрәҗәләренә карап үз чиратларын саклап, җарияләре бе-лән бергә чатырларына кереп китәләр. Алар артыннан бүтән халык та тарала: мәйданда җәзалап үтерелгәннәрнең гәүдәләре генә ка-ла. Башка урыннарда гадәттәгечә ыгы-зыгы дәвам итә.**

**43. Идегәйнең Сәмәркандтагы йорты. Кич.**

**Идегәйнең йорты Тимер Котлыйны-кыннан бик аз гына аерыла: җиһазлары да шундый ук, тик сакчылары гына барысы да Шаһ Тимер нөгәрләре. Сугышчан дусты Бәхтияр дә шул ук йортның бер өлешендә яши.**

**Бүлмәләрнең берсендә Идегәй Бәхтияр белән сөйләшеп утыра.**

Бәхтияр. Шаһ Тимернең бүгенге фәр-маннарына колак салдыңмы? Бик кызык яң-гырады!

Идегәй. Нәрсәсе кызык?

Бәхтияр *(елмая)*. Биш фәрманның дү-ртесе җинаятьчеләрне җәзалау турында, шуннан соң котелмәгәндә — сиңа дәрәҗә бирү! Сиңа сәер тоелмыймы, Идегәй?

Идегәй *(елмая).* Мине гел-гел үлемнән коткара торгач, хәзер гади бармак та хәнҗәр булып күренә башлаган, бугай, синә, җан дустым!

Бәхтияр. Белмим, белмим... *(Елмая.)* Ә син сизденме, аның Чулпан атлы иң яшь хатыны синнән күзен язмый карап утырды?

Идегәй. Әллә ниләр күреп бетерәсең син, дус кеше!

Бәхтияр. Сак бул, дип әйтәм... Коласының шомарт. Сер булмаса, Бөек Корылтай нәрсә карар итте?

Идегәй. Сер түгел. Теге вакытта Хәрәземнәр белән бергә үзбәкләр хакиме Анкатур әмир дә Әндиҗанны камаган булган икән, тик алырга көче җитмәгән. Хәзерге көндә ул, Алтай ханнарын туплап, Сәмәркандка яу килмәкче, имеш. Шуны бастырырга чыгабыз.

Бәхтияр. Ә Туктамыш?!

Идегәй. Туктамышка тешләре үтмәс, дип шикләнәләр кебек тоела миңа.

Бәхтияр. Шулай булгач, без нишләп монда ипи чеpeтеп, вакытыбызны заяга үткәреп ятабыз соң?! Илең-суың бер дә тартмыймы сине?

Идегәй. Ә нәрсә тәкъдим итәсең?

Бәхтияр. Бүтән таяныч эзлик!

Идегәй. Әйтеп кара?

Бәхтияр. Төрек солтаны Елдырым Баязитның бүресе улаган чагы! Бөтен Аурупаны тетрәтеп тора. Литвалы Җагайлу! Бер дә булмаса... Мәскәүгә таянырга була! Туктамышның Мәскәүне яндырып кайтканына җиде-сигез ел бар инде — яраларын ялап бетергәннәрдер!

Идегәй. Үз йортыңа тулы хуҗа буласың килсә, беркайчан да кан дошманыңа таянма! Мәскәү... Мәскәү Сарайны юк итәр өчен иманын сатарга әзер! Бер чакырып китерсәң... Килмешәкне өч көн кунак итсәң, өйгә хуҗа мин, дип низаг куптара, ди! Литвалы Җагайлу да Алтын Урда дигән калҗадан майлырак өлеш кисеп алырга чамалап, күптән чик тирәсендә селәгәен агызып йөри.

Бәхтияр. Ә Елдырым Баязит?

Идегәй. Юк, Бәхтияр дустым: Алтын Урда белән Туран мәмләкәте иксез үзара хәл итә торган эш бу. Ике туганның эчке эше. Ә Баязитның иле белән безнең Йортның беркайчан да уртаклыгы булмаган. Мин биатама таянырга булдым! Тик ашыктырма: игелекле эшнең иртә-киче юк.

Бәхтияр. Әгәр дә... Шаһ Тимер яудан баш тартса?

Идегәй. Баш тартмаячак ул.

Бәхтияр. Каян беләсең?

Идегәй *(елмая).* Үземнән беләм, Бәхтияр, үземнән.

Бәхтияр. Кайчагында... бөтенләй аңламыйм мин сине, Идегәй! Шулай да... үземнең хаклы икәнлегемә сине ышандыра алырмын, дип өметләнәм мин!

**Бүлмәгә Акбеләк килеп керә: ул хәзер гадәти киемнән.**

Бәхтияр *(кузгала).* Мин бәй-бәй киттем. *(Акбеләккә хөрмәт йөзеннән баш иеп чыгып китә.)*

Акбеләк *(Бәхтияр чыгып киткәч).* Гарәбең нишләптер мине күрәлми, ахры, Идегәй... *(Иренең куенына елыша.)* Һәм дөрес эшли!

Идегәй *(гаҗәпләнеп).* Ник?

Акбеләк. Чөнки... сәбәбе бар. Ул шуны сизенә. О, күрми-ишетми калган бер нәрсәсе дә юк аның! Чуар барыстан да үткенрәк ул егет.

Идегәй *(тагын да ныграк гаҗәпләнеп).* Төшендереп бир, былбылым?

Акбеләк *(кызу-кызу пышылдый).* Абыйларымнан сак бул, Идегәй! Атамнан да! Алар синнән бик нык шикләнәләр! Гомәр абыем, беләсеңме, миңа нәрсә кушты? Синең арттан шымчы булырга! Һәр сереңне аларга җиткереп торырга тиешмен!

Идегәй *(тыныч булып күренергә тырышып).* Ә син?

Акбеләк. Ә мин — сине үлеп яратам! Бу бүлмәдә беркайчан да сер сөйләшмәгез: күрше бүлмәдән бөтенесе ап-ачык ишетелеп тора! Менә әле дә... Җагайлулар, Баязитлар хакында...

Идегәй *(аның авызын каплый).* Чү, икс күзем... Мин хәзер! *(Нидандер шикләнеп, тиз генә күрше бүлмә ишеген ачып карый — әмма анда беркем дә юк. Шиген бетерер өчен аргы ишекне дә ача — анда да беркем дә юк. Акбеләк янына кире кайта.)*

Акбеләк *(ул агарынган).* Әллә берәрсе тыңлап торганмы? Сиңа әйткән сүзләремне абыйларым белсәләр, беттем! Җир йөзендә бер көн дә тотмаячаклар мине!

Идегәй. Тынычлан, былбылым... Беркем дә юк. Миңа тоелган гына... *(Кинәт.)* Ә бүтән бүлмәләргә дә ишетелмиме соң моннан?!

Акбеләк *(бөтенләй коелып төшә).* Б — белмим...

Идегәй *(ул да бик әкрен пышылдауга күчә).* Менә нәрсә, былбылым: шушы мизгелдән алып, бу йортта... бер нәрсә сөйләшмибез! Кисәтүең өчен рәхмәт! *(Хатынын сырып үбә.)* Тәхет — туганнар каберлеге ул, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер шул...

**44. Шаһ Тимер сараенда бер бүлмә. Кич.**

**Шаһ Тимернең улы Гомәр Шәех шымчы егет белән сөйләшә.**

Гомәр Шәех. Монда кергәнеңне беркем дә күрмәдеме?

Шымчы. Юк, калга Гомәр Шәех.

Гомәр Шәех. Сөйлә.

Шымчы. Минемчә, икесенең арасында иң куркынычы — Бәхтияр, Гомәр әкә! Ансын тизрәк юк итәргә кирәк. Ул Идегәйне, сезне ташлап, бүтән мәмләкәтләргә таянырга котырта! Менә аның сүзләре: Шаһ Тимергә өметләнеп, вакытны бушка уздырып ятмыйк, төрек солтаны Елдырым Баязит, яки литвалы Җагайлу, я булмаса — Мәскәү белән элемтәгә керик, ди.

Гомәр Шәех. Идегәй ни дип җавап бирде?

Шымчы. Биатама таяначакмын, диде. Әмма Бәхтияр, үземнең хаклы икәнлегемә сине ышандырачагыма барыбер өметемне өзмим, дип чыгып китте. Идегәй Бәхтиярен бик ярата, минемчә, — гел «җан дустым» дип кенә тора, ә андый чакта кешене ышандыру кыен түгел... Ә! Әйтергә онытам икән:

Бәхтияр бөек падишаһның бүгенге фәрманнарының төп мәгънәсен шундук аңлаган! Нишләп биш әмернең дүртесе — кешеләрне җәзалау турында, ә бишенчесе — кинәт кенә шулар белән янәшә куелып, сиңа дәрәҗә бирә, сере барып җиттеме сиңа, Идегәй, ди. Тегесе көлде генә! Көлде көлүен, тик мин Идегәйнең көлүенә артык игътибар итмәс идем: ул үз фикерен тиз генә ачып сала торганнардан түгел, бугай... Кыскасы, Бәхтияр һәрвакыт аның күңеленә вәсвәсә салып тора һәм торачак!

Гомәр Шәех. Әйтер сүзең беттеме?

Шымчы. Тагын бер нәрсә... Бусы — Акбеләк солтанга карый. Ул — Идегәйгә бөтен серегезне ачып салды, Гомәр әкә! Аңа нәрсәләр кушуыгызны күз алдында тотам мин.

Гомәр Шәех *(кулларын йодрыклый)*. Аңлашылды... Бәхтиярнең ятагын яхшы беләсеңме? *(Шымчы, беләм, дип баш кага.)* Беләсең... бүген төнлә башкар! *(Бәхтиярне юк ит дигән мәгънәдәй, кулы белән хәрәкәт ясый.)*

**45. Идегәй йортында аш бүлмәсе. Иртән.**

**Идегәй белән Акбеләк тәбәнәк өстәл янында идәнгә җәелгән келәмдә утыралар. Хезмәтчеләр өстәлгә төрле ашамлыклар тезәләр.**

Идегәй. Бәхтияргә ни булган бүген? Беренче булып уяна торган кеше!

Акбеләк *(бер җариягә)*. Түрәңә әйт: иртәнге ашка көтәбез.

**Җария «Тыңлыйм, хуҗабикә»,— дип чыгып китә.**

Яуга чыгасыз, дип сөйлиләр, дөресме ул, җаным?

Идегәй. Кем әйтә аны? Тиз түгел әле ул, тынычлан.

Җария *(төсе агарынып килеп керә)*. Анда... Түрәне суеп ташлаганнар!

Идегәй. Нәрсә?! *(Сикереп торып, Бәхтиярнең йокы бүлмәсенә ташлана: юл уңаена диварга элгән кылычын ала.)*

**Акбеләк тә аның артыннан иярә.**

**46. Бәхтиярнең йокы бүлмәсе. Иртән.**

**Идегәй юлында туры килгән ишекләрне тибеп ача-ача Бәхтиярнең йокы бүлмәсенә атылып керә һәм шаккатып кала: чалкан яткан дустының күкрәгендә яртылаш баткан хәнҗәр калкып тора. Идегәй Бәхтияргә килеп тотына: тәне суынып катарга өлгергән инде! Ул кинәт ыңгырашкандай итеп кычкырып куя һәм шашкан күзләре белән тирәягына карана: күзенә ишеккә башын тыккан нөгәрнең битараф йөзе чагыла.**

Идегәй *(аның янына ташлана)*. Син! Төнлә син сакта тордыңмы?!

Сакчы *(каушап)*. Мин... Тик мин бернәрсә дә күрмәдем... Гел шушы ишек катында басып тордым!

Идегәй. Ә син күрергә тиеш идең! *(Кылычы белән аның муенына чаба: нөгәр, кара канга батып, ишек тупсасына аркылы ава.)* Кая башкалары?!

**(Куркуыннан тораташ булып каткан Акбеләкне читкә этеп җибәреп, коридорга ташлана һәм юлында очраган бөтен сакчыларны кылычы белән турарга тотына. Нөгәрләрнең берсе, кылычын суырып чыгарып, Идегәйгә каршы тормакчы була, ләкин бер кызган батырны беркем дә туктатырлык түгел инде — бер-ике селтәнүдә ансын да канга батырып ташлый. Йорт эчендәге сакчылар белән эшне бетергәч, Идегәй тышка ташлана һәм тышкы ишекнең ике ягында басып торган сакчыларның берсен шундук кылычы белән чапкалап ега, әмма икенчесе, бар көченә йөгереп, агачлар арасына кереп кача. Идегәй йортына борылып керә: өйдә кабер тынлыгы урнашкан! Чөнки барлык хезмәтчеләр кайсы кая качып бетәләр. Идегәй кабат Бәхтияр бүлмәсенә керә: Акбеләк аннан куркып артка чигенә һәм бүлмәдән шыпан-шыпан чыгып тая. Идегәй аны күрми дә: үкси-үкси дустының күкрәгенә каплана. Ул шулай берничә минут, бөтен тәне белән калтыранып, тавышсыз гына елый. Менә ул кинәт сикереп тора һәм бүлмәдә булган барлык җиһазларны кылычы белән туракларга тотына, диварларга элеңгән келәмнәрне тартып төшерә. Шулвакыт аның кулына түшәмне чатырсыман итеп капланган ефәк эләгә: Идегәй аны да бар көченә тартып өзеп ташлый һәм шаккатып туктап кала: түшәмдә Бәхтиярнең ятагы турысында, зур тишек каралып тора! Димәк, хәнҗәрне Бәхтиярнең күкрәгенә шуннан томырып кадаганнар! Идегәй, бүлмәдән йөгереп чыгып, чарлакка менә торган җирне эзли, ләкин йорт эчендә андый урын тапмый. Тышка йөгереп чыга һәм йорт тирәсен әйләнә: нәкъ чорма ишеге турында җирдә озын баскыч аунап ята...**

**Ул арада искәрмәгәндә Идегәйнең йорты янына егермеләп баштан-аяк коралланган нөгәрләр йөгереп киләләр һәм хуҗаны уратып алалар. Идегәй берсүзсез канлы кылычын аларга бирә: ул хәзер бар нәрсәгә, хәтта үз язмышына да, битараф күренә. Берничә нөгәр Идегәйнең йортына керә, ә калганнары аның үзен каядыр алып китәләр. Идегәй, башын иеп, алар уртасыннан атлый.**

# 2 — бүлек

**47. Сарай каласы янында такырлык. Көн.**

**Сабантуй. Төрле урыннарда төрле уеннар оештырылган: бер җирдә бил алышу кызган чак, икенче җирдә — бау тартышу, өченче урында күзне бәйләп чүлмәк вату, дүртенче мәйданчыкта — биек шома баганага менеп, әтәч алып төшү, бишенче төркем уртасында — бүрәнәгә атланып, салам тутырылган капчык белән сугышу һәм башка шуның ише сынашулар кызганнан кыза бара. Әмма халыкны иң нык кызыксындырганы — кыз куу уены: егермеләп яшь җайдак алларыннан искиткеч житез атта чабып баручы анадан тума шәп-шәрә бер кызны куып тотарга тырыша. Халык, көлешә-көлешә егетләргә көч-дәрт биреп тора, кемнедер куәтләп янсә мыскыллап кычкыралар, хәтта Туктамыш хан да ханәше Йәникә һәм житүле игезәк кызлары Ханәкә белән Көнәкә, баш вәзир Киң Җанбай, хан яраннары, бик күп әмирләр**

**һәм төрле түрәләр дә жанланып кыз куунын ни белән бетәсен көтәләр.**

**Халык төркеме арасында кавырсыннары ката башлаган берничә таза егет үзара кычкырып сөйләшә: аларның кәефләре бик күтәренке, булса кирәк.**

Бер егет *(комарланып)*. Әйдә, Норадын дус, без дә кыз кууда катнашабыз! Әйбәт булыр иде, ә?

Икенчесе *(көлә)*. Әйбәт кенә түгел — «кырык бер» булыр иде ул. Тик кыз кууда катнашыр өчен Норадын дуска башта аргамак сатып алырга кирәк әле! Сатып алыр иде — алтыны юк. Алтыннары булыр иде — кесәләре тишек!

Өченчесе *(ул да көлеп кушыла)*. Норадынның атасы Идегәй, Аксак Тимернең бөтен атларын урлап алып кайтачакмын, дип ант эчкән, имеш! Аннан соң Норадыныбыз хан кызларын күмәртәсе белән үзенеке итәчәк тә итәчәк инде!

**Шулвакыт бар халык берьюлы «Һа!» дип кычкырып җибәрә: кыз куучыларның берсе аның атының тезгененнән эләктерә.**

**Бәхетле егет, атларын туктатмыйча, ары чабуны дәвам итә, җиләнен кызның җилкәсенә сала һәм аркасыннан кочаклый. Егет белән кыз тиздән әрәмәлеккә кереп югалалар. Бүтән егетләр атларын кирегә боралар: барысы да башларын түбән игәннәр. Халык арасында көлешү тына, бары тик кемдер аларны мыскыл итеп сызгыра башлый: аны, авызына сугып, туктаталар — уңышка ирешә алмаган егетләргә болай да бик авыр бит.**

Дүртенчесе. Егетләр! Кыз куугa катнашырга теләүче булса — уңайлы чак: хәзер икенче төркем җыела! *(Көлешәләр.)*

Беренчесе. Йә, Норадын дус: сүзеңне әйт! Ник авызыңны ершайттың? *(Көлешәләр.)*

Норадын *(кырыс)*. Саруны кайнатып, чыркылдашмагыз әле, койрыксыз чыпчыклар. Телдә — барыгыз да йөгерек акыллылар. Кыз кууда, беләсезме, мин кайчан катнашачакмын?

Беренчесе. Кайчан?

Норадын. Алдымда әнә теге куш игезәкнең берсе чапса.

Егетләр *(чын күңелдән гаҗәпләнеп)*. Хан кызлары?!

Норадын. Әйе, Ханәкә белән Көнәкә солтаннар катнашса гына! *(Ул бу сүзләрен бик каты кычкырып әйтә: хәтта кызлар үзләре дә ишетәләр һәм аңа таба борылып карыйлар. Норадын кызларга күз кыса: Йәникә моны күреп кала һәм йөзен чыта.)* Менә күрерсез, егетләр, бердәнбер көнне Ханәкәсе — минем җылы куенда булачак! Аты юк, имеш... Атың корымасын да башың сау булсын — дүрт аяклы ат табылыр! Кызык бетте монда, егетләр: чибәр кызларга өлгер хуҗалар табылды — кайтышракларын Туктамыш хан күзләсен! *(Читкә китә: дуслары аңа иярәләр.)*

**48. Сарай каласында Идегәйнең йорты. Кич.**

**Элекке мул тормышлы йортның соңгы чиккә җитеп бөлгенлеге күренеп тора: җиһазлар юк диярлек. Олыгая төшкән йөзле Айтулы, учакка кипкән тизәк салып, ут тергезеп маташа.**

Айтулы *(моңлана)*.

Син калдырдың мине кемнәргә?
Калдырдың ла авыр көннәргә.
Бу хәлемә ничек күнәргә,
Күнәргә...
Күзләремә ачы яшь тула.
Син исәндер кебек өнемдә.
Син исәндер кебек төшемдә.
Ятагымда синсез өшим лә,
Өшим лә...
Күзләремә ачы яшь тула.

**Урамнан Норадын кайта һәм, әнисенең моңсу тавышын ишетеп, өйгә керергә кыймыйча, ишек төбендә басып тыңлап тора.**

Сөенергә иде, әй миңа,
Карап кына җиткән углыма.
Кайтырмы дип әткән, сорыйм ла,
Сорыйм ла...
Күзләремә ачы яшь тула.
Кергән кебек кайгы күлемә,
Керәм төнгә, керәм көнемә.
Ялгыз камышлардай бөгеләм,
Бөгеләм...
Күзләремә ачы яшь тула. *(Тына.)*

Норадын *(өйгә атылып килеп керә)*. Өйләндер мине, Айтулы әни! Учак кайгысын килененә тапшыр, оның кайгысын үзенә ал!

Айтулы *(дертләп китә һәм көлә башлый)*. Һай, куркыттың, берләч балам! Колак артында шулай кинәт кычкырмыйлар инде... Нәрсә дидең — аңышмый калдым?

Норадын. Киләш алып кайт миңа дим, әни!

Айтулы *(шаккатып)*. Ә?! *(Улының шаяртуын аңлап көлә.)* Әй, балам, балам... Киләшеңне кайда йоклатырсың соң? Яткырыр урын, астына җәяр әйберебез дә юк ич безнең! Башыгыз астына менә шушы кипкән бәлешне салып, астыгызга — толымы кырык тотам булса — чәчен таратып йокласагыз гына инде...

Норадын. Бүген үк апкайт димим ич мин, Айтулы әни!

Айтулы *(елмая)*. Шулай дип котыл, улым. Кайчанрак апкайтыйм соң?

Норадын. Мин балигъ булган көнне иртүк! Күктәге ай тагын икс тапкыр үлеп, яңадан туугa — мин балигъ булачакмын! Урын-җир өчен кайгырма, әни: шушы зал уртасында хуш исле печәннән куыш ясап куячакмын. *(Елмая.)*

Айтулы *(ул да елмая)*. Алай икән... Минем башка ничек килмәгән бу? Тик, улым, тагын бер нәрсә бар бит әле... Оныгым туса — аны тәрбияләр өчен аталык, онықам туса — аналык ялларга кирәк булачак. Аларга түләргә акчасын ничек юнәтербез икән?

Норадын. Аңсы өчен кайгырма, Айтулы әни: беренчесен син үзең тәрбияләрсең, ә калганнары — үзләре бер-берсен карый башлаячаклар!

**Икәүләп рәхәтләнеп көләләр.**

Айтулы. Бар ягын да уйлап куйгансың икән, балам! Күзең төшкән кызың бармы соң? Мин сайлаган синең күңеленә ятмаса, нишләрбез?

Норадын. Бар, Айтулы әни! *(Җитди тәс алып.)* Аксак Тимер янына качып киткәндә Тукатмыш хан әтигә, балигъ булгач та, куш игезәкләрен бирергә вәгъдә иткән, имеш, дип сөйләгән идең син миңа. Әти качакта йөри һаман, аның каравы — мин монда: әтисенә әйткән әманәтен улына бирер, бәлки... Бирмәсә — карга авызын ачар, лачын алып качар, ди! Мин — Ханәкәне сайлар идем! *(Елмая.)*

Айтулы *(улының шаярудан туктап, күңел төбендәгесен ачып салганлыгын аңлап.)* Буебыз җитмәстәй агач сайлагансың, балам: оныт. *(Сүзе беткәнне аңлатып, үз эшенә тотына.)*

Норадын *(ужәтлек белән һәм катгый).* Әтинең буе җитмәгән — минеке җитәчәк, әни! Морадыма ирешмәсәм, атым Норадын булмасын!

**49. «Алтын Таш» хан сарае. Иртә.**

Йәникә. Башимәс Болгар белән Суарны бастырырга тагын яу әзлисең икән, шундый имеш хәбәр таралган, ханиям, озак юлга чыкканчы, йортыңда бер эшне хәл кылып китсәң иде.

Тукатмыш *(кырку).* Йорт кайгысын йорт биенә тапшыр, ханәшем, мәшәкатьләрем болай да муеннан ашкан.

Йәникә. Йорт биенең зиһене җитәрлек эш булса, сиңа әйтеп тә тормас идем, ханиям!

Тукатмыш. Аңлат.

Йәникә. Карсак нәселе Идегәй Сәмаркандта Аксак Тимердә безгә каршы теш кайрап ята...

Тукатмыш *(бүлдерә).* Борчылма: Карсак белән Аксак дигән ике затсыздан бер затлы адәм чыкмас! Бергә кушылып, яу килсәләр — тәнемдә аккан канымда Чыңгыз бабамнан калган дәртем, байрагым астында туксан тугыз йортымнан җыелган куәтем бар!

Йәникә. Миндә алар кайгысы түгел, ханиям! Күз алдыбызда шул карсакның көчеге үсә. Сабантуйда кылыгын күреп исакылларым китте. Үзен хан нәселенә тиңли, ахры, кызларыбызга күз ата башлаган! Туктамыш ханнан бабам белән казак киткән әтиемнең үчен кайтармый калмам, дип шапырына, имеш. Атасы белән бабасы астыртыннар иде, бусы алардан да арттырырга чамалый, күрәсең! Шуның язмышын хәл итеп кит!

**50. Хан сараенда бер бүлмә. Иртә.**

Җанбай. Чакырткансың икән, бөек каганым.

Тукатмыш. Киңәшең бир, баш вәзирем Җанбай би. Котлыкыя бинең башын ора чаптырганда бишектәге баласы исән калып, башыбызга бер бәла алдык. Инде хәзер Идегәй дигән карсакның углы Норадын бәлигъ булды. Бүгенге — көчек көне иде, иртәгәсе — игәр давына әйләнмәсме! Кара халык — эт халык. Норадынга кул салсам — шул этләр өере дау күтәрер, дип куркам.

Җанбай. Сүзең хак, бөек каган. Ләкин кара халык — эт өере булса да, безгә куркыныч түгел, эт өрер — бүре йөрер! Идегәй давы куркыныч! Норадынга кул салмыйк. Тик монда калдырырга да киңәш итмәс идем. Җабага тайга атландырып, атасы янына җибәрик: исән калса — үз бәхете, юлда башын салса — әҗәлен синнән күрмәсләр. Бүген сиңа тугры булып кыланып, иртәгә — аркаларын күрсәтергә әзер торган кайбер икейөзле әмирләрең бар. Норадынны ерак юлга шулардан әзерләтик, бөек каган,— куллары сиңа ныграк бәйләнсен! Идегәй яу килә калса — аңа сыена алмаслар.

Тукатмыш. Киңәшеңне кабул иттем, баш вәзирем Җанбай би.

**Киң Җанбай, хан алдында йөгенеп, чыгып китә.**

Тукатмыш *(битекчегә).* Ярлык әзерлә! Диван бие Байназар белән ханкош бие Кушназар Норадынга кием-салым әзерли. Дөрмән би белән Алман би корал бирә. Янгура би белән Илтәрәс би аргамак сайлап китерә. Кәрим би белән Гомәр би дирбия таба. Мин әйттем.

**51. Идегәйнең Сарайдагы йорты. Кич.**

**Йорт янына жабага атка атланган Норадын якынлаша: балачагалар аның артыннан мыскыл итеп кәлә-кәлә ияра килә әниләр. Норадын, атыннан төшеп, бала-чагаларны куып җибәрә. Тавышка өйдән аның әнисе Айтулы чыга һәм исе китеп катып кала: Норадынның өстендә ямаулы иске тун, билендә кынысыз тутык кылыч, аты менә-менә егылып үләм дип тора кебек, дирбиясе — киндерәдән, ияре каралып тишелеп беткән киездән!**

Айтулы *(вай-вайлап).* Әнекәем! Туктамыш хан шушы тайны бирер өчен чакыртканмыни сине, Норадын улым?! Битенә тәкерергә иде! Ник алдың?!

Норадын *(исе китмичә).* Җабага тайны хурлама — язга чыкса ат булыр, Айтулы әни! Аның каравы — мин әти янына барам: Гайсә киткән җиргә түгел ич! Кояш Иделгә төшеп чумганчы, кала капкасыннан чыгып, гаип булырга тиешмен. Туктамыш ханның фәрманы шундый!

Айтулы. Төнгә каршымы, юләр гәүдә?!

Норадын. Кайгырма, әни: кара төн ул — байларга гына куркыныч дошман, минем кебек ярлыга иң якын дус! *(Атының сыртына салынган ике капчыкның берсен чишеп, әнисе алдына куя.)* Киң Җанбайны мәңге яратмый идем — бердәнбер ул миһербанлы кеше булып чыкты: шыплап тутырылган ике капчык азык-төлек җибәргән миңа. Берсен сиңа калдырам, бер башыма күп кирәкме минем? Укларым белән җәямне чыгарчы, Айтулы әни. Әтигә бүләк-санак булмады, дип кайгырма: ярты дөнья байлыгын талаган патшада яшь. Әтигә җиткерәсе сүзләрең булса, колагыма әйт тә — Сәмаркандка карап теркелди башлармын. Аллага тапшырып. Баш сау булса, вакытсыз үлмәбез әле!

**52. Сәмаркандта Идегәйнең йорты. Иртән.**

**Идегәйнең йортын таныйрлык түгел: диварларны каплап торган чаршаулар, ефәк чатырсыман нәрсәләр алып ташланган —**

**бүлмәләрдә җиһазлар гына калган. Түшәмнәрдә, диварларда булган тишекләр томаланган. Йорт эчендә элекке кебек кизү торган нөгәрләр дә күренми: тышкы ишек янына гына ике шыгавыл баскан.**

**Идегәйнең йорты янына берничә нөгәре белән бергә Тимер Котлый хан килеп туктый.**

Бер нөгәр *(шыгавылларга)*. Туран солтаны Шаһ Тимернең кунагы Тимер Котлый хан төмәнбашы Идегәй баһадирны күрергә тели!

**Шыгавылларның берсе йортка кереп китә һәм шундук кире әйләнеп чыга.**

Шыгавыл. Идегәй баһадир Тимер Котлый ханны көтә. Нөгәрләр монда кала!

Идегәй *(үзе ишектә күренә)*. Әйдүк, хуш киләсең, хан: дусларым өчен минем йортның ишеге һәрвакыт ачык! *(Кулын күкрәгенә куеп, хөрмәт белән баш ия.)* Сине исән-имин күрүемә бик шатмын. Сәламәтлегең ничек, Тимер Котлый хан: хасталап торасың, дип ишеткән идем?

Тимер Котлый *(бер нөгәр аңа чугәләп аркасын куя: ул, аның аркасына басып, атыннан төшә)*. Аллага шөкер, хөрмәтле агам Идегәй баһадир. *(Ул да кулын күкрәгенә куеп, Идегәйгә баш ия.)* Яудан дан-шөһрәт белән кайтып кереп, баһадир исеме алуыңны ишеткәч, бик куандым!

Идегәй *(тыйнаклык белән)*. Һәр яугирнең бурычы — үзен орышта сынатмау, Тимер Котлый хан... Йортка рәхим ит. *(Ханга юл бирә, аның артыннан кереп китә.)*

**53. Өйдә. Шул ук вакыт.**

**Тимер Котлый хан белән Идегәй эчке бүлмәләрнең берсенә үтәләр. Идегәй кунакка урын күрсәтә: икесе дә артсыз утыргычларга урнашалар. Идегәй ишектә күренгән хезмәтчесенә ишарә ясый: кунак алдына шундук сусын белән кальян, алтын савыт белән җиләк-җимеш китереп куялар.**

Идегәй. Җитеш, хан. *(Кайсын телисең, үзең сайла дигәндәй, кулы белән сыйларына күрсәтә. Үзе, аңсыз рәвештә, булса кирәк, кесәсеннән сәер формалы кечкенә сөяк алып, кулында әйләндергәләп утыра: Бәхтиярдән калган борынгы ыру тамгасы ул.)*

Тимер Котлый *(сусынны кулына ала)*. Сөекле җиңгәм Акбеләк солтан саусәламәтме, агам?

Идегәй. Тәңребезгә үпкәбез юк, Тимер Котлый хан. *(Ханга сиздерми генә күлемсерәп куя: ханны бөтенләй бүтән нәрсә хафага төшергәнен белә ул.)*

Тимер Котлый *(ул үзен бераз уңайсыз тота)*. Тегә вакытта... Бәхтияр дустыбызның фаҗигале вафатын күз алдымда тотам... синең язмышың өчен бик нык борчылдык, агам. Аллаһе тәгалә гомерен озын итсен, падишаһ Шаһ Тимер гадел хөкем йөртте. Нишлисең бит, Бәхтиярнең тәкъдиренә шулай язылган булгандыр инде. Бик әйбәт егет иде. Монда беркемнән дә шикләнмичә сөйләшергә ярыйдыр?

Идегәй. Соңгы сүзең бик серле тоела миңа, хан.

Тимер Котлый. Дөресен әйтим, шөһрәтле агам: актыккы мәртәбә күрешүебездән канәгать түгел мин. Әлегә кадәр җанны нидер тырный... Гаепнең юан башы минем үземдәдер, бәлки?

Идегәй. Үткән эшкә салават, хан.

Тимер Котлый. Шулай да... Никтер һаман борчып тора ул мине. Арабыздан кара мәче узган кебек, дип әйтимме...

Идегәй. Куйчы, хан. Якын туганнар арасында ни булмас?

Тимер Котлый. Алаен алай... Туган туфрагыбыздан бик алыс яшибез. Юлга чыкканда шактый күп идек — синең белән икәү генә калдык, дияргә була. Бер-беребезгә ышанычлы терәк булсак иде, хөрмәтле агам! Ничек карыйсың?

Идегәй *(илтифатсыз гына сораган була)*. Сүз җаеннан, әтиеңнең бертуган энесе Коерчак солтан Шаһ Тимердән сыеныч сораган, имеш, хак сүзме ул, Тимер Котлый хан?

Тимер Котлый. Чынлапмы? Мин ишетмәдем, агам. *(Идегәйдән күзен яшерә.)*

Идегәй *(Тимер Котлыйның кызарынуына игътибар итә)*. Хәер, ул үзе сиңа сугылыр: якын энекәшен сагынгандыр.

Тимер Котлый. Үз агам булса да, турысын әйтим, төпле кешегә саный алмыйм мин аны!

Идегәй. Миңа ничек?

Тимер Котлый. Ныклы кыйбласын күрмим... Юк, аны белергә дә теләмим, дип өздереп әйтмим мин. Тик... Ир кешенең бер житди максаты булырга тиештер. Миңа синең белән уртак сүз табу җиңел миңа, Идегәй агам!

Идегәй *(серле итеп)*. Берәр төрле астыртын максат китермәде микән аны Шаһ Тимер янына?

Тимер Котлый *(кузгала)*. Кичер агам, синең әле генә хәвеф-хәтәрле зур яудан йончып кайтып төшкәнеңне онытып җибәргәнмен. Хәлеңне беләсем генә килгән иде — хәзер күңелем тыныч.

Идегәй *(ул да тора)*. Бераз утырыр идең, хан?

Тимер Котлый. Икенче вакытта, агам. Акбеләк җиңгәмә миннән сәлам тапшыр, зинһар: үземнең борчыйсым килми.

Идегәй. Тапшырырмын, хан. *(Тимер Котлыйны озатып керә һәм кычкырып кола.)* Күмәче көлгә төшкән моның!

Акбеләк *(ишектә күренә: иренең ялгызы гына шаркылдап көлеп торуына гаҗәпләнеп)*. Нинди кызык күрдең, җаным?

Идегәй *(хатынына таба борыла)*. Бер малай астына шыр җибәргән дә... Мине ахмакка саный, ахры, ыштан төбемә берни булмады, дип ышандырырга маташа! Әле генә шуны озатып кердем.

Акбеләк. Нинди малай?

Идегәй *(кола)*. Киләчәктә уртак арбага җигеләчәк атларның берсе. Ә икенчесе — синең ирең булыр.

Акбеләк. Ә дилбегәсе кемдә булачак?

Идегәй. Оһо! Алны-артны уйлап сөйләшергә кирәк икән синең белән! Атаң кызы, ахры, син!

Акбеләк. Ә мин берни аңламадым! *(Кола.)*

Идегәй *(хатынын кочаклый)*. Күп аңлау хатын-кызга зыян гына ул, былбылым! Син менә нәрсәне аңламыйсың һаман: малай бүләк ит син миңа! Малай — ата кешенең ышыгы ул!

Акбеләк *(Идегәйнең кулындагы сәяккә күрсәтеп)*. Кулыңда нәрсә ул?

Идегәй *(шунда гына үз кулына карый)*. Картлык галәмәте! Миңа кырык тулып килә бит инде... Яшең җитсә кырыкка, акылың китәр шырыкка, диләрме әле? *(Кулгән булып, тамганы, хатынына күрсәтми генә, кесәсенә сала.)* Син минем сүзгә җавап бирмәдең, былбылым?

Шыгавыл *(керә)*. Кичер, Идегәй, баһадир, сүзегезне бүлдерәм: Сарай хәерчесе сине сорый.

Идегәй *(ризасызлык белән)*. Куып җибәр! Тукта — бир үзенә... *(Кесәсеннән көмеш акча алып, идәнгә ташлый.)*

Шыгавыл. Алтын Урдадан килдем, ди ул.

Идегәй. Алтын Урдадан! *(Урамга ташлана.)*

**54. Йорт алды. Шул ук вакыт.**

**Идегәйнең йорты каршында йончыган кыяфәтле Норадын тора. Аты да үзе кебек үк йончу. Ишек төбе саклаучы шыгавыл аны мыскыллы караш белән күзәтә. Идегәй чыга һәм йолкышка йотылып карый: ул малаен танымый.**

Идегәй. Кем син?

Норадын *(елмая)*. Чит җирләрдә шулай бик озак качып йөрмиләр аны, Идегәй баһадир! Үз каныңны танымый башлагансың.

Идегәй. Норадын улым, синме бу! *(Улы янына баскычтан йөгереп төшә.)*

**55. Оазис. Кичке як.**

**Яшеллеккә — суга бай җир буйлап, атларын лүрт-лүрт юрттырып, ике җайдак бара: берсе Идегәй, икенчесе — үзенә бик ятышлы һәм затлы кием киенгән, шәп аргамакка атланган Норадын. Йөз илле-ике йөз адымнар артка каларак аларга бертөркем җайдак ияргән: алар, парлашып-парлашып, аякларыннан киртәләргә бәйләнгән җәйрәннәр күтәргәннәр. Ау бик уңышлы булганга охшый.**

**Идегәй улы янында булуга шатланып туя алмый: аның һәр хәрәкәте, һәр ымы шуны күрсәтә. Норадын да бик шат, әмма ул әтисе белән күпмедер дәрәҗәдә кинаяле сөйләшә: бу — аның үз әтисенә иялəшеп бетә алмавыннан да килә, булса кирәк.**

Идегәй *(кинәт атының башын бора һәм күз ачып йомган арада улы тирәсен урап чыга)*. Күземә генә күренмисең, микән, дип кинәт шикләнеп куйдым, Норадын углым. *(Кола.)*

Норадын. Әллә шаманга әйләнә башлагансың инде, әти? *(Кола.)*

Идегәй. Башлы-күзле булып, үз малаең тугач, минем хәлне аңлый башларсың әле, улым!

Норадын. Ә мин, өйләнсәм, хатынымны беркайчан да ташлап калдырып йөрмәячәкмен, Идегәй әти: кайберәүләрнеке кебек, минем башта җил уйнамый. *(Елмая.)*

Идегәй *(җитди)*. Адәм булып җил йөртми, ил йөртә, улым. *(Сүзне икенчегә бора.)* Күз аткан берәр чәчбиең бармы соң?

Норадын. Ә син үзең ничек уйлыйсың?

Идегәй *(елмая)*. Бардыр, дим. Миңа охшап туган булсаң.

Норадын. Мин дә шулай уйлыйм, әти! Тик әлегә кем икәнлеген син сорашма, мин — әйтмим. Икәү генә чакта иркенләп ачыктан-ачык аңлашыйк, Идегәй баһадир.

Идегәй *(аңа улының исеме белән дәшүе дә ошый)*. Аңлашыйк соң, кабәм.

Норадын. Гидай булып, мескенлектә күпме йөрергә чамалыйсың, Идегәй баһадир? Бу якларны минем күңел бер дә йөкләми.

Идегәй. Әйтеп бетер, улым. *(Йөзе караңгылана: ул мондый сорауны көтмәгән.)*

Норадын. Кеше икмәгендә яшәү гарьләндермиме сине? Өстеңдәге киемең — кешенеке. Астыңдагы атың — кешенеке. Торган йортың — кешенеке. Хәзер үзең дә, бәлки кешенекедер? Хәер, ник сорап торам: Шаһ Тимернең уяу күзе Акбеләк солтан бар ич өеңдә!

Идегәй *(улының каты бәгырьле сүзе кәефен кыра)*. Әйтеп бетер, дидем.

Норадын *(кыза төшеп)*. Идел-Йортка бүген — синең атаңның, минем бабамның башын чаптырган мүкләк хуҗа! Сине бердәнбер улыңнан һәм сөйгән хатыныңнан аерган шакал хуҗа! Улыңны, әмирләреңнән мыскыл иттереп, кара төнгә каршы кала капкасыннан эт өстерә-өстерә, япа-ялгызын соры бүреләр арасына куган мәрхәмәтсез ишәк хуҗа! Болгар туганнарың аның тимер дагалы күн итеге астында зар-интизар ыңгыраша! Нугай кардәшләреңнең аркасында аның аяусыз камчысы уйный! Кырым ырудашларыңның, аның өчен тоз чыгарып, бозык күлләрендә сөякләре чери! Син качып киткәндә сөлек кебек сылу гәүдәле булып калган Айтулың, вакытсыз ялгыз картаеп, әлек елкылдап торган кырык тотамлы толымына төшкән кырауны кеше күзеннән ничек яшерергә белми! Тагын бераз зимлимме, Идегәй баһадир?!

Идегәй *(кырыс)*. Зимләмә! Бузаң болай да әрем кебек ачы... Морадыңны әйт, улым!

Норадын. Менә — Шаһ Тимер сиңа үзенең киеккә бай оазисында рәхәтләнеп ауда йөрергә рөхсәт иткән — бик әйбәт. Сиңа, гаскәрен ышанып тапшырып, дан-шөһрәт казанырга мөмкинлек биргән һәм син баһадир дигән ат казангансың — мин горурланам синең белән! Ләкин һич аңлый алмыйм мин сине: туган туфрак бер дә тартмыймыни сине?! Монда килгәндә авыр юлда миңа күп кенә әмирләр очрады: синең улың икәнлегемне белгәч, алар миңа затлы тун, шәп аргамак һәм озата баручылар бирмәкче булдылар — мин берсенә дә ризалашмадым. Туктамыш ханның улыңны ничек мәсхәрәләп җибәрүен сиңа күрсәтәсем килде! Күрдең — кәефең кырылды. Хәзер — минем кәефем кырыла: кара дошманыбыздан уч алырга әзерләнүеңне күрмәдем! Күк Урда әмирләре минем мыскка чорнап җибәрделәр: Идегәй батыр кайтсын, без аңа гаскәр-

ләребезне дә, үзебезне дә тапшырырга әзер, Туктамышның өнен туздырыйк, диделәр. Кайтыйк, Идегәй баһадир: җәйрән атып йөргән үткен укларыңны явыз дошманыбызга атыйк! Тутыга башлаган кылычларыңны кайрыйк! Морадым шул, минем әти.

Идегәй *(улын кочаклап, маңгаеннан үбә)*. Менә хәзер — таныдым мин сине, углым! *(Кесәсеннән алып, борынгы ыру тамгасын улына тапшыра.)* Изге әманәт бу, Нурадын углым: югалтма, күз караң кебек сакла! *(Атын чаптырып китә.)*

**56. Туран ханы Солтан Мәхмүт сарае. Иртән.**

**Шаһ Тимер искиткеч матур эшләнгән тәхет пулатында үзенең улы Гомәр Шәех һәм шагыйрь Әхмәт Кирмәни белән көлешеп утыра. Тәхет буш: «курчак хан» Солтан Мәхмүт кермәгән әле.**

Шыгавыл *(ишектә күренә)*. Идегәй баһадир!

Тимер. Керсен.

Идегәй *(үз-үзенә нык ышанган адымнар белән килеп керә һәм уң кулын күкрәгенә куеп, иелә)*. Тәңребез сиңа озын гомер бирсен, бөек солтаным. *(Бүтәннәргә дә тыйнак кына баш ия, ләкин бер сүз дә әйтми.)*

Тимер. Гозерең нинди икәнен беләбез, Идегәй баһадир. Утырып тор: соңгы сүз — Солтан Мәхмәт хан авызында. Хәзер килеп керергә тиеш. *(Идегәйгә бер утыргычка утырырга ишарә ясый.)*

Идегәй *(Шаһ Тимернең үзен гади тотуына бик нык гаҗәпләнә)*. Рәхмәт, бөек солтаным. *(Утыра.)*

Тимер *(кәефе бик яхшы күренә, бүленгән сүзен дәвам иткән төсле)*. Дөрес әйттең, чөнки Әхмәт Кирмәни: һәркемнең үз бәясе була... Колның үз бәясе, кунакның — үз бәясе... Ә менә син миңа турысын гына әйт әле: әгәр дә, мисал өчен, мине, Шаһ Тимерне, коллар базарына илтеп сатсалар, күпмегә бәяләр идең?

Әхмәт Кирмәни. 25 алтын.

Тимер *(чын күңелдән гаҗәпләнеп)*. Егерме биш алтын!

Әхмәт Кирмәни. Мин бил каешыңны күз алдында тотам, Шаһ Тимер. Үзең син сукыр бер тиен дә тормыйсың.

**Шаһ Тимер бертын күзләрен шакмакландырып тора да кычкырып көлеп җибәрә: шагыйрь үзе дә аңа кушылып көлә. Идегәй бу сәер сөйләшүне ничек аңларга да белми: бөек илбасарның мондый чагын күргәне юк аның.**

Тимер *(бераз һаваланып)*. Уеңда ни барлыгын каян белүемне ник сорамыйсың, Идегәй баһадир?

Идегәй *(дәрәҗә саклап)*. Хакимнең бөеклеге — мәмләкәтендә кем ничек сулаганын белеп торудадыр, дип исәплим мин, бөек солтан.

Тимер. Киресенчә, Идегәй баһадир: мәмләкәтендә кем ничек сулаганын белеп торган кеше генә бөек хаким була ала.

Идегәй. Аерманы төшендем, бөек солтан. *(Елмая.)*

Тимер. Кызыбызны сагындык: бүген кичкә чатырыма рәхим итегез. Нурадын улыңны да калдырма.

Идегәй *(бераз гаҗәпләнә)*. Улымның миндә кунакта икәнлеген сиңа бүген әйтермен, дип тора идем.

**Шаһ Тимер әкрен генә көлеп куя.**

Гомәр Шәех. Улыңның Сәмәркандка киләсен без ул Сарай каласыннан чыкканчы ук белә идек, кияү.

**Шаһ Тимер улына күз койрыгы аша усал караш ташлый: аңсы шундук, артыгын ычкындыруын аңлап, телен аркылы тешли. Авыр тынлык урнаша.**

Тимер. Гаскәри кешенең шунсы начар, кияү: үз балаларына тиешле тәрбия бирергә вакыты калмый.

**Ишек артында кинәт: «Бөек Туран ханы Солтан Мәхмүт!» — дигән кычкырулар кабатлана. Идегәй Шаһ Тимернең йөзендә мыскыллы елмаюга охшаш нәрсә күреп ала.**

Идегәй *(тавышы кадрлар артында)*. Чынлап та... Солтан Мәхмүт бу сәрәннең үзен түбәнсеткәнен тоймый микәнни? «Туран хакиме бөек Солтан Мәхмүт хан!» дип кычкырырга тиешләр ич. Шушы карт төлке болай игълан итәргә боергандыр инде...

Тимер *(Идегәйгә карап)*. Хан исемен дә дөрес хәбәр итә белмиләр, наданнар.

Идегәй *(дертләп китә: тавышы кадрлар артында)*. Кешенең ни уйлаганын да укып бара, ахры, бу!.. *(Шаһ Тимергә.)* Бәлки... ялгышмыйлардыр алар, бөек солтан?

**Шаһ Тимер үзалдына елмая.**

**Ике яклы зур ишек ачылып китә һәм Солтан Мәхмүт хан хансарай аксөякләрен ияртеп килеп керә: ул чагыштырмача бик яшь күренә. Тәхет залында утыручыларның Шаһ Тимердән башкалары, хөрмәт йөзеннән, торып басалар һәм, башларын иеп, аның тәхеткә утырганын көтеп торалар. Солтан Мәхмүт хан, тәхетенә утыргач, нәрсәгә җыелдыгыз монда дигәндәй, залга карап куя.**

Тимер. Ходай тәгалә иминлек бирсен сиңа, Солтан Мәхмүт хан. Синең кадерле вакытыңны алып, борчуыбызның сәбәбе — Алтын Урда ханы Туктамышның элекке уң кулы, хәзерге көндә синең гаскәреңнең төмәнбашы Идегәй баһадирның гозере.

**Солтан Мәхмүт хан, кайсыгыз ул Идегәй дип, сорау белән карый. Идегәй, аяк өсте торып, ханга баш ия: каш астыннан гына Шаһ Тимергә карап ала һәм, аның бүтән сүз өстәргә уйламаганын сизеп, тураеп баса.**

Солтан Мәхмүт. Тыңлыйбыз сине... э...

Идегәй. Идегәй би, бөек хан.

Хан *(бөек дип дәшкәнгә канәгать була)*. Тыңлыйбыз сине, Идегәй би.

Идегәй. Бөек хан! Сүземне кыска тотам. Синең илгә үз илемдә гаделлек тапмаганга килдем. Үз туруннең данын читтә

сату ир-ат эше түгел. Әмма һәрнәрсәнең бер азагы була: Туктамыш ханның мәкерлеге чиктән ашты: күп ханнарның, тәхетләрен тартып алып, башларын нахакка кыйды, исән калганнары читтә каңгырып йөрергә мәҗбүр. Ул ханнар барысы да — бөек Чыңгыз варислары иде. Туктамыш хан хәзер синең мәмләкәтеңә турыдан-туры яу килмәкче. Аның мәкерләренә чик куярга чакырырга җөрьәт итәм. Мин үзем ошбу гадел орыштa гап-гади укчы булып катнашырга да әзер! *(Сүзе бетүне аңлатып, баш ия һәм урынына утыра.)*

**Тынлык урнаша. Утырышта катнашучылар Солтан Мәхмүт ханга карыйлар: ул Шаһ Тимергә сорау белән текәлә.**

Тимер *(юри бераз көттереп).* Карарыбызны гозерчегә җиткерик, Солтан Мәхмүт хан?

Хан *(беренче мәртәбә ишетүе йөзенә чыга).* Э...

Тимер. Әйе. Кичә кабул иткән карарыбызны. Без синең гозереңне канәгатьләндерергә булдык, Идегәй баһадир. Туктамыш хан өстенә яу чыгабыз. Якын кардәшләребезне авыр хәлдә ярдәмсез калдыру килешмәс.

Хан *(берни аңламаса да).* Әйе... Әйе...

Тимер. Идегәй баһадир!

**Идегәй торып баса.**

Тимер. Сине, зур тәҗрибәңне истә тотып, Солтан Мәхмүт хан үзәк маңгайга сәргаскәр итеп билгели.

**Идегәй күкрәгенә кулын куеп баш ия: ул шат.**

Тимер. Уң канатны Ир Каплан әмир җитәкли. Сул канатны — Күк Урданың элекке ханы Ырысның углы Коерчак солтанга тапшырабыз. *(Елмая.)* Солтан Мәхмүт хан белән мин үзем, гадәттәгечә, үзәктә булабыз. Яуга — 200 мең яугир катнашачак.

Хан *(нидер әйтмәкче була).* Э...

Тимер. Сәмәркандыбызның язмышы өчен борчылма, Солтан Мәхмүт хан: кече углым Шаһ Рәйх монда иминлек саклауны үз өстенә алырга ризалыгын бирде.

**Шаһ Тимернең икенче улы Гомәр Шәех әтисенә шаккатып карап тора: ул вазифаны башта аңа вәгъдә иткән, күрәсең.**

Хан. Э — э... Аңа ялгызына авыр булмасмы, Шаһ Тимер?

Тимер. Күтәрер. Башына бүрек кигән.

**Тыйнак кына көлешәләр.**

Хан *(аңа чигенер юл калмый).* Килештек, Шаһ Тимер.

Тимер *(елмая).* Ә елъязмачы чичәнең Әхмәт Кирмәни, хан, синең тарихи җиңүләреңне җентекләп теркәп барачак.

**Шагыйрь Әхмәт Кирмәни торып, ханга баш ия.**

Хан. Э... Кайчан...

Тимер. Искә төшерүең өчен рәхмәт, хан: яуга кыш кузгалабыз. Мин, урау булса да, Корган Түбәне кичеп, Урал тауларының көньяк итәге аша Җаекка таба юнәлергә тәкъдим итәм: чөнки без анда ау өчен киек тә, атларыбыз тукланырлык җирләр дә җитәрлек табачакбыз. Идегәй баһадир яхшы белә: Сәмәрканд белән Сарай каласы арасындагы туры юл күбрәк сусыз-үләнсез ком чүленнән гыйбарәт. Аннан соң... Туктамышның да безне туры юлда сагалап ятуы бар. Солтан Мәхмүт хан минем тәкъдимне хуплар, дип уйлыйм?

Хан *(үзенә мөрәҗәгать итүен көтмәгән).* Э... Әйе-әйе.

Тимер. Хуп. Мин әйттем. Монда ишетелгәннәр монда калырга тиешлеген берегезне дә кисәтәсе юктыр? *(Барысына да кырыс караш ташлый.)*

**57. Сәмәрканд капкасы. Таң тишелеп килгән чак.**

**Кала капкасы ачыла һәм атлы гаскәр чыга башлый: барысы да күгелҗем киемнән, сөңге, кылыч, хәнҗәр, гөрзи, садак тулы ук һәм мөгездән эшләнгән авыр җәя, озынча калканга өстәп, иярләренә элмәкле корык, озын аркан һәм күн капчык бәйләгәннәр. Көбә күлмәк өстеннән, җиңсез кыска тун кигәннәр: кыш салкын — атларның борыннарыннан куе пар бөркелә, бөтен гаскәр өстендә дә шундый ук аксыл пар бәтерелә. Гаскәрнең һәр өлеше алдыннан унбашлары, йөзбашлары һәм меңбашлары бара. Командирларның күбесенең ияренә ат койрыгы тагылган: бу — аларның элекке сугышларда казанган батырлыклары билгесе. Меңбашы белән янәшә байракчы, быргычы һәм ике адъютант бара. Беренче меңлек артыннан икенче, өченче, дүртенче... унынчы меңлек чыга. Бу бер төмән тәшкил итә. Төмәнгә кергән меңлекләр бер-берсеннән байраклырындагы тамгалары белән генә аерылалар: күгелҗем кием, күгелҗем калкаңнар, күгелҗем ат япмалары, күгелҗем байраклар. Төмәнбашының байрагы да күгелҗем, әмма ул зур һәм ыру тамгалы.**

**Беренче төмәннән соң кала капкасыннан икенче төмән чыкканы күренә: бусы — зәңгәр гаскәр. Аның артыннан — яшел гаскәр чыга башлый. Дүртенче булып — кызгылт гаскәр күренә һ. б.**

**Әнә шулай кала капкасыннан төсләре белән генә бер-берсеннән аерылып торган егерме төмән чыга. Әмма кала капкасы һаман ябылмый әле: җигүле дөяләр, атлар һәм үгезләр олавы чыгасы бар: аларның зур арбаларына меңәрләгән хезмәтче коллардан башка һәр 18 гади сугышчы, һәр 5 каһарман исәбеннән берәр чатыр төялгән. Унбашлыннан алып һәр командирга — аерым затлы чатыр. Болардан тыш, арбаларда запас кораллар, азык-төлек һәм табибләр өчен кирәк-яраклар бар. Буш арбалар да санап бетергесез: алары — трофей төяр өчен. Иксез-чиксез олау чыгып бетүгә, кала капкасы ябыла. Моның сәбәбе шундук аңлашыла: гаскәрнең чыгып беткәнен капканың ике ягында да ат өерләре көтеп торган икән. Цирк өчен өйрәтелгән диярсең: атчыларның «Хуп-хуп!» дип кычкырулары**

була — атлар олауга арттан килеп кушылалар. Беренче карашка запас атларның саны очраклы кебек, ләкин ул алай түгел: һәр унбашына — биш, һәр йөзбашына — ун, һәр меңбашына — илле запас ат билгеләнгән. Ә яуга катнашкан әмирләр — йөздән алып, ике йөзгә кадәр (бу — аларның дәрәҗәләренә карап рөхсәт ителә), ә төп сәргаскәр (башкомандующий) — берүзенә 300 запас ат ала.

**Авторлар искәрмәсе.** Режиссер игътибарына: монда китерелгән саннар — бары тик мөмкинлектән чыгып файдалану өчен генә.

**Өстәмә информация:** ханнарны, әмирләрне, солтаннарны һәм аларның нәрчелнәрен 12 меңлек махсус казаклар гаскәре саклый: алар марш вакытында үзәктә булалар, ә гаскәр төнге ялга туктаганда, дүрткә бүленеп, башкомандующий ставкасы янына (бу очракта — Шаһ Тимер һәм аның кече хатыны Чулпан мәликә белән аксөяк нәрчелнәре күз алдында тотыла), дүрт чакрым читтә беркемне дә, ягъни парольне белмәүчеләрне якын китермичә, сакта йөреп торалар. Бу гаскәр киемнәренең затлылыгы һәм коралларының нәфислеге белән бүтәннәрдән бик нык аерыла, атларның япмалары юлбарыс тиресеннән эшләнгән.

### 58. Хансарай мәйданы. Иртән.

Мәйданга халык җыелган: яуга китәсе ханнарның һәм әмирләрнең хансарай утарыннан чыгуын көтәләр. Махсус гаскәр, халыкны хансарай тирәсенә якын китермичә, сафка тезелгән.

Менә барабан каккан, сорнай кычкырткан, быргы уйнаткан тавышлар яңгырый: хансарай утарының киң капкасы ачылып китә һәм аннан иң элек Шаһ Тимернең байрагын күтәреп, берничә байракчы, алар артыннан ап-ак атка атланган Шаһ Тимер үзе, Солтан Мәхмүт хан һәм бик күп түрәләрнең чыгып килгәне күренә. Шаһ Тимернең командирлары һәм аксөяк нәрчелнәре арасында Идегәй баһадир, Тимер Котлый хан да бар. Мәмләкәт башлыкларының ике ягыннан, тыгыз рәт булып, махсус гаскәр казаклары бара.

Аларны күрүгә халык ташкыны арасында көчле алкышлау шаушуы кузгала: «Ура!», «Баеп кайтыгыз! Шаһ Тимергә — дан!» кебек сүзләр яңгырый. Хан свитасыннан махсус билгеләнгән кешеләр халык өстенә көмеш акчалар учлап-учлап сибәләр.

Горур кыяфәтле Шаһ Тимер мәйдандагы алкышларга бөтенләй игътибар да итми кебек. Менә яу башлыклары мәйданнан киң урамга таба борылалар. Шуны гына көткәндәй, урамның ике ягын да сырып алган халык арасыннан сәләмә киемле бер ир йөгереп чыга һәм нәкъ Шаһ Тимер атының аяклары астына канга баткан сарык түше ите ташлый: бөек солтанның аты, өркеп, артка чигенеп куя. Бу хәлдән киң урам һәм түрәләр белән гаскәриләр шым була. Сәләмә киемле ир шашынып кулә башлый. Идегәй аны таный: юлда очратып, Сәмәркандка үзе белән алып килгән дивана ул. Шаһ Тимер бер мизгелгә каушап кала.

Идегәй *(ул бу вакытта ничектер Шаһ Тимер белән янәшә туры килә).* Өргәнеч диванасы ул, бөек падишаһ... Аягың астына сарык түше ыргытуының бер мәгънәсе булырга тиеш: Алтын Урда да — җирнең нәкъ түше бит!

Тимер *(Идегәйгә рәхмәтле карап ташлый: бер казагының диванага камчысы белән сугарга әзерләнүен күреп, сул кулын күтәрә).* Кагылмаска! Изге кеше ул!

**Атлы казак куркып артка чигенә.**

Тимер *(ягымлы тавыш белән диванага).* Атың кем, изге җан иясе?

Дивана *(авызын ера).* Баба-Сәнгу! Ә син үзең кем?

Тимер *(елмаеп җавап бирә).* Мин — синнән фатиха өмет итәм: ак юл теләп миңа, изге җан Баба-Сәнгу! Яныма якынрак кил. *(Дивана курка-курка аның янына килә: Шаһ Тимер яшьләрчә сыгылмалы хәрәкәтләр белән кинәт аңа таба иелә һәм сул кулының сырты белән аның маңгаена кагыла. Һәм үз маңгаена куеп ала. Халыкка ишетелерлек итеп кычкыра.)* Бу изге адәмнең минем аяк астына сарык түше ташлавы — Хак Тәгаләбезнең ниятебезгә хәер-фатиха бирүе ул! Юлыбызның уңачагына ышанычыбызны арттыра бу! Димәк, Алтын Урда иле безгә баш иячәк! Шуның хөрмәтенә Солтан Мәхмүт хан, Өргәнеч каласын кабат тергезеп, Хәрәзем халкын туган җиренә кайтарырга фәрман игълан итә! Баба-Сәнгуны казнам исәбенә яхшылап киендерергә һәм ат бирергә! Ул безнең белән бергә Алтын Урдага яу чабачак! *(Күзгалырга ишарә ясый.)*

**Атлы гаскәр юлын дәвам итә: арттан «Юлың уң булсын, бөек падишабыз! Кылычың күгәрмәсен! Исән-имин уран кайт!» — дип кычкырып калалар. Кемнәрдер диванаиың җилкәсенә туп сала, аны атка атландырып үзләре белән алып китәләр. Дивана, авызын ерып, халыкка кул изи.**

### 59. Олы-Тау итәге. Көн.

Апрель лыжырдавы. Шаһ Тимернең гаскәре берничә көн хәл җыярга, авыр юлда йончыган арык атларына ял бирергә туктаган. Гаскәрнең бер өлеше ауга киткән.

Шаһ Тимернең яу чатырында сөйгән яшь хатыны мәликә Чулпан, Идегәй һәм бөек падишаһ үзе генә. Шаһ Тимер белән Идегәй шахмат уйныйлар. Чулпан, җилок-җимеш ашый-ашый, аларның уенын күзәтә: аңа Идегәй, ир кеше буларак, ошый, булса кирәк, — ул еш кына, ирен сизлермичә, аңа төбәлеп карап тора, Идегәйнең күз карашы белән очрашса, елмаеп, аның күңелен үзенә игътибар иттерергә тырыша. Идегәйгә аның кыланышы ошамый: аның йөзе отыры караңгылана бара. Ниһаять, ул, Чулпанның ачыктан-ачык каш сикертергә азаплануын сизеп, юри тиз-тиз генә ялгышлар җибәреп, бөек падишаһка бирелә.

Идегәй *(елмаеп).* Бүген дә уңышка ирешә алмадым, бөек падишаһ!

Тимер *(кинәнеп сынагандай).* Тагын бер тапкыр омтылыш ясап карарга теләмисеңме, кияү? Бәхет елмаер, бәлки?

Идегәй *(ул падишаһның нәрсәгә ишарә ясавын аңлый)*. Кичер, бөек падишаһ... Никтер баш авыртып тора. Салкын җил бәрдеме. Рөхсәт итсәң — үз чатырыма кайтып, черем итеп алыр идем?

Чулпан *(ризасызлык белән)*. Һу! Уеныгызны рәхәтләнеп карап торырмын дигән идем... Үзем уйный белмәсәм дә, яратам мин. *(Киная белән Идегәйгә карый.)*

Тимер *(хатынының сүзенә игътибар итми)*. Башың авыртуның сәбәбе җитдирәк түгелме икән, кияү?

Идегәй. Мин дә шулай дип шикләнәм шул, падишаһым.

Тимер. Кыстамыйм, кияү, алай булгач. Ял ит. Минем гаскәр башлыкларым һәрвакыт сау-сәламәт булырга тиеш! *(Кузгала: Идегәй дә тора.)* Ә минем башка бер... мәтур уй килде: бүген шахматсыз да күңелсез булмас шәт. *(Чатырдан чыгалар. Идегәй, Чулпанга күтәрелеп карамыйча гына, баш иеп чыгып китә.)*

**60. Олы-Тау итәге. Көн.**

**Шаһ Тимер ике тән сакчысы һәм битикчесе белән җирдә аунап яткан дүртпочмаклы зур гына таш янына килеп туктый.**

Тимер. Монсы — ярый... *(Битикчегә.)* Өстен тигезләп шомарттырып, мондый сүзләрне чокып яздыр: «Мин, Туран солтаны Шаһ Тимер, 200 меңле гаскәрем белән Алтын Урда ханы Туктамышның канын коярга яу чыктым. Фәләненче ел, фәлән ай.» Шушы урында кеше гәүдәсеннән тирәнрәк итеп тар чокыр казылсын, ә өске өлеше — шушы ташның төбе шыплап сыярлык булсын. *(Битикче аның сүзләрен язып тора һәм башын иеп кала.)*

**61. Шунда ук. Кичке як.**

**Тар гына тирән чокыр казылган. Чокыр янында, яссы ягын шомартып, гарәп хәрефләре белән Шаһ Тимер кушкан сүзләр чокып язылган таш ята.**

**Шаһ Тимернең чатырлардан корылган лагерына сугышчылар бик күп болан, поши, җәйрән һәм башка төрле киек түшкәләрен киртәләргә бәйләп алып кайталар: гаскәр букауллары ау ганимәтләрен исәпләп торалар.**

**Таш янына үзенең иярченнәре белән Шаһ Тимер килә. Мәликә Чулпан һәм Идегәй дә шунда.**

Битикче *(падишаһына баш ия)*. Әмерең үтәлде, бөек падишаһ.

**Шаһ Тимер чокырны һәм язулы ташны җентекләп тикшерә.**

Чулпан *(шикланып)*. Бр-р! Нәрсә була бу, солтаным?

Тимер *(кырыс)*. Тиздән аңларсың... *(Ике тән сакчысына.)* Мәликәгезне шушы чокырга төшереп бастырып карагыз әле — үзенә таманмы икән?

**Бөтенесе дә аңа гаҗәпләнеп карыйлар: Чулпанның күзләре маңгаена менә.**

Чулпан *(шаяртуга борырга теләп, артка чигенә)*. Юк-юк, мин теләмим, анда бик пычрак һәм салкын!

Тимер *(икеләнеп торган казакларына)*. Әмеремне үтәгез!

Чулпан. Әнекәем! *(Чиный-чиный читкә йөгерә.)*

**Таза казаклар аны, куып тотып, чокыр янына китерәләр.**

Чулпан *(елап)*. Гаебем булса, кичер мине, падишаһым! Синең алда бер гөнаһым да юк ич минем! *(Тезләнергә тели.)*

Тимер *(казакларга)*. Нәрсә көтәсез! Үзегезгә дә чокыр казытасыгыз киләме?

**Казаклар Чулпанны, акырта-акырта күтәреп, иплән кенә чокырга төшереп җибәрәләр: аның буе чокырның яртысыннан гына була. Чулпан кулларын күтәреп, чокыр читенә тотынмакчы була, әмма үрелеп тә буе җитми.**

Тимер. Ташны өстенә утыртып куегыз!

**Унлаган казак язулы ташны, көч-хәл белән күтәреп, Чулпанның баш очында ясалган чокырга утырта: чокыр капланыр алдыннан бичара хатынның җан өшеткеч ачы тавышы яңгырый һәм кинәт тына — җир астыннан ниндидер тонык авазлар гына ишетелгән кебек була. Барсы да, агарынып, тын алырга куркып басып торалар.**

Тимер. Менә хәзер беркемнең дә башы авыртмас. *(Уң аягына аксый төшеп, чатыры ягына китә, иярченнәре аның артыннан ияре.)*

**Язулы таш, җир астыннан аваз бирергә азапланган мескен Чулпанның кабер ташына әйләнеп, Олы-Тау итәгендә тырпаеп кала.**

**62. «Алтын Таш» хансарай. Иртән.**

**Туктамыш ханның йокы бүлмәсе. Чуклы бәрхет чаршаудан корылган балдахин эчендә — хан ятагы. Туктамыш хан шәп-шәрә яшь кәнизәге белән йоклап ята. Саташа, булса кирәк, ыңгырашып куя.**

**Ханның йокы бүлмәсенә Йәникә атылып килеп керә: аның башы-күзе тонган. Йәникәнең аяк тавышыннан уянып, кәнизәк сикереп тора һәм ханбикәне танып, куркуыннан аңа карап ката.**

Йәникә *(кәнизәккә исе дә китми)*. Прес! (Мәче кугандай кулын гына селти.)

**Кәнизәк кыз, җиңел котылуына шатланып, күлмәге белән түшен каплап чыгып йөгерә: аның каршына Киң Җанбай очрый.**

Йәникә *(аны төрткәләп уята)*. Тор тизрәк, каган! Идегәй Аксак Тимерне Җаекка китергән! Урдаңа куркыныч яу килә!

Туктамыш *(йокы йөзеннән аерылмыйча сикереп торып утыра)*. Фу! Әллә нинди төшләр күреп, саташып беттем! Нинди ау?! Баш вәзиргә әйтсеннәр: бүген ауга чыгарга кәефем юк.

Йәникә *(аны җилтерәтә)*. Уян, дим мин сиңа! Синдә һаман кәнизәкләр белән ау кайгысы! Идегәй иленә яу алып кайткан! Аксак Тимер — капкаң төбендә! Вакытында башын чаба белмәдең шул мөртәтнең!

Туктамыш *(күз алдында агарына)*. Булмас?!

Җанбай *(сүзгә кушылырга вакыт җиткәнлегән чамалый)*. Кызганычка каршы — хак сүз, бөек каган. Туп-туры йокы бүлмәңә килеп керүемне кичер — вакыты шундый. Шаһ Тимер, ике йөз меңле гаскәре белән Җаекны кичеп, Ку күле буена урнашкан. Идегәй — аның гаскәренең маңгаена баш, Ырыс ханның өлкән углы Коерчак — сул канат башы, ди.

Туктамыш *(бөтенләй югалып калган)*. Нишлибез?! Йолым түләп, килешеп булмасмы? Янывызда бер төмән гаскәребез дә юк бит — барысы да язгы кыр эшләрендә!

Йәникә. Нинди салым?! Дүрт йөз меңлек гаскәрең була торыпмы?! Тавыклар көләр!

Туктамыш *(ачык изүе аша йонлач күкрәген кашый, күкле-яшелле тавыш белән)*. Җыеп өлгерә алмыйбыз, дип торам ич мин сиңа, тавык мие эчкән хатын!

Җанбай. Ханбикәнең сүзе нигезле, бөек каган. Болай итәргә кирәк, минемчә: Идегәй заманында пир Галәветдингә бик нык табына иде — әл аның остазы булган сәет бит. Пир Галәветдинне Идегәйгә илче булып барырга күндерик...

Туктамыш *(түземсезлек белән аны бүлдерә)*. Моның белән без нәрсә отарбыз? Шуны әйтеп бир син миңа!

Җанбай. Пир Галәветдин Шаһ Тимер гаскәрен беразга гына булса да тоткарлап тора алмасмы? Ишетүемчә, Идегәй — хәзер аның кияве, имеш. Әгәр дә ул остазының сүзенә колак салса... Аңынчы без ерак олыслардан гаскәребезне туплап өлгерәбез.

Туктамыш *(ниһаять, ул бераз җанлана төшә)*. Фәрманымны әзерләт, Җанбай би!

**63. Ку күле буенда Шаһ Тимернең лагеры. Кичке як.**

**Шаһ Тимер чирүе, килеп җитмәгән гаскәрләрен көтеп алыр өчен, Ку күле тирәсенә лагерь корып туктаган: тын алудан файдаланып, сугышчылар коралларын рәткә китерәләр, кылычларына йөз салалар, кием-салымнарын сиплиләр, атларын дагалыйлар, күлдә балык тоталар. Чатырлардан корылган лагерь күз күреме бөтен офыкны сырып алган.**

**Идегәйнең маңгай гаскәре, иң алдан йөрүче буларак, нәкъ күл буена урнашкан: монда атларга үлән дә яхшырак, су да житәрлек. Идегәйнең улы Нурадын белән уртак чатыры күлгә терәлеп үк тора. Алар чатыр эчендә.**

Нурадын. Меңбашы ит мине, Идегәй әти! Үз гаскәрем белән орышта катнашып, мине мәсхәрә иткән Туктамыш бәкләреннән үч аласым килә.

Идегәй. Бу — минем кулдан килә торган эш түгел, Нурадын улым: гаскәр башлыкларын Шаһ Тимер шәхсән үзе билгели. Аннан соң ул орыш алдыннан беркайчан да аларны алмаштырмый. Гаскәр башлыкларының тәвәккәллеген кимәтә ул, дип саный. Мин үзем дә аның белән килешәм: кичүгә житкәч, атны алмашмыйлар.

Нурадын. Ул чагында мине Болгар иленә җибәр: болгар түрәсе Бодай би көтә мине: урап кайтканыңны көтәчәкбез, дип әйтеп калды ул. Син бирә алмаган гаскәрне ул бирәчәк миңа!

Идегәй *(улының кәефен кырасы килми)*. Уйлашырбыз, улым.

Нурадын *(түземсезләнеп)*. Уйласы юк, әти! Син үзең дә монда — Шаһ Тимернең әмерен үтәүче генә! Туктамыш җиңелсә — Шаһ Тимер яуны бөтенләе белән үзенеке итәчәк. Тәхеткә дә кемне тели — шуны куячак! Синең белән тамчы да санашмаячак ул, мин әйтте, диярсең, Идегәй баһадир. Синең урыныңда булсам, мин аның баһадиры булып йөргәнче, үз гаскәремнең батыры булырга тырышыр идем. Әйдә үзең дә минем белән — үз гаскәребезне җыярга киттек!

Идегәй *(елмая)*. Күз алдында көннән-көн ир-егет булып барасың, бугай, син, бәбкәм. Тик артык кабаланасың. Шаһ Тимер тырнагына эләгә күрмә: аның талканы коры!

**Тышта: «Идегәй баһадирга — Туктамыш хан илчесе!» — дип кычкырган тавыш яңгырый. Ата белән ул бер-берено аптырашып карыйлар.**

Идегәй. Кем булыр икән? *(Тышка юнәлә: Нурадын да аңа ияреп чатырдан чыга.)*

**Аның чатыры янына коралы казаклар сагы астында пир Галәветдин белән Алтын Урданың берничә дин житәкчесе килә. Туктамышның шыгавыллары Аңгысын белән Таңгысын да алар арасында — илчеләрне озатып йөрүчеләр итеп билгеләнгәннәр, күрәсең.**

Бер казак. Маңлай башы Идегәй баһадир! Туктамыш хан илчеләре сине сорыйлар.

Идегәй *(остазын танып, аларны ачык күңел белән каршы ала)*. Хуш киләсең, остазым пир Галәветдин сәет! Аяк астында тузан булыйм! *(Чын күңелдән хөрмәтләп, аңа баш ия.)* Чатырыма үтегез, хөрмәтле илчеләр. *(Чатыр ишегенең чаршавын ачып тора. Озата килгән казакларга.)* Сезгә китәргә мөмкин, кирәк булсагыз чакыртырмын. *(Казаклар киткәч, Аңгысын белән Таңгысынга әкрен генә дәшә.)* Икегезне дә исән-имин күрүемә бик шатмын. Нурадын улым, кунакларны сыйла. *(Пышылдап.)* Минем кешеләр болар, чит колак булмаган чакта сөйләш яхшылап. *(Кычкырыбрак.)* Кадерле кунакларыма сый китерсеннәр, углым. *(Чатырына керә.)* Келәмгә утырышыгыз, хөрмәтле илчеләр. *(Асларына кут мендәрләре ташлый. Үзе дә алар янына урнаша.)*

Галәветдин. Йә, бер дога кылыйк.

**Кулларын күтәреп, бөтенесе бергә дога кыла.**

Галәветдин. Амин! *(Ике учы белән битен сыпыра.)*

Идегәй. Исән-имин килеп җиттегезме барыгыз да, остазым пир Галәветдин абзый? Юл газабы бик авыр булмадымы?

Галәветдин. Ходайга шөкер, Идегәй углым: әйбәт килеп җиттек. Юлдашларымның бөтенесен дә таныйсыңдыр? Илнең хөрмәтле иман-сәетләре болар.

Идегәй. Бик әйбәт таныйм, остазым. Онытып бетермәгәнмен икән әлегә.

**Гаскәр коллары алларына төрле ашамлыклар кертеп куялар. Берсе, комган белән җиз таз алып кереп, кунакларның һәм Идегәйнең кулларын юдыра, сөлгеләр бирә. Хезмәтчеләр чыгып китәләр.**

Идегәй. Хәзинәдә булганыннан җитешегез, хөрмәтле сәетләр.

Галәветдин. Тыңлыйбыз сине, Идегәй углым: безгә әйтер сүзең күптер.

Идегәй. Дөрес, остазым: әйтер сүзем күп. Тик — сез барыгыз да миннән өлкәнләр, сезнең сүз — алдан йөри.

Сәетләр. Хуш, хуш, Идегәй батыр. Ата-баба горефен читтә онытмагансың.

Идегәй *(елмая)*. Кайда да кеше — кешечә гореф тота, хөрмәтле сәетләр.

Сәетләр. Әйе. Шулай. Шулай булырга тиеш. Кайда да адәм баласы яши! Бик мәслихәт!

Галәветдин. Сүзебез кыска безнең Идегәй углым: үз йортыңа яу чакырып, бик начар эшләгәнсең. Атыңны кирегә бор яисә Сарайга кайтып, кабат Туктамыш ханның бие бул! Үз халкыңның канын нахакка койдырма ләгыйньнән! Илләштермәк — илчедән, яулаштырмак — яучыдан!

Сәетләр. Әйе. Ыруың канын койдырма. Атыңны кире бор, Идегәй батыр!

Идегәй *(йөзе караңгылана)*. «Илләштермәк — илчедән, яулаштырмак — яучыдан»... Яхшы әйттең, остазым! Тик минем сорауларыма җавап бир, пирем: Котлыкыя атамның, йортын яндырып, башын ора чапканда син кайда идең?

**Пир Галәветдин дәшми.**

Идегәй. Алты угыл үстергән Җантимер би дә синең кебек пир иде: ул, үз башын пычак астына куеп, атамны йолып калырга тырышкан. Менә ул — пир! Бишектә яткан чагымда башымны ора чабарга торганда, ул, үз төпчеген кызганмыйча, минем урынга салып, мине ачы үлемнән йолып калган — ул чакта син, пирем, кайда идең?

**Пир Галәветдин дәшми.**

Идегәй. Туктамыш хан мине кендек каным тамган туфрагымнан аерганда син кайда идең, пирем?

**Пир Галәветдин дәшми.**

Идегәй. Гөнаһсыз Норадын углымны Туктамыш хан мәсхәрәләп минем арттан куды — ул чакта син кайда булдың, пирем?

**Пир Галәветдин дәшми.**

Идегәй. Урда тәхетенә бер үзе хуҗа булып калгач, Туктамыш хан кардәш ыруларыбызны тимер дагалы күн итекләре астына салды — син кайда идең, пир Галәветдин?!

**Пир Галәветдин дәшми.**

Идегәй *(яңак калкымын уйнатып)*. «Илләштермәк — илчедән, яулаштырмак — яучыдан»... Атыңны кайтыр юлыңа бор, Туктамыш илчесе!

Галәветдин. Авыр сораулар бирдең остазыңа, Идегәй батыр... Ниятеңнән кайтмасаң — синең үзеңә болардан да авыррак сорауларга җавап бирергә туры килер! *(Кузгала.)*

Идегәй. Тәкъдиргә язылганы булыр, Туктамыш илчесе!

**64. Идегәй чатыры алды. Кичке як.**

**Уңышсыз сәфәргә чыккан Туктамыш илчеләре караңгы чырай белән чатырдан чыгалар. Идегәй аларны озата. Чатыр янына Шаһ Тимернең сәете Бәркә килә: ул нәселдәшләрен күрергә ашыккан.**

Бәркә. Әссәламегаләйкем, Рәсүлебезнең варислары! Мин — ерак нәселдәшегез Бәркә сәет булам. *(Күкрәгенә кулын куеп, сәетләргә баш ия.)* Килүегез хакында ишеткәч, сезне күрәсем килде.

Галәветдин *(аңа бертын карап тора һәм кырыс йөз белән китәргә борыла.)* Ләгыйньгә ялланган сәет белән уртак эшебез булмас безнең!

**Туктамыш илчеләре ашыгып китеп баралар. Сәет Бәркә каушап басып кала.**

Идегәй *(аны кызганып)*. Чатырыма рәхим ит, сәет Бәркә.

**Сәет Бәркә, тегеләрнең дорфалыгына Идегәйне гаепле санагандай, бер сүз дә дәшмичә үз чатырына китә: бу очрашу аны бөгеп салган.**

**Ул арада Аңгысын белән Таңгысын, юл өстендәге бер чатырдан чыгып, Туктамыш илчеләренә кушыла. Норадын әтисе янына килә: алар чатырга керәләр.**

**65. Чатырда. Кичке як.**

**Чатырга кергәч, Идегәй белән Норадын мендәрләргә таяналар һәм пышылдап сөйләшә башлыйлар.**

Идегәй. Йә, нинди яңалыклар белдең?

Норадын. Нигә килгәннәр иде соң алар?

Идегәй. Яуны туктатуны сорыйлар.

Норадын. Шул гынамы?! *(Көлә.)*

**Әмма Идегәй аңа кушылмый.**

Норадын. Аңгысын белән Таңгысынның — Туктамыш ханның шыгавыллары икәнен беләсеңдер? Хәзер аларны Туктамыш хан байракчылар итеп билгеләргә тели икән. Чөнки Сарайда гаскәр бик аз калган: бер төмән чамасы гына. Илчеләрне җибәрүе — нидер өмет иткәннән түгел, ди, яше-

рен максаты — яуны бераз тоткарлап, гаскәрен җыеп бетерү, имеш. Мин Аңгысын белән Таңгысынга, әгәр дә Туктамыш хан чынлап та ниятендә торса, орыш кызган чакта Урда байрагын аударырга киңәш иттем. Риза булдылар. Дөрес эшләгәнмен ме, Идегәй баһадир? *(Елмая.)*

Идегәй *(йөзе ачылып китә)*. Үз гаскәребезне җыярга чыгабыз, улым! *(Улының маңгаеннан үбә.)* Ыру тамгасын дөрес биргәнмен икән мин сиңа, Норадын! *(Сикереп тора.)* Юлга чыгарга әзерлән: мин Шаһ Тимер чатырына киттем!

**66. Шаһ Тимер чатыры. Кич.**

**Шаһ Тимер уллары белән бергә кичкелекне ашап утыра: әкрен генә музыка ишетелә, кәнизәкләр бии, хезмәтчеләр ризыклар кертә.**

Шыгавыл *(ишектә күренә)*. Маңгайбашы Идегәй баһадир кабул итүеңне сорый, бөек падишаһ.

Гомәр Шәех. Туктамыштан илчеләр килүен яшереп калдырыр, дип көткән идем — түзмәде, килде.

Тимер *(улына кырыс карап куя: ансы телен тыя)*. Керсен.

Идегәй *(кереп, йөгенә)*. Кичер, бөек солтан: сиңа бер яхшы хәбәрем бар. *(Чит колак юкмы икән дигәндәй, чатырдагыларга күз йөртеп чыга: Сәет Бәркә дә анда утыра.)*

Тимер. Тыңлыйм сине, кияү.

Идегәй. Миндә Туктамыш ханның сәетләре булып китте: явыңны туктатуымны үтенделәр... *(Елмая)*. Уртак тел таба алмадылар, кичер, солтаным. *(Җитди.)* Әмма сиңа җиткерәсе хәбәрем икенче: сәетләр белән бергә ике ышанычлы кешем дә килгән иде, Туктамыш аларны Урда байрагы күтәрүчеләр итеп куймакчы икән. Егетләрем, орыш кызгач, байракны аударырга вәгъдә бирделәр. Мин аларга үземә ышанган кебек ышанам, бөек солтан!

**Чатырда тирән тынлык урнаша: барысы да ашаудан туктыйлар. Музыка тына, биюче кәнизәкләр тавыш-тынсыз юк булалар.**

Тимер *(әкрен генә урыныннан торып, Идегәй янына килә һәм аңа текәлә)*. Хак сүзме бу, Идегәй баһадир?

**Идегәй, уң кулын күкрәгенә куеп, аңа баш ия.**

Егетләреңә әйттер: үзләре күтәрә алырлык алтын бүләк итәчәкмен мин аларга!

Идегәй *(горур)*. Алтынга хезмәт итмиләр алар, бөек солтан. Алар — минем егетләр.

Тимер *(йөзеннән ачу билгесе йөгереп уза, ләкин ул аны шундук яшерә)*. Ихтыярлары, Идегәй кияү... Ихтыярлары... Шулай да... сүзләрендә торсалар, исемнәрен онытмыйм. Яудан коры кайтканчы, яралы кайт. Табышыма рәхим ит, кияү.

Идегәй. Рәхмәт, бөек солтан. Рөхсәт итсәң, мин, үз кешеләремне алып, тугрылыклы кардәшләрем арасында гаскәр җыярга китәр идем. Миннән хәбәр көткән әмирләрем бар: яуга үз өлешемне кертеп, бәхетемне сынап карыйсым килә! Рөхсәтеңне бирче, бөек солтан!

Тимер *(уйланып)*. Яхшы. Орышка соңга калма, Идегәй баһадир!

Идегәй *(шатланып)*. Калмам, Шаһ Тимер! *(Йөгенеп, чыгып китә.)*

Тимер *(үз алдына)*. Ә без — сине соңга калдырырга тырышырбыз... Орышны Чулман елгасы тирәсенә күчерәбез: анда карурманнар күп икән — Туктамыш үзе безне шуннан эзләп тапсын... Идегәй дә!

**67. Ку күле буе. Төн.**

**Куера башлаган караңгылыкта күл буеннан егерме-утыз җайдак Тимер Казык йолдызга таба карап кузгалып китә. Җайдаклар арасында Идегәй, аның улы Норадын һәм Тимер Котлый хан күренә.**

**68. Шаһ Тимер урдасы. Иртән.**

**Шактый биек калкулык: аны арттан, уңнан һәм сулдан дугасыман итеп куе карурман уратып алган. Шаһ Тимернең чатыры калкулыкның нәкъ уртасына корылган һәм аны алгы яктан зур арбалар чылбыры ярым түгәрәкләп коршап алган: ул чылбыр-ныгытманың ике очы еракта урман читләренә барып тоташа. Тезмәнең тышкы ягына туфрактан биек вал өелгән һәм ул туфрактан ясалган ныгытма белән арбалар чылбыры арасында тирән канау хасил булган. Кыскасы, Шаһ Тимернең ставкасы — көчле кальганы хәтерләтә. Калкулыктан тирә-як уч төбендә кебек ап-ачык булып күренә. Шаһ Тимер гаскәренең күп өлеше арттагы карурман эчендә, ә аның янында 12 меңлек гаскәреннән башка — үзәк маңгай, уң һәм сул канатларның маңгай гаскәрләре генә.**

**Шаһ Тимер уллары — оныклары һәм өлкән командиры белән киңәшмә уздырган, соңгы әмерләрен бирә. Шунда ук дисталәгән адъютантлары, күзәтчеләре, вәзирләре һәм киңәшчеләре җыелган. Сәет Бәркә, тез астына намазлык салып, иртәнге намазын укый.**

Күзәтче *(шатланып)*. Туктамыш гаскәре! *(Еракта калыккан караларга күрсәтә.)*

**Барысы да җанланып: «Кhа!» — дип кычкырып җибәрәләр. Аларның шатлануы аңлашыла: алар, монда күптән килеп, иң уңайлы урынны сайлап алганнар, саклану чараларын булдырганнар, орыш башлануын гына көтәләр. Ә Туктамыш ханга ерактан килгән уңайга гаскәрен рәткә тезәргә, ставка урыны сайларга һәм башка чаралар күрергә туры киләчәк. Шаһ Тимер алдан күрә белүеннән бик канәгать, әмма ул моны сиздерми, йөзе тыныч. Туктамыш ханның кырлата еraклардан килгән гаскәре алар күзе алдында әкренләп сафларга тезелә башлый, ыгы-зыгы күтәрелә.**

**69. Туктамыш хан урдасы. Шул ук вакыт.**

**Кечкенә елга буенда тугайлык: артта да алда да — сирәк-сирәк әрәмәлекләр, чокыр-**

**чакырлар. Туктамыш ашыгыч рәвештә ставка урынын сайлый: аның чатырын коралар. Сугышчылары да, Туктамыш үзе дә юктан да ярсырга әзер: чөнки алар — кыздырырга табага салынган балыклар кебек, Шаһ Тимернең күзе алдында ап-ачык җирдә туктарга мәҗбүр. Төне буе килгәннәр, ахры, барысы да шактый йончыган күренә. Калкымлы җирдә туктыйлар.**

Туктамыш. Гаскәр башлыкларын — минем янга! *(Карага кабынып, адъютантларына җикерә.)* Тиз селкенегез, аякларыгыз маймакланып черегән нәрсәләр!

**Адъютантлары кадала-кадала төрле якка сибелә. Туктамыш, ярсуын тыя алмыйча, бертуктаусыз мыегын чәйни.**

Җанбай *(ул да тыныч түгел).* Шаһ Тимер орышны хәзер үк башласа, нишләрбез? Күзе алдында инкүлектә җәйрәп ятабыз! Бигрәк лап җир эләкте.

**Туктамыш дәшми: ул, нинди дер могҗиза көткәндәй, Шаһ Тимернең байрагы җилфердәп торган калкулыкка төбәлгән, әйтерсең лә, күзләрен бераз йомып торып, кабат ачуга дошман тылсым көче белән юкка чыгачак. Ул, чынлап та, күзләрем йома һәм бераздан ача: юк, кан дошманы һаман үз урынында. Аның янына әкренләп өлкән командирлары җыела. Алар хан сүзен көтәләр.**

Туктамыш *(беркемгә дә карамыйча).* Урда байрагын күтәрсеннәр.

**Байракчылар — Ангысын белән Таңгысын да шунда — Чыңгыздан мирас булып калган кара туны, биек колгага беркетеп, күтәрәләр.**

Адъютант. Ту күтәрелде, бөек каган!
Туктамыш. Уң кулбашы Кыпчак би!
Кыпчак. Тыңлыйм, каган.
Туктамыш. Һөҗүмне син башлыйсың. Әнә теге урман очына кадәр ара — синең өстә! Иң мөһиме — көньяклап юлыбызны кисмәсеннәр! Исабәк би!
Исабәк. Әмереңне көтәм, бөек каган.
Туктамыш. Миңа сулъяклап сузылган урман ошамый. Без орыш белән мавыккан арада, Шаһ Тимер шул урман аша Идел ярына артыбызга төшмәсен! Идел ярын күз караң кебек сакла!
Исабәк. Үтәлер, бөек каган.
Туктамыш. Маңгайбашы Кара Хуҗа Аргын би!
Аргын. Мин монда, бөек каган.
Туктамыш. Маңгайга маңгай торырга. Әзер бул!
Аргын. Мин һәрвакыт әзер, бөек каган!
Туктамыш. Әзер булсаң... Калганы — Хак Тәгалә ихтыярында. Шаһ Тимергә чапкын җибәрегез: илме, яумы? Курыккан башлап йодрык күтәрә.

**Аргын би үзенең адъютантына ишарә ясый: ансы, атын камчылап, дошман урнашкан калкулыкка табан чаптырып китә. Бөтен гаскәр, тын калып, нәтиҗәне көтә. Чапкын, бер кулына ак яулык күтәреп, каршыда яткан елгачык аша чыга һәм ике арадагы кыр буйлап чаба. Шулвакыт дошман ставкасыннан да бер жайдак аерыла: аны, арбалар чылбырын бер җирдән өзеп, болышга чыгаралар. Шаһ Тимер җайдагы көтмәгәндә күз алдында юкка чыга һәм бераздан кабат күренә. Туктамыш ставкасында гаҗәпләнеп: «Kha!» — дип кычкырган тавыш яңгырый. Барысы да арбалар тезмәсе белән ныгытылган Шаһ Тимер ставкасының тирән канау һәм биек туфрак вал белән уратып алынуын аңлыйлар. Бу хәл Туктамыш гаскәрендә тагын да ныграк каушау үята: Шаһ Тимер орышка бик нык әзерләнгән!**

Исабәк. Шаһ Тимер ставкасын тирән канау белән дә уратып алган, димәк.
Җанбай. Орышка әзерләнергә вакыты җитәрлек булган, күрәсең...
Туктамыш *(ачулы).* Шым торыгыз!

**Ул арада ике илче болын уртасында очраша. Бер-берсенә кыска-кыска гына сүзләр әйтешәләр, күкрәкләренә кулларын куеп, баш иешәләр һәм атларын үз ставкаларына таба боралар. Туктамыш хан, түземсезләнеп, мыек очын чәйнәргә керешә. Чапкын ставкага әйләнеп кайта.**

Туктамыш. Илме, яумы?
Чапкын. Яу, бөек каган!

**Гаскәр бер мәлгә өнсез кала.**

Туктамыш. Галәветдин сәет кайда?

**70. Шаһ Тимер урдасы. Шул ук вакыт.**

**Шаһ Тимер каршына уллары һәм оныклары тезләнгәннәр.**

Гомәр Шәех. Атабыз! Туран мәмләкәтенең бөек хакиме Шаһ Тимер! Без — угылларың һәм оныкларың, сиңа мәңге тугрылыклы булырга һәм соңгы тамчы каныбыз җиргә тамганчы орышны ташламаска ант эчәбез! *(Кулындагы касәсен күтәреп эчә һәм саргытын җиргә түгә: бүтән туганнары да шулай ук эшлиләр.)*
Тимер. Антыгызны кабул кылдым, угылларым!

**Уллары һәм оныклары, Шаһ Тимергә йөгенеп, үз урыннарына таралалар.**

Тимер. Сәет Бәркә! Орышка фатиханы бирче. *(Аның алдына тезләнә һәм түбәнчелек белән башын ия.)*
Сәет Бәркә *(кулын Шаһ Тимернең башына куя).* Рәсүлебез галәйһиссәлам исеменнән фатихамны бирдем, сиңа, Шаһ Тимер! Юлдашың Хызыр булсын! Атың абынмасын! Кылычың күгәрмәсен! Зиһенең томаланмасын! *(Җиргә иелеп, бер уч туфрак ала һәм Туктамыш хан гаскәре ягына өч тапкыр сибә.)* Ягы качты! Ягы качты! Ягы качты! Ә хәзер, Шаһ Тимер, ялгызымны калдыр. *(Алдына намазлык җәя.)*

**Шаһ Тимер тора һәм тәхетенә барып утыра.**

**71. Туктамыш хан урдасы. Шул ук вакыт.**

Туктамыш *(ул атыннан төшмәгән)*. Орышка фатиханы бир, Галәветдин сәет!

Галәветдин *(Туктамыш янына килә һәм аңа баш ия)*. Изге фәрештәләрнең амин дигән сәгатендә башланган орыш булсын, бөек каган! Хызыр юлдашың булсын! Кылычың авырмасын! Күзең томаланмасын! Акылың зәгыйфьләнмәсен! Расүлебез галәйһиссәлам сиңа уңыш бирсен! *(Җиргә иелеп, бер уч туфрак ала һәм аны өч тапкыр Шаһ Тимер ставкасы ягына таба сибә.)* Ул як качты! Ул як качты! Ул як качты! Җиңүеңне теләп, дога кылырга рөхсәт ит, бөек каган? *(Алдына намазлыгын җәя.)*

**72. Калкулык астындагы болын. Көн.**

**Ике ставка ягыннан да көчле барабан тавышлары яңгырый: шулвакыт гаскәрләрдән җиңел атлы укчылар аерылып чыга һәм, кызу чапкан уңайга бер-берсе өстенә меңләгән ук яудырып, дошманнары алдыннан дугалап, читкә чыгалар һәм кырыйдан аталар. Алар артыннан авыр атлы сөңгечеләргә юл ачыла, болын уртасында ике яктан да унарча сугышчы егылып кала һәм җайдаксыз калган атлар, бергә кушылып, болын буйлап таралалар. Калканнар тишелә, озын саплы сөңгеләр сына, атка ат бәрелешә, сугышчылар маңгайга маңгай орыша башлый — канкойгыч кисеш кызганнан кыза бара. Дошманнар орышка әледән әле яңа гаскәрләрен кертә торалар: Шаһ Тимер уң кул маңгаен алга җибәрсә, Туктамыш хан аңа каршы сул кул маңгаен кузгата һәм — киресенчә, әлегә үзәк гаскәрләр, сугышка катнашмыйча, болындагы хәлне күзәтәләр. Көчләр тигез сыман: бер як уңышка ирешә башлауга, икенче як, үз гаскәрен көчәйтеп, орышны төзәтә тора. Болында аунаган гәүдәләрнең саны артканнан арта бара, хуҗасыннан язган атлар меңәрләп-меңәрләп болын буйлап чабып йөри. Шаһ Тимернең гаскәрләре, киемнәре бер төрле булуы белән аерылып торгангамы, болынны басып алган сыман тоела, ләкин алар да әлегә сизелерлек җиңүгә ирешә алмыйлар.**

**73. Шаһ Тимер урдасы. Көн.**

**Тимер** *(кырыс)*. Ир Каплан! Көньяклап Туктамышның юлын кис!

**Бөек әмирнең бер адъютанты шундук аның әмерен Ир Капланга җиткерергә чаба: чөнки командирлар үз гаскәрләре янында торалар.**

**74. Туктамыш урдасы. Көн.**

Туктамыш *(Шаһ Тимернең маневрын сизенеп)*. Кыпчак би! Күрдеңме? Чарасын тап!

**Туктамышның бер адъютанты әмерне Кыпчак бигә җиткерергә ашыга: аның командирлары да, шулай ук, үз гаскәрләре белән бергә ханнан фәрман көтәләр.**

**75. Болынның көньяк өлеше. Көн.**

**Ир Каплан җитәкчелегендә Шаһ Тимер гаскәренең сул канаты Туктамышны көньяктан уратып алу нияте белән, флангка томырыла: берничә минут эчендә киң болынның көньяк өлешен атлы чирү каплый. Бу шулкадәр тиз була ки, хәтта болын уртасында кызган орыш та бераз сүрелә төшкәндәй тоела. Туктамышның гаскәре Ир Капланның кысрыклавына чыдый алмыйча, тәртипсез рәвештә чигенә башлый: бөтен кырга һөҗүм итүчеләрнең дәррәү «Ура!»сы яңгырый.**

**76. Шаһ Тимер Урдасы. Шул ук вакыт.**

Тимер *(караңгы чырай белән)*. Ахмак! Кая ашыгасың?! Дошман авызына эләгеп, чәйнәләсең киләме?!

**Аның шул сүзләрен генә көткәндәй, бер адъютант Ир Каплан артыннан ташлана, әмма соң инде: Кыпчак бинең гаскәре, икегә аерылып, Ир Каплан гаскәрен уртага ала һәм аяусыз кыра башлый. Ир Каплан би белән аның бик күп офицерлары һәм сугышчылары Кыпчак би кулына әсир төшә. Моңдый хәлне көтмәгән Шаһ Тимер урдасында ыгы-зыгы күтәрелә: әмма бөек әмир үзен бик тыныч тота.**

Тимер *(берни булмагандай)*. Әбүбәкер мирза!

Әбүбәкер *(йөгереп килә: уллары һәм оныклары аның янындарак торалар)*. Тыңлыйм сине, бөек бабам!

Тимер *(сул кулы белән арбалар чылбырының тышкы ягына — нәкъ Туктамыш урдасы каршына калкулык итәгенә күрсәтә)*. Маңгай гаскәрең белән чыгып, шунда казаннар астыр һәм кичке аш пешертә башла.

**Шаһ Тимер тирәсендәгеләр барысы да шаккаталар: юлбашчылары акылдан язганмы әллә?! Әбүбәкер гаскәре янына ташлана.**

Тимер *(беркемгә дә карамыйча)*. Сул канатның икенче өлеш башы Арыслан баһадир! Туктамышка көньяк юлны кис!

**Адъютантларының берсе аның әмерен тапшырырга чаба.**

**77. Туктамыш урдасы. Шул ук вакыт.**

**Кыпчак би әсирләрен Туктамыш каршына китертә. Ир Капланның кыл киеме кыйпыкланып беткән.**

Кыпчак. Шаһ Тимернең сул кулбашы Ир Каплан пәһләвәнне кабул ит, бөек каган! Ул батырларча сугышты!

Туктамыш *(ул бик шат)*. Күрдек. Кул артың җиңел булсын, Кыпчак би! Миңа хезмәткә күч, Ир Каплан батыр?

Ир Каплан *(дәрәҗәсен саклап)*. Шаһ Тимер янында мин яхшы яшәдем: әмир һәм хаким булдым. Ул сиңа тәхет яулап бирде — ә син аңа хыянәт иттең: сине исән күргән күзләремне үзем йолкып атар идем мин! Әгәр дә миңа мәрхәмәт күрсәтергә теләсәң,

башымны чаптыр. Бөек түрәмә, кулыннан бәхет кошы ычкынып, орышта аварга язган булса — башымны — аның башы, гәүдәмне — аның гәүдәсе астына куеп, җирләгез: аның кебек бөек юлбашчының изге тәне җирдә ятарга тиеш түгел!

Туктамыш. Яхшы. Батырып әйттең. Телэгең үтәлер. *(Алып китегез, дип кул изи.)*

Кыпчак. Нәрсә бу?!

**Туктамыш хан ул күрсәткән якка карый: дошман гаскәре, нәкъ алар каршысына казаннар асып, учаклар тергезеп маташа! Туктамыш хан урдасы каушап төшә, чөнки Шаһ Тимернең үз көченә бик нык ышануын күрсәтеп тора ул.**

Җанбай. Менә әрсез Алабай! Барыбер җиңәм мин сезне, димәкче инде бу!

Туктамыш. Бала-чага уены! Мине алдый алмассың, карт төлке! Кыпчак би: каршыңда — кабат дошман гаскәре! Уяулыгыңны югалтма!

**Кыпчак би гаскәре янына ташлана.**

Туктамыш. Җанбай би! Бер төмән гаскәр ал да, туздырып ташла шуларны! *(Ул арада меңләгән учак тергезеп өлгергән дошман гаскәренә күрсәтә.)*

Җанбай *(атына менә).* Баһадирлар! Минем арттан! Измәләрен изик! *(Бер төмәнбашына кул изи һәм елга аша атын сикертеп чаба башлый, тик атыннан егылып төшеп кала: ә ул кабат атына менгәнче, гаскәре ерак китеп өлгерә. Киң Җанбайга арттан сөйрәлергә генә кала.)*

Туктамыш *(үз-үзенә).* Менә нинди камыр батырлар белән орышка чыгарга туры килә миңа... Тфү! Егәрсез яу булды, ахры, бу!

**Ә бу вакытта Кыпчак би гаскәре Шаһ Тимернең икенче сул канатын да аударып ташлый: Арыслан баһадирдан башка тагын берничә командир һәм бик күп сугышчысы әсир төшә. Калганнарын кырып бетерәләр. Туктамыш, моны күреп, шатланып көлеп куя.**

Туктамыш. Менә ничек орышырга кирәк!

**Ләкин шулвакыт аның ут ягучыларны куып таратырга җибәргән гаскәре үзе тәртипсез рәвештә чигенә башлый.**

Туктамыш. Кара Куҗа Аргын би!

Аргын. Аңлашылды, бөек каган! *(Киң Җанбайга ярдәмгә ташлана.)*

**78. Шаһ Тимер урдасы. Шул ук вакыт.**

Тимер *(оныгы Әбүбәкер мирза өстенә тагын бер гаскәр килүен күреп).* Әһә! Хаталар җибәрә башладыңмы, Туктамыш... Кыпчак биең үзеңнән зирәгрәк икән шул! Бер би белән озак каршы тора алмассың.

Солтан Мәхмүт. Арыслан баһадирны әсир алдылар. Шаһ Тимер! Рөхсәтең бир: артларыннан төшәм?

Тимер *(тыныч).* Солтан Мәхмүт хан миңа Арыслан баһадирдан кадерлерәк. Әбүбәкер мирзага маңгайдан тагып бер төмән аерып бирергә.

**Аның фәрманын шундук үтиләр: казан асучылар янында сугыш тагын да ныграк кабынып китә, Туктамышның сугышчылары, Шаһ Тимернең ике зур гаскәре бер-бер артлы тар-мар ителгәнен күргәнгәме, дошманнарын бик нык кысрыклый башлыйлар, хәзер кисеш учаклар тирәсендә үк бара. Менә озакламый орыш арбалардан корылган ныгытмага якынлаша: берничә ук хәтта Шаһ Тимер тирәсенә төшеп кадала — махсус аңа төбәп аталар.**

Тимер *(укларга игътибар итми).* Тагын бер төмән. *(Һөҗүм итегез, дип кулын алга таба изи).*

**Аның әмерен үтәп, тагын бер төмән гаскәре алга ташлана: әмма, шуны гына көткәндәй, Туктамыш ягыннан да атлы гаскәр ташкыны ыргылып килеп чыга. Шаһ Тимер сул кулын алга изи: сул канаттан бер төмән орышка ташлана. Туктамыш та аннан калышмый. Берзаман ике арадагы киң болын атлы гаскәрләр белән тула: кычкырыш, ат кешнәү, тимергә тимер ору тавышлары җиһанны каплап китә.**

**Ул да булмый, Шаһ Тимер гаскәре, хәле кыеная барып, әкренләп артка чигенә башлый. Шаһ Тимер уң кулын алга селти — әмма анда гаскәре калмаган. Сул кулын алга таба селти — анда да запас гаскәре беткән! Ә Туктамыш хан һаман аның ягына гаскәр артыннан гаскәр җибәреп тора!**

Гомәр Шәех *(атасы янына атын чаптырып килә).* Чатырыңны урманга күчерик, бөек атам! Идегәй килеп җитмәде — безне алдады, кабахәт!

Тимер *(тыныч).* Үзебезгә катнашырга чират җитте, углым. Ходай тәгалә ярдәменнән ташламас — сынатмабыз, шөт. Кул артыбыз китмәсен!

Гомәр Шәех. Бөек солтанга — ат!

**79. Туктамыш урдасы. Шул ук вакыт.**

Туктамыш. Менә хәзер бөтен көчебез белән Шаһ Тимер өстенә ташланырга вакыт! Исабәк би! Сул кулдан төш! Кыпчак би! Уң кул — синеке! Калган биләр — минем арттан!

**Туктамышның бөтен гаскәре, соңгы көчен җыеп, дошман өстенә томырыла: аның урдасында хезмәтчеләр белән байракчылар гына кала. Аңгысын белән Таңгысын да шунда. Исабәк биең гаскәре Шаһ Тимер ставкасының уң ягындагы урманнан чыгып килүче гаскәргә каршы чаба, Кыпчак би Шаһ Тимер гаскәрен уңъяклап кысрыклый. Хәлиткеч мизгел якынлаша — Шаһ Тимер менә-менә атын качу ягына борачак. Ләкин шулчак көтелмәгән хәл була: уңъяктагы урман артыннан ниндидер көчле гаскәр ташкыны атылып килеп чыга һәм таралып сирәкләнгән Исабәк би җайдакларын кыйгачлап кисеп**

**уза. Болгар яктарыннан Идегәй җыеп кайткан гаскәр бу.**

Идегәй *(Исабәк абыйсын таный)*. Исабәк би! Бу мин — имчәктәш туганың Идегәй! Минем якка чык!

Исәбәк. Игәр этқә имчәктәш бул — нәсел корткыч бәдбәхет син! *(Идегәй ягына ук ата-ата артка чигенә.)*

**Идегәй Исабәк җайдакларын болынга таратып ташлый һәм, сугыша-сугыша, Туктамыш тирәсенә омтыла. Моны күргәч, Шаһ Тимер гаскәренә яңа сулыш өстәлгәндәй була: гайрәтләнеп, Туктамыш гаскәрен кысрыклый башлыйлар. Шушы хәлиткеч мизгелдә Туктамыш хан артында җилфердәп торган кара байрак кинәт авып төшә.**

Җанбай *(ул Туктамыш тирәсендә чуала)*. Туктамыш хан! Ханбайрак ауган! Безне камыйлар!

**Туктамышның гаскәре арасында паника күтәрелә: кайда да — «Ханбайрак кая?! Ханбайрак ауган! Харап булдык — безне камыйлар!» — дип каушап кычкырган сүзләр ишетелә, әйдә, дошманга, киресенчә, дәрт өстәлә.**

Туктамыш *(атын кинәт туктата һәм урдасына борылып карый: Чыңгыздан калган байрак, чынлап та, күренми)*. Ничек булды соң әле бу?! *(Югалып кала.)*

Җанбай. Идегәй эше! *(Узләренә таба якынлашып килгән Идегәйгә төртеп күрсәтә.)* Уң кулда юл ачык әлегә, соңга калганчы качып котыл, бөек каган!

Туктамыш. Ай, эшләр харап! *(Тирәягына карана: аның гаскәре, паникага бирелеп, төрле якка сибелеп кача башлаган инде.)*

Җанбай. Синең исән калуың Алтын Урдабыз өчен кирәк, бөек каган! Халкың күп, җирең житәрлек: яңа гаскәр табылыр, илең дә сакланыр! Күрәсебез булганны ил белән күтәрербез! Тән сакчылары! Бөек каганны урап басыгыз! Безнең арттан! *(Атын чаптырып китә: Туктамыш хан да, башын иеп, аңа ияра.)*

**80. Шаһ Тимер урдасы. Шул ук вакыт.**

**Шаһ Тимер, ап-ак атына атланган килеш, зурлык-олылык белән калкулык өстендә тора: ул Туктамышның тар-мар ителүен аңлый. Ирексездән, сул кулы белән күз яшьләрен сөртә.**

Тимер *(узалдына пышылдый)*. Бәхетең бар икән, Идегәй кияү... Вакытында килеп җиттең!

**Шаһ Тимер каршындагы киң болын тиздән атлы гаскәрләрдән арына һәм имәндергеч күренеш ачыла: аның бер генә карыш җире дә буш түгел — болынны йөз меңләгән яралылар һәм мәетләр каплаган. Ат үләксәләре дә исәпсез-хисапсыз күренә. Орыштавышы көньякка, офык артына китеп, тына. Күктә каракошлар коркылдый.**

Тимер *(беркемгә дә карамыйча)*. Туктамыш чатырына юл ачыгыз!

**81. Туктамыш урдасы. Кичке як.**

**Туктамышның чатыры янында ерткаланып беткән кара байрак аунап ята. Шунда ук — ике гәүдә: Аңгысын белән Таңгысын мәетләре алар.**

**Идегәй белән улы Норадын килә.**

Норадын *(ул әле һаман да орыш кызуыннан арынмаган)*. Күңелем булды! Мине, корчаңгы тайга атландырып, Сарайдан мыскыллап куып җибәргән биләрнең берсен дә аямадым, әти! Барысыннан да туйганчы үчемне алдым!

Идегәй. Булдыргансың, улым!

Норадын *(ул әтисенең халәтен сизми)*. Тукта, Идегәй батыр: ары нишлибез?! Туктамыш хан исән бит әле! Ә Идел-Йортыбызда — Аксак Тимер гаскәре!

Идегәй. Арымы... Ары — Шаһ Тимер белән исәпне өзәбез. Аннан соң, заман кемнең заманы дигәндә — Идегәй әтиең заманы башланачак! Ары — дәвер кемнең дәвере дигәндә — синең белән минем дәвер булачак, Норадын улым! *(Чатыр янына килеп җиткәч, атыннан төшә һәм мәетләр өстенә иелә.)* Аңгысын белән Таңгысын! Менә кемнәргә рәхмәтле без, улым. Безнең өчен башларын салдылар алар бүген... Урыннары оҗмахта булсын! Хөрмәтләп җирләрбез. *(Дусларының күз кабакларын яба).*

**Алар янына уллары һәм якын кешеләре белән Шаһ Тимер килеп җитә.**

Идегәй *(аякөсте торып, аның алдында йөгенә)*. Зур җиңүең белән котларга рөхсәт ит, бөек падишаһ.

Тимер *(сынап)*. Уртак җиңү, кияү, уртак җиңү... Дан уртаксыз булмый. Норадын улыңның батырлыклары хакында да сөйләделәр миңа — азау ярган шәп яугир үстергәнсең, Идегәй баһадир!

Норадын *(аңа хөрмәт белән йөгенә)*. Безнеңчә — батыр диләр, бөек падишаһ.

Тимер *(кырыс)*. Тел тезгене генә бераз озынрак икән.

Идегәй *(улына ярдәмгә ашыга)*. Сабыйлыгы белән ул бөек падишаһ: кичер, зинһар! Һәм безгә — Туктамыш ханны эзәрлекләргә рөхсәтеңне бир?

Тимер *(бераз көттереп)*. Дөрес әйтәсең, бер кыныга ике кылыч сыймый. Ләкин кабаланма. Алда озын төн бар, уйлашырбыз, кияү: сездә дә, бездә дә — иртә кичтән хәерлерәк!

Икенче фильм тәмам.

*Ахыры бар.*

# Салих Баттал



## Төрле еллардан

**САЛИХ БАТТАЛ — егерменче гасыр татар әдәбиятының иң мәртәбәле үзенчәлекле, олуг исемнәреннән саналырга хаклы. 1905 елның августында туып, быел гына арабыздан киткән, озын һәм бәрәкәтле гомер иясе Салих Вәзих улы Баттал — безнең чор тормышын бөтен каршылыклары белән тулы чагылдырган күпсанлы шигырьләр, поэмалар, шигъри һәм чәчмә повесть, романнар, драма әсәрләре, публицистика һ. б. авторы.**

**Ул — барыннан да бигрәк — халкыбыз, аның милләт буларак яшәве өчен иң кыен чорларда да каһарманнарча көрәшкән бунтарь, үзе дә легендага әверелгән зур шәхес, милли-иҗтимагый аңыбызның бер өлеше. Бу — бәхәссез. Әле киләчәктә әдипнең гомер һәм иҗат юлы турында тулырак язылыр, төрле китаплар, хезмәтләр мәйданга килер.**

**Без бу санда С. Батталның зур иҗат мирасыннан сайлап, укучыларыбызны аның шигъриятеннән кайбер үрнәкләр белән таныштырабыз.**

### Җүләрең көтә сине!

Ачык тәрәзәмдә гөлләр
Кояшта ялтырыйлар.
Җил иссә күләгәләре
идәндә калтырыйлар.

Шул гына кирәк песигә,—
ул сикереп, ул аунап

уйный, гөл яфракларының
күләгәләрен аулап.

Чигенә дә берәр нәрсә
артына посып тора;
сикерә дә күләгәне
идәнгә кысып тора...

— Эх, җүләр! — дип мин аңарга,—
Йә, тоттыңмы? — дип сорыйм.
Уйнавында дәвам итә...
мин көләм, шундук елыйм.

Песи җүләр. Тик күп уздым
мин җүләрлеген аның:
өч ел юанып яшим тик
күләгәң белән, җаным!

Сагынудан һәр көн саен
син дә янымда минем,
тик күләгә бу күзләрең,
күләгә бөтен җирең!

Күләгәңне миңа биргән
өмет кояшым ерак;
Хат-яфракларың уйнатып
озак торасың, озак.

Көннәр үтәр һәм песи дә
уйнамый башлар,— үсәр.
Мин туктамам, юанырмын.
Мин кеше шул. Мин — җүләр.

## Туган ягыма

Акса инеш чылтырап йә
буылып, дулкынланып;
ничек үтсә дә гомерем —
шатланып, йә моңланып,

безнең инеш суы көмеш
Иделгә кушылып китә,
минем гомер дә гөрелдәп
илемә кушылып китә.

Ләкин нигәдер күңелгә
бик якын туган ягым.
Туган як бер генә шул ул,
икенчесе юк аның.

Ныграк тарта бара ул
мин ерак киткән саен;

яратуым да көчәя
гомерем үткән саен.

Күктә очсам һәр болытта
инеш тамчысын эзлим;
җирдә йөрсәм һәр адымда
синең язмышны күзлим.

Миннән башка инде синдә
яшь буын үсте туып;
чәчемә чал керде инде
ерак постларда торып.

Адашмыйча, синнән алган
гадел компасым белән,
туган ягым, туфрагыңа
инде кайтасым килә...

## Печән чаптым

Печән чаптым. Погон һәм наганлы
киемнәрне салып куйдым да,
бруствердан аэродромга үттем.
Батып барган кояш нурында

Печән чаптым. Өченче ел инде
кулга чалгы тоткан юк иде.
Шундый сагынылган! Әйтерсең лә
Һәр мускулы тәннең, һәр җире

әлегәчә богауланып торып,
хәзер кинәт ирек алдылар!
Ә чәчәкләр гүя киресенчә
ял итәргә ята бардылар...

Онытылмаган. Эш соң онытыламы! —
күзне йомып чабып карадым,
нинди үләннәрнең чабылуын
исләреннән сизә барамын.

Пырхылдады, чалгы астыннан ук
очып чыгып китте бер тургай.
Аны аулап килеп кергән елан
ялтырады киселеп урталай...

## Таң алдыннан

Егетне уятты ана,
караңгы иртә иде:
— Торчы, улым, тәрәзәгә
кемдер чиертә...— диде.

Чыкты егет. Ә анасы:
— Улым,— ди,— кем ул, сөйләш!
Ул — сугышкача әтисе
утыртып киткән миләш.

Таң җиленнән тәрәзәгә
бәреләә тәлгәшләре;
чык коела, әйтерсең лә
миләшнең күз яшьләре...

Кирәсе килми егетнең
бу хәлләрне әйтергә...
Их, керер иде өйгә ул
әтисе белән бергә!

Тетрәнеп китә егет
тәлгәш бәрелгән саен;
күк күкрәү кебек тоя ул
кыштырдауларын аның.

*

Торды анасы да,
чыкты...
Ә егет күптән инде
илнең көчен тапкырларга
эшенә киткән иде...

## Кар катламнары

Тышта, өйнең ишек кырында
бер квадрат метр урында
катлам артлы катлам эри кар.
Һәр катламның аерым сере бар.

*

Язгы кояш көлеп карады:
эрегән кар өсте каралды.
Завод корымын да, көлен дә
күрдем шунда ишек төбендә.
Директорын күрше заводның
уйлап, шунда бераз мавыктым.

*

Иртәгесен иртә торгач та
ярдәм кулын суздым кояшка:
сөбереп аттым корым катламын,—
яңа эзләр күрә башладым.
Искә төште нәни ботинка:
аны киеп йөри Катенька.
Күн букчасы аның кулында —
беренче кыш мәктәп юлында.

*

Көннәр үтте, катлам эреде;
киң, сузынкы бер эз күренде —
авто тәгәрмәче сырлаган.
Күреп калган идек бер заман —
гөр-гөр итеп дәү бер машина
туктап торды ишек каршында.
Өй җиһазы аңар төялде.
Һәм ул яңа йортка юнәлде:
зур семьялы безнең күршеләр
иркен торакларга күчтеләр.

*


Менә соңгы катлам эреде.—
Ул иң элек яуган кар иде.
Табып алдым зур бер сәдәпне.
Хәтерләдем: төнге сәгатьне
бер кыз торды шунда елышып,
сөйгәненең кулын елытып,
куеп йөрәгенең өстенә,
күкрәгенә — пальто эченә.
Пальтосыннан теге сәдәп тә
өзелгәндер шушы сәгатьтә.
Ә үзләре инде кавышкан —
бүген кайтты алар загстан.
Мин аларны котлап баш ордым
Һәм сәдәпне кызга тапшырдым.

*

Кар эреде. Җитә инде май.
Поэзиягә илем шундый бай! —
язып бетереп булмый шигырьдә
бер квадрат метр җирен дә...



# ПУБЛИЦИСТИКА



ТУФАН МИҢНУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

## КАМА ҖИЛЛӘРЕ ЧЫНЫКТЫРГАН ЕГЕТ

Гомер буе үз күләгәсеннән куркып яшәүче, күңеленнән тезләнеп иҗат итүче язучылар да була. Иманлы каләм тотарга язмаган мондый әдипләр, җәмгыятьнең флюгеры кайсы якка борылса — шуңа карап тиз генә үз төсен үзгәртәләр. Кыю, үз фикерен нәкъ вакытында ярып сала белүчеләр бармы, дигәндә, шундыйлардан һич икеләнмичә, яраткан драматургыбыз Туфан Миңнуллин исемен атар идек.

Ул үзенең иҗат дәверендә берничә дистә драма әсәрләре язды, татар сәхнәсен күтәреп барды, халкыбыз күңеленә хуш килерлек онытылмас каһарманнар тудырды. Һәм алар, тулы бер галерея булып, әдәби дәвер түреннән лаеклы урын алырлык. Пугачев явы чорында, империянең нигез ташын тетрәткән татарлар арасында нинди генә батырлар булмаган. Шундыйларның берсен — Канкай углы Бәхтиярне драматург, сәхнәгә мендереп, кабатланмас образ тудырды.

Муса Җәлилгә багышлап нинди генә жанрда әсәрләр язылмаган. Ә Туфан Җәлиле — башка... Аның «Моңлы бер җыр» пьесасында Җәлил һәм аның көрәштәшләре, батыр итеп кенә түгел, ә кеше җанлы итеп сурәтләнә.

Әсәрләрдәге төп каһарманның кайсысын атасаң да тере кеше, үзенчәлекле холыкка ия шәхес күз алдына килә, гүя алар безнең арада яшәгән. Миләүшә, Диләфрүз, Мәрвән, атаклы ат карагы Шәкүр һәм башкалар. Шуларның бөтенесен 'үз рухи канаты астына җыйган Әлмәндәр карт — татарның үзе шикелле мәңге үлемсез җан, баскычлардан елмаеп, күк катларына менеп бара...

Г. Камал исемендәге татар Дәүләт академия театрының баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов, һәм үз сабакташлары — гаҗәеп сәләтле артистлар төркеме белән берлектә Туфан Миңнуллин әнә шулай кабатланмас әсәрләр тудырды, бүген дә каләмен үткенләп тора.

Аның пьесалары үзбәк, мари, башкорт, рус, калмык, лезгин, лак, дагестан сәхнәләрендә уйналды, күп телләргә тәрҗемә ителде. Тормышчан, көтелмәгән вакыйгалар эчендә дә кеше булып калалган мавыктыргыч образлары Туфанның башка милләт тамашачыларының да йөрәген яулый алды.

Кама Тамагы районының Мәрәт Хуҗа авылында туып үскән Туфан Габдулла улы Миңнуллинга 25 августта 60 яшь тула. Кайчандыр артист булырга хыялланып, Мәскәүнең М. С. Щепкин исемендәге театр училищесын бетергән бөдрә чәчле егет бүген инде олыгаю ызанына чыкты. Т. Мин дип үзе өчен генә шигырьләр язып йөргән, көлкеле нәни хикәяләрдән башлаган гөрелдек тавышлы Туфан өч дистә ел эчендә зур

иҗат галәме тудырган драматург булуга ирештe.

Ул — Татарстанның Г. Тукай, М. Җәлил исемендәге, РСФСРның К. Станиславский исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты.

Туфанга үҗәтлек, тырышлык тумыштан бирелгән, ул аны үзенең күпьеллык иҗаты һәм яшәү рәвеше белән раслап килә. Халык депутаты буларак, тормышның эчендә кайнап, кырыс чынбарлыктан илһам ала.

Туфан ага, Сезгә — корычтай сәламәтлек телибез, иҗат чишмәләрегез күптармаклы булып, ургылып торсын.

Кәгазь — дәрья, каләм — көймә, бөятеңне әзерлә!

**Редакциядә эшләүче каләмдәшләрең.**

■

## Аны халык ярата

Туфан Миңнуллин — гаҗәп талант иясе. Берсеннән-берсе оста, талантлы сәхнә әсәрләрен коеп кына куя, коеп кына тора. Ходай аңа оригиналь фикерләү сәләтен, тормышны өйрәнә белү тырышлыгын, аны чагылдыру осталыгын бер дә кызганмый биргән.

Заманыбызның, тормышның кайсы ягына гына кагылмасын, Туфан аны үзенчә күрә, үзенчә бәяли һәм халык күңеленең иң нечкә кылларын тибрәндерерлек итеп сурәтли. Аның һәр әсәрендә әллә никадәр табыш бар. «Әлдермештән Әлмәндәр», «Моңлы бер җыр», «Үзебез сайлаган язмыш», «Әниләр һәм бәбиләр», «Гөр-гөри кияүләре» һәм башка бик күп спектакльләр — болар бит татар тормышының энциклопедиясе. «Әлдермештән Әлмәндәр», гомумән, мәңгелек, классик әсәр.

Туфан, икенче яктан, татар сәхнә сәнгатенең иң бай, иң мул, иң үзенчәлекле иҗат чыганагы. Безнең театр сәнгатен ул әйдәп бара, дисәм дә һич артык булмас. Галиәсгар Камал, Мирхәйдәр Фәйзи, Кәрим Тинчуриннар традицияләре бүген Туфан әсәрләрендә дәвам итә, үсә. Дөньяда яшәүнең тирән фәлсәфи мәгънәсен Туфан Миңнуллин әхлакый чисталык, пакь намус белән бәйләп, эмоциональ-тәэсирле, үтемле, гыйбрәтле, тормышчан итеп тасвирлый.

Туфан Миңнуллин — бәхетле талант иясе, чөнки халык аны күптән инде үз итте, яратты һәм ярата. Мин аңа тагын да иҗади уңышлар, озын гомер телим.

Минтимер ШӘЙМИЕВ,
*Татарстан Президенты.*

■

## Чакма таш

Туфан Миңнуллин белән безнең тормыштагы мөнәсәбәтләр төрлечә булды: без бер-беребезне яраттык, Язучылар берлегенең арбасын бергәләп тарттык. Булды бер-беребезне өнәмәгән чакларыбыз да. Алары объектив сәбәпләрдән дә, субъектив сәбәпләрдән дә килеп чыкты.

Әмма иҗат мәсьәләсендә мин Туфанны беренче әсәрләреннән үк үз күрдем. Табигать биргән гомерлек таланты, чәч пәкесе кебек үткен, образлы теле, сәхнәне бик яхшы тоя белүе белән ул татар драматургиясен СССР дигән бөек илдә держава аренасына кадәр алып чыга алды. Җанга бер очрашуда урнашып кала торган милли образлары белән ул Кәрим Тинчуриннар мәктәбен яңа шартларда үстерә, камилләштерә барды. Бу нисбәттән аның туксан яшьлек Әлмәндәре — мәңгелек. Аның кыю каләме аркылы Канкай батырлар, Тукайлар, Җәлилләр дөньяга чыкты, гапгади җир кешеләре, хезмәтчәннәр зирәк акыллары белән тамашачыларны таң калдырды.



Рәсемдә *(сулдан — уңга)*: Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Туфан Миңнуллин.

Минем үземне таң калдырган нәрсә — Туфан Миңнуллинның үз холкы. Мин аны чакма ташка тиңләр идем. Чакма ташка игәү белән суксаң, очкын сибелә. Туфанның чакма таш каләменә юлыккан тормыш материалыннан да дөрләп-дөрләп ут сибелә. Туган җиренә булган бик олы мәхәббәте — патриотлыгы да, туып-үскән авылын тергезүе дә, мәчетләр, һәйкәлләр салдыруы да — барысы да аны яратырга, хөрмәт итәргә, утыз ел эчендә ул иҗат иткән кырыктан артык сәхнә әсәре, аларның беркайчан да бер-берсен кабатламавы, аның усал холкын өнәп бетермәүчеләрне дә аның алдында, аның сәнгате каршында ихтирам белән баш иярго мәҗбүр итә. Татар драматургиясен Туфан Миңнуллин кебек фидакарь талантлар гына алга илтәчәк дип авыз тутырып әйтергә мөмкин.

Гариф АХУНОВ.

■

## Әлмәндәр гомере телим

**70** нче елларда Язучылар берлегендә «Тынгысыз каләм» исемле бик тә кызыклы стена газетасы чыга иде. Мөхәррире Фаил Шәфигуллин аны чын мәгънәсендә әдәби-юмористик газетага әйләндерде. Арттырып әйтмим, ул елларда язучылар өчен аннан да популяррак газета булмагандыр. Фаил, берничә эпиграмма язуымны үтенеп, миңа да мөрәҗәгать итте. Туфан Миңнуллинга багышланганы менә шундый иде:

«Ат карагы»н язганчыга кадәр
Шагыйрь Туфан атын урлаган.
Тик, Миңнуллин бәгърем, җанкисәгем,
Сине карак диеп хурламам.

Бу эпиграммага мин игътибар бирмәдем, аны язганны да күптән оныткан идем инде. Соңгы елларда Хәсән ага Туфанның үзеннән соң чыккан «Гүзәл гамь» китабында шушы дүртьюллыкны күргәч, аптырап калдым. Төзүчеләр моны ялгышып, Хәсән ага шигыре итеп тәкъдим иткәннәр. Минем фаразымча, остазыбыз стена газетасыннан эпиграмманы укыган да, күчереп алган һәм шигырьләре арасы-

на салып куйган. Димәк, Туфан энесенә һәм аның пьесаларына аеруча җылы караган шагыйрьне әлеге эпиграмма җәләп иткән.

Ә Туфан Миңнуллинга килгәндә исә, ул, чыннан да, шагыйрь Туфан атын урларга барырлык батыр егет булып чыкты. Чакырса, мин дә барыр идем, әлбәттә... Әле дә, алтмыш яшендә дә, ат кына түгел, кыз урларга барырлык егет әле ул.

Туфандагы драматургик талантым булса, эпиграмма гына түгел, аның үзе турында бер искиткеч драма яки комедия язар идем мин. Каһарманы, Тинчуриннарга тиң олы таланты... Әмма үзе турында үзе язгандыр инде ул. Әлмәндәр аның үзе түгелдер дип кем әйтә ала?!

Туфанның үз атын урларлык яшь талантлар үсеп килүенә дә сөеник. Хәзерге яшьләр инде ат урлап вакланмаслар, авылдагы тракторына да кагылмаслар, әдәбиятыбызны бәхетле иткән ат-исемен генә урларлар әле дигән өметтә калыйк...


Илдар ЮЗЕЕВ.

■

## Ихласлык

Кешенең максаты — гүзәллеккә ирешү. Әмма матурлыкны кушучка тотуда, күңел мөнбәренә оялатуда кеше уңганлыкка, намуслылыкка, игелеклелеккә һәм башка әйбәт сыйфатларга ия булырга тиеш. Бу хәл, әлбәттә, исбатлауны таләп итми торган хакыйкать. Шулай да юньле сыйфатларның дустанә җитәкләшүе әлеге олуг максатка-мәсләккә ирешүдә беренче шарт булуын гел искәрергә мәҗбүр адәм баласы. Шундый сыйфатлар арасында берсе башкаларына аеруча йогышлыдыр, минемчә. Ул — ихласлык.

Туфан Миңнуллинның ихласлыгы башка яхшы якларыннан — эшчәнлектән, дуслыкта тугрылыктан, тәвәккәллектән һәм башкалардан — калкурак булып күренә миңа. Әйе, язганында да, бүтән гамәлендә дә ихлас ул. Укучылар һәм тамашачылар аның әсәрләрен тормышны эчкерсез чагылдырулары өчен ихластан кабул итәләр. Әйе, язган һәр юлында риясыз Туфан. Моны, топ хезмәте җимешләре булган күп санлы пьесаларының һәркайсына аерым тукталмастан, аның «Көндәлек дәфтәреннән» җыелмасыннан парча-рисаләләрендә дә ачык күрәсең. Шунысын да искәртик, Туфан Миңнуллинның уйланулары-күзәтүләре турында шундый әсәрләре җөмһүрият газета-журналларында унбиш елдан артык басыла килә, күңелеңдәге ачыктан-ачык — ихластан — язу тыелган чаклардан бирле ягъни.



Рәсемдә: Туфан Миңнуллин, режиссер Марсель Сәлимҗанов.

Әйс, бүтән гамәлләрендә дә ихлас Туфан. Күңелгә кер тутырып, кешеләргә яхшылык эшләргә маташуның кылану икәнлеген, монафикълыгын, ихласлыктан мәхрүм гамәлләрнең игелек һәм изгелек саналмасын, ахыр килеп, кабул кылынмасын белә ул. Әгәр Туфан ялгышса (хаталану адәм баласына шулай ук хас), бу хакта дусларына, иш-иптәшләренә, хәтта танышы булмаган кешеләргә дә, яшермичә сөйли. Моның өчен исә ихтыярың нык, егетлегең кодрәтле булуы кирәк. Һәм моның исеме — тәүбә! Һәм Туфан гүзәллеккә ялгышыңны танмыйча — тәүбә итмичә, ягъни имансыз килеш, ирешеп булмавын күңеленә ихластан сеңдергән. Шуңа күрә Туфан халыкны үз итә, шуңа күрә халык Туфанны үз итә.

Иманлы баһадирлыгың гел юлдаш булсын сиңа, Туфан туган!

Мәгъсум ХУҖИН.

■

# Югалмас сүз[1]

*Хәсән Туфанга һәм аның әдәби энесе*
*Туфан Миңнуллинга*

Мәңгелеккә хөкем чыгаргандай
Ялтырады алтын күзлекләр —
«Туфан — искергән сүз» диеп хәтта
Әйттерделәр алар сүзлектән.

Тавыш эчкә киткән кеше сыман
Булды чорның сырхау чаклары...
Әмма халык җанга кадерлесен
Хәтер чормасында саклады.

Күпме авазларны йотты микән
Сикәлтәле чорның юллары?
Нидер сизгән сыман, бер авылда
Туфан атлы малай елады...

Бер сәбәпсез ярсый бит нарасый,
Хәерлегә булсын, диделәр.
Белмәделәр, адаш абыйсының
Эчкә йоткан яше иде лә...

Үсә төшкәч, малай көннәр буе
Кыр-болынны күпме гизмәде.
Борчылудан гаҗизләнгән ана
«Туфан кайт», дип көн дә эзләде...

Бала Туфан кичен кайта иде,
Борчулы өн кире кайтмады —
Офыкларны үтте юксынып ул,
Урады бик ерак якларны;

«Туфан кайт», дип кабатлады урман —
Зур Туфанны эзли кайтаваз!
Көткән җырлар сыман каңгылдашып
Ничәнче кат илгә кайта яз...

Бала Туфан үсте Тау ягында,
Тиешлесен инде белде ул —

---

[1] Шигырь Т. Миңнуллинның 50 яшенә язылган иде.

«Туфан-искергән» дип үртәгәндә
Сер бирмәде, бары көлде ул.

Бер сәбәпсез көлә бит бу бала,
Хәерлегә булсын, диделәр.
Хәсән Туфан кайткан дигән сүзләр
Газеталарны узып килделәр!

Бер сүзе дә югалмасын диеп,
Туган телгә кайтты җан атып —
Сүз-намусны, җыр-вөҗданны мәңге
Искермәслек итеп яңартып.

Очрашыла икән исән булгач,
Озын юллар да ул тар икән.
Иңнән кагып әйтте олы Туфан:
— Әдәбиятта энем бар икән!

Яшь Туфанның елгыр, шаян чагы,
Ул үзенчә булмас дисеңме:
— Рәхмәт, — диде адаш абыйсына,—
Акладыгыз минем исемне!

Ә чал шагыйрь узган бар юлларын,
Бар моңнарын җыйган шикелле,
Җитди иде. Олы миссиясен
Шул мизгелдә тойган шикелле...

...Олы Туфан үе безгә калды,
Киләчәккә китте эзләре...
«Югалмагыз...» — дигән васыять белән
Сынап карый сизгер күзләре.

Сүз-намусны, җыр-вөҗданны инде
Энеләргә хәзер саклыйсы.
Ул аклады халык ышанычын,
Безгә әле, безгә аклыйсы...

Шәүкәт ГАЛИЕВ.
16 ноябрь, 1985 ел.

■

## Аның хатыны булу авырмы?

Туфан инде укыганда ук үзен бездән ун башка өстен итеп күрсәтә белде. Әгәр дә Туфан артист булса, үзен драматургиядә шуның кадәр күрсәтә алмас иде. Чөнки сәхнә икенче өлкәгә куәчне гафу итми. Сәхнә аны «үтерер» иде кебек. Театрдан китү аның бәхете булды. Ләкин шул ук вакытта актер булса, ул үз теләге белән театрдан китмәс тә иде. Аңа, билгеле, үзенең сәбәпләре булды. Артык туры сүзле, үз фикерен һәрвакытта да ярып әйтә торган кешегә җылы урынга җайлашу, ай-һай, җиңел түгел шул.



Рәсемдә: Туфан Миңнуллин хатыны Нәҗибә Ихсанова һәм оныгы белән.

«Драматург Туфан Миңнуллин хатыны булу авырмы?» — дип миңа еш кына сорау бирәләр. Чынлап та, Туфансыз мин театрда ничек яшәгән булыр идем икән? Мин һәрвакыт очраклы рольләрдә үстем. Үземнең көчем, тырышлыгым аркасында үстем. Дөрес, мин Туфан драматургиясендә бик күп рольләр башкардым. Бәлки ул минем өстәмә бәхетем генәдер. Туфанның әсәрләрендә уйнау миңа икеләтә авыр. Чөнки ул әсәр Туфанның башында туганда ук, аның язылу процессы минем аша узган була.

Ике иҗат кешесенә бер түбә астында тормыш итү җиңел бирелми. Шулай да без язмышыбыздан канәгать. Кызыбыз Әлфия педагогия университетында математика укыта. Ике оныгыбыз бар. Туфанның язылачак әсәрләренә алар да илһам бирә.

Нәҗибә ИХСАНОВА,
*Татарстанның халык артисткасы.*

■

## Сабакташ

Шактый гына олы яшьтәгеләрнең: «Карале, гомер узып та бара, ә яшәлмәгән дә», — дигән сүзләрен еш ишетергә туры килә. Чынлап та, гомер буе бер генә минутларын да әрәмгә уздырмаган кешеләр генә шулай әйтә торгандыр. Иҗат кешесе бигрәк тә. Баксаң, безнең Туфаныбыз да шундый яшькә килеп җиткән икән. Ә бит уйлап карасаң, әле яңа гына Щепкин исемендәге Театр училищесына укырга кергән идек лабаса. Күптән түгел генә Ильскаялар, Әбҗәлиловлар, Уразиковлар тирәсендә буталып йөргән кебек идек. Ә гомер уза... Безнең Туфан гомумән яше белән дә, акылы белән дә безнең күбебездән өстенрәк иде.

Укыган чорның бер кызыклы өзеге искә төшә: философиядән Илья Михайлович Бычков дигән бик шәп укытучыбыз бар иде. Безнең белән янәшә курста укучы рус курсы өчен шушы укытучыга имтихан тапшыруы бер газап иде. Тегеләр берни

белми, күрәсең, белергә дә бик теләмиләр. Бер вакытны Илья Михайлович, үзе арганнан соң, тегеләрдән имтихан алырга Туфанны кертеп утырта «Ал шулардан имтихан!» — ди. Үзе Туфанны аудиториядә калдырып чыгып китә. Һәм ала тегеләрдән Туфан имтиханны... Карале, бу урыс курсы бигрәк надан икән, берни белмиләр, дип сөйләнгәнне әле дә хәтердә. Укыган вакытта ук ул яза башлады. Маяковскийның «Мунча» дигән әсәрен Миргалим Харисов белән икәүләп тәрҗемә иткәннәр иде. Ул безнең диплом спектакле булды. Менә болар барысы аның күпкырлы талант иясе икәнлеген күрсәтә иде.

Әгәр дә без бүген 1961 еллардан башлап, татар драматургиясеннән Туфан Миңнуллинны алып торсак, ул нинди ярлыланыр иде. Мин һич кенә дә арттырмыйча әйтә алам: иң зур уңышлы рольләрем Туфан пьесаларында булды. Драма артисты өчен әйбәт, тирән характерлы образлар кирәк. Туфанның «Моңлы бер җыр»ы Муса образына бөтенләй яңача карарга мөмкинлек бирде. Һәм шулай ук башка бик күп пьесалары.

Туфанның иҗатына анализ ясый башласам, бик озак вакыт кирәк булыр иде, анысын театр белгечләре ясарлар. Мин Туфанга иҗат уңышлары белән бергә исәнлек-саулык телим, әле күп еллар без артистларны режиссерларны тәмле ризык, ягъни, шәп пьесалар белән тукландырып торсын иде.

Ринат ТАҖЕТДИНОВ,
*РСФСРның һәм Татарстанның халык артисты.*

■

## «Нихәл, таз?..»

Әзрәк күренми торса, без аны сагына башлыйбыз. Кызык бит, ә! Кайбер кешеләрне айлар-еллар буе бер күрмәсәң дә, исеңә төшермисең. Дус-ишләренең сине юксынып көтүе, синең дөньяда барлыгыңны тоюы, шуңа сөенеп яшәве — зур бәхеттер ул. Туфан абый белә-сизә микән шушы бәхетен? Мөгаен, беләдер, сизәдер. Юкса ул да безне — «Идел» журналында эшләүче яшь каләмдәшләрен сагынып килер идемени?..

Без аның көр һәм дәртле тавышын урамнан ук ишетәбез. Ул тавыш тәрәзәдән ургылып керә, редакция бүлмәләренә тарала, диварларга бәрелеп чыңлап ала.

«Нихәл, таз?!», — бу Туфан абыйның якын күргән кешеләре белән үз итеп, яратып күрешүе. Бервакыт мин үпкәләп: «Нишләп мин таз булыйм инде», — дигәч, драматург: «Син җегет кеше, җегетләр белән мин шулай исәнләшәм», — диде.

Гадәттә редакциядә Туфан абый озак юанмый. Аны каядыр мең төрле мәшәкать сагалый. Ләкин ун-унбиш минут кына утырса да, ул һәрберебезнең хәл-әхвәлен сорашырга өлгерә, нәрсә язасыз дип төпченә, тәмәке пыскыткан Ркаил Зәйдулланы аз язасың дип орышып ташлый. Ә безгә аның тиргәвен тыңлавы да рәхәт. Чөнки Туфан абыйның һәр сүзе ихлас була. Шәхсән, минем үземә аның иң охшаган сыйфатлары да шул: төчеләнмәү, ялагайланмау, алдашмау. Әйтик, минем яңа әсәрем басыла. Әсәр турында иң беренче Туфан абыйның фикерен сорыйм. Хәтерен калдырмыйм дип урынсызга мактаганы яки үсенмәсен әле дип хаксыз тәнкыйтьләгәнен хәтерләмим. Ул барны бар, юкны юк дип, өздереп сөйләшә.

«Идел»гә Туфан абый килеп киткән көнне безнең һәммәбезнең дә кәеф күтәрелә, редакция җанлана, яшәрә. Ул күңел түреннән нинидер бер якты нур сирпеп калдыра ахрысы. Шуңа күрә без аны сагынабыз да бугай. Өч көн күренмәсә: «Туфан абый кайда икән?» дип юксынырга тотынабыз.

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА.

■

# Кош хокукы

*Туфан Миңнуллинга*

Хакны әйтергә дә хокук кирәк.
Әйтим дисәң ярып турысын,
«Птичье право» дигән гыйбарәсе
Искә килеп төшә урысның.

Һава ярып әнә кошлар оча,
Кош тоткандай яна күзләрең.
Күкне иңләп очкан кошка баксаң,
Искә килеп төшә үз хәлең.

Үз хәлеңне күршеләрдән сора —
Ут-күршеләр яши күршеңдә...
Хакны әйтергә дә хокук кирәк,
Кош хокукы кирәк кешегә.

Ут-күршеләр әнә ут салганнар
Тарихыңа синең, телеңә.
Ничә гасыр тарих пыскып ята,—
Казынабыз бүген көлендә.

Хакны әйтергә дә хокук кирәк.
Хакны әйтүчеләр илдә бер.
Кошлар хокукына ия җаннар
Кеше хокукына иядер.

Хаклылар да, хаксызлар да сыйган
Империя дигән калыпка.
Империя калыпларын ватып,
Хөр мәмләкәт төзи халыклар.

Ирек яуларга да хокук кирәк.
Сорап алып булмый ирекне.
Кошлар хокукына ия халык
Бәйсез халык — димәк, ирекле!

Һава ярып әнә кошлар оча,
Син очасың бары төшеңдә.
Кеше булырга да хокук кирәк,
Кош хокукы кирәк кешегә.

Газинур МОРАТ

# Туфан Миңнуллин

## «КЫЗЫЛ ТЫШЛЫ ДӘФТӘР»ДӘН

### ТӨНГЕ УЙЛАР

Кичтән соң ятсам да, төнге сәгать икеләрдә йокым туеп уяндым. Мондый чакта мин, гадәттә, укыйм. Бу юлы нигәдер укыйсы да килмәде. Сергач агайлары әйтмешли, потолокка бактым да каттым. Баш фәлсәфи уйларга көйләнгән булып чыкты. Үзенең көче җитмәслек нәрсәләр турында уйлый. Дөньяда яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә, янәмәсе. Гомумән, нәрсә ул яшәү?

Әгәр дә мин бу якты дөньяга үз теләгем белән килгән булсам, ул чакта аңлашыла — мин яшәргә килгән, нәрсәнедер үзгәртергә килгән, минем үземә генә билгеле максатым булган. Әмма мине бу дөньяга үземнән сорап-нитеп тормыйча тудырганнар. Яшәсен дигәннәр. Ничек яшәргә? Әлбәттә, яшәүнең әлифбасын өйрәткәннәр. Калганын тормыш үзе өйрәтер, дигәннәрдер. Менә тормыш үзенекен эшләде — мин алтмышка җитеп килүче «мыжик баласы», яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә, дип уйланып ятам.

Бәлки аның мәгънәсе юктыр, аны эзләп интекмәскә кирәктер? Ходай биргән гомернең ахыры җиткәнен тыныч кына көтәргәдер. Ике кулны кесәгә тыгып, уңга-сулга караңгалап, сызгырып кына йөрергәдер? Алай да килеп чыкмый. Күңел барыбер эзләнә. Нидер эзли. Ул канәгать түгел. Әлегә хәтле яшәүеннән дә, бүгенгесеннән дә канәгать түгел, киләчәге өчен борчыла.

Кайчандыр философия дигән фәнне укытканнар иде. (Яшәргә өйрәтүләре булгандыр инде.) Яшәешнең төрле-төрле законнары бар иде бугай анда. Каракаршы көчләрнең көрәше дигән нәрсә дә чагыла иде шикелле. Шуннан чыгып, тормыш ул туктаусыз көрәштән тора, дип әйтәләр иде. Баштарак моның нәрсә икәнен аңлап тә бетермәгәнбездер. Яшьлек бит һәртөрле кануннарга буйсынырга яратмый. Яшьлекнең үз кагыйдәләре бар. Дөньяда яши-яши күп нәрсәне аңлыйсың, тормыш башыңа суга-суга төшендерә.

Әйе, тормыш туктаусыз көрәштән тора. Көрәш булгач, анда кемдер яки нидер җиңәргә һәм кемдер яки нидер җиңелергә тиештер.

Безне яшәргә өйрәткәндә кайсы якка күбрәк басым ясап өйрәттеләр соң? Җиңәргәме, җиңелергәме? Бер караганда ахмаграк сорау инде: ничек инде ул җиңелергә өйрәтү? Җиңәргә — анысы аңлашыла. Җиңелергә нигә өйрәтергә? Өйрәнмичә дә җиңеләсең ул.

Уйлап-уйлап торам да алай түгел икән шул. Җиңелергә бик шәпләп өйрәтергә кирәк икән. Аңа өйрәнүе җиңәргә өйрәнүдән дә читенрәктер.

Спортның кайбер төрләрендә егылырга өйрәтәләр. Егыла белеп егылырга. Әгәр дә җайсыз туры килеп егылырга туры килсә, син егыла белергә тиешсең. Белсәң, егылганнан соң имгәнмисең, янадан торып китәсең дә янадан ярышка кушыласың. Тормышта да шулай. Җиңелә белеп җиңелсәң, тормыш сине юл кырыена болгап ыргытса да син үлмичә, имгәнмичә торып китәсең, яңадан көрәшә башлыйсың. Җиңелә белмәсәң, бетәсең.

Әзме булды бездә җиңелә белмичә харап булганнар. Әнинең, җылап өйгә кайтасы булма, дип әйтүләре шул җиңелүгә өйрәтүе дә булгандыр. Югыйсә, борынымны канатып өйгә кайткан саен әни минем борынымны канаткан малайны кыйнап кайткан булса, гомерем бу җылак булып кала идем. Болай әле ярыйсы — борынымны канатсалар, читкә китебрәк канны туктатам да, нишләргә кирәген уйлыйм: мине рәнҗеткәннең, җаен туры китереп, үз борынын канатыргамы, әллә вакланмаскамы, әллә инде борынымны теләсә кая тыгып йөрмәскәме, йә булмаса борынны төрле ударлардан сакларга өйрәнергәме, яки... Кыскасы, җиңелергә өйрәнергә. Ә җиңелергә өйрәнү җиңүгә илтә, һәрбер җиңү — ул инде яшәү.

Кара син, төн уртасында уянып, уйланып ятуның да файдасы бар икән ич! Көрәш аша яшәүнең мәгънәсенә төшенә барасың икән, дөнья ул чаклы күңелсез дә түгел икән.

Ярый монысы да булды. Яшәүнең мәгънәсе тагын нәрсәдә? Бәлки, мәхәббәт һәм нәфрәттәдер? Шушы капма-каршы ике хис булганда гына кеше яшидер. Кешедә матурлыкка соклану, ярату хисләре булмаса, яки ямьсезлек белән очраш-

канда нәфрәт хисе тумаса, кешенең яшәве корсак тутыру өчен көн уздыру гына буладыр. Хайван сыман дип әйтмәкче идем дә, дөрес үк булмас кебек тоелды. Кайбер хайваннарда да хәтта матурлык белән ямьсезлекне аеру инстинкты бар.

Яшәүнең мәгънәсе турында уйланганда мәңгелек һәм мизгел дигән төшенчәләр дә бар бит әле. Без бу дөньяга мәңгелеккә килгәнме, әллә вакытлыча гынамы? Һәркемнә үлем көтә. Әйе, парадокс, әмма хакыйкать — кеше үләр өчен туа. Ул чакта нигә туып торырга? Әмма әлеге дә баягы — тудыралар. Тугач яшәргә кирәк. Ничек итеп? Мәңгелеккә килгән кебекме? Бик авыр сорау. Бәлки, вакытлыча гына килгәнеңне онытмыйча мәңгелеккә килгән сыман яшәргәдер? Һәрхәлдә, кылган эшләрең мәңгелеккә килгән затныкы кебек булырга тиештер.

Хәтердә: бервакыт минем әнинең өлкән абыйсы (яшь бабай) үзләренең капка төбендә колхозның трактор чанасына имән табан юна иде. Ул чакта аңа 84 яшь иде инде.

Яшь бабай янына бер исерек килде дә:

— Нәрсә, Гата бабай, мәңгелеккә килдең мәллә, эшлисең дә эшлисең,— дип ыржайды.

— Мәңгелеккә,— диде яшь бабай,— мин ясаган чана табаны мин бүген үлсәм дә ике кыш йөриячәк, ике ел мине искә алачаклар. Син бүген үлсәң, иртәгә онытачаклар, чөнки син вакытлыча гына яшисең,— диде. «Вакытлыча» дигән сүз минем хәтергә шунда сеңеп калган иде. Яшәү турында уйланганда һәрчак яшь бабай искә төшә.

Без бүген үткән заманны сүгәбез. Әшәке дибез. Шулайдыр. Чөнки аның иң начарлыгы — кешене вакытлыча гына яшәргә өйрәтеп калдыруында. Авылларда, шәһәрләрдә вакытлыча гына яшәүчеләр күбәйде. «Бүген тамагым туйса, шул җиткән»,— психологиясе кешенең геннарына үтеп керә башлады. Җир өстендә ике аяклы дуңгызлыклар туктаусыз бөтерелеп йөри. Төпләнә алмыйлар кешеләр. Төпләнеп яши башлар иде, ышанычы юк — куптарып алулары ихтимал. Хәтта тулы бер халыкларны туган җирләреннән куптарып алып ыргыталар. Шуның нәтиҗәсендә анда качак, монда качак.

Вакытлыча гына яшәү — куркыныч. Мең рәхмәт бабайларга, алар мине вакытлыча яшәргә өйрәтмәделәр.

Бервакыт шулай өлкәннәр белән бергә Идел аръягындагы болынга печән чабарга чыктык. Олылар чалгыларын алып эшкә керештеләр, без бала-чагаларга төнгелеккә куыш-шалашлар ясарга куштылар. Тиз-тиз генә, аннан-моннан корыштырдык та куышларны болын күлендә су коенырга чаптык.

Ашка туктагач, өлкәннәрнең дә өлкәне бер абзый безнең куышларны карады да:

— Нинди карга оясы корып куйдыгыз монда?— дип эшебезне туздырып ташлады.

Без телләштек:

— Ике көннән барыбер өйгә кайтыла ич,— дидек.

— Алайса, ике көннән соң авылга кайткач ашарсыз,— дип безне әбәтсез калдырдылар. Бик рәнҗедек. Шулай да кич җиткәнче шалашларны җиренә җиткереп эшләдек.

Кичен теге карт безнең аркаларыбыздан сөеп чыкты.

— Менә шулай кирәк,— ике көнгә генә булса да ике ел торырлык итеп ясагыз, оланнар. Адәм баласының гомере өчен ике көн аз түгел ул,— диде.

Олыгайган саен ул сүзләрнең мәгънәсе тирәнәя бара — шуңа көннән-көн ныграк төшенәм: ике көн бик күп икән ул, вакытлыча гына яшәп аны әрәм итү гөнаһ икән.

Уйлар, уйлар... Уйлаган саен уй туа, уй туган саен сораулар арта. Чыннан да, нәрсәдә соң яшәүнең мәгънәсе?

*1993.*

## ФИЛОСОФ

Яшәү мәгънәсе турында уйланганда бер вакыйга искә төште әле. Аны аерым язып куярга кирәктер.

— Нихәл, Туфан энекәш. Йә-йә, кулыңны иренеп кенә сузма, әйбәтләп күреш. Елмайганыңнан күреп торам, бик үк күрешәсең килми инде минем

белән. Исерек дисең инде мине. Ялгышасың, бик нык ялгышасың, Туфан энекәш, исерек түгел мин. Салган — анысы факты! Бәлки, бераз артыграк киткәндер — анысы да факты — кем белгән аның чамасын. Чамасын аның син дә белмисең. Сиңа чаклы да белмәгәннәр, синнән соң дә белмәячәкләр. Әгәр дә бөтен нәрсә бу дөньяда чама белән үлчәп кенә бирелсә, яшәүнең кирәге калмый.

Син мәхәббәтнең нәрсә икәнен беләсеңме? Ярый, беләсең дип алыйк. Менә син бер кызга гашыйк булдың ди, әйеме? Үлеп гашыйк булдың ди. Ә сиңа әйтсәләр, чама белән генә, Туфан иптәш, гашыйк бул, дисәләр? Үлчәп кенә бирсәләр? Булмый... Булмый ул чамасына туры китереп. Син елмайма. Калхузник дигәч тә, җүләргә санама син мине. Мин синең сыман укымасам да, тукыган.

Минем бер хикмәтле җырым бар. Урысча җыр ул. Шул җырны җырласам, хатын әйтә, булуың җиткән, йокла, ди.

Аңламый, аңламый томана. Анысы дөрес — булуым җиткән. Ләкин дә мине нигә йоклатырга? Йоклатма син мине. Булуым җиткән икән, димәк ки, мин өлгергән. Әгәр дә мин өлгергән икән, нишләргә кирәк? Йоклатмыйча мине тыңларга кирәк. Туктале, бу булуы җиткән шайтанниндирәк кихмәтле сүз әйтер икән, дип тыңларга кирәк. Кихмәт дигән сүзнең ни икәнен беләсеңме син, Туфан энекәш? Хикмәт дигән сүз ул. Мин аны юри кихмәт дип әйтәм. Алай дип әйтсәң, икенче төрлерәк булып китә сүз, саллырак яңгырый.

Менә шул. Кихмәтле җырым бар минем. Урысча җыр. Ат чаво палучается чаво, ат ничава ни палучается ничава. Төшенденме инде? Татарчасын әйтмә. Бу җырның татарчасын әйтергә ярамый. Кызыгы бетә. Ул, беләсеңме, матур хатынны чишендереп караган кебек була. Карап торырга матур ул, әйеме?. Бөтен җире килгән инде менә. Чишендерергә тотынасың, ә аның нәкъ кирәкмәгән җирендә дификтысы бар. Дификтыны беләсеңме син? Җитешмәгән җире инде. Беләсең инде үзең дә...

Шулай, син, Туфан энекәш, бер нәрсәне дә чишендермә. Ничек бар, ничек күзеңә күренә — шулай кара.

Менә син нигә елмаясың? Чөнки син мине чишендереп карадың. Һәм дә күрдең минем дификтымны. Шуңардан көләсең. Әгәр дә ки син мине чишендермичә минем сүземне генә тыңласаң, елмаймас идең син. Карале, акыллы сүз сөйли бу дип, колагың торгызып тыңлар идең.

Ни өчен мин менә булуым житкәч, ат чаво палучается чаво, ат ничава ни палучается ничава, дип җырлыйм? Син мине татарча җырлый белми дип уйлыйсыңмы? Беләм. Татарча мин җырлыйм кайчан? Йөрәк сораганда, күңел әллә нишләгәндә. Өзелеп китә үзәк, аңа җыр кирәк, җыр гына өзелгән үзәкне ялгый ала.

Теге җырны җырлыйм мин урысча, башны эшләтер өчен. Шуны җырлап җибәрәм дә баштагы механизмнар тотына эшләргә. Теге шистирна әйләнеп куя, бу шистирна келт итеп ала. Шуннан әкрен генә тотына эшләргә баш.

Әгәр дә ат чаво получается чаво икән, ни була инде? Миңа хәтле дә дөнья булган була. Шулай бит? Миңа хәтле дөнья булмаган булса, мин тумаган да булыр идем бит. Әгәр дә ки миңа хәтле дөнья булган икән, аңарга хәтле дә булган бит инде дөнья. Шуннан ни килеп чыга? Әйт син, әйт менә, ни килеп чыга? Килеп чыга шул: син дөньяда мин генә дип борыныңны күтәрмә. Сиңа хәтле дә булган дөнья, синнән соң да булачак. Юкса кайсыберәүләр түш киереп йөргән була, үзе генә дөньяга килгән диярсең.

Нигә елмаймыйсың, Туфан энекәш? Сизеп алдыңмы инде минем кем икәнлегемне? Шулай ул. Син дә үзеңне әллә кем дип уйлама. Сине әллә кем дип бүтәннәр уйласын. Сине әллә кем дип мин уйласам, син — бар, уйламасам, син — юк. Ат чаво палучается чаво, ат ничава ни палучается ничава.

Ул син, әллә нишлә, юк әйберне бар итә алмыйсың. Бер яртылык сәмәнең юк икән кисәңдә, юк инде ул. Бар дип уйлап кына булмый ул. Аны булдырырга кирәк. Булдыру өчен нишләргә кирәк? Йә берәрсеннән сорарга кирәк, йә урларга кирәк, йә эшләп табарга кирәк!

Сораныргa ярамый. Соранган, теләнгән кеше — кеше түгел ул. Ул беләсеңме кем? Ул — кешенең күләгәсе. Кояш чыкканда бар, кояш баегач, йә дә булмаса, кояшны болыт капласа — юк. Ә дөнья ул гел кояшлы гына булып тормый, Туфан энекәш. Болытлы чагы күбрәк була.

Урларга да ярамый. Нигә ярамаганын син үзең дә беләсең. Тоталар да ябалар. Ә кеше дөньяга ябылып тотыр өчен тумаган. Кеше гел иректә булырга тиеш. Ябылдымы кеше — җанварга, йә хайванга әйләнә. Ул инде кеше түгел дигән сүз.

Нәрсә кала кешегә? Эшләргә кала. Бер яртылык сәмән табу өчен эшләргә кирәк. Эшләр өчен нишләргә кирәк? Менә бу инде, Туфан энекәш, иң төп сорау.

Бу сораудан да катырак сорау юк дөньяда. Ул сораута җавапны эзләп маташма да, барыбер таба алмыйсың? Ни өчен дисеңме? Чөнки син аны әллә каян эзлисең. Эзләмә әллә кайдан. Янында гына ул. Эшләр өчен, Туфан энекәш, эчмәскә кирәк. Эчкән кеше кеше түгел ул, күләгә генә. Ә күләгә эш эшли белми.

Сизендеңме инде ни өчен җырлыйм мин теге урысча җырны? Ат чаво палучается чаво, ат ничава ни палучается ничаваны җырлагач, мин беләм инде — миңа бүтән эчәргә ярамый. Миңа житкән, мин булган, мин өлгергән. Иртәгә дә эчәр өчен миңа сәмән кирәк, сәмәнне эшләп алырга кирәк, эшләр өчен айнырга кирәк.

Күрдеңме инде баш ничек эшләп бара? Ә син елмаясың. Алай түгел ул, Туфан энекәш.

*1993.*

## КҮҢЕЛДӘГЕ ЭЗЛӘР

Кызык кына бу кеше күңеле — кайвакыт әллә нинди тетрәнүләргә дә түзә, кайчакларда юктан гына уала да төшә. Кайвакыт кемдер сиңа жылыйжылый үз башыннан узган хәсрәт-кайгысын сөйли, син аны тыңлап торасың, хәленә керергә тырышасың, әмма икенче көнне үк ул хакта онытасың, ә менә кечкенә генә, күпләр хәтта игътибар да итмәгән вакыйга күңелгә уелып кала.

Күрше авылда бер өйне сүткәннәр. Шунда матчага кыстырган бер язу килеп чыккан. «Кеше үз-үзен бәхетсез итәсе килсә, крәстиян булсын икән», — дип язылган, ди. Миңа аны сөйләүче көлеп диярлек сөйләгән иде. Мин менә шуны һаман оныта алмыйм. Авыл турында, авыл кешесенең үткәне һәм бүгенге хәле турында уйлана башладыммы, кылт итеп әлеге язу искә төшә. Шул язуның язылган мәлен күз алдыма китерәм. Кайсы елны язылды икән ул? Колхозга куып керткән чаклардамы, сугыштан соңгы талау вакытындамы, әллә?..

Хәер, кайчан гына язылса да, дөрес язылган. Ачы хакыйкать. Җаны әрнегәннән язган инде хуҗа.

Нигә матчага кыстырып куйды икән? Берәрсе күреп алып, тиешле урынга барып әйтмәсен өченме? Барып әйтсәләр, андый сүзләр өчен төрмәсенә дә ябып куйганнар ич. Алай дисәң, ертып кына ыргыткан булыр иде. Мөгаен, үзе бу дөньядан киткәч, кемнәрнеңдер ул язуны табып укуларына өмет иткәндер. Белсеннәр киләчәктә яшәүчеләр крәстиянның хәлен, дип уйлагандыр.

Әйе, беләбез. Беләбез. Ул язу язылган көннән әллә ни үзгәреш юк бүген дә. Крәстиянне кычкыртып талау дәвам итә. Ул язуны яңа салына торган берәр өйнең матчасына кыстырып куеп, тагын әллә ничә дистә елдан табылса да үзгәреш булмас сыман әле. Шунысы аяныч.

Күңелгә уелып калган тагын бер вакыйга.

Мәктәптә укыганда тарих укытучысы Әхмәт абыебыз бар иде. Сугыш вакытында моряк булган. Ә авыл җирендә моряклар һәм очучыларга аеруча хөрмәт бар иде. Малайларның хыялы да моряк яки очучы булу иде. Шуңа күрә Әхмәт абыйга без барыбыз да мөкиббән идек. Хәтта безнең белән бергә укучы кызыйлар да. Өстәвенә, матур кеше дә иде Әхмәт абый.

Укытуы да ошый иде аның. Кайбер укытучылар кебек юкка-барга бәйләнеп теңкәгә тими иде. Дәреслеккә дә ябышып ятмый иде шикелле. Кыскасы, кызык иде безгә аның дәресләрендә.

Хәтердә нык сакланып калганы — безне ул берничә тапкыр Иделгә су керергә алып барды. Йөзә белмәгәннәрне йөзәргә дә өйрәтте бугай әле. Әле дә күз алдымда аның йөзүе. Чапыр-чопыр килмичә, балык кебек кенә суны ерып бара иде. Суны яратканы күренеп тора иде.

Бервакыт ишеттем: Әхмәт абыебыз суга батып үлгән. Баткан җире дә Иделнең иң сай җирендә — яр читендә ди. Суның тирәнлеге тездән генә ди. Йөрәге туктаган Әхмәт абыйның. Кирәк бит шулай туры килүе — балык суда батып үлсен инде. Иделгә су коенырга кергән саен Әхмәт абый искә төшә дә, язмыш турында уйлана башлыйсың, йөрәк чеметеп ала.

Алтынчы класста укый идем. Озын-озын шигырьләрне ятлап сәхнәдә укый идем. Класс җитәкчебез Мөршидә апа минем активлыкны мактап үсендерә иде. Мин аның саен тырыша идем.

Ул заманда үзешчән сәнгатьтә катнашучыларның смотрын үткәрә башладылар. Олимпиада дип атыйлар иде аны. Мөршидә апа мине район үзәгенә

олимпиадага алып барырга вәгъдә итте. Безнең авыл үзешчәннәренең чираты җиткәч, районнан килеп безне карадылар. Йомгаклау концертына сайлап алдылар. Мине дә алып барырга куштылар. Ләкин көне килеп җиткәч, мине онытып калдырып егетләр-кызлар атларга төялеп үзләре генә киткәннәр.

Мөршидә апа оныттырмаган булыр иде, әмма ул күрше авылда, мине калдырганнарын белмәгән дә. Йомгаклау концерты турында мин өйлә авышкач белдем. Һәм кышның салкын көнендә әнигә, әтигә дә әйтеп тормыйча бер кат юка ыштан кигән килеш, мамыгы оешып беткән бишмәт белән, шарф-фәләнне әйткән дә юк инде, район үзәгенә чыгып йөгердем. Унбиш чакрым. Җылыйҗылый йөгердем.

Клубка ничек барып кергәнемне хәтерләмим инде. Мөршидә апаның мине күргәч ахылдавы һәм безнең авыл егетләрен ачуланганы гына истә калган.

Концерт узды. Мин сәхнәдә йөгереп йөри-йөри «Ятим тай» дигән озын шигырьне сөйләдем. Кем булгандыр аның авторы — белмим. Концерттан соң фатирларга урнаштырдылар. Мөршидә апа мине үзеннән калдырмады. Без кунарга тиеш фатир салкын иде. Мөршидә апа үзенең пальтосын ябынып ятты, мине куенына алды. Шунда җылынып йокладым.

Һич онытылмас вакыйга. Унике яшьлек малай укытучы апасының кайнар кочагында. Бу — бик сирәкләргә туры килә торган сирәк бәхет. Укытучы апалар, бигрәк тә аларның чибәрләре, бигрәк тә аларның рәхимлеләре безнең өчен фәрештә иделәр. Бәлки шуңадыр да минем язмышым миңа рәхимле булды. Алдагы көннәрем дә шулай булсын иде, ходаем.

*1994.*

## БЕР МИН ГЕНӘ ТҮГЕЛ...

Илдар Юзеев шалтыратты. Төш күргән.

— Мин төшләр җыймыйм, син җыясың, бүләк итәм,— ди.

Төше мондый:

— Икәүниндидер бер музейга кергәнбез икән. Экспонатларны карап йөргәндә кинәт кемнәрдер сине тотып алдылар. Тишек оек белән музейга керергә ярамый икән, ә синең оегыңның тишеге күренеп тора. Син дулыйсың, җибәрегез, дип кычкырасың икән. Җибәрмәгәч, музейдагы халыкка мөрәҗәгать итеп:

Тишек оек белән музейда
Бер мин генә түгел, Юзей да,—

дип такмакларга тотындың. Бактың исә минем оекның да үкчәсе тишек икән. Көлештек.

— Төшне юрамыйча гына бүләк итәм, үзең юра,— диде Илдар.

Менә юрап утырам. Ни хикмәт икән бу? Дөресен әйтим, минем үземә ошамый бу төш. Чөнки мин анда сатлык җан кебегрәк килеп чыкканмын. Илдарның да оегы тишек, янәсе. Андый ук әшәке түгел лә инде мин. Миңа әллә нинди гаепләр тагып буладыр, әмма сатлык җан дип берәү дә әйтә алмас. Аллага шөкер. Киләчәктә дә ходай сакласын. Бәләкәй чагымда да әләкләшә белмәдем шикелле. Әләкләшкәнне өйдә яратмадылар.

Шулай да нәрсә булыр бу тишек оек? Бардыр инде тишек-тошыклар. Тормышыбызда да булгандыр, иҗатыбызда да юк түгелдер. Алай дип Илдарны да кушып әйткәнгә Илдар үпкәләмәс, дип уйлыйм. Үпкәләсә, бүләк итмәсен иде төшен.

Шул тишек-тошыклар белән дөнья музеенда экспонатлар карап яшәвебез һәм күргәннәребез турында фикеребезне әйткәндә ялгышлар киткән булса, гафу итсеннәр иде экспонатлар.

Илдар төшендә мин, әлбәттә, ул үзе еш кабатлый торган рифмаларны кулланып сүз уйнатканмын. Ә төшкә комментарийны үзем тапкан рифма белән төгәлләп куйыйм:

Тишек оек белән бу җиһанга
Без гаепле мени туганга?

*(Тишек иләк)*

Тегә заманда күп милләтле совет әдәбияты классигы булу өчен рус булмаган язучыга шәп итеп язу гына җитми иде. Рус телендә китаплар бастырып «бөтенсоюз уровене»на күтәрелүең кирәк иде. Шуңа күрә каләм кыштырдаткан һәркем диярлек Мәскәүдә китап чыгарырга омтыла иде.

Мәскәүдә эт теле калынлыгы булса да китап чыгарган кемсә Казанда менә дигән китапларның авторыннан үзен өстенрәк саный иде. Хәтта Мәскәү газеталарының берсендә исеме күренеп китүчеләр дә Берлинны алган батыр кебек йөриләр иде.

«Бөтенсоюз уровене»на күбрәк шомарак әфәнделәр күтәрелә иде. Шигырьфәләнне аннан-моннан гына әвәләп, татар телендә татар укымаслык нәрсәләрен бирәр оста урыстан (күбрәк яһүдтән) тәрҗемә иттерүчеләр аеруча зур уңышка ирештеләр. Тәрҗемәчеләр дә, әлбәттә, почетта иделәр. Аларны Мәскәүгә барып та, Казанга чакырып та сыйлый идек.

Минем исемем театр афишаларында еш күренеп, Казан һәм Мәскәү тәнкыйтьчеләренең теленә кергән иде инде. Ләкин «совет әдәбияты классигы» булыр өчен тәрҗемә ителеп, кайсыдыр бер урыс театрында куелуым җитми иде. Һәм мин бу кимчелегемне төзәтергә керештем. Аның өчен җае да чыкты.

Россия Федерациясенең (бүгенгесе белән бутамагыз, элеккеге федерация турында сүз бара) Мәдәният министрлыгыннан Казанга берничә ханым килеп театр спектакльләрен карап бәя бирделәр. Нәрсә әйтерләр икән дип калтырап тордык. Мәскәүдән килгән һәр тәнкыйтьче безнең өчен иң куркыныч ревизор иде бит.

Аллага шөкер, мактадылар. Макталган спектакльләр арасында минем «Ир-егетләр»ем дә бар иде. Мине мактау белән бергәттән, пьесаларымның русчага тәрҗемә ителмәвенә кызгану хисе белдерәләр, бу эштә ярдәм итәргә вәгъдә дә бирделәр. Башым күккә тиде инде, әлбәттә. Өйнең (фатирның инде) ишеген бутар дәрәҗәгә җитеп бәйрәм иттем.

Министрлыктагы ханымнар «Ир-егетләр»нең сүзгә сүз (подстрочник) тәрҗемәсен үзләре белән үк алып киттеләр. Тәрҗемәчене үзебез табарбыз, тәрҗемә иткәне өчен акчаны үзебез түләрбез, диделәр. Миңа, Мәскәүгә баргач, Министрлыкка әбизәтелни керергә куштылар. Тагын бәйрәм иттем.

«Совет әдәбияты классигы»на ирешү юлында тагын бер этәргеч ярдәм итте. Берничә татар драматургын Мәскәү янында Руза дип аталган гаҗәеп матур урындагы артистларның иҗат йортына бер айлык Бөтенсоюз семинарына чакырдылар. Мин «Ат карагы» дигән пьесаны күтәреп бардым. Семинар җитәкчеләренә пьеса ошады. Аның да тәрҗемә итәргә булдылар. Бусы инде минем өчен җитдирәк иде. Чөнки пьесаны аеруча ошатучы кеше без хөрмәт иткән намуслы урыс (хәзер мәрхүм инде) Петр Григорьевич Демин иде. Мәһабәт гәүдәле, чибәр, ягымлы кеше иде. Аның сүзе белән Мәскәү министрлыгы тирәсендә чуалучы шашәрәләр исәнләшә һәм хәтта бераз шүрлиләр дә иде. Урысның начары бик әшәке булган кебек, яхшысы да бик әйбәт була бит аның. Безнең ише «чүчмәкләрне» аз гына да кимсетеп карамый иде, семинарга килгән Мәскәү драматургларына күрсәтеп:

«Каждый из вас выше их, вы знаете жизнь. Вам намного труднее жить и творить что-либо достойное»,— дия иде.

«Ат карагы»н Петр Григорьевич үзе тәрҗемә итәргә булды. Мин инде үземне җиде кат күктә итеп тоя башладым. Совет әдәбиятының коеп куйган классигы булам лабаса.

Көннәр үтә торды. Бервакыт җыенып, кесә ягын да караштыргалап, Мәскәүгә тәрҗемә өлкәсендә зур уңышларга ирешергә киттем.

«Россия» кунакханәсенең люкс дип аталган номерына урнаштым. Алай-болай минем янга керүче тәрҗемәчеләр булса, төшеп калган малай дип уйламасыннар. Расул Гамзатов тәрҗемәчеләрне мичкә-мичкә коньяк белән сыйлый икән, дип сөйлиләр иде. Мин дә сараңланмаска тырышып, татарның дәрәҗәсен төшермәү ниятеннән, берничә шешә коньяк алып суыткычка тыктым. Закускафәләннәрнең дә затлыракларын алдым. Мәскәү бит ул без түгел, бәрәңге ашамый. Аннан киттем министрлыкка. «Ир-егетләр»не алып киткән апаларны эзләп таптым. Баштарак танымый торсалар да исләренә төшерделәр тагын.

— Пьесагызны бүлек мөдире Игорь Станиславович укый,— диделәр. (Күп исемнәр, хәтта яратып йөргән кызларымның да исемнәре истән чыккан, ә менә Игорь Станиславовичны мәңге онытасым юк).

Алып керделәр Игорь Станиславович янына, кем икәнемне әйттеләр. Бик зурлап каршылады. Пьесаны укып чыгуын, искиткеч әсәр икәнен, бөтен рус театрларында шаулап барачагын әйтте.

— Бик шәп тәрҗемәче кирәк. Бергәләп эзләрбез. Мәскәүдә озак буласызмы? — дип сорады.

— Махсус шуның өчен килдем,— дидем.

— Бик яхшы,— диде Игорь Станиславович.— Төштән соң бу эш белән шөгыльләнербез. Ә хәзер әбәд якынлашкан. Сез кайда ашыйсыз төшке ашны?

Классик булырга җыенган иптәш бу очракта ни әйтергә тиешлеген белеп бетерми шул. Сыйларга тиешлеген белә, ә менә ничегрәк итеп чакырырга белми.

Ярый әле Игорь Станиславович коткарды:

— Бәлки, төшке ашны бергә ашарбыз,— диде.

Шатлыгымнан чак кына кычкырып җибәрмәдем. Булды гына бу! Бергә ашыйбыз, мин түлим, Игорь Станиславович минем кулда булачак, дип уйлыйм.

Игорь Станиславович үзе белән тагын өч-дүрт хатын ияртеп (икесе мин белгәннәр) киттек «Россия» ресторанына. Игорь Станиславович ашарга заказ бирде. Эчү мәсьәләсен үзем кузгаттым. (Молодец, Туфан).

— Бәлки, берәр шешә коньяк алырбыз,— дидем.

Хатын-кызлар эш вакыты дип коньяктан баш тарттылар, шампанское гына эчәргә булдылар. Без, әлбәттә, коньяк алдык. Бик шәп утырдык. Башта бергәләп мине мактадылар. Аннары, минем барлыгымны да онытып, үзара кемнәрдәндер көлделәр.

Дүрт сәгать утырганнан соң таралыштык.

Мин түләдем инде, билгеле.

Эш сәгате беткәнгә күрә, иртәгесе көнне сәгать унберләрдә очрашып сөйләшергә булдык.

Эшнең кая таба барганын сизгер укучылар сизенә торгандыр инде. Шуңа күрә, иртәгесе көн ничек булганын сөйләп тормыйм. Әйе, әйе, нәкъ беренче көн кабатланды. Төшке ашка бару һ. б. һ. б. һәм таралышу.

Шулай итеп, дүрт көн үтте. Сизеп торам — мәсьәләне хәл итмичә болар мине бераз «савып» калырга чамалыйлар. Мин риза, чөнки классик буласым килә.

Бишенче көн — җомга көнне чакырылган чакка төш вакытларына министрлыкка килдем. Игорь Станиславович һәм аның хезмәткәрләрен көтеп коридорда йөри идем, Петр Григорьевич очрады. Исәнләштек.

— Нишләп йөрисен, конокрад? — ди. («Ат карагы»н яратканнан соң мине шулай атый башлаган иде ул.)

— Менә,— мин әйтәм,— бер пьесаны тәрҗемә иттерәбез дигәннәр иде.

— Ничек соң? — ди Демин.

— Көтәм,— дим.

— Күптән көтәсеңме?

— Дүшәмбедән бирле.

— Һәм көн саен ресторанга барасызмы? — ди Петр Григорьевич. Мин ыкмык иләм.

— Һәр көнне дүрт-биш кешене сыйлыйсыңмы? — дип төпчечә Демин, һәм минем җавабымны да көтмичә, көләргә тотынды.

— Эх син, наивный татарин, конокрад,— ди үзе.— Алар бит сине ыштансыз калдырачаклар. Алар бит — банда... Әйдәле.

Ул мине Игорь Станиславович кабинетына алып керде. Деминны күргәч, Игорь Станиславович нидер сизенде, ахры, торып басты. Деминнан курыкканы күренеп тора иде.

— Кайда аның пьесасы? — дип, Петр Григорьевич миңа күрсәтте.

Игорь Станиславович өстәлдә, тәрәзә төпләрендә өелеп торган кәгазьләр арасында актарынды. Пьесаның исемен миннән кат-кат сорады. Ләкин таба алмады. Кемнәргәдер шалтыратты. Күрәсең, анда да таба алмадылар.

— Их сез!..— диде Петр Григорьевич. Аннан мине култыклады.— Киттек конокрад. Бүтән син бервакытта да монда йөрмә. Бу урын синең кебекләр өчен түгел. Бу сөлекләр каныңны эчеп бетергәч, өстеңә төкереп китүчеләр.

Петр Григорьевич мине «Арагви» ресторанына алып кереп иң затлы ризыклар белән сыйлады. Тегеләр өчен дә гафу үтенергә теләгән сыман, Мәскәүдәге бөтен кеше дә жулик түгеллеген расларга теләгәндәй сыйлады.

Министрлыктагы пьеса онытылды. Бүтән мин дә бармадым. Алар да искә төшермәде.

«Ат карагы»н да тәрҗемә иттерү бәхетенә ирешә алмадым. Безнең Обком аның юлын кисте. Мәскәү: «Мы с местными обкомами не ссоримся»,— дип,

төзелгән договорны юкка чыгарды. Һәм мин ул вакытта күп милләтле совет әдәбиятының классигы булалмый калдым.

Бу — 1973 ел иде.

1994.

БАР ИДЕ ЗАМАНАЛАР

*(Тишек иләк)*

Руза дип аталган Иҗат йортында үткәрелгән драматургларның Бөтенсоюз семинарында Аяз Гыйләҗевның «Өч аршын җир»е һәм минем «Ат карагы»м макталды. РСФСР Мәдәният министрлыгы (СССР нныкы бугай әле) вәкилләре безнең белән килешү төзеп, безнең пьесаларны сатып алырга һәм урысчага тәрҗемә итәргә вәгъдә бирделәр. Семинарга нәтиҗә ясаган җыелышта без түшләрне киереп утырдык. Ул хәтле мактауга ничек тыйнак булып утырасың инде.

Семинар бетеп Мәскәүгә кайткач та, үз бәябезне үзебез белеп кенә, «Украина» кунакханәсенең уналтынчы катындагы ындыр табагы хәтле бер номерына урнаштык. Тәрәзәне ачып, уналтынчы каттан Мәскәү өстенә карадык. Аяз ике кулын кесәсенә тыгып башын чөеп торды да:

— Мәскәү безнеке! — диде.

— Безнеке, — дип кабатладым мин.

— Моны юарга кирәк, — диде Аяз.

— Кирәк, — дидем мин.

Киттек ВААПка. ВААП ул — авторларның хокукын һәм драматургларның театрдан килгән акчаларын саклау урыны.

Бәхеткә күрә, ВААПта безнең счетларда акча шактый иде. Кесә тутырып акча алдык.

— Киттек ЦДЛга! — диде Аяз.

— Киттек, — дидем.

ЦДЛ дигәне — язучылар йорты. Аның бик кәттә рестораны бар. Безнең акча күп плюс үзебез семинарда макталган драматурглар. Без нәкъ менә шушында типтерергә үзебезне лаеклы дип санадык.

Бик шәпләп сыйландык. Аяз ресторандагы аракы белән генә юанучы язучыгоЛәмәгә җирәнеп кенә карады. Чөнки без иң кыйммәтле әрмән коньягын гына авыз итеп утырдык.

— Шулай ул татар малайлары! — диде Аяз.

— Шулай, — дидем мин.

Як-якка мыскыллы караш ташлап, рестораннан чыктык.

Каршыга без белгән бер Мәскәү драматургы очрады. Мәскәү гадәте буенча, безне бераз гына талап калмакчы була бу. Безне күккә чөеп мактый. Без язганнарны тәрҗемә итеп Мәскәү театрларында куйдырмакчы. Без икебез дә мыек астыннан гына елмаеп тыңлыйбыз. Чөнки икебез дә беләбез — тәрҗемәләрен түгел, үзе язганнарын да Мәскәүдә куймыйлар, провинциал театрларда гына куела.

— Бездән эчәргә чамалый, — диде Аяз татарчалап, — әйдә, күңеле булсын урысның, исерткәнче сыйлыйк әле үзен. Безне мокытларга саный, күрсәтик әле мокытлыкны.

Буфетка алып кереп эчерттек без моны. Күп эчте. Исерми. Мәскәүне эчереп исертеп буламы инде? Исермәсә дә, күп сөйләнә башлады. Мәгънәсез сүзләре белән туйдырды.

Бу юлы «киттек»не мин әйттем.

Тегенең бездән аерылырга исәбе юк. Бушка бездән башка Мәскәүдә кем эчерә аны! Теләнә торгач, безнең кайда урнашканыбызны белде.

— Бәлки әле кызлар белән дә килермен, — дип калды.

Бик озак буталып йөрдек Мәскәүдә. «Наполеон» дип аталган коньяклар сатып алдык. Куна тактасы зурлыгындагы «Бабаевский» дигән шоколадлар төяп «Украина»га кайттык. «Өч аршын җир» һәм «Ат карагы»н язган драматурглар иң затлы нәрсә эчеп, иң затлы нәрсәләр белән генә закусить итәргә тиеш ләбаса.

Кунакханә номерында «Наполеон» капкалап рәхәтләндек кенә мактанып. Дөресен әйтергә кирәк, үзебезне генә мактамадык. Татарны мактадык. Татар малайлары төшеп калган түгел алар, дип, тагын бер тапкыр Мәскәү өстенә карап әтәчләндек.

Җырлап алдык, биеп тә җибәрдек. Шул арада өстәл өстендә җәелеп яткан шоколадтан кисәкләр сындырып алып кына кабабыз.

Караңгы капкач, үтә дә чибәр бер ханымны ияртеп теге драматург килеп керде. Икебез дә ханымны күреп әсәрләнеп, гипнозланып калдык. Драматургның барлыгын да онытып, икәүләп ханым тирәсендә бөтерелдек. Ханым, үз кадерен үзе белеп кенә, нәзакәтле елмаеп, өстәл янына утырды.

Теге драматург өстәл өстендәге байлыкның ияләре үзенең дуслары икәнлеген ханымга аңлатты. Портфеленнән кәкрәеп беткән ике тозлы кыяр чыгарып өстәл өстенә куйды — бусы аның зур ялгышлыгы иде.

— Бик шәп закуска,— диде.

Шуннан китте кураж. Миннән бик күпкә тәҗрибәлерәк Аяз сүзләрнең әллә нинди әрен сайлап сайрады. Бу ханымны оста итеп мактады. Бу, әлбәттә, теге драматургка ошады. Ханымның иңбашына кулын салып:

— Ну как, моя Нинуленька? — диде.

Әйтүенә карап, Нинуленьканың драматургка хатын түгеллеген төшендек.

— Әйдә, бу урысның марҗасын тартып алабыз,— диде Аяз. Һәм тотындык эшкә.

Безнең кемнәр булуыбызны белергә чамалап утырган ханым, бераз коньяк кабып алгач, сөйләшә башлады, әмма вульгарлыкның эзе дә юк. Үз дәрәҗәсен белә. Без дә сынатмаска тырышабыз.

«Наполеонны» чөмереп калырга тырышкан Мәскәүский драматург утыра-утыра җеби башлады. Без ипле утырабыз. Ханым моны сизенә. Уңайсызланып теге драматургның мәгънәсез сүзе саен кызарып та куя шикелле. Очына-очына Аяз иң югары дәрәҗәгә менеп җитте, экстазга бирелеп, теге ханымга күрсәтебрәк ике тозлы кыярның берсен чеметеп кенә тотып чүп савытына ыргытты. Икенче кыярны чүп савытына мин озаттым.

Ханым кем белән кемнәр янына эләккәнен тәмам аңлады. Мәскәүский драматургтан читкәрәк китеп, безгә якынрак елышып утырды. Без салган коньякны эчми башлады.

Мәскәүский драматург урыныннан торып, алпан-тилпән килеп номер буйлап йөрде.

— Каковы мои друзья! — дип мактанды.

Нинуленькасын кочакларга теләп ханым өстенә иелгән иде, ханым чалт моның яңагына. Торып басты да уңлап-суллап яңаклады тегене. Аннан:

— Дурак! — диде дә тиз-тиз генә киенеп чыгып китте. Без сүз әйтергә дә өлгерә алмадык.

Мәскәүский драматургны үзебез куып чыгардык. Куылып чыкканын аңламады ул, әлбәттә. Аннары караватларга аудык та аякларны селки-селки, буыла-буыла көлдек.

— Шулай ул татар малайлары! — дип кычкырды Аяз.

— Безнең кулга эләксәң, шулай була ул,— дип мин үкердем.

Иртәгесен хәлләр хәл иде инде. Анысы һәркемгә мәгълүм.

Ә безнең шатлыкның сәбәпчеләре булган пьесаларның язмышы махмырдан да кызганычрак булды. Аларны куйдырмадылар. Аяз Гыйләҗевның «Өч аршын җир»ен — кулакны мактаганы өчен, минем «Ат карагы»н — ат карагына мәхәббәтле карашым өчен. Казан Обкомының сүзенә Мәскәү министрлыгы каршы килмәде. Этлек эшләгәндә Казанның сүзенә дә колак сала иде Мәскәү.

Ярый инде, хәерле булсын. Аның каравы бер типтереп калдык. Хәзер менә сагынып искә алып утырам.

*1994.*

## ВАТАН КАЙДАН БАШЛАНА?

«Шәһри Казан» газетасының 1995 ел 15 февраль санында яшь журналист Рәмис Аймәтнең «Бөркетләр кыяда оча» исемле бик яхшы мәкаләсе басылды. Ул халкыбызның талантлы баласы, дөньяга танылган мәшһүр биюче, бүгенге көндә Англиядә яшәп иҗат итүче Ирек Мөхәммәтов турында.

Мәкаләнең ахырында Иректән Ватан турында сүзләре китерелгән. Мин аны тулысы белән күчереп язам.

«Нәрсә ул Ватан? Мин гомер буе әнә шушы төшенчәнең асылын аңларга тырышып карадым. Ватан ул кемнәрдер өчен туган җир булса, минем өчен театр да, гаиләм дә, дусларым да. Бүген Лондон — минем өчен барысы да. Ерак

гастрольләрдән мин аны, үз туган йортыма кайткандай, сагынып кайтам. Монарчы мондый халәтне беркайчан да кичергәнем булмады. Элек мин кемнәрнеңдер фикере белән яшәргә мәҗбүр булсам, бүген мин — ирекле. Бары тик үзем өчен үзем генә җавап бирәм. Мине монда тотып торган тагын бер нәрсә бар. Ул — кызым Чулпан. Англия — аның туган җире. Мин аның туган җирен перчатка урынына алмаштырып йөрүен теләмим».

Менә шундый сүзләр. Аларны үз колагым белән үзем Ирек Мөхәммәтов авызыннан ишетмәгәнгә, аларның дөреслеген исбатлап ант итә алмыйм. Бу очракта Рәмис Аймәткә ышанам.

Бу сүзләр мине бик нык уйланырга мәҗбүр итте. Һәм мин кулыма каләм алып уйланып утырдым. Әлбәттә инде, әйткән һәрбер сүзем чын хакыйкать дияргә ашыкмыйм. Шуңа күрә, сүзләрем ачырак булса, гафу үтенәм. Бәхәс чөнки бик җитди нәрсә турында барачак. Әйе, әйе, мин 60 яшьлек татар язучысы 35 яшьлек бөек татар биючесе белән бәхәсләшергә җыенам. (Ирек Мөхәммәтов бөеклеккә ирешкән шактый гына татар балаларыннан үзенең татарлыгын яшермәве белән аерылып тора.)

**Димәк, нәрсә ул ватан?**

Ирекнең фикерен беләбез. Инде мин үз сүземне әйтеп карыйм.

Мин, Иректән үзгә буларак, Ватан төшенчәсенең асылын эзләп интекмәдем. Миңа аны мәктәптә ачык аңлаттылар. Советлар Союзы — Ватаның, диделәр. Мин шуңа чын күңелемнән инанып яшәдем. Кайвакытларда, бигрәк тә үзем үземчә фикер йөртергә өйрәнә башлагач, күңелдә шик тә уяна башлый иде. Ни өчен әле миңа — татар баласына үз Ватанымда икенче сорт кешегә караган кебек карыйлар? дигән сорауга җавап эзли идем. Әллә соң бу минем Ватаным түгел микән? кебек куркыныч сорау да күңелгә килгәли иде. Ләкин ул шикләр минем кыйбламны үзгәртә алмадылар. Чөнки мине уңга-сулга авышудан саклап торган минем төп Ватаным — авылым булды. СССРны Ватаным дигәндә беренче нәүбәттә мин, бәлки, авылымны күз алдына китергәнмендер. Чөнки ул җир минем кендегемнең каны тамган җир, аның зиратында минем әби-бабаларым ята, минем телем шунда ачылды. Беренче тапкыр кызларга күзем шунда төште, беренче кат... Авылым минем күңелемә мәңге җуелмас булып кереп урнашкан иде. Олыгая төшкәч, моның шулай икәнлеген акылым белән дә аңладым. Шуңа күрә Советлар Союзының таркалуы да миңа Ватанны югалту булып ук тоелмады. Киресенчә, минем чын Ватаным миңа тагын да якыная төште. Бүген инде мине дөньяның әллә нинди бизәкләре белән дә Ватан мәсьәләсендә саташтырып булмый. Дөнья малы дуңгыз каны дигән сүзләрнең асылын аңлар дәрәҗәдә мин бүген. Туклык хисабына Ватанымны алыштыра алмыйм мин. Алыштырырга теләсәм дә булдыра алмыйм. Һәм шуңа үземне бәхетле дип саныйм. Бәлки, мин дөньяны сокландырырлык чәчәк түгелмендер, авыл урамындагы чирәм генәдер, ләкин минем тамырым бар. Мин өч-дүрт көннән шиңәчәк чәчәк букеты түгел. Миннән соң туган авыл малайлары чирәмгә ятып аунаганда мине искә алачаклар. Каз, үрдәк бәбкәләре мине чемченеп тәм табачаклар. Мине шул юаныч яшәтә. Бәлки әле бу юаныч кына түгелдер, ышанычтыр. Мине онытырлар. Рәсәй тере чагымда ук оныта инде, Казан да онытыр, ә авылда тиз генә онытмаслар. Авылның хәтере яхшырак.

Шунысын да әйтергә кирәк, авыл дигәч тә мин авылымның чикләреннән бер карыш та чыкмыйча, шуны гына Ватан дип санап Ватан төшенчәсен тарайтырга җыенмыйм. Әлбәттә, Ватан дигәндә һәрчак Татарстанны уйлыйм. Чөнки ул да ата-бабаларымның рухы сыенган җир.

Әгәр дә кеше 35 яшькә җитеп шуны аңламый икән, димәк, бу дөнья гыйлемен аның күңеленә салмаганнар. Кызганыч, бик кызганыч, бик күп татар балаларын шундый изге нәрсәдән мәхрүм итәләр һәм соңыннан еш кына үзләре дә үкенеп туя алмыйлар.

**Ватан кайчан кирәк?**

Сабый чакта безгә әни кирәк. Чөнки әнидә мәми бар, әнинең җылы куены бар. Бераз үскәч, әти дә кирәк була башлый. Әтинең дә мәми тапканын аңлый башлыйбыз. Өстәвенә, ул әле безне усал малайлардан да саклый икән.

Бераз үсә төшкәч, әни дә кирәкми башлый, әти дә. Үзебездән дә шәбрәк җан иясе юктыр, дип йөрибез. Кайберәүләр өчен әти, әни, туганнар артык мәшәкатькә әйләнәләр. Алардан ничек котылырга белмәүчеләр бар. Ятлар якынрак булып тоела.

Менә берзаман берәр бәлагә юлыгабыз. Һәм әти-әни, туганнарны оныттырган ятлар югала, эзләре дә калмый. Һәм без әти-әни исән булса, туган йортка, алар үлгән булса, туганнар бусагасына кайтып егылабыз.

Бәлагә юлыкмаган очракта да тормышның бер мизгелендә күңел нидер эзләнә башлый. Тамагыбыз да тук, өстебез дә бөтен, әмма җан уйный, җанга нидер җитми, кеше үзе дә сизмәстән юксыну дип аталган чир белән чирли башлый. Кеше бәргәләнә, өзгәләнә. Яшәүнең яме калмый. Әти-әнисе, туганнары исән булып, аларның барлыгын белеп торса, аларның кирәклеген аңласа, кешедә юксыну булмый, сагыну гына була. Сагыну инде изге хис. Ул кешенең рухын сындырмый, киресенчә, кешене өметле итә. Сагынган кеше сагынган кешесен күреп сөйләшү бәхетенә ирешә ала, юксынган кеше еш кына андый бәхеттән мәхрүм инде.

Мин әти-әни, туганнар дип сөйләдем. Ватан да шул. Койрык чәнчеп кушаяклап чабып йөргәндә Ватан кирәкми. Кайда да рәхәт. Ә инде көтмәгәндә өстеңә фаҗига өелеп төшсә һәм син дөнья уртасында ялгыз калсаң, сыеныр урын эзли башлыйсың. Ят җирдә син беркемгә дә кирәкмисең. Ят җир ул сөяркәләр кебек — син сау-сәламәт чакта гына кадерлиләр. Эштән чыккач, «иди к черту»га әйләнәсең.

Әлбәттә, безне тормыш үз Ватаныбызда каккалап торса, бәхетне читтән эзлибез. Һәм анда рәхәтрәк яшәсәк, бәхеткә ирештек дип уйлыйбыз. Бу үзүзебезне вакытлыча юату гына. Күңелдә исә, их, бер кайтып күрәсе иде дип уйлатып, туган җир, ягъни-мәсәлән, Ватан яши.

Әнә бит, СССР таркалды да качаклар пәйда булды. Бәхет эзләп киткәннәр ят җирдә артык була башладылар. Ватанын сагынып яшәүчеләр, Ватаны барлар Ватаннарына кайттылар. Ә Ватаннарын онытканнар нишли? Дуңгәләк булып дөнья буйлап тәгәрәп йөри.

Заманында Рудольф Нуриевка — дөньяның мәшһүр биючесенә үз илендә бөек талантын күрсәтергә ирек булмады. Чит илгә китеп дан алды. Ватан төшенчәсен аңламыйча бөтен дөньяны Ватан дип санап, минем милләтем театр, дип тәкрарлады. Аны зурладылар, байлыкка чумды. Әмма үләр алдыннан җаны бәргәләнә башлады бахырның. Казанга да кайтып карады. Җанына урын тапмады. Читтә үлде. Кадерләп күмделәр күмүен. Һәм бүген аның киемнәрен Европа аукционда сата. Европаның хәтере кыска, берничә елдан татар баласын ул онытачак.

Әгәр дә Нуриевның күңелендә Казан яки Уфа яшәсә, рухи таянычы үзенең халкы булса, ул Ватанына кайтып егылыр иде дә, җирләгез мине монда, ата-бабаларым җирендә, әнә минем байлыгым. Салыгыз бер балет мәктәбе, кушыгыз ул мәктәпкә минем исемне дисә, аның исеме озаграк сакланыр иде дә, татар балалары ул салдырган йортта бөек татардан үрнәк алып, аның данын тагын да күтәрерләр иде. Рудольфның СССР чиновникларына үпкәләргә, рәнҗергә тулы хакы бар иде, әмма халыкка үпкәләргә хакы юк бит. Ул халыкны толпа белән бутады. Ватанның кайдан башланганын аңламыйча һәлак булды. Бик кызганыч, бик аяныч. Рудольф фаҗигасе фаҗигале үлемендә түгел, үлгәч тә үз Ватанын таба алмавында.

Моңа, әлбәттә, без, татарлар, үзебез гаепле. Нигә шундыйларны үзебездән биздерәбез? Нигә Ватанын оныттырабыз кешегә? Ярый, Рудольф каһәр төшкән заманда илдән качарга мәҗбүр булды да кайта алмады. Ә Ирек Мөхәммәтов? Нигә аны чакырмыйбыз? Аның талантына баш иеп, олылап чакырсак, Казанда, Татарстанда үзенең бөеклеген күрсәтергә шартлар тудырсак, аның уңышларына сөенсәк, безне ят итәр идеме? Ватан кайдан башлана дигән сорауга җавап таба алмый интегер идеме?

Әнә Гата Камский каңгырып йөри. Без аны үзебезнеке дип саныйбызмы? Нигә санамыйбыз? Бүтән милләттә шундый бөек талант булса, Ватанын онытырлык хәлгә җиткерерләр идеме? Әле ярый, әтисе Рөстәмгә рәхмәт, татар икәнлеген, Ватанының кайда икәнлеген онытмый һәм улы Гатага оныттырмый.

Әйе, шулай. Әмма ләкин шундый бөеклеккә ирешә алган шәхесләр үзләре дә кемгәдер үч саклап изге нәрсәләрне онытмасыннар иде. Муллага үч итеп Коръәнне утка ягуның ничаклы зур гөнаһ икәнен аңласыннар иде.

Бервакыт шулай үзебезнең районда Идел ярында район җитәкчеләре белән сөйләшеп торабыз.

— Без сине яратабыз, Туфан абый,— диләр егетләр.

— Дөрес эшлисез,— мин әйтәм,— сез яратсагыз да, яратмасагыз да бу минем туган жирем, мин монда барыбер кайтып йөриячәкмен, лучше сез мине яратыгыз инде, шулай уңайлырак булыр барыбызга да,— дидем.

Егетләр көлештеләр. Бу мизгелдә мина рәхәт иде. Үзебезнең егетләр, үзебезчә сөйләшәләр, үзебезчә зурлыйлар.

Ирек Мөхәммәтовны да, Роальд Сәгъдиевне дә зурлыйлардыр. Зурларга чын-чынлап лаек булганга зурлыйлардыр. Ләкин мин алардан бәхетлерәк — мине үзебезнекеләр үзебезчә зурлый. Бу милли чикләнгәнлек тә, аздан канәгать булырга өйрәнгән коллык чире белән чирләү дә түгел. Киресенчә, минем жаным, рухым азат. Минем Ватаным бар. Минем яшькә житкәч Ватан мина рухымның таянычы буларак кирәк. Бөеклеккә ирешеп кыйбланы бутый башлаган татар балалары шуны онытмасыннар иде.

**Безнең балаларга, безнең оныкларга безнең ватаныбыз кирәкме?**

Бәлки, кирәкмидер. Чыннан да, Ирекнең Англиядә туган һәм шунда үсәчәк кызы Чулпанга Татарстан бәлки кирәкмәстер. Өстәвенә, аңа татар тәрбиясе бирелмәве дә ихтимал. Әмма шулай да...

Бу уңайдан бер вакыйганы сөйләп алыйм әле.

Моннан унбиш еллар элек Декабристлар урамындагы «Наратлык» дигән кафеда утырам. Мин утырган өстәл янына кулына бер шешә коньяк тоткан кеше килде.

— Сезнең янга утырырга мөмкинме? — диде.

— Утырыгыз, урын буш ич,— дидем.

Өстәл өстенә шешәсен куйды бу. Ике стакан алып килде. (Әйе, кафеларның шундыйлары бар иде ул заманда.) Шешәне ачып ике стаканга да әз-әзләп коньяк салды, кесәсеннән бер уч конфет алып өстәлгә сипте.

— Минем исәнлеккә эчеп куйыйк,— диде.

Нишләп әле бу тик торганнан мине сыйларга булды, дип шикләнеп-уйлап, моңа төбәлебрәк карадым. Күргән дә бар сыман, ләкин танымыйм.

— Шикләнмәгез,— диде бу,— сез танымасагыз да мин сезне беләм, диде. Без бер подъездда торабыз. Минем фамилиям Литвинов, сез Миннуллин. Язучы. Шулай бит?

— Әйе,— дидем.

— Тотып куйыйк танышу хөрмәтенә.

Бу юлы инде сыеннан авыз итмичә булмады.

— Эч пошып китте дә кердем әле. Әллә ничек. Жан үрсәләнә. Дусны озаттым да дөньяда яшәүнең мәгънәсе калмады сыман. Менә кергән идем, сезне күрдем. Сез язучы кеше — минем хәлне аңларсыз. Кемгәдер хәсрәтемне сөйлисем килә, сөйләрлек кеше юк,— диде Литвинов.

Фамилиясен ишетүгә, мин моның яһүд кешесе икәнен аңлап алдым. Ул халык бит бик акыллы, алны-артны уйлап кына сөйләүче халык. Кинәттән генә мина ачылырга жыенуы мина бераз сәер тоелды. Ул минем гажәпләнүемне сизеп алды:

— Ә нигә? Була бит шулай, сөйләп котыласы килә. Хәер, сөйләрлек сүз дә юк инде. Әгәр сезгә читен булмаса, утырыйк аз гына.

Ләкин ул ни өчендер сөйләргә ашыкмады.

Тегене-моны сөйләшеп шактый утырдык. Әз-әзләп уртлый торгач коньяк та үзенекен итте. Әңгәмәнең дә эзлеклелеге югалды. Кызып алгач ир затлары нишли? Йә хатыннарын сүгәләр, йә сәясәткә кучәләр. Без сәясәткә күчтек.

Ул заманда сүзеңне чит кешеләр алдында үлчәбрәк сөйләргә кирәк икәнлеген белсәм дә, шешәдәшемнең яһүд икәнлеген онытып жибәргәнмен. Тотындым бит Израильгә китүче яһүдләрне сүгәргә. Имеш, алар патриот түгелләр. Ватаннарын ташлап жиңел тормыш эзләп китәләр. Мин кызган саен Литвинов дәшмәде. Мин дә, каршымда кем утырганын исемә төшереп, туктап калдым. Уңайсыз тынлык урнашты.

— Әйтегез әле, Туфан Абдуллович,— диде, ниһаять, Литвинов.— Әгәр дә жир шарының кайсыдыр бер жирендә Татарстан дип аталган бер дәүләт булса, һәм ул дәүләтнең территориясендә сезнең борынгы бабаларыгызның сөякләре ятса, сезне биредә кешегә санамасалар, жае чыккан саен тәрткәли торсалар, сез нишләр идегез? Израильгә китүчеләрнең барсы да диярлек жиңел тормыш эзләп

китәләр, дип уйласагыз, ялгышасыз. Арада андыйлар да юк түгелдер... Мин бүген Израильгә китүче якын дустымны озаттым. Китәсе килеп китмәде. Әтисе белән әнисе җылый-җылый сорагач, алар белән китте. Әтисе әйтә, каберемнең бабамнар җирендә булуын телим, ди. Үзем ишеттем. Китте, тормышның анда да бик үк җиңел түгеллеген белеп китте. Бабамнар туфрагында ачтан үлмәм әле, дип китте. Югыйсә, дустымның бабалары һәм аларның бабалары Казан зиратларында яталар. Йә, инде ни әйтәсез?

Ул чакта ни әйткәнемне язып тормыйм. Һәрхәлдә, Литвинов белән аңлашып өйләребезгә бер юлдан кайттык. Тыныч йокылар теләштек. Киләчәктә дә очрашканда дусларча исәнләшеп йөрдек.

Менә әле бу вакыйганы искә төшерергә җай чыкты. Аны сөйләп биргәч, оныкларыбызга безнең Ватаныбыз кирәкме? дигән сорауга җавап соралмыйдыр. Аңлаган кешегә аңларлык. Аңламаганнар яһүдләрдән киңәш сорасын. Яһүдләр акыллы халык. Кайда гына яшәсәләр дә, Израиль дип аталган Ватаннарының барлыгын онытмыйлар һәм оныттырмыйлар.

Ирек аңлата алырмы кызына үзе аңлап бетермәгән Ватан төшенчәсен, нәселнәсәбенең кай яклардан икәнлеген? Аңлата алса, Чулпанның күңеле барыбер тартылыр безнең якка. Хәерле булсын. Бәхетле булырга язсын Ирек Мөхәммәтовка.

*1995.*

## Хөрмәтле укучыларыбыз!

«Казан утлары» журналы якындагы саннарда түбәндәге әсәрләрне сезнең игътибарга тәкъдим итәргә ниятли:

Садри Максуди. «Англиягә сәяхәт».
Миркасыйм Госманов. «Инкыйраз» һәм цензура». *Г. Исхакый турында яңа мәгълүматлар.*
Гариф Ахунов. «Йолдызлар калка». *Документаль повесть.*
Рабит Батулла. «Кылдан нечкә, кылычтан үткен». *Документаль кыйсса.*
Тәлгат Галиуллин. «Тәүбә». *Бүгенге көннәр романы.*
Әхсән Баянов. «Сез аңларсыз мине». *Автобиографик повесть.*
Әнәс Галиев. «Мизгелләр». *Роман.*



## Абай,

казакъ шагыйре

(1845—1904)

* * *

Дөнья — салкын,
Гүя ялкын,
Тулды кайгы гәүдәгә.
Серләшә алмыйм,
Сүз ача алмыйм
Бәндәгә.

Бер кабындым,
Бер ялындым,
Кемне күрсәм, мин аңар.
Әрнидер җан,
Дәрткә дәрман
Кем табар?

Йокы качкан,
Татлы аштан
Авыз итсәм, тәме юк.
Ял да белмим,
Дөньяның, дим,
Яме юк.

Сызлый йөрәк,
Яна дөрләп,
Бер тыныч җир кайда бар?
Үзең аң бул,
Тугры, ак юл
Сайлап ал!

Яшь яфрагы
Калтырана
Тал-тирәкнең, сукса җил.
Сулды гөлем,

Ytte гомерем,
Сынды бил.

Шат күңелле,
Чая телле,
Яши идем кайгысыз.
Хәстә — җаным,
Тирә-ягым
Инде боз.

*М. Максуд тәрҗемәсе.*

* * *

Аркасында беләктәй калын толым,
Ишетәмсең атлавында чулпы моңын?
Камчат бүрек, ак муенлы, кара кашлы,
Күргәнмидең мондыйларын син сылуның?

Хәйләсез, көзгедәй саф күзләр кара,
Баккан саен йөрәккә ялкын сала,
Ак тәнле, ачык йөзле, энҗе тешле...
Очрадымы сиңа шундый бер кыз бала?

Сыгылма бил, нәфис аяк, сылу гәүдә.
Юлыккалый шундый сылу анда-санда.
Пешкән алма шикелле чибәр кызны
Күргән кебек булам мин һаман алда.

Әгәр дә кулың тисә беләгенә,
Тамырдан лепелдәп кан йөгерә генә;
Йөзең белән сыенсаң ак муйнына,
Рәхәт-кайнар сулышы үтә йөрәгеңә...

* * *

Яшьлек уты, кайда син?
Тергезмисең йөрәкне.
Сизеп белем файдасын,
Дөнья бизәү кирәкме?

Яшәүнең табып хәйләсен,
Кешелекне кайгыртып,
Күңел корал сайласын,
Гомер юлын яктыртып.

Сөю кадерен кем белер,
Тәмен татып бакмаса, —
Җан фида, дип кем килер,
Башы гамьгә батмаса?

Дус кызганмас, жан бирер,
Юлдашлыкны акласа.
Алдыңа әйдәп кем килер,
Иренми мал бакмаса?

Мал багу да яхшы эш —
Хәләл кәсеп, алдамый.
Тик гомергә йөр, имеш,
Юньле һөнәр сайламый!

Инде нәрсә эшлибез?
Барыннан да буш калдык.
«Авызга алма төш!» — дибез,
Кылганыбыз — ялкаулык!

*Н. Арслан тәрҗемәләре.*

* * *

Яктырмас кара күңелем, ни кылса да,
Күк йөзендә Ай-Кояш чагылса да,
Дөньяда миңа синең кебек яр юк,
Сиңа миннән артык яр табылса да.
Мескен гашыйк, саргайса, сагынса да,
Яхшы сүзе гел читкә кагылса да,
Мәхәббәткә түзә ул риза булып,
Хурлык һәм мәсхәрәгә абынса да.

*Ә. Рәшит тәрҗемәсе.*

* * *

Кырык ямау йөрәктә
Хыянәтче дөньядан.
Ничек исән калсын ул
Бертуктаусыз уйлаудан?

Кайсы — үлде, кайсы яу,
Кемне сөйсә бу йөрәк.
Кайсы — үчле, кайсы — дау,
Сөялергә юк терәк.

Якынлаша картлык та,
Котылырга юл кайда?
Гамьсез — ашап юана.
Безгә аннан ни файда?!

Кан савырылса йөрәккә,
Кара артка борылып:

Шундый нәрсә ул йөрәк,
Белми мәңге тынгылык.

*Ә. Исхак тәрҗемәсе.*

* * *

Көчек алып үстердем —
Балтырымны канатты.
Бирәүгә мылтык тоттырдым —
Мәргән булды, җанга атты.

* * *

Якты күккә ашкынып үскәнсең син,
Үскәнсең кыю, кайгысыз ир булып;
Гүя җәйдә җирнең йөзен каплаган
Яшел үлән, буй җиткән иген булып.

Аннан бирле рәхимсез еллар үткән,
Урак төшәр, иген җыяр чорлар җиткән.
Эссесен дә, салкынын — барын күреп,
Хәйран күңел сынмаган, гайрәт иткән.

Авыр уйлар күтәреп авырган җан,
Кайгы-хәсрәт йөзеңә эзләр салган.
Тән тулышкан, баш — өлгергән игендәй,
Чал башыңны игәнсең җиргә табан.

Үләмен дип яшәми үләрлек җан,
Мәңге яшәр шикелле гамәл кылган.
Әҗәл килеп кул салса, җанны алса,
Гомер кайда, син кайда? — шуны уйлан.

Ир-егет бүген — адәм, иртән — туфрак,
Бүгенге көн ул балкып алдар гына.
Иртән үзең кайдасың — белмисең син,
Үлмәк өчен тугансың, адәм, уйла!

*М. Шабаев тәрҗемәсе.*



# САФА САБИРОВКА 80 ЯШЬ

# УЛ ҺАМАН ФАРВАТЕРДА

Безнең дә балачаклар бар иде! Ә инде үзегез беләсез, бала чакта күбрәк мажаралы әсәрләр белән мавыгасың, тасвирланган вакыйгаларны тормышта чынлап та булган, үз күзең белән күргән кебек кабул итәсең. Әле дә исемдә: бермәлне мин, «Боз өстендә йөз километр» дигән повестьне зур дулкынлану белән укыганнан соң, төшемдә әсәрнең геройлары — маякчы карт һәм һөнәр мәктәбе укучысы Закир дигән малай белән бергә, үзем дә төнгә каршы Идел буйлап боз өстендә мажаралы сәяхәт кылган идем...

Ул вакытта мин әле укыган китапларның авторлары белән артык кызыксынмый да идем бугай. Бераз үсә төшкәч, әлеге әсәрнең авторы Сафа Сабиров икәнен белдем, Казан университетында укыган елларда үзе белән очрашып танышырга да туры килде... Әйдәгез, кешенең — бу очракта язучының — гомер юлларына бераз гына күз салып китик булмаса.

Сафа Сабировның Бөек Ватан сугышы елларында Владивостоктан «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналына җибәргән беренче хикәяләре 1945 елда чыга башлый. Һөнәре белән елгачы булганга күрә, ул үзе яхшы белгән мохит — Идел, су транспорты кешеләре турында повестьлар, хикәяләр, нәсерләр язарга ярата. Югарыда телгә алынган «Боз өстендә йөз километр» повесте 1953 елда балалар әдәбияты әсәрләренә үткәрелгән конкурста бүләкләнә, Мәскәүдә «Пионер» журналында тәрҗемә итеп басыла, «Советская Россия» нәшриятында китап булып та чыга.

Аның «Хатлар язам сагынып» повестенда исә Татарстан елгачыларының Сталинград сугышындагы батырлыгы сурәтләнә. Әсәрнең үзәк герое — Казан елга техникумында укып чыккан Мәрьям Билалова сугыш вакытында Идел пароходында капитан була һәм фронтка киткән әтиләренә, ирләренә алмашка хатын-кызлардан бердәм команда туплый. Алар Сталинградка гаскәр, корал ташыйлар, Казан госпитальләренә яралыларны алып кайталар. Мәрьям үзенең күңел көче, фидакарьлеге белән иптәшләрен батырлыкка рухландыра, интригаларга бирешмичә, саф мәхәббәтенә тугры кала.

Иҗат эше — гаҗәеп бер нәрсә бит ул. Кемдер, бигрәк тә шагыйрьләр, яшьлектә үзенең сүзен әйтеп өлгерә. Кемдер, акыл җыйнап, күңел һәм тормыш тәҗрибәсен тәмләп кенә бүтәннәргә җиткерергә тырыша. Инде сиксәнгә баруына карамастан, Сафа абый, ару-талуны белмичә, яшьләрчә дәрт белән эшләп тора бит, күз тимәсен!

Мавыктыргыч, үтә кискен конфликтка корылган «Хәвефле сәфәр» исемле яңа повесты әле күптән түгел генә «Казан утлары» журналында дөнья күргән иде. Аның төп юнәлешен, максат-мәгънәсен бер сүз белән болай дип әйтергә мөмкин: ата-ана бозыклыгы бала күңелендә мәңгелек яра булып сызлый, уйландыра, гамьләндерә, яз-

**мышларны теге яки бу якка таба хәл итә...**

**Сафа агай, образлы итеп әйткәндә, әдәбиятка Идел пароходыннан, Идел-Кама дулкыннарыннан килгән язучы. Әмирхан ага Еники бик дөрес әйтә: «Аның үз материалы, үз теле, үз стиле бар. Гомумән, Сафа Сабиров иҗатына яхшы мәгънәсендә гадилек, табигыйлек, сүзнең кадерен белеп язу, кешеләр һәм вакыйгаларны ничек тә тормышчан, ышандырырлык итәргә тырышу бик хас нәрсә».**

**Әдәби әсәрләр язу белән беррәттән, Сафа Сабиров журналистика өлкәсендә дә даими һәм уңышлы эшләп килә. Публицистик мәкаләләре, яңа чыккан әсәрләргә рецензияләре, өлкән буын әдипләр турында истәлекләре матбугат битләрендә әледән-әле күренә тора. Җәмәгать эшлеклесе буларак та ул һәрвакыт активлык үрнәге күрсәтә. Кайчандыр үзе эшләгән Татарстан китап нәшриятында ветераннар советы рәисе, нәшриятның китап музеен төзүгә җитәкчелек итте. Авылга мәдәни шефлык отличнигы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мәртәбәле исемнәрен дә әйтеп китсәк, бик урынлы булыр. Кыскасы, ул һаман фарватерда — әдәбият агымының уртасында.**

**Сафа абый Сабировка сиксән яшь, әдәби эшчәнлегенә илле ел тулу уңае белән без аны күпсанлы укучыларыбыз исеменнән кайнар котлыйбыз, аңа сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез. Әйдә, каләмең сүрелмәсен, тутыкмасын, һәрвакыт эштә-хәрәкәттә булсын әле, Сафа абый!**

**Тормышта һәм иҗатта егетләрчә кала белгән бу әдипнең яңа язмасын укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәбез.**

**Рашат НИЗАМИЕВ.**

■

## Сафа Сабиров

# БИШБАЛТА МӨГАЛЛИМЕ

Миллэтебезнең фаҗигале язмышы турында игътибар белән, тирәнтен уйласаң, тетрәнүдән чәчләрең үрә торырлык, кот чыгарлык хәлләр күз алдына килеп баса. Кайчандыр Атлантида кыйтгасын океан йоткан кебек, безнең халык та чүт кенә юкка чыкмаган, аяусыз җәбер-золым астында күпләп кырыла барган бит.

Ерак бабаларыбыз моңа каршы күп тапкырлар баш күтәргән, изге сугышта бик күпләре корбан булган. Гасырлар буе тырышып-тырмашып та азатлыкка ирешә алмагач, күбесе өметсезлеккә төшкән; гаделсезлеккә каршы көрәштән ваз кичеп, суфилыкта, дини фанатизмда җанына тынычлык эзли башлаган.

Әмма шул ук вакытта, кара язмышка бирешмичә, туган халкының киләчәге турында тирәнтен кайгыртучы, кыю фикерле акыл ияләре дә булган. Шуларның берсе — Шиһабетдин Мәрҗани, мәсәлән, туган халкының чын тарихын язып, аның мондый фаҗигагә ничек дучар булуын күрсәткән, ачы хакыйкатькә күзен ачкан. Бу юлда ул хәтта миссионерлар мәктәбеннән дә файдалана белгән, дини сабак укыту белән бергә, шәкертләренә дөньяви белем дә биргән, аларны туган халкына хезмәт итәргә сәләтле шәхесләр итеп тәрбияләргә омтылган.

Мәрҗани эшләгән укытучылар мәктәбендә төрле елларда Хөсәен Ямашев, Исхак Казаков, Гафур Колахмәтов, Галимҗан Сәйфетдинов, Садри Җәләл, Якуб Чанышев һәм башка күренекле шәхесләр укып чыкканнар, халкыбыз тарихында онытылмас эз калдырганнар.

Болар арасыннан «Габдрахман учитель» — яшь ягыннан шактый өлкәне, беренче буын вәкиле. Мәрҗани үлгәндә ул инде уналты яшьтә булган, аны күреп, аның турында әтисенең олылап сөйләгәннәрен ишетеп үскән. Мәктәптә укып чыкканнан соң, илле ел дәвамында армый-талмый эшләгән, наданлыктан, караңгылыктан башы чыкмаган Бишбалта, Ягодный бистәсе ярлыларының балаларын аң-белем белән коралландырып, милләтпәрвәр, фән, әдәбият һәм җәмәгать эшлеклеләре итеп тәрбияләп үстергән.

Бу мәкаләдә аның кыскача тормыш юлы, педагогик һәм җәмәгать эшчәнлеге тасвирлана.

Мөселманнарны чукындыру, аларның балаларына русча укытучылар әзерләү максаты белән 1876 елда Казанда рус-татар укытучылар мәктәбе ачыла. Татар дин әһелләренең күбесе моны мәгъкуль күрми, яман сүзләр белән каһәрләп, каршы чыга. Шәһәрнең беренче мәхәллә мулласы Шиһабетдин Мәрҗани исә, киресенчә, бу чараны хәерлегә юраган, аны ачу тантанасында хуплап нотык сөйләгән, хәтта мәктәпнең педагогия советы члены булган, байтак еллар дини сабак укыткан. Беренче карашка гайре табигый күренгән бу тырышлыкның сере бик күпләргә азактан, миссионерлар мәктәбендә укучылар арасыннан туган халкы мәнфәгатен кайгыртучылар үсеп чыга башлагач кына ачыла.

Казан артындагы Олы Кавал авылы итекчесе Мөхәммәтвәли улы, уналты яшьлек үсмер Габдрахман Рафиков бирегә укырга кергәндә олугъ галим мөдәррис инде дөнья куйган булса да, аның өчен ул әле һаман исәндер кебек тоела. Мәктәптә укучылар, укытучылар арасында сүз чыкканда аның исеме, әйткән фикерләре ихтирам белән һәм еш телгә алына. Мәрхүм хәзрәт әсәрләреннән, васыять итеп әйтеп калдырганнардан яшь Габдрахманның да күп нәрсәгә күзе ачыла, туган халкының дәһшәтле язмышын белә ул.

Башта бик озакка сузылыр кебек тоелса да, дүрт ел үтеп китә, укулар тәмамлана. Хәзер инде укучылар һәм укытучылар, надзирательләр, түрәләр һәм дәрәҗәле кунаклар белән тулы зур залда мәктәпне тәмамлаучыларга тантаналы төстә аттестат тапшыру бара. Менә Габдрахман Рафиковка да чират җитә. Мәктәп инспекторы аны алга, өстәл янына чакырып алып, укуны тәмамлау белән котлый: «Инородец балаларны алдынгы рус культурасы рухында тәрбияләүдә уңышлар телим»,— дип нәсыйхәтләп, кулына аттестат тоттыра.



Габдрахман Рафиков һәм аның җәмәгате Рабига ханым (кыз фамилиясе Имангулова). 1908 елның 17 августы, Казан, Бишбалта бистәсе. *А. Ф. Федоров фотографиясе.*

Бу сүзләрнең төбендә балаларны урыслаштыру, диннән биздерү идеясе ятканын яхшы белгән Габдрахман, кинәт сулышы кысылгандай, әчке ризасызлык белән тамак кырып куя.

Аны Тәтеш өязендәге Чирмешән авылына укытучы итеп җибәрәләр. Бу — русча-татарча укыту максаты белән казна исәбенә ачылган өяздәге бердәнбер мәктәп. Чирмешәнлеләр башта ук аны ачуга каттый рәвештә каршы чыкканнар, балаларыбызны ирексезләп чукындырмакчылар дип, шикаять белән хәтта Ибраһимов Шәмсетдин дигән кешене губернаторга ходатай итеп җибәргән булганнар. Бу ризасызлык, чуалыш Рафиков килгән вакытта да әле шактый көчле була, авыл халкының күпчелеге балаларын укырга йөртми.

Әнә шундый киеренке хәлгә карамастан, яшь укытучы балаларга җылы мөнәсәбәте, яхшы укытуы белән тиз арада халыкның ихтирамын казанып өлгерә. Аның иртәнге-ахшам намазларын калдырмыйча мәчеткә йөрүен күреп, башта кырын караучылар да тәмам тынычлана, уразада авыз ачу мәҗлесләренә чакыра, балаларын шикләнмичә укырга җибәрә башлый. Бераздан соң уку-укыту округыннан килеп җентекле тикшерү үткәргән инспектор да аның эшеннән бик канәгать кала, сүз арасында күп урыннарда шундый сәләтле укытучылар җитешмәүдән зарланып та ала.

Шул инспектор тәкъдиме буенча булса кирәк, озакламыйча, 1896 елның көзендә Рафиковны Казанга, Бишбалта бистәсендә русча-татарча укыта торган икенче номерлы башлангыч мәктәпкә күчерәләр. Моның тикмәгә түгеллеген тиздән ул үзе дә күрә: чөнки ата-аналарның күбесе фанатиклар коткысына бирелгән, русча укытып диннән биздерәләр, чукындырырга әзерлиләр, дип, балаларын сабакка йөртмәс булган. Хәзер аларны тынычландырып, шик-шөбһәләрен таратып, мөмкин кадәр тизрәк укуны җайга салырга кирәк икән.

Халыкның бу чуалышы юкка түгел икәнлеген Габдрахман яхшы аңлый һәм хуплый. Әмма бет ачуын туннан алган кеше кебек, укудан, мәгърифәттән ваз кичәргә ярамый. Юкса наданлыктан, караңгылыктан гомер бакый баш чыкмаячак. Мәрҗани хәзрәт үзенең хезмәтләрендә бу хакта тикмәгә генә кабат-кабат искәртмәгән бит.

Габдрахман әле дә хәтерли: Чирмешәндә беренче дәрескә кергәндә укучылар аны аяк үрә басып, ихтирамлы сәламләп каршылаган иде. Бирелә исә сыйныфка барып кергәч, аңа борылып караучы да булмый. Бөтен класс шау-шу килә, балалар арткы партада утырган җирән чәчле базык малай тирәсендә җыелганнар да, ачулы сүзләр белән кемнедер тиргиләр. Ишек янында чит кеше басып торганын күрү белән, алар шым булалар. Аның яңа укытучы икәнен белгәч, гафу үтенгәндәй, нидер сөйләнә-сөйләнә таралышып, урыннарына утыралар. Парталарның яртысыннан күбрәге буш икән, килмәүчеләрне, чукындырудан куркып, әти-әниләре җибәрмәгәнлеге ачыклана. Теге җирән чәчле малай Сәмит исә, әтисенә әйтмичә яшерен рәвештә, үзлегеннән килгән икән.

Яшь укытучының сыйныф белән беренче очрашуы шулай башлана һәм күңелсез тәэсир калдыра. Бу хакта инспектор белән сөйләшү дә ачыклык кертмәгәч, Рафиков укырга йөрмәүчеләрнең өйләренә барып, әти-әниләре белән сөйләшергә була. Иң башлап әлеге җирән чәчле малай Сәмитләргә китә.

Казан суы буенда иске баржа такталарыннан корылган ике тәрәзәле җыйнак кына өйдә торалар икән. Хуҗа кеше, нәкъ улы Сәмит төсле җирән чәчле агай, өй артындагы алачыктан цинк калайдан самавыр торбасы ясап маташа. Укытучының ник килгәнен белгәч, озын-озак уйлап тормастан:

— Школага мин аны үзем җибәрмим. Кәферчә укыткан булып, баламны диннән яздырыр хәлем юк,— ди.— Ах, шайтан малай, урамга уйнарга чыгам дигән ие, тагын шунда каферлек дөньясына олаккан икән. Кайтсын гына, алдаган өчен кирәген бирим әле...

— Чү, нишләп диннән язсын ул?!— ди Рафиков, аны бүлеп.— Менә мин урысча укысам да, хәзер үзем урысча укытсам да, динемнән язмадым ич. Башкалар кебек биш вакыт намаз укыйм, кичләрен мәчеткә икенде-ахшамга йөрим.

— Ә-ә, шулаймы... Сез шул учительмени?!. Яңа учитель килгән, тәкъва кешегә охшаган дип кичә мәчеттә хәзрәт сөйләгән иде шул. Дөресен әйткән, димәк. Чөнки моңарчы бер учительнең дә болай килеп адәм рәтле сөйләшкәне юк иде әле.

Шул арада хуҗабикә аларны өйгә чәй эчәргә дәшеп кертә, табынга зур тәлинкә белән кайнар бәрәңге пәрәмәче китереп куя. Укытучының ашарга керешкәнче бисмилла әйткәнен күргәч, хуҗа кешенең йөзе тагы да яктырып китә, теле отыры чишелә төшә. Пәрәмәч ашап, берәр чәшке чәй эчкәннән соң:

— Анысын үзем дә аңлыйм мин, укыту, әлбәттә, файдалы эш,— ди ул, үзалдына уйлангандай.— Әмма безнең ише кара мужик баласына түгелдер. Укыган булып тырышу-тырмашудан барыбер рәт чыкмас, мәйтәм.

— Ник чыкмасын, һичшиксез, чыгачак,— ди Габдрахман.— Менә мин дә, нәкъ синең малаең кебек, гади кустарь, ягъни итек ямаучы улы идем. Тырыштым, башкалардан ким укымадым... Журналдагы билгеләренә караганда, сезнең Сәмит белемгә хирыс, сәләтле күренә, укытырга кирәк аны.

Бу киңәшкә калайчының хатыны да кушыла. Бервакыт уйланып торганнан соң, әти кеше үзе дә күнә һәм, иртәгедән башлап, Сәмитне укырга йөртергә була.

Яшь укытучы бүтән ата-аналарга да әнә шулай шик-шөбһәдән арынырга ярдәм итү нәтиҗәсендә сыйныфта балалар барысы да укырга йөри башлый. Бу очрашулар аның үзенә дә файдалы сабак була: һәм укучының тормышын, мәнфәгатен аңлап якын килергә мөмкинлек бирә. Кайберәүләр кебек адым саен коры вәгазь сөйләү, акыл сатудан бигрәк, дәресләрне җиңел аңлаешлы һәм мавыктыргыч итеп үткәрү, һәр укучыга карата гадел һәм ихтирамлы булуны үзенә бурыч итеп куя.

Күп еллар хыялланып йөргән якты максатыңа ирешү, яраткан эшең белән шөгыльләнү — зур бәхет бит ул. Эшләгән саен эшлисе килеп тора, рухи күтәренкелек белән, ләззәтләнеп эшлисең. Укытучы Рафиков та яраткан эшенә әнә шулай шатланып чума, үзенең шәкертләрен белемле һәм туган халкына турылыклы уллар итеп тәрбияләүгә дәртләнеп керешә. Рәсми программа белән генә чикләнмичә, күңелләренә туган халкына тугрылык, мәхәббәт хисе сеңдерергә тырыша. Моны укучылар гына түгел, аларның әти-әниләре дә бик тиз сизәләр. Ул хакта сүз чыкканда: «Аллага шөкер, учительдән уңдык, күз генә

тимәсен берүк»,— дип мактап сөйлиләр. Балалардан аның классына күчерүне сорап мөрәҗәгать итүчеләр дә булгалый хәтта.

Мәгәр тормышта кеше уңышын күпсенүче хөсетле бәндәләр дә була икән. Укытучы Рафиковның мәчеткә йөрүенә бәйләнүчеләр, дәүләт мәктәбендә балаларга ислам дине тарата дип гайбәт сатучылар да очрый. Яшерен рәвештә һәм читләтеп тикшерү, балалардан сораштырулар да сизелә. Әмма рәсми рәвештә гаепләргә нигез таба алмыйлар. Боларны сизеп торса да, Рафиков сабырлыгын югалтмый, берни дә күрмәгәндәй, сизмәгәндәй, тел-теш тидермәслек итеп укыта һәм шуның белән бергә җәмәгать эшендә дә җин сызганып катнаша.

XIX гасыр азагында һәм XX гасыр башында Урта Идел буенда, шул исәптән Казан губернасы шәһәрләрендә һәм авылларында да таралган йогышлы чәчәк авыруы балаларны күпләп кыра башлый, исән калучыларның битләре шадралана. Хәвефле эпидемиягә каршы көрәшкә киң җәмәгатьчелек күтәрелә. Рафиков та бу эштән читтә калмый. Бистә хастаханәсенен баш врачы Борисов укыткан кыска сроклы курста имтихан тотканнан соң, төп эшеннән буш сәгатьләрдән ул халыкка чәчәк сала башлый.

Ләкин бу кампания барышында көтмәгәндә тоткарлык килеп чыга: төрле коткы-хорафатка бирелүчән бистә кешеләре чәчәк салдырудан баш тарталар, табипларны якын да җибәрмиләр. Абруйлы укытучы бу чараның зыянлы зәхмәт түгеллеген, авыру йокмасын өчен кирәклеген аңлатканнан соң гына, бишбалталылар чәчәк салдырырга риза була. Рафиков бу эш белән ун елдан артык шөгыльләнә. Җәйге каникул вакытларында ул хәтта өязләргә чыгып авыл балаларын бәладән коткарып йөри.

Унҗиденче елның августында Елга аръягында дары складлары шартлау Казан каласына котчыккыч афәт китерә, бигрәк тә Ягодный һәм Бишбалта бистәләрендә йорт-каралты күп җимерелә, кешеләр һәлак була, яралана. Бәлагә таручыларга ярдәм комиссиясе әгъзасы буларак, Рафиковка бу мәшәкатьләрдә актив катнашырга, хәрабәләр астында калып имгәнүчеләрне коткару, хастаханәләргә урнаштыру өчен көнне төнгә ялгап эшләргә туры килә.

Туган халкының хак тарихын, фаҗигале язмышын иң элек Мәрҗани хезмәтләреннән укып белгән, иҗтимагый һәм милли җәберләүне үзе татып үскән Габдрахман Рафиков патша самодержавиесе җимерелүне шатланып каршылый, башка бик күпләр кебек, революция мәзлум халыкларга хөррият китерер дип өметләнә. Мәктәптән буш вакытларда кичләрен дары заводы эшчеләре арасында мәдәни-агарту эшләре алып бара, казармаларда кызылармеецларны укыта, Казан мөселман комиссариатыннан шәһәр хуҗалык советына вәкил итеп сайлана.

Бу эшчәнлеге өчен карагруһчы-шовинистлар Рафиковны күралмыйлар. Казанда фетнәче чехлар хөкем сөргән көннәрдә аның фатирын талыйлар, үзен зинданга утырталар. Коры җир гаскәрләре һәм хәрби флотилия десантчылары шәһәрне көтмәгәндә штурмлау аркасында гына ул үлем тырнагыннан исән-сау котылып кала.

Элек, патша елларында, татар телендә укыта торган мәктәп-мәдрәсәләргә дәүләт һичнинди ярдәм күрсәтми, мәгариф ихтыяҗларына бер тиен чыгым тотмый. Киресенчә, бюрократия тарафыннан бу эшчәнлек, гомумән, кирәксез санала, адым саен төрлечә тоткарлана. Октябрь революциясеннән соң мәзлум халыклар мәгърифәте дәүләт карамагына күчкәч, татарлар яшәгән шәһәр, авылларда яңа мәктәпләр ачыла, аларның эшен оештыру һәм педагогик кадрлар, дәреслекләр белән тәэмин итү көнүзәк проблема булып әверелә. Рафиков бу эшкә бөтен барлыгы белән чума. Үз мәктәбендә укыту һәм мөдирлек вазифасын үтәүдән тыш, ул Елга аръягы районында мәгариф халык комиссариатының җәмәгать башлангычы тәртибендәге инструкторы итеп билгеләнә. Шәһәр советына ике тапкыр сайланып, халык мәгарифе бүлегендә яңа ачылган татар мәктәпләренә педагоглар туплау, аларны укыту өчен кыска сроклы курслар оештыру белән шөгыльләнә. Шул ук вакытта рабфакта рус теле укыта, Г. Ибраһимов тәкъдиме буенча, Г. Рәхим, Г. Гали, Г. Сәгъди белән бергә, Нәшрият комитетында фәнни-фәлсәфи әсәрләр тәрҗемә итүгә тартыла.

Бу вакытта Габдрахман Рафиковның Бишбалтага килеп укыта башлавына инде чирек гасыр үткән була. Кайчандыр ул үгетләп-кыстап укыткан беренче шәкертләр — инде күптән укымышлы галимнәр, врачлар, инженерлар булып җаваплы урыннарда эшлиләр, мәшһүр «Рафиков мәктәбе»ндә укып чыгулары белән горурланалар. Хәзер аларның уллары-кызлары шунда белем ала, Бишбалтада һәр татар баласы — Рафиков шәкерте.

Шуңа күрә, табигый ки, аның педагогик эшчәнлегенә егерме биш ел тулу датасын киң җәмәгатьчелек олылап билгеләп үтә. Шул уңай белән «Кызыл Армия» газетасында (1919 ел, 12 сентябрь) басылган мәкаләсендә Ф. Әмирхан болай ди: «Бу таифә мөгаллим-учительләрне без, бер дә тәрәддәтсез, халыкның мәдәниләшүендәге гамиләрдән берсе саныйбыз. Боларның хезмәтләрен халык юлында эшләнгән бер каһарманлык дип таныйбыз... Менә бүген тәгълим вә тәрбия хезмәтенең егерме биш еллык бәйрәм-юбилеен үткәрә торган Габдрахман әфәнде соңгы таифәгә мәнсүп мөгаллим-учительләрнең иң самимиләреннән берседер».

Фатих Әмирхан үзе Рафиков белән 1912 елда таныша, аларга еш килгәли торган була. Унҗиденче елның июль аенда Рафиковның улы Хәбибрахман капитан ярдәмчесе булып эшли торган «Сорокин» исемле пароходта әдип Уфага сәяхәткә барып кайта. Ф. Әмирхан белән Г. Рафиков икәү бергә заманында беренче баскыч мәктәбенең икенче, өченче сыйныфлары өчен «Мәгариф» нәшриятында «Ана теле» дәреслекләре чыгаралар.

Җомга көннәрне кунакчыл Рафиковның иркен фатиры үзенә күрә әдәбият, сәнгать салонына әверелә: Ф. Әмирханнан тыш, бирегә Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, Ш. Әхмәдиев, Г. Кутуй, Г. Гали, Р. Ишморат, бераз соңрак яшь артистка Сара Садыйкова һәм башка әдипләр, сәнгать әһелләре килә. Рафиков мәктәбендә әдәбият укытучы яшь шагыйрь Х. Туфан дүрт ел аларда фатирда тора, шул вакытта Һ. Такташ белән очрашулары турында Х. Туфан язган мондый шигырь юллары бар:

Бишбалтага озатып килә мине,  
Ә мин аны озатам Казанга.  
Утыз чакрым йөргәнбездер инде,  
Ә сөйләр сүз  
Бетми һаман да...

Элекке урысча-татарча укыта торган башлангыч мәктәп революциядән соң Нариманов исемендәге җидееллык мәктәп итеп үзгәртелә һәм үзенең талантлы педагоглары белән, укучыларны төпле белем белән коралландырып, туган халкына тугрылыклы яшь кадрлар тәрбияләп үстерүе белән киң танылa. Аннан белем алып чыккан Бишбалта бистәсенең уллары-кызлары төрле тармакларда зур эшләргә сәләтле белгечләр булып күтәрелә. Аларның барсын санап та бетерерлек түгел. Үзем күреп, байтак еллар аралашып белгән берничәсен генә мисал итеп китерәм: татар әдәбияты хәзинәсенә кергән «Маякчы кызы», «Маратның язмышы», «Замана балалары» повестьлары авторы Гариф Гобәй; «Яшел эшләпә», «Туган авылым» исемле популяр пьесалар авторы драматург Гамир Насрый; «Бүләк», «Ана йөрәге» һәм башка китаплар авторы Әминә Бикчәнтәева — алар өчесе дә әдәбиятка беренче адымнарын шушы мәктәптә башлаган әдипләр.

Бу уңышларның башлыча талантлы педагог Рафиков эшчәнлеге нәтиҗәсе икәнлеген Бишбалта татарлары яхшы белә, чөнки бирedә барча яше-карты анда укыган, аның хәерле тәэсирен тоеп үскән, һәркайсы ихластан рәхмәтле. Шуңа күрә Рафиковның педагогик һәм җәмәгать эшчәнлегенең утыз еллыгы республика күләмендә тантаналы төстә билгеләп үтелә, аңа Хезмәт Герое дигән мактаулы исем бирелә, төрле төбәкләрдән күпсанлы котлаулар килә...

Бу вакытта Габдрахман агай Рафиковка инде илле ике яшь тулган була. Игътибар белән уйлап карасаң, әллә ни күп түгел, әле җир җимертеп йөрер чагы шикелле. Әмма югарыда тасвирлаганнардан күрәбез, ул ифрат кыен, дөньяны чукындыру, Беренче дөнья сугышы, Октябрь революциясе, гражданнар сугышы һәм ачлыктан халык меңәрләп кырылган кытлык елларда яшәгән. Шуның өстенә, һәрвакыт иҗади эзләнеп, камиллеккә омтылып эшләгән, шәкертләрен шуңа әйдәп үстергән, ятимнәренә кайгыртучан әти булган. Укып бетереп, мәктәптән чыкканнан соң да, ул аларны күздән югалтмаган: акыллы киңәшләре белән тормыш юлы сайларга бәла-казага тарыганнарга аякка басарга, юлдан язганнарга акылга утырырга ярдәм иткән.

Хәер, болар бар да һәр намуслы тәрбиячененң, укытучының төп вазифасы. Әмма хөрриятпәрвәр педагогны моннан тыш тагын бер проблема — егерменче елларның икенче яртысыннан алып илдәге сәяси атмосфераның акрынлап салкынaя баруы, милли мәдәниятkә кырын караш көчәю, шул юлда актив эшләүчеләрне кысрыклау, төрлечә җәберләүләр борчуга сала. Әнә, аның якын дустын, бергә «Ана теле» дәреслекләре язган каләмдәшен, күренекле әдип Фатих Әмирханны

буржуаз милләтчелектә гаепліләр. Аны, Татарстан җөмһүриятенең бишьеллыгына багышланган тантаналы җыелышка кертмичә, борып җибәргәннәр... Г. Тукайның якын дусты, милли азатлык идеяләре белән янып иҗат итүче шагыйрь Сагыйть Сүнчәләйнең дә, татар балалары яратып укый торган «Ак юл» журналының нәшере һәм редакторы язучы Фәхрелислам Агиевның да солтангалиевчелектә гаепләнеп кулга алынулары турында шомлы хәбәрләр килгән...

Озакламыйча Габдрахман агайның үзенә дә чират җитә. Аңа катгый рәвештә: дини кешегә совет мәктәбендә эшләргә ярамый, йә ачыктан-ачык мәчеткә йөрүеңне ташла, йә эштән китәргә тиеш буласың, диләр. Мәгариф халык комиссариаты түрәләреннән берсе, кайчандыр аның шәкерте булган кеше, моны бик уңайсызлану белән, читләтеп-уратып әйтә һәм, сәламәтлеге какшау сәбәпле дип, пенсиягә китәргә киңәш бирә. Безгә «Фанатик диндар совет мәктәбендә директор булырга, укытырга хаклымы?» — дип исемсез донос килде. Баш өстеңдә болыт куерганчы, күз алдыннан китеп торуың хәерле. Заман гел болай тормас, без сине онытмабыз, кулдан килгәнчә булышырга тырышырбыз, ди ул аңа.

Пенсиягә чыгу турында ул очраклы рәвештә әйтмәгән, сөйләшер алдыннан поликлиникадан да белешкән. Чөнки менә икенче ел инде Габдрахман абыйның башы сызлый, төннәрен уянса, сәгатьләр буе йоклый алмыйча интегә. Врачларга күренгән саен, хәзер үк ялга чыгарга, дөнья мәшәкатьләреннән, борчулардан арынып, тыныч шартларда чынлап торып дәвалана башларга әйтәләр. Шуңа күрә Габдрахман абыйга, теләсә-теләмәсә дә, бу тәкъдимне кабул итәргә туры килә. Озын-озакка сузмыйча, утыз беренче елның көзендә илле җиде яшьлек педагогны, РСФСР күләмендә персональ пенсия билгеләп, зурлап тантаналы төстә ялга озаталар.

Габдрахман агай Рафиков 1954 елның 3 маенда 81 яшендә вафат булды. Мәрхүмне соңгы юлга озатырга җыелган халык белән урамнар тулды. Туганнары һәм шәкертләре аның гәүдәсен Бишбалтадан Яңа бистә зиратына хәтле иңбашларына күтәреп илттеләр, зурлап җирләделәр.

Игелекле хезмәт кешесе үзе дөньядан китсә дә, эзсез югалмый, буыннан-буынга күчеп, аның якты исеме халык күңелендә яши.



Шагыйрь Хәсән Туфан, җырчы Илһам Шакиров һәм композитор Сара Садыйкова 1968 елның 10 маенда Габдрахман Рафиковның улы Хәбибрахман, оныклары Наилә белән Сафия һәм аларның хезмәттәшләре, танышлары арасында.

Габдрахман Рафиковның дөньядан китүенә инде кырык елдан артык үтүгә карамастан, туган халкы аны яхшы хәтерли. Матбугатта һәм әдәби кичәләрдә аның түгәрәк даталарын билгеләп үтәләр, исән шәкертләре очрашып искә алалар. Оныклары Наилә, Сафия Рафиковалар һәм Рәим Хатипов аның бай истәлекләрен, документларын саклап тоталар. Материалларның бер өлеше Ветераннар музеена тапшырылган.

Тиздән аның Бишбалта һәм Ягодный эшчеләре балаларын укыта башлауга йөз ел тулачак. Шул дата уңае белән бистә җәмәгатьчелеге исеменнән Ветераннар музее советы Бишбалта урамнарының берсенә, Рафиков исемен бирүне сорап Казан шәһәр советына мөрәҗәгать итте.

...Авыр заманнарда Мәрҗаниләр башлаган мөкатдәс омтылыш безнең көннәрдә уңышлы дәвам итә, халкыбыз яңа шартларда кыю адымнар белән алга таба атлый. Бу юлда намус белән хезмәт итү — һәркайсыбызның изге бурычы.

Сафа САБИРОВ.

■



## ХУШ, ИБРАҺИМ АГА!

Аяныч ки, 1995 елның 1 июль көне татар язучыларына тагын бер кайгы алып килде — әдип, тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме Ибраһим Зиннәт улы Нуруллин арабыздан китеп барды.

Ибраһим Нуруллин 1923 елның 18 апрелендә Ульяновск өлкәсенең Мәләкәс районы Питрәү авылында дөньяга килә.

1945 елда, сугышта авыр яраланып кайткан солдат, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә; соңрак, аспирантураны тәмамлагач, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклый.

Галим буларак, ул үзенең эзләнүләрен Г. Тукайның идея-эстетик карашларын өйрәнүдән башлый һәм бөтен гомерен шуңа багышлый. Ниһаять, 1957 елда И. Нуруллин шагыйрьнең җанлы образын бербөтен итеп күз алдына китереп бастырырлык фәнни-нәфис әсәрен — «Габдулла Тукай исемле китабын язып тәмамлый. Мәскәүдә (1977) һәм Казанда (1979) «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә басылган бу хезмәте өчен И. Нуруллинга 1982 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде. Бу үзе үк символик мәгънәгә ия иде — гомерен Тукай иҗатын өйрәнүгә багышланган әдип якты дөньядан «Тукайлы» булып китеп барды.

Соңгы елларда И. Нуруллин татар әдәбияты классигы Г. Исхакый иҗатын кабаттан халыкка кайтару үе белән яшәде һәм эшләде.

Хуш, Ибраһим ага! Урының җәннәттә булсын.

**«Казан утлары» журналы редакциясе.**



# ХАКЫЙКАТЬНЕ ЮЛДАШ ИТЕП...

Үзенең күп кенә хикәяләре, мажаралы повестьлары һәм үзенчәлекле романнары белән Атилла Расих әдәбият сөючеләрнең олы ихтирамын казанды. Күпләргә мәгълүм: ул иҗат белән фәнни эшне бергә бәйли алды һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, аның әсәрләре тема ягыннан тагын да баеды. Фән кешеләренең уртасында кайнап, аларның хезмәтен бөтен нечкәлекләре белән аңлап, көнем дип түгел, ә денем дип яшәргә кирәклеген ачык сурәтләде.

Еллар узып, җитдиләнә, олыгая барган саен кеше гомер юлын, кылган эшгамәлләрен кабат-кабат күздән кичерә, хакыйкатьнең күзенә туры карап, яшәүнең мәгънәсен ачыклый. А. Расихның «Елларны чигерсәм» исемле автобиографик романы да шушы уй-фикернең нәтиҗәсе буларак язылган. Әдип үзе яхшы белгән, тирәнтен төшенгән, алай гына да түгел, аерылмас язмышы булып әверелгән даирә турында ныклы ышандыру көче белән иҗат итә. Бу роман өчен ясалмалык ят нәрсә.

Әсәр үзе өч аерым китаптан тора. Беренчесе «Ишан оныгы» дип исемләнгән. Аның журнал варианты «Казан утлары»ның 1990 елгы 1 нче һәм 2 нче саннарында дөнья күрде. Икенче китап — «Кәгазьдәгеләр һәм хәтердәгеләр». Ул да «Казан утлары» журналының 1993 елгы 4 нче санында басылып чыкты. Өченче китап «Тыныч еллар күләгәсе» дип атала.

А. Расихның бу колачлы әсәренә гаҗәеп күп төрле төсләре һәм авазлары белән тормыш үзе килеп керә. Әсәр үткән, хәзерге, киләчәк тормыш белән чын күңелдән сөйләшү, әлек әйтә алмаганны әйтеп бушану, үзенә бик якын һәм кадерле кешеләр турында истәлек калдыру максатыннан чыгып язылган.

Трилогиянең беренче китабы — «Ишан оныгы» — нигездә, мәшһүр Зәйнулла ишанның гыйлемле килене Зәйтүнә Мәүлүдова һәм тынгысыз оныгы Атилла Рәсүлевләрнең үзләре күреп белгән, ишеткән һәм архивларда сакланган күпсанлы истәлекләренә таянып язылган. Алар безне үткән еллар, тарихи вакыйгалар эченә, әйтерсең лә, тере шаһит итеп чакыралар, бу нәсел-ыруның, язмышын кин катлау укучыларга гадел хөкем өчен тапшыралар.

Ни сәбәп булгандыр, А. Расихның әтисе Кадыйр абзый да Зәйнулла бабасы турында сөйләми, шунлыктан аның турындагы истәлекләрне оныгы А. Расих берәмтекләп үзе җыя. Бәхеткә күрә, Зәйнулла ишан турында бик күп истәлекләр сакланган икән. Бу үзе үк аның халык өчен эшләгәнлеген раслаучы дәлил булып тора. Истәлекләрнең төрле характердагылары бар һәм бу аңлашыла, чөнки дөньяда вөҗданың кушканча яшәсәң, барлык кешегә дә ярау мөмкин түгел.

1917 елда «Вакыт» типографиясендә «Шәех Зәйнулла хәзрәтнең тәрҗемәи хәле» исемле 105 битлек китап басыла. Ул Зәйнулла хәзрәтнең вафатыннан соң бик ашыгыч рәвештә чыгарыла. Китапны чыгаручы, аңа кереш сүз язучы кеше —

танылган галим, тарихчы Ризаэтдин Фәхретдин. Китапның сүз башында ул «Русия мөселманнарының олуг адәмнәреннән вә файдалы хадимнәреннән булган шәех Зәйнулла хәзрәтләре» турында олылап яза.

Әсәрдә Зәйнулла Хәбибулла улының чыгышы белән башкорт Куакан ыруыннан булуы, 1833 елда Троицк өязе, Тунгатор волосте, Шәрип авылында тууы әйтелә. Зәйнулла кечкенәдән үк белем алуга бөтен күңелен сала һәм бу омтылыш аны гомере буе озата бара. Зәйнулла ишанга төрмә-сөргеннәрне дә күрергә туры килә. Ул анда да, булдыра алганча, белемен арттыру өчен туктаусыз эшли. Күп истәлекләр аның тормыштан хәбәрдар булуы һәм файдалы яңалыкларга каршы килмәве турында сөйлиләр. «Вакыт»та (№ 2171): «Зәйнулла хәзрәт әчке Россиядәге мәшһүр затларның иң олысы һәм абруйлысы... Гасырыбыз аның кадәр мәшһүр һәм абруйлы зат күрмәгәндер диелсә, ялгыш булмастыр... Троицкидагы Зәйнулла хәзрәт әчке Россиядә иң мәшһүр вә иң атаклылардандыр. Заманында аның сүзе һәркемгә закон — шәригать иде... Вөҗданы ни кушса, шуны ачыктан-ачык сөйләде вә язып таратты»,— дип язылa. Гади халык аның киң күңелле булуы, авыруларны (хәтта акылына зыян килгәннәрне) дәвалавы, Тибет медицинасы серләрен яхшы белүе, кешегә кулдан килгәнчә ярдәм итүе турында сөйли.

Күпсанлы истәлекләр белән танышкач, Зәйнулла ишанның оныгы Атилла Расих шундый нәтиҗә ясый: «Мин хәзер Зәйнулла бабамның прогрессив карашлы, халыкка хезмәт итү юлыннан барган бер шәхес булуын аңлыйм. Хәер, бер мин генә түгел, Башкортстан галимнәре дә аның нәкъ шундый кеше булуын таныйлар, «Совет Башкортстаны» газетасының 1986 елгы бер санында алар нәкъ шул хакта язып чыктылар».

А. Расихның әтисе — Кадыйр абзый шушы мәшһүр Зәйнулла хәзрәтнең уртанчы улы булган икән. Ул, мәдрәсәдә белем алганнан соң, Истанбулда өч ел укып, төрек гимназиясен тәмамлый. Имамлык аша да халыкка хезмәт итеп була дигән тәрбия ала. «Хаталары өчен тормыш тарафыннан рәхимсез рәвештә кыйналган бер кеше»,— дип яза автор аның турында. Үзе яшәгән җәмгыять тарафыннан аяусыз кыйналса да, мин исә ул хаталарны Кадыйр абзыйныкы дип әйтмәс идем, чөнки аңа бер җәмгыятьтә тәрбия, белем алып, бөтенләй икенче җәмгыятьтә яшәргә туры килә.

Әтисенең мулла булып торуы аркасында Атилла ага гаиләсенә соңрак күп җәфалар күрергә туры килә. Кадыйр абзый Троицкида чыга торган «Вперед» газетасының 1928 елгы бер санында «Мулла порвал с религией» дигән кечкенә мәкаләсендә һәм 1930 ел башында «Фән һәм дин» журналында басылып чыккан «Соңга калган бер тавыш» мәкаләсендә ни өчен муллалыгын ташлавы һәм моның сәбәпләре турында язып чыкса да, Атилланың укуы уңай хәл ителми, әнисе үзе теләгән эшкә урнаша алмый, үзе дә эш эзләп ерак җирләргә китәргә мәҗбүр була. «Әмма кем белә, әтинең бу эше аркасында минем хафалы юллар узуым бәлки файдага да киткәндер? Бәлки шул сикәләтле юллар гына мине кеше, әдип иткәндер?»— дип уйлана автор.

Төрле авырлыклар белән Атилла мәктәпне тәмамлый. Токарь һөнәре алып эшкә урнашкач та укыйсы килү теләге сүнми. Үзенең чыгышын яшереп, авыл хуҗалыгы институтында тугыз ай гына укып кала, институттан чыгаралар... Озак уйланганнан соң, тагын бер тапкыр бәхетне сынап карау өчен, дәреслек эзләп, Мәскәүгә юл тота. Мәскәү урамнарында, тилмереп, язмышын хәл итүләрен көтеп йөргән авыр көннәрдә Атилла үзенең ата-бабасы, әнисе һәм аның нәселыруы турында кабат-кабат искә төшерә, нык уйлана. «Башкалар укыганны нишләп мин укымаска тиеш?!»— дигән нәтиҗәгә килә. «Аның ата-бабасы халыкка яхшылыктан башка берни дә эшләмәгән бит! Әйе, аек акыл белән, бүгенге көн бизмәннәренә салып үлчәсәк, аларның халкы һәм вөҗданнары каршында йөзләре ак. Аларның уй-фикерләре, кылган эш-гамәлләре бары тик ул чорның — социализмның принципларына туры килмәгән, аның кысасына гына сыймаган.

Гомумән алганда, әсәрдәге барлык истәлекләр Атилла күңелендә Мәскәү урамнарында каңгырап йөргәндә җанлана. «Ишан оныгы» романының сюжеты да шул композицион җирлеккә корылган.

Зур авырлыклар белән, үзенең тырышлыгы һәм сәләте аркасында Атилла югары белем алуга ирешә. Ләкин бу әле тормышта барлык ишекләр дә ачык дигән сүз түгел, чөнки җәмгыять һәм аның кануннары һаман да каттый.

Атилла институттан чыгарылган елны әнисенә дә институтта укырга рөхсәт ителми. Шулай да соңыннан, укырга мөмкинлек булгач, әнисе институтның татар теле һәм әдәбияты бүлеген язучы Абдулла Әхмәт, Шәйхи Маннурлар белән бергә уңышлы тәмамлый. Әтисе Кадыйр абзый да һаман белемен арттыру өстендә эшли. «Гаиләбезнең укуга булган мөнәсәбәтен һәм шул юлдагы кичерешләрне

күз алдымнан уздырам да, ирексездән үзебезне кыяларга үрмәләүче альпинистлар белән чагыштырасым килә. Мең төрле газап-җәфалар чигеп булса да, уку, белем алу иң олы максат итеп куелган»,— ди А. Расих. Язучының әсәрен башта ни өчен «Альпинистлар» дип атавы менә шуннан аңлашыла инде.

А. Расихның рухи тормышында әнисе аеруча зур урын били. «Ишан оныгы» әсәре аның көндәлек хатирәләре белән аеруча җанланып китә. Шул уңайдан, билгеле бер дәрәҗәдә, ул яшәгән дәвернең иҗтимагый һәм рухи атмосферасы да чагыла. Без бу татар хатыны тормышында булган әһәмиятле вакыйгалар, ул үзе генә тойган хисләр, кичерешләр белән танышабыз, аның серле һәм бай күңел дөньясы белән яшибез. Аның белән бергә шатланабыз, кайгырабыз, чөнки әсәрне уку барышында ул безнең көтеп алынган якын сердәшчебезгә әйләнә.

Әсәрдән күренгәнчә, Зәйтүнә ханым нинди генә авырлыклар кылсә дә, курыкмыйча җиңә белә. Халык дошманы хатыны санап, укытучылык эшеннән чыгарсалар да, ул коелып төшми, ничек кенә булса да авырлыклардан чыгу юлын эзли. Шәһәрдән авылга күчеп китеп, балалар укыта, җәмәгать эшләрендә актив катнаша, күңелен төшерми.

Зәйтүнә ханым яшьлегендә Буби мәдрәсәсендә укый. Соңыннан, Троицкида кызлар мәктәбендә укыту белән бергә, Гыйбад Алпаровтан дәресләр ала. Кияүгә чыгу да белемгә омтылышына киртә була алмый. Хаҗ сәяхәте вакытында да ул Истанбулда алдынгы мәктәпләр белән таныша, андагы уку программаларын, укыту ысулларын үзе барып өйрәнеп йөри. Бу эштә аңа ул заманда Истанбулда яшәгән зыялы милләттәшебез Йосыф Акчура ярдәм итә. Хаҗ сәяхәте вакытында да укуын дәвам иттерү — Зәйтүнә ханымның иң беренче максаты булып кала, хәтта акча җитмәүчелек тә бу эшкә комачаулый алмый.

Беренче Бөтендөнья сугышының хаҗ сәяхәте вакытына туры килүе алар өчен өстәмә кыенлыклар тудыра. Берничек тә туган илгә кайту мөмкинлеге юк. Тора-бара ашау-эчү яклары авырая, торак өчен дә түләргә кирәк, чит илдә булсалар да, әтисен солдатка алабыз, дип торалар.

Роман-истәлек буларак, Зәйтүнә Мәүлүдованың Габдулла Тукай белән үзара мөнәсәбәтләре сурәтләнгән урыннарны аеруча күңел биреп укыйсың. Вакыйгалар Фатих Әмирхан, Габдулла Кариев, Вафа Бәхтияров һәм башка тарихи шәхесләр белән бәйләнештә бирелә. «Тукайның әниемә булган мәхәббәте кайнар, серле һәм яшерен була»,— диелә әсәрдә. «Кызык гыйшык» шигырендә Г. Тукай моны үзе дә яза:

...Мин сөям, хәтта ки гакълымнан шашам —
Сөйгәнемнән шүрәле төсле качам...

Шулай ук Зәйтүнәгә атап язылган икенче бер шигырендә («...гә»):

Очраган юлда, сине күргән, иелгән ул бүген;
Ул шуңар да шатлана бит — чын җүләр түгел диген!

— дип, үзенә-үзе гаҗәпләнә. Әйе, Тукаебыз чынлап сөйгән, янган, яшерен генә шатланган. Аның тормышында, һичшиксез, Зәйтүнә якты эз калдырган, шулай булмаса аңа атап шундый шигырьләр язар идеме?

Зәйтүнә ханым да шагыйрьне гомере буе йөрәгендә саклый. Аның бүлмәсендә Тукайның моңсу, уйчан портреты яшьлек елларының якты истәлеге булып эленеп тора. Шунда ук, стенаның каршы ягында, Зәйтүнә туташ портреты, аның нурлы йөзендә яшьлек дәрте балкый. Күпме гомерләр үтсә дә, алар әле дә бер-берсенең күзләренә карап, әйтерсең лә мәңгелек очрашуга юл эзлиләр...

Г. Тукайның үлемен Зәйтүнә бик авыр кичерә, аның көндәлегендәге юллар да шул турыда ачык сөйли. Тукайның иртә үлеме халкыбыз өчен авыр кайгы, әдәбиятыбыз өчен зур югалту булды. Шулай да, романны укып, Тукай өчен шатландым: үлгәннән соң каберең янында корьән укырлык сөйгәнең булу үзе зур бәхет бит! Тукаебыз, без уйлаганча ук, бәхетсез булмаган икән: яшерен булса да сөйгән, бик аз булса да, сөелгән...

«Ишан оныгы» әсәрендә язучы тарихи шәхесләргә шактый урын биргән. А. Расих аларның күбесен үзе күреп белә, алар турында үз фикерен әйтә.

1924 елда Казанда җырчы Әлмөхәммәдев, композитор Солтан Габәши белән очрашулар авторның аеруча исендә кала. Чөнки заманында яшь Атилла музыка белән мавыга. *(Ул әле дә үзәкләрне өзәрлек итеп скрипкада уйный. А. Расих, сугыш истәлеге итеп, Германиядән скрипка алып кайткан. Бу турыда автор «Кәгазьдәгеләр һәм хәтердәгеләр» романында искә ала.)* Ә инде Атилла аганың мандолинада уйнап моңлы «Рәйхан»ны җырлавы каткан күңелләрне дә йомшартып җибәрә.

Әсәрдә дин галиме, заманында Тукайның якыннарыннан булган Муса Бигиев турында да язылган. Бу шәхес — 1910 елларда Петербургта мулла булып торган кеше. «Муса Бигиевне мулла дип атаудан элегрәк, интеллигент дип әйтергә мөмкин булыр иде»,— дип, нәтиҗә ясый автор.

Татар дөньясының абруйлы кешеләреннән Габдрахман ага Әхмәрев тә искә алына. Ул революциягә кадәр кызлар мәктәбе ачкан, җәмәгать эшләрендә бик актив катнашкан, милләтне күтәрүдә зур тырышлык күрсәтеп йөргән зыялыларның берсе. Аның улы — рәссам Чыңгыз Әхмәревне кемнәр генә белми!

А. Расихның «Ишан оныгы» әсәрен укыгач, шул ачык аңлашыла: чыннан да, Зәйнулла ишан үз оныгына бик күп байлык, зур мирас калдырган икән. Болар — гомер буе белемгә омтылу хисе, халкына мәгърифәт өстәү, аның киләчәге өчен янып яшәү. Шушы юлдагы каршылыклар белән көрәшә-көрәшә, Атилла Расих тормышта үзенең лаеклы урынын тапкан, күренекле әдип булып җитешкән. Әйе, ул чын мәгънәсендә Зәйнулла ишанның лаеклы оныгы.

Тормыш төбенә төшеп юкка чыгудан Рәсүлевләрне хакыйкать эзләү, тормышны ярату, чын кеше булып яшәү өчен көрәш, нык ихтыяр көче, аң-белемгә булган көчле омтылыш коткарып кала. Ә бит ул елларда күпме күренекле шәхесләр өметсезлеккә бирелеп, тормышта үзләренең урыннарын ала алмыйча, рухи яктан сындырылды, физик яктан күпләп юк ителделәр. «Безне бетерергә теләү безне исән калдырды»,— дип сөйләгән үзенең бер нотыгында татарның күренекле журналисты Фатих Кәрими. Һәм бу дөреслек тарих тарафыннан расланды да.

А. Расих иҗатын әлеге автобиографик әсәрләреннән башка тулаем аңлау кыен булыр иде. Чөнки әдипнең балалык елларын үз эченә алган әсәре юк иде. Ә язучының балачагы гади генә үтмәгән, безнең өчен, киләчәк буыннар өчен кыйммәтле хатирәләргә бай булган икән. Ничек бай булмасын, тууын да Истанбулның үзендә туа бит ул! Кендек әби вазифасын Расиха ханым башкара. Язучыбыз үзенең Расих дигән әдәби исемен Расиха ханымга олы хөрмәте йөзеннән алган икән. Расих исеме мәгънәле дә: гарәп телендә төпле, ныклы, җитди дигәнне аңлата. А. Расих бу исемне тулысынча аклады. Төпле акылы, нык характеры, җитди иҗаты белән бик күп укучыларыбызның олы мәхәббәтен яулады.

А. Расихның «Елларны чигерсәм» трилогиясенең икенче китабы «Кәгазьдәгеләр һәм хәтердәгеләр» дип исемләнгән. Исеме үк әйтеп торганча, ул кәгазьгә язылгыннардан һәм хәтергә уелганнардан гыйбарәт.

«Яшьлегем хатирәләре булып миндә йөз дә егерме җиде солдат хаты саклана... Ул хатлар минем өчен бик, бик кадерле. Шул өчпочмаклы хатларны кулыма алган саен, узган тормыш юлымның иң хәтәр, иң сикәлтәле һәм дәртле чорын күз алдыма китереп бастырам. Һәм шунда ук бу хатларны саклаган кешегә рәхмәтләр укыйм»,— ди автор. Армиягә алынган көннәреннән алып, Бөек Ватан сугышы тәмамланганчы Казанга, әти-әнисенә язган хатларны А. Расихның әнисе Зәйтүнә ханым кадерләп саклаган. Аларның барысыннан да әнисенә тирән ихтирам, ярату сизелеп тора. Хат саен кабатлана бу шулай да укучыны ялыктырмый, киресенчә, укыган саен ана белән улы арасында булган олы мәхәббәт, тирән хөрмәткә сокланасың гына.

Әсәрдә язучы 127 хатның яртысыннан азрагын гына файдаланган, әмма аларның бирелгән кадәресе дә байтак вакыйгаларны күз алдына бастыра.

1938 елның көзендә Атилла Казан ветеринария институтының зоотехника факультетын тәмамлый. Үз теләге белән Дагыстан якларына китеп тә бара. Андагы гаҗәеп матур табигать егетне әсир итә. Шунда җиде ай тырышып хезмәт итсә дә, ул эшләгән оешманың яшь белгечне торыр урын белән тәэмин итә алмауларын ачыклагач, Мәскәү аны Казанга республиканың җир эшләре комиссариатына белгеч итеп җибәрә.

Озакламый Финляндия белән Россия арасында сугыш башлана, Атилла үзе теләп армиягә китә. Куйбышев өлкәсенең Кузнецк шәһәрчегенә килеп эләгә. «Бу атаклы, заманында татар байлары белән дан казанган, халкыбызга Шамил Усманов кебек гүзәл шәхесләрне бүләк иткән бер кала»,— дип яза автор. Атилла әдәбият белән кызыксынуын дәвам итә. Кавказдан кайткач, өч-дүрт хикәясен «Совет әдәбияты» журналына тәкъдим итүен, бу хикәяләр турында Татарстан Язучылар союзының җитәкчесе Муса Җәлилнең бер чыгышында мактап сүз әйтүен Атилла эчке бер куаныч белән искә ала.

Әнисенә язган хатларында Атилла әдәбиятка, татар язучыларына, шагыйрьләренә кагылышлы сорауларны күп яудыра. Бу гаҗәп түгел, Зәйтүнә ханым үзе дә татар әдәбияты белән кызыксынучы югары белемле укытучы. Кирәкле газета-журналларны, әдәби әсәрләргә рецензияләрне дә Атиллага әнисе почта аша

җибәреп тора. Шулай итеп, әдәбият өлкәсендә дә алар бер-берсен яхшы аңлыйлар.

Әдәбиятның сихри көче Атилланы үзенә һаман ныграк тарта. 1940 елның 20 августында язган хатында ул «Каһәр төшкән тел» сатирик хикәясенең караламасын төгәлләп килүе турында хәбәр итә. Мәгълүм булганча, 1940 елларда сатира — татар әдәбияты өчен сирәк күренеш. Ул вакыттагы проза күбрәк чынбарлыкны расдау — тормышыбызны мактау дигән караштан чыгып эш итә иде. Хәзер аңлашыла: бу — социализмны халыкара пропагандалау өчен кирәк булган. «Минем карашымча, әдәбият иң беренче чиратта үз халкың өчен иҗат ителә. Шулай уйлап, мин язылачак хикәядә тормышыбызның күләгәле якларын, безнең алга барышыбызга комачаулый торган якларын сатира утында көйдерергә булдым»,— ди автор. Әдәби тәнкыйтьнең бу әсәргә карата нинди карашта буласын алдан ук белсә дә, Атилла эшен туктатмый. Ниһаять, «Каһәр төшкән тел»не автор «Совет әдәбияты» редакциясенә җибәрә. Кави Нәҗми әсәргә карата уңай фикердә була. Афзал Шамов исә: «Бездә сатира булырга тиеш түгел!»— дип, кискен каршы чыга. Шулай итеп, әсәрне хәзергә басарга яраклы түгел, дип табалар. Бу инде Атилла өчен әдәбият, аның җәмгыятьтәге урыны, әһәмияте, нинди булырга тиешлеге турында өзлексез уйланырга, танылган тәнкыйтьчеләрнең әсәрләрен яхшылап укып анализларга бер этәргеч була. Алгарак китеп шуны әйтергә кирәк: «Каһәр төшкән тел» сатирик хикәясе күп еллардан соң, язучы сугышлардан әйләнеп кайткач, нигезе үзгәрмәсә дә, яңа редакциядә татар һәм урыс телләрендә дөнья күрә. Әсәр әле бүгенге көндә дә үзенең актуальлеген югалтмаган.

Тиздән, хәрби хезмәтне төгәлләп өйләргә кайтабыз, дип шатланып йөргәндә, Германиянең сугыш башлавы турында хәбәр ишетелә. Барлык уйланган ниятләр җимерелә, алга яңа бурычлар килеп баса. Сугыш җилләре А. Расихны да үзенә бөтереп ала.

«Совет әдәбияты» журналының кайсыдыр бер санын укыганда А. Расих яшь язучы Габдрахман Әпсәләмовның госпитальдә язган истәлекләре белән таныша. Г. Әпсәләмовны күреп белми. Ләкин аның фронттагы кичерешләрен укыганнан соң, Габдрахманны бик якын итә башлый. Тиздән А. Расих аның белән бәйләнешкә керә. Алар даими рәвештә хатлар язышып торалар.

Бер җай чыгып Казанга кайту белән Бауман урамына, матбугат йортына ашыга Атилла. Ул анда Гази Кашшаф, Әнәс Камал белән таныша, Абдулла Гомәр, Фатих Хөсни, Кави Нәҗмиләр белән очраша. Ф. Хөсни аны үз туганыдай каршы ала, алар шуннан дус булып калалар. Шул кайтуда А. Расихны Язучылар берлегенә әгъза итеп тә алалар, билет тапшыралар. «Ул билет миндә әле дә бер истәлек буларак саклана. Идарә утырышының рәисе Тажи Гыйззәт иде. Минем иҗатым турында Гази Кашшаф сөйләде»,— дип искә ала автор.

Сугыш чоры хатлары һәм истәлекләре А. Расих хезмәт иткән армиянең югалтулары, җиңүләре турында да сөйли. Ләкин алга таба авторның хатларында җиңүгә ышаныч өстенлек ала. Шунда ук ул эти-әнисенең авыруларына да борчыла, үзенчә ярдәм итәргә тырыша. 1943 елның 8 декабрендә язган хатында «Шат күңелле Галләметдин» дигән кечкенә хикәя өстендә эшләве турында хәбәр итә. Авыр фронт шартларында, ял һәм йокы хисабына А. Расих әсәрләр язуын туктатмый. Ул үзенең иҗат эше белән шөгыльләнүенең серләрен ачып болай яза: «Бу шундый бер эш инде. Бик татлы да, авыр да. Аның файдалы ягы шунда: үзеңнең җаваплы зур эш башкаруың шатландыра һәм сине тормыш ваклыкларыннан өстен торырга өйрәтә».

«Фронт хакыйкате» газетасы татар язучылары белән фронтта очрашу үткәрә. Анда яшь драматург Гамир Насыйрый, шагыйрь Шәрәф Мөдәррис, «Фронт хакыйкате» газетасының редактор урынбасары Гани Гыйльманов, дивизия газетасында хезмәт итүче Хатип Госман, шагыйрь Нур Гайсин, журналист Габдулла Әхмәдиев һәм Атилла Расих катнашалар. Фронт штабыннан килгән бер татар майоры исә Үзәк Комитетның Нәкый Исәнбәт җыеп бастырган «Идегәй» эпосы турындагы карарын укый, гомумән, эпосның халык өчен зарарлы булуы турында сөйли. Бу инде шул чордагы матур әдәбиятның иҗат мөмкинлекләрен чикләү, сәяси идеологик карашларны көчләп тагуның бер мисалы була. Аннан соң әдәбият турында сөйләшәләр. А. Расихның «Сагынылган мәхәббәт» исемле хикәясен озаклап тикшерәләр. Шушы очрашудан соң Ш. Мөдәррис белән А. Расих тагын да якынаялар, хатлар алыша башлыйлар. Ш. Мөдәррис җибәргән дүрт-биш хат А. Расихта әле дә булса саклана.

Шул елларда «Совет әдәбияты» журналында А. Расихның «Сагынылган мәхәббәт» хикәясенә карата Латыйф Җәләйнең тәнкыйть мәкаләсе чыга.

А. Расих ул вакытта Латыйф Җәләйнең мәкаләсен, үзе әйтмешли, «ифрат авыр кичерә». «Әйтергә кирәк, әгәр ул бүген басылган һәм минем тарафтан бүген укылган булса, мин тәнкыйтьчегә әз генә дә үпкәләмәгән булыр идем», дип искә ала хәзер язучы.

1944 елның 18 сентябрендә язылган хатында А. Расих Польша җиренә килеп җитүләре турында хәбәр итә. Истәлекләрендә Польшаның Круле атлы бик фәкыйрь, әмма зур бер авылында яшәүләрен яза. Шушы авылда үзенең «Бәхет орлыклары» исемле маҗаралы повестын иҗат итә башлый ул.

А. Расих, язучы буларак, солдатларның чит илдә үз-үзләрен тотуларына игътибар итә: «Безнең солдатлар ул шәһәрләрне узганда буш, хуҗасыз өйләргә кереп, кирәк дип табылган әйберләр күрсәләр, алып чыгудан тартынмыйлар...»

Әйе, чынбарлык газеталар язганча алсу төсләрдән генә тормый шул. Әнә бер белорус егете ундүрт яшьлек немец кызын көчләве белән мактана. Иптәшләренең нәфрәтен сизгәч, ул немецларның аны өйсез калдыруын, яндыруын әйтеп, акланырга тели. Тагын бер шофер солдат, әсирлеккә бирелергә дип, куаклыктан чыккан немец солдатлары төркеменә үзенең машинасын борып җибәрүен һәм байтак кына дошман солдатын таптатып үтерүен әйтә. Бу солдат та кылган эшен, дошман кулыннан һәлак булган гаиләм өчен үч алдым, дип аңлата. Кайбер солдатлар, командирларының катгый боерыкларына карамастан, агулы агач спирты эчеп, юктан күзләрен бозалар. Бөтенләй сукыр калганнары да була... Билгеле булганча, сугыш чорының мондый тискәре күренешләре турында безнең әдәбиятта язылмады. Совет солдаты батыр һәм матур итеп кенә күрсәтелде.

...Безнең әдәбиятта эпистоляр жанрдагы әсәрләр бик сирәк күренә. Ләкин алар укучыны җәлеп итә, аның күңел түренә үтеп керә. А. Расихның «Кәгазьдәгеләр һәм хәтердәгеләр» әсәре дә безнең күңелләрне яулап алды. Чөнки әсәрдә уйлап чыгарылган геройлар, вакыйгалар юк, роман-истәлек бу ягы белән документаль әсәргә тартым. Аннан соң А. Расихның хатлары, үзе кебек, мәрхәмәтле, мәгънәле, җитди, эчкерсез. Истәлекләре шатлыклы, кайгылы, тетрәндергеч һәм шул ук вакытта гыйбрәтле дә. Әсәрдәге хатлар, истәлекләр — чынбарлыкның бер өлеше генә. Ә аларның язылмаганнары һәм онытылганнары күпмедер?!

«Елларны чигерсәм» роман-истәлеге әдипнең тормыш һәм иҗаты белән кызыксынучыларның күп төрле сорауларына да шактый тулы җавап бирә. Әсәр автобиографик характерда булса да, шул ук вакытта ул тулы бер буынның әхлакый һәм рухи дөньясын, фикер-карашларын да сурәтли.

Бу әсәр укучыны уйландыра, кешелекнең күп кенә кыйммәтләренә чынбарлык күзлегеннән карарга, кешегә бер генә тапкыр бирелгән гомерне файдасыз уздырмаска, мәрхәмәтле булырга, кешелек бәхете өчен яшәргә чакыра.

**Равия ЗАРИФ.**

Мәсгут Гайнетдин

# ВАКЫЙФ ҖӘЛАЛНЫҢ ГАЕТ ШИГЫРЬЛӘРЕ

Татар җәмәгатьчелеге һәм шул чордагы әдәбиятыбыз 1917 ел революцияләрен ничек кабул иткән? Вакыйгалар агышында ул мөнәсәбәт нинди үзгәрешләр, борылышлар кичергән? Бу сорауларга җавап безнең хәзерге фәнни әдәбиятта конкрет фактлар нигезендә бөтенләй яктыртылмаган килеш кала бирә. «ВКП(б) тарихының кыскача курсы»нда теркәлгән рәсми караш кешегә мәктәп бусагасыннан сеңдерелә башлый һәм ул, вакытлы матбугат, радио тапшырулары рәвешендә озак еллар буе өстерәлеп килде. Гүя ки гади халык революцияне дүрт күз белән көткән, мөмкинлек туу белән, аның кочагына ташланган. Гүя халык Февраль революциясенең «буржуаз» булганын тиз генә аңлап ала да, «большевиклану»— Октябрь күтәрелешен әзерләү ягына авыша...

Юк, тарихи чынлык ул кадәр туры сызыклы булмаган. Шул чор гәзитләрен карасаң, кеше мондый, кискен тарихи борылыш булган вакыйгаларны, сискәнеп уянгандагыдай иләсләнеп, аңын җыя алмас хәлдә югалып калган бер рәвештә каршы алганлыгын күрәсең. Әмма империянең чуен табаны изү, канлы патша режимы илне шул дәрәҗәдә интектергән ки: халык хөрриятне кабул итәргә дә әзер... Шуңа күрә дә хакимият тирәсендә яланып яшәүнең ни дәрәҗәдә ләззәтле, җинел табышлы, төшемле икәнен татыган, белгән кешеләр инде яңа «хуҗалар» ягына ташланганнар. Алар терсәкләре белән этешә-төртешә, уңайлырак, җылырак», иркенрәк урын алып калырга дип мыж киләләр. Гүя хөрриятне ясаучылар да, яклаучылар да тик алар гына; болар яклавыннан башка гүя хөррият бер минут та яши алмаячак...

Ә илдә дөрестән дә — хөррият. Аның сулышы, аның иркенлеге көн саен ачыграк сизелә. Аннан да бигрәк, киләчәккә якты өметләр уята ул...

Февраль революциясенә һәм шуннан соңгы хәлләргә мөнәсәбәт безнең демократик әдәбиятта ничек үзгәрүен Вакыйф Җәлалның шул елгы гает шигырьләренә карап та берникадәр күзаллап була. В. Җәлал — вакытында күзгә күренгән, әмма билгеле сәбәпләр — артык та турыдан яручы булуы нәтиҗәсендә, әдәбиятыбызда игътибардан читләтелгән шагыйрьләребездән. Г. Тукай вафат булган 1913 елда гына да ул 4-5 шигырь җыентыгы чыгара. Бу исә, бер яктан, әдәби җәмәгатьчелекнең аңарда Тукай дәвамчысын күрергә теләвен чагылдырса, икенче яктан, аның үзенең дә күңелендә шундый ук омтылыш һәм мөмкинлек сизүен искәртә. Дөрестән дә, әле 1917 елдан алдагы татар шигъриятенә күз салсак, тормыштагы хәлләргә караш-мөнәсәбәтләрнең нәкъ менә шул В. Җәлал иҗатында кайтаваз тапканын күрәбез. В. Җәлал аларны калкытыбрак, ачыграк итеп, димәк, конкретрак, гомумиләштереп бирә белә. Шуңа күрә В. Җәлал шигырьләрен ул чор борчылу-өмет-сагышларын әдәбиятыбызда тәгәлрәк чагылдырган әсәрләр дип карап була.

Июль башы. Бәйрәм — ураза гаете көне. В. Җәлал, шул уңай белән «Гает фитыр мөнәсәбәте илә» дигән шигырь язып, «Кояш» гәзитенең 7 июль (№ 1137— 1917 ел) санында бастыра. Менә ул шигырь:

Хөр бу бәйрәм! Солтанатлы көн, бүген, рәхәт, хозур!..
Балкыйдыр һәр якта-шатлык йолдызы! Һәр якта, нур! —
Тугды зур таң. Инде, балка ак кояш,— ямьләр бирер
һәм, алыр зәкъкум һавасын, илгә нык тәмнәр бирер!
Капланып торган сулышлар алсын инде киң һава,
Бәндәгә, гамь булсын оҗмах! Һәм дә булсын тик һава!
— Изге көндер — ошбу көн,— дим,— мәгъфирәт[1], рәхмәт көне!
Ошбу көннәрнең төне, һәр берсе-бер рәхмәт төне!
Ул — мөкатдәс,— дим,— гали,— дим,— һәр түбәнлектән ару.
Булса сырхаулар, тәзәлсеннәр, бу — һәр сырхаудан дару!
Хөр бу бәйрәм! Солтанатлы көн, бүген, рәхәт, хозур!
Балкыйдыр, һәр якта — шатлык йолдызы, һәр якта — нур!
— Бар да яхшы,— әмма соң рәхәт,— димен,— бәйрәм көнең...
Тик күрә алмыйм, һәммәдән бигрәк, кызыл каннар төнен.
Әйтер идем наләсез[2]мин шанлы илгә шат сәлам,
Кяшки кипкән булса каннарның силе җирдән тәмам.

Сигез бәетле бу шатлык җырын шигъриятебезнең революцияне тәбрикләп әйткән иң якты, иң уңышлы әсәрләреннән берсе дип бәяли алабыз. Бу шатлык шигыренең кешегә дә, дуслыкка да, якты көн булу ихтималына да ышанычын җуйган пессимист шагыйрь тарафыннан язылуы аның объектив мәгънәсен тагын да калкыта. Шагыйрь илдәге хөрлек чынбарлыгын якты, изге бәйрәмгә тиңли, аның барлык кешегә гомуми («гам») булуын тели, шуңа ышана, чөнки бу якты хис «һәр сырхаудан дару». Шагыйрьне тик «кызыл каннар төне» — дәһшәтле сугышның дәвам итүе генә борчый. Шигырьнең һәр гыйбарәсе кайнар, һәр сүзе диярлек үз мәгънәсенә тәңгәл килә.

Вакыт — су кебек, ага да ага: аның агымын һичнинди вакыйгалар тәэсире туктата алмый. Менә инде «революцион» илгә икенче гает — корбан гаете дә килеп керә. Вакыйф Җәлал бу гаетне дә аерым шигырь белән билгеләп үтә. «Гает корбан өметләре» дигән бу шигырен дә ул «Кояш»та (14 сентябрь, № 1162—1917) «В. Җ.» имзасы белән бастыра. Ике гает арасы-ике ай да ун көн генә ләбаса. Ә караш мөнәсәбәттә нинди тирән, тетрәндергеч үзгәрешләр... Менә ул шигырь:

Төн караңгы. Дөм караңгы... Якты шәм янмас микән?
Яңгыр урнында, ходайның рәхмәте яумас микән?
Каннан эшләнгән баганалар тәмам аумас микән?
Дөньяның шәйтаннары бер-бер богауланмас микән?
Йөзтүбән китмәсме афәт — аска капланмас микән?
Канлы диңгез фәйзе[3] кодрәт берлә пакьланмас микән?
Канга манчылган кешелек дөньясы, баштан-аяк
Фетнә чокчый, йәрсә туфрактан вә йә таштан, аяк
Һәр кешеләрдер — еланнар. Һәр күренгән җеп-таяк.—
Анда сахтә[4] булмасын ул, юлны күрсәткән маяк!
Вак-вак алдаулар, түбәнлекләр богауланмас микән?
Чәчтеләр орлык,— нифактан[5] нык кыраууланмас микән?
Бетте өлфәт бәндәләрнең җаннарында кан белән! —
Тапса, рәхәтлек-хозурлыклар таба гыйсьян белән.
Иң түбән,— этләр, песиләр,— уйныйлар гыйрфан белән! —
Чарпашалар мең зәбанилар, бүген,— Ризван белән...
Тарлана җан: әллә анлар — җан ачыткан газ микән?
Ил котырды! Әллә инсаннар, бары, ханнас[6] микән?
Җир белән күкнең арасын каплаган зур-әр бүген,—
Күрмисеңме, һәрбер инсан, бер, Нәкир — Мөнкәр бүген.
Һәр сәмави изгелекне таптап изде шәр[7] бүген.—
Җир йөзендә, бер, кыяматтер, бүген, мәхшәр бүген.
Кипте илләр... Корды күлләр... Тамчы су таммас микән?

---

[1] Мәгъфирәт — ярлыкау
[2] наләсез — зарсыз
[3] Фәйзе — муллык
[4] сахтә — ялган
[5] нифак — икейөзлелек
[6] ханнас — аздыручы
[7] шәр — оят

Бер илаһи көч белән ил инде сафланмас микән?
Сакла салкынлыкны, әй эч, шашма, тукта, йотма гамь! —
Әйдә, үткәрсен бу язмыш имтиханын һәр адәм,
Әлмисактан бирле, гыйсьян берлә мәфтүндер[1] Галәм.—
Әһле дөнья канга гашыйк булган иде дәм ба дәм[2]
Җир чыланды баштан-аяк, күк тә канланмас микән
Күккә ашмаслармы,— инсаннар туфанланмас микән?
Юк, өмидсез булмыйм әле, бар хыялымдыр, өмид
Мин фәкыйрь, булсам, хәзердә, шанлы малымдыр өмид!
Чын бәхеткә, гакыйбәтъ чөн ихтималымдыр өмид,
Сыкраныйм эчтән вә ләкин әнфәгалемдер — өмид.
Ялтырыйм бәйрәм көнемдә,— милли җан — алмаз микән?
Ут көленнән җәүһәр эзли бу каләм, гаввас[3] микән?

Бу гаеп шигырен шагыйрь иҗатындагы иң уңышлы әсәрләреннән дип санарга була. Чын шигырь итеп эшләнгән ул. Аның шундый җыйнак-җиңел (димәк, халыкчан) яңгырашлы үтә катлаулы композициясенә генә игътибар итик: сирәк очрый торган 6 юллы строфа. Аларның баштагы 4 юлы бер үк рифмалы — үзара рифмалаша. Һәр строфаның соңгы ике юлы беренче строфа белән рифмадаш. «Өмидләр» шигыре булганлыгы әсәрнең исеменә чыгарылган: соңгы строфа өмет җырлый, өмет сүзләре белән тәмамлана. Дөрес, шагыйрь ул өметнең «ут көленнән җәүһәр эзләү кебегрәк бер нәрсә булуын да искәртә. Әмма әсәрдә инде «фитыр гаете шигыре»ндәге шатлыклар, хөрлекләр юкка чыккан. Киләчәк караңгыланган. Кеше аягы тагын фетнә сукмагына тарыган,— гомуми бәхет-омтылыш чәлпәрәмә килгән: һәр кеше — елан. Вак-вак алдаулар, түбәнлекләр. Бар кеше фетнәгә омтыла... Бу хәлләрдән шагыйрь ярсып борчыла. Әмма әле ул бу ярсуын — эчке борчылу дип кенә билгели. Моңа җавап, аның күңелендә: өмет һәм якты теләкләр. Шуңа күрә риторик сораулар рәвешендәге бу өмет тә, кызыл җеп булып шигырьнең буеннан буена бара. Әмма шигырьнең төп тукымасы — алгы планга чыгарылган сискәндергеч күренешләр һәм шул афәт шәүләсеннән туган шомлы куркынычлар. Боларның һәммәсенең тарихи җирлеге бар. Революцион ил — хакимият һәм өстенлек өчен үзара сугыш чигенә якынлаша. Июль башында большевиклар, хәрби көч белән басым ясап, хакимият алу өчен кораллы бәрелеш китереп чыгаралар. Хөкүмәт, моңа җавап итеп, канлы патша чоры хокуксызлыкларына илтүче тар сукмакка баса. Генерал Корнилов житәкчелегендәге уңнар, хөкүмәтнең бу эзгә чыгуы нәтиҗәсез калмаслыгын аңлап, гаскәргә таянып, хөррият нәтиҗәләрен юкка чыгарачак хәрби диктатура урнаштырырга омтыла.

Шул чордагы барлык күренекле язучыларыбыз хәленә күз салсак, аларның да шул В. Җәлал шигырендә сурәтләнгән борчулар пәрәвезендә чәбәләнгәнен күрәбез.

Мәскәү һәм Петроградта да, Казанда да һәм Уфада да, Оренбурда да шул хәл. Г. Исхакый, С. Максудыйлар шул шартларда милләтнең чәлпәрәмә килгән көчен ничектер таркаттырмау, бердәмлеген саклау юнәлешен күзлиләр. «Март каһарманы» хикәясендә Ф. Әмирхан революционер битлеге астына яшеренеп типтергән мещаннан көлә,— шул көн «социалистларын» көлке объектына әйләндерә. Уфада Бабич «социалистларга» «мөртәт» тамгасын баса, милли хәрәкәт ягына йөз бора. Ә Г. Ибраһимов исә популистлык юлына басып, сыйнфый җирлектә яңа суеш әзерләү юлына авыша. Оренбурда да Ш. Камалның социалистлардан ризасызлыгы билгеле. Ф. Кәрими дә элекке юнәлешеннән кискен борылыш ясарга мәҗбүр: ул үзенең күз карасыдай күргән «Вакыт» газетыннан китеп, «Яңа вакыт» исемле яңа газет оештырып, үзенең элеккеге «Вакыт»ы белән бәрелешләр башлап җибәрә.

Боларның берсен дә инде тегe, ураза гаете шатлыгы дип булмый. Алар — яңадан башланган «караңгылыкта» капшанып юл эзләү, шул юлда үзара бәргәләнүләр. «Өлфәт» — тату бердәмлек беткән. «Ил котырган». Һәркем үзенчә, шул «ут көленнән алмаз эзләп», халкының юлын яктыртмакчы.

Күренә ки, В. Җәлал шигыренең сүз-тәгъбирләре хәтта шул чордагы халәтне атап күрсәтерлек образ була алалар. Бу инде әсәрнең югары фикри-шигъри гомумиләштерүгә ирешү билгесе. Шигырь шул чор халәтен уңышлы чагылдыра.

[1] мәфтүн — исереклек
[2] дәм ба дәм — тоташ
[3] гаввас — су астында йөзүче

Бу глобаль темалы әсәрләрдә социалистлар яки башка берәр социаль төркем телгә алынмый, макталмый, шелтәләнми. Шагыйрь киң җәмәгатьчелеккә («гам») мөрәҗәгать итә, җаваплылыкны аларга йөкли. Аларны өнди, аларны шелтәли, аларны үзгәртү-яңарту, җанландыру турында хыяллана. Бу (Тукайлар кебек) шагыйрь-пәйгамбәрләр эше, шагыйрь-пәйгамбәрләр йөкләмәсе. Менә шушы үзенчәлек автор иҗатының нинди омтылышлы булуын шактый искәртә. Әдәбият тарихында андый күренешне читләтеп үтү мөмкин түгел. Шагыйрь иҗатының социаль кыйбласын билгеләү дә әллә ни кыен түгел. Ул халыкка эндәшә: ул — ирекне, хөрриятне, һәм тормышны бәйрәмгә әйләндерүне тәбрикли. Ә аның революциягә кадәрге писсемист шигырьләрендә мондый мотивлар юк. Димәк, аның мондый хисләре царизмга («патша хәзрәтләре») һәм байларга («буржуазия») өмет белән бәйләнмәгән. Күрәсең, авторга социалистларның ирек, тиңлек, гаделлек идеаллары якын һәм үз булган. Моны ул үз әсәрләрендә түбән катлауга, мазлумнарга даими һәм самими теләктәшлек рәвешендә дә сиздерә: «Гарипләр күз яшен киптер... «Мәдәт мазлумга бир...» Әмма бу мәсьәләнең асылын үзгәртә алмый. Шул ук вакытта, күпләрдән аермалы буларак, кеше канын түгүне ул социалистларга да рөхсәт итә алмый, кичерми. Аның ярсу өметсезләнүләре дә нәкъ менә социалистларның (большевикларның) кораллы күтәрелеш юлына керүе белән бәйләнгән. Шагыйрь бу юлда кан океаны күрә, ирекнең һәлакәтен сиземли һәм шул хакта халкына аваз сала. Шул ук «Кояш»та (17 октябрь, № 1173—1917) басылган тагын бер шигыренә күз салыйк.

## Дөньяның лисан хәле

*Хәзерге ләүхәләр*

Күзем канлы; бөтен җәсәдемдә — кан, — кул һәм тезем канлы.
Коры җир калмаган, күптән йүеш ул, диңгезем канлы.
Зөбанилар Шәрекъның һәм Гаребнең шәүкәтен бозды;
Күрәм, оҗмахларым ишегендә канлы дошманны.
Алар сызгандылар канлы җиңен: канлы — беләкләр дә, —
Кыялар ошбу юлда бер ходайсызлык белән җанны. —
Кабахәт бөркүдер уң-сул. Зәмин бетте. Заман үтте. —
Күрәм инде хәзер, мотлак, җылан рәсмендә инсанны.
Мөсәллат булдылар[1] анлар зөбани эч вә көч берлә,
Кагалар, бер-бер артлы, читкә миннән барча ризванны.
Орылды ничә мең зәрбә сәмави дингә-фәрманга.
Мозарым каплады, шул көндә, Инҗил һәм дә Коръанны
Бикәрдер эзләвең җирдән илаһи яз вә мәгънаны.
Халыклар сөрделәр, валлаһ, иленнән динне, гыйрфанны,
Һәлакәттер! Һөҗүмнәр һәм дә астан һәм дә өстән дә
Итәләр кателе гам[2] ханҗәр белән әхван әхванны[3]
Мокаррәр исемем үчте, калды «көчле вәхши» дә намым
Җиһан шуныңдыр ки, кем итсә кабахәт телдә, гыйсьянны.
Кабер булды мәкинем һәм мәкянем[4], һәммә мәйданда,
Күрерсең кайда барсаң шунда йөз мең канлы корбанны
Дәвасыздыр җиһан дәрте! Сөям җир юк әмәлләргә,
Күрәм шул көн: хисаплар бар бөтен кылган гамәлләргә.
Гарибләр күз яшен, тәңрем, үзең киптер; бу ачлыктан
Мәдәд мазлумга бир, сакла котырганнан, котылганны.

Шагыйрьнең башка гәзитләрдәге чыгышларында да бу көннәрдә шул ук мотивлар кабатлана. Мәсәлән, солдатлар гәзите — Хәрби шура органы булган «Безнең тавыш» гәзитендә дә солдатларга багышланган махсус корбан гаете шигыре бар («Хөррият урдусына бәйрәм сәламе», 12 сентябрь, 1917 ел, № 27). Анда да:

Хыялдыр сезнең эч, бүген, авыр тойгы белән янгач,
Янарсың, дус, баш тәкъдир елан төсле яманлагач...

[1] Мөсәллат булдылар — узындылар
[2] кателе гам — гомуми кырылыш
[3] әхван әхванны — туган туганны
[4] мәкянем — яшәү урыным

...Җылындык изге хөррият вә кодсият[1] кояшында
Вә ләкин кан күрәм дуслык вә кардәшлек зыясында,—

дип кисәтә. Шул ук газиттә, инде Октябрь үзгәрешеннән соң, 15 декабрь (№ 55) санында басылган «Гаскәригә» дигән шигырьдә шомлы кан куркынычының нәкь менә үзара суешу юлына басу белән бәйләнгәнен аеруча ачык искәртә:

...Канлы ачу, золым, каһәр, ләгънәт! —
Кабер газабыдыр зәмин вә Заман.
Җирдән күккә ашты ачы хәсрәт
Зинһар әйт: кайда бар — имин, әман?!..
Кан зәңҗере чолганган лаләгә,—
Бу бәшәрдә[2] йөрәк яргыч вулкан!
Әверелде җирләр, күкләр наләгә
Коръән, Зәбур, Инәҗил вә Тәүрат — кан!

Ул чакта борын астыннан арыракка карый алмаган күпләр яңа хуҗалар табыны тирәсендә җимлерәк урын алырга дип мыж килгәндә, В. Җәлал офыкларны каплаган ерак киләчәк афәтләрен сизенә. Үзе сизенеп, әрнеп кенә калмый: шул хакта илгә җар сала,— әдәбиятның «Тугры Тукай» сызыгында кала. Менә шушы аның киләчәк язмышын билгели. Үзе дә 1922 елда фаҗигале рәвештә юкка чыга: әсәрләре күп елларга әдәбияттан куыла.

[1] кодсият — изгелек
[2] бәшәрдә — кешелектә

**Рифгать Әхмәтҗан**

# ТУКАЙ ӘКИЯТЛӘРЕНДӘ КҮЧМӘ СЮЖЕТЛАР

**Күчмә сюжет дигәннән, гасырдан гасырга, илдән илгә, халыктан халыкка күчеп йөри торган гыйбрәтле, еш кына фантастик вакыйга турындагы сөйләкне атыйлар. Шундый сөйләкне сүз сәнгате остасы (чәчән, бәхши, язучы) үзенчә эшкәртеп, бөтен килеш яисә зуррак әсәр составына кертеп, төрлечә үзгәртеп бирә алган. Мондый сюжетлар, гадәттә, халык әкиятләрендә бик еш очрый. Әмма чыгышы белән үк саф китаби-әдәби күчмә сюжетлар да аз түгел. Бөтен дөньяга билгеле Гамлет, Фауст, Дон-Жуан турындагы кыйссалар шундый сюжетларга корылган.**

**Түбәндә каралачак сюжетлар нәкъ менә китаби җирлектә таралганнар җөмләсенә керә.**

## Өч хакыйкать

Габдулла Тукайның «Өч хакыйкать» дигән шигыре XIX гасыр урыс шагыйре А. Н. Майковның «Три правды» дигән әсәренең иреклe тәрҗемәсе булып тора. Әсәрнең нигезендә яткан әкияти сюжет түбәндәгедән гыйбарәт: ничектер тоткынлыкка эләккән чыпчык телгә килә һәм өч акыллы сүз — хакыйкать әйтү бәрабәренә азатлык бирүне үтенә. Хакыйкатьләре: **«Үткән эш кире кайтмый»**, **«көчең җитмәгән эшкә тотынма»** һәм **«һәр сөйләгән сүзгә ышанма»**. Чыпчык эләктергән бәндә боларны тыңлый да: «Сүзләрең яңа түгел, әмма бар, азат бул»,— дип, кошчыкны ирекккә җибәрә. Тик чыпчык үҗәт булып чыга, ул кешегә бәйләнә, аны мыскыллый: «Әгәр мине кулдан ычкындырмасаң, корсагымда тавык йомыркасы чаклы алмаз табыр идең»,— ди. Кеше моны ишетеп үкенә, чыпчыкны юмалап кабаттан кулга төшермәк була. Менә шунда инде чыпчык әлеге «өч хакыйкать»нең никадәр актуаль булганлыгын гамәлдә күрсәтеп бирә: «Бер ычкынган чыпчык кабат тотылмый һәм син, мине тотам дип, булмастай эшкә керешмә: аннары, мин үзем тавык йомыркасыннан кайтышрак була торып, нишләп эчемә шундый йомырка сыйсын — син шуңа да ышанасың»,— дип, адәмнән көлә. Шулай итеп, бу — асылда мәсәл сюжеты һәм аны һөҗү-сатира максатларында файдалану кулай.

Бу сөйләкне Майков турыдан-туры кайдан алгандыр, безгә мәгълүм түгел, тик шунысы билгеле: аны инде XIII гасырның мәшһүр суфи шагыйре Җәлалетдин Руминең «Мәснәви мәгънәви» дигән дидактик поэмасында да күрергә мөмкин. Аннары, XIV гасырның атаклы галиме Зәкәрия Казвини бу сөйләкне үзенең «Хайваннарның хәятләре» дигән хезмәтендә китерә. XIX гасырда, А. Н. Майковтан башка, бу сюжет немец балладаларында һәм бөек украин әдибе И. Франко иҗатында чагылыш таба, һәм, ниһаять, бу сюжетка совет чорында С. Маршак та бер мәзәк-шигырь язган.

Майков әдәби күчмә сюжетлар белән, гомумән, бик мавыккан: аның шулар буенча язылган йөзләрчә әсәрләре — балладалары, поэмалары бар. Нинди сюжетның нинди характердагы әсәргә ярашлы булуын ул инде яхшы белгән.

«Өч хакыйкать» турындагы сөйләкне Майков, үзенә чордаш социаль типаж һәм көнкүреш детальләре белән баетып, сатирик әсәр итеп эшкәртеп биргән. Болай эшкәртү Тукайның иҗади сәләтенә бик муафыйк булган һәм ул Майков шигырен компенсация ысулы белән тәрҗемәләп, оригиналь әсәр тудырган. А. Майковта да, Г. Тукайда да чыпчыкны тоткан кеше типик сәүдәгәр, беренче очракта — урыс, икенчесендә — татар. Г. Тукай А. Майковның бөтен фабуласын һәм мөмкин кадәр чагыштыру, эпитет һәм башкаларын саклый. Әмма татар сәүдәгәрләренә хас булмаган детальләрне Тукай төшереп калдыра һәм нәкъ менә ошбу хәл (телне һәм шигырь үлчәмен исәпкә алмаганда) әсәрнең оригинальлеген тәшкил итә.

А. Майковта:

Именитый жил купец на свете,
Вышел раз он в сад после обеда.
А в саду для птиц стояли сети.
Видит он, в сеть попалась птичка...

Г. Тукайда:

Бер заман аулак урамнан барса Бай,
Әллә ни чыр-чырр килә, Чыпчык бугай.
Чыпчык ул, Чыпчык! Менә очты хазыйрь,
Ул очып Бай өстенүк төште хазыйрь[1] ...

Кошчык белән сөйләшеп, аны ирекка җибәргәч, А. Майковтагы купец:

Заложил сам за спину он руки
И пошел тихонько по дорожке.

Тукай бу урынны сүзмә-сүз диярлек тәрҗемәли:

Тукталыштан абзый шул чакта туеп,
Китте юлдан, кулларын артка куеп...

Чыпчыкның эчендә «йомырка чаклы алмаз» барлыгын белгәч, «У купца аж подкосились ноги» — «Һәм баса никтер аяклар да кыек». Купецның кошчыкны кабат тотмакчы булып башлаган сүзләре дә шул рәвештә төгәл тәрҗемәләнә.

А. Майковта:

Я дивлюсь и вашей братье-птице,
Что за радость жить вам по-цыгански...

Г. Тукайда:

Мин карыйм һәм дә күрәм: кош халкы сез,
Валлаһи, дим, мин сиңайтим, жалкы сез...
Йорт-нигезсез, анда оч та монда оч,
Шәпмени, җә, бу чегәннәрчә торыш?

Кошчыкның зәһәрле сүзләреннән соң «Обругал купец птицу, плюнул» — «Сүкте Чыпчыкны, төкерде җиргә Бай». Шигырьнең бетемендә дә охшашлык вә аерма шактый тәэсирле.

А. Майковта купец:

Двадцать лет молчал про этот случай,
Рассказал под хмельком на крестинах внучки.

Г. Тукайда:

Булган эшне чәчми йөрде ул һаман,
Торды яшьреп нәкъ егерме ел тәмам.
Тик фәкать бер көнне «башка ис тигәч»,
Азрак эчкәч, башка киткәчтен «пирәш», —
Кемгәдер ул иске серне итте фаш,
Бәлки, шигыйрь шуннан иткән икътибас.

---

[1] Хазыйрь — «шундук» мәгънәсендә.

Шулай итеп, А. Майковның купецы XIX гасыр уртасындагы надан урыс кебек сөйләсә һәм кыланса, Г. Тукайда «Бай абзый» XX йөз башындагы татар сәүдәгәренең теле белән сөйли һәм нәкъ шуның кебек кылана.

Г. Тукай А. Майковка караганда ике тапкыр диярлек озынрак, тәфсиллерәк язган. А. Майков халык сөйләкләре рухында һәм Пушкинның «Балыкчы һәм балык турында әкият» поэмасы үлчәмендә ак шигырь белән язган. Шуның белән Майков үз әсәрен билгеле бер шигъри традициянең бер буыны итеп куя. Тукай исә төрки «кыйсса»лар үлчәмендә һәм рухында яза.

Тышкы охшашлыкка карамастан, Г. Тукай шигыре А. Майков әсәренең татарча кабатланышы гына түгел, асылда борынгы сюжетның өр-яңача, яңа кимәлдәге варианты. Г. Тукайга кадәр булган әсәрләрдә һәм соңрак — С. Маршакта да чыпчык — аек акыл иясе һәм шуннан гайре беркем дә түгел. Г. Тукайда чыпчыкның тәфсилле шәхси сурәтләмәсе аны социаль тип дәрәҗәсенә күтәрә (шунысы ук игътибарга лаек — Г. Тукайда «птичка» — «кошчык» түгел, ә нәкъ халык мәкалендәге «карт чыпчык»ка тәңгәлләнә торган кош төре). Г. Тукайның чыпчыгы «хәсрәтле күз» белән «башлый сүз», ул хакыйкатьне аңлатканда сәүдәгәрләргә Мәскәү компанияләре белән ярышып маташмаска («алма көч житмәслек эш») киңәш бирә һәм, гомумән, байның психологиясен белеп эш итә һәм шунлыктан:

Сездиләргә сезчә: «чыпчык баш», диләр.
Әмма бездә сездән артык баш, миләр, —

дигән юллар — байлар «чыпчык баш» дип сүккән кешеләр авазы, диярге мөмкин. Гомумән, Тукайның «Өч хакыйкате» дөнья әдәбиятында бу сюжетны файдалануның иң уңышлы үрнәге булса кирәк.

## Алтын әтәч

Тукайның «Алтын әтәч әкияте», мәгълүм ки, Пушкинның «Сказка о золотом петушке» дигән әсәреннән «икътибас ителгән». Пушкин, үз чиратында, әкиятенең сюжетын Америка язучысы Вашингтон Ирвингның (1783—1859) «Гарәп астрологы турында легенда» дигән новелласыннан алган. Ирвинг төрле легендалар җыю белән мавыккан һәм фантастик сюжетка корылган новеллалар остасы булган. Берзаман ул Испаниядәге АКШ илчелегендә хезмәт иткән һәм шунда Пиреней ярымутравында булып үткән вестгот һәм гарәп дәүләтләре хакындагы риваятьләрне күпләп язып алган. Шуның белән бергә, ул гарәп әкиятләре дөньясын да бик яхшы белгән. Һәм Ирвинг үз новелласында бик ачык искәрткәнчә, атаклы хәким тарафыннан ясалган алтын әтәч турындагы легенданың тамыры гарәп әкиятләренә барып тоташа. Аларда еш очрый торган мотив — кеше тарафыннан ясалган һәм җан иясе шикелле хәрәкәт итә торган хайван вә кеше сыннары, оча торган агач атлар, сугыша белгән агач солдатлар антик чорда Александрия шәһәрендә ирешелгән техник казанышларның (Герон машиналары һ. б.) кыргый гарәпләр аңындагы чагылышы булып тора.

Ирвинг шактый күләмле чәчмә әсәрләрендә (анда алтын әтәчтән башка тылсымлы карта, җир асты сарайлары һ. б. да телгә алына) борынгы Кордова һәм Гранада хәлифә вә әмирләренең сугышчанлыгын, деспотизмын, акылсызлыкларын фаш итә һәм шул ук вакытта фән-техника казанышларын сугыш юлында файдалануның никадәр түбән эш булуын күрсәтә.

Пушкинның «Сказка о золотом петушке» әсәре үз заманындагы патшага каршы сәяси сатира булып тора (бу турыда Анна Ахматованың зур гына махсус тикшеренүе бар). Тукай әсәре исә, гүяки, асылына кайта — ул гыйбрәтле бер Шәрекъ кыйссасы гына.

Шунысы кызыклы ки, һәр өч әдип сюжеттагы вакыйганы үзләре теләгән урынга күчерә, тик патшага алтын әтәч бүләк итүче Шәрекъ хәкиме генә һәр өч әсәрдә бердәй диярге була.

Ирвингта Гранада әмиренең ил чигенә барып очраткан чибәр кызы — борынгы вестгот кәникәсе (принцессасы). Моның белән Ирвинг: «Туктаусыз сугышлар заманасында бер яулап алучының башына икенчесе житә», — дигәндәй була. Пиренейне яулап алган вестготларны гарәпләр җиңә, әмма гарәп әмире Абен Абусны вестготларның өрәге — әлеге шул кәникә һәлак итә.

Пушкинда «царь Дадон» (урыс фольклорында Дадон — көлке кыяфәтле кеше, Бова Королевич турындагы атаклы эпик әкият персонажы) ил читендә Шәмәхә ханбикәсен очрата.

Тукайда «Мәмәт атлы һират ханы» (Мәмәд Солтан турында әкиятләр төрекләрдә һәм әзәрбайҗаннарда очрый) «царь Дадон»ның тулы күчермәсе булып тора. Пушкин әсәрендә дә, Тукай әкиятендә дә бердәй сатирик детальләр кулланыла: үлеп яткан шаһзадәләрне күргәч, патша артыннан бөтен гаскәр дәррәү аһ ора һәм аларның аһы тауларны тетрәтә. Ләкин әле генә кайгысы шулчаклы зур булган карт патша, алдына чибәр кыз чыгу белән, ихтыярын югалтып, нәфес юлына китә... Болар, һичшиксез, һөҗү элементлары. Шул ук вакытта монда Шәрекъ стиленә хас хәттин ашырудан да көленә. Патша, сугышкак булу өстенә, демагог — фарисей, азгын һәм сүзендә дә тормаучан булып сурәтләнә.

Гомумән, «Өч хакыйкать»тән үзгә буларак, «Алтын әтәч» турындагы риваятькә югары фәлсәфи оеткы хас: монда «хакыйкатьләр» өчәү генә түгел, сансыз, монда күп катлы сәнгатьчә хакыйкать өстенлек итә. Гомумән, «Алтын әтәч» турындагы легенда иҗтимагый үсешнең югары баскычларын чагылдыра һәм аны төрлечә эшкәртү мөмкинлекләре киң.

## Сак-сок

Тукайның «Халык әдәбияты» дигән язмаларында «Сак-сок бәете» турында тәфсилле мәгълүмат беренче тапкыр бирелгән дип әйтергә мөмкин. «Сак-сок»ның киң таралган мәгълүм варианты да тулай сайлап алган «тәнкыйди текстка» нигезләнә, ахры (Тукай үзе кулына кергән вариантларның артык озын булуын, аны кыскартырга туры килгәнлеген яза). «Сак-сок бәете»нең элегрәк бөтенләй бүтән үлчәм белән язылган вариантлары да булган, әмма алар бөтенләй онытылганнар.[1] Сак-сок турындагы бәетне татар халкының үз җимеше дип атарга мөмкин. Бүтән төркиләрдә «Сак-сок» дастаны булганлыгы мәгълүм түгел. Дөрес, чувашларда «Сак-сук» балладасы бар, әмма ул, күренеп тора ки, татарчадан сүзгә-сүз тәрҗемә.[2]

Үзенең әдәби характеры буенча «Сак-сок» — язма фольклор җимеше. «Мәдрәсәләрдә китап киштәсе», «мәдрәсәләрдә пыяла ишек» шикелле юллар анда юкка гына килеп кермәгән: бу әсәрне төптә шәкертләр иҗат иткән.

«Сак-сок» (сак һәм сок) ның килеп чыгышы турында бик күп фикерләр әйтелгән. Мәсәлән, сакны турыдан-туры сак (бдительный), ә сокны сок (жадный до еды) дип аңлату, яисә угыз төркиләрендәге (әзәрбайҗан, төрек, төрекмәннәр һ. б.) сак, саг «уң» һәм сук «сул» сүзләренә кайтару; ниһаять, көньяк Уралда капма-каршы юнәлештә аккан Сак һәм Сок (Сук) елгалары белән бәйләүләр шактый кызыклы.

Археолог А. Халиковның Сак сүзен борынгы саклаб, саксин һәм сак дигән кабилә исемнәре белән баглап каравы да игътибарга лаеклы.[3] Шуны әйтергә кирәк, әлеге фикерләр бер-берсенә кискен каршы килми — алар бер үк тарихи хакыйкатьнең төрле чагылышлары булырга мөмкин.

Һиндстанда язылган атаклы Сукапрабандһа («Тутыйнамә»нең һиндчә варианты) китабында шундый легенда китерелә: Вишвавасу һәм Малавати дигән ике фәрештә, җыр белән мавыгып, Индра дигән алланың кушканын үтәргә кичегәләр. Шуннан Индра үзе аларны эзләп китә. Болар, алланың каһәреннән куркып, берсе тутыйга, икенчесе майнага (көньяк сыерчыгына) әверелеп качалар. Индра аларны «мәңгегә шулай калыгыз» дип каргый. Һинд (санскрит) телендә тутыйкош — суука, ә майна — сарика, сарка, сака. Легенда сюжетының да, исемнәренең дә охшашлыгы Сак-сок (Сак белән Сок) риваяте шул Сака һәм Сука турындагы мифологик сөйләк белән баглы булуына шик калдырмый.[4]

---

[1] Яхин А. Г., Бакиров М. Х. Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе. Казан, 1979. 92—95 бб. Бакиров М. Х. Бәет эволюциясенә бер караш. «Татар фольклор жанрлары». Казан, 1978. 58—61 бб.

[2] Чаваш халах самахлахе. 4 т. Шупашкар, 1979. 286—296 бб.

[3] Халиков А. Х. Татар халкының килеп чыгышы. Казан, 1974. 28—34 бб.

[4] Сака һәм сука турында k. Das Paragejenbuch. Berlin, 1981, 292—298 bb. Monier-Williams A'Sanskrit-englich Diktionary, Оксфорд, 1899(1964), 1045 б.

Шунысы кызыклы вә гыйбрәтле ки, Сак һәм Сок дигән кошларның чынлап булуына халык күптән ышанган. Сок инде үлгән, Сак кына калган дип сөйлиләр.[1] Чыннан да, безнең якларда тутый, билгеле, кыргый хәлдә яши алмый. Ә майна — сак килеп чыгарга мөмкин. Көньяк Уралда Сак дигән кошның тавышын ишетеп йөргәнлеге турында М. Гафури дә яза.[2]

Майна-Сак, тутый шикелле үк, читлектә тотыла һәм сөйләшергә өйрәнә ала. Сак кошының кешедән килеп чыгуы турында легендалар барлыкка килүгә, күрәсең, аның кыяфәте дә этәргән: сак-майнаның күз карасы һәм күз агы ачык аерылып тора (бүтән кошларда күз карасы гына күренә), шуның белән ул озын борынлы кешене хәтерләтә. Борынгы һиндчә (санскритча) сака сүзе хәзерге Казагыстан җирендә яшәгән Сак дигән борынгы фарсы кавеме (атамасы белән баглы) әмма кайсы беренче икәнлеген әйтеп булмый). Шулай итеп, тарихчы А. Халиковның «Сак-сок»ны ерак үткәндәге саклаб, саксин, саклар белән бәйләп каравы, ихтимал ки, хакыйкатьтән ерак тормыйдыр. Гомумән, дөнья кителгәннән таррак: кайчакта, мөгаен, очраклыдыр дип уйланылган охшашлыклар астында тирәнтен уртаклык ачылырга мөмкин.

Татар шәкертләре дөньясына Сак белән Сук (Сок) турында легенда ничек килеп эләккәндер — монысы безгә әлегә мәгълүм түгел. Тик шунысы ачык: «Сак-сок бәете»ндә беренчел (ихтимал, бик катлаулы булган) сюжеттан тик гыйбрәт алуга хезмәт итәрлек өлешләр генә торып калган, ягъни, «бер дә юк өчен» каргарга ярамый, дигән нәтиҗә генә күз алдында тотылган, шикелле.

Мисаллардан күренгәнчә, Г. Тукай күчмә сюжетлар файдаланганда иҗади бурычка ярашлы рәвештә төрлечә эш иткән. Бер очракта («Өч хакыйкать») күчергеч текстның сәнгатьчә детальләре файдаланып, әсәр асылда нык үзгәртелсә, икенче очракта сәнгатьчә детальләрне файдалану бик чамалы («Алтын әтәч»), яңа детальләр күп өстәлә, әмма әсәрнең төп корылышы, астары саклана. «Сак-сокны» Г. Тукай, аның үз сүзләренә караганда, бик нык кыскарткан, «кирәклесен» генә калдырган.

## Шүрәле, әбедә һәм ярымтык

Шүрәле сурәте һәм сүзе Идел-Урал буе өчен хас, монда барлыкка килгән булса кирәк: кыргыз телендә шурали, казакъ сөйләмнәрендә сөрәле сүзе бар барын, әмма кыргыз һәм казакъ телләренә бу сүзләр татар теленнән (татар мөгаллимнәр аша) кергән булуы бик мөмкин.

Бу сүзнең килеп чыгышын билгеләү бик кыен. Хикмәт шунда ки, аны төрлечә аңлатып була. Өстәвенә, алда күрербез ки, шүрәле сурәте татар мифологиясендәге әбедә һәм ярымтык сурәтләренә баглы.

Шүрәле сүзенең хәзерге көндә унлап этимологик аңлатмасы бар. Һәрбер дөрес этимология барлык булган фактларны һәм соңыннан мәгълүм булганнарын да бертөрле аңлатып бирергә тиеш. Шуңа күрә башта барча билгеле мәгълүматларны китереп үтик.

Шүрәле сүзе һәм сурәте хакында матбугатта тәүге тәфсилле мәгълүматны венгр галиме Г. Балинт венгр телендә 1875 елда чыккан «Казан татарлары теленнән үрнәкләр» дигән китабында бирә. Ләкин озак вакытлар, гадәттә, шүрәлене «леший» дип кенә бик гадиләштереп аңлату аркасында, шүрәле образының оригиналь чалымнары югалып калган.

Г. Тукай әкиятендәге шүрәле инде «леший» генә түгел. Ул бик конкрет чалымнары белән бирелгән: бер мөгезле, аның бармаклары озын — шулар ярдәмендә ул урманда үзенә очраган кешеләрне кытыклап үтерергә мөмкин. Шуның белән бергә, шүрәле бик үк акыллы яки хәйләкәр дә түгел: гади авыл егете аның бармакларын бүрәнә ярыгына кыстыра ала һәм өстәвенә үзенең исемен дә Былтыр дип алдап китә.

---

[1] Материалы по татарской диалектологии. Казан, 1983. 151—152 бб.
[2] Гафури М. «Әсәрләр», 4 т., 1982. 420 б.

Г. Тукай әкияте 1907 елда язылган һәм аны шүрәле турында Русиядә беренче тәфсилле фәнни язма дип тә карарга мөмкин. Шуннан со өч ел үткәч, Казан университетының тарих вә филологиягә багышлнган еллык җыентыгында *(ИОАИЭ, 1910 XXVI, 415—475 б.)* Я. Ф. Кобловның «Мифология Казанских татар» дигән хезмәте басылып, шүрәле турында төрле әкияти сөйләмәләр дә бәян ителә.

Озакламый Н. И. Ашмаринның атаклы чуваш сүзлеге басыла башлый: ул сүзлектә (Ар-Сури мәкаләсендә һәм бүтән урыннарда) шүрәле турында күп кенә яңа мәгълүматлар бирелә.

Ниһаять, 1910 елларда Ә. Гобәйди үзенең «Шүрәле каргаган авыл» дигән поэмасын язып чыга. Анда шүрәле икенче яктан ачыла: ул төнлә атка менеп йөреп, аны алҗытып бетерә. Һәм бер агай шүрәлене тоту ниятендә атының аркасына күп итеп сумала сылый. Төнлә шүрәле, гадәтенчә, атка атланып йөри, ләкин, таң аткач, инде төшәм дисә — төшә алмый: ул атка ябышып калган була. Иртән теге агай шүрәлене тотып, бөтен авыл халкын җыя һәм бу җыен шүрәлене утта яндыра.

Шүрәле турында сөйләкләр тагын 1913 елда «Аң» журналында һәм, ниһаять, 1987 елда чыккан «Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар» китабында бастырыла. Бу басмаларда шүрәле хатыннарының имиләрен аркага ташлап йөрүләре, атка атланганда артка карап атланулары һ. б. тәфсиллекләр искә алына.

Шүрәле исемендәге рух турында сөйләкләрнең күбесе татарга карый. Мари һәм удмуртларда шурали, урали рухы турында әкият-сөйләкләр бар, ләкин сирәк очрый. Чувашларда шурел (шүрәл), шүрәгәй, шүрәкәй дип кечкенә, көчсез рухларны атыйлар.

Шуның белән бергә, шүрәле турында булган барлык сөйләкләр вә тәфсиллекләр мариларда овда дигән рухка, ә чувашларда ар чури һәм ама чури дигән рухларга япсарыла.

Овда, авда, абыда сүзенең чувашча параллеле абыда, апыта, татарчасы әбедә (Тау ягында, З. Бәшири мәгълүматлары буенча, атапа, апата, ләкин бусы чуваштан алынган вариант). Төптә бу сүз Себер төркиләрендә һәм монголлардагы абита, амита дигән рух исеменнән килә; аны ахыр чиктә санскрит телендәге амитһаба «табигать рухы» сүзеннән дип уйлыйлар. «Татар халык иҗаты. Әкиятләр» китабының беренче томында әбедә сүзен әби сүзеннән дип аңлаталар, ләкин бу дөрес түгел (әби сүзе әбәй варианты аркылы борынгы абагай, апагай вариантыннан килә һәм апа сүзе белән тамырдаш).

Чувашның ар чурисе «ир яртысы», ә ама чурисе «хатын яртысы» дигән сүз. Асылда бу татардагы ярымтык рухы атамасының бер варианты. Евразиянең бик күп халыкларында сыңар күзле, бер аяклы, бер куллы җан ияләре турында сөйләкләр йөри. Удмуртларда алар паләс мурт (ярты кеше) дип, ә эвенкларда чулурэ, чулокэ (татарча чулак сүзе шуннан түгелме икән?) якутларда сучуна, коми һәм ненецларда хумпал, гарәпләрдә ниснас, фарсыларда шыр дип атала һ. б.

Шүрәле сүзе каян килеп чыккан соң? Мин башта шүрәле сүзенең этимологиясен ар чури белән баглап карадым: шүрәле чувашча чуриле, борынгы чувашча җаралы (җары борынгы төркичә яры «ярты») сүзеннән булыр дип язып йөрдем. Ләкин бу аңлатма артык катлаулы булып чыкты. Аннары, нәкъ менә «яртылык» шүрәлегә хас түгел (дөрес, ярымтык сыйфатлары бөтенләй «Ярты» мәгънәсендәге сүзгә бәйле булмаган овда — әбедә атамалы рухка да хас, әмма бу инде икенче мәсьәлә һәм аны марилар аңлатырга тиеш).

Шүрәле сүзенә безгә кадәр ясалган аңлатмаларның кайберләрендә дә шундый ышаныч ята: чувашча шүвер әле «очлы куллы» (?), марича шугырлы «мөгезле» (?). Ләкин бит, әйткәнебезчә, чуваш һәм мариларда шүрәле сүзе сирәк кулланыла. Чуваштан һәм маридан дип барганчы, хакасча сүрүнле «хәтер, куркыныч» сүзеннән яисә әлеге эвенча чулурэ «ярымтык» сүзеннән дип уйлау табигыйрәк.

Кайберәүләр, шүрәленең хас сыйфатларына бик үк игътибар итмәстән, шүрәле сүзен урысларның чурило, чурилья «бичура» сүзеннән дип (мәсәлән, «Мифы народов мира» дигән икетомлыкта), яисә ерак эвенклардагы чурил «кәрлә рух» сүзенә баглап һәм, хәтта, чура иле «хезмәтчеләр авылы» сүзеннән дип тә аңлатып карадылар. Ләкин бу аңлатмалар башлыча сүз яңгырашына гына нигезләнгәннәр шикелле.

Безнең хәзер уйлавыбызча, шүрәле сүзе татарның үзендә чүрәле «кирегә караган» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан. Шүрәлегә дә, әбедәгә дә һәм ярымтыкка

да атка менгәндә артка карап утыру вә, гомумән, аякның артка каравы нисбәт ителә. Татар телендә чүрә «кире, тискәре» (яракның чүрә ягы диләр). Шуннан кайбер сөйләмнәрдә уңлы-чүрәле дип тә сөйлиләр. Чүрә сүзе «тискәре (як)» мәгънәсендә бүтән көнбатыш кыпчак телләрендә: кумыкларда, карачай-балкарларда да очрый. Нугайларда бу сүз шүрә яңгырашын ала (оңлы — шүрәле «уңлы — тискәре»).

Урман иясенең, кыргый адәми затның — атаклы «кар кешесенең» һ. б. аягы артка караган булу мотивы Евразия фольклорында киң таралган: Э. Хиллари һәм Д. Дойчның «кар кешесен (йэтине)» эзләүгә багышланган «Суык шыганнарда» *(На холодных вершинах. М., 1983)* дигән китабында (49—69 бб.) «барча җирле легендалар кар кешесенең аягы кирегә карый дип раслый», диелә. Монголлар алмас (албасты) турында да шуны сөйли. Хәтта ерак Африкада да «җир ияләрен ярты метрлы, аяклары тискәре нәрсәләр итеп күзаллыйлар» (М. Л. Вольпе. *Эсхатологические представления африканцев. «Народы Азии и Африки», 1988, № 4. 50—58 бб.).* Әлеге «овда — апыта турында сөйләгәндә,— ди мари мифологиясен тырышып өйрәнгән венгр галиме Өдән Бэке — һәрвакыт аның аяклары кирегә караганлыгы, шуның нәтиҗәсендә аның эзеннән барып ялгышулар һ. б. искә төшерелә». Овда һәм шүрәленең атка кирегә, артка карап утыруы да шуннан килә. Башкортларда тиресаяк (тирескә-тискәрегә караган аяклы) дип һәртөрле җен-шайтанны атыйлар (Башкорт һөйләштәренең һүзлеге. П. Өфе, 1968. 249 б), ә сүрәкә (чүрәкә) дип ниндидер кәрлә рух атала. Чувашча, инде әйткәнебезчә, шүреке (шүрәкә) — «вак рухларның бер төре», а татар сөйләмләренә чүрәкә — «башы кәкре итеп бөгелгән таяк, кәшәкә» — болар барысы да, чүрәле кебек үк, әлеге чүрә нигезеннән ясалганнар.

Чүрә нигезе үзе явыз рух атамасы түгел микән, дип уйлаучылар булыр. Түгел шул. Чүрә сүзе, һичшиксез, борынгы кыпчакча чәүрә (шуннан чувашча сявра), төрекчә чәврә (cevre) «әйләнеч, әйләнә-тирә» сүзеннән, чәүермәк, чәвермәк» әйләнмәк фигыленнән ясалган сүз.

Инде «ни өчен чүрәле түгел, ә шүрәле соң?» — дигән сорау бик урынлы.

Минемчә эш болай тора, шүрәле сүзе (һәм сурәте) бөтен татарга Казан арты сөйләменнән таралган. Казан артында, бигрәк тә Дөбьяз урынчылыгында, ч авазыннан качу, аны с — яисә ш — белән алмаштыру тенденциясе көчле. Шуңа күрә биредә чүрә, чүрәкә, чүрәле сүзләре шүрә, шүрәкә, шүрәле булып әверелүе бер дә гаҗәп түгел (ә чувашлар һәм марилар шүрәкә, шүрәле сүзләрен татар сөйләшләреннән алганнар). Бәлки чүрәленең шүрәлегә әверелүендә тау ягы сөйләшләрендәге шүберле «җен» сүзе дә роль уйнагандыр.

Әлбәттә, китерелгән этимология әле өстәмә дәлилләргә һәм аныклауларга мохтаҗ. Ләкин ул безгә билгеле булган барлык мәгълүматларга туры килә.

# САРМАН САНДУГАЧЛАРЫНЫҢ БЕРСЕ

*Сандугачлар кунып кайда сайрый? —*
*Сарман буйларында тирәктә...*



Җырларда мактап җырланган Сарман яклары — әдәбиятыбыз вә сәнгатебезгә шактый гына сандугачтай талантларын бүләк иткән як. Бүгенге көндә күренекле язучы булып җитешкән, актив җәмәгать эшлеклесе Мәдинә Габделхак кызы Маликова да әнә шушы җырлы, сандугачлы Сарман районының Мортыш Тамагы авылында 1935 елның 5 августында туган. Балачактан ук әдәбиятка-сәнгатькә гашыйк кыз, җидееллык мәктәп тәмамлаганнан соң, башта Минзәлә педагогия училищесында, аннары Казан дәүләт педагогия институтында белем ала. Институтның тарих-филология факультетын уңышлы тәмамлап чыкканнан соң, ул — журналистлык хезмәтендә. «Чаян» һәм «Азат хатын» (хәзерге — «Сөембикә») журналларында эшли. Бу елларда ул журналист буларак та, язучы буларак та осталыгын үстерә. Аның вакытлы матбугатта, «Азат хатын», «Казан утлары» һ. б. журналларда тормышның көнүзәк мәсьәләләрен яктырткан очерклары, матур-матур хикәяләре дөнья күрә. 1967 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Юлдашлар» исемле хикәяләр китабы татар әдәбиятына тирән әхлакый проблемаларны тормышчан образларда чагылдыручы, үткен каләмле прозаик килгәнлеген бик ачык күрсәтә. Шуннан соң аның акыл хезмәте кешеләре — инженерлар, рәссамнар һәм башка иҗат кешеләре тормышын, аларның катлаулы эчке кичерешләрен чагылдырган «Кояш күпере» (1973), «Казан каласы — таш кала» (1967), «Янартаулар яктысында» (1977), заман зилзиләләрен сынмыйча кичә алган татар хатыны образын үзәккә алган «Язгы такыялар» (1974) повестьлары басылып чыга. Аларның берсе дә укучылар һәм әдәби җәмәгатьчелек игътибарыннан читтә калмый. «Хөкем» (1969) һәм «Адашканга юл кайда?» (1971) исемле мажаралы повестьлары Мәдинә Маликованың детектив жанрда да уңышлы иҗат итә алуын күрсәтте.

Тема һәм жанр төрлелегенә омтылу юнәлешендәге эзләнүләрен дәвам иттергән хәлдә, ул 1983 елда үзенең «Ак давылда тал бөресе» («Шәфкать») дигән романын «Казан утлары» журналында бастырып чыгарды, яратып, гыйбрәт алып карарлык сәхнә әсәрләре дә иҗат итте.

Мәдинә Маликова, нәтиҗәле иҗади җимешләр бирүдән тыш, җәмәгать эшләрендә дә актив эшләп килә: ул шактый еллар Татарстан Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы, идарә каршындагы Матур әдәбиятны тарату комиссиясе җитәкчесе булды. Хәзерге вакытта ул — Бөтентатар Кызыл Ай җәмгыяте президенты буларак бүгенге катлаулы чорда күпләгән мохтаҗларга ярдәм кулын suza.


Язучылык, журналистлык иҗаты һәм актив җәмәгать эшчәнлеген исәпкә алып, Мәдинә Маликовага 1976 елда Татарстанның атказанган мәдәният

хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелде, ул 1980 елда Татарстан журналистларының Хөсәен Ямашев исемендәге республика премиясенә лаек булды.

Түгәрәк юбилее уңаеннан без каләмдәшебезне ихлас котлыйбыз, аңа киләчәктә дә мул җимешле иҗат сөенечләре, гаилә бәхете, җан тынычлыгы белән озын гомерләр телибез.

**«Казан утлары» журналы редакциясе.**

# НАИП ЛАИСОВКА 60 ЯШЬ



Наип Хәбибназар улы Лаисов 1935 елның 10 августында Татарстанның Актаныш районы Түбән Яхшый авылында колхозчы гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылы мәктәбендә ала, аннары, күрше Олы Имән авылындагы җидееллык мәктәпне тәмамлап, 1950—1954 елларда Минзәлә педагогия училищесында укый. 1954 елның көзеннән 1957 елның июленә кадәр Совет Армиясе сафларында хезмәт итә.

1957—1962 елларда Н. Лаисов — Алабуга педагогия институты студенты. Институтның рус-татар филологиясе бүлеген тәмамлаганнан соң, аны рус һәм чит ил әдәбияты кафедрасында эшләргә калдыралар. Шунда ул 1967 елның көзенә кадәр башта ассистент, соңыннан өлкән укытучы булып эшли.

1967—1970 елларда Н. Лаисов Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы каршындагы аспирантурада укый һәм, аны уңышлы тәмамлагач, кандидатлык диссертациясе яклап, яңадан Алабуга педагогия институтына кайта. Хәзер ул — Алабуга педагогия институты ректоры.

Язучы буларак, Н. Лаисов әдәбият белеменә караган фәнни хезмәтләре һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән билгеле. Аның Тукай иҗатының лирик-эстетик хасиятләрен ачуга, анализлауга багышланган «Лирика Тукая (вопросы метода и жанра)» исемле (1976) һәм М. Мәһдиев, Ф. Ганиевалар белән берлектә язган «Әдәбият теориясе» дәреслек китабы (1979) матбугатта уңай бәя алды. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә Н. Лаисовны күбрәк поэзия проблемалары кызыксындыра. Аның М. Җәлил, Х. Туфан, С. Хәким, Р. Харис, М. Шабаев һәм башка шагыйрьләр иҗаты турындагы мәкаләләре теоретик яктан нигезле, дәлилле һәм заманча гомумиләштерүләре белән кызыклылар.

Н. Лаисов — 1984 елдан Язучылар берлеге әгъзасы.

Каләмдәшебезне юбилей уңаеннан кайнар котлыйбыз һәм яңа иҗади уңышлар, олы шатлыклар телибез.

**«Казан утлары» журналы редакциясе.**

## Исәнмесез, кадерле дуслар!

1972 елда беренче һәм соңгы тапкыр Казанда булдым, анда мин «Казан утлары» белән таныштым. Кайткач, журналга бик кыенлык белән генә язылдым (еракта яшн идек). Менә шул вакыттан бирле ул, көтеп алган кунактай, ай саен килеп тора.

Басылган материалларның барысын да укый алмыйм. Шулай да журнал килгән көнне аны җентекләп карап чыгам: нинди рәсемнәр бар, кемнәрнен әсәрләре басылган, тышлыгы ничек бизәлгән, кемнәр бизәгән, редколлегиядә нинди үзгәрешләр бар, тиражы күпме, хаталарны кемнәр төзәткән? Гадәттә, культура тормышындагы яңалыкларны укып чыгам (хәзер ул бүлек бик кызык түгел). Берничә көннән соң журналны тагын алып утырам. Петит белән язылган бүлеген түкми-чәчми укып чыгам. Яңадан әйләнеп кайтканда зур күләмле әсәрләрдән парчалар укыйм, озак итеп шигырьләрне карыйм. Кыскасы, чираттагы саны килгәнче, монысын аркылыга да буйга да «йөреп чыгам». Кайсыбер әсәрләрне башыннан азагына кадәр укыйм.

Табигый ки, бөтен танышкан нәрсәләр белән килешеп бетә алмыйм: кемгәдер ярарга тырышып язылган юллар да бар, чиле-пешле әсәрләр дә очрый, күңелгә ятышсыз язмалар да юк түгел. Инде шул азмы-күпме «кибәкләр»не алып ташласаң, аның астында, алтындай ялтырап, көшел ята.

Менә шул көшелләр өчен чиксез зур рәхмәтемне белдереп, сезгә хат язам. Әдәбиятыбызны вә мәдәни мирасыбызны саклауда, аны үстерүдә, эзлекле рәвештә халкыбызга җиткерүдә «Казан утлары»ның тоткан урыны үзенә бер аерым. Әлеге «кыен» вакытларда да «Казан утлары» ышаныч чаткылары булып кала бирде. Төшенкелеккә бирелми, канатын төшерми, киләчәкне алданрак күрә белеп эшләгән кешеләргә сокланмыйча карау мөмкин түгел. Мәгърифәтчелек эше дә зур булды. Мин үзем журнал аркылы татарлар, аларның тарихы, культурасы, киләчәге турында ару гына мәгълүмат алдым.

## Рәхмәт сезгә, фидакарь хезмәткәрләр!

«Журналны тагын да әйбәтрәк итеп ничек чыгарырга?» — дигән сорау куясыз. Мин белмим. Миңа калса, аның килешмәгән җире юк. Аннан үзегез дә бер урында таптанмыйсыз бит: эзлисез, табасыз, һаман алга атлыйсыз.

Мин үзем журналда нәрсәләр күрергә теләр идем: шул турыда яза алам.

1. «Ата-аналар һәм балалар почмагы». Анда, бәләкәй генә өлешләр белән, балаларга ана теле дәресләре, ә өлкәннәргә — тел өлкәсеннән кайбер белешмәләр (күп сүзләрне дөрес эшләтмибез, җөмләләрне тәртипсез төзибез, тыныш билгеләрен урысларга охшатып куябыз).

2. Олы шәхесләрнең портретлары, аларга өстәмә рәвештә биш кенә юллык аңлатма.

3. Һәрбер санда бер генә бит әдәбият вә мәдәни мирас җәүһәрләреннән өлгеләр (оныкларыбыз белән бергә укыр идек). Монда күпме байлык, нинди көчле катлам — Дәрдемәнд, Ш. Бабич, Һ. Такташ, Г. Тукай турында әйтеп торасы да юк; Г. Кутуй, Х. Туфан, М. Җәлил, С. Сәйдәш, Р. Ваһапов, Р. Яхин һәм башка дистәләгән, йөзләгән милләттәшләребез...

4. Гарәп хәрефләре белән басылган бер генә шигырь, чирек кенә бит проза (хәзерге әдипләрдән), болары — хәрефләр истән чыкмасын өчен...

Мин беләм, бу — мәшәкатьле эш, өстәмә чыгымнар да таләп итә. Шулай да...

Бервакыт Һ. Такташның кечерәк формат белән басылган китабын сатып алдым. Мәскәүдән апам килгәч, аңа күрсәттем. Ул «Мокамай»ны укып жылады. Нинди юллар шулкадәр тәэсир итте икән? Шигырьне тагын бер кат укып чыктым — башыннан азагына кадәр көчле язылган. «Хат язсам да хәзер соңга калдым, укымассың минем хатымны...» — дигән юллар хәтердә уелып калды. Күпме әрнү, үкенеч, сагыш сизелә аларда! «Гасырлар һәм минутлар»ны укыдым — ул мине тетрәндерде.

Без бит шундый әсәрләрнең дөньяда барлыгын да белми үстек, балаларыбыз да бу өлкәдә надан калды, инде нәүбәт оныкларыбызга житте. Әйе, алар урысларның олы шагыйре О. Мандельштамны, башкорт халкының кабатланмас әдибе М. Кәримне беләләр. Ә хрустальдай чиста Х. Туфанны ишеткәннәре бармы икән?..

Туган тел турында уйлануларымны да язармын әле...

Мин гомерем буена шигъриятькә гашыйк булып, шигъри юллардан илһамланып, көч алып яшәдем. Шуның өчен хатымны да «шигырь» белән тәмамлыйм.

Минем күңелемдә бер жыр туган иде,
Сүзләренә көе бәйләнеп.
Жырлый алмый калдым... Әллә шуңа микән,
Ул жыр кайтты тагын әйләнеп.

Ләкин бик соң инде — аны жырлар өчен
Тик берәүгә олы сер итеп:
Дәрт учагы сүнгән, үткән яшьлек кайтмас
Йөрәктәге бозны эретеп.

Әллә жырлыйм микән алсу таңда,
Ишеткәннәр отып алсынмы?
Әллә жырланмаган жырым булып
Хыялымда торып калсынмы?

Тормышыгызда бәхет, эшегездә уңыш теләп:

**Ү. ХӘЛИЛ,**
Өфе каласы.

## ТР ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ СЕССИЯСЕНДӘ

5—6 июль көннәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чираттагы сессиясе булып үтте. Анда күп кенә мөһим мәсьәләләр каралды.

Сессиядә ТР Дәүләт Советының парламент контроле комитеты турындагы Закон проекты тикшерелде һәм кабул ителде. Парламент хакимиятнең вәкиллекле һәм башкарма органнары хезмәткәрләрен яңа һөнәргә өйрәтү, аларның квалификацияләрен күтәрү буенча Дәүләт Советы каршында республика курсларының вакытлы положениесен раслады, курсларның җитәкчесен билгеләде.

ТР Дәүләт Советы Чувашстан Республикасы Дәүләт Советының кызыклы башлангычын — Россия Федерациясенең «Дәүләт пенсияләре турындагы Законы»ның 12 нче маддәсенә үзгәрешләр кертү турындагы инициативасын хуплады. Чөнки күрше республика парламенты авыл хуҗалыгында кимендә 20 ел тракторчы-машинист булып эшләүчеләрне пенсиягә 55 яшьтән, 20 ел сыер савучы булып эшләгән хатын-кызларны 50 яшьтән пенсиягә җибәрүне тәкъдим итә.

Республикада «Татарстанның атказанган җир эшләрен оештыручы» дигән мактаулы исем булдырылды һәм әлеге сессиядә аның положениесе расланды.

Сессия эшендә Коми Республикасы парламентарийлары делегациясе катнашты. Ике республика парламентлары арасында үзара хезмәттәшлек килешүенә кул куелды.

## РОССИЯ ИЛЧЕЛӘРЕ — ТАТАРСТАНДА

Казанда Россия Тышкы эшләр министрлыгы делегациясе вәкилләре булып китте. Аның составында гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчеләр В. Кузнецов (Төркия), П. Стегний (Кувейт), А. Алексеев (Пакыстан), Б. Головин (Уругвай), В. Земский (Грузия) һ. б. бар иде.

Делегацияне Татарстан Республикасы Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин кабул итте.

Очрашу барышында җөмһүриятебезнең тышкы икътисади эшчәнлеге, башка дәүләтләр белән үзара мөнәсәбәтләре турында сөйләшү, фикер алышу булды.

## ЗЫЯЛЫЛАР МӘНФӘГАТЬЛӘРЕН КАЙГЫРТЫП

Июль башында Мәскәүдә Татар интеллектуаль милек агентлыгы (ТАИС) һәм Россия авторлык җәмгыяте (РАО) арасында үзара хезмәттәшлек итү турындагы килешүгә кул куелды.

РАО һәм ТАИС үз компетенцияләре чикләрендә Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы территорияләрендә зыялыларның авторлык хокукларын яклау буенча тиешле шартлар тудыру турында йөкләмә алдылар.

## ПРОФСОЮЗ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ КИҢӘШӘ

6—7 июльдә Казандагы Хезмәт сараенда БДБ илләрендәге профсоюз берләшмәләре җитәкчеләренең киңәшмә-семинары үткәрелде. Аны профсоюзларның Гомумфедерациясе, Россиянең Бәйсез профсоюзлар федерациясе һәм Татарстан профсоюзлары федерациясе оештырган иде. Семинар-киңәшмәдә «Хезмәт ияләренең социаль-икътисади мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү буенча профсоюзларның дәүләт органнары белән элемтәдә торуы турында» дигән темага олы сөйләшү булды.

## РЕКТОРЛАР КАЗАНГА ҖЫЕЛДЫ

Мәркәзебездә 21—23 июнь көннәрендә Евразия университетлары Ассоциациясенең VI корылтае эшләде. Иң өлкән уку йортларыннан саналучы Казан университетына Россиянең һәм БДБ илләренең 47 университеты ректоры килгән иде.

Корылтайда югары уку йортлары арасында үзара мәгълүматлар алмашу, белгечләр хәзерләүдә һәм фундаменталь тикшеренүләр өлкәсендә көчләрне берләштерү, фән һәм мәгариф өлкәсендә кадрларга бердәм аттестация бирү, белгечләрнең әзерлеген күтәрү системасын тагын да камилләштерү турында эшлекле сөйләшү булды, җитди чаралар билгеләнде.

## ЯҢА ВӘКИЛЛЕК

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевның 1995 ел, 3 июль Указы нигезендә, Рөстәм Садри Татарстан Республикасының Австралия Берлегендәге тулы вәкаләтле вәкиле итеп билгеләнде (Вәкиллек Аделаида шәһәрендә урнаша).

Р. Садри — 1945 елда туган, татар, югары белемле. Ул — Аделаида университетын, Яңа Көньяк Уэльс университетының менеджмент буенча Австралия югары менеджмент мәктәбен тәмамлаган, лингвистика һәм халыкара мөнәсәбәтләр бакалавры, бизнес-администрация магистры. Рөстәм әфәнде татар, урыс, инглиз, алман, төрек, кытай телләрен белә. Ул, Австралиянең Татар ассоциациясе президенты сыйфатында, күп мәртәбәләр Татарстан Республикасының суверенлыгын як-

лап мөрәҗәгать белән чыккан, чыгышлар ясаган күренекле шәхес.

## ЯЗУЧЫ—МИНИСТР

Татарстан Республикасы Президентының 1995 ел, 3 июль Указы белән, тагын бер милләттәшебез — күренекле эшкуар һәм Язучылар берлеге әгъзасы, 41 яшьлек Рәшит Ахунов Татарстан Республикасы тышкы икътисади элемтәләр министры итеп билгеләнде. Моңарчы ул, Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң, Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, «Ләйсән» кооперативы житәкчесе, СССР Иҗат академиясе вице-президенты, «Халыкара коммерция берлеге» генераль директоры булып эшләгән иде.

Р. Ахунов — Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов һәм әдибә Гөлшаһидә ханымның улы. Аның тәрҗемәсендә татар язучыларының кайбер әсәрләре рус телендә дөнья күрде, киң яңгыраш тапты.

## ШАГЫЙРЬЛӘР БӘЙГЕСЕНӘ ХӘЗЕРЛЕК

Мәскәүдә, әдәбиятчыларның үзәк йортында, «Шагыйрьләр глобусы» берләшмәсенең чираттагы утырышы булып үтте. Берләшмә рәисе Виктор Урин үзенең чыгышында төп игътибарны шушы елның августында Нью-Йоркта узачак «Шагыйрьләр турниры»на юнәлтте һәм аңа хәзерлек мәсьәләләренә киң тукталды.

Әлеге бәйрәмгә багышлап күләмле махсус шигъри җыентык чыгару да күздә тотыла. Кичәдә катнашкан шагыйрь Әхмәт Саттарга Татарстан шагыйрьләре иҗатыннан әлеге җыентыкка әсәрләр сайлау эше йөкләнде.

## СЕБЕРДӘ — «ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ»

11—18 июнь көннәрендә Иркутск шәһәрендә «Татар мәдәнияте көннәре» булып узды. Анда Казаннан Татарстан мәдәният министрлыгына караган Республика халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре фәнни-методик үзәге хезмәткәре Илгиз Кадыйров һәм «Мирас» ансамбле катнашты.

## ӘДӘБИ—МУЗЫКАЛЬ ОЧРАШУЛАР

Күренекле шагыйрь, әдип һәм драматург — Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт бүләге лауреаты Фәнис Яруллин, хәләл җефете Нурсөя ханым белән туган ягы Баулыда, Кызыл Яр авылында булып, якташлары белән очрашты. Нефтьчеләрнең М. Җәлил исемендәге мәдәният йортында, аның үзенчәлекле тормыш юлына һәм киң колачлы иҗатына багышлап, әдәби-музыкаль кичә үткәрелде.

Район хакимияте башлыгы Н. Зарипов атаклы якташы Ф. Яруллинга һәм аның ышанычлы таянычы булган хатынына, баулылар исеменнән кайнар рәхмәт белдереп, кыйммәтле бүләк тапшырды.

* * *

Журналыбызның бүлек мөдире — танылган шагыйрь Рәдиф Гаташ Арчада булып, андагы педагогия колледжы студентлары белән очрашу-әңгәмә үткәрде. Ул аларга «Казан утлары» турында сөйләде, сорауларга җаваплар бирде. Очрашуда шулай ук журналның авторы — яшь шагыйрә һәм галимә Чулпан Зариф та катнашып, якташларын үзенең яңа шигырьләре белән таныштырды.

* * *

Ф. Яруллин кебек көчле рухлы шагыйрь — җилкәннәрен тормыш җилләре екканда да бирешмәгән батыр диңгезче Рәниф Шәрипов, республика үзәк шифаханәсендә эшләүче апасы — танылган һәвәскәр җырчы Люция ханым һәм «Казан утлары» журналының бүлек мөдире, шагыйрь һәм публицист Шәһинур Мостафин белән бергә, туып-үскән төбәгендә — Кукмара районының Аман-Оштарма, Березняк авылларында, район үзәгендәге мәктәпләрдә, «Хезмәт даны» газетасы редакциясендә һәм музейда булып, әдәби-музыкаль очрашулар үткәрде. Бирегә алар район мәгариф бүлеге (мөдире — Р. Мансуров, очрашуларны оештыручы — Р. Низаметдинова) чакыруы буенча махсус кайтканнар иде.

## ГАРӘП КИТАПХАНӘСЕ ИШЕКЛӘРЕН АЧА

Гарәп мәдәни үзәге Казандагы 18 нче мәктәп базасында гарәп әдәбияты китапханәсен оештырды. Сүрия Гарәп Республикасы һәм Кувейтның Мәскәүдәге илчелегеннән матур әдәбият китаплары, дәреслекләр, методик ярдәмлекләрнең беренче партиясе килде инде. Китапханә каршында гарәп телен өйрәнү курслары да эшли.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Шәмаил. Авторы Рөстәм. Мөхәммәтҗанов.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле шагыйрь һәм җәмагать эшлеклесе, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин. Аккош күле, 1995 ел.

# ЯҢА КИТАПЛАР




НОВИЦКИЙ А. И. **Бакый Урманче.** *Монографик хезмәт.* Казан: Татарстан китап нәшрияты. 1994 ел. 192 бит.

Китап — татар халкының бөек шәхесләренең берсе Бакый Урманченың тормыш һәм иҗат юлын тасвирлауга багышланган. Моннан биш ел элек, 93 яшендә вафат булган рәссам, нәкыш остасы, график, сынчы Б. Урманче XX гасырның бөтен каршылыкларын, катаклизмнарын үз язмышында кичергән һәм шул кичергәннәрне үзенең әсәрләрендә тасвирлаган. Монографиядә рәссамның тормыш юлы һәм иҗади үсеш баскычлары хронологик эзлекле рәвештә объектив яктыртылган. Китапта байтак фоторепродукцияләр урын алган, һәм шулай ук, ахырда Б. Урманче турында язылган хезмәтләрнең кыскача библиографиясе бирелгән. Бу китап — татар халкының мәдәниятенә хезмәт иткән олуг шәхесләр белән кызыксынган һәркем өчен дә гыйбрәтле һәм файдалы хезмәттер.

МӘҺДИЕВ МӨХӘММӘТ. **Ачы тәҗрибә.** *Истәлекләр.* Казан: Татарстан китап нәшрияты. 1995 ел, 384 бит.




Татар халык язучысының бу китабы истәлек язмалардан гыйбарәт. Китап геройлары — авылдашлар, замандашлар, чордашлар... шул исәптән танылган галимнәр һәм каләмдәшләр. Истәлекләр, Мөхәммәт Мәһдиевкә хас булганча, йөгерек тел белән, мавыктыргыч итеп язылганнар. Егермедән артык бүлектә байтак җир-сулар, ил-халыклар тасвирлана, күпләребезгә мәгълүм булган күп шәхесләр күз алдына килеп баса. Китап автор редакциясендә чыккан, ягъни китапның авторы да, редакторы да үзе — Мөхәммәт Мәһдиев. Аяныч, «Ачы тәҗрибә»нең планлаштырылган дәвамын язып бетерә алмыйча, сөекле әдибебез вакытсыз арабыздан китте.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог